
ISSN 0206—

# КАЗАН УТЛАРЫ

8.1989






**Шагыйрь Һади Такташ**

**(1901—1931)**

А. Тимергалина рәсеме.



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1989

8

(802)

## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Н. ДӘҮЛИ. Сталинга хат. *Повесть* . . . . . 3
М. ХӘБИБУЛЛИН. Илчегә үлем юк. *Роман* . . 25
Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Йөрәк тавышы. *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . . 55
Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Тукайны эзлим. *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . . 60
Ф. БӘЙРӘМОВА. Кыңгырау. *Повесть* . . . 65
Л. ШАКИРҖАНОВА. Шәрык шагыйренә ияреп. *Шигырьләр* . . . . . . . . . . 101
И. ӘХСӘНОВ. Ике шигырь . . . . . . . . 105
Ж. РӘХИМОВ. Ярсу. *Хикәя* . . . . . . . . 107
Р. ХАФИЗОВА. Зөләйханың сәгать чылбыры. *Хикәя* . . . . . . . . . . . . . . 113
Ф. ЯРУЛЛИН. Иске йорт истәлеге. *Хикәя* . . 120

ПУБЛИЦИСТИКА

Ю. АЛАЕВ. Күңелләргә күпер салучы . . . 127
И. ЗАРИПОВ. Сигезенче кое . . . . . . . 132
Д. ТАБАЧНИК. Генштабның үзендә . . . . 136

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Н. ХАНЗАФАРОВ. Вакыт иләге — вак иләк... 142

С. СҮНЧӘЛӘЙНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

З. РӘМИЕВ. Вакыт җитәр, кояш чыгар! . . . 148

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. ӘГЪЗАМОВ. Тормышның үзеннән . . . . 152
Җ. ЗӘЙНУЛЛИН. Борынгы дуслык эзләреннән . 155

ИЛЕБЕЗ ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘРЕ ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ТУРЫНДА

В. ВАСИЛЕВСКИЙ. Көмеш дага . . . . . 158

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Р. ӘМИРХАНОВ. Дәреслекләребезнең тирән тамыры . . . . . . . . . . . . . . . 162

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

ТАТАР ХАЛЫК МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

Р. ГЫЙЛӘҖЕВ. **Сорнай** . . . . . . . . . 173
**Укучы сүзе** . . . . . . . . . . . . 175

БЕЗГӘ ЧИТ ИЛЛӘРДӘН ЯЗАЛАР

Г. ВӘЛИЕВА. **Казанны сагыну** . . . . . . 180

КОТЛЫЙБЫЗ

**Яхъя Халитовка 60 яшь** . . . . . . . . . 161

ЮМОР ҺӘМ САТИРА

Ә. СИНУГЫЛ. **Адәм әүлиясе.** *Шигырьләр* . . 181
В. МОНАСЫЙПОВ. **Тантана. Бурыч. Шикаять.** *Хикәяләр* . . . . . . . . . . . . 184
БАТУЛЛА. **Нотыкчы.** *Хикәя* . . . . . . . 186

**Мәдәният тормышы көндәлеге** . . . . . . 190

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . 192


## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Повесть Н. ДАУЛИ «Письмо Сталину»; окончание романа М. ХАБИБУЛЛИНА «Послу нет смерти»; повесть Ф. БАЙРАМОВОЙ «Колокол»; рассказы З. РАХИМОВА, Р. ХАФИЗОВОЙ, Ф. ЯРУЛЛИНА.
Стихи Ф. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ, Роб. АХМЕТЗЯНОВА, Л. ШАКИРЗЯНОВОЙ, И. АХСАНОВА.
«Публицистика»: очерки Ю. АЛАЕВА, И. ЗАРИПОВА, Д. ТАБАЧНИКА.
«Литературная критика»: статья Н. ХАНЗАФАРОВА «Проверка временем».
«Библиография»: рецензии на книги А. Хасанова; Б. Касыймова и А. Каттабекова; Дж. Тарджеманова.
В номере отмечаются 100-летие поэта С. Сунчалай и 60-летие переводчика Я. Халитова.
«К истории культуры»: статья Р. АМИРХАНОВА об истоках татарских учебников.
«Татарские музыкальные инструменты»: Р. ГИЛЯЗЕВ. «Сорнай».
«Нам пишут из-за рубежа». Г. ВАЛИЕВА. «Тоска по Казани».
«Юмор-сатира». Стихи А. СИНУГЫЛА. Рассказы В. МОНАСЫПОВА и Р. БАТУЛЛЫ.
Дневник культурный жизни.
На наших обложках: золотошвейный нагрудник. Вид внешних стен Казанского Кремля. Репродукция с картины английского художника XIX века Э. Турнерелли.


*Баш редактор*
РЕНАТ ХАРИС
*Редколлегия*
ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙПОВ
*(җаваплы секретарь)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек редакторы)*
РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН
МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек редакторы)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН



Безнен адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.



*Бүлек редакторлары* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин
*Редакторлар* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов
*Техредакция:* Р. Вафина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Р. Сөләйманова

Производствога бирелде 31.05.1989 ел. Басарга кул куелды 31.07.1989 ел. ПФ 05271. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 77049. Заказ Б 250. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.


С «Казан утлары», 1989 ел.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

# Нәби Дәүли

# СТАЛИНГА ХАТ

ПОВЕСТЬ



Туган якларга кайтып барышым. Мин инде атна буе юлда. Башта пароходта йөздем. Аннан соң самолетта очтым. Ә менә хәзер җәяү генә атлыйм.

Кулымда әллә ни авыр йөгем дә юк. Аркамда — солдат биштәре, ә солдат капчыгы бер вакытта да авыр булмый. Чөнки аңа салган әйберләр дә шул кадәр генә.

Өстемдә — телогрейка. Ул инде ала-кола булып беткән, ләкин тузмаган, бары майлаган күн шикелле ялтырап тора. Шәп исем кушканнар аңа: тәнҗылыткыч... Исеме җисеменә бик тә туры килә. Тагын да дөресрәк итеп әйтсәң — Россиянең универсаль киеме ул. Аны үтә салкын якларда да, мәңге җәй булып торган җирләрдә дә бик рәхәтләнеп кияләр. Чөнки ул — кышын өшетми, эсседә тирләтми. Ул кемгә дә килешә. Аның әле тагын бер хикмәте бар: телогрейка кигән кешеләр берберсе белән бик тиз танышып китәләр. Язмышлары тарта, күрәсең. Мәсәлән, мин үзем, телогрейка кигән кешене күрсәм, аны кайдадыр очраткан шикелле булам. Йә лагерьда бергә булганбыз төсле, йә бер камерада сыңар тәмәке төпчеген бүлешә-бүлешә тартканбыз кебек...

Аякларымда кирза итек. Минем шикелле сугылган, кагылган кешегә үзе бер дәрәҗә шикеллерәк ул итекне киеп йөрү! Түземле затлар, үзең белән бергә картаялар...

Мин менә шулай уйлана-уйлана бара торам. Көн аяз. Җәй үзенең яшел келәмен кырлар өстенә җәеп салган. Иген басуларында аксыл дулкыннар йөгерешә. Арышлар инде серкә очыра башлаган. Алардан ниндидер хуш ис бөркелә. Күңелдә дәрт кузгала. Рәхәт!

Гаҗәп, мин бу якларны әле яңа гына, әле менә хәзер генә күрәм төсле. Бу җирләргә әле тәүге кабат кына аяк бастым шикелле. Ә бит мин нәкъ менә шушы якларда туып үскәнмен. Әйтерең бармы, туган җирләремне танымас булып калганмын.

Кызык, әнә баш өстемдә генә тургай җилпенә. Челтер-челтер иттереп юл буена көмеш тәңкәләр сибә диярсең. Мин аңа исем китеп карыйм. Әнә шул кошчыкны минем әле беркайчан да күргәнем юк иде шикелле.

Әнә, юл читләрендә аллы-гөлле чәчәкләр тирбәлә. Алар шулай миңа:

---

*Нәби ДӘҮЛИ (1910) — шагыйрь һәм прозаик, күп кенә шигырь китаплары, «Яшәү белән үлем арасында», «Җимерелгән бастион» һәм башка проза әсәрләре авторы. 1989 елның май аенда вафат булды.*

— Исәнме, якташ, исәнме! — дип баш ияләр сыман. Әллә таныйлармы? Бәлки, чыннан да, таныйлардыр. Ни әйтсәң дә, мин аларга — үз кеше.

Кайчандыр мин биредән узган идем ләбаса. Ул чакларда сезне ничек күрмәдем соң, чәчәкләр! Ничек күрмәдем? Ваемсыз булганмын шул, ваемсыз. Чөнки ул вакытта әле чынлап кайгыра да, шатлана да белмәгәнмен. Әле минем йөрәгемне мәхәббәт сызлатмаган. Миңа әле диңгез тубыктан гына булган...

Нигә болай сагышланам әле мин? Каян килде миңа бу хисләр? Беләм, шулай булмый хәле юк. Мин бит иректә хәзер, иректә! Әнә теге чәчәкләр сыман, кояш нурларына коенам. Әнә теге тургай шикелле очам кебек. «Мин иректә, мин а-за-ат!»— дип кычкырасым килә. Нишләргә соң хәзер миңа? Нишләргә? Әллә бер кочак итеп чәчәкләр җыяргамы? Ярый, җыярмын. Ә кемгә бирермен аларны? Кемгә? Андый кешене әле эзләп табасым бар. Бәлки, бервакыт ул мине үзе очратыр. Шуңа кадәр калсын әле бу чәчәкләр үз дөньяларында, калсын. Көтсеннәр, без бервакыт икәү килербез бирегә...

Әллә җырлап җибәрергәме? Чыннан да, нигә җырламаска? Кем мине тыя? Мин ирекле кеше хәзер! Уйлар агылып килә тора. Күпме генә яшәдем әле мин бу җиһанда? Күпме генә? Санарлык та түгел, бик аз әле, бик аз. Ә маңгаема кемдер нәрсәдер сызгалап өлгерде сыман. Беләм, җыерчыклар төште маңгаема. Җыерчыклар.

Көзгегә караган саен, башымда ак чәчләрем арта бара шикелле. Беләм, һәрбер ак чәчнең үз «тарихы» бар. Мине караңгы камерага китереп япкан көнне иң беренче чәч бөртегем агарып киткәндер. Аннан соң «Син — дошман» дигән, нахак сүз ишеткәч, икенче бөртек чәчем сулып калгандыр. Аннары лагерьда бозлы җир казыганда, караңгы, шыксыз баракларда ачлы-туклы килеш чак-чак кына җан асраганда, конвоирларның зәһәр йөзләрен күргән саен, башыма чал төшә баргандыр. Әмма һәрчак тешләремне кысып, телемне тыеп түздем, бер генә дә еламадым.

Ә менә шатлыкка түзеп булмый икән, юк, булмый! Менә хәзер минем күзләремнән тозлы тамчылар бер-бер артлы ташып чыгалар да битемне чылаталар. Әйе, мин елыйм, шатлыктан елыйм. Туган авылыма кайтып барам ич, туган авылыма! Мин иректә!

Алга атлыйм. Артка таба әйләнеп карарга да куркам. Минем арттан конвоир да атлап килә сыман. Гадәткә кереп язган бу хәл, бәлки, мине әле гомер буе газаплар.

Мин барам. Кояш инде кичкә авышты. Инде җил дә иелеп кенә исә. Үләннәр арасына кача-поса йөри сыман. Әнә, алда тагын ниндидер бер авыл каршыга калкып чыкты. Миңа бүген шул авылда кунып чыгарга туры килер инде.

Әмма бу минем өчен шактый кыен эш. Әле узган көнне дә, шулай бер кич кунып чыгар өчен, бусага саен үтенеп йөри-йөри алҗып беткән идем. Хәзер авыл халкы ят кешене үз өенә кертергә әллә ни ашкынып тормый. Исем китә, заманында безнең татарлар юлчыны якты йөз белән каршылап, түрләренә утыртып кунак итәләр иде бит. Ә хәзер, әнә, күрмәмешкә салышалар. Күп очракта ишек тә ачмыйлар, сөйләшмиләр дә. Сизелә, алар куркуга сабышкан. Аларны ниндидер шикләнү биләп алган. Шулай булмый хәле юк. Кем белән генә сөйләшсәң дә, «халык дошманы» дигән сүзләр телгә керми калмый. Ә син кем? Бәлки, сиңа яхшылык итәм, дип, үзең тозакка төшәрсең. Юк, агайне, юлыңда бул...

Менә мин бу авылга да килеп кердем. Авыл башындагы беренче йортка якынлашырга да өлгермәдем, капка астыннан бер бик усал эт атылып чыкты да котырынып өрә башлады. Мин, тукталып, хуҗаны көтәм. Юк, хуҗа йөз күрсәтмәде. Ул үзе урынына, әнә, этен җибәргән: бар, «сөйләш» әле шул килмешәк белән, дигәндер инде...

Күрше йортка уздым. Ишек төбенә килеп, акрен генә дөбердәттем. «Кем бар, нәрсә кирәк?»— дип тә сорап тормадылар.

— Кунарга чит кеше кертмибез,— дигән бер бик калын тавыш кына ишетелде.— Гаепләштән булмасын, агайне, өйдә сырхау бар, вәт шул...

Сырхау бар өйгә мин үзем дә кермәс идем, билгеле. Әмма бу сүзләрне мин һаман ишетә киләм. Төшендем, халык хәзер әнә ничек кенә алдашырга күнегеп җиткән. Килешми дә бит, нишләмәк кирәк, заманы шундый — кеше кешедән курка.

Инде кич якынлашып килә. Караңгы төшкәнче миңа каядыр кереп урнашырга кирәк иң. Ашыга-ашыга тагын бер йортка сугылдым. Монда да эш барып чыкмады. Ишекне кагып та өлгермәдем, бер карчык тәрәзә ачып:

— Ир затларны кертмибез, биредә кыз-хатыннар гына яши,— диде.— Авыл советына барып карагыз, ярдәм итәрләр, шәт...

Мин нәрсәдер әйтмәкче идем дә, тәрәзә ябылды, пәрдә төште.

Авыл советына барырга кирәклеген мин үзем дә белә идем инде. Әйтүләренә караганда, хәзер авылларда бик җитди тәртип куйганнар: кем генә, каян гына килсә дә, иң элек авыл советына барып күренергә тиеш. Анда, документларны тикшергәч кенә, фатирга урнаштыралар. Моның өчен әле чират та билгеләгәннәр. Кая кушсалар, шунда кунарга барасың...

Әле кичә генә мин кунып чыккан авылда да нәкъ шулай эшләгәннәр иде. Авыл советында мине тикшерә-тикшерә ялангач калдыра яздылар. Шунда бик таза бер хәрби кеше (район үзәгеннән килгән булса кирәк), минем паспортымны алып, күзләрен чекерәйтеп карады-карады да:

— Значит, «тегеннән» кайтып киләсең икән, егетем,— дип, йөзен җыерды.

— Әйе, «шуннан»...

Башкалар, бәлки, бу «тегеннән» дигән сүзне бик үк төшенеп тә җитмәгәннәрдер. Әмма хәрби кеше белән без бик тиз «уртак тел» таптык. Без бербеебезне таныдык дияргә була. Мин аны лагерьда күргән идем шикелле.

Бу хәлгә минем әллә ни исем китмәде. Хәзер мондый хәрби кешеләр кайда гына буталмыйлар. Хәтта алар мәет җирләгәндә зиратта да булалар. Әмма бу хәрби кеше паспортыма карап кына да минем «чит элемент» икәнлегемне ничек белеп алды? Бу мине чиктән тыш гаҗәпләндерде. Димәк, минем паспортта бары тик органнар гына белә торган ниндидер яшерен билге бар.

Коелып төштем. Мине лагерьдан азат иттеләр итүен, ләкин миңа бер «койрык» та тагып җибәргәннәр икән бит. Бу инде миңа гомерлек тамга. Мин — «чит элемент». Кая барсам да, кая керсәм дә, үземнән сорап тормаслар. Паспортымны гына ачып карарлар. Димәк, миңа тормыш бусагасы төбендә гел хәерче кебек кенә басып торырга туры киләчәк. Менә бу минутта минем тагын бер бөртек чәчем агаргандыр, бәлки... Ә иптәш Сталин: «Атасы өчен улы җавап тотмый»,— дигән иде. Уйла, уйлама — бу берничек тә аңлашылмый. Минем лагерьдан азат ителүем юлбашчының әнә шул сүзләрен гамәлгә ашыру нияте белән булды лабаса. Мин хәзер, үземне иректә дисәм дә, барыбер «тамгалы» кеше икәнмен. Дөресрәге, ирекгәге тоткын.

Менә хәзер дә миңа авыл советына барырга кушалар. Ә минем кабат-кабат үзем турында сөйли-сөйли йөрәк авырттырырга бер генә дә теләгем юк.

Менә тагын бер йорт каршына килеп туктадым. Карандым. Бу өй башка өйләрдән бер ягы белән дә аерылмый иде. Урам якта гадәти ике тәрәзә. Каршыда яртылаш корый язган каен. Аның аклы-каралы кәүсәсе ямалып беткән иске бишмәткә охшый. Бу килеш ул әнә шул тәрәзәләр алдына килеп тукталган хәерче кебегрәк иде.

Йорт капкасы бер якка авышкан. Койма какшаган, такталары таралышып беткән. Йортка керим дисәң, кыйшайган такталар аралыгыннан да бик иркен узарга мөмкин иде.

Җилкапкага килеп чак кына кагылуым булды, капка шыгырдап ачылып китте. Кердем, ишек янына барып бастым, дөбердәттем. Ишеттем, ишек катында кемдер кыштырдады.

— Кем бар анда? — диде бер хатын калтыранган тавыш белән.— Кем бар?

— Мине советтан сездә кунып чыгарга җибәргәннәр иде. Бер генә тәнгә...

Бераз тынлык булып торды. Шул арада мин:

— Бик ерак яклардан кайтып киләм,— дип ялвардым.— Юлчы мин, туган авылыма кайтып барам...

Җавап булмады. Мин тагын ашыга-ашыга әйтә куйдым:

— Бушка түгел, кирәгеннән дә арттырып түләрмен...

Миңа әле тагын бераз көтәргә туры килде. Хуҗа кыштыр-кыштыр китеп барды. Менә тәрәзә капкачлары ярыгыннан ут шәүләсе чагылып китте.

Әкрен генә ишек ачылды. Җилкәсенә шәл салган баягы хатын болдырга чыгып басты. Сүзсез генә буй-сынымны күзәтте, йөземә карады. Шикләнә, күрәсең. Минем өстемдәге киемем дә әллә ни шәптән түгел. Сакал-мыекны да инде атна буе диярлек кырган юк.

— Мине авыл советында тикшерделәр инде, документларымны да карадылар,— дидем.— Курыкмагыз, мин угры-карак түгел...

— Курыксам, ишекне дә ачмаган булыр идем,— диде хатын.— Әйдәгез, түргә узыгыз. Совет кушкач, тыңламый хәлем юк. Чират җиткәндер, күрәсең. Югыйсә, мин теләсә кемне өемә аяк та бастырмыйм. Ялгыз мин, тол хатын дисәм дә ярыйдыр, шәт. Ике бала белән яшәгән булам шунда...

Мин алдадым, билгеле. Дөресрәге, кыек атып, туры тидердем. Ояласы түгел икән. Авыл советына барган булсам да, чират буенча мине барыбер шушы йортка җибәргән булырлар иде.

Як-ягыма карана-карана өйгә кердем. Кинәт үзем дә куркынып, артка чигенә яздым. Чәчләре маңгаена тузып төшкән бер кыз бала, күзләрендә ут чаткылары ялтыратып, мич башыннан миңа карап тора иде. Шул арада бер малай башы да күренеп алды.

Әниләре әйтте:

— Сез генә биредә кирәк идегез,— диде, мич буена эленгән чаршауны тартып куйды.— Тик кенә ятыгыз, төшеп йөрисе түгел...

Мин, җилкәмнән юл капчыгын сала-сала, бүлмәне күздән кичереп чыктым. Түрдәге стенада пыяла өлгедә, лампа яктысында ялтырап торган Сталин рәсемен күреп алдым. Дөресрәге, шул өлгедән Сталин мине үзе дә күзәтеп тора кебек иде. Үзем дә сизмәстән, бил каешымны рәтләп, тартыбрак куйдым. Өс киемнәремне сыпырып җибәрдем, ычкынган төймәләремне каптырдым.

Күренә, бу өйдә бөек юлбашчыны бик яратып, олылап ихтирам итәләр икән. Рәсем өлгесенә як-яклап чиккән сөлгеләр элеп куелган. Түбәнгәрәк, Сталинның нәкъ күкрәк турысына, бик матур, кып-кызыл кәгазь чәчәкләр кадаганнар. Ул чәчәкләрне әле хәзер генә бакчадан өзеп алып кергәннәр диярсең.

Хуҗа хатын, мич алдына барып, самавыр кабызып җибәрде. Ә мин уңайсызланып кына:

— Сезнең исемегез ничек соң? — дип сорадым.— Апа дисәм, бик яшь күренәсез, сеңлем дип әйтсәм дә бик үк туры килмәс бугай.

— Кайдан килгән сеңел булыйм, ди. Сез, бәлки, үзегез миңа энедер әле. Мине гади генә итеп Кадерия дисәгез, бик дөрес булыр...

— Ә мин Газиз исемле. Урыслар Гази Шакирович диләр...

Мич башындагы балалар, чаршауны күтәреп, башларын суза-суза, тагын бу якка караштылар.

— Әй, сез,— диде әнкәләре,— тукраннар, арткарак китеп ятыгыз, кара син аларны, ояла да белмиләр!..

— Ачуланмагыз аларны, кунак абыйларын күрергә телиләрдер,— дидем мин.— Сабыйлар шундый инде, тынгысыз җаннар.

Кадерия эндәшмәде. Ул әле казан тирәсендә кайнаша иде. Сизендем, хуҗа хатын үзен ничектер оялган шикеллерәк тота. «Бу юлчыны нәрсә белән сыйларга соң инде?»— дип борчыладыр ул, мескен. Үзем дә күрәм ләбаса, өйдә шып-шыр.

— Хафаланмагыз,— дидем мин, үзем биштәремне чишәргә керештем.— Миндә кайбер нәрсәләр бар. Менә чәй, рәхим итеп алыгыз, менә шикәр комы. Сездән кайнар самавыр суы да бик җитеп торыр. Менә икмәк...

Кадерия кинәт куркынып, тиз-тиз атлап яныма килде. Колагыма гына пышылдап әйтте:

— Икмәгегезне күрсәтә күрмәгез! — диде.— Зинһар өчен, үтенәм...

Гаҗәпләндем:

— Ни өчен, нәрсә булды? — дим. Бу бер дә көтелмәгән хәл иде.

— Без,— диде Кадерия, яшьле күзләре белән миңа карап,— инде бик күптәннән бирле үлән икмәге ашап яшибез...

— Соң шулай булгач, сез инде чын икмәкне сагынып беткәнсездер. Әйдәгез, мин сезне сыйлыйм әле. Рәхим итегез...

— Анысы дөрес, чын икмәкне ашау түгел, күптән инде кулга тотып та караганыбыз юк. Әмма хәзер безгә чын икмәк ярамый. Юк-юк, ярамый, биштәрегезгә кире салып куегыз. Соңыннан үзегез дә аңларсыз әле...

Әмма бу сүзләрдән, дөресен генә әйткәндә, мин бернәрсә дә аңламадым. Аптырап, исем китеп калдым...

Балалар инде мич башыннан сикерешеп төшәргә атлыгып торалар иде. Әниләре тагын күреп алды:

— Кара син аларны! Күзләре дүрт булган! Китегез, кит арткарак, йокларга вакыт җиткән ич, иртә белән елап йөдәтерсез...

Кадерия самавырны өстәлгә китереп бастырды, чынаяклар алып килде. Аннан соң, сандыгын ачып, кызыл шакмаклы төргәк чыгарды, чиште. Аннан, кара дисәң — кара түгел, дөресрәге, соры таш шикеллерәк бер нәрсә алып, өстәлгә куйды.

— Менә без нәрсә ашыйбыз,— диде. Үзе, миңа текәлеп карады да, елмайган булды. Янәсе, исең китәме?

Юк, минем исем китмәде. Моның нәрсә икәнен миңа аңлатып торасы түгел. Бу — татар җирләрендә халыкны ач үлемнән коткаручы атаклы «күмәч».

— Без,— диде Кадерия, тагын сүз башлап,— менә шушы ризыкны ашап җан асрыйбыз. Күндек инде аңа. Чын икмәкне бар дип тә белмибез. Балалар да йөз борып тормыйлар. Кимерәләр генә кетердәтеп...

— Ә мин чын икмәк, Казан икмәге куям,— дидем, тагын биштәремә сузылып.

— Үзегез ашагыз, ә балаларга бер генә кабым да бирмәгез. Алар чын икмәкнең тәмен белеп калсалар, бу «күмәч»не кулларына да алмас булырлар. Ә иртәгә мин чын икмәкне каян алырмын? Рәхмәт!

Бу сүзләргә каршы мин нәрсә әйтә ала идем соң? Уйга калып тордым, ә Кадерия тагын әйтә китте:

— Күңелегез тартынмаса, үзегез безнең «күмәч»не авыз итеп карагыз. Шикләнмәгез, аңарда әллә нинди ярамаган нәрсәләр юк. Бәрәңгегә бераз кычыткан оны, бераз алабута орлыгы, тагын бер-ике кашык ярма, арыш кибәге кушылган. Кыскасы, витаминнар оеткысы дисәң дә ярый. Бездә, бу «күмәч»нең җитмеш төрле сырхаудан шифасы бар, дип сөйлиләр.

Без шулай сөйләшеп торган арада, балалар мич башыннан әкрен генә төшеп тә өлгергәннәр. Әниләре аларны яңадан үз ояларына озатмакчы иде дә, мин каршы чыктым:

— Тимәгез, утырсыннар,— дидем.— Сабыйларның кәефе кырылмасын. Миңа да алар белән күңеллерәк булыр...

— Карагыз аны,— диде Кадерия балаларга,— тып-тын гына утырыгыз. Әдәпле генә кыланыгыз. Кунак абыегызны борчымагыз. Ул — юлдан килгән кеше...

Тегеләр, мәче балалары шикелле йомшак кына атлап, өстәл янына килеп чүктеләр. И күзләре лә, күзләре нинди иде аларның!? Йөзеңне көйдереп алырлар төсле. Мондый яшь күзләрне, мондый саф карашларны минем инде күптәннән күргәнем юк иде. Алар, үзләре дә сизмәстән, миңа

ниндидер шатлык бүләк иттеләр.

Әниләре әлеге соры таштан нечкә генә телемнәр кисеп алды да балаларның кулларына тоттырды:

— Тиз-тиз генә кимерегез дә, выж мич башына,— диде.— Төнгә каршы сезгә чәй килешми...

Ә мин балаларның ул телемнәренә шикәр комы сиптем — менә шулай тәмлерәк булыр, дидем.

— Кирәкми, кирәкми,— диеште балалар икесе дә бер тавыштан. Үзләре шул ук минутта телем өстендәге шикәр комын идәнгә себереп төшерделәр.

— Тоздан туеп беттек инде,— диде кыз бала. Малай да йөзен чытты. Бик кирәге бар иде, янәсе, каян килгән яхшы абый. Тоз белән сыйламакчы...

— Күрәсезме,— диде Кадерия.— Ни шикәрең аларга, ни тозың...

— Карап карыйк әле,— дидем мин, чыннан да, оныткannар микән? Үзем, бал кашыгы белән шикәр комын эләктереп, боларның авызларына тидереп алдым. Күзләре балкып китте, йөзләренә нур инде. Алар бу юлы кодрәт бирә торган дару каптылар сыман. Шунда ук, икесе дә идәндә мүкәләшеп, шикәр комын бармаклары белән берәм-берәм эләктереп, авызларына каба тордылар.

Бер-берсен төрткәләп көлешәләр. Әнә шул кечкенә генә шикәр бөртеге дә нәниләрне тиңсез шатландырды. Бу минутларда әниләренең дә йөзе яктырды. Әмма күзләре моңлы иде аның. Ул күзләрдә сагыш бар. Моны беренче күрүемдә үк шәйләгән идем инде.

Мин янадан балаларның телемнәренә шикәр комы сиптем:

— Инде барыгыз, тыныч кына йоклагыз,— дидем. Алар карышмадылар. Шунда кыз бала әйтте:

— Әни, идәнне иртәгә үзем себерермен,— диде.

— Сезгә дигән сезнеке булыр,— диде Кадерия.— Монда сезгә «эш» көн буена җитәрлек.

Кадерия минем алдыма да, үз алдына да чәй ясап куйды.

— Эчегез, ашагыз,— диде,— ни бар — шуның белән. Үзе чәйне бер генә тотты да, йөзен җыерды.

— Ни булды? — дидем мин,— әллә минем чаем дә сезгә килешмәдеме? Югыйсә, Кытай якларыннан килгән нәрсә бит ул. Первый сорт...

— Кызык,— диде Кадерия.— Чын чәй эчми торгач, анысыннан да бизәсең икән. Әллә нәрсә шунда, эче дә кебек, тышы дә шикелле. Шулай да исе хуш, күнелне күтәрә. Күптән узган көннәрне искә төшерә...

Мин, бер генә дә тартынмыйча, Кадериянең витаминлы икмәгән чәй белән җебетеп, бик тәмләп кенә ашарга керештем. Юк, әллә ни тәмсез түгел иде. Чыннан да, үзеннән ниндидер үлән исе аңкый. Аз гына телне дә әчеттереп ала. Мин моны, халык икмәге, дип әйтер идем. Халык шундый ул, нинди генә авыр чакларда да яшәр өчен әмәлен таба. Әнә ул нинди икмәк ижат иткән. Ачлыктан котылырга ярап тора. Юк әле, алай гына да түгел, шул «витаминнар оеткысы» бала бишеге янында сакчылык итә. Мәхәббәтне дә үз янәшәсендә тота. Тота гына түгел, яшәтә, кешелек нәселен дәвам иттерә.

Өйдә тынлык. Балалар да үзләренең «патшалыкларында» йоклап киттеләр бугай. Кайдадыр ялгыз чикерткә кычкыра. Әкрен генә сәгать йөри. Мин тыныч кына чәй эчеп утырам. Ә Кадерия миңа текәлеп караган да тынып калган. Күзләреннән мөлдереп яшь коела. Күрдем дә, кинәт минем дә йөрәгем авыртынып китте.

— Нәрсә булды? — дидем.— Нигә елыйсыз?

— Еламый хәлем юк. Нәкъ менә шулай, сез утырган урында, минем ирем дә утыра иде. Аның белән дә шулай сөйләшеп, гәпләшеп чәйләр эчә торган идек.

— Хәзер кайда соң ул?

Кадерия, күз яшьләрен сөртеп алды да, бераз ачуланган төслерәк итеп миңа карады:

— Сез,— диде,— бу сорауны әле минем бусага аша атлап узганда ук бирергә тиеш идегез. Күрәсездер ич, өйдә ир кеше күренми.

— Гафу итегез, Кадерия, мин моны беләм. Дөресрәге, сезнең капкадан кергәндә үк күрдем. «Бу йортның хуҗасы юк икән», дип, үз-үземә әйтеп куйдым.

— Каян белдегез?

— Әнә ич, коймаларыгыз таралышып беткән. Ишегалдыгыз да җыештырылмаган. Ир кеше торган йортта иң элек капка-коймалар тәртиптә була...

— Күзегез очлы икән...

— Шуны белгән килеш,— дидем мин,— бу турыда сүз кузгытырга уңайсызландым. Йөрәгегезне кабат сызлатырга теләмәдем. Гафу итегез.

— Анысы өчен рәхмәт. Әмма минем йөрәгемнең сызламый торган җире калмады инде.

— Кайгыгыз зур, күрәсең...

— Сүз чыккач, әйтмичә дә булмас, ахрысы. Минем ирем инде менә ничәнче елын төрмәдә уздыра. Кайда, нинди җирдә? Үзем дә белмим. Сорасам да әйтмиләр...

Кадерия тагын чәй яңартты.

— Әчегез,— диде,— эчегез. Бәрәңгегә дә житешегез. Анысын сатып аласы түгел. Үзебезнең бакчада үсә. Ярый әле табигать дигән шәфкатьле анабыз бар. Берсен бирмәсә, берсен бирә. Югыйсә барыбыз да кырылып беткән булыр идек...

— Әйе шул,— дидем мин,— бердәнбер таянычыбыз — бәрәңге. Бөтен дөньяны туендыра...

— Сыерым да бар иде, сатарга туры килде. Авырга төшә. Хәзер миңа колхоздан печән түгел, салам да бирмиләр. Үз кешеләребезгә дә житми, диләр.

— Сез колхоз кешесе түгелмени?

— Колхозныкы да бит, үз кеше түгел. Халык дошманының хатыны мин. Әнә, мәктәптә кызыма дәфтәр дә сатмаганнар, «Мәкәрҗәдән әтиең җибәрер»,— дип көләләр икән. Ул, мескенем, гел елап кайта.

Кадерия, шулай сөйләшә-сөйләшә, савыт-сабаларны өстәлдән җыештырып алып, үз урыннарына куйды, минем каршыма ук килеп утырды. Йөземә карады, кулларыма да күз төшерде.

— Карагыз әле,— диде.— Сезнең фамилиягез миңа таныш кебегрәк тоела. Сез язучы түгелме? Хәтерем ялгышмаса, сезнең нindидер бер китабыгызны да укыган идем шикелле. Әле бик яшь чагымда. Кәсебегезне яшермисездер бит?..

Бу сүзләр минем инде тынып калган хисләремне кузгатып җибәрделәр. Мин бераз каушадым да, шикләнебрәк тә калдым. Бигрәк тә Кадериянең: «Кәсебегезне яшермисездер бит,»— дип, күзләремә үтә карап биргән соравы уйга салды.

Мин бу өйдә тыныч кына төн кунармын да, иртә белән юлга чыгып китәрмен дип кенә өметләнгән идем. Ә хәзер бирedә әнә нинди сорауга да җавап бирергә тиешмен.

Кадерия дөрес әйтә. Мин, чыннан да, әле институтта укыган вакытымда ук, шигырьләр китабы язып чыгарган идем. Әнә, ул китапны бу ерак авылда да укыган кеше бар икән. Башка вакытта булса, шатланып туймас идем. Язучы белән укучы очрашканда дуслар кавышкан төсле була бит.

Әмма бу юлы мин, Кадерия әйтмешли, «үз кәсебемне» яшерергә тиеш идем. Бу хакта сөйли китсәм, Кадерия, бәлки, шикләнеп, куркып калыр, әллә нәрсәләр уйлап бетерер.

Хәзер бит шундый заман: кешеләр кеше сүзеннән карактан, бандиттан, кеше үтерүчедән дә битәр ныграк куркалар. Туганнарыннан, дусларыннан шикләнәләр. Сүз әйтү — иң куркынычлы эш. Нинди генә кайгың булса да, эчеңдә тот. Ян, көй — төтенең чыгарма, эндәшмә. Серләреңне иң якын кешеңә дә чәпчемә, соңыннан үкенерсең.

Әнә бит, төрмәләргә ябылган язучыларны да «халык дошманы» дип атыйлар. Алай гына түгел, шпионнар, илгә хыянәтчеләр, капитализм ялчылары дип тә әйтәләр иде аларны. Язучы дигән исем куркынычлы сүзгә әйләнеп бара иде. Хәтта язучылар үзләре дә бер-берсен очратканда күрмәмешкә салышалар, берсе урамның бу ягыннан, икенчесе каршы яктан узып йөриләр. Чит күзләрдән сакланалар, янәсе.

Миңа да, бәлки, бу юлы телемне тезгендә тоту яхшырак булыр. Әмма Кадерия соравын читләтеп кенә узып булмый. Әнә ул, йөземә караган килеш, җавап көтә.

Җавапны уйлап чыгардым, билгеле. Башымны читкәрәк борып: «Ул, сез укыган китап башка берәүнеке булгандыр, бер төсле фамилияле язучылар гел очрый тора,— дидем. Һәм тагын әйттем:

— Мин укытучы булырга теләгән идем. Барып чыкмады, институттан кудылар...

Моннан соң Кадерия: «Ни өчен кудылар?»— дип сорарга тиеш иде кебек. Ә бу сорау мине бик авыр хәлдә калдырачак...

Ләкин Кадерия сорамады. Хәтта, ишетмәгән кебегрәк, уздырып җибәрде. Тик ахырда гына:

— Укымышлы кеше икәнсез,— диде.— Ярый әле мин сезне ишек төбеннән үк борып җибәрмәгәнмен. Сез миңа бик кирәк кеше булып чыктыгыз бит әле...

— Нигә?

— Йомышым бар.

— Нинди йомыш?

— Бик матур итеп кенә, күңелгә кererлек, җайлы итеп кенә иптәш Сталинга хат язасы иде. Әнә бит, күпме каракларны, спекулянтларны, хәтта дезертирларны да, төрмәләрдән чыгарып, өйләренә кайтарып җибәрә торалар. Ә минем ирем әле һаман кайдадыр җәфа чигә, картаеп беткәндер инде, мескенем.

— Моңа кадәр язганыгыз булмадымыни?

— Булмаган кая, яздым, кабат-кабат яздым, башка кешеләрдән дә яздырып карадым. Бер генә дә җавап бирмәделәр. Казанга барып, төрмә ишекләренә дә төртелгән чакларым булды. Анда бит баш сыярлык тишек аша гына сөйләшәләр. Шуннан миңа да әйтә тордылар: «Ирегез исән-сау, күчтәнәчләрегезне алмыйбыз»,— диләр дә, тишекне шалт иттереп ябып куялар.

Кадерия, түрдәге сандыктан бер дәфтәр чыгарып, өстәлгә китереп куйды.

— Менә сезгә кәгазь,— диде,— языгыз, зинһар өчен, сез, бәлки килештерә төшәрсез. Әлегә кадәр язган хатларымны Мәскәүдә бик яратып җиткермәделәр, күрәсең. Берсен әле татарча да сырлап җибәргән идем. Бер бик явыз татар кулына эләккәндер дә, мөгаен, әрәм булгандыр.

Мин, дәфтәрне ачып алдыма куйдым да, тагын уйга бирелдем. Чыннан да, мондый мөһим хатны — Бөек юлбашчыга, халыкларның иң-иң якын дустына, кешелек дөньясын бәхетле киләчәккә җитәкләп баручы иптәш Сталинга дигән хатны ничек башлап китәргә? Бәлки аны иптәш Сталин үзе укымас та әле. Әмма, барыбер, аңа якын кешеләрнең берсе укырга тиеш булачак. Менә шул кешенең күңелен йомшатырлык итеп язасы иде.

— Сезгә, иптәш Сталин, бер татар авылыннан, бер татар хатыны хат язган,— дисен иде ул кеше.— Ул татар хатынының кайгысы бик зур,— дисен иде.— Аңа ничек кенә булса да ярдәм күрсәтәсе иде,— дип тә әйтсен. Белмәссең, бәлки, иптәш Сталин кулына каләмен алыр да, «Хәзер үк, һич көттермичә, бу татар хатынының ирен төрмәдән азат итәргә»,— дип, хат читенә шытырдатып язып та куяр...

Мин шулай уйланып торган арада, Кадерия сандыгыннан бер дистә газета алып килеп, алдыма җәеп салды.

— Әллә менә шулардан үрнәк алыбрак язасызмы? — диде.— Монда бигрәк тә килештереп сырлаганнар...

Мин газеталарның әле берсен, әле икенчесен карый башладым. Иптәш Сталинга кемнәр генә хат язмаган? Укып кына чыгарлык түгел иде. Бер үк газетада бер-ике, хәтта өчәр хат басылган. Заводлар, колхозлар исеменнән иптәш Сталинга шатлыклы телеграммалар өзелмәгән. Барысында да хезмәт фронтында бөек җиңүләр турында әйтелгән. Хәтта бер колхоз яки әллә кайдагы бер совхоз, тавык кетәклеге салса да, «Бөек уңышларга ирештек», дип, тизрәк рапорт бирергә ашыккан.

Дөньяның атаклы язучылары, күренекле әдипләре, шагыйрьләре иптәш Сталинга шигырьләр багышлый, поэмалар, романнар яза. Хәтта үз имзасын да куя белмәгән бәетчеләр газетада бөек юлбашчыга җыр белән хат язмый калмаган.

Минем алда җәйрәп яткан газеталарда да әнә шушы хатлар. Алар үрнәгендә иптәш Сталинга хәтта шәхси хатны да язарга мөмкин. Әмма минем эш башка. Миңа бит «халык дошманы» хатыны исеменнән язарга кирәк. Четерекле эш.

— Йә, башлыйбызмы? — диде Кадерия, бераз тынлыктан соң.— Озак уйлансаң, эшнең кадере китә...

Сизәм, Кадерия ашыга. Мин язган хат һич җавапсыз калмас кебек тоела аңа. Бу хәсрәтле кешенең хәлен аңлыйм, әлбәттә. Миңа, чыннан да, бик җитди эш кушыла бит. Мондый чакта уйламыйча гына ярамый. Хатка җавап көтә-көтә, бу мескен хатын елап күзләрен бетермәсен иде. Уйлап кына язсаң, бәлки, хат хуҗасына барып ирешер...

— Ярый, башлыйбыз,— дидем дә, язып киттем.

«Безнең иң якын дусыбыз, Бөек юлбашчыбыз, безне Ленин юлы белән бәхетле киләчәккә алып баручыбыз, мәңге сүнмәс кояшыбыз иптәш Сталин!..»

Хатның бу беренче юлларын Кадериягә укып күрсәттем:

— Шулай килешәме? — дидем.

— Бигрәк тә әйбәт чыккан!

Кадериянең йөзе яктырды. Керфек очларына энҗеләр тезелеште сыман. Мин бу хатынны менә хәзер генә күреп алдым кебек. Йөзенең ябыклыгы аңа ниндидер ямь бирә төсле. Күз карашлары уйлы, карадың исә, үзең дә уйга каласың.

— Инде,— диде ул,— миннән сүз башлыйбыз.

— Ничек?

— Мин сөйләрмен, ә сез килештереп яза барыгыз. Беренче кат кына түгел бу зарлануларым. Җылауларым аннан да күбрәк булды. Нишлим соң, кая барыйм? Иптәш Сталинга язмыйча хәлем юк. Ул бит безнең бердәнбер яклаучыбыз. Шундый хәсрәткә төшкән татар хатынын кызганмый калмас...

Мин бу сүзләрне дә хатка тиешле булганча язып чыктым, укып күрсәттем. Күрәм, Кадерия хатның башланышы белән бик риза.

— Хәзер инде тыңлап торыгыз, Газиз Шакирович. Мин сөйли барырмын, ә сез кирәклесен генә яза барыгыз...

— Килештек.

Кадерия сөйләп китте:

— Минем иремне, ягъни Гыйльфан Мансуровны, тәк кенә торганнан, бер дә көтмәгәндә генә кулга алдылар... Әмма, икмәк тотып әйтәм, минем иремнең тырнак очы кадәр дә гаебе юк...

Кадерия кинәт йотлыккан шикелле булды, сүзеннән тукталып, миңа текәлеп карады.

— Сез нигә болай сәерләндегез әле? Йөзегез дә ничектер үзгәреп китте.

— Юк, болай гына,— дидем мин,— болай гына. Борчылмагыз...

Әмма бу минутта минем хәлем «болай гына» түгел иде шул. Гыйльфан Мансуров дигәч тә, кинәт сискәнеп куйдым. Ул кешене мин беләм ләбаса. Әйе-әйе, беләм. Шикләнер урын юк. Шулай да, бу хакта хәзергә дәшми торырга карар иттем.

— Минем ирем,— дип дәвам итте Кадерия,— иптәш Сталинны үлеп ярата иде. Иптәш Сталин белмидер әле, ирем аны утта чатырдап янудан саклап калды. Әнә,— Кадерия стенадагы рәсемгә күрсәтте,— иптәш Сталин моңа үзе шаһит...

— Туктагыз,— дидем мин Кадериягә,—нәрсә сөйлисез? Иптәш Сталин Мәскәүдә, Кремльдә утыра, ә сезнең ирегез аны уттан саклап калган? Бу бит уйдырма! Хатны болай язарга ярамый...

Ә Кадерия бер дә хафаланмыйча гына әйтте:

— Языгыз, яз,— диде.— Бер генә дә алдамыйм, бик дөресен сөйлим... Безнең авылда,— диде ул,— кечкенә генә клуб бар иде. Менә бер төнне шул клубка ут капты. Авылда шау-шу купты. Минем ирем дә, йокысыннан сикереп торып, аннан-моннан гына киенде дә шунда йөгерде. Ул килеп житкәндә клуб инде дөрләп яна икән. Ирем, аны-моны карамый, шул утлы упкынга кереп китмәкче булган. Аны тотып алганнар.

— Кая барасың, юләр,— дигәннәр,— әллә синең дә янып бетәсең киләме? — дип орыша башлаганнар. Ирем:

— Анда иптәш Сталинның портреты янып бетәчәк! — дип кычкыра-кычкыра, боларның кулыннан тартылып ычкынган да, ут эченә ташланган.

Тирә-яктагы кешеләр::

— Бетте бу, харап булды,— дип, нишләргә дә белми аптырап калганнар. Ә минем ирем шул ут эченнән иптәш Сталинның портретын үз гәүдәсе белән каплап алып чыккан. Дөрес, үзе дә шактый янган-көйгән иде. Аның каравы, иптәш Сталинның бер генә жиренә дә ут тимәгән. Әнә, шул рәсем инде ул. Ирем, аны өйгә алып кайтып, шулай бизәкләп элеп куйды. Шул көннән башлап, ирем үзен: «Мин — сталинчы»,— дип әйтә торган булды. Иртә белән эшкә киткәндә рәсемгә карый-карый кул болгый. Янәсе, хуш иптәш Сталин, мин эшкә киттем, ди иде кебек. Эштән кайткач та, аның белән күрешкән-сөйләшкән кебек итә...

Без икебез дә, иптәш Сталин рәсеменә карап, тынып калдык. Сталин да безгә карый төсле. Кадериянең бу сүзләреннән соң Бөек юлбашчы кинәт кенә телгә килер дә:

— Рәхмәт,— дип әйтер иде шикелле.

— Моны хатка язмыйча булмас,— дидем мин.— Сезнең ирегез тиңсез батырлык күрсәткән...

— Аны авыл кешеләре дә «батыр Гыйльфан» дип атый торганнар иде. Район газетасында рәсемен дә басып чыгардылар. Мактап та яздылар...

Чыннан да, бу мине кызыксындырды. Менә мин кем өенә килеп кергәнмен икән.

— Ул газетаны күрергә мөмкин түгелме? — дип сорадым.— Бәлки, хат белән бергә шул газетаны да жибәрергә кирәк булыр?

— Юк шул,— диде Кадерия,— ул газетаны өйне тентүчеләр үзләре белән алып киттеләр... Ә аңынчы безнең өйгә әллә кайлардан пионерлар, комсомоллар төркем-төркем килеп йөриләр иде. Сорашалар, белешәләр: «Абый, сез ничек, бер дә курыкмыйча, иптәш Сталинны уттан алып чыктыгыз?»— дип сөйләттерә-сөйләттерә арытып бетерәләр иде...

Баш өстендә генә янып торган лампа бер сүнеп, бер кабынып китте.

— Әнә,— диде Кадерия,— утларны сүндерәләр. Бездә бит шулай, төн уртасы життеме, утларны басып куялар. Движокның артыкка көче житми. Тимердән булса да, арый, күрәсең.

Кадерия керосин лампасын кабызды. Нәкъ минем алдыма ук китереп куйды:

— Моның яктысы әле яхшырак та. Күзләрне авырттырмый... Кирәк чакта ярап куя. Юкка гына аны «сукыр лампа» диләр...

Аннан соң инде Кадерия тыштан капкачлары ябылган тәрәзәләрне эчке яктан юрган, иске-москы әйберләр белән каплады:

— Ут нуры су кебек ул, ярык-мырыктан да агып чыга,— диде.

Чыннан да, бәлки шулайдыр. Өй эче бераз яктырып китте.

Юк, моның башка сәбәбе дә бар иде, беләм. Бу кара төндә нәкъ авыл

уртасында утырган өйнең тәрәзәләре ярыкларыннан ялтыраган яктылыкны кем күреп алмас? Күрер дә, халык дошманы өендә әле һаман ут яна, дип, мыштым гына күзәтеп, карап китәргә дә җаен табар. «Дошман хатыны тик кенә тормый икән шул»,— дип, авызыннан гайбәт очырып җибәрер. Кадерия әнә шуннан курка иде.

Мин инде хатны шактый гына яздым. Әмма тагын дәвам итәсе бар иде әле. Кадериянең сөйләвен көттем. Ул яңадан чәй ясады.

— Бу һаман үз ирен мактый, дип әйтерсез, бәлки. Андый кешене мактамаска да мөмкин түгел шул. Ничек әле, егет кешегә житмеш төрле һөнәр дә аз, диләрме? Менә минем ирем дә шул житмеш төрле һөнәр белгән егет иде. Авылга килгән беренче тракторны да ул иярләде. Комбайнга да беренче булып күтәрелде. Балта тотса — кулында балтасы уйнап кына тора иде. Боларны болай гына әйтүем, бәлки, хатка язып та тормассыз...

— Сүз барышында, бәлки, ярап куяр,— дидем мин.— Эш кешесен иптәш Сталин аерата ихтирам итә дип сөйлиләр. Мондый эшлекле, уңган хезмәтчене төрмәгә япканнары өчен Бөек юлбашчы гафу итмәс...

— Мин дә шулай уйлыйм,— диде Кадерия. Сталин рәсеменә карап-карап алды.— Бөек юлбашчы гафу итмәс аларны. Кая керергә тишек тапмас ул нәләтләр, алар иремнең кискән тырнак очына да тормыйлар...

Әлбәттә, Кадерия бераз кызып алды. Аның йөрәге кузгалды, күрәсең. Күзләрендә ачу чагылды. Йөзе бер кызарды, бер агарды. Аннан соң, нәрсәнедер исенә төшергән шикелле, уйланып торды да, әйтеп куйды:

— Сез, зинһар өчен, бу сүзләрне хатка кыстыра күрмәгез. Бик каты әйтеп ташладым бугай, үзәгем өзгәләнә шул, яндыра, көйдерә...

— Бу кадәресен генә аңлыйм, борчылмагыз. Мин ишетмәде дип белегез. Ачу килгәндә тел шулай чыгымланып куя инде ул.

Бер-беребезгә карашып көлешкән булдык. Әмма бу шатланып көлү түгел иде. Кеше бит кайчак кайгыдан да көлә... Кадерия сүзен дәвам итте:

— Колхозчыларның беренче съездына иремне делегат итеп сайладылар. Беләсезме, ул Мәскәүдән бер кочак китаплар төяп кайтты. Съездда аларга иптәш Сталин исеменнән тагын төрле-төрле бүләкләр дә биргәннәр икән. Иремә безнең илдә әле яңа гына эшләнә башлаган бик матур радио эләккән. Ул шуңа бик шат иде. Кемнәр белән генә очрашса да, үзенең башкалада нәрсә күргәннәрен, кайда булганнарын сөйли иде. «Мин иптәш Сталинны күрү бәхетенә ирештем, гомер буе онытасым юк,— ди иде.— Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинга рәхмәт, ул безне бәхетле итте, безгә кояш бирде, су, икмәк бирде. Яшәсен безнең атабыз — иптәш Сталин!» — дип кабат-кабат әйтә торган иде.

Кадерия үзе дә бу сүзләрне шактый күтәренке тавыш белән әйтте. Әллә шул тавышка сискәнепме, мич башында кыз баланың «Әтием...» дип нидер сөйләнеп куйганы ишетелде.

Кадерия мич башына каранып алды:

— Төш күрәләр, ахрысы, мескеннәрем,— дип, авыр уфтанып куйды.— Алар, шулай төн уртасында уянышып, миннән әтиләрен таптыралар. Елашалар. Ә мин аларга нәрсә әйтә алам соң? Башта «Тиздән кайтып житәр»,— дип ышандыра тордым. Аннан соң, «Бер-ике атнадан»,— ди идем. Соңрак, «Киләсе елда әтиегез кайтып төшәр»,— дип әйтә башладым. Әтиләреннән хәбәр дә, хат та юк. Хәзер инде мин бер сүз дә эндәшмим. Балаларымны һаман саен алдарга көчем житми. Алар инде еламыйлар да, сорамыйлар да, ышанмыйлар да...

Кадерия йөзеннән күз яшьләрен сөрткән саен, алар күбрәк агыла төсле. Әйе, күз яшьләре кешенең авыр кичерешләрен, сагышларын, ә кайчакта шатлыкларын да дөнья алдына чыгаралар.

Мин хәзер үзем дә бу бәхетсез ана белән бергә елыйм шикелле. Күз яшьләрем генә күренми, ә җаным сулкылдый. Минем дә йөрәгем сызлый: минем дә «халык дошманы» дип аталган дусларым исемә төшә. Исәннәрме, әллә дөнья куйганнармы?

Юк, бу хатны бик җитди язарга кирәк. Сүзләрнең дә күңелгә үтеп керә торганнарын гына сайлап алырга. Чыннан да, бу хат кемнең дә булса, бәлки, җанын кузгатыр. Бәлки, кем дә булса укыр да уйланыр. «Нигә гаепсез кешеләр һәлак була? Каян чыкты бу афәт?» — дип, Үзәк Комитетта яки Верховный Советта «халык дошманнарын» яклап сүз әйтер. Җитди хат бу. Уйлап кына, сүзен-сүзгә китереп кенә язарга кирәк.

Мин шулай уйлана-уйлана яза барам. Бу хат иптәш Сталинның үзенә эләгә калса, аның да йөрәге дерелдәп китсен. «Бу ниткән эш? Хәзер үк тикшерергә, халык намусына тап төшерүчеләрне хәзер үк җавапка тартырга!» — дисен. Бу хатны мин үз исемемнән дә язам шикелле. Бәлки, газапка дучар булган, хаксызга рәнҗетелгән дусларыма да файдасы тияр.

Минем дә җаным көя. Минем бит әле бу өйдә сөйләрлек авыр истәлегем бар. Сөйләргәме? Әллә?..

Гыйльфан Мансуровны ни өчен кулга алганнар? Аңа халык дошманы дип әйтергә кемнең теле барган? Шул турыда да тизрәк беләсем килде минем. Сорарга да өлгермәдем, Кадерия үзе сөйләп китте:

— Иремнең бер генә тамчы да гаебе юк,— диде ул, идән уртасына чыгып басып. Бу хәлдә ул судьялар каршына баскан адвокат шикеллерәк иде.— Аның гаебе юк! Кем-кем, әмма мин үз иремнең һәрбер адымын гына түгел, һәрбер сулышын, йөрәгенең һәрбер тибешен белеп тора идем. Шатлыкны да, кайгыны да без бергә бүлеп яшәдек. Ул яшьтән үк комсомол булды. Партиягә керде. Читтән торып агроном булырга укыды. Игенне фән кушканча үстерми торып, безнең тамаклар туймас, ди иде. Тагын бер генә ел аңа тимәсәләр, ул инде кулына диплом да алган булыр иде. «Ни өчен төрмәгә эләкте?» — дип сорыйсызмы? Әйтәм: Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинны яклаган өчен! Әйе, әйе, иптәш Сталинны яклаган өчен төрмәгә керде ул...

Теләсә кемнең дә җанын дерелдәтерлек иде бу сүзләр. Башка сыймый, берничек тә аңлашылмый иде алар миңа. Кадерия үзе дә бу сүзләрнең бик четерекле икәнен сизенде. Бераз тынып торды да, әйтә куйды:

— Бу турыда сез, зинһар өчен, бик аңлатып кына, сүзен сүзгә килештереп кенә яза күрегез...


— Әйе, ашыгырга ярамас. Җентекләп кенә язарга тырышырмын. Сез дә сак булыгыз, андый-мондый уйдырма була күрмәсен.

— Икмәк тотып ант итә алам. Ирем иптәш Сталинны җаны-тәне белән ярата иде. Һәркөнне, иртә белән йокыдан торгач та, әнә шул рәсемгә карап уйланыр иде: «Хәзер инде иптәш Сталин да йокысыннан уянгандыр,— ди торган иде.— Аның эшләре бит безнеке шикелле генә түгел. Әнә нинди зур ил, ярты дөнья кадәр. Анда күпме җирләр, диңгезләр, урманнар бар. Ничә миллион кеше яши. Барысын да белеп, күреп торырга кирәк. Бәлки, ул безнең авылны да искә төшерәдер. Анда халык ач түгелме, җәберләмиләрме минем игенчеләрне, дип борчыладыр...»

Ирем көннәр буе кырдан кайтып керми иде. Авылдашларны эшкә өнди, киңәш итә, яңа ысул белән иген чәчәргә өйрәтә. Тегеләр ык-мык килеп карыша башласалар, «Иптәш Сталин шулай куша»,— ди дә, тегеләрне каршы сүз әйтмәслек итә.

Бервакыт шулай өйдә чәй эчеп утырганда ул: «Иптәш Сталин булмаса, без ничек яшәр идек? — диде.— Нишләр идек?» Шунда мин аңа шаярган шикеллерәк итеп: «Яшәр идек әле,— дидем.— Ата-бабалар аны белмәгәннәр дә, күрмәгәннәр дә, кырылып бетмәгәннәр ич»... Шул сүзләрем өчен ирем мине кыйнап ташлый язды. «Контрлар сүзен тыкылдыйсың,— диде.— Тагын шулай телеңә салынсаң, әнә, әйберләреңне төенлә дә — выжт минем өйдән! Күземә күренмә! Ә иптәш Сталинга сүз тидермә. Ул булмаса, без инде күптән аякларны сузган булыр идек», ди.

Чыннан да, тормышыбыз җайлы гына бара иде. Эш көненә икмәк тә ул елларда җитәрлек бирелә килде. Яңа өй салып кердек. Ике балабыз туды.



*А. Тимергалина рәсеме.*

— Туктагыз әле, Кадерия,— дидем мин.— Бераз ашыга төштегез бугай. Онытылмасын, мин яза барыйм...

— Әйе шул, чыннан да, сөйлим дә сөйлим. Үземнең дә телем кипшенде. Сез яза торыгыз, ә мин самавырны яңартып җибәрим әле...

Чәй бераз кәефне күтәргәндәй итте. Әмма борчылуым басылмады. Бу йортка кергәндә мин, үз язмышым белән дә очрашырмын, дип һич кенә дә көтмәгән идем. Башына яшьли чал төшкән бу мескен хатынга минем әйтәсе бик авыр сүзләрем бар лабаса. Нигә кердем бу өйгә? Хәзер ничек чыгып китәрмен? Әгәр ул сүзләрне әйтсәм, бирелә көне-төне елашырлар. «Нигә әйттең безгә ул хәбәрне?» — дия-дия, бәлки, мине дә авыр сүз белән телгә алырлар.

— Башлыйк инде,— дидем мин, каләмемне кулыма алып.— Ял итеп алдык бугай.

Кадерия башта, мич башына күтәрелеп, балаларын карап, урынҗирләрен рәтләп төште. Өстәл янына килеп, лампа фитилен күтәрә төште.

— Шулай,— диде ул яңадан сүз башлап,— ирем төннәр буе китаплар актара, укый, яза. Иртә белән миңа сөйли. «Беләсеңме,— ди,— иптәш Сталин, Ленин үлгәч, аның табуты алдында ант тоткан. Без, дигән, Владимир Ильич, син сызган юлдан тайпылмабыз, синең байрак астында алга барырбыз, синең эшләреңне дәвам итәрбез, дигән».

Иремнең сөйләгәннәрен тыңлап, башым күккә тиярлек булып шатлана идем. Көннән-көн аның күзләре күбрәк күрә, дөнья хәлләрен күбрәк төшенә бара кебек иде ул. Сүзләре дә матурлана, тавышы да көр, йөзе дә чибәрләнә төсле иде. Кайчакта шул шатлыгымнан яшерен генә елаган чакларым да булды. Бәхетле мин, бәхетле, ди идем. Безгә бит күп кирәкми иде. Өстәлебездә бер телем икмәк булса, шөкер итә идек.

Юк, мин әле дә бөтенләй бәхетсез түгел. Үзең сөйгән кеше белән бер генә сәгать бергә яшәсәң дә, бәхетнең нәрсә икәнен белеп каласың. Гыйльфан белән аз гына торып калсам да, онытылмаслык булды. Көтәм әле. Ул кайтыр да, шул аерылган бәхетне кабат бергә кушарбыз...

Кадерия, әнә шул бүленеп калган ярты бәхетен эзләгән шикелле, тирә-якка каранды. Нәрсәгә генә күз төшерсә дә, күңеле юанмады, күрәсең. Авыр сызланды. Өйдәге һәрбер нәрсәне — өстәл-урындыкларны, тәрәзә өлгеләрен, хәтта балалар уенчыкларын да аның ире үзе ясаган икән.

Кадерия сүзеннән туктады. Бераз уйланды. Аннан соң, инде суынып беткән чәйне эчеп, хәл алды.

— Беләсезме,— диде,— беркөнне ирем, укыган китабыннан башын күтәрде дә: «Карале, әйт әле,— диде.— Коммунист синеңчә кем?» Ә мин каян белим? Андый сорауга миннән акыллырак кешеләр дә җавап бирә алмас иде әле. Ә ирем, күзләрен миңа текәгән дә, җавап көтә. Үзе матур итеп елмая. Мин ык-мык итебрәк торгач, ул үзе җавабын да әйтеп салды: «Коммунист,— диде ул,— әллә кем түгел, гади кеше. Әмма саф намуслы, тәне дә, җаны да чип-чиста булырга тиеш аның. Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин шикелле. Менә бирелә,— диде ул, китабын миңа күрсәтеп,— менә бирелә бер француз язучысы да «Сталин — бүгенге Ленин» дип язган. Хәтереңә салып, бикләп куй...»

— Туктагыз әле,— дидем мин,— Сталинга шул кадәр бирелгән кешене ни өчен кулга алдылар соң? Гафу итегез, әллә ничегрәк килеп чыга бит. Хатка язсаң да ышанмаслар төсле.

Болай соравымның сәбәбе бар иде, билгеле. Атылганда да мылтык көпшәсенә туп-туры карап: «Яшәсен иптәш Сталин!» дип кычкыра-кычкыра үлгән кешеләр турында мин бит инде белә идем.

Алар шулай үзләренең гаепсезлекләрен тере кешеләргә әйтеп калдырырга теләгәннәрдер, бәлки? Бу сүзләр кайчан да булса иптәш Сталинга ишетелер, дип, соңгы ышанычларын белдергәннәрдер.

Ә менә бу хатның язмышы нинди булыр? Кремль диварлары аша

үтеп, тиешле кеше кулына килеп керерме ул? Әллә кайда да булса югалып калырмы?

— Бая әйткәнемчә,— диде Кадерия, кабат сүзгә керешеп,— без ирем белән тыныч кына яши бирдек. Бер көнне иртә белән минем Гыйльфаным елап уянды. Әле уянгач та бик озак үкседе. Күзләреннән эре-эре тамчылар чәчрәп чыкты.

— Ни булды? — дидем мин аңа.— Ни булды?

— Авыр төш күрдем,— диде ул,— бик авыр төш...

— Ир башың белән төш күреп еларсың икән?! Хатыннарга гына килешә ул,— дип, иремне бераз орышып алмакчы идем. Ә ул әйтте:

— Төше нинди иде бит, белмисең,— диде.

— Нинди иде соң? Сөйлә...

Ирем бераз уйланып ятты. Ул хәтта нигәдер куркынган шикеллерәк тә иде. Мин дә сагаеп калдым.

— Йә, сөйлә инде,— дидем,— сөйлә...

Ирем авыр сулады, ыңгырашкан шикелле итте. Аннан соң, пышылдап кына әйтте:

— Мин төшемдә иптәш Сталинны күрдем,— диде,— иптәш Сталинны!..

— Бик шәп төш ич бу, бик шәп төш, шатланырга кирәк, мондый төшләр теләсә кемгә керми. Ничегрәк күрдең? — дим.

— Сөйләргә дә куркам, бигрәк авыр төш бит. Имештер, мин ниндидер диңгез ярына килеп чыкканмын. Карасам, ни күрәм: ниндидер кара киемле кешеләр иптәш Сталинны, кул-аякларын богаулап, көймәгә яткырып салганнар да, каядыр алып баралар. «Иптәш Сталин, Сталин! — дип кычкырам, имеш.— Сине кая илтәләр?» — дим. Иптәш Сталин ник бер сүз әйтсен. Мин шунда ук елап җибәрдем. Ә теге кара киемле кешеләр авызларын ыржайтып көлешәләр. Шунда берсе әйтә: «Без синең Сталиныңны кара атауга алып барабыз,— ди.— Анда көн дә, төн дә булмый»,— ди. Аңладым, димәк, Бөек юлбашчыны алар зиратка озата баралар. Мин: «Хуш, иптәш Сталин, хуш!» — дип кычкырырга телим, ә тавышым чыкмый. Ярый әле, син мине төртеп уяттың, югыйсә, мин әллә нишләп беткән булыр идем...

— Бер дә куркасы түгел, төшкә ни кермәс,— дидем мин, иремне кочаклап.— Төштә җылаган кеше өндә шатлана, диләр...

Әле дә үкенәм, шунда: «Бу төшеңне беркемгә дә сөйләмә»,— дип кисәтеп куясым калган икән. Ул юләр, шул ук көнне җыелышта, халык алдында шушы төшен сөйләп ташлаган. Соңыннан әйткән:

— Иптәшләр, уяу булыйк, безнең Сталинны дошманнар сагалыйлар. Бу төшемне мин шуңа юрыйм,— дигән.— Шул хакта Мәскәүгә хәбәр итә торыйк. Анда иптәш Сталинны саклаучылар уяу булсыннар. Күз дә йоммасыннар. Әнә, тирә-якта капиталистлар дөньясы мәш килә. Алар безнең иптәш Сталинны хәзер үк гүргә бөтәрләп тыгарлар иде...

Шул чакта өстәл катында утырган авыл советы председателе урыныннан сикереп тора да:

— Провокация бу,— ди,— провокация! Каян килгән уяу кеше! Без исән чакта иптәш Сталинның башыннан бер бөртек чәче дә төшмәс!

— Дөрес, дөрес! — диләр җыенда утыручылар.— Дошман сүзе бу. Төш күргән, имеш. Үзең уйламасаң, төшкә керми ул!

— Правильно! — ди авыл советы председателе. Бармагы белән минем иремә төртеп күрсәтә.— Синең үзеңне иплэп кенә тикшерәсе бар. Иптәш Сталинга син үзең кул күтәрергә теләмисеңме икән әле? Вот вопрос!..

Ирем бу җыеннан каралып, боегып кайтты. Йөзенә карап кына да сизеп алдым. Сорадым — эндәшмәде. Икенче көнне дә өйдә урын таба алмыйча арлы-бирле сугылып йөрде. Өченче көн дә шулай узды. Бу мине шикләндерде. «Юкка түгел бу, юкка түгел»,— ди-ди, мин дә нишләргә белми калдым.

Әберчакны ирем миңа ачулы күзләре белән карады да:

— Синең элеккеге сөйгән ярың минем башымны ашамакчы,— диде.— Бәйләнде бит, «Син үзең дошман»,— ди. Халык алдында хур итте...— Аннан тагын әйтә куйды: — Белдеңме инде,— ди,— синең өчен миннән үч ала ул шулай сөйләнеп. Үч ала...

Кадерия, сөйләвеннән туктап, яшь тулы күзләре белән миңа текәлде. Янәсе, ышанаммы мин аның бу сүзләренә. Ә мин әйттем:

— Эшләр бит тирәнгә китеп бара, сөйләгез, сөйлә,— дидем.— Хатка кирәкле сүзләрне мин язмый калмам. Болай яла ягучыларны судка биреп утлы табага бастырырга кирәк. Тик, шулай да, мин аңламый торам әле. Ни өчен үч ала ул?

— Яшь чагында шул Фәррах исемле бәндә, элеге дә баягы шул авыл башлыгы, минем арттан еллар буе сөйрәлеп йөргән иде. Очраган саен: «Мин сине сөям, сөям»,— дип бәйләнә иде. Клубка барсам, анда көтеп тора, урамга чыксам, бозау кебек, артымнан ияреп килә. Сөймәгән кешеңә якты йөз күрсәтеп буламы соң? Төскә-буйга дисәң, начар сүз әйтерлек түгел иде, югыйсә. Әмма күңелем кабул итмәде. Аннан соң ул мине куркытып та карады. Өегезне яндырам, нәселегезне корытам, дип тә янады. «Теләсәң, хәзер үк күзләремне чокып чыгар, сине күрмәсәм тынычрак яшәрмен»,— дидем мин аңа. Чөнки инде түзәр хәлем калмаган иде. Бу явыз минем хакта берәр гайбәт чыгара күрмәсен, дип, җаным алынып курка идем. Ә минем бәхетем бар иде инде. Медицина курсларында укып, мин инде авылда шәфкать туташы булып эшли идем. Ә йөрәгемдә Гыйльфан исемле егет яши иде. Мәктәптә укыганда ук башланган мәхәббәт иде ул...

Тора-бара яхшы кешеләр ишеттерделәр, Фәррах мине урлап китәргә ниятләнә икән. Ә мин, мыштым гына җыендым да, Гыйльфаныма ябышып чыктым. Фәррахның юлы өзелде.

Бервакыт, инде туйлар узгач, ул мине очратты да: «Ярый-ярый,— диде,— мин моны онытмам». Ә хәзер инде ул, әнә, авыл башлыгы булып алды. Чыннан да, онытмаган икән. Шул еллардан бирле, юха елан шикелле, башына агу җыеп йөргән. Менә хәзер, иремне генә түгел, мине дә чакты ул явыз...

Кадерия авызын яулыгы белән каплады. Калтыранды, йөзе җыерылды. Күзләреннән яшь коелып төште. Ул, балалар куркышып уянмасын дип, тавышсыз гына елый башлады.

Мин аны тыймадым. Тимә, еласын, күз яшьләре белән аның кайгысы да бераз сүрелер, дидем үз-үземә.

Кадерия бераз тынып сулыш алды, яңадан сүзгә кереште:

— Шуннан соң, бервакыт төн уртасында, безнең капка алдына дөбер-шатыр дулап нindидер машина килеп туктады.

Без барыбыз да берьюлы уяныштык. Ул вакытта әле бишектә генә яткан улым башын күтәреп тыпырчынды. Ул да нидер сизенә иде шикелле. Менә ишекне дөбердәттеләр. Ишеттек, элеге шул Фәррах тавыш салды:

— Ачыгыз ишекне, живо! — диде.— Совет вәкилләре килде. Сезнең белән сөйләшергә телиләр. Живо, живо!

Йөрәгем жу итеп китте. Сизендем, яхшыга түгел бу. Кызым итәгемә килеп ябышты. Ишекне ирем ачты. Менә, бәреләсугыла ике ир кеше килеп керде. Үгез шикелле тазалар, башлары чак кына түшәмгә тими.

Авыл башлыгы, элеге шул Фәррах, башта миңа текәлеп күзләрен чекерәйтте. Елмайган булып маташты. Янәсе, туйларыгыз бик матур узган иде дә, менә хәзер, күрәсеңме, эшләр ничек килеп чыкты...

Йөзенә төкерермен дип курыктым, башымны читкә бордым. Ә ул бик кәпрәеп: «Хәзер сездә тентү булачак,— диде.— Мин Совет властеисеменнән катнашам».

Теге кешеләр аны-моны сөйләп тормадылар. Өйнең астын-өскә китереп тентергә керештеләр. Идән астына да төшеп менделәр. Мендәрләрне,

түшәкләрне изгәләп, селкеп карадылар. Шунда берсе: «Халык дошманнары хитрый була, беләбез, не первый раз»,— дип сөйләнә-сөйләнә, Сталин рәсеменә сузыла башлады. Ирем каршы төште:

— Кулларыгыз юылганмы? — диде.— Сез минем өемне тенти бирегез, ә бөек юлбашчыга бармак белән дә кагылырга рөхсәт итмим...

— Анысын инде синнән сорап тормаслар,— диде авыл башлыгы, иремне бер читкә төртеп. Сталин рәсемен сузылып алды, теге кешеләрнең берсенә бирде. Ә тегесе рәсемнең артын каергалап карады. Икенчесе стенага йодрыгы белән суккалады.

— Беләбез,— диде,— халык дошманнары Сталин рәсемен үз түрләренә менә шулай элеп куеп, күз буалар...

Ирем бәс төсле булып агарды:

— Ни сөйлисез? — диде.— Ни сөйлисез? Мин — партия члены...

— Идең...— дип сүз атты авыл башлыгы.— Идең!.. Хәзер инде партиядән колак кактың син!

Ирем тиз генә бирешергә җыенмый иде.

— Әйдәгез, райкомга! — дип җикеренде.— Анда, минем нинди «халык дошманы» икәнлегемне әйтеп, сезгә дә тиешле сабакны укытып чыгарырлар!

Совет вәкилләре дип аталган бу кешеләр корсакларын киерә-киерә киңәштеләр. Шунда берсе әйтте:

— Зачем райкомга? Без сине прямо Казанның үзенә алып китәбез. Киенегез! Живо!

Балаларым нәрсәдер аңлап алдылар шикелле. Икесе дә берьюлы елый башладылар. Кызым әтисенә барып сырышты.

— Мин сине, әтием, беркая да җибәрмим! — диде.— Җибәрмим...

Әтиләре балаларның башларыннан сыйпады, юатырга тырышты:

— Еламагыз, мин бик тиз әйләнеп кайтырмын,— диде. Үзе дә инде еларлык хәлгә килеп җиткән иде.

Шулай да ул тартышты:

— Мин иптәш Сталинның үзенә язачакмын,— диде.— Белеп торыгыз, ул сезне акылга утыртыр әле, менә күрерсез...

Без ирем белән саубуллашып та өлгермәдек, машина тырылдап китеп тә барды. Ә Фәррах, ишек төбенә басты да, өй эчен күзләре белән айкап чыкты. Әмма минем йөземә карарга бу юлы вөҗданы җитмәде. Чыгып барышлый әйтте: «Гы-Пы-У эшне белеп йөртә,— диде.— Йомышың булса, миңа кил»,— дип тә әйтә китте. Беләм, бу аның мине шулай мыскыл итүе иде. Сабыйлар каршында да аның йөзе кызармады...

— Беркөнне ишеттерделәр,— дип дәвам итте Кадерия,— ул явыз, мине санитарлык эшеннән алып, башка урынга күчерергә кирәк, дип сөйләнә икән. Янәсе, дарулар халык дошманының хатыны кулында булырга тиеш түгел. Ул алар белән нәрсә кыландырмас, имеш. Әнә, ди икән, кырга тирес чыгарсын.

Бу хәбәрне ишеткәч, мин аның янына йөгереп барып баш иярмен дип көткәндер. Бәлки, чыннан да, бервакыт аның каршына барырга туры килгән булыр иде. Ни әйтсәң дә, ул бит авыл советы председателе.

Тик башта аның үзенә минем өемә йөгереп килергә туры килде. Хатынын бизгәк тота башлаган. «Тизрәк ярдәм ит»,— дип ялынды Фәррах. Шул чакта да ояла белмәде, мәлгунь. Мин нишлим, тизрәк аларга йөгердем. Үзегез дә беләсез булыр, безнең эштә дус та, дошман да юк. Безнең өчен — кеше теләсә кем булса да — медицина ярдәменә хаклы...

— Сезне язмыш кызганган, күрәсең. Бәладан котылгансыз...

— Үзем дә шулай, дим. Бәлки, ул әле тагын берәр мәкер уйлап табар иде. Әмма беркөнне үзе дә мәтәлде. Районнан кайтып килгәндә, җиккән айгыры дулап китеп, моны юлга ыргытып калдырган. Шунда җан биргән. Исерек булган, дип сөйләгәннәр иде.

Кадерия инде еламый. Юк, елый иде ул. Әмма күз яшьләре эчтә генә, йөрәк кызулыгында кибеп бетә баралар иде, күрәсең.

Хат инде язылып беткән иде. Мин, чәй белән тамагымны чылаттым да, хатны азагына кадәр укып чыктым.

Кадерия бераз уйланып калды.

— Хатны бик каты язмадык микән? — диде.— Иптәш Сталинның йөрәге кинәт кенә авыртып китмәсме бу хәлләрне белгәч! Ул да бит дөнья күргән кеше, Себерләрдә булган, төрмәләрдә яткан...

— Юк,— дидем мин,— тыныч бул, Кадерия, иптәш Сталин нинди генә сынауларга да бирешмәгән. Аның бит фамилиясе дә корыч дигән сүздән алынган. Тап-таза ул.

— Хатның азагына: «Бу хатны чын күңелдән яздым»,— дип өстә. «Әгәр сүзләрем нахак булса, мине җир йотсын»,— дип тә язып куй, ышансын иптәш Сталин. «Бу хатка күз яшьләрем дә тамды»,— дип әйт...

Барысы да Кадерия теләгәнчә булды. Кадерия хатка имзасын салды. Ә мин конвертка адресны да язып куйдым. Хат, тере җан иясе кебек, бу татар хатынының кайгы-зарлары белән конвертка кереп ятты...

Иртә белән мин яңадан юлга чыктым. Кадерия капка төбендә озатып калды. Сүзсез генә кул болгады. Их, ул минем кем икәнлегемне белгән булса, нишләр иде икән, мескенем? Нишләр иде? Белми калды шул, белми калды. Бу шулай кирәк булгандыр дип уйлыйм. Ә мин кем идем соң?

Мин бит үзем дә «халык дошманы» дип аталган кешеләрнең берсе идем. Ләкин мине, Кадерия ире шикелле, машинага утыртып алып китмәделәр. Повестка җибәреп кенә чакыртып алдылар да кайтармадылар.

Җилкәмнән тотып алып, җилтерәтә-җилтерәтә, караңгы камерага кертеп яптылар. Башта «Ни өчен?» дип, тәмам һушсыз калдым. Соңгарак белдем: «гаепләрем» хәтсез күп икән...

Иң әлек мин бер бәйрәм табынында: «Заманалар авыр, еллар ябык, дус-иш кирәк гомер итәргә»,— дип җырлаганмын. Аннан соң бер шигыремдә: «Сандугач моңлы сайрый, йөрәктә хәсрәт кайный»,— дип әйткәнмен.

— Нинди авыр заманалар, нинди яман еллар? — дип сорадылар.

— Бу бит — халык җыры,— дидем мин.— Җырдан сүзне алып ташлап булмый.

Ә ни өчен «Йөрәктә хәсрәт кайный?» — дип сорау куйдылар.

— Дөньяда хәсрәтсез кеше юк, хәсрәтсез йөрәк буш йөрәк ул,— дип җавап бирдем.

— Шулай икән алайса... Җырдан сүзне ташлап булмый икән?..

— Әйе.

— Ә без ташлатырбыз, ничек кенә ташлатырбыз әле! — диделәр.— Икенче юлы телеңне авыз эчендә генә тотарсың...

Аннан соң:

— Синең бабаң кем булган? — дип сорадылар.

— Каян белим? — дидем.— Мин туганда ул инде дөньядан китеп барган...

— Ә без беләбез,— диде тикшерүче.— Без беләбез: синең бабаң авылларда дини китаплар сатып йөргән. Ә дин — агу ул. Моны син үзең дә яхшы беләсең булыр, бывший студент!

— Беләм, билгеле. Дин — агу. Маркс та шулайрак өйрәтә.

— Вот как!? Марксизм белән дә таныш икәнсең! Димәк, сыйнфый көрәш сиңа шулай ук билгеле нәрсә...

— Аз гына...

— Бу безнең эшне җиңеләйтә...

Мин эндәшмәдем. Болар эшне зурдан чамалыйлар. Ишеткәнем бар иде: ГПУ вәкилләре белән телеңә күп салынырга ярамый. Сөйләгән саен, алар сорауларны арттыра гына баралар икән. Шулай да, эти турында сүз чыккач, сорамый кала алмадым:

— Анысы өчен дә мин җаваплымы?

— А что думаешь, син бит аның токымы, шулай булгач, безнең өчен

этиеннең кем булуы да не простой вопрос...

Әйе, минем этинең «гаебе» бар иде шул. Ул хакта мин ишетеп кенә белә идем. Эш болай булган. Колхозлашу вакытында ул бер җыенда:

— Колхоз, бәлки, яхшы нәрсәдер, әмма белмәгән килеш тәртәне сындырып куйсак, бик үк күңелле булмас, агай-энеләр,— дигән.— Теләгәннәр керсеннәр ул колхозга, ә мин сабыр итәм әле. Инде эшләре барып чыга икән, пужалыста, мин — ике аягым-кулым белән колхозныкы. Ә хәзергә атымны да, сыерымны да ул колхоз йортына илтеп бәйлисем юк,— дигән.

Озак та үтмәгән, минем этигә урын тапканнар. Себергә сөргәннәр. Ул бары тик үләр алдыннан гына авылга кайтып егылды.

Мине институттан куып чыгарганда да әнә шул «эшне» фаш иткәннәр иде. Усал ният белән, чыгышымны яшереп йөргәнмен, янәсе. Совет Вузына алдап кергәнмен...

Менә хәзер мине тикшерүче дә әнә шул турыда кабат искә төшереп узды:

— Әнә,— диде,— бармак белән генә тисәң дә, йомгак сүтелә башлый, сразу очы килеп чыга. Так-что сиңа: «Ни өчен мине кулга алдылар?» — дип сорарга да урын калмады. Все ясно!..

Мин, күз яшьләремә буылып, сүзсез калдым. Нindидер кара төндә авыр төш күрәм шикелле. Инде ул төшемнән мин бик озак еллар уяна алмадым.

Төрмәдә озак яткырмадылар.

— Җитәр дәүләт җилкәсен кимереп ятарга,— диделәр.— Без сезне эшләп ашарга өйрәтербез...

Һәм беркөнне минем шикелле «кулак токымнарын», «халык дошманнарын», каракларны, тагын-тагын әллә кемнәрне, картын-яшен бер эшелонга төяделәр дә билгесез тарафка алып киттеләр.

Атна буе бардык. Җир шарының икенче ягына чыгып җитәрдәй булдык. Кайчакларда җанга курку төшә. Әллә безне шулай ерак-ерак алып китеп, беркем дә белмәс-күрмәс урынга илтеп дөмектерергә җыеналармы?

Менә бервакыт килеп җиттек. Ул билгесез тараф дигәннәре «Беломорканал» булып чыкты. Каналның үзе дә юк иде әле, исеме генә билгеләнгән. Аны киләчәктә «Бөек халык төзелеше» дип тә атарлар.

Күрдек, әнә без торасы лагерь. Ул чәнечкеле чыбыклар белән каткат урап алынган. Эчтә озын-озын буйлы тәбәнәк кенә бараклар тезелеп тора. Алар барысы да сап-сары нараттан. Читтән караганда бу, үзенә күрә, агачтан салынган кечкенә генә шәһәрчек кебегрәк иде. Әнә бер морҗадан сузылып-сузылып төтен чыга. Анда, бәлки, безнең өчен аш-су әзерлиләрдер. Юк, биредә дә яшәп була торгандыр әле. Күңелләр бераз тынычланды. Без бит әллә кайда түгел, үз илебездә. Әнә лагерьның капка башына ук, кызылга буялган фанер тактага: «Иптәш Сталин, тыныч бул, без син куйган бурычны вакыттан элек үтәрбез!» дип, зур хәрефләр белән язып куйганнар. Әнә без кемнәр икән: бөек юлбашчы куйган бурычны үтәүчеләр. Шулай булгач, куркасы түгел, безгә әллә ни кыен булмас кебек.

Мин менә шундый уйлар белән лагерь капкасы аша уздым. Беләм, минем янымдагы «дошманнар» да шундыйрак хис кичергәннәрдер. Аларның да йөзләре елмаюлы. Кайберләре, әнә, мәзәкләр дә әйтешеп куялар.

Икенче көнне үк безнең кулларга көрәкләр, ломнар тоттырдылар. Ян-якларыбызга мылтыклы сакчылар куеп, җир казырга йөртә башладылар. Эшләү «премияле» иде. Планны арттырып үтәсәң, икмәк паегын да артыграк аласың. Әмма планны үти алмасаң, үпкәләмә, паегың яртыга ким булыр. Тырышып эшләмисең, димәк.

Без казыган җирне тау итеп өйсәң, Кавказдагы Казбек та ул тау янында «бөҗәк» шикелле генә булып калыр кебек иде. Ә лагерь башлыклары һаман азсыналар. Алар «Беломорканал»ны төзеп бетерү ту-

рында иптәш Сталинга тизрәк рапорт бирергә ашыгалар иде.

Ә без ниндидер җансыз, йөрәксез, телсез, бары тик төсебез, буй сыныбыз белән генә кешегә охшаган исемсез затларга әвереләдек. Баштарак әле туган җирләрне сагынып уфтана идек. Кошлар кебек очып кына китәр идек шикелле. Тора-бара ул сагышлар да инде дулкынландырмый башлады. Хәтта туган җирләребез, туган аналарыбыз, туган йортларыбыз да беркайчан булмаган кебек. Бар белгәнебез шул: иртән торырга да, тезелешеп эшкә барырга, кайтып йокларга да, тагын иртә торып җир актарырга...

Менә шул лагерьда мин Кадериянең ирен, Гыйльфан Мансуровны, очраттым да инде. Сөйләшә торгач, якташлар булып чыктык. Билгеле, дуслашып та киттек. Минем аңа исем китә иде. Ул кайгырмый да, зарланмый да. Эшен җиренә җиткереп башкара. Планны гел арттырып үти. Лагерь башлыклары аны мактыйлар, «Безнең Мансуров — ударник», диләр иде. Ә Гыйльфанның түбәсе күккә тия, шатланып туя алмый.

Бервакытны ул мине үгетләгән дә иде әле.

— Кайгырма, туганкай, безне, бәлки, шулай эшләтеп, ачлы-туклы тотып сыныйлардыр,— дигән иде.— Иптәш Сталинга безнең ышанычыбыз хакмы? Без икейөзле булып кыланмыйбызмы? Партиягә, совет властена чын йөрәктән бирелеп яшибезме? Тел белән бит теләсә нәрсә сөйләп була. Ә биредә көрәк белән, лом белән шул ышанычны күрсәтә белергә тиешбездер. Бу — вакытлы хәл. Түзәргә кирәк. Телне тешләп торырга!

Ә икенче юлы Гыйльфан тагын менә болай да диде:

— Безгә «халык дошманнары» диеп нахак исемне, бәлки, юри генә кушканнардыр. Боларның йөрәкләренә ут салыйк әле, дигәннәрдер. Түзәрләр микән? Ә без әнә түзәбез. Бу бит туган илгә тугрылык! Иптәш Сталин моны күрми калмас. Вакыты җитәр, кемнең кем икәнлеге ачыкланыр. Хәзер бит заманы шундый, Газиз энем...

Очрашкан саен, Гыйльфан мине шулай тынычландырырга тели иде. «Бу яшь егет кайгыга сабышып йөрмәсен»,— дигәндер. Беләм, ул мине кызгана. Мин аңа исеме белән генә дәшсәм дә, ул миңа инде абый булырлык кеше иде.

Аның үз хәле тагын да авыррак. Лагерьда безнең аш-суларыбыз бертигез бирелсә дә, «халык дошманнары»н иң авыр, иң пычрак эшкә йөртәләр, ә каракларны һәм башка вак-төяк «шварьләр»не аларга каршы котыртып үчекләндерәләр иде. Лагерьда гел ызгыш булып тора. Ә «начальствога» шул гына кирәк тә. Алар, тәртип урнаштырабыз дип, таяк очын иң элек «халык дошманнары» җилкәсенә эләктерәләр иде.

Тагын бер шулай сөйләшеп торганда мин Гыйльфанга үземнең чыгышым турында әйттем.

— Мин бит «халык дошманы» түгел, кулак малае,— дидем.

Гыйльфан, исе китеп, миңа озак кына карап торды. Кашларын җыерды, йөзен чытты:

— Шулай ук мени,— дип сузды.— Шулай ук мени?

Сизендем, юкка гына исе китмәде. Аныңча, кулак — «халык дошманы»ннан да хәтәррәк дошман, күрәсең. Ул, үзе дә сизмәстән, миннән бер адым арырак китеп басты.

— Алай булса,— диде,— без икебез ике төрле кешеләр. Син — сыйнфый дошман икәнсең. Авыр хәл. Мин сине бер укымышлы кеше диебрәк чамалаган идем. Ә син — әнә кем!

— Барыбер түгелмени соң?

— Юк, барыбер түгел. Сезнекеләр колхозга каршы сугыш ачтылар. Кулларына «кискән мылтык» алдылар. Караңгы почмактан советка каршы аттылар. Ә без, ярлылар, колхозга оештык. Нәкъ менә шул чакта безнең юллар аерылышты да инде...

— Бирелә бит безнең язмышлар тигез,— дидем мин, каршы сүз башлап.— Синең кулда — көрәк, минем кулда — лом. Кашыкларыбыз да

бер төрле — тимердән.

— Анысы шулай, сүз дә юк. Ләкин моннан соң бик үк аралашып йөрмик әле. Яман күзгә чалынып, яман телгә эләгүебез мөмкин. «Әнә, әшнәләр бер-берсен тапкан», дип, каләм белән билгеләп куярлар.

— Куркасыңмыни?

— Юк, курыкмыйм. Син — сыйнфый дошман, мәнә кайда мәсьәлә...

Шуннан соң мин Гыйльфан Мансуров белән очрашмадым. Ул да мине эзләп килмәде. Мин дә аны күрергә бик ашкынып тормадым...

Бәлки, ул да менә бу көннәрдә туган авылына, үзенең сөекле Кадериясе, балалары янына кайтыр иде. Әмма көтмәгәндә генә зур бәхетсезлеккә дучар булды ул, мескенем.

Бик салкын бер көндә бер төркем «халык дошманнары»н машинага утыртып эшкә алып киттеләр. Кич булды, алар кайтмадылар. Иртә белән белдек, аларның машиналары, юлда ватылып, туктап калган. Нәкъ шуны гына көткән шикелле, көчле буран чыккан. Буран басылыр әле дип көткәннәр. Ә буран дулаган да дулаган. Шунда кайбер тоткыннар:

— Әйдәгез, лагерьга җәяү генә кайтабыз,— дип сакчылардан үтенеп сораганнар. Сакчылар карышкан:

— Не смей, приказ юк! — дигәннәр.

Көткәннәр, көткәннәр дә машинага чүмәкләшеп утырган килеш йоклап киткәннәр, шуннан инде кабат уянмаганнар. Берничә көннән соң аларның катып, агарып беткән гәүдәләрен машинага утын кебек чалыш-чолыш салып алып кайттылар. Шул үле гәүдәләр арасында мин Гыйльфан Мансуровны да танып алдым. Таным алдым да кинәт сулышым буылды. Чөнки бу минутта мин үзем дә туңып калдым сыман.

Лагерьда өч ел вакыт узды. Атаклы «Беломорканал»ны казып, төзеп бетердек. Аннан беренче кораб тантаналы рәвештә узып чыкты. Бу турыда иң элек иптәш Сталинга рапорт бирделәр.

Шул уңай белән лагерьда митинг булды. Онытасым юк, бу бик кызыклы, бик күркәм җыен иде. Шул митингта лагерь башлыгы хөкүмәт карарын укыды. Анда лагерь житәкчеләренә рәхмәт сүзләре әйтелгән иде. Безне дә, әлеге «халык дошманнарын» да, читтә калдырмаганнар. Без үзебезнең тырыш хезмәтебез белән совет гражданнары исеменә лаеклы булганбыз икән. Моннан соң без совет паспортын кулыбызда йөртергә хаклыбыз икән. Син кичә «халык дошманы» идең, бүген — совет гражданины! Мондый шатлыкны әйтеп бирергә телдә сүз юк. Хәтта кайберләребезгә орденнар да, медальләр дә бирделәр. Яңа паспортлар да тоттырдылар. Юлга бераз акча да чыгардылар...

Уйларым яңадан Кадериягә кайта...

Бу узган төнне йокладыммы, йокламадыммы? Дөресрәге, Кадерия өендә мин үземне кая куярга белмәдем. Яңадан лагерь искә төшеп йөдәтте. Чөнки бу мескен хатын да үзенең ике баласы белән лагерьда яши иде шикелле. Тик менә хәзер генә, юлга аяк баскач кына, офыкны балкытып кояш чыккач кына, бу чыклы иртәдә, бу хуш исле иркен кырда мин әле үземне дөньяда яшим дип хис иттем.

Ә Кадерия нишли икән бу сәгатьтә? Ул бит үзенең кайгысы белән, ике нарасые белән ташландык атауда калган төсле. Аның өенә беркем дә килеп китми, ничек яши, ничек гомер итә — беркем дә белми. Хәтта туган-тумачалары да. Куркалар. Болай караганда кеше ирекТә кебек. Әмма — юл ябык. Беркая да китәсе түгел. Телеңә күп салынма. Нәрсә кушсалар, шуны эшлә. Сораулар биреп маташма. Бу нәкъ төрмәдәге шикелле түгелме соң? Бу хәлдә бөтен ил үзенең ата-аналары белән, бала-чагалары белән күләмсез зур лагерьга ябылган төсле. Мин дә хәзер шул лагерьга килеп кердем кебек.

Боегып киттем, адымнарым авырайды. Әнә, алда бер авыл күренә башлады. Әнә, зират урманы кемнедер көтеп тора кебек. И җаныем, бу

минем туган авылым лабаса. Әйе, ул үзе!

Чү, минем авылыммы соң бу? Минем авылыммы? Элегрәк еллардa безнең авылга җитәрәк, башта мәчет манарасы күренә торган иде. Ә хәзер кайда соң ул биек манара? Нәрсә булган аңа, кая киткән ул яммьяшел гөмбәзле, көмеш айлы манара? Ул бит, юлчыларга маяк шикелле, бик ерактан балкып тора иде.

Күңелемә шом төште. Бәлки минем туган нигеземне дә пыран-заран китереп бетергәннәрдер? «Дошман оясының эзе дә калмасын» дигәннәрдер?..

Ә Кадериянең хаты иптәш Сталинга барып җитәрме? Кремль дивар-лары аша үтеп керерме? Без лагерьда андый хатларны Мәскәүгә көн саен диярлек яудырып тора идек. «Товарищу Сталину не до вас», диләр иде лагерь башлыклары. Ә без, барыбер, нинди булса җавап килер әле, дип өметләнә идек. Өмет кешенең җанын җылыта, яшәтә.

Кадерия дә, аның балалары да шул өмет белән яшәсеннәр. Мин аларның кайгыларын үз йөрәгемә салып киттем. Аларга авыр хәбәрне әйтергә телем бармады. Мин моңа хаклы идемме, әллә хаклы түгел идемме? Бу турыда теләсә кем, теләсә ничек уйласын, теләсә нинди хөкем чыгарсын.

Ә Кадерия мине гафу итсен иде...

*1988 ел.*

**Мөсәгыйт Хәбибуллин**

# ИЛЧЕГӘ ҮЛЕМ ЮК

**РОМАН**

31



Кунакка гаскәр белән йөрмиләр. Әйе, кем булса да: ханмы ул, сәүдәгәрме, гади ташчымы, ниһаять. Ә Сәлим хан угланы Хаҗига алты мең азат белән юлга чыкты. Яңа Казан Бөек Каладан ерак түгел, ул ашыкмады, алдан барган багучылары, атна элек җибәрелгән шымчылары аңа хәбәр итә тордылар. Яңа Калада аның гаскәр белән юлга чыгуын берәү дә белми.

«Бик әйбәт, — дип уйлады Сәлим хан. — Белмәүләре яхшы, ләкин хак микән бу хәл?.. Угланы Хаҗи җеп очын яшерә белә. Яңа Калада атасының кешеләре булган кебек, аның да Бөек Калада «күзе» бардыр һәм атасы Сәлим хан гаскәр белән килә дигән хәбәрне әллә кайчан угланга җиткергәннәрдер». Тегесеннән дә, монысыннан да курыкмады Сәлим хан. Ничек килергә тели, шулай килә. Ул олуг хан, ил белән идарә итә, тели — ялгызы чыга юлга, тели — гаскәр белән. Кыскасы, бу мәсьәлә ханны борчымады. Гаскәр алдыннан ул меңбаш Баян баһадирны җибәрде. Сәлим хан арбада барырга булды, әкрен генә аңа да картлык килә иде, бигрәк тә озын юлда атка атланып йөрүләре кыенлаша башлады. Баян баһадир азатлары бер көнлек юлны алдан бара. Алардан һәр ярты көн саен хәбәрче әйләнеп килә һәм алдагы хәлләр турында яңалыкны җиткерә. Сәлим хан аларны тыңламады, бу вазифаны вәзире Камайга йөкләде. Камай исә хәбәрчедән һәммәсен дә тәфсилләп сорашты, барысы хакында да белергә тырышты.

Ибраһим каласына җитәрәк Сәлим хан инеш буенда атларны туктатырга кушты, арбадан төшеп, яшел үләнгә утырып чәй эчте. Гаҗәп хәл, ханбикә күңеленә әллә ниткән коткылар салып җибәрсә дә, хан аңа ышанып җитми иде. Угланы Хаҗи да ул хәтле мөстәкыйльлеккә тормышка омтылмыйдыр, кызы Назлыгөл исә анда юк та юк инде. Ханбикәнең шиге бары тик хатын-кыз хыялы гына. Ә шулай да күңелдә нindидер икеләнеп калу кебек хикмәт бар.

Сәлим хан атларны җигәргә, кузгалырга кушты. Кичкә кадәр аның Ибраһим каласына барып җитәсе килә иде. Анда ишан ук булмаса да, шул чамада даны таралган Ягкуб би бар. Сәлим хан аны күреп белә, аннары Баян баһадиры җиткерде, калага урын карарга барганда вәзире Исхак та Ибраһим каласына туктаган, гаҗәбе шул иде янә, онытгы

*Ахыры. Башы 6, 7 саннарда.*

Гали шул бигә кунакка барган һәм аның кызы белән танышкан икән. Ягкуб бинең кызы матур икән, белекле, укымышлы икән. Ханны би үзе кызыксындыра иде. Ни уйлый икән ул угланы әмир Хаҗи турында?

— Вәзир Камай, калага хәбәрче җибәр, тарханга түгел, кала биенә туктармын, — диде Сәлим хан.

Җансакчылары ханның әмерен үтәргә җыенды, барысының да калага беренче булып барып җитәсе килә иде, бигрәк тә хан сезгә килә, сездә туктый дигән сөенечне беренче булып кала биенә җиткерәселәре килә. Җансакчылар ишеткәннәр иде инде, кала бие Ягкубның күз камашырлык белекле, гүзәл кызы бар икән һәм кияүгә чыгарга теләми икән. Кем белә, хан җансакчысын күргәч, кызның фикере алышынып куюы мөмкин. Өметсез шайтан диләр, хан җансакчылары исә өйләнү һәм гаилә кору өмете белән яши иде, чөнки күзе төшкән кызы булса, Сәлим хан җансакчыларының өйләнүенә каршы килми, киресенчә, үзе башкода булып бара торган иде. Моны, әлбәттә, беренче булып вәзир Камай сизеп алды һәм җансакчылары арасыннан иң шыксыз егетне сайлады.

— Син барасың, менә син, син, атың ничек кенә әле, әйе, Гаптери, — диде.

Хәбәрче җайдак тузан тасмасы калдырып, калага таба чапты. Сәлим хан елмаеп куйды. Ул кисәк кала биенә туктагач, кала тарханының чытык йөзен күз алдына китерде. Тарханнарны ул калаларга үзе атап куймады, вәзиренә йөкләде. Ибраһим каласы тарханын мәрхүм вәзире Исхак билгеләгән иде. Хан аңа гаскәрен кунак итәргә кушар.

Олыгаеп китмәгән булса, кала бие Ягкубны Сәлим хан, һичшиксез, сарайга алыр иде, ләкин хәзер инде картаеп бара һәм ул турыда уйларга соң.

Күр инде кала һаман күренми, ә бит җитәргә тиешләр кебек иде. Бу җирнең ике-чиге бармы икән? Бар, бар. Чулманны чыгасы да, Иделне кичәсе, аннан бер көнлек юл узасы да Сүрә елгасы башлана. Шул булыр Болгарның чиге. Сүрә елгасының аръягына Китан кенәз берничә кирмән салдырды, кирмән саен чиркәү, чиркәү саен епископ. Төзүче кушаматын алса да, Китан кенәзгә җитә алмады Сәлим хан. Ул әнә атасы салып калдырган икенче Ибраһим каласын хәзер Мәкәрҗә диләр, Болгардан тартып алды һәм үзенеке итте. Хәзер анда чиркәү күтәртә икән инде. Әйе, үзе китте, аты-исеме калды Китан кенәзнең. Бүген вәзир Камай әйтүенчә, яшь кенәзләр тәхет бүлешә икән. Бүлешсеннәр, кем генә Владимир тәхетенә утырмасын, Сәлим хан аның белән килешә алыр. Бүләсе бүленеп бетте бугай инде: Иделнең аръягындагы базар каласын бирде, мукшы илтабары Пургасны якларга бармады. Мукшы илтабары хәзер әнә Владимир кенәзләренә йөз тота. Хәерле булсын.

Владимирдә әнә кенәз кенәз белән генә тәхет бүлешми, байлар да баш күтәрә башлаганнар, ди. Әйе, буталчык вакытлар китте. Шушы йөгәнсезлектән файдаланып, Владимиргә яу чапсаң да, ару булыр иде, Ибраһим каласын кире кайтарса, Пургасны аерып алса — шул житкән иде, әмма Сәлим ханның бер дә кузгаласы килми иде, чөнки үз илендә тәртип китеп тора.

Сәлим хан офыкка күз төшереп алды, анда көнбатыш тарафта болытлар куера, яңгыр ява булса кирәк. Олуг елга Идел күренми, тиздән ул да күренер. Көз килергә дә күп калмады, халык икмәкләрне җыйды, амбарларга тутырды, ясакчылар да эшкә кереште. Владимир-Сүздәл якларында корылык икән, сәүдәгәрләр Болгардан икмәк сатып ала башлар һәм, ике-өч бәягә арттырып, Новгород базарына илтеп сатар. Ил ил белән аралашмыйча, сәүдә итмичә тора алмый. Авыл игенчеләре хан казнасына уннан бер өлеш икмәкләрен карусыз бирәләр иде, быел карышучы авыллар да булган икән. Сәлим хан ул авылларны яндырырга, икмәкләрен бер бөртегенә кадәр җыеп алырга, халкын Җаек буйларына куарга боерды. Ә менә Ибраһим тирәсендәге авылларда карышучылар аздыр. Димәк, тархан да, кала бие дә игенчеләр белән аралаша белә.

Ибраһим каласыннан ерак түгел бер авылда (аты Карамалы диделәр бугай) күптән түгел игенчеләр ашлык сатырга теләмәгән. Бу хәлне ишетеп, Сәлим хан кала тарханына ямчы җибәрде. Карамалы халкыннан икеләтә ясак җыярга һәм карышкан кешеләрен Җаек буена сөрергә боерды. Илләә хан кылавызын[1] тархан түгел, кала бие Якуб кабул итә һәм аны, барысы да үтәлер, дип тынычландырып җибәрә. Үзе исә берни дә кылмый. Шул хакта ишетеп, Сәлим хан икенче ямчысын җибәрде. Тикшерергә. Чынлап та, ике тапкыр артык ясак җыелганмы? Җыелган булып чыкты, икмәкне Бөек Калага — хан казнасына кала бие үзе китерде. Аны кабул итүен үтенеп, вәзир Камайга хат язды. Камай Ягкубны кулыннан тотып, хан янына алып керде. Шул нәрсә ачыкланды: ханның ясакчылары ул авылда тиешеннән ике тапкыр артык ашлык җыйганнар икән инде, моның өстенә тагын килгәннәр, ә халык: «Үзебезгә ни кала, ачка үликмени», дип каршы чыга. Әнә шуны Ягкуб авызыннан ишеткәч, Сәлим хан ясак җыючыларны Бөек Калага чакыртып алды, хәлнең асылын тикшерүне баш казыйга тапшырды. Баш казый ике көн дигәндә эшне ачыклап бирде. Ясакчылар ил халкыннан салымны чынлап та артык җыйганнар һәм икмәкне ерак та йөрмичә, сәүдәгәрләргә сатып барганнар икән. Баш казый әлеге икмәкне сатып алган сәүдәгәрләрне дә тапкан, ясакчыларның исемнәрен дә атаган иде. Сәлим хан халыкны рәнҗеткән, ханны алдаган, аллаһы тәгалә алдында язык кылган ике ясакчының башын кистерде, җиде кешене зинданга яптырды һәм өй-каралтыларын гына түгел, хатынын вә бала-чагаларын сатып җибәрергә әмер бирде.

Ханның бу гамәленә шатланып Ибраһим каласы бие Ягкуб бер ай дигәндә генә иленә кайтып китте. Шушы ай эчендә Сәлим хан Ягкуб белән берничә тапкыр очрашты һәм, ышбу кеше чынлап та ишан икән, дигән нәтиҗәгә килде. Хәтта ул аны вәзире итәргә дә уйлаган иде, бары үзенең дә, Ягкубның да картаеп килүләре сәбәпче булды — бу уеннан кире кайтты. Әйе, акыллы вәзир аңа кирәк иде. Шундый чакларда Сәлим хан еш кына Исхакны искә төшерә. Акыллы, төпле кеше иде мәрхүм, тик бер нәрсәдә хата ясады — угланны кала нигезенә күмдерергә дип киңәш бирде. Ата-бабаларыбыз йоласы буенча яңа кала нигезенә хан токымыннан углан күмдермәскә дә мөмкин иде. Сәлим хан әллә нигә ризалык бирде шунда. Томаналык эшедер. Ләкин ул томана булса да, вәзире томана түгел иде ләбаса. Вәзир Исхактагы акыл җиде кешегә җитәрлек иде. Нигә андый киңәш бирде ул аңа? Сәлим хан әле булса аңлап житкерә алганы юк. Болгар дөнья уртасындагы илдер. Шуның өчен монда Багдат, Һират, Сәмәрканд, Кияү-кала, Новгород һәм башка мәркәзләрдән, төрле мәмләкәтләрдән сәүдәгәрләр очратырга була. Якынтирәне инде әйткән дә юк! Владимир белән бер дәүләт кебек яши башладылар сыман, тик менә дин генә читләштерә: икесе ике ярга басып сөйләшәләр. Уртаклык юктыр. Халык икесе ике телдә сөйләшсә дә, бер сыман, ә менә дин, тоткан иманнары... Йә хода, шул иман аркасында хан кызларына өйләнгән кияү кенәзләр Болгарга яу кила башладылар. Югыйсә, әнә Китан кенәзгә ике-өч аршин җир җитте, хәер, ханга да әллә ни күп кирәкми, булганына канәгать булып яшәрлек, ә менә дин әһелләренә... Катлаулы да соң бу дөнья. Бер динне хупламасаң, икенчесе куәт ала, аннары беренчесен кыса башлый, беренчесенә ирек бирер идең, икенчесе зарлана. Зарланып кына калса ярый, чиркәүгә ут сала, епископларны үтерә башлыйлар. Нәкъ шуның белән зур хата кылалар. Югыйсә, дин иркле имандыр. Телисең — муеныңа тәре так, телисең — башыңа чалма ура. Ә инде теге яки бу дин явызлык кыла икән, нишләп халык иркле көнен коллыкка алыштырсын, ди?!

Пәһлеван Мәхмүт Сәлим ханга ел саен хат яза, күккә күтәреп ислам

[1] Кылавыз — юл күрсәтүче.

динен мактый. Хуш, син башка диннәрдән, әйтик, христианлыктан мәҗүсилектән ерак торасың, башка диннәр сиңа карурман, ә Сәлим хан аларны һәр көн күреп тора ич. Ул диннәргә табынган кешеләр дә шул дый ук, әллә ни үзгәрешләре юктыр. Кигән кием генә кешене теге яки бу йола вәкиле итә алмый.

Олуг шәех белә булса кирәк, Сәлим хан соңгы хатында бик нык үпкәләп язды. Әйе, нигә, әйтик качып киткән шәех Игәнәй халыкны христианнарга каршы котыртты? Болгарда төрле дингә табынган кешеләр яши ләбаса. Ашыга нәтиҗә ясарга Пәһлеван Мәхмүт, ашыга. Шәех Игәнәй качу белән олуг шәех Бөек Каладагы хан мәчетенә каенишен җибәрмәкче булды, иллә Сәлим хан тыйнак кына баш тартты, яшь шәехне яңа салынып яткан, әмма инде хан мәчете күтәртелгән Казанга җибәрергә кушты. Пәһләван Мәхмүт каршы килмәде, Сәлим хан теләгәнчә итте, ә Бөек Каладагы мәчеткә шәех итеп баш казый Ишкулны куйды. Ишкул шәех түгел иде түгелен, иллә тыңлаучы, беркайчан да хан сүзеннән чыкмады, каршы әйтмәде. Ә менә тәхет ягы авыррак иде. Тәхетне кемгә калдырыр? Булат оланга?!. Башка чара юктыр. Тик Булат углан бер дә ил башлыгына охшамаган, диләр. Аңа, имеш, берни дә кирәкми, яу ярата, кирмән салдырган да, аның түренә йорт кордырып, кызлар биетә икән. Олуг Мөхәммәт чире кагылган, күрәсең, угланга. Ул шулай кызлар биетүдән, яшь хатынга өйләнүдән туймый, диләр. Димәк, Булат та төшеп кала була. Их, Гали оныгы исән булса икән! Төпле фикер йөртер, акыл белән эш итәр иде.

Сәлим хан кисәктән янында кемнеңдер житмәвен тойды. Әйе, кәтибен алмады бит әле. Ни сәбәпледер ханбикә калдырырга кушты. Сәлим кәтибе Хафизны үзе белән алмавына үкенү тойды. Киңәшергә рәтле җайлы кешесе дә юк икән бит әле. Вәзире исәптә түгел, Камай аңа беркайчан да акыл бирә алмады. Дөрес, әйтер фикере булды, ләкин хан аны бик сирәк файдаланды.

— Ханиям, кала күренде, кала! — диде арба янында баручы бусагабаш. Шулай диюгә бер иш җайдак жилле генә юырттырып китте. Күзгә күренеп кала якынлашты, басу капкасында бер төркем кала кушханы ханны көтә иде. Галиҗәнап бусагабашыннан:

— Арада Ягкуб би дә бармы? — дип сорады.

— Күчәрбаш, күчәрбаш дим! — дип кычкырды вәзир Камай, атын чаптырып та арбага иярә алмый башлагач. — Кая болай куалыйсың эт ялаган нәмәстә!

— Ханиям, Ягкуб та анда! — диде бусагабаш.

— Хуш, — диде хан. — Мине туры Ягкубка илтерсез!

— Тархан үпкәләмәсме соң, ханиям?

— Үпкәләсә, үпкә ашатырсыз.

— Ягкубны беләм, — диде бусагабашы. — Ишан диярсең үзен, китап җыя, кызына кадәр китап укый. Шәех Игәнәй яратмый иде аны, ханиям.

— Өргәнечтә түгел, диләр ул шәехне, ханиям. Владимирда күргәннәр. Чалмасын салган да муенына тавык тәпие таккан, диләр. Имеш, мактана икән: «Мин башта ике динне дә тотып карыйм, кайсы камилрәк, шуңа иман китерәм», — дип әйтеп әйткән, диләр.

— Менә монысы инде дошман сүзедер, бусагабаш.

— Ни әйтсәләр, шуны саттым, ханиям.

— Очсыз, очсызга сатасың гайбәтең, бусагабаш. Хак, усал иде шәех Игәнәй, күпләрне, хәтта мине тешләргә иткән иде дә, тешләре коелган булып чыкты. Ибраһим каласы бие Ягкубны шәех итеп куясы булган миңа, бусагабаш.

— Әле дә соң түгелдер моны кылырга, ханиям.

— Соң инде, соң, бусагабаш. Життек бит, життек. Атларны бик куаламасаң да ярар, күчәрбаш дим! Туй төшермисеңдер ич! Әнә вәзир Камай да артта калды.

— Аңа нинди ат чыдасын, ханиям.

Басу капкасына житүгә, хан арбадан төште. Капкага кадәр келәм җәелгән иде. Сәлим хан буыннары каткан аякларын шыртлата-шыртлата кала куштаннарына таба китте. Ул барысы белән дә кул биреп күреште, аннары:

— Тархан, мин кала бие Ягкубта кунарга булдым, — диде.

— Олуг хан, без сезгә кирмән сараеннан торак җайлаган идек, иң гүзәл биючеләрне җыйдык, — диде тархан.

— Син кызларыңны баһадирларыма күрсәт. Кызларны җылата-җылата ата-аналарыннан аерып, авыллардан җыйгансыңдыр әле?

— Иң чибәрләрен! — диде Сәлим ханның кинаясен сизмичә тархан.

— Һе, Баян баһадир кайда соң? Бусагабаш, Баян баһадирны дәш әле! — диде хан.

Баян баһадир килеп житте дә атыннан сикереп төшеп, хан янына килде.

— Баһадир, кирмәнгә житкәч, тарханны кулга ал һәм зинданга яп. Кара аны, синнән башка берәү дә аның ни өчен кулга алынуы хакында белмәсен. Тархан минем дошманым, баһадир.

— Баш өсте, ханиям! — диде Баян һәм тархан ягына күз төшереп алды.

Калага кергәч, тарханны хан бусагабашы куып житте һәм:

— Кача алсаң, кач, тархан. Хан сине зинданга ябарга кушты, үз колагым белән ишеттем, — диде. Шулай диде дә атын камчылый-камчылый алга чапты.

Тархан аңардан хәтта: «Ни өчен?» дип сорарга да өлгерә алмый калды.

Олуг хан туп-туры кала бие Ягкуб йортына юнәлде.

* * *

Сәлим хан Ягкуб белән төне буена диярлек сөйләшеп чыкты. Кала бие генә булып торган кешедән бик гыйбрәтле нәрсәләр ишетте ул. Хикмәт, Ягкуб би бар яктан да хәбәрдар икән. Яңа кала нигезен корарга барганда ханның оныгы аларга кереп чыккан, әмма кайтканда вәзир Исхак тиңнәре арасында углан булмаган. Ягкуб би угланның акыллы фикер йөртүенә шаклар каткан икән, кайта-кайта шул хакта сөйләде. Ә инде атна-ун көннән Гали угланның яңа кала нигезенә күмелүе хакында ишеткәч, ни кылырга белмәгән, чөнки бу хәлне акылга сыймас вакыйга итеп кабул иткән. Аннары тархан Садыйк үз тирәсенә ялагайларны, тәлинкә тотучыларны җыйган. Хәер, бу хакта Сәлим хан хәбәрдар иде инде. Ясак җыючыларына ул җәзаны бирде, хәзер әнә тархан Садыйкка чират житте. Элек ул аңа кагылмаска булган иде, ә менә Ибраһим каласына килгәч, нигәдер бу кешегә карата янә ачуы кабарды. Тарханны зинданга ябарга боеруы да шуннан иде. Сәлим хан Ягкуб бигә бер сүз дә әйтмәде, кызын дәшәргә кушты. Ягкубның кызы чынлап та чибәр иде, ләкин бу чибәрлек күзгә ташланган чибәрлек түгел, ә кызның күзләрендәге акыллы карашы, гомумән, үз-үзен тотышында, хәтта затлы киемсалымында иде.

Зөләйха хан белән баш иеп кенә исәнләште һәм атасына карады, янәсе, ни йомыш иде, атам?

— Бар-бар, юлыңда бул, — диде ата кеше. — Гали углан, урынысы ожмахта булгыры, нигә калада кызлар өчен мәдрәсә ачмыйсыз, дип сораган иде. Мин хан булсам, беренче көннән үк мәдрәсә ачачакмын дип мактанган иде, мәрхүм.

— Кызың житкән, кияүгә бирергә кирәк, Ягкуб, — диде хан.

— Сораучылар булды, әллә нигә теләмәде, — диде би.

— Күңеленә ошаган кеше булса, теләр, — диде хан. — Кызны вакытында кияүгә бирергә, тозны вакытында ашка салырга кирәк, Ягкуб.

— Анысы хактыр, ханиям. Пәйгамбәребез дә хөрмәне вакытында өзәргә кушкан...

* * *

Икенче көнне Сәлим хан кирмәнгә барча кала куштаннарын да җыярга кушты. Кирмәнгә килгәч, ул иң әүвәл кала хисапчысын чакыртты. Хан казнасына озатылган икмәк белән кызыксынды. Кәгазьләрне актара торгач, шуңа инанды: кала тарханы хан казнасына җыелган ясакның яртысын гына җибәрә барган икән, яртысын сәүдәгәрләргә саткан. Ышбу кыек эштә катнашкан куштаннарның исемнәрен кычкырырга кушты хан сөрәнчегә. Ат-исемнәре кычкырылган куштаннар хан каршына килеп, баш ордылар.

— Зинданга, барысын да зинданга. Хөкем итәргә! Казый кайда?

— Мин монда, ханиям, — дип хан янына килеп басты казый.

Куштаннарның берсе төркем арасыннан чыкты, хан каршына килде.

— Олуг хан, гаеп бер тарханда гына түгел, бездә дә, — диде.

— Йә-йә, — диде хан авыз чите белән генә елмаеп. — Ни әйтергә исәбең?

— Олуг хан, кала кирмәне диварларын тархан шул акчага күтәртте. Урыс килде, әмма бер тапкыр да Ибраһим каласын ала алмады. Өстәмә җыелган җыемның кая китүен раслау өчен зур дәлилләр дип уйлыйм.

— Кала меңбашы, бу чынлап та шулаймы? — дип сорады хан.— Чынлап та, өстәмә җыелган ясак кирмәнне ныгытуга киттеме?

— Языклы буласым килми, ханиям. Кирмәнне ныгытуга тархан акча кызганмады.

— Кирмән ныгытуга мин аңа үзем акча биреп тордым, меңбашы. Вәзир Камай, Ибраһим каласы күпме акча алып тора хан казнасыннан?

— Елына мең алтын, олуг хан.

— Хисапчы, күрсәт әле вәзиргә китабын, кая китте икән хан казнасыннан җибәрелгән акчалар!

Хан каршына кулына китап тоткан хисапчы килеп басты. Карсак гәүдәле, утырып яза-яза бөкресе чыга башлаган хисапчы китапны ачты да:

— Һиҗри белән 580 елда Ибраһим каласы тарханы казнабаш Вартаннан бер мең алтын алып киткәндер. Һиҗри белән 581 нче елда мең дә ике йөз алтын алгандыр. Имзасы бар.

— Элегрәк күпме алган?

— Һиҗри белән 579 елда сигез йөз алтын акча алган. Имзаны тархан Садыйк куйгандыр.

Вәзир Камай хисапчы кулыннан китапны алып карады, барысы да җайда дип ханга баш иде.

— Казый, — казый баш ия-ия ханга якынайды. — Йә, казый, син бу хакта ни әйтерсең? Хөкемең ни булыр? — диде Сәлим хан.

— Минем хөкемем шәригать кануннарына таяныр, ханиям. Вә ләкин башта менә нәрсә әйтер идем. Бермәлне бүре, төлке һәм куян кәҗә бәтие тоталар. Аучылар арасында бәхәс туа. Бәти кечкенә, өч борынга җитми. Кемгә булырга тиеш? Бәхәсләшә торгач, бәтине аллаһа тәгалә тарафыннан иң алда яратылган җанварга бирергә дигән карарга киләләр. Беренче булып куян сүз ала: «Җәмәгать, мин аллаһы тәгалә күк белән җирне яратканда ук бар идем», — ди бу. Төлке исә: «Җәмәгать, куянның хәтере кыска, ялгыша. Аллаһы тәгалә куянны яратканны мин карап тордым», ди бу. Бүре исә кәҗә бәтие түшкәсе яткан якка карап, иреннәрен ялап ала да: «Җәмәгать, сез икегез дә хаклы. Сезне аллаһы тәгалә алдан яратты. Вә ләкин каты тырнакларым, нык тешләремне ул сезне яратканчы ук ясап куйган иде», ди. «Шулайдыр, шулайдыр», — диләр куян белән төлке ирексездән. Моннан чыгып шуны әйтәсем килә, олуг хан, ришвәт алуны тархан Садыйк башлап җибәргәндер. Юкса ышбу куштаннар берни дә кыла алмаслар иде. Хөкемем шул булыр, олуг хан.

— Куштаннарны гаиләләре белән Җаек буена куарга кирәк, ханым, — диде вәзир.

— Йә-йә, казый, әйт, әйт хөкемең! — диде хан Камайга игътибар итмәстән.

— Олуг хан, вәзиреңнәтиҗә ясарга ашыга төште кебек миңа. Бу хакта янә хикмәтле бер хикәят бар. Борын-борын заманда, кешеләр кошлар телен, кошлар кешеләр телен белгән чакта, илтабар белән акыл иясе урманга чыккан. Йөри торгач, агач башында бәхәсләшүче ике мәче башлы ябалакка тап булганнар. Илтабар яу чаба-чаба кошлар телен аңламый башлаган икән. Ә беләсе килә, ни хакында бәхәсләшәләр икән мәче башлы ябалаклар? Шуннан ул акыл иясеннән сорый: «Ни турында бәхәсләшә бу ике кош?» — ди. «Әйтергә куймыйм», — ди акыл иясе. «Әйт, курыкма, мин сине рәнҗетмәм», — ди илтабар. «Алайса әүвәл җәберләмәм дип ант эчегез», — ди акыл иясе. Илтабар ант эчә. Шуннан акыл иясе әйтә: «Илтабарым, ябалаклар бик хикмәтле хәл турында бәхәсләшә. Берсенең житеп килгән кызы бар, икенчесенең угланы бар икән. Оланнарны кавыштырырга булганнар. Иллә эш бирнәгә барып җиткәч, бәхәс купкан. Кыз атасы бирнәгә йөздән артык җимерек авыл бирергә вәгъдә итә, егет ягы азсына. Шуннан кыз ягы булачак кодасына әйтә: «Әгәр дә мәгәр ышбу ил халкы моңа кадәр яшәгән кебек яшәсә, бер елдан мин сиңа тагын мең авыл бирергә вәгъдә итәм», ди. Куштаннарны куарга кирәкмәстер, олуг хан, алар киткәннән соң җимерек авыллар гына өстәлер. Балык башыннан чери, җәзаны тарханга бирү хәерле.

— Җәллад, — дип кычкырды Сәлим хан. — Үтә хөкемне!

Хан тархан Садыйкның башын чапканны карап тормады, үлем җәзасын бирсә дә, кан исен яратмый, башы әйләнә торган иде.

## 32

Ләкин хан булгач, кан исен татымыйча яшәп булмый икән шул, кан исен, житмәсә үз халкының кан исен Сәлим ханга Яңа Калада тоярга туры килде. Ә бит нияте бер дә алай түгел иде.

Атасы олуг ханның гаскәр белән Яңа Калага кунакка килергә кузгалуын әмир Хаҗи ишеткән иде инде. Бу хәбәрне барча кала халкы белә иде. Шуннан китте имеш-мимеш, сафсата, гөман итүләр, юраулар. Берәүләр, хан каланы яулап алырга һәм оныгы Булатка бирергә тели икән дип юраса, икенчеләре, ханның бу чарасында бернинди дә хилафлык юк, дип бәхәсләште. Өченчеләре, кирмән диварларын тизрәк өеп бетерергә кирәк, кунакка гаскәр белән йөрмиләр, хан каланы юк итәргә килә, дип базарда ук кычкырып йөри башлады. Каладагы имеш-мимешләрне багучылары түкми-чәчми әмир Хаҗига житкереп торды. Әйе, гаскәр белән кунакка килмиләр, атасы Яңа Калага бер-бер ният белән кузгалгандыр, дип әмир Хаҗи чара күрергә кереште. Иң әүвәл ул Иске Казанга ямчы җибәрде. Бачман баһадирга гаскәре белән Яңа Калага килергә боерды.

Халык теленә Иске Казан дип керә башлаган кирмән Яңа Каладан ерак түгел, ярты көнлек юлдыр, икенче көнне иртәнге якта, биш мең азаты белән Бачман баһадир Арча капкасына килеп туктады. Баһадирның гаскәрен әмир Хаҗи кирмәнгә урнаштырырга һәм өелеп бетмәгән Нугай капкасы тарафындагы диварны төгәлләргә кушты. Диварны өеп бетерү өчен оста Дәүранга өстәмә ташчылар бирде. Капканы утырткач, аның эшен карарга әмир Хаҗи үзе килде. Башкарылган эштән канәгать калып, азатларга һәм ташчыларга бирәр алтын өләшергә боерды. Шуннан соң ике-өч ямчысын Кашанга, ике-өчен Шайтан каласына җибәрде. Колларына фәрман тоттырды. Бикәсе белән тимерче Әхмәтне һәм аның углы Бәкерне ашыгыч төстә Яңа Казанга[1] чакыртты. Кашан вә Шайтан кала-

[1] Яңа Казан — әүвәл «Яңа Кала» дип аталса да, тора-бара халык-теленә «Яңа Казан» дип керә башлый.

лары Яңа Казаннан ерак булмаса да, әмир чакырган кешеләр икенче көнне кичке якта Әрмән капкасы янына килеп туктадылар. Акбикәне әмир Хаҗи үзе каршы алды, әмир янында Бачман баһадир да бар иде, бикә күзләре белән генә булса да иң әүвәл аның белән сәламләште. Күрдеме моны әмир, юкмы, күреп, күрмәмешкә салыштымы, әмма Җик Мәргән чамалады һәм янәшәсендә торган Зәйтүнәсенә:

— Абыең һаман бикәне ярата икән, — дип пышылдады. Зәйтүнә бер сүз дә әйтмәде, әйтергә хакы булмаудан түгел, ул бу турыда күптән белә иде инде. Бары тик авыр итеп көрсенеп кенә куйды.

Әмир Хаҗи моңа кадәр беркайчан да ашыгып карар чыгармады. Хәзер исә ул ашыкты, каударланды. Иң әүвәл Кашан һәм Шайтан каласыннан килгән халыкны — куштаннарны һәм Тәтеш шәехне сараена дәште һәм тегеләр килеп, һәммәсе дә урнашкач:

— Тимерче Әхмәт! — дип кычкырды.

— Мин монда, әмирем! — диде тимерче Әхмәт, халык арасыннан алгарак чыгып.

— Тимерче Әхмәт, син монда азатларың белән килдеңме?

— Азатларым белән, әмирем. Тик азатларым барысы да тимерчеләр, әмирем.

— Мин сине, тимерче Әхмәт, Яңа Казанга тархан итәм, — диде әмир һәм шәех ягына карап алды. — Тәтеш шәех тә фатихасын бирә.

— Әмирем, мөмкин хәлме, мин бары тик тимерче, корал ясаучы!

— Углың да мондамы, кала тарханы Әхмәт?

— Кала тарханы! — дип гаҗәпләнде тимерче Әхмәт һәм тураебрак басты.

— Әйе, син ышбу мизгелдән кала тарханы, тимерче түгел, — диде әмир Хаҗи. — Каладагы һәммә кеше, чүлмәкчеме ул, арбачымы, чит ил сәүдәгәреме, тау ягыннан килгән чирмешме — һәммәсе дә сиңа буйсына. Син — миңа!

— Баш өсте, әмирем, баш өсте! — диде тархан Әхмәт, куанычыннан ни кылырга белми.

Тархан Әхмәт янына чуен коючы углы Бәкер килеп басты, янәшәсендә урыс кызы, егет марҗасын кулыннан тоткан, моны күреп, әмир Хаҗи көлемсерәп куйды.

— Оста Бәкер, сине ниндидер таш ата торган утчагыр[1] ясаган диделәр, хакмы шул?

— Аңа Табгачтан килгән дары кирәк, әмирем. Аннары ул бирәү генә.

— Шайтан каласындамы утчагырың?

— Шайтан каласында, әмирем.

— Иртәгә үк утчагырың Яңа Казан диварында булсын, оста!

— Булыр, булыр, әмирем, — дип атылып, әмир Хаҗи каршына барып басты тархан Әхмәт. — Алып килер ул аны. Үзем оештырырмын.

— Юк, тархан. Утчагырны Бачман баһадир китерер, — диде әмир Хаҗи.

Бачман баһадир әмир ягына карамый гына баш иде.

— Инде фәрманым тыңлагыз, Кашан вә Шайтан каласы оста Бәкер кулында калыр. Тарханын соңрак билгеләрмен! — диде әмир Хаҗи һәм таралырга дип ишарә ясады.

Бачман баһадир оста Бәкер янына килде һәм азатларына мичәүле атлар белән юлга чыгарга боеруы турында әйтте. Аннары оста янәшәсендә ояла-тартына басып торган урыс кызына күз төшереп алды.

— Никахлаштыгызмы соң әле, коралчы?

— Юк, баһадир, — диде оста Бәкер. — Өлгермәдек әле.

— Димәк, ышбу кыз хатының түгел әле? — диде баһадир.

— Хатыным инде, баһадир, хатыным. Тиздән бәбиебез туачак.

— Ишеттең булса кирәк, оста, Бөек Каладагы чиркәүгә ут салганнар, епископны үтергәннәр. Минемчә, барысы да мөридләр эше. Итәк

[1] Утчагыр — туп.

астыннан ут йөртәләр. Хатыныңны мөселман диненә күчереп, муенындагы тавык тәпиен алып ташлатмасаң, яман хәлләргә юлыгып куюың бар.
— Мин аңа әзер, бaһадир.
— Нәрсәгә әзер?
— Яман хәлләргә.
— Син әзерсең дә, туачак балаң әзерме соң? Башта аның турында кайгыртсаң иде. Хатының чибәр, зифа. Безнеңчә дә аңлыймы?
— Сукалый бераз.
— Сукалый, — диде Бачман бaһадир һәм нигәдер Акбикә ягына күз төшереп алды. — Сукалагач, сөйләшер дә...
Оста Бәкернең хатыны бaһадирга мөлаем итеп елмаеп куйды.
— Мин сүләшә, багатур, сүләшә, — диде.
— Яратуы хак булса, телне тиз өйрәнер, — диде бaһадир. — Оста, монда хәтәр орыш булмагае. Хатыныңны Кашанга алып кит, анда калыр. Олуг хан Яңа Калага гаскәр белән килә. Кунакка гаскәр белән килми торганнар иде төркиләр...
— Рәхмәт, бaһадир, яхшы сүзегезгә рәхмәт, — диде оста Бәкер. — Мин сез дигәнчә итәрмен.
— Атаң белән киңәш, атаң акыл иясе. Әмир хәйләкәр, атаңны тархан итте дә азатларын үз канаты астына җыйды. Күрәсең, әмирнең хыялы зурдандыр, оста. Елгадан Кабан күленә бугаз казытырга исәп тота икән. Дәүран атлы остасы шул төбәкләргә сызымнар эшләп ята, дип ишеттем. Аннары ике як ярга да кәрван-сарайлар салдырыр. Бүген әнә мәчет өстенә мәчет күтәрә. Шәех мөридләре хатының марҗа дип бәйләнә башласа, курыкма, үзем белән алып китәрмен.
— Иске Казангамы?
— Иске Казангамы, арырак булыр...
— Уйлап карармын, бaһадир. Ләкин без кеше кешесе ич. Ишләрем Шайтан каласында, эрүташ коючыларым дим...
— Кешеләреңне минем азатлар саклый шикелле, оста.
— Әйе, бaһадир.
— Шулай булгач, оста?
— Мин уйлап карармын, бaһадир, уйлап карармын...

* * *

— Әхмәт тархан, — диде әмир Хаҗи яңа гына тархан итеп куелган тимерчесенә. — Сиңа кала бие итеп бусагабаш Борнашны бирәм.
Борнаш әмир каршына килеп баш орды.
— Борнаш икән Борнаш, — диде Әхмәт тархан.
— Борнаш берничә тел белә, Сүздәлдә сәүдә иткән кеше, миңа калса, ул сиңа яхшы ярдәмче булыр.
— Бик хуп, бик хуп, әмирем, — диде Әхмәт тархан.
— Болак бугазын төгәлләгез, ике яклап кәрвансарайлар салдыра башлагыз. Кәгазь-сызымнар оста Дәүран кулында...
— Әмирем, — диде Әхмәт тархан. — Калага олуг хан гаскәр белән килә, дигән сүз йөри, хакмы шул, хак булса, ни кылырга тиеш мин?
— Ни кылу хакында сине өйрәтәсе юктыр, тархан. Кашаныңны ничек сакласаң, шулай сакла, хан гаскәреннән бер генә азат та, әлбәттә, җансакчылары вә якыннарыннан башка, калага керергә тиеш түгел. Мине аңладың булса кирәк, тархан?
— Аңладым, әмирем. Барысын да сез дигәнчә кылырмын.
— Игелек сиңа, тархан!
Әмир кул селтәде, тархан белән кала бие сарайдан чыгып киттеләр.
Икенче көнне калага чыккач, әмир Хаҗи таң калды — кирмән эче бәйрәм төсе алган иде. Әхмәт тархан кала бавырчыларына мул итеп аш хәстәрләргә кушкан икән, анда да, монда да кымыз эчәләр, аш ашыйлар. Күренеп тора, халык канәгать. Әмир Хаҗи урыс һәм әрмән сәүдәгәрләренә дә урамнар билгеләп биргән иде, анда да бәйрәм итә халык.

Әрмән капкасы янында ыгы-зыгы күреп, әмир җансакчылары белән шунда юнәлде. Ачык капка янында Бачман баһадир белән Җик Мәргәнне күргә, әмир аларны үз янына дәштерде. Кичәле-бүгенле ул бернәрсәгә төшенде: баһадир өзелеп бикәне ярата. Бу хакта ул элек тә ишеткәләгән иде, әмма күзгә-күз карашуларын күргә, тәгаен инанды — ярата баһадир бикәне һәм бикә баһадирны. Ни чара кыла ала ул? Белми иде. Әмир чарасыз иде. Баһадирны янына дәшсәләр дә, шактый вакыт килми торды — Шайтан каласыннан китерелгән утчагырны диварга күтәрәләр. Шунда ук оста Бәкер, тупчы яван. Яванны алтын куллы, диләр. Утчагырны Бәкер белән ул ясый.

Ниһаять, Бачман баһадир әмир янына килде.

— Авыр, көчкә күтәрдек, — диде.

— Җик Мәргән синең кул астындамы, баһадир?

— Әйе, әмирем. Мин аны меңбаш иттем.

— Яхшы, баһадир. Сиңа мәгълүм булса кирәктер...

— Мәгълүм, әмирем. Җик Мәргән Зәйтүнәгә өйләнде, никахлашканнар.

— Зәйтүнә кияүдә?! — Әмир усал итеп Җик Мәргәнгә, аннары хәрби киемдә ат өстендә утырган Зәйтүнәгә карап алды. — Никахны кем укыган?

— Әмирем, Җик Мәргән миндә меңбаш. Кем укыса да, барыбер түгелмени. Иң мөһиме, алар бер-берсен ярата, бәхетлеләр. Бар кешегә дә ул бәхет тими, әмирем.

Шулай диде дә Бачман баһадир сарай ягына күз төшереп алды.

— Гашыйк — диванага тиң кешедер, баһадир.

— Гашыйктан да бәхетле кеше юктыр, әмирем.

— Җик Мәргән абыйсы белән җир бүлешә, баһадир. Абыйсы Тубыкбай аны ил бетереп эзли. Минем Тубыкбай белән ачуланышасым килми. Йә, Җик Мәргән, якынрак кил әле. Кил-кил, Зәйтүнә син дә, — диде елмая төшебрәк әмир.

Җик Мәргән Хаҗиның җансакчыларына күз төшереп алды, тегеләр әмирнең боерыгын көтеп кенә торалар иде. Ләкин куркасы юктыр. Дивар өстендә дә, капка яклап та Бачман баһадир азатлары. Олуг хан каланы алырга дип яу килеп ятканда кирмән эчендә фетнә кузгату әмир өчен юләрлек кылу булыр.

— Син хаклы, баһадир. Ышбу дөньяда гашыйк кешедән дә дивана кеше юктыр. Юкса Җик Мәргән әмир кадәр әмир каршына килеп басмас иде. Бүген кич белән Мәргән кияүне сарайга алып килерсең, баһадир. Бикәгә дә күренсен.

— Атаңа дамы, әмир?

— Атама да, баһадир.

Шул мәлдә, җир астыннан калыккандай, әмир алдында Тәтеш шәех пәйда булды. Әмир Хаҗи аны күрде дә, нәкъ менә син кирәк иден миңа, дигәндәй, атыннан төште, шәехнең терсәгеннән кысып тотты.

— Шәех, мин сине кич белән сарайга дәшәм. Килми калма, җир астыннан булса да таптырырмын.

— Мәргәнгә никахны мин укымадым, әмирем, — диде шәех каударланып.

— Анысын сарайда аңлашырбыз, шәех, сарайда, — диде әмир Хаҗи һәм сикереп атына атланды да Нугай капкасына таба чапты. Иллә ярты юлга житкәч, борылып, сараена юнәлде. Сарайга житүгә, атыннан төште, тезгенен җансакчысына ташлады да йөгереп болдырга менде, ишеккә житәрәк артына әйләнеп карады һәм артыннан килүче җансакчыларын күреп:

— Берегез дә кирәкми, калыгыз! — диде.

Сарайда аны ышанычлы багучылары көтеп тора иде.

— Йә, ни әйтерсез? — диде әмир түргә уза-уза. — Атай кай тирәдә хәрәкәт итә?

— Атагыз ашыкмый, әмир. Ибраһим каласының тарханын хөкем итте. Тархан итеп, элеккеге кала бие Ягкубны калдырды. Тәүге тархан урлашкан, халыктан икеләтә ясак җыйган. Язмышы шулдыр.

— Картайды атам. Кала тарханын ике ел саен алыштырып торалар аны. Ярар, анысы минем эш түгел. Әйтегез әле, багучыларым, нигә атам гаскәр белән килә?

— Анысын белә алмадык, әмир. Күрәсең, килгәч ни кыласын барысыннан да сер итеп саклыйдыр.

— Чыгып торыгыз, үзем генә каласым килә...

Багучылары чыгып киткәч, әмир Хаҗи ишекле-түрле йөренергә керешә. Инде нишләргә тиеш ул? Атасына Җик Мәргәнне тотып бирсә? Бачман баһадир ризасызлык белдерер, ул гынамы, бикә лаф орыр. Кирмән тулы баһадир азатлары. Бәлкем, Җик Мәргәнне атасы килгәч тотып бирергәдер? Алай итсәң, Зәйтүнә балакай кызганыч. Бала бикәдә тәрбияләнде. Моны кылса, бикәнең каһәрләве бар. Болай да аралары суынды, иплэп сөйләшә алганнары да юк. Әллә соң атасы килгәч, ил кузгатырдай туй итәргәме? Бикә дә канәгать калыр иде. Качкынга туй иткән өчен атасы ни әйтер? Кул астыңа качкыннар җыеп ятасың, дип битәрләсә? Күр инде бу кыз баланы, кемне тапкан. Беткән идеме үзенә качкыннан башка кеше, тугыз яктан тугыз яучы килде, бераүсен дә кабул итмәдең, ә хан качкынына кияүгә чыккансың. Никахны кем укыган икән? Нигә баһадирга шул сорауны биргәч, җир астыннан калыккандай, шәех Тәтеш килеп чыкты? Хәйран, ни булды бу дөньяга? Әмир сараенда үскән кыз бала ир итеп кемне сайлый? Качкынны. Качкын Җик Мәргән һәм сарайда тәрбия алган Зәйтүнә. Тәмам мәхәббәткә сусаган булган икән балакай. Бикә дә белә микән бу хакта? Багучыларым, бикә Бачман баһадирга тартыла, дип җиткереп тора. Ә күңел моңа ышанмый. Мәгәр бүген ул моңа ышанды, бикә чынлап та Бачман баһадирны ярата! Йә хода! Әллә соң бар шик-мәшәкатьләрен куеп торып, кирмән диварларын әйләнеп чыксынмы? Башта калаңны сакла, аннары бикәң турында уйларсың.

Әмир Хаҗи түр якка күз ташлап алды, ахыр чиктә Акбикәсен дәшәргә ниятләсә дә, кул селтәп чыгып китте. Башта атасының ни өчен Яңа Калага килүен ачыкларга кирәк. Гарәпләр әйтмешли, калаңа дошман килгәндә, гаиләңдә җәнҗал куптармыйлар. Сабыр ит.

## 33

Акбикә ансыз яши алмый башлады. Аңарда урта яшьләрдәге хатын-кызга хас җаны тартылган кешесе белән яшәү теләге уянды. Бачман баһадирны күргән саен аның каршына барып егылырга, сыкталып еларга әзер иде. Кашанга аны алырга килгән ямчыдан Бачман баһадирның Яңа Калада булуы хакында белде. Шуннан сандыкларын актарырга, кыз чакта яратып таккан тәңкә-көмешләрен, алкаларын, затлы әйберләрен карарга кереште. Ахыр бер сандык итеп аларны Яңа Калага алып килде. Килә-килүгә, кыз чагындагы киемнәрен киеп алды да, күл буена төшеп, үз-үзенә карады. Бикәнең йөрәге ашкына, күңеле җилкенә иде. Соңгы вакытта ул бары тик бер хыял белән яши башлады — Бачман баһадир. Җитмәсә, кәнизәгенең берсе кич якта Бачман сарайда булачак дип әйтте. Шул хәбәрдән соң тәмам йөрәге җилкенә башлады. Мәхәббәт ярсу бикә өчен иманга әверелде. Соңгы ике-өч ел эчендә кәнизәк кызларын бик теләп кияүгә бирде. Кем дә булса кәнизәкләренең берсен яучыласа, әүвәл кыздан: «Яратасыңмы ышбу егетне?» дип сорар иде. Ни өчендер кәнизәкләренең күбесе егет ошаса да, ошамаса да, ризалык бирер иде. Бикә бу хәлне аларның күзләреннән күрде, хәтта шул очракта да каршы төшмәде. Арба тутырып бирнәсен бирде, бәхет-тәүфыйк теләде, итәк тутырып бала табарга юрады. Бирер

иде дә кәнизәкләрен, үзе яшьләрне алыр иде. Кияүгә чыгу гаеп түгел, кияүсез яшәү гаеп, дияр иде. Бикәне аптырауда калдырган кеше үзендә тәрбияләнгән Зәйтүнә булды. Ул аны үз баласыдай итеп карады, ә тәкәббер кыз уйламаган кешегә кияүгә чыкты да куйды. Юкса аны кемнәр генә сорамаган иде. Насыйп иткәне, ходайдан язганы Җик Мәргән булгандыр инде. Качкынга язгандыр балакайны. Ахыры хәерле була күрсен. Качып кияүгә чыгу кыпчак халкы өчен ят нәрсә түгел иде, ә Зәйтүнә кыпчак нәселеннән.

Акбикә бу хакта әмиргә әйтергә булды, чит-яттан ишеткәнче, бикәсеннән белсен әле.

— Әмир,— диде ул түргә узмый гына.— Зәйтүнә Җик Мәргәнгә кияүгә чыккан. Тартышып торма, фатихаң бирерсең...

Әмирнең ачулы чагы иде, бикәсенең бу хәбәренә нидер әйтер әмәл таба алмый торды, ахыр:

— Мин аларның икесен дә зинданда черетәм, бикә, зинданда! Йә ат койрыгына тактырам!— дип җикерде.

— Зәйтүнә минем балам,— диде бикә тыныч кына, әмирнең җикерүенә бер дә исе китмәгәндәй.— Сез аңа фатиха бирерсез, әмир.

— Нәрсә булды сиңа, бикә?— дип урыныннан купты әмир Хаҗи. Кузгалмаслык та түгел иде, бикә аңа «сез» дип дәшә башлады.

— Сез аларга тимәссез, әмир. Ишетәсезме, тимәссез! Бәхиллегем юктыр. Җик Мәргән йөзендә Зәйтүнә үз тиңен, үз бәхетен тапты. Миңа ул бәхет гомер итеп тә тимәде.

— Сөбханалла-машалла, бикә, бу ни дигән сүз тагын, ни булды сиңа? Шундый чакта?— дип гаҗәпләнергә дә, ачуланырга да белми торды әмир Хаҗи.

— Җик Мәргәнне сараеңа баһадир итеп алырсыз, әмир. Бу минем сезгә соңгы үтенечемдер,— диде Акбикә һәм борылды да чыгып китте.

Шунда гына әмир күреп алды: бикә кыз чагындагы күлмәгеннән икән ласа. Шаккатырга өлгермәде, ямчысы килеп керде. Керде дә идәнгә капланды:

— Әмирем, олуг хан гаскәре белән Кабан күле буена җәйләү туктады.

Әмир Хаҗи атылып болдырга чыкты, ишек төбендә торган иярле атына атланды да егермеләп җансакчысы белән Нугай капкасына таба чапты. Ул килгәндә капка тирәсендә шау-гөр киләләр иде инде. Әмиргә шундук юл бирделәр. Әмир баскычтан диварга менеп баручы Бачманны күрде дә:

— Баһадир, ни булды?!— дип кычкырды.

— Олуг хан йөзбашын җибәргән, капканы ачарга куша.

— Янына төшегез дә әйтегез: кирмәнгә хан җансакчылары белән генә керер. Ишеттегезме, баһадир, әмир боерыгы!

— Ишеттем, әмир,— диде баһадир Бачман һәм дивар өстенә менде, шуннан аны йөзбаш янына төшерделәр.

— Мин — йөзбаш. Хан капканы ачарга боерды, нигә ачмыйсыз?

— Көн озын, йөзбаш, сабыр ит, ачарбыз. Дегетчеләр капка күгәннәрен майласыннар, корсыннар утчагырны,— диде тыныч булырга теләп баһадир Бачман.

— Нинди утчагыр,— дип өскә күтәрелеп карады йөзбашы һәм дивар өстендә торучы әмирне күрде дә баш игәндәй итте.— Галиҗәнаплэре әмир Хаҗи, атагыз сезгә боерды...

— Кем боерды?— дип сорады Бачман баһадир йөзбаштан.— Кем колы син?!

— Мин кол түгел, мин йөзбаш, баһадир Бачман!

— Йөзбаш,— диде ирен чите белән генә баһадир Бачман.— Кол син! Мин — әмир колы, син — хан колы!

— Мин кол түгел!

— Кол син, кол!— дип кычкырды баһадир, каешына кыстырган

камчыны алды да йөзбашка сыдырды һәм тегене атыннан сөйрәп төшерде дә күкрәгенә тезен кадады. Ул арада йөзбашның азатлары баһадирга ташландылар. Азатларның берсен Җик Мәргән укка алды, ярый әле ук азатның очлымын гына бәреп төшерде. Азатлар өскә карады, аларга меңләгән мәргән укларын төбәгән иде. Азатларның кайсыдыр әче итеп сызгырып җибәрде, Бачман баһадир йөзбашның кылычын тартып алды да суга ташлады.

— Асма күперне күтәрегез!— дип боерды әмир.

Баһадир Бачман йөзбашны ычкындырды да күперга ташланды, көчкә чыгып калды. Йөзбаш Баһадирга йодрык яный-яный атына таба китте, атланды да Кабан күле буена туктаган хан чатырына элдерде.

Бачман баһадирны аркан белән яңадан тартып алдылар. Әмир Хаҗи баһадирга кара коелып карап торды, торды да:

— Зинданга, зинданга илтеп ябыгыз!— дип боерды. Әмир азатлары баһадирны «эһ» дигәнче бәтереп алдылар һәм сүз әйтергә дә бирми алып та киттеләр.

— Баһадир кеше салкын канлы булырга тиеш. Ә ул Баян баһадирның йөзбашы белән якалашырга тотынды. Мин аңа гаскәремне ышанып тапшырдым, ә ул? Баһадир урынына Җик Мәргән калыр!— диде әмир Хаҗи.— Ишеттегезме, азатларым, бүгеннән баһадирыгыз Җик Мәргән булыр!

«Ур-ра» кычкыручы булмады, әмир Хаҗи аны көтмәгән иде дә. Ул бик тиз сизеп алды. Азатлар баһадирны да, Җик Мәргәнне дә хөрмәт итә, кыскасы, икесе дә бер йөкне тарта. Ләкин Бачман баһадир әлегә әмир үзе дә аңлап бетермәгән яманлык кылырга теләде. Җик Мәргән аны яклаячак иде, Зәйтүнә алар янында. Хата эшләмәде, азатлар дәшми, димәк, аның белән килештеләр.

— Әмир, мин бары йөзбаш идем,— диде Җик Мәргән.

— Җик Мәргән, мин сине баһадир иттем. Кирмәндәге гаскәр синең кулыңда. Атамны каршы ал, кунак ит! Сине моңа өйрәтәсе юктыр. Зәйтүнә булышыр.

— Тупны корырга, Нугай капкасын ачарга!— дип боерды Җик Мәргән.— Олуг ханга үзем илче булып барам. Җансакчым бер Зәйтүнә булыр!..

Әмир Хаҗи Җик Мәргәннең кискен итеп әмер бирүенә гаҗәпләнеп тә өлгермәде, Зәйтүнә әмир янына килде.

— Атам, олуг хан килгәндә сарайда булыгыз, үз кадерегезне үзегез белегез!— диде.

Әмир Хаҗи тәмам ни әйтергә белми торды. Аннары җансакчыларына:

— Ышбу баланы күз карасы кебек саклагыз!— дип, китеп барды.

Аждаһа койрыгыдай тузан туздырып, Җик Мәргән белән Зәйтүнә хан чатырына таба чаптылар. Хан аларны чатырында көе, йомшак мендәргә кырын төшкән килеш каршы алды. Ул нигәдер каршында Җик Мәргән булуына гаҗәпләнмәде, гаҗәпләнгән заты Мәргән янындагы хәрби киемдәге Зәйтүнә иде.

— Олуг хан, капкалар ачык, сезне угланыгыз әмир Хаҗи сараенда көтә,— диде Җик Мәргән.— Кирмәндә кеше күп булу сәбәпле, гаскәрегезне биредә калдыру хәерлерәк булыр, ханиям. Җансакчыларыгызга урын табылыр. Әмир шулай теләде...

Шул чак Зәйтүнә чатырдан чыгып китте һәм кирмәндәгеләргә яулык болгады. Кирмән ягында туп шартлады, Кабан күле буендагы атлар сискәнеп, куркынып киттеләр, азатлар да бу көтелмәгән хәлгә сикерешеп тордылар. Рум тукымасыннан тегелгән калын мендәргә кырын төшкән Сәлим хан, туп тавышын ишетүгә, торып басты, йөгереп һавага чыкты.

— Ни булды, нинди шартлау бу?

— Утчагырдан аттылар,— диде хан артыннан чыккан Җик Мәргән.

— Нинди утчагыр? Кем ясаган?

— Тимерче Әхмәт углы белән яван Фатий, олуг хан.

— Һе,— диде Сәлим хан.— Һе, әмирдә утчагыр. Үзе кайда?

— Сараенда, олуг ханым. Сезне көтә.

— Вәзир Камай!

— Мин монда, ханиям.

— Бөек Калада утчагыр ясаучы бармы?

— Юк, ханиям. Утчагыр әмир Хажида гына. Көпшәсен агачтан ясыйлар, тимер белән коршаулап чыгалар. Дарыны Табгач сәүдәгәрләре китерә. Оста Бәкер белән яван Фатий күптән маташалар иде инде ул туп белән, ханиям.

— Ә син, син ни карадың? Апара тәпәне. Ни өчен алтын түләп торам мин сиңа? Котсыз! Җиктер атларым, кирмәнгә керәбез!

— Гаскәр белән ни кылабыз, ханиям?

— Гаскәр монда калып торыр. Минем белән субаш Байсар, жансакчыларым гына барыр.

Бик тиз мичәүләп атлар җиктеләр, хан арбага менеп утырды һәм кулындагы таягы белән арбачыга кагылды.

— Кузгал, аллага тапшырдык. Баян баһадир, гаскәрең белән калырсың. Вәзир Камай минем белән барыр. Әйдә, кузгал, кузгал!

Арбаның ике ягына дүртәр-дүртәр булып ханның жансакчылары басты. Җик Мәргән белән Зәйтүнә алдан киттеләр. Кирмәнгә җитәрәк Зәйтүнә андагыларга янә яулык болгады. Нугай капкасы ягыннан янә туптан аттылар. Шунда һич көтелмәгән хәл булды — мичәүләп җиккән хан атлары дулап китте. Ни кылырга чарасыз калган арбачы дилбегәләрне аяк терәп тартты, мәгәр котлары алынган атларның күзләре тонган иде, кирмән буйлап җан-фәрманга чабып киттеләр. Арба кирмән тирәли казылган су чокырына очса — хан харап булачак. Аның беркайчан да болай өметен югалтканы юк иде әле. Арбачы белән янәшә чапкан җансакчыларына, кирмән тирәли казылган су чокырына карады да:

— Йә аллам, ни гөнаһ кылдым! Коткар, коткарыгыз!— дип кычкырып җибәрде.

Мичәүле атларның дулап китүләрен күреп, Җик Мәргән алар үзе янына җитүгә, тезгенне эләктерде һәм толпарын янәшә атлатып тыя башлады. Юртаклар шундук сабырланды, ахыр бөтенләй туктадылар. Җансакчылар хан арбасын уратып алды. Җигүле атларның күзләре акайган, борыннары киерелгән, аяклары калтырана иде. Җик Мәргән аларның тезгенен хан җансакчысына бирде дә арба янына килде.

— Олуг ханым, олуг ханым!— дип эндәште.

Галиҗәнап бер сүз әйтми арбадан төште, сәерсенеп Җик Мәргәнгә карады, аннары үпкә катыш ачу белән җансакчыларына, бигрәк тә Байсарга күз төшереп алды. Соңгы мәлдә генә Җик Мәргәннең мичәүле атлар каршына төшкәнен күреп калган иде хан.

— Олуг ханым, атларыгыз юк нәрсәдән дә өркергә тора. Атланыгыз менә минем юртакка!

— Хуш, хуш.— Сәлим хан арбадан ычкына алмый торгандай итте, икенче мәлдә килеп, Җик Мәргән кулыннан тезгенне алды.

— Рәхмәт, мәргән.

Хан җилле генә атка атланды да Нугай капкасына таба кузгалды. Ул килүгә, капкаларны ачып, асма күперне төшереп куйганнар иде инде.

Нугай капкасыннан калага килеп кергән олуг ханны Яңа Кала халкы тыенкы гына, шауламый, «ура» кычкырмый гына каршы алды. Әмир сараена җитәрәк күрде хан: атасын каршы алырга дип угланы болдырга чыгып баскан иде.

«Капка янына гына түгел, чатырыма киләсе иде сиңа, углан, атаңны каршы алырга»,— дип үртәлеп уйлап куйды Сәлим хан һәм сарайга

житәрәк Жик Мәргәнне күтәреп алды. Ул арада болдырдан әмир Хажи йөгереп төште, атасына кулын сузды.

— Атам, исән-сау килдегезме, юл бик авыр булмадымы?!

— Тукта әле син,— диде Сәлим хан угланын бүлдереп.— Тубыкбайның энесе Жик Мәргән ничек сиңа килеп эләкте? Ул бүген мине яман хәлдән коткарды. Рәхмәт аңа, әмма...

Сәлим хан тирә-ягына күз ташлады да, тыңлап торучыларны күреп, башын чайкады.

— Атам, Жик Мәргән миндә баһадир,— диде әмир Хажи.

— Баһадир?!— дип гаҗәпләнгәндәй итте Сәлим хан.— Баһадир! Хуш, хуш... Кирмәнең киң вә зур итеп салгансың, ә атаң гаскәренә урын тапмадың. Качкын Жик Мәргән азатларына урын тапкансың.

— Күл буенда күңеллерәк булыр аларга, атам,— диде әмир Хажи.— Аннары бүген базар көн. Инде узыйк, рәхим итегез, атам.

Сәлим хан әкрен генә болдырга менә башлады, аңа жансакчылары иярергә иткәннәр иде, Зәйтүнә аркылы төшеп:

— Ханны бирегә күтәрсез,— диде.— Субашы Байсар үзе белән бары тик бер азат ала,— дип боерды.

Ханга ике жансакчысы ияреп кереп китте, калганнары елмаешып, Зәйтүнәгә ирәя башладылар.

— Азатлары житмәгәч, хатын-кыз тота башлаган бу әмир, ә?— диде берсе.

— Бусагасын да кызлар саклый әмир Хажиның, малай. Әллә монда каласы инде,— диде икенчесе.— Әллә ниткән утчагыр да уйлап тапканнар. Күрдеңме, ташы кая килеп төште, күл буена ук. Очар арасы бер чакрым булыр, билләһи.

— Карале, туташ, шаехне дәшсәң, билләһи дип әйтәм, ике дә уйламый никах укытыр идем үзең белән...

— Соңга калдың, азатым, соңга калдың,— диде Зәйтүнә кинаяләп.— Хан кызын урлаганнар, дип ишеттем, ни карадыгыз соң?

— Һе, хан кызын урларга башыма тай типмәгән лә минем. Кызын урлаган кешене хан тапса, беләмсең нишләтәчәк ул аны, туташым? Тереләй тиресен тунатачак.

— Ул арада хан кызы табылып куйса?

— Һәй, туташ! Ханга бала ни дә, хатын ни. Зөбәрҗәт ханбикә ничәнче хатын дип уйлыйсыз? Өченче. Житмәсә, сарай тулы жария дә кәнизәк, биюче дә такмакчы.

Ул арада сарайдан Жик Мәргән килеп чыкты.

— Жансакчыларга шушында көтәргә кушылды. Ишеттегезме, азатлар. Ясавыл Байсар дим!

— Ишеттек, ишеттек, мәргән.

— Зәйтүнәкәй, сине хан дәшә,— диде Жик Мәргән.— Бар, кер. Күп сөйләмә. Дәшкән бер откан, дәшмәгән — ике. Мин азатларым янына киттем. Хан абыеңны да дәштерде.

* * *

Баһадир Жик Мәргән чыгып киткәч, Сәлим хан углана әмир Хажигә, үпкә белдергәндәй, әйтеп куйды:

— Качкын кешене баһадир иткәнсең, углан, килешми. Тубыкбай баһадир аны ил бетереп эзли.

— Атам, юкка борчылмасана. Тубыкбай Агыйдел буенда, Жик Мәргән Идел буенда. Миңа калса, Тубыкбайда энесе кайгысы калмагандыр. Угылларын өйләндереп ята, диделәр. Аннары Жик Мәргән Бачман баһадирның сеңлесенә өйләнде. Ә ул бала бикә кулында тәрбияләнгән иде. Зәйтүнә белән Назлыгөл дә кунакка йөрештеләр — ахирәтләр иде.

— Назлыгөлне тапкан кешегә Суар каламны бирәчәкмен. Әйткән

сүзем — аткан угымдыр. Анаң Назлыгөлне Яңа Калада дип саташа. Имеш, Назлыгөлне урлаучы шул бер оста Дәүран гына, бер дә бүтән түгел дип бара. Имеш, кемдер, кайчандыр, чирмеш камы диме, юраган икән: Дәүран хан кызына өйләнәсе икән.

— Оста Дәүран миндә. Назлыгөл аңарда булса, бер күренмәсә бер күренер иде.. Кеше кош түгел — канатсыз. Назлыгөл, атам, Олуг Мөхәммәт кулында. Ул бездән үч алды. Сездән...

— Миннән, димәк. Һе, илчесе өчен үч алуымы икән? Үзенәме, угланнарынамы дигәндәй?..

— Юк, атам, миңа шундый хәбәр килеп җитте: Хәрәземшаһ җиде илдән җиде кыз китерткән, шулар арасыннан иң зифасын үзенә сайлап алган һәм, бер хода белә, ничәнче хатын итептер. Әйе, калганнарын куштаннарына өләшкән, имеш. Назлыгөлнең дә шулар арасында булуы бар, диюем.

— Назлыгөлне Олуг Мөхәммәт кешеләре урлап алып киткән булса, Хәрәземшаһ үз теләгенә иреште булып чыга, углан.

— Олуг Мөхәммәт хатыннарны ат сайлаган кебек аралый, диләр. Анасы Күркә шаһинә угланы өчен кызларны үзе сайлый икән. Чибәрме, тәне-сыны камилме, зифамы, акылы иплеме — һәммәсен дә чишендереп, хәтта комга утыртып карый, диләр. Биккол сәүдәгәр шулай дип сөйләде, аның анда кермәгән кешесе, белмәгән сәүдәгәре юк. Ышанмагач, мин Тәтеш шаехтән сорадым, ул да шулай дип раслады.

— Назлыгөлнең кем кызы икәнен белүгә, Олуг Мөхәммәт Болгарга илчеләр җибәрер, бирнә соратыр иде. Андый хәл булмады шикелле.

— Атам, Назлыгөлне колҗария итеп сату өчен урлаган булсалар? Аның хан кызы икәнен сиздермәсәләр? Мәкерлекнең чиге юк ич аның. Ә инде Олуг Мөхәммәт Назлыгөлне сараенда калдырырга, угланнарының берәрсенә бирергә уйлаган булса, туйга дәшмәсә дә, һич югы, хәбәр итәр иде, шаһ та аллаһы тәгалә колы.

— Булмады шул инде, углан. Мин анда багучыларым җибәреп карадым, тапмадылар. Биккол да Назлыгөлнең исеме-аты чыкмады дип бара.

— Назлыгөлне колҗария итеп читкә сатып җибәргән булсалар, атам?

— Сөйләмә тузга язмаганны. Иншалла, исән-саудыр. Сабыр итик, бер хәбәре килмәсә, бер килер, кеше энә түгел. Үзең, үзең соң ни кылып ятасың, углан? Илһамның да бер дә килеп чыкканы юктыр, синең дә Бөек Каладан эзең суынды. Калаң килешле, миңа ошады, урыны иплե булган, изге урындыр, су юлында, биек яр буенда, дигәндәй. Тарханың кем, калада күп нәрсә тарханнан тора?

— Тарханым тимерче Әхмәттер, атам. Ипле кеше, игелекле.

— Кашандагы тимерче Әхмәтме, корал ясаучы?

— Үзе, атам. Ул кешенең кулыннан килмәгәне юктыр.

— Хуш, утчагыр дигәненне аның углы ясадымы?

— Тупны Фатый яван белән ул ясады, атам.

— Фатий яван ирекleme?

— Ирекле, атам. Мин аңа алтын белән түлим.

— Өй-биналарыңны оста Дәүран суктырдымы?

— Әйе, атам. Дәүран хәзер кол түгел, мин аңа ирек бирдем.

— Хәтерем ялгышмаса, ул минем колчурам иде шикелле, углан?

— Дәүран ил өчен игелекле кеше булды, син аны кичерерсең, атам.

— Белмим, бәлкем кичерермен дә. Аның атасы Алпар да бик тә игелекле адәм иде. Мәчетне дә ул күтәрдеме? Әйбәт салган, каланың йөзек кашыдай утыра.

— Мәчетне сез биргән акчага салдым, атам. Хан мәчете дип атадым. Халык теленә дә кереп бара инде, хан мәчете дип.

— Каланны Казан дип үзең атадыңмы?

— Бачман баһадир азатлары шулай дип йөри башлады ла.

— Ярый, хәерле булсын. Калаң гүзәл күренә, әмма кылган эшләреңә рәнҗимендер. Калаң күтәрелеп кенә килә, инде урыс, әрмән сәүдәгәрләре урам-урам утыра башлаган. Күп тә үтмәс, чиркәү сала башларлар. Шуннан ни кылырсың? Ишеткәнсеңдер, Бөек Каладагы чиркәүне яндырдылар, ул гынамы, епископны үтерделәр.

— Мөридләр эшедер инде, шәех Игәнәй ни караган соң?

— Шәех Игәнәй илдән качты, яманлык аның тарафыннан кылынды, ахры. Карале, нишләптер Бачман баһадир бер дә күземә чалынмады, углан. Начармы, яхшымы, баһадир олуг хан сараен саклаган иде.

— Баһадир монда, атам. Кич белән сарайда булыр,— диде әмир Хаҗи һәм борылды да:— Әхмәт тарханга әйт, баһадирны алып килсен.

Шаулый-гөрли Акбикә килене килеп керде, керә-керүгә олуг хан янына узды, күрешергә дип ике кулын сузды.

— Исән-имин килеп җиттегезме, атам? Анам исән-имин калдымы?

— Аллага шөкер, аллага шөкер кылырлык, килен. Үзегез исән-сау торасызмы, иминлекме?

— Менә улым күмелгән калага күчеп килдем әле, атам. Ул бала өчен елый-елый күзләрем бетте инде, атам. Вәзир Исхакны каргый-каргый каберендә әйләнерлек иттем, дәҗҗалны. Тәмугтан башы чыкмасын иде, раббым.

— Йә-йә, килен, каргышың карга башына, каргыш һәрчак уртак төшәр, ди китап. Җәннәт кебек дәргаһта яшисең, биргәненә разый булып тор,— диде Сәлим хан килененә һәм өс-башына, буй-сынына күз төшереп алды. Килене йөзендә мөлдерәп торган шатлык күреп, сәерсенә калды. Аннары килене кызларча киенгән, гелән яшәреп, гүзәлләнеп киткән иде. «Шифалы сулар эчеп торадыр бу хатын,— дип уйлады Сәлим хан, хатирәгә бирелеп.— Туйбикә, мәрхүмә, гелән ышбу килен кебек назга сусагандай бөтерелеп йөрер иде. Гүзәл, гүзәл килене, сынбатлы егетләр күзе төшәрлек. Бәлкем, шуңа Хаҗи углан икенче хатынга өйләнергә теләмәгәндер, башкаларга җаны тартмыйдыр». Ә бит Сәлим хан өлкән угланына икенче хатынлыкка Пургас илтабарның кызын тәкъдим итеп караган иде, якын да килмәде. Пургас илтабар кызына өйләнгән булса өлкән угланы, кем белә, бәлкем ул илтабар Болгардан йөз чөереп, кенәз Андрейга сыенмаган да булыр иде. Хәер, белмәссең, Андрей кенәз янә Рокыяга өйләнде дә, оятын югалтып, Болгарга яу килде, шактый зыян китерде. Яшь кенәз Всеволод та янә безнең ыруга өйләнде, иллә аның да Болгарга күзе кыза икән, диләр. Хатын-кыз ни ул, күл буендагы камыш, кай тарафка җил исә, шул якка авыша, әйе, кем ишеген ачып керә, шуның җырын җырлый. Рокыя турында алай дип әйтәсе килми килүен. Кенәзне үтерүдә гөнаһы булмаса да, тату яшәмәгәннәр икән. Андрей кенәзне Болгарга яу килүдән тыеп торган. Яу чабып көн күрергә өйрәнеп киткән урыс кенәзләренә, аларга гына түгел, куштаннарга, дин әһелләренә, байларга хатын сүзен тыңлаган кенәз ярый торган буламы. Үтерәләр бичараны. Югыйсә милади белән 1175 елда булган яу башында Андрей Боголюб кенәз үзе килгән булыр иде.

Килене чыгып киткәч, Сәлим хан түр якка узды, мендәргә кырын төште. Янә килене килеп керде. Юлдан йончыгансыңдыр, атам, дип, читекләрен салдырып алды, кулларын чайкатты, ул арада асраулары табын хәстәрләде. Сәлим хан әгузе-бисмилласын әйтә-әйтә бөкләнеп утырган гына иде, ишектән баһадир Бачман инде.

— Әссәламе галәйкем, олуг хан!

— Вәгаләйкем әссәлам, баһадир!— дип Сәлим хан урыннан купты, баһадирга кул бирде.— Йөзең качкан, кәефең юк сыман, баһадир, ни булды?

Бертын җавапсыз торгач кына баһадир:

— Туптан атканнар иде, атым дулады, әллә кая алып китте,— диган булды.
— Һе, ул туптан атканнан соң минем атлар дулаганын күрсәң иде син, баһадир. Алай да ходай бар икән әле, качкын Җик Мәргән коткарды. Мәргән дигәннән, баһадир, синең кул астындамы ул? Әйе, Тубыкбай зарыгып көтә аны. Әмир Хажи, баһадирым иттем, дип саташтыра. Үзем белән алып китәрмен, ахрысы, мин аны, баһадир. Әйдә, уз, утыр, чәйләп алыйк. Һәй, кем бар анда!— Әмир Хажи керде.— Җик Мәргән кая китте, углан?
— Монда, атам, кирмәндә.
— Хуш, бик югалмасын, ул миңа кирәк. Тәтеш шәехне дә дәштеңме?
— Дәштем, атам.
— Игелекле кеше күренә, әллә мин әйтәм, шәехне Бөек Калага бирәсеңме, углан? Пәһлеван Мәхмүт сиңа тагын җибәрер әле. Рәхмәт аңа, Болгарны якын итә.
— Әйе, якын итә, табибләрне үзенә ала, галим-могтәбәр кешеләрен бире җибәрә,— диде әмир Хажи.
— Бәрәкалла, бәрәкалла, бик әйбәт, бик хуп. Елга тугайсыз, кеше кардәшсез булмый. Вәзир Камай килмәдемени? Нинди үзсүзле кеше булды бу вәзир. Китә дә югала, китә дә югала.
— Вәзирне кала тарханы Әхмәт кунакка алды, атам.
— Хуш, тархан белән аралашуы әйбәт, алай да монда булуы хәерлерәк булыр иде. Әйдә, йөри бирсен инде алайса.
— Атам, нигә кәтиб Хафизны алып килмәдең? Минем аны бик тә күрәсем килә иде?
— Анаң җибәрмәде, Өргәнечтән китап сәүдәгәрләре киләсе диме шунда, Саксиннан шагыйрь Габделгаләү белән очрашасылары бар диме... Мин ул Габделгаләүне сарайга алырга булдым әле, углан.

Шулчак Тәтеш шәех килеп керде.
— Әссәламе галәйкем, олуг хан!
— Вәгаләйкем әссәлам, шәех!— диде Сәлим хан янә утырган урыныннан күтәрелеп.
— Сау-сәламәт кенә килдегезме, ханиям? Юлда бик кыен булмадымы? Яңгыр-мазарга очрамадыгызмы?
— Бәрәкалла, шактый ипле кеше булып чыктың бит әле син, шәех. Хуш. Кем шәкерте дип белик инде сине, шәех?
— Пәһлеван Мәхмүттә сабак алдым, ханиям. Ул минем җизнәмдер.
— Йә-йә, бик хуп, бик әйбәт. Уй-ниятләрең ничегрәк инде? Әллә, мәйтәм, Бөек Калага күчәсеңме?
— Бөек Калаңа кайтыр кешең бар дип беләм мин, ханиям. Пәһлеван Мәхмүттә сабак алып, күп еллар мәдрәсәдә шәкертләргә сабак бирүче онытыгыны әйтәм, ханиям.
— Онытыгым?! Сөбханалла! Бу ни дигән сүз инде, шәех? Аты, аты ничек ул мөдәрриснең?
— Аты Кол Галидер, ханиям.
Сәлим хан Кол Гали исемен ишетүгә, чак кына сикереп торып басмады. Әүвәл һәммәсенә дә күз йөртеп чыкты, әйе, барысы да ишеттеме? Ишеткән хәлдә нигә, әйтик, угланы берни дә дәшми? Ләкин Сәлим хан ялгыш уйлаган икән, шәех шулай диюгә, иң әүвәл әмир Хажи урыныннан кузгалды һәм килеп шәех алдына тезләнде.
— Кабатла, кабатла, зинһар, сүзләреңне, шәех!
Тәтеш Шәех һични аңламый тирә-ягына каранып алды. Ул бераз каушаган иде. Ләкин ни дә булса әйтер алдыннан һич югы азрак беләсе килә иде: нигә барысы да, хәтта ханга кадәр шаккаттылар? Әйе, ул

Болгардан килеп, җизнәсе Пәһлеван Мәхмүттә сабак алып, менә ничә ел инде шаһ мәдрәсәсендә мөдәррис булып торучы Кол Галине белә иде. Әмма моңа ник ул хәтле шаккатырга? Пәһлеван Мәхмүттә йөзләгән менә-менә шәех буласы мөридләр сабак ала. Бире килгәч, Тәтеш шәех кала нигезенә күмелгән хан онысы турында хикәятләр ишетте, мәгәр ул аңа беркайчан да җитди хәл дип карамады. Болгарда гына түгел, андый уйдырмалар бар халыкта да тулып ята, ул уйдырмаларга җитди итеп карауны гомумән аңлап бетерми иде яшь шәех. Ә монда барысының да күзләре акайды, җитмәсә, әмир Хаҗи каршына ук килеп тезләнде

— Минем угланымны үз күзең белән күрдеңме, шәех?

Йә хода, тагын ни әйтергә тиеш инде ул әмиргә? Дөресен сөйләп бер-бер тозакка эләгеп куймасын тагын. Кол Гали турында оста Дәүран өендә дә сүз кузгатканнар иде бугай. Менә бит син аны, әй.

— Йә, шәех, «ә» дигәч, «мә» дә диген инде!— дип, хан да урыныннан купты.

Тәтеш Шәех тәмам курка калды.

— Арада чукраклар юк бугай!— диде әмир Хаҗи.— Барыгыз да ишеттегезме?

— Ишеттек, ишеттек!— диештеләр табындагылар.

Шәех утырган җирендә борсаланып куйды, астындагы мендәрне җайлагандай итте. Җизнәсе Пәһлеван Мәхмүт ялганлаган булса, ахыры ни белән бетәр бу хәлнең?

— Гали олан, диде бугай, остазым. Әйе, Гали олан, диде. Иң галим мөдәррисләремнең берсе, диде.

— Ә сез бит Кол Гали, дидегез. Кол Гали? Ә хәзер тагын Гали?!

— Кол Гали, диде бугай шул, әмирем. Әйе, Кол Гали...

— Кисеп кенә әйт инде, шәех Тәтеш, Пәһлеван Мәхмүт аңа Гали дипме, Кол Гали дипме дәште?— диде Сәлим хан.

— Олуг остазыбыз Пәһлеван Мәхмүт шәкертләренә дә, мөгаллимнәренә дә, мөдәррисләренә дә атлары белән дәшми, хан. «Димәк, дип уйлады шәех Тәтеш, җизнәсе Пәһлеван Мәхмүт янында хан онысы булмаган. Алай дисәң, нигә соң аңа җизнәсе Болгар ханының онысы диде? Ә болар, авызлары белән кош тотарга җыенган бәндәләрдәй, аннан җавап көтә. Монда нидер булган, йә хан онысын сөргәннәр, йә яшереп укырга җибәргәннәр? Тик кемнән? Хан угланыннанмы, угланы атасыннанмы? Шуны беләсе иде җавап биргәнче...»

— Төс-йөзгә, күрер-күзгә кыяфәте, буй-сыны ниндирәк иде соң ул адәмнең?— дип сорады янә әмир Хаҗи.

Менә килеп капты. Атасы буларак үз угланын белә булса кирәк, төс-йөзен дә, буй-сынын да. Әйе, күзләре зәңгәр иде, чак кына кырын караган сыман тоелды, буйга да озын түгел, карсак та түгел. Чәче хәтердә калмаган, күрмәдем, чалмадан иде.

— Ике тамчы судай бер-берсенә охшаган кешеләр була, җәмәгать, минем ялгышып куюым да бар.

— Әйе шул,— дип шәехкә ярдәмгә килде Сәлим хан.— Кеше белән кешене түгел, кайчак тау белән тауны да аерып булмый.

Әмир Хаҗиның тәхет бүлмәсенә Җик Мәргән килеп керде, Сәлим хан мәргәнгә таба борылды.

— Хуш килдең, Җик Мәргән. Әйдүк, түрдән уз. Хода сиңа ике гомер бирдеме әллә, мәргән?

— Олуг ханым, атам исән булган булса, мин бу көнгә калмаган булыр идем. Атам-анам алдында кылган языгым юктыр, ханиям. Ике туган арасында ни булмас. Мин үземне ил алдында гөнаһлы дип санамыйм, ханиям.

— Хуш, мәргән, шулай да булсын, ди. Нигә соң абыең зарлана?

— Җирне мин бүлмәдем, ханиям, сыеныр урын эзләдем. Безнең ыру җир сөрми, мал асрый, абыемда...

— Әмир Хажи, Җик Мәргән — баһадирым, дидең бугай?
— Әйе, ул минем баһадирым, атам.
— Бачман баһадир, син кем инде хәзер?
— Җик Мәргән — киявем, ханиям. Яшьлек — кыюлык билгесе. Җир сорауның нинди гаебе булсын. Җир кадерен хан, ир кадерен ир белер, ди. Тубыкбай баһадир белән мин үзем килешермен, ханиям.
— Атам, Тубыкбай баһадир ялгыша. Ул аңа җир бүлеп бирергә тиеш булган,— диде әмир Хажи да.
— Углан, Тубыкбай баһадирга мин качкын энеңне тотып бирермен дип вәгъдә иттем. Хан сүзе — аткан уктыр. Аткан укны кире кайтарып булмый.
— Ул аткан угыгыз үз батырыгызга төбәлгән түгелме соң, атам?
— Ил батыры качкын була алмый, углан. Ил батыры йә орыш кырында ятып кала, йә илен саклый. Абыең Мөхәммәтгалимбәк нишләде?
— Әле булса тәхет турында хыяллана икән. Гаскәре белән Саксин каласы тирәсендә урала башлаган. Туган — туган белән, углан — ата белән җир-су вә тәхет өчен орыша башласалар, кая тәгәрәр бу Болгар?!
— Язмыштан узмыш юктыр, атам. Язганны күрербез. Иллә әйтер сүзем әйтим: Җик Мәргән миндә калыр, атам,— диде әмир Хажи.
Сәлим хан куырылып киткәндәй булды, әмма угланы әмир Хажига кайтарып сүз катмады. Яңа Калага явыз ният белән килсә дә, әлегә ул аның кунагы иде. Кунак булсаң, тыйнак бул, гәрчә олуг хан булсаң да. Ә явыз ниятне явызлык кылганда гына тормышка ашыру мөмкин. Хикмәт, ни белән куәтләнә бара бу углан? Кем кодрәт биреп тора? Тәтеш шәехме әллә? Бик ихтимал ич! Белекле, яшь, ил дәрвишләре арасында дәрәҗәгә ия, олуг шәех Пәһлеван Мәхмүттән фатиха алган кеше.
— Углан, атаң турында яман уйламасаң иде, мин Җик Мәргәнне җәзаларга уйламыйм. Бачман баһадирның сеңлесенә дә өйләнгән икән. Игелек аларга. Минем бары тик бер хакыйкатьне беләсем килә: никахны кем укыды икән? Әйе, шәех Тәтеш синме?
— Аллам сакласын, олуг хан, гөнаһка батасым килми. Мин укымадым никахны. Хак анысы, кызыгыз Назлыгөлгә...
Шәех шулай диюгә, Сәлим хан тәмам йөзгә алышынып, аңа таба кузгалды.
— Кабатла әле, кабатла, шәех! Ни дидең?!
Тәмам коты алынган Тәтешнең кулыннан кымыз касәсе төшеп китте, Хажиның чапан чабуына түгелде. Асрау кыз әмирнең чабуын сөртергә ташланды, ләкин юлына хан очрап, аңа килеп төртелде, Сәлим хан асрауны селтәп кенә җибәрде. Әмир Хажи да корт чаккандай сикереп торды, ул һичнигә игътибар итми шәехкә карады. Тәтеш шәех, очкылык тоткандай ык-мык итте дә, соңгы чарасы иде бугай, авызын тотып, күңелем болгана дип, күрше бүлмәгә чыгып китте. Сәлим хан белән әмир Хажи һични аңламый күзгә-күз карашып алдылар, ул да түгел, әмир Хажи шәех артыннан юнәлде. Бүлмәгә килеп керүгә, ул шәехне урап алган асрауларны сибеп җибәрде дә шәехнең изүенә килеп ябышты.
— Нәрсә Назлыгөл, шәех? Никахны Назлыгөлгә кем укыды? Кайда?!
Әмир Хажиның күзләре акайган, авызы кыйшайган, ил башы үзүзен белештермәс хәлгә җиткән иде.
— Әмир, угланың исән, Өргәнечтә мәдрәсәдә мөдәррислек итә. Бу хак, әмир,— диде шәех ашыга төшебрәк. Шәех моңа чарасыздан барды, әмирнең акайган күзләрен күреп, коты алынудан.
Әмир Хажи шәехнең изүеннән җибәрде, агарынып, лып итеп шәех янәшәсенә сәкегә утырды. Бары тик бертын торгач кына, авызына күз теккән асрауларының берсенә:
— Тиз булыгыз, бикәне дәшегез!— диде.
— Аһ аллам, ни булды тагын!— дип килеп керде бикә.
— Бикә,— диде әмир Хажи аңа карамый гына, акылдан шашкан

бераүдәй.— Бикә, Гали углан исән, Өргәнеч мәдрәсәсендә мөдәррис.
Акбикә кинәт агарынып китте һәм әкрен генә ишелеп төшә башлады, әмма асраулар бикәләренә егылырга бирмәделәр, кулларына күтәреп, хатын-кызлар ягына алып чыгып киттеләр. Кайдандыр кендек әби килеп керде, кызларны туктатып, бикәнең йөзенә дога укый-укый ачу таш бөркеде һәм асраулар:

— Әбием, анда әмиргә әллә ни булган!— дигәч, түр якка ашыкты.

— Әмир балакаем, ни булды?— диде ул Тәтеш шәехкә игътибар итмичә, ил башының күзләренә карады.

Бикәнең һуштан язуын кендек әбинең беренче генә күрүе түгел иде инде, артык исе китмәде, ничек язган булса, шулай исенә дә килер, ә менә әмирнең төсе-йөзе качып, агарынып утыруын әүвәл тапкыр күрүе иде. Әйе, хатын-кыз гел юк-барга да һуштан яза, аңа ходай тәгалә шулай язгандыр, күрәсең, ә инде ир-ат миңгерәүләнеп утырса, хәлләр яман, йә бер-бер нәрсә буласы, йә төннән көн туасы. Әнә шуны аңлап алды әмирне күрүгә күпне белгән кендек әби.

Ул арада Сәлим хан килеп керде һәм әмир янәшәсендә утыручы кендек әби янына килде дә:

— Сыз моннан, тиз бул, убырлы карчык!— дип ысладьы.

Бүлмәдәге асрауларны һәм кендек әбине гүя җил алды, Тәтеш шәех исә ике кулы белән авызын каплаган килеш, күзләрен шар ачып, калтыранып утыра бирде.

— Атам, Гали углан исән, исән! Өргәнечтә шаһ мәдрәсәсендә мөдәррислек итә,— диде әмир Хаҗи һаман бер ноктага караган рәвештә.

— Суга батучы саламга тотынып булса да котылырга тели, ди, без дә шулай, углан. Син дә бу иблискә ышандыңмы? Ни сөйләгәнен беләме соң үзе? Күрәмсең, коты алынган,ниләр кылана...

Сәлим хан, өшеп киткәндәй, чапанына төренә төште.

— Олуг хан, олуг хан!— дип, Тәтеш шәех аның алдына килеп егылды, мәгәр Сәлим хан аягы белән тибеп кенә җибәрде.

— Ялганчы бушбугаз. Ат койрыгына тагарга кирәк үзен!

— Мин ялганчымы, олуг хан?— диде Тәтеш шәех һәм торып басты, хәтта башын чөя төште.— Мин беркайчан да, беркемгә дә ялганламадым!

Бу хәлгә Сәлим ханның күзләре акайды, ияге күтәрелде.

— Йә-йә, шәех, тагын ни әйтерсең?

— Кызыгыз Назлыгөлгә никахны мин укыдым, ханиям. Мин! Өргәнечтә түгел, монда, Яңа Калада!

Әле генә идәндә аунаган шәехнең кыланышына шаккатмалы иде, тәкәбберлек, горурлык, һавалану үзендә, солтаннардан алган диярсең.

— Кем белән, кайда укыдың Назлыгөлгә никахны, шәех? Ир-егете кем дип белик инде?

— Оста Дәүран, ханиям. Кызың оста Дәүран кулында.

Сәлим хан арыслан кебек бакырып җибәрде.

— Кем дидең? Кабатла, кабахәт, кем дидең?!

— Оста Дәүран, ханиям.

Хәзер инде шәех Тәтеш гаять дәрәҗәдә тыныч иде, аңардан элгәрерәге курку киткән, ул һәр сүзен кисеп куйгандай һәркем ишетелерлек итеп әйтте.

— Ишеттеңме, углан, ишеттеңме ни ди бу кабахәт! Ул минем кызыма колчура Дәүран белән никах укыган! Никах! Онгыгым хакындагы хәбәре генә җитмәгән... Иллә кызым Назлыгөл хакындагы хәбәрең ялган булса, мин сине, беләсеңме, нишләтәм, шәех?!

— Беләм, ханиям.

— Юк, белмисең, белмисең, шәех. Мин сине таштан аттырып үтертәм, таштан! Кая җансакчыларым, кая сез?!— Бүлмәгә ике җансакчы йөгереп керде.— Хәзер үк миңа кала остасы Дәүранны китерегез! Хәзер үк!

— Атам, Назлыгөл анда булса...— Әмир Хаҗиның һаман да хәле

начар иде, әмма хан аны күрмәде, күрер халәттә түгел иде.

— Кызымны да, кызымны да!— дип кычкырды җансакчыларына Сәлим хан.

Акбикә керде, йөзе төнбоек чәчкәседәй саргаеп калган, күзләрендә яшь. Сәкедә утырган әмирне гүя күрмәде дә, Сәлим хан янына узды.

— Атам, олуг хан. Мин иртәгә үк Өргәнечкә китәм, фатиха бирегез.

Сәлим хан иңбашын сикертеп куйды, бер сүз дә әйтмәде, бары тик угланы әмир Хаҗи ягына сирпелеп кенә алды.

— Миннән фатиха, фатиха,— диде һәм бүлмәдән чыгып китте. Атасы күздән югалгач, әмир Хаҗи да кузгалды, шәехне дә үз артыннан кул белән ишарә ясап кына әйдәде.

Күп тә үтми, ханның җансакчылары оста Дәүранны хан каршына китереп бастырды. Останың ике ягында ике сакчы, кыймылдарга да бирмиләр.

— Калдырыгыз безне!— диде хан җансакчыларына кул селтәп.

— Әссаләме галәйкем, олуг хан!— диде оста тыйнак кына баш иеп.

— Хуш, хуш, оста Алпар угланы Дәүран, хуш. Йә, ни әйтерсең ханыңа?

— Әйтер сүземне җиткергәннәрдер инде, олуг хан. Кызганыч, ханиям, каламны салып бетерә алмадым...

— Әһем, каланы матур суктыргансың, күзгә күркәм өйләр бар, мәчет тә күңелемә хуш килде. Әй-әй-әй, атаң игелекле кеше иде, авыр туфрагы җиңел булсын, урынысы оҗмахта булгыры, ә менә син, хан кызын урлап, көчләп никах укыткансың, диләр. Хакмы шул?!

— Олуг хан...

— Тик тор! Мин сөйлим. Телең тешлә! Никахны менә бу шәехтән укыттыңмы? Шулаймы, Тәтеш шәех?

— Көчләп, янап укыттырдылар, ханиям!— диде Тәтеш шәех.

— Никах укыган өчен уч тутырып алтын бирделәрме? Ни белән түләделәр, кем? Оста Дәүран, күпме алтын бирдең?!

— Мин шәехкә бер түгәрәк тә алтын бирмәдем, олуг хан.

— Кем бирде, кем мәҗбүр итте, шәех, никах укырга? Шәех, сиңа әйтәм, нигә телең йоттың?

— Алтынны Җик Мәргән бирде, ханиям. Ул көчләп илтте, ул укырга мәҗбүр итте.

— Әһә, димәк, Назлыгөлне качкын Җик Мәргән урлаган, син түгел? Тархан Әхмәт, Җик Мәргәнне дәшегез!

— Баш өсте, ханиям. Тиздән Җик Мәргән монда булыр.

— Тиз йөр, тархан. Тимерне кызуында сугасым килә.— Хан Тәтешкә таба борылды.— Йә, шәех, никах укыган өчен күпме алтын бирде качкын Җик Мәргән? Оныттың, санарга вакытың булмады? Һай, кем анда, Җик Мәргәнне дә дәшегез! Ул да миңа кирәк...

Сәлим хан угланы әмир ягына карап алды, бераз аптырады, тик аңа әллә ни игътибар итмәде, угланы әмир Хаҗи, дөньядан ваз кичкән берәүдәй, тын гына утыра иде, гүя аңа биредә барган хәлләр кагылмый да иде.

— Олуг хан, шәехнең гаебе юктыр,— диде оста Дәүран.

— Юктыр-юктыр, сез барыгыз да әүлияләр, бер гаепсез изге җаннар. Тик менә җир ничек йөртә микән сезне! Ничек ярылып, убып алмый икән? Җик Мәргән хан кызын урлый, оста Дәүран аңа өйләнә, кол башы белән өйләнә, ә яшь шәех аларга никах укый. Шулайдыр бит?!

— Димәк, алтын биреп янаганнар,— диде баһадир Бачман.

— Булмады андый хәл,— диде шәех.

— Нинди хәл?— дип сорады Сәлим хан.

— Алтын белән янау...

— Мин сезне барыгызны да бер бауга тезеп,— дип башлаган иде Сәлим хан, Акбикә килене аның аяк астына килеп егылды.

— Кылмагыз, атам, бу хатаны. Рәнҗетмәгез кыз баланы. Наз-

лыгөл моны күтәрә алмас. Назлыгөлне мин үзем табырмын.
— Ярый, килен, алып кил Назлыгөлне. Мин сиңа ышанам.
Акбикә чыгып киткәч, Сәлим хан яңа килеп кергән Җик Мәргәнгә төбәлде.
— Инде әйт, Җик Мәргән, ничегрәк урладыгыз хан кызын?
— Без аны урламадык, ханиям, ул үзе килде,— диде Җик Мәргән.
— Үзе килде!— дип шамакайланды хан.— Күл буена төшкәч, илтегез мине оста Дәүран янына, дидеме? Хан колы Дәүран янына, ә?!
— Без барыбыз да алла колы, ханиям. Аллаһы тәгалә кешене кол итеп яратмый. Кешене ханнар кол итә, авыр тормыш, яман хәлләр.
— Әнә ничек икән! Ишетәсеңме, углан? Углан дим?!
Әмир Хаҗи дәшмәгәч, Сәлим хан аңа кул гына селтәде.
— Олуг хан, сөнниләр колга кияүгә чыгуны да, кол хатын-кызга өйләнүне дә гөнаһ санамыйлар,— диде Тәтеш шаех.
— Останы акладык та, ди, шаех. Тик кылган гөнаһың өчен сине кем хөкем итәр икән? Ни өчен димә, авызың ачсаң — язгыгың күренеп тора. Хан колы белән хан кызына никах уку язык түгелмени?!
— Гөнаһ түгел, ханиям. Аннары оста Дәүранны угланың әмир Хаҗи коллыктан азат иткән иде инде. Шәригать, ханиям, сәхилек күрсәтүне хуп күрәдер, оста мөселман, ханнар кайчак кызларын кяферләргә дә кияүгә бирә.
— Әнә ничек сөйләшә башладың син, шаех. Сөбханалла-машалла, үлем алдыннан шулай гайрәтләнәме кеше. Сакчыларым, алып китегез шаехне. Зинданга, барысын да зинданга! Җик Мәргәнне дә, останы да! Иртәгә бөтен халык алдында хөкем итәрмен!.. Тукта, останы калдырып торыгыз,— диде хан.
Алып чыгып китеп барган Дәүран останы яңадан хан каршына китереп бастырдылар.
— Яшь атны өйрәткәндә иң әүвәл нишлиләр, оста?
— Тамга сугалар, ханиям.
— Хак әйттең, оста, тамга сугалар. Атаңа суккан тамганы мин сиңа да суккан кебек идем, оста.
— Адәм баласына тамганы бер хода гына сугадыр, ханиям.
— Хуш, хуш, оста. Атка тамга суккач, янә нишлиләр инде?
— Йөгән кигезәләр, ханиям.
— Ә син ул йөгәнне салырга исәбеңме? Мин кигергән йөгәнне дим?
— Ул йөгәнне ташлар көн безгә дә җитте, ханиям.
— Әһә, әнә ничек икән ул. Телең дә бик озын икән бит синең, оста?!
Оста Дәүран дәшмәде, башын түбән иде.
— Кичерегез мине, ханиям, кичерә алсагыз. Мин Назлыгөлне яратам, ул да мине...
Сәлим хан тәхет бүлмәсендәгеләргә күз йөртеп чыкты. Тышта ниндидер тавышлар ишетелә башлады. Сәлим хан ияк кагып кына ишек янында торган җансакчысына карап керергә кушты. Җансакчысы ялт итеп әйләнеп тә керде.
— Ни анда?
— Җыен җыелган, урам тулы халык, ханиям.
Оста Дәүранны алып чыкканда Сәлим хан аңа карап калды һәм йөрәге кысылып куйды. Оста Дәүранның йөреш-кыяфәтендә Туйбикә гәүдә-сынын күреп, чак кына «кияввен» яңадан чакырып алмады. Туйбикә, Туйбикә, син бит бу, холкың-фигылең, күр инде, төс-йөзеңә, хәтта гәүдә-сыныңа кадәр бу углыңа биреп калдыргансың икән ләбаса. Әллә соң син теләдеңме угылың минем кызыма өйләнсен, дип? Булмас, булмастыр синеңчә, Туйбикә. Сине яраткан идем, яраткан идем... Ә углыңны барыбер Бөек Калага озатырга булыр. Юлда аны арба авыпмы, атлар дулапмы, качып баргандамы үлтерерләр. Ул мине хур итте, рәнҗетте. Үлем аңа, үлем! Назлыгөл аны яңадан күрмәс. Башкача аннан котылыр чара юктыр. Назлыгөл кайгырыр-кайгырыр да онытыр. Үлгән артыннан үлеп булмый. Сөлек түгел, канына ябышмагандыр әле...

— Кем анда, кем?
— Мин бу, атам, мин! Атам!— дип хан кызы Назлыгөл ханга таба китте.— Атам!
— Кызым, кызым, күз нурым, балакаем, Назлыгөлем!
Сәлим хан кызын кочагына алды да күз яше белән елап җибәрде.
— Атам, сине күрер көнем дә бар икән. Анам исәнме, бире килмәдеме? Кендек әби ни хәлдә, кәтиб Хафиз-мөгаллимем? Мине югалттыгыз, югалттыгыз... Атам, мин югалмадым, югалмадым.
— Югалттык, балакаем, югалттык. Иллә ходай бар икән әле, бар икән. Йә алла, күзләремә генә күренмисеңме, балакаем?
— Атам, Дәүран кая? Кайда минем ирем?
— Дәүран минем колым, балам. Кол кеше синең ирең була алмый.
— Ул — минем ирем, атам. Синең колың булса да, ул минем ирем, никахлы ирем!
Сәлим хан кызының кулы белән авызын каплады.
— Әйтмә алай, балакаем, әйтмә. Кешедән яхшы түгел. Син кем? Хан кызы! Мин аны зинданга яптырдым, балам. Ул сиңа тиң түгел.
— Атам!— дип Назлыгөл атасы кочагыннан чыкты да, күз яшен дә сөртмичә Сәлим ханга карады.— Атам, син аны чыгарырсың. Син аны хәзер үк чыгарырсың. Чыгарырсың ич?!
— Ханиям,— диде Назлыгөл янына килеп баскан Акбикә.— Атам, Назлыгөлнең аңардан...
Сәлим хан аяк типте, ачу белән килененә карады.
— Тик тор, килен! Тик тор, дәшмә! Дәшкән бер, дәшмәгән ике откан. Телең тешлә! Бар Назлыгөлне үз ягыңа алып чыгып кит, тынычландыр. Иртәгә, мин аның белән иртәгә сөйләшермен.
Акбикә кисәк сыгылып төшкән Назлыгөлне иңеннән кочып алды да хатын-кыз ягына алып чыгып китте.
— Казыйны дәшегез, казый керсен!— диде Сәлим хан.
Тәхет бүлмәсенә казый килеп кергәч, Сәлим хан чак кына торып басмады.
— Йә алла, казый Нисбах?!
— Әссәламе галәйкем, олуг хан!
— Вәгаләйкем әссәлам, Нисбах! Син һаман исәнмени әле!
— Иллә чыпчык үләме, ханиям. Ә мин — кеше.
— Хәтерем ялгышмаса, мин сине Гали оныгыма бәйләгән идем кебек?
— Ялгышмыйсыз, ханиям. Гали оланга беркеткән идегез. Иллә ул олан мәрхүм инде.
— Һе. Өең, атың-кураң да бармы?
— Угланың әмир Хаҗига рәхмәт, казые итеп тота.
— Хуш, дуга барда — дога бар, диләр. Җомгага да йөрисеңме?
— Йөрим, ханиям. Хөтбә әйткән саен иманым арта бара.
— Казый Нисбах, иртәгә хөкем мәйданына килерсең.
— Баш өсте, ханиям, килермен. Тик кемне хөкем итәргә исәбегез ханиям?
— Анысы синең эш түгел, казый. Хан ни кушса, шуны кылырсың.
Казый Нисбах баш иде, Сәлим хан кул селтәде һәм казый Нисбах чыгып китте. Аның артыннан ишек ябылгач, Сәлим хан үртәлгән бер рәвештә:
— Яман кешеләрне мин куам, син җыясың, углан,— диде.
— Казый Нисбах гадел вә белекле кеше, атам,— диде, ниһаять, әмир Хаҗи, ләкин бер ноктага текәлгән килеш, әйтерсең, атасы белән дә сөйләшми иде.
— Гадел кеше илдән качмый. Гали олан югалу белән бу да юкка чыкты.
— Казый Нисбах, атам, синең тарафтан Гали угланга бәйләүле иде, үзе булмаса, атасына хезмәт итәрмен, дип килүедер.

— Казый анаңа һәрчак каршы сөйләде. Хәер, яши бирсен. Каланда урыслар да урам салып яталар икән.

— Урын житәрлек, салсыннар. Мин аларга кибетләр суктырырга да рөхсәт бирдем.

— Кибетләр суктыр, чиркәү салдырма. Елдан-ел мин шуңа инана барам: халык түгел, диннәр сугыша, диннәр җир бүлешә хәзер.

— Халкы булгач, чиркәве дә булыр инде, анын, атам. Халык имансыз булмый.

Сәлим хан янә бер гаҗәпләнә төшеп, угланы әмир Хаҗига карап алды да, тәхеттән кубып, ишекле-түрле йөренергә кереште.

— Бер ханнан сораганнар, ди. Кем белән табында утырасың?— дип. Ул әйткән: мин кешеләр белән бер табында утырырга яратмыйм, чебеннәр булгач бик җиткән, дигән. Чебеннәр җыясың каланда, углан, чебеннәр, җыен әтрәк-әләм синдә хәзер. Качкыны да, карагы да, казагы да, илдән куылган казые да...

— Атам, берәүдән: «Иң яман кеше кем?» дип сораганнар, ди. Ише аңа әйткән: «Иң яманы җайлап әрли дә, рәтләп мактый да белми торган кешедер»,— дип җавап биргән, ди.

— Һе, углан, мактаргамы миңа сине, яманнаргамы соң?

— Мактауга мохтаҗлыгым юктыр, атам. Ә мәнә яманлаганыңны күп күрдем, шөкер итәрлек булды. Хәер, яманланган эзләнер, макталган тезләнер, ди әнә минем шәех.

— Углан, бер хикмәт иясе: «Акылы таза кешенең тәне дә таза булыр», дип әйтеп әйткән. Икенче берәү исә аңа: «Юк, хәзрәт, теше таза кешенең генә тәне таза булыр», дигән. Син кайсы хаклы дияр идең?

— Икесе дә, атам. Акылы таза кешенең тәне дә, теше дә, зиһене дә таза буладыр. Карт кешенең акылы да зәгыйфьләнер, теше-тәне дә таза булмастыр.

Сәлим хан арлы-бирле йөрүеннән туктады, бүлмәдәгеләргә күз төшереп алды һәм һәммәсенә дә, чыгып китегез, дип ишарәләде. Шуннан соң гына угланы янәшәсенә килеп утырды.

— Углан, оныгым Гали хакында халык телендәге хикәят хак булса, исән-имин илгә кайтса, Болгар тәхетенә ул утырыр. Казый Нисбахны Өргәнечкә җибәр, син теләгәннең барысын да башкарыр, хәтерем ялгышмаса, уттан исән, судан коры чыга торган кеше иде.

— Шулай итәрмен, атам,— диде әмир Хаҗи.

Шул чак сарайга анын җансакчысы килеп керде. Керде дә түргә узды, әмирнең аягына егылды.

— Әмирем, Бачман баһадир ышанычлы меңбашларын алып, Нугай капкасыннан чыгып китте.

Аталы-уллы хан белән әмир күзгә-күз карашып алдылар, әмма икесенең берсе сүз катырга базмады.

— Янында хатын-кызлар да бар идеме?

— Күрмәдем, әмирем.

— Күзле бүкән, югал сарайдан!

Җансакчысы артыннан ишек ябылгач, Сәлим хан сорап куйды:

— Бу ни була инде, углан?— Хан көенергә дә, сөенергә дә белмәде.— Бачман баһадир кая китә, туган ягы Саксингамы, әллә Бөек Калага, олуг хан кул астынамы? Китүе ихлас булса, кирмәндә күп азат калмаячак сыман.

— Бачман баһадир Саксин каласына китәргә күптән сорап йөри иде инде, атам,— диде, ниһаять, әмир Хаҗи.

— Үпкәләгәндер. Баһадир кадәр баһадирны зинданга яптыр инде.

— Бу хәл бары тик миңа гына кагыла, атам. Баһадирның китү сәбәбе башкадыр.

— Кем син, әмирме? Куа кит, җит, орыш!

— Юк, атам. Мин аның белән орышырга теләмим. Бачман баһадир колчура Дәүран түгел.

— Хуш, углан, сабыр итик. Саксин каласы Каф тавы артында түгел, ачыкларбыз,— диде хан һәм иснәп куйды. Гади генә әйткәндә, бу хәлгә хан шат иде. Әмир Хаҗи нык терәге булган баһадир Бачманны югалтты. Киткән кошлар кире кайтса да, аккан бозлар кире кайтмый. Әйе, Бачман ким дигәндә өчтән бер гаскәрен алып киткәндер әле. Димәк, угланны буйсындыру, каласыннан куып чыгару җиңелрәк булачак. Син миңа баш бирми башладың, углан, ә ходай тәгалә моны теләми. Әнә бүген Бачманыңны югалттың, иртәгә Җик Мәргәнең чыгып качса... Ходай бар ул, углан, бар. Бирәсе колына чыгарып куяр юлына, диләр.

## 34

Сәлим хан урамдагы шау-шуга уянып китте. Юрган башын кайтарып, ишек катында басып торган җансакчысына эндәште:

— Нинди тавыш анда? Бар әле белеп кер!

— Мин сезне күптән көтәм инде, ханиям. Халык оста Дәүранны зинданнан чыгарыгыз дип тавышлый. Кичә тархан Әхмәт: иртәгә барысы да хәл ителәчәк дип, аларны тынычландырып җибәргән иде. Хәзер әнә мәйдан тулы халык.

— Тархан Әхмәт тә андамы?

— Аны тыңламыйлар да, ханиям, әмир Хаҗины сорыйлар.

— Мине нигә сорамыйлар?— диде Сәлим хан тора-тора.

— Олуг хан кунак кеше, аның монда ни эше бар дип кычкыралар.

— Кара халык — кара сарык. Һәй, кем бар анда! Киемнәрем китерегез, таз-комган!

Кулына таз-комган, иңе аша сөлге ташлаган асрау керде.

— Йә-йә, якынрак кил, котың алынмасын, мин кеше ашамыйм,— диде Сәлим хан, асрау кызны күз-баштан уздырып.— Кем җибәрде сине? Атың бармы?

— Асрау мин, ханиям. Атым Зәмзәмбикә.

— Зәмзәмбикә,— диде Сәлим хан бит-кулын юып, асрауның иңендәге сөлгене алгач.— Исемең матур, татлыдыр. Үзең дә шулай татлысыңдыр әле?

— Татлы булып кына кияү чыкса икән ул, ханиям.

— Сөбханалла, сөбханалла, кияүгә чыгасың киләме?

— Нинди хатын-кыз кияүгә чыгарга теләмәс икән, ханиям.

— Чык минем вәзиремә. Үзем димлим. Кыяфәте килешсезрәк, иллә аю түгел, адәм баласы. Аюга да кияүгә чыгалар.

— Бикә җибәрсә, чыгар идем, ханиям,— диде асрау кыз.

Сәлим хан янә асраука күз төшереп алды. Гәүдәсе тутырган тавык кебек таза, биле булмаса да, күкрәкләре аллага шөкер, бүрек хәтле. Вәзир Камай өчен туган бу фәрештә. Әллә соң өйләндеримме үзен?! Үзе кая икән соң, кая йөри икән күзле бүкән! Кичә булып кичә күренмәде? Сәлим хан җансакчысына карады.

— Вәзир Камайны дәш.

— Вәзир Камай халыкны тыя, ханиям.

Бүлмәгә әмир Хаҗи килеп керде, тыенкы гына исәнләште.

— Атам, халык мине сорый, оста Дәүранны зинданнан чыгарсын әмир, дип кычкыра. Ни кылыйм?..

— Әүвәл атаңны ашатыр идең, углан. Халык качмас, атаң ач калмасын...

— Табын әзер, атам, рәхим ит,— дип, әмир Хаҗи атасын түр якка әйдәде.

## 35

Әмир Хаҗи халык каршына атасы олуг хан белән бергә чыкты. Тоташ бер дулкын булып, мәйдан тулы халык шаулый, хан белән әмир күренгәч, шау-шу басыла төште. Әмир азатлары халыкны хан белән әмир чыгып баскан болдыр янына якын җибәрми, тоташ ихата булып басканнар да, әрсезләнә башлаганнарны этә-төртә читкәрәк куалар. Уң якта әмир Хаҗи боерыгы белән салкын таш[1] ясалган, Сәлим хан шунда атлады. Ул Яңа Казанда бернидән дә курыкмый иде. Халык арасында меңбаш Таймас кешеләре. Хан турында яман сүзләр кычкыручыларны алар соңыннан булса да җыярлар. Баш кисеп кылыч тутыкмый. Мәйданга таба алдан киткән хан, артына әйләнми генә, угланы әмирдән сорады:

— Оран салучың бармы? Оран салучыңны дәш!— диде.

Оран салучыны шундук хан янына китереп бастырдылар. Кирәкмәгән дәү гәүдәле, озын сакаллы оранчы хан янына килеп басуга, халык тынып калды. Халык арасыннан берәү:

— Хан, хан, оста Дәүранны нигә зинданга яптыгыз!— дип кычкырды.

Сәлим хан бер тын дәшми торды, оран салучы ханның авызына баккан да нидер көтеп тора. Бу тамаша халык алдында кызына ата-ана рөхсәтеннән тыш өйләнгән останы хөкем итү ярармы?.. Сәлим хан тирәягына каранды, давылбазчылар, җәллады һәм казый Нисбахны күреп, янына дәшеп алды.

— Казый Нисбах, ни кылабыз?

— Дөресен әйтәбез, ханиям. Халык барысын да белә.

— Оранчы,— диде Сәлим хан.— Кычкыр. Кол буларак, оста Дәүран хан кызын урлаган һәм аны көчләгән, диген. Кычкыр, кычкыр!

Оранчы хан сүзләрен кычкыргач, халык бермәлгә тынып калды. Үзара бәхәсләшә башладылар, ыгы-зыгы китте. Нисбах казый, хәйләкәр төлке, эшне дөрес башлап җибәрде, әлбәттә. Яман сүз — бәхәс тудыра. Халык арасында шәригать кануннарын белүчеләр бар. Ә хатын-кызны көчләү шәригатьтә яман эш. Иллә халык ышанмый иде булса кирәк, әйе, ничек инде әүлия кебек оста хан кызын көчләсен икән?

— Казый Нисбах,— диде, ниһаять, арадан берсе.— Ничек көчләде икән хан кызын оста? Хан кызы Бөек Калада, оста Яңа Калада...

— Урлап, урлап!— дип кычкырды ханның оранчысы.

— Ялган! Җәмәгать, халаяк, булган хәл түгел бу! Кызның үзен китерсеннәр, үзен!

— Чынлап та кара сарык, кара халык икән шул. Менә хикмәт. Оранчы, хан кызы авырта, дип әйт. Авырта ул, халык алдына чыга алмый,— диде Сәлим хан.— Ә менә останы китерербез.

Оранчы хан сүзләрен кычкыра торды, халык шаулый торды. Ул да түгел, оста Дәүранны җилтерәтеп мәйданга алып менделәр.

— Оста,— диде казый Нисбах.— Сине хан кызын көчләүдә гаеплиләр. Көчләп урлап алып килгәнсең, көчләп никах укыткансың. Акланыр әмәлең бармы?

— Юк, казый. Минем беркем алдында да акланасым килми, чөнки минем гаебем юктыр. Хан кызына мин яратып өйләндем.

— Атасы-анасы рөхсәтеннән башка, шулаймы?

— Казый, ул мине, мин аны ярата идем, без кавыштык. Шәех безгә никах укыды. Бу хәл гөнаһмы?

— Гөнаһ түгел, оста. Тик кызның ата-анасын рәнҗетмә. Шәригать кушканча булсын, яучы җибәр, ата-ананың ризалыгын ал.

— Шәригать канунын мин бозмадым, казый, никах укыттым. Мин

[1] Салкын таш — җәзалау урыны.

берәүгә дә явызлык кылмадым. Барысы да гайбәт, мин хан кызын урламадым, ул үзе бире килде, никахны үзе теләп укытты. Дөньяда дүрт ялганчы яшәр, ди: берсе әләкче, берсе гайбәтче, берсе шымчы, берсе дошмандыр. Ләкин хаклык аларны да җиңә икән. Ә менә дүрт кешене хаклык җиңә алмый: берсе казый, берсе вәзир, берсе шәех, берсе...

— Берсе ханмы, әмирме, оста?— дип сорады Сәлим хан.

Оста Дәүран Сәлим ханга кулын күкрәгенә куеп баш орды. Сәлим хан «кияве» кыланышында янә Туйбикәсе чалымнарын күреп, әллә нишләп китте.

— Кичерә күрегез мине, атам. Мине бу сүзне әйтүдән мәхрүм итттеләр. Ләкин кызыгыз белән никахлашкач, сезгә «атам» диеп әйтергә хакым бар, дип уйлыйм. Шәригать кануннарына хан да, оста да бер чамада буйсынадыр, дип уйлыйм мин, ханиям.

— Җәллад, җәллад кая! Оста Дәүран гөнаһлыдыр!

— Хан, оста Дәүранның кылган языгы юктыр,— диде казый.

— Алыгыз бу күзле бүкәнне!— дип кычкырды хан җансакчыларына казый Нисбах ягына күрсәтеп.— Зинданга, зинданга үзен!

— Атам, тыел!— диде әмир Хаҗи һәм ханга таба ымсынып куйгандай итте, ләкин аны каяндыр килеп чыккан җансакчысы туктатты.

— Кирәкми, әмирем!

Сәлим хан берәүне дә күрмәде дә, берәүне дә тыңларга да теләмәде, останың кулларын бәйләргә кушты һәм җәлладка:

— Җәза шул аңа, шул. Чап башын, юкса үзеңнекен чаптырам!

Ул арада давылбазчылар дөңгер кага башлады.

Сәлим хан аста торучы меңбаш Таймаска үзләре генә белгән ишарә ясады, шундук мәйданга егермеләп кеше күтәрелде. Ләкин җәллад аларның берсенә дә игътибар итмәде, ул үз эшен әйбәт белә иде, күрәсең, останың күзен бәйләде дә салкын ташка башын салырга кушты. Шуннан соң гына ханга карады. Янәсе, мин әзер, бир әмереңң, хан.

Шул мәлдә җәлладның аркасына ук кадалды, җәллад капчык кебек бер якка ава башлады. Нииндидер мизгелдә генә югалып калган Сәлим хан ишелеп төшкән җәлладның кулыннан кылычын тартып алды да кизәнде. Кылычка ук тигәнне, кулыннан кылычның ычкынып киткәнен Сәлим хан сизми дә калды. Оста янына җансакчысы килде, тегенең бәйләгән чүпрәген йолкып атты, кулын чиште. Шул чак мәйданда Зәйтүнә пәйда булды.

— Оста Дәүран, әйдә, тиз!— диде ул. Дәүранның кулыннан алды да халык арасына алып кереп китте.

— Тотыгыз, тотыгыз үзләрен!— дип кычкырды исенә килә башлаган Сәлим хан. Ләкин аны берәү дә тыңламый иде инде. Каршы өй түбәсендә Җик Мәргән күренде.

— Сәлим хан!— дип кычкырды ул бугаз ертып.— Кузгалма!

Меңбаш Таймас кешеләре уратып алган Сәлим хан каршы өй түбәсендәге Җик Мәргәнне күрде. Хан белә иде: кирәк икән, кешенең күзенә тигерә ала ул, мәргән атын үзе бирде ул аңа!

— Кан коймый гына каладан чыгып китсәң иде, ханиям.

— Коралга!— дип кычкырды Сәлим хан һәм күз ачып йомганчы оранчы артына посты.

Шул мәлдә үк оранчының күкрәгенә мәргәннең угы кадалды. Меңбаш Таймасның азатлары ханны каплап, әмир өенә алып кереп киттеләр. Сарай ишекләре бикләнгәч, Сәлим хан меңбаш Таймаска кызы Назлыгөлне һәм асрау кыз Зәмзәмбикәне Кабан күле буена алып төшәргә кушты, ә үзе яшерен юлдан Арча капкасына юнәлде.

Меңбаш Таймасның гади киемгә киенгән азатлары Кабан күле буендагы чатырына китереп җиткергәндә көн төш вакытыннан авышып бара иде инде. Чатырына керүгә, түр якта, үзенең мендәренә кырын төшеп, кымыз чөмереп яткан вәзирен күрде дә Сәлим хан яшелле-зәңгәрле тавыш белән бакырып җибәрде.

— Хайван, капкорсак, бирән беткән, мин анда кыл өстендә йөрим, син кымыз чөмереп ятасың. Яу, яу чык калага! Халык баш күтәрде. Асарга, кисәргә, турарга, ут салырга калага, ут!

Вәзир Камай ничек торганын, ничек чатырдан чыгып киткәнен, күл буенда балык тотып утырган Баян баһадир янына ничек килеп җиткәнен сизми дә калды. Ул тотлыга-тотлыга баһадирга хан боерыгын җиткерде. Һәм иярләгән атын чатыр янына Сәлим ханга илтергә кушты.

Күп тә үтмәде, кунакка алып килгән гаскәр, кирмән янына җитте, меңбаш Таймас кулга төшергән Арча капкасы аша калага тула башлады. Китте калада гаебе булганны да, булмаганны да кадау, кисү, укка алу. Әмир урамына ертаюл азатлары белән хан үзе беренче булып килеп керде. Монда халык сарайның ишекләрен ваткан, эчкә кереп бара иде. Урамны иңләп килгән хан азатларын күрде дә, халык кача башлады. Хан аларны турарга, чәнчергә боерды. Урам үле гәүдәләр белән чуарланды, чыр-чу, аһ-ваһ килә-килә халык йортларга тулды, биек коймалар аша ишегалларына сикерде. Күп тә үтмәде, хан азатларына таш ява башлады, каршы торучы кораллы кала кешеләре күренгәләде.

Сәлим хан угланы әмир өенә җитте. Ханның ике ягында да кисәү агачы тоткан азатлар. Ханның бер сүзе белән азатлар әмир өенә ут салачаклар иде. Болак буендагы урамнарда ялкынлап өйләр яна башлаган иде, күрәсең, шул яктан төтен исе килә. Икеләнүе шуннан иде Сәлим ханның: Назлыгөлен алып китеп өлгердеме икән меңбаш Таймас? Алып китмәгән хәлдә ушбу өйдә үз кызын яндырачак иде. Хәзер инде хан угланы һәм килене Акбикә турында уйламады. Баш киселгәч, бүрек турында кайгырмыйлар.

Сарайның капкалары кинәт ачылды, хан азатлары каршында баһадир Бачман азатлары пәйда булды. Алар күп, ишегалды тулы иде, хан янында йөзләп азат кына, Баян баһадир Болак буйларын яндырып йөри. Сәлим хан Бачман баһадирның азатларын да, баһадирның үзен дә белә, үзеннән өч-дүрт тапкыр артык дошманга каршы барып та җиңгәне бар. Кайдандыр атка атланган угланы әмир Хаҗи килеп чыкты, ул атын юырттырып, атасы янына килде.

— Атам, син калама килеп зур гөнаһ кылдың. Каламны яндырырга керештең, кан койдың. Синең, атам, моннан китүең хәерлерәк булыр. Азатларыңны калдырырсың. Явызлык — явызлык китерәдер. Җик Мәргән, урап алыгыз хан азатларын!

Шул чак чаптырып меңбаш Таймас килеп җитте. Аның белән йөзләп азат иде, Сәлим хан кылычын күтәрде.

— Алга!

Суеш, кырыш китте. Әмир Хаҗиның атын кысрыклап, сарай дивары на китереп сыладылар. Кемдер аңа сөңге атты, әмир чак кына тайпылып өлгерде. Шулай да хан азатларын Җик Мәргән азатлары урап алганнар икән. Хан уртада калган.

— Хан, Җик Мәргән минем киявем, син аңа тимәссең!— диде әмир Хаҗи.

Өермәдәй килеп чыккан Баян баһадир азатларын күрми калдылар. Җик Мәргән алыпларына ике якка орышырга туры килде. Алай да алар бирелмәде, көч туплар өчен урамның мәчет башына таба чигенде. Әмир Хаҗи да алар арасында иде.

— Алга, ур-ра!— дип кычкырды әмир. Аларны куа килгән Баян баһадир азатлары кисәк туктап калдылар. Әмирнең көчен беләләр иде, күрәсең. Шул чак баш очында кылычын болгый-болгый алар янына Сәлим хан килеп җитте. Ханны унлап җансакчысы урап алган иде.

— Туктагыз, тукта!— дип кычкырды тамагы ертылыр дәрәҗәгә җитеп Сәлим хан.— Туктагыз, кан коймагыз!

Кылыч-сөңгеләрен, чукмарбашларын әзер тоткан азатлар бер мәлгә тынып калды. Баян баһадир чаптырып хан янына килде.

— Ханиям, баш күтәрүчеләрне Кабан күле янына җыйдык.

Моны ишеткән Җик Мәргән чаптырып, хан янына килде.

— Баян баһадир, син аларны азат итәрсең. Хәзер үк ямчың аша боерырсың да өйләренә кайтарып җибәрерсең!— диде.

Орыш, кисеш, чәнчешне күп күргән Баян баһадир тирә-якка күз төшереп алды һәм өй түбәсендә җәясенә ук салып торган әмир азатларын күрде дә, янындагы таныш йөзгә игътибар итмәстән, ямчысын чакырып алды һәм кычкырып боерды:

— Кабан күле буендагы баш күтәрүчеләрне өйләренә кайтарып җибәрергә! Хан әмере!— дип кабатлады.

Сәлим хан баһадирының әмерен раслап, ияк кенә какты.

— Ханиям!— диде Җик Мәргән.— Мин сезгә сөенче әйтәм. Янымда кем торуын күрәсезме? Апанай. Ул сезгә сөенче китергән. Урыс кенәзе Олы Оя Всеволод кул астындагы ишләре, кыпчак ханы Янтак вә энең Мөхәммәтгалимбәк белән Болгарга яу чыккан. Кенәзләр Идел буйлап корабларда төшә, кыпчаклар яр буйлап түбәннән менә. Сезгә, ханиям, тизрәк Бөек Калага кайтырга кирәк. Ашыгыгыз! Апанай, расла сүземне.

— Кодрәтле хан,— диде Апанай. Шулчак Баян баһадир азатлары арасыннан берәү аны укка алмакчы итте. Иллә өлгерә алмый калды, үз аркасына ук килеп кадалды. Азат ияреннән сүзсез генә ишелеп төште. Сарай ишекләре ачылды, аннан утызлап укчы чыгып басты, җәя керешләре тартылган, хан җансакчыларына төбәлгән иде. Укчылар арасында Бачман баһадир сеңлесе Зәйтүнә дә бар икән, ул алгарак чыкты да:

— Кергән капкадан чыгып китүегез хәерлерәк булыр, ханиям!— диде.

Ханның җансакчысы ирдәүкә кызны укка алырга итте, әмма өлгерә алмый калды. Үз аркасына ук кадалган җансакчысы да ияреннән ишелеп төште. Сәлим хан хәтта аңа таба әйләнеп тә карамады, ат башын каерып борды да Нугай капкасына таба чапты. Аңа Баян баһадир азатлары иярде.

*Беренче кисәк бетте.*

# ШИГЪРИЯТ

## Флера Гыйззәтуллина

### Йөрәк тавышы

Йөрәгемдә ачыш ясап киләм
Мин дә, дуслар, ничә ел аша:
Сугыш йоткан бала чагым елый,
Дөнья елый — йөрәк еласа.

Зур дөньяга калкып чыга алам,
Үз дөньямның көен көйләсәм.
Дөнья күзлегеннән көнгә багам,
Йөрәк тавышым белән сөйләшәм.

«Туктал эштән, туктал җырлаудан», дип,
Боерыр бәлки берәр эшлексез.
Туктап калсам әгәр, дөньядашлар,
Кичерерсез мине ничек сез?

Мин үземне ничек кичерермен,
Төшеп калсам гомум фикердән?
Үземчәлек, дөньячыллык белән
Берәүгә дә зыян китермәм.

Эшсезлекне күрәчәккә такмам,
Сөйләр телен ватмам сүземнең.
Ни күрсәм дә, каян килсәм дә мин,
Язмышымнан киләм үземнең.

Бер өзлексез ачыш ясап киләм,—
Кылган гамәлләрем халкымча:
Ватанымның чал тарихы балкый,
Дөнья балкый — йөрәк балкыса.

❋

Биеклектә басып торган килеш,
Биеклекне эзләп тәкать корый.
Шигырь язып рәхәт чиккән саен,
Кешеләргә күңел шәфкать юрый.

Эшли-эшли алҗып беткәчтен дә,
Кеше эзли күңел, кеше көтәм.—
Бу соң гади кеше көче микән,
Әллә үлемсезлек төсе микән?

---

Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА — *шагыйрә, «Чишмә юлы», «Сәлам хаты», «Акчарлагым — асыл кошым» һ. б. шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

❁

Су буйларын күп буйладым инде,
Күп тыңладым былбыл сайравын.
Әмма үзем бер дә сөеклемә
«Былбылым!» дип әйтә алмадым.

Су буйларын күп буйладым инде,
Күп сер багышладым суларга.
Ул өлгергән китеп, мин килдем — тик
Суга карап ямансуларга.

Су буйларын күп буйладым инде
Мәхәббәткә эзләп тирәнлек...
Чал дукыннар булып судан утка
Сикерергә без дә өйрәндек.

❁

Илгә миһербанлы һәркем
Тотадыр истә моны:
Ил даны белән бертуган
Вөжданның чисталыгы.

Туган иле дә төс бирми
Вөжданы кысыр җанга.
Күкрәк көчендә яулана
Вөждан да, миһербан да.

❁

Тыйсалар әйтер сүземне,
Бирмәсәләр эшләргә,—
Хокукым даулап ташландым
Мин зур бәрелешләргә.

Сөйләр сүзем, эшем белән
Калмадым камалышта:
Иҗат ирегемнән киләм
Бүгенге ярышка.

❁

Бәхетемә уза алмыйм
Су аша, басма аша,—
Сердәшем суга таш ата
Басмага баса-баса.

Күзәтә тымызык суның
«Бәхетле күзәнәг»ен.
Төшенми аткан ташының
Бәхеткә төзәлгәнен.

Атышу хакын, таш хакын,
Һай, кыйммәт түләр әле...
Таш тигән саен кителә
Бәхетнең түгәрәге.

❁

Уңга багам, сулга багам,
Алга барам ашыгып.
Бу дөньяда очрап тора
Адым саен яхшылык.

Уңда кала, сулда кала
— Саумы? — дип дәшүчеләр.—
Сүзләре белән дөньяга
Яхшылык чәчүчеләр.

Уң якта якты елга бар,
Сул якта кара урман.
Кемнеңдер яхшы баласы
Барадыр яман юлдан.

Кемнәрдер яхшы-яман йөк
Төйидер пароходка...
Яхшысы — яманы белән
Дөньябыз бара «ход»та.

Барышны, «ход»ны як-якка
Башланса каерулар,—
Авырга килә яхшыны
Яманнан аерулар.

## Керфекләр чыклы чордан

Үзләрен бәхет, тылсымнар
Ышыклап торгангамы,—
Хыялда балкып утыра
Абага урманнары.

Белмичә тылсым утында
Җемелдәп яначагын,
Калды бит шушы урманда
Минем дә бала чагым.

Шигырьгә күчкәннән бирле,
Мин гүя утлы урман.
Шаулыйсы тылсымнарым да —
Керфекләр чыклы чордан!

Куша чор: кирәк сүзеңне
Соңармый өлгер әйтеп...
Сугарам һәрбер хәрефне
Керфектә мөлдерәтеп.

Хыялым мине алдаса
Чәчәген ата-ата,
Тормышның ялганы белән
Киләм якага-яка.

Көттерми, минем җиңүне
Расларга килә вакыт,
Чәчәктә йомылып калган
Сабый чаклардан калкып...

❁

Тою, юрауларым — юшка килә,
Күрәзәлегем бар минем дә:
Төшләремдә ут чыкканын күрсәм,
Гашыйк була идем өнемдә.

Кабат кайнар сөю газабына
Салыр инде мине бу янгын:
Наз сурәте чиккән ак пәрдәмдә
Ут үрләвен күреп уяндым.

## Йөз аклыгы кирәк

Юлда буран купкан көннән башлап
Туктамыйча дөрләү, янудан,
Мин бит сине кышкы сагыш белән,
Ярсу язмыш белән сагынам.

Ярсу бураннарга үз каныннан
Өстәмәгән килеш бер нәрсә,—

Кемдер минем шушы язмышымнан
Кара көнләү белән көнләшә.

Кем сабыша сагыну тугрылыгын
Сизмәгәнгә, танымаганга,—
Аларны да терким язмышка мин,
Күрәчәктән табып алам да.

Аларның да саклыйм хәтерләрен
Җан көчемдә, хәтер көчемдә.
Йөз аклыгы кирәк — язмышларга
Язмаганны әйтер өчен дә.

## Кулларыңда киләм

Бик үтенәм — матур күзләреңне
Тәгәрәтмә түбән.
Синең күз караңда — мин үземнең
Рәсememне күрәм.

Күрәм, миннән бер дә кызганмыйсың
Кызгануларыңны.
Әйтмәдем дә ич мин, каян белдең
Сызлануларымны?

Син яшь, ләкин мине юатасың
Ярдәмнәрең белән.
Кулларыңда киләм — беләгеңнең
Талганнарын беләм.

❁

Узар юлларыма бер карасам,
Йөз кат хисап бирәм узганыма.
Узган көннең күргән рәхәте дә,
Авыр михнәте дә кызгандыра.

Узганымда — киләчәгем яши,
Яшеннәре яшьни кочагымда...
Йөз кат күзаллаган күрәчәгем
Якты киләчәккә ышандыра.

❁

Холкын мактап, ай-кояшын мактап,
Йолдызларын күзгә каратып,
Без дөньядан тулы бәхет көттек,
Зур ярату көттек һәрвакыт.

Дөнья кочагында ярлар сөйдек,
Ир көйләдек, бала биләдек.
Үзебез күрсәк, дөнья күрде безне,
Сердәш булып йөрде «ияреп».

Безнең белән ул карурман кичте,
Чыгар өчен якты көннәргә.
Үзебез мәңге яшәр дөнья бит ул,—
Тигез тотыйк аны иңнәрдә.

## Киләчәккә таба

Мин киләмен,
Янәшәмнән килә
Җандаш дустым, кандаш туганым...
Яуда түккән канның арзаны юк,
Туганлыкның чиге юк аның.

Киләчәкнең бикле ишеге юк,
Сукмагы юк палач таптаган.
Саклап йөртү өчен әсире юк,
Тентеп кертүче юк капкадан.

Анда һичкем уран урмый әле,
Ярылырга тормый атомнар.
Гайбәт белән дөнья буталмаган,
Тол калмаган гүзәл хатыннар.

Саксыз эшкә, затсыз товарларга
Сугылмаган сыйфат билгесе.
Яуган яңгырларда — йолдыз төсе,
Искән җилдә — чиста гөл исе.

Әмма бу киләчәк шундый сизгер:
Кемлегеңне бик тиз тоючан.
Гөлләр сулса — җил дә сагаючан...
Сез уйчанга, дуслар, мин уйчан.

Әмма киләчәккә өметем ак,—
Сезнең намус пакъка күрәдер...
Гөлчәчәксез, киләчәксез язмыш
Кайсыбызга безнең кирәгер!?

## Роберт Әхмәтҗанов

### Тукайны эзлим

Дөнья буйлап аваз салып барам,—
мин Тукайны эзлим телләрдән;
яшәлмичә калган гомерләрдән,
тау-тау китап янган көлләрдән...

Ут актарам — зөбаныйлар оча!..
Бүгенгегә кучә хәтерләр.
Эзләмәсәк бүген Тукайны без,
туар чорлар нәрсә әйтерләр?!

Тавышы кая аның, әйтегезче,—
ник тындыгыз, көйсез җырчылар?
Үзе исән чакта болай тентеп
эзләмәгәндер лә шымчылар!..

Эзлим аны бөтен кыйтгалардан,
укучы һәм шагыйрь булып та.
Үзе белән фатихасы кирәк,
кирәк миңа шушы минутта!

Кирәк миңа анам сөте хакына,
иман иңсен өчен нигезгә,
Балыкка — су,
кошка — канат кебек,
һава кебек кирәк ул безгә!

Гизәм дөм-дөм Кырлай урманнарын,
Казаннардан эзлим, Җаектан...
Тавышы кая аның? Шигъриятем,
анам теле әллә саеккан?
Дәверләргә тирән кергән саен,
җырларымның моңын азсынам.
Ераграк киткән саен миңа
Тукай биргән тылсым аз сыман.

Дөм-дөм урманнарны гына мени? —
эзләп барам гомер үтәли!
Клячкинның ачам ишекләрен:
тыны бетеп кемдер ютәлли!..

---

Роберт ӘХМӘТҖАНОВ *(1935) — шагыйрь, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән («Кызыл усаклар», «Идел-йорт», «Гомер тирәге» һ. б.) уннан артык китап авторы. Казанда яши.*

И мөкатдәс моңлы сазым минем,
хәзинәбез китә Тарихка.
Без Тукайны алып кайтыйк, шигырем,
үткәннәргә чаклы барыйк та!

Кочак җәеп көтә аны халкым,
көтә шигырь — нокта куймаган...
Чорлар буйлап барам Тукайны эзләп.
Табуыма өметем җуймаган.

Өметемне, шөкер, җуймаган!

## Кайтаваз

*Шагыйрь Хәсән Туфан һәм репрессия корбаннары истәлегенә*

...Кайтып житте бугай!.. Алда — Идел.
Кычкырды ул аргы ярларга.
Тавышы булмаса да, кайтавазы
ишетелер җаны барларга!

«Чәчәк аткан ласа туган ярлар!
Сездән, гөлләр, ерак кителде...»
Ышанмыйча, аң-таң булып торды
бер Фәтхулла хәзрәт шикелле!

Чал чәчләрен сыйпый Идел җиле,
шаулый таллар — аны сагынган!
«Сагыну тулы йөрәгемне, канәт,
алып кайттым Себер ягыннан.

Төштә түгел бугай, сезне уйлап,
далаларда учак якканым?..
Ардым бугай, яшел чатырыңда
ял иттерче, сеңелем, ак каен!

Ялалардан мине яклый алдың
бер син генә, җирем, син генә!..»
И йөгерә җилдә ромашкалар,
акчарлаклар куна иңенә!

«Бу төшемме, юк ла, бар иде лә
тайгак кичүләрең, Ватаным!
И Шигърия, зынҗыр кыса җанны,
әмере белән «бөек ата»ның!..»

Гаебең юкмы? Кирәк булса — табылыр!
Гаепле син — илең сөйгәнгә!..
Баш имәгән күпме пакь җаннарның
каны тамды бетон идәнгә!
Җиңгән кыяфәттә әйтте аңа
беләкләре йөнтәс абзыйлар:
«Бу шагыйрьләр — ахмак! Каләм белән
үзләренә кабер казыйлар!..»

Көчләп кулга каләм тоттырдылар,
бер-бер артлы биреп боерыкны:
— Мин Кировны үтердем, дип яз син,
үтердем, дип, яз син, Кировны!

Ә язмагач, янә йодрык белән
суктылар да егып аяктан,
күтәрелгәч, тагын сугып егып,
күтәрделәр кабат бер яктан...

«Нинди вәхшәт! — диеп сыкрады җан,—
социализм җиңгән илдә дә!..»
Кайтыр кошлар... Канат очларыннан
каннар тамар
Черек Күлгә дә...

Кар сахрасын үтеп китте шулай,—
җан богаулы,
салкын ятаплар...
Сакласа тик халык хәтәре саклар,
сыйдыра алмас моны китаплар!..

...Кайтып җитте бугай... Бу — төш түгел!
Кычкырды ул аргы ярларга!..

Идел өсләрендә кайтавазы...
Бу — кисәтү
җаны барларга!..

## Сәхнәдән китү

Сәхнәдән
җиңел китү рецепты юк
(мөмкин аннан егылып төшү дә!).
Уйнадыңмы, я хуш, юлыңда бул,—
тормыш та уйнады җитәрлек!
Инде хикмәт —
вакытыңны, дәрәҗәңне белеп,
сабырлыкка күчүдә.

Бик беләсең,
елмайганда сиңа бүген яшьләр,
син аларның түгел күптән кумиры.
Кабул ит тә, бәхиллә син —
бары шулай,
тик шыңшыма!
Мәңге түгел кояшның да гомере!

...Сәхнәдән китү, дустым,
ташлап авыр перчаткаларын,
рингтан киткән боксер кебек,
иелеп йолдызларга табынган,
яшь көчләргә сәҗдә кылган,
тулган айга мөкиббән булып утырган
дәрвиш сыман...

Хәерле юл!
Юлларыңа — ак әскәтер!

Тик бер теләк онытылган:
бәхил, туган!
Кайт яңадан, диеп сиңа
кайсы әйтер?..

## Казан гүзәле

*«Мәгълүм булганча, Казанда гүзәллек конкурслары бара...*
*Икенче турда гүзәлләр саны күпкә кимеде...*
*Тиздән «Казан гүзәле»нең исеме билгеле булачак».*

«Татарстан яшьләре» газетасыннан.

/зәллеккә пәрдә ачык бүген:
ілкый сәхнә — кызлар-сылулар!
күңелле чәчәк атулары!
1 моңсудыр гөлдәй сулулар!..)

әр чибәрнең, шәхси язмышыдай,
з номеры үзенә тагылган.
йтә берәү: «Абау, туганда ук
әрештәнең кулы кагылган!..»

– Кай чишмәнең суын эчкән болар?!
у матурлык безгә күчмәгән...
– Иделкәйнең суын эчкәннәрдер.
[ без эчкән шул ук чишмәдән.

– Карбыз түгел, ярып карап булмый,
үзәллеге бармы эчендә?..
– Чикләвекнең (хәер, тешләр үтми)
өгънәсе шул аның — төшендә!

) конкурс кыза, сайланалар,—
ирәкләнә бара гүзәлләр.
Гормыш сәхнәсендә сайланырлар,—
өшеп калганнары — түзәрләр!..

Сылуларның кала сылулары,—
сылулардан бар бит сылулар!
Мең карашны шулай күтәр әле!
Кыендыр ул сылу булулар?!

Гүзәлләрнең саны кими һаман,
арта бара кызыксынулар.
Тормыш конкурсында булмас әле
авыз ачып карап торулар!

Кемнәрнеңдер алар сөйгән яры,
(танышкандыр бары күз күреп);
Сыналырлар килен булып төшкәч,
сыналырлар бала үстереп!..

Сайланырлар һәм... сайларлар әле,—
гүзәлләр ул оста сайларга!..
Хатын-кызның холкы ирләр затын
адаштыра әллә кайларда!

Башын җуя шул матурлык өчен,
йә рухланып аша күкләргә!
Җирдә яңа легендалар кала,
сабак булып кала күпләргә!..
...Бүген алар Казан сәхнәсендә
(чыккан алар күбесе авылдан),
Һәр гүзәлнең, шәхси номерыдай,
үз бәхете үзенә тагылган!
Гүзәлләрнең саны кими бара...
(Кем калыр соң? Күңел, түз әле).
Күз тидермик!
Сөйгән ярына гына
мәгълүм булсын
«Казан Гүзәле!»

❁

Патша да һәм
президент та була алмыйм,
хәер, булалсам да
булмас идем —
иркем бетә,
мин — табигать улы,

аерылмыйм табигатем карыныннан!
Ак манжетлы җиңем канга буялмасын,
алтын тоткан бармакларым
тартышмасын,—
адәмнәр җанына кагылышым юк!
...Кармак белән,
таллар арасыннан,
агып яткан исемсез инешләрдән
чәнчә бармак буе комкорсаклар,
аллы-гөлле шарлама
балыклары тотып
куанам мин...
Яныма гына
шәхси вертолетым килеп төшә —
тал яфрагында
ефәк канатлы ... энә карагы!
Яланаяк
барам дөнья буйлап.
Барасы юл, шөкер,
бар әле!..
Юл уңае, ябалдаштан өзеп,
алма өзеп тешлим шартлатып.
Базарларда сатулашам,
гадилегем белән катлаулы мин:
олы дөнья
карап тора миңа
шаккатып!

❁

Мактауларны, ялган шөһрәтләрне
ташлап чыгам таллар янына,
тыңлыйм җилне,
олы мәгънә белән
ишетәм шунда бер өн —
иске зират якларыннан,
йолдыз асларыннан
килә бер өн, җил шавына кушыла,
иңә җанга:
онытма син
туган анаңны,
нигезләрне,
гомерләрне!
Онытылма, кызыгып,
дискотека сыман
тормыш ыгы-зыгысына,
шау-шуына!

Син шаһит бул
фани белән мәңгелекнең
кавышуына!

## Чәчмә әсәрләр

**Фәүзия Бәйрәмова**

# КЫҢГЫРАУ

ПОВЕСТЬ

### Төннең беренче яртысы



Бүген авылда мәктәпне ябалар...

Ябалар дип әйтү дә бик үк хак булмас, дөресрәге, сүтеп, күрше авылга күчереп салалар. Нигез ташларына хәзергә кагылмаска булганнар, бүрәнәләре терлекчеләр йортына китәсе, ди. Өйләдән соң сүтә дә башламакчылар икән...

Айсылу карчыкка боларны үги улы Касыйм кайтып сөйләде. Балалар күрше авыл мәктәбенә йөриселәр икән. Өлкәнрәкләр инде күптән шунда укыйлар, кечкенәләр өчен Өтернәстәге шушы башлангыч мәктәп тә ярап тора иде әле. Аны да ябасы иткәннәр...

Өйләдән соң сүтә башламакчылар, ди. Сүтә... Бүрәнәләре кирәк булгач, алай ордым-бәрдем генә кыланмаслар кылануын, җимерттереп үк китмәсләр. Бүрәнәсен бүрәнәгә җыеп барырлар. Агачы ныктыр әле аның. Ерак урманга барып иң яхшы наратларны гына сайлап кискәннәр иде бит теге чакны. Кайткан еллары гына иде. Кайгысыннан карурманны кисеп аударырлык кара еллары иде...

Айсылу карчык мәктәп тирәләреннән бер әйләнеп кайтырга булды. Ул укытудан киткәннән бирле анда инде берничә яшь кыз эшләп чыкты. Килделәр дә киттеләр, килделәр дә киттеләр. Җәй ахырында, Өтернәснең иң матур чагында киләләр иде дә ул кыз балалар, аһ итәләр иде. Ул тау итәгенә сыенып утырган җыйнак, бизәкле йортлар, ул бакча башларыннан гына агып яткан Әрә елгасы, ул Әрә буенда бөдрә әрәмәлекләр, болыннар... Аһ итәрлек тә шул. Өтернәскә беренче тапкыр килгән кеше: «Дөньяның җәннәте шушында икән!» — дип китә. Аннан кара көзләр башлана. Авыл урамнарына соры, салкын, ябышкак пычрак җәелә. Атлы да, җәяүле дә үтә алмый аннан. Яшь укытучы кыз да, авыл хатыннары кебек, аягына резин итек киеп йөри башлый. Аннан әкренләп белән генә кыш килә. Озын, салкын, ялгыз авыл кышы. Һәркем үз өендә, олы урамга йомышы булса гына чыга. Һәркөн мәктәп белән ике араны таптаган укытучы кыз инде тизрәк кышның үтүен көтә. Алты-җиде балалы авыл мәктәбенә ул икенче елны килми инде.

Быел менә бөтенләй ябарга булганнар. Күрше авыл якын, күре-

---

Фәүзия БӘЙРӘМОВА *(1950) — прозаик, «Болын» исемле китап һәм драма әсәрләре авторы. Казанда яши.*

неп кенә тора, мәктәбе дә таш. Өтернәснең алты-жиде баласын гына сыйдырыр. Барыбер... йөрәге әллә нишләп куйды менә, мәктәпне сүтәләр икән дигәч. Иске булса да, авыл уртасында шау агачка күмелеп утыра иде әле. Айсылу карчык йоклый торган почмакның тәрәзәсе дә шул якка чыга иде. Хәтта яз-көз көннәрендә кыңгырау биргән тавышларга хәтле ишетелеп тора иде.

Айсылу карчыкның тәне эсселе-суыклы булып китте. Кыңгырау! Бөтенләй исеннән чыгарган бит! Тавышын әле яз көне генә ишеткән иде, куанган, уйланган иде... Ул мәктәпне сүткәч, әйберләрен дә кайсын кая таратып бетерерләр инде. Йә, чүп дип, чыгарып ташларлар...

Айсылу карчык кызурак атларга тырышты. Ерактан ук күрде: мәктәпне әле сүтә башламаганнар, ишеге генә төбенә чаклы ачылган, жилдә шапы-шопы бәргәләнеп тора. Ташландык мәктәп бакчасына бала-чага жыелган, алар, укытучы карчыкны күргәч, иске гадәт буенча чыгып йөгерергә уйладылар. Ләкин чыкмадылар, бакчаның куерак, караңгырак почмагына чумдылар.

Мәктәп баскычына аяк баскач, Айсылу карчыкның башы әйләнеп китте. Борынга таныш ис — мәктәп исе, искергән кәгазь исе бәреп керде. Күптән килгәне юк икән — баскычлар биегәеп киткән кебек. Ул үзе кыңгырауны укытучылар бүлмәсендә, өстәл астында гына тота иде. Бу яшь кызлар да шунда куйдылармы икән? Карчыкның юка гәүдәсе, шәүлә кебек кенә шуып, укытучылар бүлмәсенә үтә. Бүлмә туздырылып ташланган, идәнгә өем-өем иске дәфтәр, класс журналлары өелгән, акбур кисәкләре тапталып көл булган. Глобус та, барабан-быргылар да күренми. Йә күрше авыл мәктәбенә озатканнардыр, йә...

Карчыкның калтыранган куллары өстәл астында капшанды. Кыңгырау юк иде! Карчык, тезләнеп, иелеп-иелеп, өстәл астын карады. Кыңгырау юк иде... Ул тезләнгән урыныннан тора алмады, башын өстәл читенә төртеп, күзләрен йомды; уйлары караңгыланды, зиһене таралды. Елыйсы килде. Елый алмады. Тегеннән кайтканнан бирле ул инде елый алмый иде.

Кинәт карчыкның колагына көмеш кыңгырау зеңгелдәгән кебек тоелды. Ул капшанып урыныннан торды, хәлсез аяклары белән кыңгырау тавышы килгән якка таба атлады. Дүртенче класслар бүлмәсеннән килә, юк, беренче... Кыңгырау тавышы, чыгарга урын таба алмагандай, бүлмәдән-бүлмәгә ташлана, коридор буенча еламсырап уза. Әнә инде тавышы бөтенләй дә ишетелми, тынды, беренчеләр укый торган бүлмәгә керде дә тынды.

Карчык бик озак барды кебек. Ачык калган ишектән класска керде. Башына: «Әле парталарны да чыгармаганнар икән», — дигән уй килде. Парта араларында укучы балалар утырадыр кебек тоелып китте. Ләкин класс буш иде. Шулчак кинәт тагын кыңгырау тавышы яңгырап киткәндәй булды. Карчык әсәренеп шул якка карады, карлыккан тавыш белән: «Кем бар анда?» — дип сорады. Парта астыннан акрын гына башта бер кара баш күтәрелде, аннан йөзе дә күренде. Бу алты-жиде яшьләрендәге ир бала иде. Тик аның йөзен күргәч, карчык сискәнеп китте: баланың күзләрендә бернинди аң-нур әсәре юк, әйтерсең, тар маңгай астында ук ике буш чокыр, ә ачык авызының бер кырыеннан теле күренеп тора. Малай ике кулы белән көмеш кыңгырауны кысып тоткан, кыска кара бармаклары әйтерсең лә ак көмешкә батып кергән, ычкындырыр исәбе юк...

Малай тиле иде. Алай да карчык иппәп кенә эндәшеп карарга булды.

— Улым, бир ул кыңгырауны миңа, — диде ул, малайның күзенә туры карарга тырышып. — Бир, мәктәпнеке ул.

Малай жавап урынына мөгрәп кенә куйды. Тар маңгай жыерылды, йөзенә дәһшәт, ризасызлык билгесе чыкты. Карчык кулын кыңгырауга таба сузып карады, ләкин малай урыныннан кубарылып чыкты да икенче парта артына ташланды.

«Кем баласы икән соң бу?» — дип уйлады Айсылу карчык борчылып. Үзенә карап кына төсмерләп булмый. Юк, авылныкы булмас. Авылда ул һәркемнең тормышын белә. Берәрсенә кайткан бала булса кирәк. Ничек тә җайлап кына алырга кирәк кыңгырауны. Галимҗанның төсе булган кыңгырауны.

Аның якынлашуын күреп, малай парта астында бәргәләнә башлады. Чәченә Айсылу карчыкның кулы килеп кагылуга, яман тавыш белән үкереп җибәрде. Айсылу карчык баскан урынында катып калды.

Малай үкергән тавышка коридордан кемдер дөпелдәп йөгереп узды. Айсылу карчык зиһененә килгәндә, ул аның янында басып тора иде инде. Кыяметдин. Изүе ачык, җиңе сызганулы, протез кулындагы кара бармакларын бер җыя, бер җәя. Карчыкның бу бәндә белән сүзгә керешәсе килмәде. Тизрәк борылып чыгып китәргә уйлады. Баланы урамда көтеп торып, артыннан өенә хәтле барырга иде исәбе. Кыяметдингә карамый гына ишеккә таба борылды.

— Нигә акыртасың ул баланы? — Аягында чак җилбердәп басып торган карчыкка Кыяметдин үзе козгындай ташланды. — Сиңа гына һаман житмәде, инде сүтеләсе мәктәпкә дә килеп җиткән. Һи-и, төрмә кошы...

Соңгы сүзләр Айсылу карчыкның йөрәгенә пычак булып кадалды. Егылып китмәс өчен ишек яңагына сөялде. Ул арада тиле бала да, парта астыннан чыгып, Кыяметдин картның симез бармакларына тар маңгаен төртте.

— М-м-м...— дип мөгрәде ул каш астыннан Айсылу карчыкка карый-карый. — М-м-ммм! — Аннан, көмеш кыңгырауны өскә күтәреп, кизәнгәндәй хәрәкәтләр ясады.

— Нәрсә, улым, куркыттымы бу карчык? — Кыяметдин кыңгырауны кулына алып әйләндергәләде, җиңенә сөртеп, ялтыратып алды. — Кыңгырау кирәк булган... Кара аны, килеп җиткән... Сиңа кирәкме? Миңа да кирәк ул...

Бу кешедән барысын да ишетергә була иде. Ул инде заманында аннан барысын да ишеткән иде. Һаман юллары аерылмый. Әйләнә дә бергә килеп төйнәлә, әйләнә дә... Менә хәзер... соңгы истәлек тирәсендә төйнәлде төеннәре. Ләкин Айсылу карчык моннан кыңгыраусыз чыкмаячак! Ул — Галимҗанның төсе, анда баласының нәни бармак эзләре саклана. Тегендә, төрмәдә, төннәрендә шул кыңгырау тавышын ишетеп, уянып китә иде. Берсе дә калмады! Яхшысы да, яманы да... Бары шушы кыңгырау гына. Сиксән еллык гомере эреде дә сүнде. Иренеке сүнде. Улыныкы. Бары кыңгырау гына калды. Анысы да... акылсызлар кулында.

— Кыяметдин, — дип башлады ул сүзен акрын гына. — Кыңгырау — Галимҗанның төсе. Чәч тәңкәләремнән койдырып ясатып алып кайткан иде. Син аны үзең дә хәтерлисең. Бир миңа кыңгырауны...

Айсылу карчык Кыяметдингә таба берничә адым атлады. Карт урыныннан кыймылдамады, аякларын аерып басып, карчыкның якынлашуын көтте. Бер кулына кыңгырауны сытардай итеп кысып тоткан, икенче кулы — тиле малайның башында.

Карчыкка ул көмеш кыңгырауны бирмәячәк! Үлгәндә дә! Нигә икәнен үзе дә белми, әмма ләкин — бирмәячәк! Соңгы сүзен сүз итәр, үзенчә итәр.

— Кыңгырау дисең алайса... Кыңгырау исеңә төшкән. Минем дә менә монда утыра ул! Каберең дә алып китәргә уйлыйсыңмы аны?

— Сиңа да шунда барасы... Без анда инде... мең тапкыр киттек. Алтын-көмешләрсез генә... Барысын да сезгә калдырып. Инде соңгы тапкыр кайттык. Исәп-хисапны өзәргә. Бир...

Карчык, сөяктәй кулларын сузып, Кыяметдин өстенә килә башлады. Тиле бала ямьсез тавыш белән үкереп-чинап җибәрде. Әллә аның кыргый тавышыннан, әллә җил белән — тәрәзә каерылып ачылып китте, кисәк килеп бәрелүдәнме, пыялалар зыңгылдап урам якка коелып төште

Ватык тәрәзәдән җил бәреп керде, ул идәндә яткан кәгазь кисәкләрен бөтереп алды. Айсылу карчыкның ак чәчләрен битенә сипте; төптәй Кыяметдин карт та урынында чайкалып куйды, тиле баланы үзенә ныграк кысты. Тәрәзә тагын көч белән тупсага килеп бәрелде, калган пыяла кисәкләре инде бүлмә якка коелды.

Кайчан бу?! Ул вакытта да шулай иде бит! Тәрәзә пыялалары челпәрәмә килеп ватылды. Август ае иде бит... Ул чагында да менә шушылай каршысына басканнар иде... Әйләнә дә кайта, әйләнә дә кайта...

Ул арада бөтен дөнья яктырып киткәндәй булды. Әрә елгасы буена яшен кылычы кадалып төште. Күп тә үтмәде, чатырдаган тавыштан мәктәп селкенеп куйды, түшәмнән шыбырдап туфрак коелды. Кыяметдин карт чүгеп куйды, терсәген күтәреп башын каплагандай итте, ләкин кыңгыравын ычкындырмады.

Дөнья дөбердәде, ду килде. Коеп яңгыр ява башлады. Мәктәпне сүтәргә җыенган төзүчеләр йөгерешеп эчкә керделәр. Караңгыланып калган бүлмә уртасында ап-ак күлмәктән басып торган карчыкны күргәч, барысы да имәнеп китте, телсез калгандай булдылар. Ләкин аның укытучы карчык икәнен белгәч, шыпырт кына идәнгә тезелешеп утырдылар, телдән ычкынырга торган тозлы-борычлы сүзләр дә тыелып калды, чөнки Айсылу карчык аларның барысын да укытып чыгарган Авыл Анасы иде.

Ыгы-зыгыдан файдаланып, Кыяметдин карт кыңгырауны чалбар кесәсенә шудырды. Малайны җитәкләп, чыгарга кузгалды. Айсылу карчык тагын аның юлына аркылы төште.

— Оланнар, — диде ул кемгә әйткәнен дә белмичә. — Оланнар, кыңгырауны алды. Мәктәп кыңгыравын... Галимҗан абыегыз кыңгыравын...

Галимҗанның кем икәнен белмәсәләр дә, кыңгырау барысына да таныш иде. Кыяметдин картның кулына асылынган укытучы карчыкны күргәч, нәрсә булганы да аңлашылды.

— Салып сөйләш, Кыяметдин абзый! — диделәр алар ярым шаяртып, ярым чынлап. Кайсыдыр Кыяметдиннең чалбар кесәсеннән бүлтәеп беленеп торган кыңгырауга чирткәләп тә алды.

— Миңа соң, авыл советына гына илтеп бирермен дигән идем, — Кыяметдин карт кыңгырауны чыгарып, учында чөйгәләп алды. Җайсыз төшкән саен, кыңгырау ыңгырашып куйгандай булды. — А как же! Дәүләт милке. Бу карчык сорар ул. Сорар... Ул аласын алып бетерде инде.

Ләкин кыңгырауны Айсылу карчыкка бирергә ашыкмады. Маңгай астыннан гына төзүчеләргә сөзеп карап чыкты, аннан кыңгырауны өстәл уртасына китереп куйды.

— Авыл советы белән килеп алганчы, кыңгырау шушында торасы! — диде ул, бармаклары белән өстәлне төеп. — Көмеш бу! Юкка чыкса, кое-кому җавап бирергә туры килмәсен.

Барысы да уңайсызланып, тынып калдылар. Айсылу карчыкка күтәрелеп карарга да кыен, Кыяметдин карт сүзендә дә хаклык бар. Авыл советы икән, авыл советы. Бүген инде мәктәпне сүтеп булырга охшамаган, яңгыр энә бөтен авыл өстенә җәелеп, котырынып ява. Яңгыр пәрдәсен ярып, тагы яшен яшьни, тагы күк күкри. Караңгы класс бүлмәсендә кешеләрнең йөзе яктырып-яктырып китә, күк күкрәгән саен, өстәлдәге көмеш кыңгырау да зыңгылдап куйгандай була.

Мәктәп ишегеннән кайсыдыр йозакка бикләп алды. Кешеләр берәмберәм, башларын тотып, яңгыр астына чыгып йөгерделәр. Кыяметдин дә, тиле малаен күтәреп, түбән очка таба йөгерде. Айсылу карчыкның өе әнә генә, килгәндә коймаларга таянып, әкрен генә килеп җиткән иде. Көн чалт аяз иде. Августның соңгы җылы көннәре иде. Инде менә көз. Кара көз. Ә атларга кирәк. Яшәп бетерергә дә кирәк.

Кемдер җилкәсенә кием китереп сала. Төзүче егет. Айсылу карчык

укыткан соңгы класс. Ул чакта ук ак чәчле карчык булгандыр инде, бу малай аны «әби апа» дип йөртә иде. Ак чәч... Ул үзенең кара чәчле вакытын хәтерләми дә инде. Тегендә, тезенә төшкән толымнарын кистереп ташлаганда, алар ап-ак иде инде. Ул вакытта аңа утыз өч яшь иде...

Кайтып та җителгән. Яңгырда чыланмаса да, бөтен тәне дерелди. Алай да чүәкләре чыланган икән бит, яулыгы әнә башына ябышкан. Әллә нинди авырлык, әллә нинди авырлык. Нәрсәдер баса... Елый да алмый. Ә анда көне-төне елый иде бит. Елый да йөрәк белән егыла. Башкалар алай бәргәләнмәделәр шикелле, алар әнә хәзер елый. Ул еллар турында сөйләшә дә алмыйлар — үксиләр генә... Ул менә хәзер елый алмый... Кипкән, корыган, ташка әйләнгән.

Килененең кайнатып биргән бер чокыр сөтле чәен эчте дә, карчык тизрәк урынына менеп ятарга ашыкты. Яңгыр белән яшен китмәскә килгәннәр, ахры — кечкенә генә Өтернәсне каплап алганнар да, авыл өстендә тантана итәләр. Тәрәзә пәрдәләрен ярып, яшен кадалып төшә. Нәкъ Айсылу карчык яткан турга, аның йөрәгенә төшә. Ничә еллар шулай аның йөрәгенә төште ул! Тегендә ятканда да, кайткач та. Ташны сукты, гел кара көйгән, ташка әйләнгән бәгырен сукты! Нигә аны гына сукты? Нигә? Нигә аны сайлап сукты соң ул яшен?! Аh-h-h-a-a...

— Әнкәй! — Килене эндәшә, ахры. Юк, килен, юк, сөякләр генә сызлый. Яңгырдан, ахры... Яңгырдан...

Шулай... Сайлап алып кына сукты... Иң бәхетлеләрне, яшәргә иң омтылганнарны, иң ышанганнарны... Менә, ярты гасыр вакыт үткәч, ни өчен сугылганнарын да белмиләр. Кешеләр дә белми. Нәрсә кешеләр, хәтта үзләре дә белмиләр бит. Аяклары йөргәндә Казанга, Зөләйхаларга барган иде. Өстәлендә — Сталин портреты. Шуның чорында бит Зөләйха ун ел төрмәдә утырды, ирен югалтты, өч баласын ил буйлап чәчте — һәм, үләр вакыты җиткәч, өстәлендә һаман Сталин портреты!

Бернәрсә әйтә алмады ул Зөләйхага. Күзләре белән таныш рәсемгә бакты, аннан җавап эзләде, көтте. Теге еллардагы кебек! Аның исемен әйтмәгән, өметләнеп аның исемен телгә алмаган көннәре булдымыни аларның?! Гел: «Ул белмидер, ул белсә, аңа барып ирешсә, коткарыр», — диделәр. Ягылмаган камераларда, баракларда төрле телләрдә аңа ялвардылар, ышандылар, көттеләр. Ләкин баш очларында һаман салкын Себер урманы гына шаулады. Меңләгән хатынның хәсрәтен киметергә теләгәндәй, кара урман гына шаулады...

Тагын сызылып яшен төште. Монысы хәтергә төште. Галимҗанны алып киткәннәренә җиде ай... Эштән чыгардылар, квартираларының бер бүлмәсен алып, күршеләренә бирделәр. Унөч яшьлек улы Газизҗан олыгаеп киткәндәй булды, күзләре борчулы, уйчан; гел шаян, иркә бала иде — эндәшми, сөйләшми. Казанда яшәү авырлашты. Элек бергә мәҗлесләрдә утырган кешеләр эндәшмичә генә үтеп китәләр, һәркем үзе өчен курка, шикләнә, күзгә чалынмаска тырыша. Газеталар яман хәбәрләр белән тулган — әле тегендә, әле монда шпион тотканнар. Зур-зур кешеләр япон, немец фашистларына хезмәт иткәннәр. Мәскәүләр турында язылган нәрсәгә Казанда да ышандылар. Телгә «халык дошманнары» дигән куркыныч сүз килеп керде. Аларны гаепләп, атарга дип, Казанда да бик ышанып кул күтәрделәр. Шагыйрьләр, халык дошманнарын хурлап, хакыйкать кылычын зурлап, шигырьләр яздылар. Икенче көнне үк үзләрен дә алып киттеләр.

Бу шау-шу, ыгы-зыгы башлангач, Галимҗан сизенгән кебек йөрде. Каралды, йөзе тартылды, сөйләшергә, киңәшергә кеше юк иде, җанында укмашкан төенне ир төннәрен хатынына чиште, кайчан гына дөньяның оҗмахы булып күренгән йорт шом белән, дәһшәт белән тулды.

— Сине алмаслар, Галимҗан! — Хатын дерелдәп иренә сыена, юатырга тырышып әйтсә дә, куркуы тавышына чыккан. — Безнең бит байлыгыбыз да, чит илдә туган-тумачабыз да юк.

— Ә аларның бар дип беләсеңме? — Галимҗан бераз дәшми тора,

әйтерсең, караңгыда үз тавышын үзе тыңлый. — Инде ЦК аппаратын алып бетерәләр, барысы да шпион микәнни?

Әйе шул,ниләр генә язмыйлар, ниләр генә сөйләмиләр. Кайсы Германиягә хезмәт иткән, кайсы — Япониягә. Илдәге иң яшерен хәрби серләрне җиткереп барганнар. Айсылу моңа үзе дә ышана, мәктәптә балаларга да шулай дип сөйли.

— Сине алмаслар, Галимҗан! — Хатынның бу юлы инде тавышы ышанычлы, нык. — Ул бит барысын да күрә, белә. Син — намуслы коммунист, намуслы җитәкче. Сине алмаслар...

Ышана идеме ире аның бу сүзләренә? Төнлә булса да ышанасы килгәндер. Иртәгә алып китәсе дигән төнне, сизенгән кебек, Айсылуны авылга кайтырга үгетли башлады.

— Кайт Өтернәскә. Балалар укытырсың. Газиз дә үз янында булыр. Монда әле белеп булмый... Монда әле белеп булмый дөньяларның нишләп бетәсен.

— Гаебебез юк, Галимҗан. Ил алдында да, кешеләр алдында да гаебебез юк. Аннан...

Хатын тынып кала. Ир, терсәкләренә таянып, ай яктысында аның йөзен карый. Кара чәч араларына ай нуры яткан, керфекләре тагын да озын, серле булып күренә. Битләре нәфис, озынча. Киткән тәкъдирдә... Ир күзләрен авыртканчы кысып йома, ыңгырашып, башын хатынының җилкәсенә төртә. Киткән тәкъдирдә...

— Аннан, — дип дәвам итә хатын, иренең җанында нинди уйлар кайнаганын аңлагандай,— аннан... кая китсәң дә, эзләп табарлар. Дөнья читенә качсаң да...

Бәлки, ул чагында ашыгып нәтиҗә чыгаргандыр Айсылу? Әнә бит киткән кеше китеп калды. Урта Азиягә, казах далаларына киттеләр. Шау-шу башлануга киттеләр. Һәм исән дә калдылар. Әле дә яшәп яталар. Ә безнекеләр... Ә без...

Яшеннең туктарга исәбе юк. Хәтернең бөтен почмакларына барып җитә. Килененең юрган астыннан гына пышылдап дога укыганы ишетелә. Ул дога да укый алмый менә. Белмәүдән түгел. Гарәпчә дә әлкте аңа, элекке абыстайлар да... Табыныр кыйбласы калмады. Ышанган берен яшен суга барды. Бар да күп бетте менә. Яше, җаны күп, корып килеп керде картлыгына. Инде төн уртасында пышылдарга сүзләр дә юк. Инде улының исемен дә тәсбих итеп тартмый. Йөзен онытаа... Аһ, шул бала өчен бит... Кипте, корыды, берни калмады...

Галимҗанны январьның салкын төнендә алып киттеләр. Ул чагында НКВД машинасын «карга» дип йөртәләр иде. Елашу юк, аңлату юк, кендерәләр дә алып китәләр. Йортына кара машина керү — тиф керү, йогышлы авыру керү белән бер. Икенче көнне үк синең белән беркем исәнләшми, читләшәләр, качалар. Хәтта Галимҗан үзе дә, хатыны Кремль астындагы төрмәгә очрашырга килгәч: «Башка килеп йөрмә, кит, кит!» — дип куды. «Казаннан кит!» — диде. Белгән кебек куган икән. Белгән кебек...

Утыз җиденең кышын әйберләрне саткалап, ничек кирәк алай очынучка ялгап чыктылар да, җәйгә авылга кителәр. Җәйгә дә, бәлки, китмәгән булырлар иде — әллә нинди шик керде Айсылуның күңеленә. Гел кемдер күзәтә кебек тоела иде аңа. Төнлә ятса — тәрәзәдән карыйлардыр, көндез урамга чыкса — артыннан киләләр кебек тоелды. Менә тотарлар, менә алып китәрләр... Галимҗан белән дә элемтә өзелде. Бәлки, чыгарырлар, дигән өмет тә бетте. Чыгармадылар, киресенчә, һаман җыйдылар, һаман җыйдылар... Беркем берни белми иде...

Шулай итеп утыз җиденең җәендә унөч яшьлек Газизҗан белән алар авылга кайтып егылдылар. Өтернәскә әле бу эшләр килеп җитмәгән, кайдадыр шпион, халык дошманы тотканнар икән, дип ишетсәләр дә артык гаҗәпләнмиләр, борчылмыйлар да, сөенмиләр дә. Өтернәс искечә яшәп ята — чәчә, ура, печәнен, утынын әзерли. Кызының кайтып төшүе-

нә әни карчык та бик сөенде. Кияүне нәрсә өчендер алып китүләрен, кызының әшсез калуын ул инде белә, кала жире бит, ни булмас, дип уйлый. Гаебе булмаса, кияүне дә чыгарырлар, андый зур кешеләрне тикшерми-нитми генә төрмәдә утыртмаслар, дип фикер йөртә. Казанда тамам сүнеп, сулыгып калган Газизжанга да жан керде, малайлар белән су буеннан кайтып керми, битенә ит кунды, көлә, шаяра башлады. Соңгы җәен шулай ваемсызланып уйнавын белдеме икән ул бала? Әнисенең авылын да соңгы тапкыр күрүен сизендеме икән...

Өтернәстә калырга насыйп булмады Айсылуга. Әнисе үләр алдыннан әйтте: «Шул Кыяметдин казынып йөрмәсә, кала идең син», — диде. Кыяметдиндә генә булдымы икән сәбәбе? Ә башкалар язмышында нинди Кыяметдин казынган? Аннан — кем иде соң ул вакытта Кыяметдин? Үз исемен чакка-көчкә сырлап имза куючы бер бәндә. Дөрес, урындыгы бар иде, кыршылып беткән бер портфеле. Өтернәс авыл советы рәисе дигән исеме.

Яшен нәкъ түбән очка, Кыяметдиннәр өй турына атылып төште. Ул да йоклый алмыймы икән әллә бу төндә? Йоклыйдыр. Ул бит үзен бернәрсәдә дә гаепле итеп сизми. Бәлки, гаебе дә юктыр... Хәзер, илле ел вакыт узгач, кем гаепләне эзләсен? Кыяметдин — шөреп кенә. Күгәргән шөреп...

Ул чагында гарәп хәрефләре белән укыту иде әле. Айсылу — революциягә хәтле үк Аитова мәктәбен бетереп чыккан кыз — авылга кайткач та эшсез калмады. Мәдрәсәне бетереп, авылда мәктәп ясадылар. Ләкин укыта алырлык кеше юк, әзрәк хәреф таныганы да мәчет-мәктәпкә барып балаларга сабак бирергә курка. Әти-әнисе белән кечкенәдән үк Кавказ якларында яшәгән, әтисе үлгәч Казан шәһәренә кайтып белем алган Айсылу ризалык бирде. Юк, алай чәчрәп торган, кызыл яулык бәйләп йөргән кыз түгел иде ул. Киресенчә, аны артык тыйнак, артык оялчан диләр иде. Мәктәпкә баруының да сәбәбе — шул нужа булды. Ачлык елны бөтен нәрсә кырылып, ашалып беткән. Таяныр ата юк. Казанда бала карап, төрле авыр эш эзләп кызларын укыткан ана авылда нидән тотынырга да белми. Һәм өлкән бала — Айсылу мәктәпкә барырга ризалык бирде...

Галимжан кайдан килеп чыкты соң аларның авылына? Тикшерергә килгән иде ахры ул, районда инспектор булып эшләгән чагы иде. Көз көне иде, ахры. Әйе, бик пычрак чак иде. Соңыннан Галимжанның әйткәне исендә: «Пычракка батып килеп кердем мәктәбегезгә. Ә синең аякта ап-ак йон оекбашлар. Идән сап-сары итеп юылган. Акшарланган мичтән җылы бәреп тора. Тактага гарәп хәрефләре белән «Ленин» дип язып куйгансың. Ә үзең...»

Шул турына җиткәч, Галимжан гел хыялга бирелә иде. Шул турын бигрәк тә кат-кат кайтып сөйләргә ярата иде. Ә Айсылу үзе бер дә ис китәрлек нәрсә тапмый ул елларда. Өстендә Аитова мәктәбе формасы — кәрән төстәге йон күлмәк, дөрес, ул гәүдәсенә сыланып тора, изүендә һәм җиң очларында сәдәфләр, итәге — гармун итәк. Аягында — ак йон оекбашлар. Ул чагында балалар да ак йон оекбаштан йөриләр иде. Тагын нәрсә? Ә, тагын иң кызыгы бар икән әле. Чәчләре озын иде Айсылуның. Тезенә төшеп тора. Һәм ул аларны, тасма очына чулпылар тагып, үреп куя иде. Атлаган саен, ул чулпылар, бер-берләренә бәрелеп, матур гына чыңлап куялар. Хәер, ул вакытта авылда барлык кызлар да шулай йөри иде бит. Һәм Айсылу да монда гаҗәпләнерлек бернәрсә дә күрми иде.

Ә Галимжан гаҗәпсенде! Кара чәч толымында ялтырап торган ап-ак тәңкәләрне уч төпләренә җыеп биетте, уйнады, Айсылуны үртәде.

— Их син, совет укытучысы! — Галимжанның көлү авазы менә бүген Айсылу карчыкның таш булып каткан бәгыренә килеп-килеп бәрелә. — Чулпылар тагып килгән бит мәктәпкә. Әллә син Өтернәснең абыстаемы?

Үзе көлә, үзе яратып, сокланып Айсылуны күзәтә. Айсылуның яңаклары кызарып чыга, дерелдәгән бармаклары белән ул шуны яшерергә тырыша, әллә оялудан, әллә башка нәрсәдән — күзенә яшь килә. Бу нинди чибәр егет икән? Айсылу аңа бер генә күз сирпеп карап алды — йөрәге кысылып, оеп калды. Кара кашлары астыннан яшькелт үткен күзләр карап тора, юк, ачуланып түгел, ничектер яратып, баласытып карый алар. Йөзе, тәне кара-кучкыл, әллә җил-яңгырдан шундый төскә кергән, әллә тумыштан шулай? Чәчләре — бөдрә, алкаланып, маңгаена ук төшеп тора. Егетнең йөзе, карашы бөркетне хәтерләтә — нык, кырыс, горур, серле-сихерле.

Тышта көзге яңгыр сибәли. Балалар мәктәптән кайтып киткән. Айсылу ап-ак итеп акшарланган мичкә аркасы белән терәлгән.

Галимҗан — Өтернәс башлангыч мәктәбен тикшерә килгән инспектор егет — дәфтәр-журналлар караган булып утыра. Ара-тирә шаян сүзләр әйтеп, Айсылуны үртәп ала. Әллә мич җылылыгыннан, әллә эчтәге ут кайнарлыгыннан, Айсылуның тәне бер эсселәнә, бер суына. Аны тынычландырырга теләгәндәй, тәрәзәгә сибәләп-сибәләп көзге яңгыр ява.

Аннан соң да күпме яуды ул яңгырлар аның тәрәзәләренә! Карлыбозлысы да булды, тәрәзәне челпәрәмә китергән давыллылары да хәтерендә, әмма шул көзге яңгыр — иң кадерлесе, иң сагышлысы, иң онытылмасы...

Көмеш тәңкәләрен Айсылу аңа үзе салып бирде. Инспектор егет аңа икенче килүендә «сюрприз» алып киләсен әйтте. Кыз анысын аңлап та бетермәде, ләкин егетнең икенче тапкыр килергә вәгъдә итүе аның бертөрле авыл тормышын яктыртып, әллә нинди сөенечле сагышка күмде. Көннәре аның килүен көтеп үтә башлады. Ул аны бары тик бер тапкыр күреп калган иде — кулына да орынмады, якын да килмәде, ерактан гына елмаеп карап утырды, ләкин Айсылуның башын әйләндерде, телсез итте, төннәрен йокысыз калдырды.

Кыш буе тилмереп көтте ул аны. Баскычта аяк тавышлары ишетелү белән, сискәнеп, ишеккә карый иде. Хәвеф һәм өмет белән. Сөенеч һәм оялу белән. Аның бу карашын балалар да белеп бетерделәр, аяк тавышлары килгән саен, сагаеп, апаларының йөзенә карыйлар, шым булалар, тын алганнары да сизелми.

Арткы партада утырган зур малай — Кыяметдин генә шырык-шырык көлеп ала. Аның инде яше байтак, гәүдәгә дә нык, күзләрендә балаларга хас булмаган сынаулы, вакыты-вакыты белән тонык, вакыты-вакыты белән ялтыравыклы караш. Бу караштан Айсылу үзе дә уңайсызланып, куырылып килә. Кыяметдин Айсылудан берничә яшькә генә кече, мәдрәсәдә әзме-күпме хәреф таныган; атасы Нурый карт, ачлыктан эт-мәче ашап исән калган бердәнбер улына дөньяви белем дә бирергә уйлапмы, аны Айсылуның мәктәбенә китереп куйды. Малай башта бер кем белән дә сөйләшмәде, аралашмады — маңгай астыннан гына сөзеп карап утыруын белде. Үзеннән күпкә яшь бала-чага аннан курка иде, үзе дәшмәсә, якын да килмәделәр. Кеше арасында Кыяметдиннең атасы Нурый карт турында әллә нинди шомлы, куркыныч сүзләр дә сөйлиләр иде. Имеш, ачлык елны алар ярамаган нәрсә ашаганнар. Имеш, Кыяметдиннең карашы шуңа күрә тонык, гәүдәсе төп кебек нык... Айсылулар авылга егерме бернең ач кышы үтеп икенче ел уңышы өлгергәч кенә кайттылар. Авылдагы шомлы хәбәрләргә ышанып та бетмиләр. Ләкин Нурый карт Кыяметдинне җитәкләп мәктәпкә алып килгәч, Айсылу дерелдәп куйды, беләкләренә каз тәне чыкты. Алай да үсмер малайга үз хәлен сиздермәскә тырышты, кулыннан алып, иң соңгы партага китереп утыртты.

Шул көннән бирле күзләре белән Айсылуны «ашый» Кыяметдин. Дәрескә аның әллә ни исе китми, бераз хәреф таный, хисап белә. Ләкин малай мәктәпне ташлап кайтып китәргә дә ашыкмый, анда, Нурый карт-

ның аралыгында бүрәнә ярыгы санап ятканчы... Һәм тагын тонык карашы белән талчыбыктай нәфис укытучы кызның гәүдәсен капшый, эзәрлекли башлый. Айсылу уңайсызлануыннан кая карарга да белми, калку күкрәге бер менә, бер төшә. Кыяметдин анын саен урынына сеңә, башын җилкәләренә яшерә, карашы тона, тын алуы авырлаша башлый...

...Айсылу карчык яткан урыныннан башын калкытты, терсәкләренә таянып, караңгы өй почмагына текәлде. Кайда күрде соң әле ул кабат мондый авыр, тонык карашны? Бүген бит, кыңгырауны эзли баргач, теге тиле малай аңа шулай караган иде бит! Кеме булды соң ул Кыяметдиннең? Карашына кадәр кабатлангач, берәр якыны бит инде, якыны...

Бер-бер артлы ике яшен угы Кыяметдиннәр турысына төшеп югала. Аннан күкнең чатнап ярылганы ишетелә. Кыяметдин карт яткан урыныннан калкынып куя, коты чыгып, түшәмгә карый, шом белән тыңлап тора. Гел аның йортын сугар кебек бу яшен. Янында яткан оныгы да, нидәндер качкандай, бөгәрләнеп килгән. Баланың котын алды бүген теге карчык. Кыңгырау, имеш... Кыңгырау... Кыяметдиннең дә бәгыренә таш булып утырган кыңгырау ул. Айсылу карчыкка биргәнче, ул аның телен йолкып алып утта эретер, чүкеч белән төяр, кыңгыравыннан бер йодрык тимер ясар, әмма бирмәс! Мыскыллыкта үткән малай чагына үч итеп булса да бирмәс!

Көзге пычракта Галимҗанның килеп керүе Кыяметдинне дә йокысыннан уятып җибәргән кебек булды. Тар маңгаенда мең төрле уй котырып алды. Нигә укытучы кызга болай карый ул килгән егет? Нигә ул егет Кыяметдингә караганда гәүдәлерәк тә, чистарак һәм чибәррәк тә? Нигә укытучы Айсылу шулай кинәт югалып калды, бармакларына хәтле калтырый? Тар маңгай җавап таба алмады, кыргый йөрәк аның саен котырынып типте. Һәм бер күрүдә Галимҗанны кан дошманы итте. Ул көнне мәктәптән дә бәрелеп-сугылып чыгып китмәде Кыяметдин, мәш килеп киенеп яткан бала-чаганы аралап, мич тирәсенәрәк елышты. Укытучы Айсылу белән тикшерә килгән егет аңа игътибар итмәделәр, алар ул көнне Кыяметдинне дә, башка балаларны да күрмәделәр шикелле. Ә Кыяметдин барысын да күрде! Укытучы кызның дерелдәгән бармакларын да, ут капкан йөзен дә, елап җибәрергә әзерләнгән кабарынкы иреннәрен дә — барысын да күрде! Аның әле мондый булганы юк иде. Килгән егет тә әнә ничек итеп карый бит аңа! Алар авылында болай карамыйлар! Кешегә болай карарга ярамый!

Ерткыч җанвар тизлегендә, Кыяметдин мич арасына кереп кача. Йөрәгенең типкәне үзенә ишетелә. Моннан укытучы кыз күренми, килгән егетнең өстәлгә куйган сул кулы гына күренә. Бармаклары озын, нык. Бугазыңнан бөтереп алса, тының да чыкмас. Кыяметдин үзенең куллары карый. Тырнаклары кап-кара, чәйнәлеп беткән, бармаклары кыска, үзләреннән йон, тирес исе килә. Өстендәге киеме дә теге егетнекеннән начар: атасыннан калган, бөрмәләрен бет баскан иске бишмәт. Малайның бугазына төер тыгыла, күзләре әллә зәһәрлектән, әллә яшьтән әчетеп куя. Менә укытучы кыз мичкә килеп сөялде ахры, тавышы бөтенләй якын ишетелә. Менә ул бер кулы белән тәрәзә төбенә таянды, кулы Кыяметдиннең борын төбендә генә. Нинди чиста, бәләкәй кул! Үзе шундый ак! Кыяметдиннең борыны белән шул кулга капланасы, аны ялыйсы, иснисе килә. Һәм шуларга битен куеп торасы иде... Аз гына, күзне йомып кына...

Кыяметдиннең башы әйләнеп китә. Үзе кереп чүгәләгән караңгы мич арасы аяк астыннан шуа башлый. Шул чак чулпы чыңлаган тавыш ишетелә. Чыңлый да чыңлый, чыңлый да чыңлый! Идән чайкалуыннан туктый, ә чулпы һаман чыңлый! Малай, куркуын җиңеп, башын мич арасыннан чыгарып карый. Нишли ул укытучы Айсылу?! Нигә ул аның каршында чәчләрен сүтә? Озын кара чәчләре әнә, таралып җилкәсенә төште, аркасын каплады. Ярым караңгы класс бүлмәсендә дә аларның

дулкынланып торганын күрергә була. Малайның кыргый җаны әллә нәрсәләр уйлап бетерде. Әгәр күлмәген салса, әгәр бу килгән егет белән кочаклаша башласа? Кыяметдин мич арасында яткан утын агачына таба кулын сузды, сикерергә әзерләнгән җәнлек кебек, бөтен тәне җыерылып килде.

Ләкин укытучы кыз чишенмәде. Таралган чәчләреннән чулпысын аралап алды да егеткә сузды. Тегесе, әллә нәрсә алып кайтырмын, дип, төреп, кесәсенә салып куйды. Аннан, кыз белән саубуллашып, көзге пычрак урамга чыгып та китте.

Класс бүлмәсе бераз тынып торды. Аяк тавышлары да ишетелми. Үсмер малай, оеган аякларын кыймылдатып, әкрен генә мич арасыннан чыга, караңгыдан таныш гәүдәне эзли.

Әнә бит, тәрәзә янагына килеп сөялгән! Чәчләре һаман таралган килеш, карашы әллә нишләгән. Малай аның янына ук барды, ә ул аны күрмәде, сизмәде. Малайның чәчләргә орынып карыйсы, сылу затның сулыш алганын ишетәсе килде. Үзенең исә тын алуы кисәк кенә авыраеп китте, йөрәге тагын кысылып куйды. Ләкин ул аңа кагыла алмады. Укытучы кыз белән аның арасында үтә алмаслык кыя-тау тора кебек тоелды. Шуны тойган саен ачуы артты, кемнәндер үч аласы, нидер эшлисе килә башлады. Ул, дөп-дөп итеп басып, үзе утырган арткы өстәл янына килде, аны кузгатып тавыш чыгарды, үзе астан гына һаман укытучы кызны күзәтте. Әһә, кузгалдыңмы, янына ук киләсеңме? Кил, кил, күрмәгән булсаң, күр, менә ул Нурый малае Кыяметдин! Төкерә ул сезнең «а»ларыгызга, «б»ларыгызга!

— Чү, чү, ни булды, Кыяметдин, берәр нәрсәңне югалттыңмы әллә?

— Югалттым шул! — Малай, бишмәт чабуларына урала-урала, ишеккә ташлана, бәйләнми калган чабата бавына басып егыла яза, яланбаш көе көзге яңгыр астына атылып чыга, сукмак-мазар сайлап тормастан, пычракның үзәгеннән түбән очка таба йөгерә. Караңгы урамнан да караңгырак өйләренә кайтып кергәч тә тынычлана алмый, җимерек мич почмагына борынын төртеп, үксеп-үкереп ала.

Яңадан мәктәпкә бармаска, ул якка борылып та карамаска әченнән ант итә. Икенче көнне, таң беленү белән, иске бишмәтенә төренеп тагын шул якка китеп бара...

...Кыяметдин карт авыр гына уфылдап куйды. Яшьлеген, үзенең беренче яратуын искә төшереп сөенмәде ул, гарьлеге, мескенлеге, түбәнлеге тагын бер кат бугазыннан алды, иске бишмәтле ул малайны, үзенең кадерсезлектә үткән гомерен, янында яткан тиле онытын кызганды. Менә шулар өчен бөтен дөньяга ачуы, зәһәре бар иде аның. Һәм барысына да гаепле кеше — шул Айсылу, якын килә алмаслык, буй җитмәслек, үлгәндә дә якыная алмаслык укытучы Айсылу иде...

Шулай... Баскычта аяк тавышлары ишетелгән саен, Айсылу әсәрләнеп ишеккә карый, аның артыннан утыз бала берьюлы борыла, алар артыннан Кыяметдиннең авыр карашы ишеккә төбәлә. Шулай итеп, көз үтә, кыш җитә, инде көннәр дә язга авыша башлый. Айсылу күзендәге өмет тә әкренләп сүнә, тарала, аяк тавышлары килгән саен ул инде башын күтәреп ишеккә карамый. Укытучы сүнгән, тынычланган саен, Кыяметдингә җан керә, өмете үсә, менә җәй генә җитсен, дип хыяллана, шахтага китәр, киенеп кайтыр, Айсылуның үзе Кыяметдин янында бөтерелеп йөрер...

Малай татлы хыялларга чума. Шулчак колагына нindидер сәер тавыш ишетелә — туй атларындагы кебек, кыңгырау чыңлый! Нишләп мәктәп ишеге төбендә чыңлый соң ул?! Нәрсә булган?

Шул чак ишек ачылып китә дә... Ул!.. Кара чәчләре сирпелеп маңгаена төшкән, бөркет күзләреннән ялкын бәреп тора, каршындагы бөтен нәрсәне яндыра, ут итә! Пальто төймәләре чишелеп киткән — очып, канатларын җәеп киләмени?! Әнә ул укытучы кыз каршына килеп басты, кулындагы нәрсәкәйне тагын чыңгылдатып җибәрде. Кыңгырау бит

бу! Бизәкләп эшләнгән көмеш кыңгырау! Балалар, авызларын ачып, катып калдылар. Айсылуның битенә тагын ут капты. Ике кулын берьюлы теге егеткә суза! Кыңгырауны алыр өчен бер кул да җитә бит инде. Нигә ике кулын суза ул? Кыяметдиннең йөрәге башында тибә башлый, күзләре зур булып ачыла, сулышы буыла. Нәрсәдер сөйләшәләр дә бит.

— Менә чулпыларыңнан кыңгырау койдырып кайттым!

— Бигрәк матур...— Нигә укытучының тавышы шулай калтырый, матур булгач, нигә сөенми?

— Менә монда, эчкәре, каралтын белән синең исемеңне дә яздырдым. Ай-сы-лу! Ай, сылу!

Укытучы нигә эндәшми? Башы нигә ул егеткә таба иелә? Әнә инде чәчләре дә чәчкә тиде, якынаеп беттеләр! Кыяметдин урыныннан сикереп тора, бәрелә-сугыла өстәл артыннан чыга, каралып беткән кулын кыңгырауга таба суза:

— Кая, ничек шалтырый икән?

Аннан, бөтен классны яңгыратып, кыңгырауны селки башлый. Кыңгырау челтерәп җавап биргән саен, ярсуы арта төшә, кыңгырауны ике куллап баш очында селки, әйтерсең, аннан нидер коярга, нидер алып ташларга тели! Кыңгырауның нечкә тавышы тәрәзә пыялаларына килеп бәрелә, алар да зыңгылдашып куялар, кыңгырау тавышы бүрәнә ярыкларына, мич араларына тула. Кыяметдин аның саен туктамый, әрнү катыш ярсуын йөзенә һәм кыңгырауны кысып тоткан бармакларына чыгарып, кагуын белә! Пычрак бишмәт араларыннан йөрәген шулай алып селкимени! Аннары кыңгырауны кисәк кенә өстәлгә куя да чыгып китә. Кыргый малай булып килеп кергән мәктәбеннән карт иргә әйләнеп чыгып китә...

...Кыяметдин карт икенче ягына әйләнеп ятып карый. Яшен уты барыбер хәтеренең әллә кайсы почмакларына барып җитә. Әле анда чәчләре таралган яшь Айсылу, әле йөзенә хәвеф чыккан, карашы яралы боланны хәтерләткән Айсылу, әле төрмәдә ятып йөзенә сары иңгән, күзләреннән хәсрәт тамып торган Айсылу. Һәм менә бүгенге ап-ак чәчле, йөзе ташка әйләнгән карчык — ул да Айсылу... Гомер буе шуңа якыная да алмады, ерак та китә алмады. Бер төен булып, гел бер чоңгыл — тормыш чоңгылы тирәсендә бөтерелделәр. Айсылу ничә тапкыр төпкә китте, инде бетте, инде югалды дигәндә тагын калыкты, бер чоңгыл тирәсендә тагын бергә бөтерелә башладылар. Кыяметдин карт та бу мәгънәсез бөтерелүдән инде туйган, арыган иде, картлык көнендә аңа җ а н тынычлыгы кирәк иде. Һәм ул Айсылу карчыкның мәңгегә төпкә китүен, үзен тынычлыкта калдыруын көтте, теләде, ходайдан ялварды.

Ә Айсылу карчык китәргә ашыкмады, яшенле төннәрдә хәтеренә кереп җанын кыйнады. Аның ни гаебе бар иде соң?!

...1937 елның ул хәвефле көзендә Айсылу Өтернәстә калырга булды. Кулга алынган кешеләрне һаман чыгармадылар, күпләрен атканнар икән, дигән хәбәрләр дә йөрде. Шушындый вакытта эшсез, бала өстерәп Казанга баруы хәвефле, куркыныч нәрсә иде. Дөньялар бераз тынычлангачны, бераз ачыклык кергәнче, Айсылу улы белән авылда калып торырга булды. Карап чыгыйм, дип, мәктәпкә килде. Мәктәп бикле иде, урамдагы бер баланы авыл советына ачкычка йөгертте, үзе мәктәп бакчасына керә торды. Үзе керде, үзе егылып китмәс өчен, тизрәк коймага тотынды. Һәр агач арасыннан Галимҗан карап торадыр кебек! Ул шушы мәктәптән килеп эзләп тапты бит Айсылуны! Эзләп тапты, үзенә каратты һәм алып та китте...

Шактый вакыт үз уйларына батып утырды Айсылу. Бакчага, авылга алма исе таралган. Якында гына, тырышып-тырышып, яшь этәч кычкырып җибәрде. Әрә буеннан бака кычкырган тавышлар ишетелеп куя. Әйтерсең лә дөньяга берни булмаган! Әйтерсең лә ил өстендә кара шом, шикләнү дә юк, төнлә алып китә торган НКВД машиналары да юк,

халык дошманнары да юк... Әйтерсең лә Галимҗан да төрмәдә түгел, эшендә, менә ял көненә кайтып та житәр. Портфеленә шәһәр нигъмәтләре төяп, кочагын җәеп, кара чәчләрен җилбердәтеп, кайтып та җитәр! Сагынудан, хәсрәтле уйларыннан саташа башлаган хатынын күкрәгенә кысар, назлар, юатыр...

Күз яшенең тып итеп туфракка тамуыннан гына айнып китте Айсылу. Кул аркасы белән яшьләрен сөртеп алды. Үзен тагын да картаеп, олыгаеп киткән кебек сизде. Галимҗанның бер сүзе, бер карашы аны терелтә, яшәртә алыр кебек иде. Юк, бары бер хәбәре... Исән дигән бер хәбәре...

Мәктәп капкасы ачылган тавышка янә сискәнеп китте. Карашын үзенә таба килгән ир-атка текәде. Башта, әллә Галимҗанмы дип, йөрәге кысылып куйган иде, ләкин бөкрәйгән гәүдәне, тездән узган килбәтсез озын кулларны, тар маңгайны күргәч, шатлыгы шундук таралды. Каршына чит ир килә иде. Ләкин кайда күргәне бар соң Айсылуның бу тар маңгайны, тонык карашны? Колагында, кинәт ярсып, кыңгырау чыңлаганы ишетелгән кебек булды. Үткән еллардан аңа таба тар маңгайлы, сәер карашлы үсмер малай килә иде. Кулында, елардай булып, көмеш кыңгырау чыңлый...

— Кыяметдин...— Айсылу башка сүз әйтә алмады, утырган җирennән торды да, егылып китмәс өчен, агачка сөялде.

— Таныйбыз икән әле...— Кыяметдин тагын нидер әйтте, күреште дә бугай, Айсылуның аңына ул сүзләр, ул хәрәкәтләр барып җитә алмады.

Кыяметдин дә тар маңгае астыннан Айсылуны күзәтте. Суырылган, тартылган, йөзендә кайгы. Ирен утыртканнар, дип ишеткән иде, шул кайгыдан бетеренгәндер.

Кыяметдин кесәсеннән тәмәкесен чыгарды, Айсылу янына чүгәләп, бер-ике тапкыр суырып алды. Аннан күн итек табаны белән тәмәке төпчеген туфракка батырды.

— Авылда калырга булдың инде, алайса?

Айсылу җавап бирмәде. Үзенең кайгы-хәсрәте, шик-шөбһәләре турында сөйлисе килмәде аның бу кешегә. Кыяметдин инде кыргый малайдан авыр, салмак карашлы иргә әйләнгән иде. Тик, шулай да, карашының төбеннән вакыт-вакыт ниндидер ялкын бәреп ала. Әллә нәфрәт, әллә сагыш ялкыны. Шул ялкын Айсылуны куркыта, шикләндерә, дәшмәс итә.

— Тормышыңда казынырга килмәдем, — Айсылуның дәшмәвен Кыяметдин үзенчә аңлады, ахры. — Авыл советы председателе мин монда. Шуңа килдем.

Монысы инде икенче Кыяметдин иде. Кыңгырау тоткан малай юкка чыкты, аның урынына үгездәй муенлы юантык кеше басып тора. Һәм Айсылу, аның элекке укытучысы, эш сорап бүген аның каршына килә. Ул шушы караш астында эшләргә, яшәргә тиеш. Айсылуның тәне эсселесуыклы булып китте. Юк! Җанын бораулап торган бу караш астында яшәгәнче... Кая бара? Күз алдына тагын Казанның караңгыланып калган урамнары, Галимҗанны алып чыгып киткән салкын январь төне, башларын иеп исәнләшми генә үтеп киткән танышлары килде. Кая барырга? Нигә дөнья шулай тар? Әйтерсең, ниндидер читлеккә һаман куа да кертә, куа да кертә...

— Эш кирәк иде шул, Кыяметдин...

— Иртәгә авыл советына кил, шунда сөйләшербез.

Ләкин белә идеме соң Айсылу авыл советында үзен ниләр көткәнен? Казандагы кара күзәтүченең үткен күзе, озын кулы Өтернәскә дә килеп житкәнен белә идеме ул? Ул белмәсә, Кыяметдин белә иде. Ире халык дошманы икәнен дә, Айсылуның үзенең дә шик-күзәтү астында икәнен белә иде Кыяметдин. Андый кәгазь-документлар иң беренче авыл советына килә. Шул кәгазьне алган көннән Кыяметдиннең тынычлыгы качты. Халык дошманының хатынын, гомумән, гаиләсен монда ул күзәтергә, «сакларга»,

ул-бу була калса, тиешле урынга хәбәр итәргә тиеш. Аяк астында җир яна. Күрше авылда бригада активына хәтле җыеп алып чыгып киттеләр. Кыяметдин үзе дә җәй буе киенгән килеш йтты. Инде шау-шу үтә, өстә калам дигәндә генә... Бу Айсылу белән нишләргә? Әйтергәме аның артыннан күзәтү оештырылганын? Ярар, әйтте дә ди, Айсылу баласы белән берәр җиргә чыгып качты, ди. Шуннан нәрсә? Шуннан Кыяметдиннең үзенә — таш капчык, стена...

Кыяметдиннең башы шул уйлар белән тулды. Кайчагында миен, җанын котыртып, тиле уйлар да килеп китте. «Менә хәзер Айсылуга өйләнсәң! Теге карчыга танау төрмәдә чериячәк ул, инде стенага терәмәгән булсалар. Менә ул хәзер сыгылыр, сынар иде... Ак гәүдәсе, ничә еллар саташтырып күз алдында тибрәнгән гәүдәсе Кыяметдин кочагында сынар иде... Авылда аңа хатын-кыз якын килергә курка. Теләсә, ул башка җирдән дә табар иде, әлбәттә, һаман шул Айсылу... Һаман... Өйләнсә, бәлки Айсылуга тимәсләр дә иде... Ә болай... кыл өстендә бит аның тормышы...»

Көн яктысы Кыяметдиннең башыннан бу уйларны куып тарата. Газеталарда көн дә яңа хәбәр — теге районның җитәкчесен кулга алганнар, обком кешеләрен утыртканнар. Бүген ил шпион белән тулган. Авыл советында, Айсылу Мостафинаны да күздә тотарга, дигән мөһерле кәгазь ята. Кыяметдиннең тар маңгае икегә ярылырлык була, ләкин җавап табалмый!

Менә Айсылу да килә. Гәүдәсе һаман зифа, сыгылмалы. Йөзе, сагышлы булса да, нәфис. Карашы да кайгылы, ләкин әллә нинди горур, чит караш. Әллә нинди өстенлектән, югарылыктан карый Айсылу Кыяметдингә. Арада һаман шул боз тавы...

Кыяметдин торып, ишек төпләрен әйләнеп килде. Кеше юкмы, дигәндәй, өйалдын ачып карады. Аннан тагын Айсылу янына килеп басты.

— Кит! — диде ул кинәт кенә Айсылуга таба иелеп.— Кит син Өтернәстән. Сиңа монда калырга ярамый.

— Кая?! — Айсылу, ярдәм көткәндәй, күзләрен тутырып Кыяметдингә карады. — Кая китим?

«Кая?» Кыяметдиннең башында мең төрле уй котырынып алды. Кая дисен? Авылдан башка җиргә чыгарып җибәрсә, аның үзен утыртачаклар. Белүгә, утыртачаклар. Өйдә үлем көтеп, карт атасы ята. Бөтен хуҗалык Кыяметдин кулында. Үзенең дә һәр адымы күзәтү астында. Кая җибәрсен ул үзеннән тилмереп җавап көтеп утырган бу бәхетсез хатынны. Бәлки... бергә китәргәдер?!

Кыяметдиннең бугазына төер килеп тыгылды. Ул, үз-үзен тыя алмыйча, тәкатьсезләнеп Айсылуның өстәлдә яткан кулларына капланды. Аннан ашыгып, буталып пышылдарга тотынды:

— Китик бергә? Казах далаларына качыйк! Миндә документлар бар... Качыйк! Юкса, харап буласың!

Айсылу, шашынып, урыныннан сикереп торды. Юешләнгән кулын җиңнәренә ышкырга тотынды. Кыяметдин әйткәннәрдән аның коты очты, чиркануы күзләренә, йөзенә бәреп чыкты. Ул, юеш бер әйбергә кагылырга курыккандай, артка таба чигенде, стенага килеп терәлгәч тә аңына килә алмады.

— Төрмәдә черетәләр бит үзеңне! — Бу юлы Кыяметдин ярсып, ачу белән пышылдады. — Бердәнбер юл — минем белән китү... Үзеңне кызганып әйтәм. Их, син!

Кыяметдиннең соңгы сүзләреннән Айсылу аңга килгәндәй булды. Күзенә яшь бәреп чыкты, дерелдәгән бармаклары белән йөзен каплады.

— Юк... — диде ул ишетелер-ишетелмәс кенә. — Үлгәндә дә бу хәл булмас. Үлгәндә дә... Галимҗан исән, аның гаебе юк, ул кайтыр... Ничек телең әйләнә синең миңа шундый сүзләр әйтергә?

Кыяметдин башкасын ишетмәде. «Үлгәндә дә!..» дигән сүз, миенә ябышып, акылын суыра башлады. Үлгәндә дә!.. Ярар... Җирәнәсең...

— Кит! — диде ул, үз-үзен кулга алып. — Мин сиңа теге сүзләрне әйтмәдем. Бүгеннән Казанга кит. Мин халык дошманының хатыны өчен җавап бирә алмыйм. Мин сиңа моны авыл советы председателе буларак әйтәм, аңлыйсыңмы? Югыйсә, үзем чарасына керешәм...

Казанның нәрсә икәнен икесе дә яхшы аңладылар. Ләкин өченче юл юк иде. Дөнья тар, һай, тар иде! Һәм ике кеше бер кояш астына сыймадылар... Ике генә кешеме?...

Августның кояшлы, җылы бер көнендә, әнисе Асылбикә карчыкны елатып, улы Газизҗанны җитәкләп, Айсылу юлга чыкты. Бакчадагы сары көнбагышлар иелә-иелә озатып калдылар, аяк астында җылы туфрак нидер пышылдады. Берсенең — мәңгегә, икенчесенең озак еллар кайтмаска китүен аңладылармы икән әллә алар?..

Казандагы күршеләре аларны куркып, шикләнеп кенә ачып керттеләр. Бу бүлмәләрнең барысында да элек Айсылулар яши иде, Галимҗанны алып чыгып киткәч, башкалар килеп утырды. Зал аша Айсылу үз бүлмәсенә үтте. Бүлмә эче буш, шыксыз кебек тоелды. Элек бу аларның йокы бүлмәләре иде. Галимҗан ай нурында аның кара толымнарын бер үрә, бер сүтә иде, шулар белән уйнарга бик ярата иде ул. Аннан аларны җәймә итеп Айсылуның ак тәненә каплый иде, ай нурыннан көнләшәм, шуннан яшерәм үзеңне, ди иде.

Салкын караватт тимеренә Айсылуның яшьләре тамып төште. Җилкәсендә кемнеңдер кулын тоеп, шашынып башын күтәрде. Газизҗан икән. Бала күңеле сизенә, юатмакчы була — сүзе юк. Бала үзе дә еллар буе хыянәтчеләргә, халык дошманнарына нәфрәт белән тәрбияләнгән. Һәм шул дошман — аның атасы. Малай гаҗиз булды, сүздән калды, бу сораулар ул җавап табарлык кына түгел иде шул.

Ул төнне дә, бөтен Казанны каплап, котырып яңгыр яуды. Җәйнең соңгы яңгыры иде ахры ул. Ана белән бала, яңгыр тавышыннан бераз тынычлангандай булып, йокыга киттеләр. Ана белән бала, бер-берләренең сулышын тыңлап, бер түбә астында соңгы төннәрен йоклыйлар иде...

Айсылу карчык урыныннан торып утырды. Яңгыр бераз басылган кебек. Ә хатирәләр аның саен өелеп өскә киләләр. Ул бит инде боларны искә төшерми иде. Күз яшьләре дә кибеп-корып беткән иде бит инде аның! Малае да, ире дә бик-бик еракта калганнар иде. Җәрәхәтләр җөйләнгән иде бит инде! Бер төндә нигә бүген бөтенесе өелеп өскә киләләр соң? Улым, Газизҗан! Нигә искә төштең? Анаң синең йөзеңне дә оныта башлаган иде бит инде... Кыйнады еллар, кыйнады, кыйныйкыйный ташка әйләндерде. Дөньяда бер өмете калмады! Күз яше кипте, җаны кипте... Арыды... Яши-яши арыды... Һәм менә, бер төндә, кабат бөтен гомерен яшәргә... Кем аның кипкән тәненә, җанына күтәрә алмаслык авыр йөк сала? Аның күргән газаплары аз тоелдымыни әле язмышына? Шушы бер төн белән тагы каһәрлимени бәгырен...

Төн уртасы якынлаша. Карчык авырлык белән күзләрен йома. Хәзер аның янына улы киләчәк. Юк, башта ул аның тавышын ишетер...

...Караңгылыкны ярып, Газизҗанның үзәк өзгеч тавышы яңгырады:

— Әни! Әнине калдырыгыз!

Айсылу сискәнеп уянып китте. Кайда ул? Газизҗан нигә кычкыра? Әллә ходаем...

Ләкин өй эче тын. Ишек бикле. Газизҗан яткан караваттан кинәт сулкылдау авазлары ишетелде. Айсылу ашыгып баласы янына килде. Газизҗанның бите яшькә чыланган, үзе юрган астында тыела алмыйча үкси иде.

— Ни булды, балам? — Ана шул сүзләрне әйтүгә, Газизҗан үксеп, башын аның күкрәгенә яшерде.

— Сине алып киттеләр, әни. Сине алып киттеләр...

Айсылуның эче җу итеп китте. Тезләнгән җиреннән идәнгә чүкте.

Нигә бала төшенә кергән? Нигә бала төшенә кергән?!

Аннан, аңына килеп, улын юата башлады.

— Төш кенә ул, балам. Син ул турыда уйлама, уйлаганга күрә керә ул. Нигә мине алып китсеннәр ди? Мин бит дошман түгел. Мин — укытучы кеше.

— Әти дә дошман түгел иде бит...

Айсылу башын тизрәк юрган астына яшерә. Яшенә төелеп, баланың колагына пышылдый:

— Атаң да дошман түгел иде... Аны барыбер чыгарырлар, менә күрерсең...

Бала, куркыныч сер әйткәндәй, әнисенә пышылдый:

— Әни! Мин Сталин янына барам! Фәтхи дә бара. Фәтхи әйтә, Сталин боларны белми, ди. Аңа әнисе әйткән.

Фәтхи — язучы Гали малае. Аның да атасын кышын алганнар иде. Ни турыда уйлап йөриләр икән сабыйлар!..

Айсылу улын юата башлады. Үзенең дә бу сүзләргә бик ышанасы килде. Әлбәттә, Сталин белми, белсә, бу хәтле кешене төрмәгә яптырыр идеме? Хатынның эченә шикләнү корты да керә — әгәр гаепләре булса? Бәлки, чыннан да, ул кешеләрнең гаепләре бардыр? Ә Галимҗанның? Галимҗанның гаебе юк! Юк! Галимҗан ялгыш кына эләкте. Ә язучы Гали, Сәйфи, Хәсән, Гомәр?.. Ә галимнәр? Ә укытучылар? Айсылу җавап таба алмый. Тәрәзә артында җәйнең соңгы яңгыры ява. Иртәгә нәрсә булыр? Монысын беркем белми. Монысын илдә беркем белми...

Таң атты. Айсылу авылдан алып килгән ризыкларны ипләп кенә бүлеп куйды. Әле алда ниләр күрәсен белеп булмый, эш юк, запаста бер тиен акча юк, ризык ягы да такы-токы. Кулында бала. Кара көзгә кереп баралар. Авылдан алып килгән ризыкларны иплә кенә тотар. Бәлки, ул арада әле эшкә дә урнашып куяр. Мәктәп тирәсенә бару турында уйларга да ярамый, я тегүгә урнашыр, я заводка керер. Эшчеләр арасында алай кулга алулар сизелми әле, иренең алынганын да әйтмәс, балалы ялгыз хатыннар азмыни? Ул арада бәлки әле Галимҗанны да чыгарып куярлар.

Шул уйлардан Айсылуның күңеле күтәрелеп киткәндәй булды. Йомырка, кыяр, помидорларны өстәлгә матур итеп тезеп куйды, ярып кына берничә яңа бәрәңге пешерде. Әнисенең якты йөз белән өстәл тирәсендә бөтерелгәнен күреп, Газизҗанның да күңеле күтәрелеп китте. «Сталин янына барырга!» — дигән карары башында тәмам ныгыды, ул үзен үсеп киткәндәй тойды. Табын янында да күңелсез сүзләргә, уйларга бирелеп утырмадылар. Тиздән беренче сентябрь җитә. Газизҗанга мәктәпкә барыр өчен кайбер нәрсәләр аласы бар. Шул турыда сөйләшеп алдылар. Айсылу кибетләргә үзе генә чыгып керергә булды. Газизҗан исә тизрәк Фәтхиләргә чыгып йөгерде. Малайларның да сөйләшер сүзләре, планнары күп иде.

Алар яши торган тирәдә кибетләр аз. Айсылу җәяүләп кенә Бауман урамына төшәргә булды. Төнге яңгыр шәһәр урамнарын чиста итеп юган, берни булмагандай, чат саен алма сатучылар утыра. Коймаларга, театр тирәләренә зур-зур афишалар эләнгән. Җәй көне башкорт театры артистлары килеп киткән икән, алардан калган ертык афиша җилдә җилферди. Галимҗан белән бер генә яңа спектакльне дә калдырмый иде алар. Театрда үзләренең махсус урыннары да бар иде. Галимҗан Айсылуның театрга матур итеп киенеп барганын ярата иде. Аннан кайтканда, «Халык сәхнәгә түгел, сиңа гына карап утырды», — дип шаярта иде. Айсылу уңайсызлана, кызара иде...

Күңелгә тагы моңсу уйлар килә башлады. Бар нәрсә Галимҗан белән бәйләнгән! Һәр урам, һәр чат, һәр йорт — барысы да аның белән бәйле. Шулар арасында дивана кебек йөри Айсылу. Кибетләргә керә, малаена вак-төяк ала, куллары хәрәкәтләнә, ә башында һаман үз уе. Ичмаса, берәр танышлары да очрамый бит! Бәлки ни булса да беләләр-

дер, Галимҗан бит үзе генә утырмый, бәлки суд булып, гаепсез дип тапкаиннардыр? Алай дисәң, гаепсез булса, чыгар иде, кайтыр иде. Ябылган урыннарына, Кремль тирәсенә барырга ярамый, Галимҗан үзе рөхсәт итмәде. Ул тирәдә күзәтү аеруча көчле, халык дошманнары янына бары тик халык дошманнары гына килергә мөмкин икән. Кая барырга? Кемнән белергә?

Кибеттән урамга чыга. Газеталар сатып торучыны күрә һәм ашыгып берничә санны ала. Латин хәрефләренә башта күзләре ияләшмичә тора, ашыгып Мостафин фамилиясен эзли башлый. Атылган булса да, аклаиган булса да — газетага язылырга тиеш! Калтырап, шашынып газеталарны актара. Аннан, акылына килеп, туктап кала. Җүләр! Нәрсә эшли ул! Нишләп атылсын Галимҗан! Курку нәрсәгә китерә бит! Ил белән утыралар, хәтта обком кешеләре утыра, язучыларны алып бетерделәр, укытучы, врач, юристларны алдылар. Бөтенесен атсаң, илдә эшләргә кем кала? Менә бит чамадан тыш хәвефләнү кешене ни эшләтә! Аннары Айсылу тынычланып укый башлады.

Язучылар арасында һаман ыгы-зыгы. Бер-берсеннән корткычлык эзлиләр. Әнә Фатих Кәрим, Хәсән Туфанны бетереп ташлаганнар, Кутуйга кизәнәләр. Кем ялгыша? Кем корткыч? Икәүнең бер-берсен сатып төрмәгә утыруы кемгә кирәк?

Газеталар шундый хәбәрләр белән тулган. Инде алынганнар турында гына бер хәбәр дә юк. Халык арасында гына төрле шомлы хәбәрләр сөйлиләр — Галимҗан Ибраһимовны атканнар икән, Шамил Усманов үзүзен үтергән. Инде шундый зур, билгеле кешеләр дә котылып кала алмаганны... Галимҗан нишләр? Аның Галимҗанын нишләтерләр?

Айсылу куркып як-ягына каранды. Әйтерсең, аның уйларын кемдер күзәтеп килә, күзәтеп тора! Шулчак эшләпә кигән бер чандыр ир, кибет почмагыннан борылып, юкка чыкты кебек. Әллә, чыннан да, күзәтәләрме? Курыкканга гына шулай тоеламы? Айсылу тизрәк кибет эченә, халык арасына чумды. Бераз вакытны уздырыр да өенә кайтып китәр. Өенә кайтып китәр дә бикләнер, беркемгә ачмас, ул бит бер нәрсә дә эшләмәде, ул бит бер нәрсә дә эшләмәде!!!

Халык арасында Айсылу кинәт кенә Зөләйханы күреп алды. Аларның ирләрен бер көндә алганнар иде. Өченче баласына авырлы булып калган Зөләйха, ире китүгә, баласын вакытсыз тапты. Хәзер әнә шул баласын юрганга төреп күтәргән. Калган икесе ике ягыннан итәгенә ябышкан. Олы кызы быел беренче класска барасы иде, шуңа әйберләр алырга чыккандыр. Элек алар еш кына Айсылуларда кунакта булалар иде, балалар да бер-берсен беләләр иде. Зөләйханың олы кызын, шаяртып, Газизҗанга ярәшеп тә куйганнар иде. Аларның да оялары пыр туздьт.

Кешеләр арасында бәрелә-сугыла, Айсылу Зөләйхага таба ашыкты, ерактан ук исемен әйтеп эндәште. Зөләйха кинәт сискәнеп башын күтәрде, үзенә таба якынлашып килгән Айсылуны күргәч, бер мизгелгә югалып калды. Аннан, балаларына иелеп, тиз-тиз нидер әйтте дә, алыр әйберен дә алмыйча, ишеккә ташланды. Айсылу баскан урынында катып калды. Кемнән кача Зөләйха? Әллә аны да күзәтәләрме? Айсылу артына борылып карады, шикләнерлек нәрсә күрмәде. Һәм тагы Зөләйха артыннан ашыкты. Зөләйханың кечерәк баласы абынып китте, аны торгызырга иелгән арада Зөләйха тагын Айсылуга күз ташлап алды. Айсылу, тез астына китереп суккандай, туктап калды. Ул Зөләйханың карашында курку да, ялвару да, нәфрәт тә күргән кебек булды. Шунда Айсылуның башына барып житте — Зөләйха аннан кача иде! Менә ул, балаларын ияртеп, ишеккә барып җитте, халык арасына буталып, урамга ук чыгып китте. Айсылу аның артыннан берничә адым атлады да туктап калды. Зөләйха йортлар арасына кереп тә югалды.

Соңыннан, ун ел буе, шул Зөләйха белән бер камерада утырды, чарасыз калып егылганда, бер-берсен юаттылар, иректә узган көннәрен ис-

кә төшереп юандылар, тик бу вакыйганы гына беркайчан да искә алмадылар...

Шулай... Зөләйха качты. Айсылу тагын бер кат үзенең халык дошманы хатыны икәнен исенә төшерде. Зөләйха да халык дошманы хатыны иде. Алар хәтта бер-берләреннән дә куркалар иде...

Кайтып якка таба борылды. Ул арада кич тә җитеп килә иде, көн кинәт суытып җибәргән кебек булды. Газизҗан да кайткандыр, дәфтәр-каләмнәре белән сөендерсен әле баланы.

Айсылу ашыгып-ашыгып атлый башлады. Һәм тагын үзен кемдер күзәткән кебек тоелып, сөрлегеп китте. Күз кырые белән генә җилкә аша карады. Шул! Чандыр гына кечкенә гәүдә, зәңгәр күзләре Айсылуны тишәрдәй булып карыйлар, үзләре салкын, җансыз. Айсылу йөгерә үк башлады, икенче катка ничек менгәнен хәтерләми, ишеккә килеп капланды, күрше хатынны бәрердәй булып үз бүлмәсенә үтте, өстәл янында нидер ясап утырган Газизҗанны сискәндереп, караватына ауды. Аннан кинәт сикереп торды, ишекне тиз генә бикләп куйды, ул гына җитми кебек тоелгач, урындык белән дә терәтте. Колагын ишеккә куеп, бераз тыңлап торды. Ишек артындагы тынлык шактый озынга сузылгач кына бераз тынычлангандай булды, минут эчендә картаеп, суырылып, караватына килеп утырды.

Анасының күңелсез кайтканын күргәч, Газизҗан да боекты. Хәтта дәфтәр-карандашларга кагылмады, киенеп, тизрәк урамга чыгып китәргә ашыкты.

— Мин озак тормам, әни! — Газизҗанның соңгы сүзе шул булды. Аның тавышын Айсылу бүтән ишетмәде...

«Мин озак тормам!» — диде. Менә инде киткән җиреннән Айсылу да кайтты, бик озак торып, чәчләре агарып кайтты. Ә бала һаман юк! Менә инде әнисе бөкрәйгән бер карчык булды. Ә бала һаман юк!.. Озак тормам дигән иде — мәңге юк...

Айсылу карчык торып ишеккә таба бара. Урамда яңгыр туктаган, ахры — шыбырдаганы ишетелми. Дөбердәгән тавышлар да ерагая төшкән. Яшенле яңгыр уза, карчык күңелендә күтәрелгән газаплы хатирәләр генә узмый. Өйалдына чыга, башы әйләнеп, ишеккә сөяләә. Урамда юеш, дымлы төн. Яшен әле ерак китмәгән — Әрә буенда ялтыраганы күренә. Яңадан әйләнеп килергә охшаган. Бәла-каза, ялгышлар да шулай — әйләнеп килә. Әйләнеп килә дә тагын бер кат суга.

Иске бишмәтен җәеп, карчык болдыр баскычына утыра. Йөрәгенең сикерүе бераз басыла төште кебек. Югыйсә, гел шушы төндә үләр кебек иде. Көндездән әзәрлекли башлаган хатирәләр аны куркыта, ул алар авырлыгын күтәрерлек түгел иде. Күңелләне искә төшерү генә рәхәт бит. Авыры һаман йөрәкне яра, телә. Ул аларны искә төшермәскә тырыша. Булган. Күрелгән. Алар язмышына шулай туры килгән. «Кем гаепле?» — дип тә эзләнмәде, ул авыр елларын күңеленең иң ерак почмагына яшерде. Бер генә кешене гаепләргә корбаннар артык күп иде, бик күп иде. Ул елларда сүз кузгату түгел, бу хакта уйларга да ярамый иде. Әкренләп миңгерәүләнде, ул еллар хакында уйланмас булды Айсылу карчык. Шуңа үч иткәндәй, бүген уйлары үзләре дөньяга бәреп чыктылар, хәзер арык тәнен, җанын яндыралар, яткан урыныннан торгызалар, җавап эзләп караңгы урамга чыгаралар. Нинди җавап? Үләргә торган карчыкка кем җавап бирсен? Дөньяның аның уйларында ни эше бар? Дөньяның ул елларда ни эше бар? Ул чакта утыз җиденең августы иде, бүген сиксән җиденең августы. Ярты гасыр баскан да куйган. Кешеләр белми. Нәрсә яшьләр? Айсылу карчык үзе дә һаман белми бит нәрсә өчен утырганын, иренең ни гаебе барын, улының кайда икәнен. Дөньяның кемдә ни эше бар? Әнә, яшен дип тормыйлар, каршыдагы йортта дөбердәтеп туй ясыйлар. Тәрәзәләрен ачтылар, ахры, бөтен урамга гармун тавышы яңгырады. Тегендә, төрмәдә, Зөләйха белән әй хыялланалар иде — исән-сау кайтсак,

Газизҗан белән Зөһрәне өйләндерәбез, дип! Себер урманының шаулавын тыңлый-тыңлый, туй турында хыялландылар. Хәзер Зөләйханың ул кызы үзе алтмышка җитеп килгән карчык инде. Ә Газизҗан һаман унөч яшьлек үсмер бала. Исән булса, ул да алтмышның теге ягында булыр иде. Ә хәзер гел бала, гел бала...

Тагын искә төште! Тагын!.. Нинди төн булды бу?! Ашыга-ашыга искә төшеп калырга тырышалар. Аңлатып калырга тырышалар. Үзенең фаҗигасен. Ил фаҗигасен. Меңләгән корбаннар фаҗигасен...

...Газизҗан: «Мин озак тормам, әни!» — дип чыгып китте. Айсылу урын җәя башлады. Тизрәк төнне җиткерергә, бөгәрләнеп ятарга, качарга, качарга, качарга!.. Чөнки аның баласы бар, шул баласын үстерәсе бар! Ул курка — күзәтүләрдән курка, шомлы хәбәрләрдән курка, кешеләрдән курка. Ә качарга башка урын юк.

Урамда машина килеп туктаганны ул ишетте, ләкин тәрәзәгә бармады, мендәрен күкрәгенә кыскан килеш туктап калды. Менә баскычта аяк тавышлары ишетелде, менә зал аша үттеләр, менә аның ишегенә җиттеләр. Менә керделәр. Ниндидер кәгазьләр күрсәттеләр, җыенырга куштылар. Ә ул, мендәрен тотып, һаман басып тора. Кемдер килеп кулыннан мендәрен алды, хатын-кыз иде бугай, әйберләрен җыярга булыша башлады. Галимҗанны да нәкъ шулай алып чыгып киткәннәр иде. Тын алырга да, борылып карарга да ирек бирмичә. Үзен алып чыгып киткән хатынны да Айсылу соңыннан Себер төрмәләрендә күрде. Аның да бары тик корбан икәнен аңлады, ләкин ни өчен, кем өчен кирәк иде ул корбаннар — анысын гомер буе аңлый алмады.

Урамга чыккач, борыла-борыла улын эзләве хәтерендә. Караңгыда Газизҗан күренмәде. Анасын алып киткәннәрен өй почмагыннан карап тора идеме бала, әллә ул тирәдә бөтенләй юк идеме — Айсылу белмәде. Улының күренмәвенә бер яктан сөенде дә шикелле. Газизҗан монда булса, аны баладан аерып ала алмаслар иде! Куллары белән, тешләре белән киеменә ябышыр, җирләрдән өстерәлеп барыр, башын юл ташларына бәрер иде — улыннан аерылмас иде... Барыбер аерырлар иде... Ә болай... бушлыкны кисеп алган кебек — юк, һәм күзеңне йомып караңгылыкка атлыйсың...

Шул китүдән Айсылу яңадан бу йортка әйләнеп кайтмады. Галимҗан да кайтмады. Газизҗан да... Алай да... Ире белән очрашканнар икән ишек төбендә. Инде чәчләре агарып, бөкреләре чыккач. Инде үләр вакытлары җиткәч... Анысы соңыннан...

Ә теге чакта Галимҗанны гел «чит ил шпионы» дип йөрттеләр. Бөтен кәгазьләргә шулай язылган иде. Айсылуны да шуларга кул куярга өндәделәр. Айсылу шуларга кул куйса, иреннән ваз кичсә, аны чыгарасылар икән. Күп хатыннарга шулай дип әйткәннәр. Кайберәүләр балаларын, киләчәкләрен уйлап, ирләреннән ваз кичтеләр, шпион икәнлекләрен раслап, кул куйдылар. Ләкин алар да, караңгы көзге төндә вагоннарга төялеп, барыбер Себер ягына киттеләр. Берни ярдәм итмәде...

Айсылуны кечкенәдән юаш, куркак диләр иде. Беренче көннәрне Кремль астындагы төрмәдә ул да коелып төште, әллә куркудан, әллә соры стеналарның шыксызлыгыннан, әллә туңудан дер-дер килде. Каушаудан җылы киемнәрен дә алмаган булган, кемдер иңенә мамык шәл салды, алай бетеренмәскә кушты. Айсылу шунда гына игътибар белән як-ягына карады — күбесе танышлар. Әнә, бер почмакта, юешләнгән күкрәкләрен кысып, Зөләйха утыра. Аның бала имезер вакыты җиткән, ахры, сөте юка күлмәк аша таш идәнгә тама. Әнә, Фәтхинең анасы Мәрьям. Әнә язучы хатыннары, активист хатыннар, танылган врачлар, юристлар. Карашлары алай ук өметсез түгел: «Тикшерерләр дә чыгарырлар». Барысының уенда шул. Бу өмет әле озак еллар дәвам итәр, кайсыларының ун, кайсыларының егерме елга сузылыр. «Ул белмидер. Ул белсә, чыгарыр»... Шул өметләр белән күпләр Себер урманнарында

күмелеп тә калыр, кайтканнары да аны гаепләргә ашыкмас. Корбаннар, һай, корбаннар...

Айсылу иреннән ваз кичмәде, шпион икәнлегенә дә кул куймады. Чит илләр белән хат алыша дигәннәренә дә ышанмады, чөнки Галимҗан ата-анасына хат язарга да иренә торган кеше иде. Гомумән, язарга яратмый иде. Кешеләр белән дә ул хәтле аралашмады. Башта районнарда эшләде, аннан Казанда баш-аягы белән эшкә чумды. Җор кеше иде, күңелендә тырнак очы кадәр дә кер саклый алмый иде. Бала җанлы, уенчак кеше иде. Ышанмады Айсылу аның шпион икәненә. Ышанмады, кул да куймады.

Шулай итеп, барысы да хәл ителде. Күзгә салкын, шыксыз бер көнне аларга — халык дошманнарының хатыннарына — хөкем карары чыгарылды. Аларның кайсын — ун, кайсын — унбиш елга Себергә сөрделәр, ә балаларын, аерып алып, балалар йортларына, дәүләт тәрбиясенә тапшырдылар. Илне дошманнардан, аның нәселеннән арындырдылар. Төрмәләр, каберлекләр, ятимнәр һәм җүләрләр йортлары шыплап тулды. Канның да, купшы-кызыл сүзләрнең дә төсе бертөрле иде...

...Еракта поезд кычкырткан тавыш ишетелде. Айсылу карчык, башын күтәреп, шул якка карады. Алардан тимер юл станциясе җиде генә чакрым. Төннәрен поездларның кычкыртканнары ачык ишетелә. Поезд тавышы йөрәгенә ярамый аның. Шуны ишеткән саен үкереп елыйсы килә. Ә күз яше юк, беткән. Ул яшьсез генә сулкылдый, ыңгыраша. Бу юлы да моңсу тавыш җанына килеп бәрелде. Нәкъ теге еллардагы кебек...

Поезд кузгалып киткәнче, Айсылу улын көтте. Рәшәткәле «Столыпин вагоннары» юка өс-башлы хатыннар белән шыгрым тулган. Утырып түгел, басып торырга да урын юк. Аяк астындагы салам пычрак белән тапталып, изелеп беткән. Ләкин әле аяк астына караучы юк. Ишек янына якынлаша алган һәркемнең күзе урамда. Төн карасыннан таныш йөзләрне эзлиләр. Суд вакытында аларга әйттеләр, балаларыгыз сездән ваз кичте, алар хәзер халык дошманнарының балалары түгел, диделәр. Күпләр моңа күңеленнән ышанмады. Айсылу да ышанмады. Аның Газизҗаны анасыннан баш тартмаячак! Әйтсә дә, куркудан гына әйткәндер. Кремль астында суд карарын көтеп утырганда, башкаларның балалары күренеп-күренеп китте. Ишегалдына түгәрәк ясап йөрергә чыкканда, таш койманың теге ягыннан бала елаган, дәшкән, чакырган авазлар ишетелеп тора иде. Тик Газизҗан гына нигәдер бер тапкыр да килмәде. Нәрсә булды, нигә кинәт юкка чыкты бала? Айсылу билгесезлектә газаплана иде.

Вагоннар әкрен генә тартылып куйдылар. Шуны гына көткәндәй, меңләгән хатын берьюлы үкереп җибәрде. Ишек янына туры килгәннәр яртылаш тышка сузылып, эчтә калганнар стена аша караңгылыкка кычкырдылар. Чәчләре тузган, киемнәре сыдырылып төшкән шашкан аналарны хәрбиләр, этә-төртә, кире вагоннарга тутырдылар, урамда буыла-буыла этләр өрде, кемдер ачы тавыш белән елап җибәрде, ул вокзалдагы ир-атның сүгенгән тавышы белән буталды. Ул арада ишеккә асылынган яшь бер рус хатыны бөгелә-сыгыла көләргә, нидер кычкырырга тотынды. Бу мәхшәрдә көлү авазы елау авазыннан да сәеррәк, шомлырак иде. Тәртип өчен җавап бирүче хәрби кесә фонарен хатынның йөзенә юнәлтте. Яктыда аның шашып акайган күзләре, җилкәләренә таралып төшкән сары озын чәчләре күренде. Хәрби аңа якынрак килеп нидер әйтте. Янындагы эте хатынга карап сикерә-сикерә өрергә тотынды. Хатын көлүеннән кисәк туктап калды, тәне һөҗүмгә ташланган ана җәнлек гәүдәсе кебек киерелде һәм, хатыннар аша үрелеп, ул үзенә каршы өргән этнең битенә төкерде. Аннары тагын шашкан тавыш белән: «За Сталина! За нашего отца!» — дип кычкыра башлады. Ул арада вагоннар тагын селкенеп куйдылар һәм, Себер ягына карап, әкрен генә кузгалып киттеләр. Юлга чыкмас борын җүләрләнгән хатынны салам

өстенә сузып салдылар. Ул инде көлми иде, сугымга салган мал кебек, вагон түбәсенә карап ята... Кая алып баралар, нигә — аңа инде барыбер иде...

Поезд инде станцияне чыгып барганда, вагоннар артыннан берничә карт-карчык та ярде. Тоткыннарны озатканнарын чамалап, алар вокзал тирәсендә тәүлек буе чуалганнар иде. Вагон тирәсеннән ишетелгән үкерү тавышы аларга балаларының монда икәнлеген сиздергән, әнә хәзер, абына-сөртенә, поезд янәшәсеннән йөгерәләр.

— Балаларыгызны җыеп алдылар! Детдомнарда балалар!

— Кызым, бәхил бул! Бәхил...

— Надя, Надежда! Сережу в детдом забрали. Слышишь...

— Кызым, балам... Ходайдан сора, ходайдан...

«Җыеп алдылар!»— дигән сүзне ишетүгә, Айсылу пычрак салам өстенә сыгылып төште. Әле Газизҗан авылга кайтыр, әнисе янына сыяр, дип өметләнгән иде. Инде аны да алгач... йә, хода! Нинди гөнаһларым өчен болай газаплыйсың мине?! Балама гына тимәсәләр дә газапларым җиңелрәк булыр иде! Ун ел! Газизҗаннан, Галимҗаннан башка ун ел! Юк! Хәзер үк төшеп калырга! Күзне йомарга да караңгылыкка сикерергә! Ун ел!

Айсылу аяк араларыннан үрмәләп ишеккә бара. Башы белән тимер рәшәткәгә килеп төртелә. Кая барсаң да — шул рәшәткә, рәшәткәгә аның кебек үк йөзләгән хатын сарылган. Вагон коридоры буйлап эт житәкләгән хәрбиләр йөри. Айсылу тимер рәшәткә буенча идәнгә шуып төшә, чарасызланып, үксеп, сузып елап җибәрә. Аңа кушылып вагон ярыкларында җил улый, тәгәрмәчләр ярсып дөберди, ара-тирә поезд моңсу тавыш белән сузып-сузып кычкыртып җибәрә. Туган җирләрен, балаларын, ата-аналарын калдырып, кая бара бу хатыннар? Нигә баралар? Монысын беркем белми. Мал куган кебек куалар да куалар...

...Станция яныннан үтеп киткән поезд моңсу тавыш белән тагын бер кат кычкыртып алды. Айсылу карчык урыныннан торды. Аякларын авырлык белән генә кыймылдатып, яңадан өйгә керде. Өйдәгеләр барысы да йоклыйлар. Үги улы Касыйм гына вакыт-вакыт ыңгырашып куя. Эше авыр аның. Көне буе тимер-томыр арасында. Өйгә йокларга гына кайтып егыла. Бу ятим баланы нишләптер Газизҗанына охшатты ул. Әтиләренә дә, өч ятим өстенә, кызганып кына чыкты. Алары инде кайткач булды. Ул вакытта Айсылу үзе дә бөтенләй башка кеше иде инде. Бөтенләй башка... Газизҗанын югалтканнан соң, ул бөтенләй яшәүдән туктады. Тегендә «Кайтам, улымны күрәм!»— дигән өмет кенә яшәткән иде аны. Газизҗанның юк икәнен анда чакта ук белсә... беренче агач аныкы булган булыр иде. Белмәде, очып кайткан иде бит, шуышып кайткан иде...

Авылның теге башында Кыяметдин картны да һаман йокы алмый... Шулай, һаман бер чонгыл тирәсендә бөтереләләр. Теге вакытта, Айсылу белән улын Казанга куып җибәргәч, Кыяметдин инде аларны башка күрмәм, тормышларын да белмәм, тынычланырмын, дип уйлаган иде. Киткәннәр икән, киткәннәр, илдә чыпчык үлми. Һәркемнең үз язмышы, үзенә язылганын Айсылуга да үзенә күрәсе. Алалар икән — алалар, анда Кыяметдиннең бер катнашы да юк. Кала икән — кала, аннан күз күрер. Кыяметдин, алай да районга барып, Айсылуның Казанга киткәнен хәбәр итеп кайтты. «Вакыты шундый,— дип аклады ул үз-үзен.— Һәрберебез җеп очында тора».

Шулаен шулай, тик менә Айсылуны күргәч, нигә һаман җаны актарыла соң аның? Әйтерсең лә аның утырып чыкканына ул гаепле. Кыяметдин булмаса да алып китәрләр иде Айсылуны, ире өчен алып китәрләр иде. Кыяметдиннең гаебе, булса да, Айсылуның улы каршында гына бар. Ә анысын үзеннән башка, ходайдан башка беркем белми...

Айсылулар китеп, өч-дүрт көн үткән иде, ахры, станциягә ат белән

барды Кыяметдин. Йомышын йомышлап, төштән соң кайтырга да куз-
галды. Атын юырта төшеп тузанлы юлдан куганда, тәгәрмәч астыннан
чыккандай, юлда бер карачкы пәйда булды. Өстендәге киеме тетелеп бет-
кән, аягына ниндидер чүпрәкләр ураган. Карачкы, аны күргә, урылма-
ган арыш арасына чумды. Кыяметдингә бу сәер тоелды — тынгысыз за-
ман, кем йөрмәс авыл арасында. Башта атын чаптырып китеп барырга
уйлады, аннан карачкының ябык, кечкенә гәүдәсен күз алдына китереп,
туктап калды.

— Чык,— дип кычкырды ул арыш арасына карап.— Чык, тимим.
Өтернәскә кайтасыңмы? Чык, утыртып алып кайтам...

Арыш арасы башта дәшми торды. Аннары, башаклар селкенеп куй-
ды да, кечкенә генә йөз күренде. Бите каралып, танымас хәлгә килгән,
арык йөзендә зур күзләре генә утырып калган. Өстендәге киеме тәмам
теткәләнеп беткән, тезләре канга баткан, аягына чүпрәк уралган... Кыя-
метдин, сәерсенеп, аны баштанаяк карап чыкты. Аннан тагын йөзенә ка-
рады. Бала бит бу! Арыш арасында чак селкенеп басып тора, катырак
җил иссә, авып китәр кебек. Карашы таныш... Бик таныш...

Шул чак Кыяметдиннең түбәсенә китереп суккан кебек булды. Тук-
та! Айсылуның улы түгелме соң бу?! Аларның җитәкләшеп чыгып китүен
авыл советы тәрәзәсеннән әле бер көнне генә карап калган иде бит. Шу-
шы малай. Йөзе, карашы да нәкъ Айсылу.

Малайны тануга, эшнең нидә икәнен аңлады Кыяметдин. Алганнар.
Димәк, Айсылуны да алганнар. Бала авылга кайтып бара. Качып кайт-
канга охшаган.

Малай аңа якын килергә һаман курка иде. Кыяметдин аны үзе чакы-
рып алды.

— Син Айсылуның улы, ахры? — диде ул, малайны өркетмәс өчен,
сак кына.— Әбиең янына кайтасыңдыр? Утыр, мин дә шунда бит.

Малай аны таныган иде инде. Авылда күргәне бар иде. Шуңа күрә
куркуы да үтте, әкрен генә ат янына килде. Ләкин арбага менеп утырыр-
га хәле калмаган иде, калтыранган нечкә куллары аны тыңламадылар.
Кыяметдин үзе аны сак кына арбага тартып менгерде, чапкан яшел пе-
чән өстенә утыртты. Ат җай гына кузгалып китте. Кыяметдин малайдан
сораштыра башлады:

— Кайда бу хәлгә төштең? — диде ул, аның теткәләнеп беткән өс-
башына күрсәтеп.— Ничек бу киемең белән поездга утырттылар үзеңне?

— Мин җәяү кайттым,— диде малай әкрен генә.

— Ничек җәяү? Кайдан?

— Казаннан арлык җәяү кайттым. Поезд артыннан. Утырырга ак-
чам булмады. Курыктым да...

Кыяметдиннең тәне өшеп киткән кебек булды. Аннан малайның аяк-
ларына күз салды. Чүпрәк арасыннан суелган, канаган бармаклар күре-
неп тора иде.

— Нигә юлга болай гына киенеп чыктың соң? Өеңдә кием-салымың
бардыр бит?

Малай бертын арба селкенгән уңайга чайкалып барды. Ишетмәдеме
әллә дигәндәй, Кыяметдин аңа иелеп карады. Малайның керле бите
юешләнгән, юл-юл эз төшкән иде. Малай елый иде.

— Йә, йә,— диде Кыяметдин, аны юаткандай итеп.— Буласы бул-
ган... Анаңны кайчан алып киттеләр?

— Өч көн элек... Мин Фәтхиләргә киткән идем. Кайтсам, ишек бик-
ле.— Малай сулкылдап куйды.— Без күршеләр белән торабыз. Ачмады-
лар. Үзләре өйдә иде, йөргәннәрен ишеттем. «Әни!»— дип тә дәшеп кара-
дым. Аста яши торган әби, ишектән башын тыгып кына: «Анаңны алып
киттеләр!»— диде, аннан тизрәк ишеген япты. Урамга чыгып йөгердем.
Караңгы иде. Безнең тәрәзәдә ут юк, күршеләрдә бар. Өй почмагында
бик озак чүгәләп утырдым. Ашыйсым килде. Салкын иде. Кача-поса гына
Фәтхиләргә бардым. Нигәдер, качарга кирәк, дип уйладым. Фәтхи өйдә

иде, капланып елап ята иде. Аңа няреп кечкенә сеңлесе шыңшый. Аларның да аналарын алып киткәннәр. Ишекне бикләп, өчәү бергә ятып йокладык. Иртә белән аларның күршеләре әйтте, сезнең барыгызны да жыеп, детдомга бирәләр, диде. Шуны ишетүгә, мин вокзалга чыгып качтым. Авылга кайтырга. Поездга утырырга курыктым. Гел юл буенча йөгердем...

Кыяметдиннең эченә шом керде. Детдомга жыялар, диген... Жыялар, димәк, тамырдан чистарталар. Ул атын акрынайта төште.

— Ничә көн кайттың? — диде ул, сүзсез калмас өчен генә.

— Өч көн, өч төн. Арыш уып ашадым, бәрәңге, кишер... Кырда ни үсә...

Малай арыган иде, ахры, башы бер якка янтая башлады. Кыяметдин аны иплап кенә печән өстенә яткырды, баш очына иске кожанын салды, өстенә жәймә япты. Малай шундук изрәп йокыга китте.

«Алай,— дип уйлады Кыяметдин, атын тагын да акрынайта төшеп.— Детдомга жыялар, диген. Бу малайны алып кайтып әбисе янына яшергән өчен миңа нәрсә булыр? Нәрсә булсын, стена! Тирә-юньдә бер мин калып барам кагылмаган. Бу малайны яшерсәм, үземә стена...»

Атын тагын да акрынайта төште. Аннары арыш арасыннан уратып, жай гына кире борды. Инде Өтернәснең өй түбәләре дә күренә башлаган иде, шуңа күрәме, ат башта бераз чыгымчылады, атлар-атламас кына барды. Сыртында каеш чыбыркы уйнап алгач, үргә таба чабулап алып китте. «Бу хужа жүләрләнгәнме әллә? — дип уйлады ат.— Авыл күренгәч, кире борылды. Кая куа инде ул аны хәзер, төнгә каршы?..»

Ат район үзәгенә ак күбекләрен агызып килеп туктады. Дежур милиционерны дөбердәтеп уятты да Кыяметдин аның кулына йокылы-уяулы малайны тоттырды.

— Менә,— диде, Газизжанга карамый гына.— Халык дошманының малае. Казаннан качып кайткан.

Төн уртасында килеп кергән авыл агаена милиционер егет астан гына ачуланып карап алды.

— Таң атканын көтә алмадың инде син,— диде ул теш арасыннан гына.— Котың чыкты?

— Син, агай-эне, сүзеңне чамалап сөйлә. Нинди заманда яшәгәнеңне оныткансың. Разный контр мыжгып торганда...

Милиционер егет аңа сүзен бетерергә ирек бирмәде. Теш арасыннан гына: «Пошел ты...»— дип сүгенеп куйды да, идәнгә чүгәләгән баланы кузгатып, бүлмәсенә кереп китте. Кыяметдингә урам якка атлаудан башка чара калмады. Милиционер аның кем икәнен дә сорамады, кул да куйдырмады. Соңыннан Кыяметдин аның шулай булуына сөенеп бетә алмады. Ул милиционер сугыштан кайтмады, Айсылуның улы да юкка чыкты, шулай итеп, ул баланы тотып бирүен Кыяметдин үзе генә белә. Һәм бер ходай белә. Бу вакыйганы искә төшерергә яратмый ул. Заманы шундый иде — бетте-китте. Тик Айсылу карчыкны күргәндә генә барысы бугазга килеп төелә — ул бала, үзенең малай чагы, ярату, курку, нәфрәт, ачу! Ичмасам, авылдан да китеп бармады! Соңыннан, элекке Айсылудан инде күзләре генә торып калгач та дәшеп карады бит аңа Кыяметдин. Үзенә сыендырып, гөнаһларын юмакчы иде. Юк, Айсылу һаман шул Айсылу булып калды. Өч баласы өстенә көтүче Вәлигә барса барды, Кыяметдин ягына әйләнеп тә карамады. Төрмәләрдә утырып кайтты, көтүче хатыны булды, авыл хатыннары кебек, жилкә белән печәнен ташыды, утынын кисте, каралды, янды, корышты — ләкин сынмады! Кыяметдин каршында беркайчан да керфеген түбән төшермәде. Сынын төз тотты. Бүген, мәктәптә теге кыңгырауны тапкач та, ялынуын көткән иде ул аның. «Кыяметдин!»—дип, елый-елый ялваруын көткән иде! Күзе коры, күңеле коры, тәне кипкән, аның да бәгырен корытты. Гомер буе бер ягымлы сүзен, бер ягымлы карашын кызганды. Күз алдыннан да китмә-

де, якын да килмәде. Бергә яшәгән авыл тәмугка әйләнде. Бу хатынга ул дөньядагы иң зур бәхетсезлекләрне теләде, шулар сындырып, башын, билен идерер дип көтте. Юк! Бәхетсезлек килгән саен, ул ката гына барды. Һәм кипкән сынга, мумиягә әйләнде. Инде бернинди фаҗига дә аны эретә алмас кебек. Ходайның каһәре төшсен бу таш сынга! Юк, нәрсә тели... Ходай үзе сакласын. Чарасызлыгыннан гына каргый аны Кыяметдин карт. Каршында гаебе барлыгын да белә, ходайдан ничә тапкыр шул гаепне юу мөмкинлеген сорады. Юк. Юк! Ә Кыяметдин картның бу дөньядан андый зур гөнаһ белән китәсе килми. Кыңгырауны алуы да шуңа иде, аның артыннан Айсылу карчык барыбер килер, ялыныр, йомшарыр, сөйләшер дип уйлады. Бәлки, ул еллар өчен кичерер дә иде. Заманы нинди иде бит! Кыяметдин үзе дә кечкенә бер шөреп кенә иде. Шул кара, котырган заманга ул нинди үзгәреш кертә алсын?! Һәркемнең җаны кадерле, җан сакларга кирәк иде. Шуңа күрә Кыяметдин сенде, аска китеп торды, ә Айсылулар, Галимҗаннар әнә, өскә чыгып, ургыла-ургыла агып киттеләр. Ничә тапкыр бетә яздылар, тагы калыктылар, шушы бер гомерне, бата-чума, ут белән су арасында яшәделәр. Гомер ахырында нигә Кыяметдин алардан кичерү көтә соң?! Аның ни гаебе бар?! Төптә ятып, исән калганы өченме? Аның да гомере бер генә бит... Бер генә!!!

Картлык көнендә ул дингә ышана башлады. Авыл советында эшләгәндә, мөһер үз кулында вакытта, ул үзе алла иде. Картлык килеп, посттан киткәч, кечерәйде дә калды. Тирә-ягында әллә нинди шыксыз бушлык. Ул гел рәтен белеп, тормышны төп башына утыртам, дип яшәде. Гөнаһым бардыр, кеше өлешенә керәмдер, дип уйламады, хәйлә белән умырып ала бирде. Сугыш башланыр алдыннан балта белән кулына ялгыш чапкан иде. Ярасы алай тирән булмаса да, шактый канын югалтып, өйдә ятты. Бөтен авыл халкы Кыяметдиннең кулына чапканын белә иде. Сугыш башлану хәбәрен хатыны йөгереп кайтып әйтте. Кыяметдин лапаска өч кенә сикерде — балта яралы кулны яртылаш чабып керде. Авылда: «Кыяметдиннең сугыш хәсрәтеннән ярасы ачылган икән»,— дип сөйләделәр, әле беркөнне генә кулын бәйләп киткән врач та гаҗәпләнеп башын селкеде, алай бетеренмәскә кушты. Ләкин шикләнеп гөнаһысына кермәделәр — ярасы сугыш башланганчы ук бар иде. Шулай итеп, Кыяметдин кулсыз да калды, сугышка да бармыйча калды. Хатынын Кыяметдин бераз тилемсәрәк дип исәпли иде, шуңа күрә аны кызганмыйча кыйнады. Тегесе эндәшмәде, гел аркасын куярга, эч-башын сакларга тырышты. Хатыны рәттән берничә үле бала салды. Сугыш ахырында зәгыйфь кенә бер кыз бала табып, үзе дөньядан китеп тә барды. Үлгәндә генә йөзенә елмаю билгеләре чыкты. Аның нинди тормышта яшәвен белүчеләр: «Котылды, бичара»,— диделәр.

Кыяметдингә хатын-кыз бетмәде. Ул чагында авылда хатын-кыз чутсыз иде. Айсылу төрмәдән кайтып күзенә күренгәнче, шулай азып-тузып, өй борынча кунып йөрде. Айсылу кайтып күзгә күренгәч, авыл аның өчен яктырып та, караңгыланып та китте. Үзенең хайванга әйләнеп баруын да, дөньяда бернинди изге нәрсә, сөенече калмаганын да аңлый башлады. Уйлый китсәң, үзе дә кадер күрмәгән, кешегә дә кадер күрсәтмәгән икән. Һәм Айсылуга ул теше-тырнагы белән ябышты, төрмәдән кайтса да, кипсә дә, чәчләре агарып бетсә дә — ул аның өчен барыбер элекке Айсылу, чулпы таккан укытучы кыз иде. Һәм ул аны кая барса да эзли, эзәрлекли башлады...

Кыяметдин карт исән кулы белән тәсбихенә үрелде. Калтырана-калтырана, кипкән хөрмә төшләрен тарта башлады, авыз эченнән туктаусыз догасын укыды. Җирдәге гөнаһларын җирдә калдырып китәсе килә иде аның. Сөйләп булса да калдырасы, кеше җанына күчерәсе, арынасы килә иде...

Төннең беренче яртысы үтте. Авылда соңгы утлар да сүнде. Дөньяны караңгылык каплады. Хәтердәге гомернең дә яртысы үтте. Утларын сүндереп, Себер урманнарына килеп җиткәндә, алар гомерләренең кыл урталарында иделәр. Кемгә — 33, кемгә — 37, бик сирәкләренә 40 яшь. Иң пешкән, өлгергән, тормышның тәмен, кадерен белгән чорларында җыйдылар аларны. Җыймадылар, тамырларыннан каерып, йолкып алып, барысына берьюлы балта чаптылар. Иң үзәкне өзгәне — балалар. Ир дә түгел, мәхәббәт тә түгел, эш, карьера да түгел — балалар! Кайсыныкы — яңа туган, кайсыныкы — буй җиткән. Кышларын да ягылмый торган салкын баракларның һәр почмагыннан, бәс сарган бүрәнәләрнең һәр җегеннән балаларының күзләре карап тора иде! Айсылу да күпме саташты улының зур кара күзләре белән! Әле алар яшь белән тулган була, әле кызганып карый, әле чакыра, ялвара. Колагында һаман соңгы сүзләре: «Мин озак тормам, әни!» Күз алдында яшь, арык гәүдәсе. Ай, бер генә кагылырга шуның кара чәчләренә, йоклаганда бер генә тапкыр битләреннән үбеп алырга, өстенә юрганын ябарга... Юрган... Тукта, балаларны җыйдылар, диделәр. Димәк, Газизҗан да хәзер детдомда. Җылырак якка гына алып киткән булсалар ярар иде. Өстенә киенергә өлгердеме икән? Ашарга нәзберегрәк иде, мәктәп ризыгыннан да күңеле болгана иде, детдом ашларына ничек ияләнер икән?

Улы турындагы бер дә бетмәс уй-хәсрәте Айсылуны элеп киптерде. Элек тә арык, сылу гәүдәсе бөтенләй кипте, күзләре зураеп, сагаеп калды. Төрмәнең кара халаты йөзенең аклыгын тагын да көчәйтеп күрсәтә, нечкә аякларында зур резин итекләр. Кышын да, җәен да шулар. Ун ел буе. Лыштыр-лыштыр, лыштыр-лыштыр...

Хәзер, картлык көн җиткәч, менә барысы да аяксыз калдылар. Айсылу, әле ярый, тотынып булса да, акрын гына атлый. Зөләйха аяк белән бөтенләй егылды, өйдән чыга да алмый. Мәрьям коляскада утыра. Башлары, хәтерләре — исән. Ә менә аяктан калдылар. Кара язмышлары, сөлек булып, картлыкларына кадалды, елан булып, аякларына сарылды. Атлар чара калмады. Ары таба атларга урын, максат та юк иде...

Бәргәләнде Айсылу төрмәдә, һай, бәргәләнде! Ун ел буе шулай шашынса, алгысынса, ул аннан исән-имин кайта алмаган да булыр иде. Йә акылына зыян килер иде, йә Валентина кебек, асылынып үләр иде. Әле дә ярый, Айсылудан акыллырак, сабыррак хатыннар булды. Исән калуы белән дә Айсылу шуларга бурычлы. Бигрәк тә Кәримә апасына.

Кәримә апалары яшькә алардан өлкәнрәк иде. Аны Казан төрмәсенә Мәскәүдән китерделәр. Ире биредә кулга алынган булган. Аның белән очрашырга чакыралар дип уйлап, ул өстендәге бер кат кием белән Казанга кайтып төшә. Һәм шул ук көнне — камерага. Айсылу аның белән шунда ук танышкан да иде. Баласын уйлап шашар дәрәҗәгә җиткән Айсылуны ул бик гади, сабыр гына юата белде. Юк, башкалар кебек: «Ул белми, ул белсә, безне моннан чыгарачаклар...» — дип корыга хыялланмый иде Кәримә атлы хатын. «Түзәргә кирәк, дөнья бер үз урынына кайтачак», дип юата иде. Ә үзе, эзгә калгач, түзә алмады. Төрмә сроклары тулгач, аларны шартлы рәвештә иреккә чыгардылар. Исеме генә ирек, асылда шул ук барак, шул ук күзәтү. Элек солдат киеме теккән булсалар, хәзер шахтага төшерделәр. Шул вакытта анасы кебек якынаеп өлгергән Кәримә апасын башка урынга — Казахстан тирәсенрәк күчерделәр. Шуннан соң Айсылу аны башка күрмәде. Иреккә чыккач, эзләтеп тә караган иде, тиз генә таба алмады. Соңыннан билгеле булды — Кәримә апаны Казахстан далаларында сарыклар көтәргә куйганнар. Ике югары белемле булган, революциягә хәтле үк медицина өлкәсендә эшләгән, соңыннан юрист булып киткән, төрмәгә дә ЦК аппаратыннан алынган Кәримә апа түзә алмый — утар аратасына асылынып үлә. Киемнәре теткәләнеп беткән арык тәнен шул утар артындагы чокырга күмеп куялар...

Алары — соңыннан... Төрмәдә вакытта Кәримә апалары татар хатыннарының анасы урынына булды. Айсылуны аерата сакларга тырышуы сизелә иде. Көндез сөйләшергә ярамый, көндез беркем беркемгә күтәрелеп карамый. Төннәрен — бер метр урынга өч кеше. Берең борылганда өчеңә дә борылырга кирәк. Айсылуның бер ягында — Кәримә апасы, икенче ягында — Зөләйха. Зөләйха үзе дә елак, төне буе балалары өчен мышкылдап чыга. Аңа ияреп Айсылу да үкси башлый. Ул сулкылдаган саен, Кәримә апасының да аркасы, йөрәге дерелди. Аннан ул түзми, авырлык белән генә Айсылуга таба борыла: «Елама, Айсылу,— ди.— Балаң исән, ирең исән, үзең исән. Гомер анда да үтәр иде, монда да үтә. Көчеңне яшәү өчен калдыр».

Шулай, төрмәдә еладыңмы, артык бәргәләндеңме — беттең. Янасың, бәргәләнәсең — чыгар урын юк. Барыбер чыгар урын юк! Ун ел. Бөтен көчеңне, сабырлыгыңны, сәламәтлегеңне шул елларга тигезләп бүләргә кирәк. Сабырлык, сабырлык, сабырлык. Болай да сабыр, аз сүзле татар хатыннары монда бөтенләй таш сынга әйләнделәр, көлү юк, кызып китү юк, хәтта соңга табарак елаулар да бетте. Бары тик тешләре генә кысылып, уртларына керде, яңак сөякләре калкып чыкты, күзләр каш астына тагын да тирәнрәк батты. Ун ел! Аңа барып җитәргә кирәк иде...

Аларның авыр, соры тормышлары июньнең аяз, җылы көнендә бер чатнап, кайнап алды. Айсылу ул көнне сакчыларның эчке күлмәк-ыштаннарын юа иде. Нигәдер бу эшне гел авырдан башкарды ул. Әллә нинди төер бугазга килеп утыра, укшыта, күз яше ләгән эчендәге керләр өстенә тама. Ул гел башын читкә борып юарга тырыша иде. Берсендә Кәримә апасы читтән күзәтеп торган икән, әкрен генә килеп әйтте: «Бик алай итмә, Айсылу, күрсәләр, яратмаслар»,— диде. Монда кечкенә генә бер тәртипсезлек эшләдеңме — җәза срогың арта, катылык арта. Ун ел! Болай да ун ел бит инде ул...

Шулай азапланып ап-ак пар эчендә кер юып ятканда, төрмә мунчасына Кәримә апасы килеп керде. Чәчләре тузгыган, күзләре ут булып яна. Әллә ходаем?! Айсылу билен турайтты, үзе дә Кәримә апасы каршына атлады. Әллә ходаем...

— Амнистияме? — калтыранган кулларын аңа таба сузды.— Барыбызга дамы?

— Сугыш...

Кәримә апасы бер генә сүз әйтте. Сугыш. Сугыш?! Ә без?! Ә безнең детдомдагы балалар? Ирләр? Кайда сугыш, кем белән? Аларны нишләтәләр?

Ул көнне барак эче гүләп торды. Чаярак лар шунда ук гариза язарга, сугышка китәргә җыена башлады. Барак эче яктырып, биегәеп китте. Илгә килгән кара хәсрәт мондагы хәсрәтне таратып җибәрде. Чөнки нидер үзгәрергә тиеш иде! Илгә чын дошман килде! Алар дошман түгел. Бәлки шуны аңларлар, чыгарырлар, ирекә булмасын — сугышка җибәрсеннәр, тик биредә генә калдырмасыннар! Илләре яна бит, балалары, йортлары яна, шуны тимер чыбык аша ничек карап утырсын алар?!

Баракның руслар, яһүдләр, украиннар яшәгән башы аеруча кайнап тора. Рус хатыны Валентина бер төркемнән икенчесенә күчә, битләре алсуланып чыккан, сары чәчләре таралган, зәңгәр күзләрендә әллә нинди кыргыйлык, ярсу. Ул Ленинградта бик зур кешенең хатыны булган, диләр. Ирен Кировны үтерүдә гаепләп кулга алганнар. Ләкин Кировны «үтерүчеләр» дә соңыннан дистәгә якын җыелган. Һәрберсенең хатынын, балаларын алганнар. Валя да шуның өчен утыра. Ленинградта ялгыз карт анасы калган.

Валя сугышка китәргә җыена. Аның дәрте башкаларга да күчкән. Ләкин башкалар сабыррак, шикләнебрәк карыйлар, артык сүз ычкындырырга куркалар. Ышанмыйлар. Монда кергәннән бирле, артыгын ычкындырмыйк дип, телләре аңкауларына ябышты, түзәргә өйрәнделәр, бернәрсәгә дә ышанмаска өйрәнделәр.

Валя комендант янында кара коелып, башын иеп кайтып керде. Шул көнне үк барактагы күзәтүче хатын белән телгә килде. Күзәтүче хатын: «Сез дошманнарны анда җибәрсәң, бөтен илне сатачаксың бит!»— дигән. Валя, кайда икәнен дә онытып, күзәтүче хатынга ташланган. Тешләрен, тырнакларын аның тәненә батырган. Хатыннар, йөгереп килеп, Валяның кулларына асылына, читкә алып китәргә тырышалар, ләкин Валяның таш бастырып куйган җаны бәйдән ычкынган иде. Нинди сүзләр генә кычкырмады Валя! Сталинга да, аның ялчы-ялагайларына да, төрмә сакчыларына да ләгънәтләр яудырды ул. Айсылу коты чыгып аны тыңлады. Ул гомердә дә алай әйтә алмас иде. Алай уйлый да алмас иде. Монда да, язмышымдыр, дип, көнде, тынды, башкалар да шулай яшиләрдер дип уйлаган иде. Ә башкаларның эчендә әнә нинди уй икән...

Коралды сакчылар килеп, Валяны ялгыз камерага алып киттеләр. Ә икенче көнгә Валя асылынып үлгән иде. Ленинградтагы ялгыз анасын, кайсыдыр детдомдагы нәни кызларын язмыш иркенә калдырып, Валя асылынып үлгән иде.

Шушы хәлдән соң сугышка китәргә җыенучы булмады. Ләкин каядыр сугыш барганын беләләр, һәркем үз шәһәре, үз баласы турында уйлый, ил белән утларда яна-яна, бу мәхшәрнең азагын көтә иде.

Соңыннан, бик күп еллар үткәч белде Айсылу карчык: сугыш башланган көнне төрмәдә асылынып үлгән рус хатыны беренче комсомоллардан булган икән. Авылларына аклар кергәч, аны җәзалап, мәсхәрәләп, каенга асып китәләр. Аклар артыннан ук авылга уктай атылып кызыллар керә. Әле тәне дә суынып өлгермәгән комсомолка кызны элмәктән алалар. Валя могҗиза белән исән кала. Ләкин кара язмышы аны төрмә камерасында куып җитә — элмәк булып муенына урала, барыбер алып китә... Бу корбан ни өчен? Монысын да әлегә хәтле беркемнең әйткәне, аңлатканы юк. Яшьләр белми, белгәннәр берәм-берәм китә бара. Аңа да китәр вакыт җитеп килә. Ул да шулай белмичә китәрме икәнни? Улының кайда икәнен белми, ни өчен утырганын белми. Тоталар да, ялгыш диләр. Шул хәтле корбаннар ясарлык итеп ялгышып буламы икәнни?! Алар ничә мең, миллион бит — билгесез корбаннар. Бик сирәкләрнең исемнәрен китапларга кертә башладылар, көрәшчеләр сафына яңадан кайтардылар. Ә менә аның кебек билгесезләр? Алар турында кем белер, кем әйтер? Язмышлары ботарланып, кара каннарга батып бетте бит. Ни өчен?! Ни өчен?!!

Айсылу карчык моны үзе дә белми. Ничә тапкыр ант итте, уйламыйм, уйламыйм, җанымны борчымыйм, диде. Барыбер җавап юк, шул килеш үлим, диде. Юк бит! Әнә шул бер кыңгырауны күрде — Галимҗаны да искә төште, Газизҗаны да, төрмә дә... Кара кан булып укмашкан төерләр... Йотып та җибәреп булмый, таралмый да...

Бала сагышы белән төрмәдә ул иреннән шактый ерагайган иде. Җаны белән бергә тәне дә катты, Галимҗанның карашы, назлары да онытылды. Үзенең хатын-кыз икәнен дә онытты. Ничек тә бу тәмугтан исән-сау котылырга, илгә кайтырга, баласын, анасын күрергә... Ә Галимҗан... Галимҗан егерме елга алынды, Айсылу кайткач та әле ул ун ел утырачак. Алып киткәндә кырык яшьлек, ут чәчеп торган ир иде, алтмыш яшендә кайтачак. Исән булса. Айсылу аны көтәр. Төрмәдә көтәргә өйрәнгән кебек, сабыр гына көтәр. Айлы төннәрне, чулпы тавышларын гомернең теге ягында, якты ягында мәңгегә калдырып, сабыр гына азагын көтәр...

Ләкин кара язмышы аның җилкәсенә төшмәскә дип менеп утырган булган икән. Бу оялчан, йомшак татар хатынының иреннән, баласыннан аерылуы, бер сәбәпсезгә ун ел төрмәдә газап чигүе аның өчен аз булган — ул аңа хәсрәтнең яңаларын әзерләп куйган.

Акылы, хисабы белән улының сугышка алынырлык яшькә җиткәнен белә иде Айсылу. Унөч яшьлек бала, исән булса, инде җиткән егет булырга

тиеш. Сугышка да алганнардыр. Дөнья белән элемтә юк. Сугышның кай тирәдә, ничегрәк барганын алар белми. Барысы да чама белән яшиләр. Барысы да якыннары исәндер дип өмет итә. Алар арасында хәрбиләрнең хатыннары күп. Алар дөньяда ни барганын Айсылуларга, Зөләйхаларга караганда яхшырак беләләр, төннәрен пышылдашкан, үһылдашкан тавышлар ул тирәдән ешрак ишетелә. Айсылулар башы авыр, хәсрәтле йокыда. Айсылулар башы сабыр гына бу мәхшәрнең азагын көтә.

Аның срогы тулганда сугыш беткән иде инде. Соңгы елларда Айсылу шахтада эшләде, саргайган йөзенә күмер тузаны кунды, зур күзләрен җыерчыклар сарды, куллары, тәне сөяк һәм сеңердән генә тора иде. Ирек кәгазен кулга алгач, ул бер тын ак кар өстендә чайкалып торды. Кар өстенә ятып үкерәсе, тәгәрисе, урмандагы һәр агачка, һәр җанварга үз хәлен сөйлисе килде. Дәшмәде. Сөенмәде дә, кайгырмады да. Нигәдер үкерәсе килде. Читлектән чыгарылган ана җәнлек кебек, күккә карап, җиргә тезләнеп үкерәсе килде.

Беренче товар поезды белән үк Казан ягына кузгалды. Төрмәдә үк әйттеләр — аны Казанга кертмәячәкләр. Киткән җирдән алтмыш чакрым ераклыкта торырга, ди. Айсылу Өтернәскә кайтыр. Әнисе исән булырга тиеш. Бәлки, Газизҗан да шунда кайткандыр. Әлбәттә, шунда кайткан! Алар Айсылуның срогын беләләр, кайтасын да беләләрдер, көтәләрдер. Поезд акрын кайта. Шуышып кайта. «Йә, хода! Әни! Газизҗан! Сезне күрер көннәрем дә бар икән! Исән-сау күрешергә насыйп булса, аяк астындагы җирләрне ятып үбәр идем. Беркемгә үпкә, рәнҗеш сакламас идем. Җиргә баскан саен куанып, рәхмәт әйтер идем. Йә, хода! Йә, тәнрем! Акылларымны гына алма бу мизгелләрдә. Түзә алмас, йөрәкләрем ярылыр... Ун ел бит! Ун ел!!!»

Поезд һаман Казанга таба шуыша. Тамбурда торучы хәрби егет әйтте, поезд алар станциясендә туктамый икән. Ничек туктамый?! Ул Өтернәс турыннан үтеп китеп, Казаннан әйләнеп кайтсынмы?! Аны бит өйдә көтәләр, сәгатен, минутын санап көтәләр...

Төенчеген хәрби егеткә тоттырды. Поезд әкрен генә үр менгән вакытта, томырылып ак кар өстенә сикерде. Артыннан төенчеге очты. Төшкән уңайга, капланып, ак кар өстендә шактый ятты. Поезд үтеп киткәч, башын күтәрде. Бөтен дөнья зәп-зәңгәр. Кичке зәңгәрлек. Әнә тегендә, тау астында — Өтернәс. Ул менә шушыннан туп-туры төшәр. Юл юк, сукмак юк, зәңгәр карда, зәңгәр кичтә аның кара гәүдәсе генә селкенә. Аягында — һаман шул резин итекләр. Кайта, барыбер кайта, кара булса да кайта, җаны исән ич, өмете исән, ризыгы бетмәгән. Менә кайта. Зәңгәр карга кайнар яшьләре тама. Ташкүмер тузаны сеңгән битләрендә тирән эз калдырып, зәңгәр карга кайнар яшьләре тама. Соңгы яшьләре. Калган гомерендә башка елый алмаячак ул. Елап калсын, шатлыктан булса да елап калсын...

...Айсылу карчык, төн карасы аша әрнеп, шул хатынга карап тора. Ул аны туктата алмый. Ул хатынны туктатырлык көч хәзер дөньяда юк. Шушы мизгелне ун ел көтте бит ул! Августның җылы бер көнендә улын җитәкләп чыгып киткән иде авылдан. Көнбагышлар үрелеп-үрелеп карап калганнар иде. Менә кышын кайтып килә. Ак кар диңгезеннән йөзеп кайта. Кайта-а-а...

Менә ул яртылаш кар баскан тәрәзәгә килеп каплана. Өйдә лампа яна. Әнисе почмак белән ике арада йөри. Адымнары бигрәк әкрен. Газизҗан күренми! Бәлки, ул аны каршы алырга киткәндер? Айсылу бит бөтенләй башка яктан кайтты. Турыга кайтты. «Әни, мин кайттым бит! Кайтты-ы-ым...»

Карчык, сынын тота алмыйча, кызы кочагына ава. Йә, хода! Аның кызымы соң бу?! Күзләрендә адәм күтәрә алмаслык кара моң, хәвеф, өмет. Яңаклары эчкә баткан. Тәне — коры сөяк. Кипшергән иреннәре... улын сорый! Газизҗанны сорый...

— Әни! Газизҗан кайда?

Хәле бетеп, карчык мичкә сөялә. Аннан капшана-капшана почмак якка үтә. Нинди тынлык бу? Нинди шомлы тынлык бу?!

— Әни! Газизҗан кайда?!

Өстен дә салмаган килеш, Айсылу идән уртасында басып тора. Төрмәнең соры җаймәсе аяк астына шуып төшкән. Резин итекләргә ияреп кергән кар, эреп, түргә таба агып ята. Ябык хатын берни күрми. Могҗиза көткәндәй, мич арасыннан әнисенең чыкканын көтә. Тик яман хәбәр генә булмасын, тик яман хәбәр генә булмасын...

Карчыкның кулында саргаеп беткән кәгазь. Үлгән? Юк? Яраланган? Юк... Нәрсә булган соң алайса?! Кайда аның Газизҗаны? Бердәнбере, улы, багалмасы?! Тагын ун ел утырырга риза, егерме ел, улы гына исән булсын, аңа гына тимәсеннәр. Нәрсә дигән? Хәбәрсез югалды? Ничек кеше хәбәрсез югалсын ди? Сугышта хәбәрсез югалалармыни? Аның улы — Мостафин Газизҗан Галимҗан улы — ничек инде югалсын? Сугыш беткәнгә кайчан? Ике ел? Ул кайчан югалган? Кырык икенең кышында. Биш ел? Ул биш ел дөньяда юкмыни инде?! Кайда югалган?! Кайда?!!

...Айсылу карчык, коты чыгып, идәндә бәргәләнгән ул хатынга карап тора. Аның үзәк өзеп кычкыруын, юеш идәндә бәргәләнүен ул кырык елдан соң да ишетә. Әнә ул үрмәләп караватт янына килеп җитте, аягына баса алмый, күзләре тонган, инде кычкырмый — үкерә, сугымга салган җанвар кебек, шомлы тавыш белән үкерә. Күзендә бер бөртек яшь юк, йөзендә тормыш әсәре юк, тезләнгән килеш, алга-артка чайкалып, бер көйгә үкерә дә үкерә. Аңа кушылып, тышта кышкы җил улый, авыл өстенә кара төн булып җаелгән караңгылык үкерә, тормыш үкерә. 1947 ел. Кыш. Өтернәс авылы.

Газизҗанны соңыннан военкоматлар аша эзләтеп-эзләтеп тә карады ул. Хәбәрсез югалган, диделәр. Пленга эләккәнме, үлеп, җир асларында күмелеп калганмы — беркем белми. Кабере кайда — анысын да белүче юк. Детдомнан авылга берничә хаты, сурәте килгән, фронттан бер фотосын җибәргән. Ул да кебек, түгел дә кебек. Күзләрендә әллә нинди үҗәтлек, катылык. Маңгай астыннан сөзеп карый. Сугышка да үзе теләп, язылып киткән. Гаризасына: «Әти-әни китергән оятны каным белән юарга телим»,— дип язган. Нинди оят?.. Әй, бала, бала... Бәгырь кисәге... Соңгы сүзең, соңгы уең ни булды икән? Анаң — төрмәдә, атаң — төрмәдә, ә син билгесез җирләрдә үлеп ятасың. Йә, тәңрем! Нинди үчең булды синең аларда?! Бер нәселгә, бер гаиләгә нигә бу кадәр җәбер-җәза? Нигә?

Улының югалганын белгәч, яшәүнең мәгънәсе калмады. Берьюлы сынып, картаеп китте. Авылдан чыгарга ярамый — һаман күзәтү астында. Сөйләшергә, аралашырга кеше юк, барысы да читсенеп, шикләнеп карыйлар кебек. Галимҗаннан хәбәр юк, ул кайдадыр Магадан якларында ук. Кайчакларда төннәрен әллә нинди шашкын уй-теләкләр дә килеп китә — бәлки, тәвәккәлләп, Галимҗан янына чыгып китәргәдер? Аның да кара чәчләре инде агаргандыр, горур башы иелгәндер, гәүдәсе сынгандыр. Ул хәзер шартлы рәвештә иреккә чыгарылган булырга тиеш, ләкин бу якларга кайтырга барыбер ярамый. Барыбер күзәтү астында. Шул тирәгә барып, бәлки, шахтага эшкә урнашыргадыр? Тагын ун ел бик күп гомер бит әле ул. Галимҗанның көче, түземе җитәрме? Бик горур, кызу җан иде бит.

Һәм Айсылу үзен ире янәшәсендә күз алдына китерә. Йә, хода, Галимҗан белгән Айсылумы соң бу? Чәчләр агарган, тешләр коелган, бил сынган. Җаны тулы хәсрәт, кара сөрем. Шулар белән барырмы ул аның янына? Беткән, беткән, барысы да беткән. Тән дә калмаган, җан да. Ә ничек яшәргә?

Әнисе карчык аягында чак селкенеп йөри. Өйдә хәзер кайгы, өметсезлек баскан ике карчык. Ә яшәргә кирәк. Өмет булмаса да, бирелгән

көннәрне яшәп бетерергә кирәк. Мәктәп турында уйларга да ярамый, кешеләр өчен ул — халык дошманы, төрмәдән кайткан кеше. Димәк, кайда кушсалар, шунда эшләргә. Башны иеп, үлгәнче эшләргә дә эшләргә. Ташка, агачка, тимергә әйләнгәнче эшләргә. Эшләргә...

Чокырын да казыды, абзарын да салды, урманын да кисте. Бүген сүтеләсе мәктәпнең агачларын да шул елларны кисте ул. Кайгысыннан карурманнарны кисеп аударырлык кара еллары иде шул... Бүген, мәктәп сүтеләсе көнне, тагын шул бәндә белән очрашты. Теге елны, урман кискәндә дә, каршына килеп чыккан иде ул Айсылуның. Һаман да шул авыр караш, авыр сулыш. Әйтерсең, яраланган җәнлек артыннан erтkычы куа килә. Егылыр, тез чүгәр, башын аның тырнагы астына салыр дип, еллар буе эзәрлекләп килә.

Айсылу төрмәдән кайтканда Кыяметдин авыл советында эшли иде. Документларын тапшырганда Айсылу аның каршына бер барды, ләкин күтәрелеп карамады. «Кайттыңмы?»— дип сорады, ахры. «Кайттым»,— диде, «Бетерепме?»— диде, «Бетереп»,— диде. Башка сүз ялганмады. Айсылуның аңа карата күңелендә ачуы, үче юк иде. Утырды. Монда кемне гаеплисең. Кыяметдин үзе дә мескен бер бәндә генә. Куйганнар — утыра, төшерәләр — китә. Теге вакытта, алып киткәндә, Кыяметдин хәбәр иткәндер, дип уйласа да, соңыннан ул уеннан кире кайтты. Ә бүтәннәрне кем чаккан, кем хәбәр иткән. Ата — улыннан, ир хатыныннан шикләнгән кара, ышанычсыз заман иде бит. Кешеләр курку белән агуланганнар иде. Шулай тиеш, дип белделәр, күбесе кулга алуны көтеп яшәде. Һәм йөзләп, меңләп, дәшми генә, Себер төрмәләрендә чиределәр, дәшми генә илгә кайттылар, дәшми генә яшәп яталар. Ә Кыяметдин? Ә Кыяметдин — хода бәндәсе. Айсылуның аңа бер ачуы да юк.

Урманда булган очрашуга хәтле ул Кыяметдингә шулай тыныч карый иде. Әллә бар ул бәндә авылда, әллә юк. Ә ул аны, әнә, канлы фаҗигале эзеннән эзәрлекли килгән икән, куа килгән...

Гаять авыр, ачлы-туклы еллар иде. Ул елның җәендә корылык булды, болай да хәерче, караңгы авылларга өметсезлек, ачлык килде. Крестьян кубарылып шәһәр ягына, шахта, Себер якларына китә башлады. Җанны, гаиләне, нәселне сакларга кирәк иде. Китә алган китте. Айсылу авыру анасы белән урыныннан кузгала алмады. Төрмәдән кайткан кеше буларак, аңа авылдан китәргә дә ярамый иде. Айсылу үзе төрмәнең кырыс тормышына, аз ашап та җан сакларга өйрәнгән. Ә әнисе карчыкка җылы ризыксыз бик авыр. Бөтен карап торганы — Айсылу; ул юнәтергә, тормышны инде ул алып барырга тиеш. Урман кисүчеләргә бераз икмәк, он бирәләр икән дигәч, Айсылу да урман кисүчеләргә иярде.

Тормыш авыр булса да, төптән юан чыккан, нык гәүдәле авыл хатыннары... Тәрбия, наз күрмәгән йөзләре корыч төсенә кергән, аларда эреле-ваклы тәртипсез, тирән җыерчыклар. Телләр тупас, куллар кытыршы, күңел дә туктаусыз кара эштән каралып килә. Айсылуны чит итәләр. Илгә килгән бу авырлык, хәсрәт, сугышларда аларны гаеплиләр. Утырган — димәк, гаебе булган. Укыган кеше — чукынган кеше. Аларның берсенә дә ышанырга ярамый. Майларына чыдаша алмыйлар.

Айсылуны урманда да чит итәләр. Кырык биш яшьлек, кипкән-корган, чәче-башы ап-ак бу хатын үзе дә кешеләрдән читләшә, дәшми, көлми, эчендәген сөйләми. Башын аска иеп, иренен кысып, пычкысын тартуын белә. Карашы авыр, кырыс, салкын. Үсеп утырган агачны түгел, үзенең уй-хыялларын, калган гомерен тамырыннан кисәмени?! Башын күтәрми ышкый да ышкый, ышкый да ышкый.

Хатыннар ялга туктаган арада Айсылу урман эченәрәк кереп китте. Тегеннән кайткан гадәт — Себер гадәте — аяк астында ашардай ни бар, барын да җыя. Гөмбә очрыймы, сабагында килеш кипкән җиләкме, чикләвекме, баланмы — барысын да җыя. Озын ач кыш якынлаша. Запас юк. Икмәк юк. Акча юк. Мал-туар юк. Бөтен карап торганнары шул бәрәңге. Һәм менә шушы юк-бар.

Урман тын гына, моңсу гына шаулый. Урманнан баш әйләндергеч күзгә ис килә. Әллә нинди яктылык, сагыш, бушлык. Агач араларыннан менә шушылай атларга да атларга иде. Качарга иде узган гомердән, киләчәгеннән, шикләрдән, кара хәсрәтләрдән... барысыннан да качарга иде. Күпме күтәреп барырга була?! Башы һаман аска иелә, аска тарта бит. Туйды, арыды. Нинди өмет, нәрсә көтә аны алда?! Ире — төрмәдә; үзе — күзәтү астында. Тирә-ягында чит-ят кешеләр. Кемгә сыенырга, кемнең иңнәренә шушы агарган башны салып, үксеп-үксеп еларга? Кая барырга?..

Ялгыз ак каен төбенә тезләнгәнен хәтерли. Себер урманнарында сынмаганны, улының югалган хәбәрен ишетеп тә исән калганны, бүген әнә сынды, язмышы каршында тезләнде. Болытлы авыр күккә карап, нәрсә ялвара ул? Ак чәчле башын бер кара җиргә бәреп, бер күкләргә төбәп нинди дога укый ул? Җил карурман эченнән дөньяга нинди куркыныч сүзләр тарата? Аның яшисе килми! Нинди авыр елларда да түзде, исән калгач, аның яшисе килми? Җил, карурман, төпсез күк! Туктатыгыз сез ул хатынның илереп ялваруын, туктатыгыз, югыйсә, быел төшкән орлыклар киләсе елга тамыр җибәрмәс; югыйсә, иртәгә кояш чыкмас, дөнья бетәр. Хатын-кыз яшәүдән туйган бит, ишетәсеңме, табигать, яшәүдән туйган...

Урман өстендә җил бөтерелә. Күкләр ерак, ерак... Догалар барып җитми. Еррактан, биектән исә тезләнеп ялваручы ул хатын да кырмыска, бөҗәк булып кына күренәдер. Урман гына шаулый. Әллә кызганып шаулый, әллә ризасызлыктан...

Әйе, Кыяметдин карт та хәтерли ул көзге көнне. Берничә көн элек, районга чакыртып, Айсылу кебекләр турында сөйләшкәннәр иде. Аларны яңадан ала башлаганнар икән. Илдә тагын корткычлык, астыртын эш йөртү башланган, ди. Шуңа күрә аннан кайтканнарның һәрберсен аерым сак, күзәтү астына алырга, ди. Ирләреннән ваз кичеп, гариза язмасалар, яңадан алып китүләре дә мөмкин. Кыяметдин, авыл советы рәисе буларак, бер тәүлек эчендә менә шушыларны хәл итәргә тиеш. Айсылуны авылга алып кайтып, менә шуларны хәл итәргә.

Атын кара күбеккә батырып урманга куганда, ул эшнең бары тик шул рәсми ягы турында гына уйлады. Айсылуга якынаерга, теге еллардагы кебек, кулына асылынып, «кал!» дип ялварырга уйламый иде инде Кыяметдин. Нидер булды, нидер үзгәрде. Айсылуга ул малайлык, егетлек тартылуы белән тартылган. Башка хатын-кызны белмәгән, күрмәгән. Күз алдында аның гәүдәсе, аның толымнары гына булган. Теләге тормышка ашмады, кочагында сындыра алмады, Кыяметдин үзе сынды. Дөресрәге, теләге үлү белән, җанында ниндидер яктылык та сүнде. Айсылудан соң күп күрде ул хатын-кызны. Унҗиде яшьлеген дә, илле яшьлеген дә. Күрде, туйды, күңеле кайтты. Бөтенесе бер иш! Бөтенесе сынды, Кыяметдиннең маңгаеннан тамган тирен сөртте, ташлама, дип елады. Кыяметдин икенче төнне инде аның янына бармады. Кызык түгел иде, йөрәге урынында һәммәсе өчен дә таш иде.

Менә Айсылу кайтты. Авылга мәет кыяфәтле ак чәчле карчык кайтты. Кая чәч толымнарында чулпыларын чыңгылдатып йөргән Айсылу? Кая билләре өзелергә торган, кара кашлы, оялчан карашлы Айсылу? Авыл буйлап тере мәет йөри, шәүлә йөри, тик Айсылу түгел, хатын-кыз түгел...

Кыяметдин атын урман эче буйлап куды. Ат кинәт йөрешен әкренәйтте, башын чайкап, пошкырып куйды. Кыяметдин, бүре-мазармы әллә дип, үрелеп, алга карады. Агач төбенә иелеп утырган карачкыны күргәч, үзе дә шикләнә калды. Атын туктатты. Тыңланып тора башлады.

Карачкы нидер сөйли иде, ахрысы, җил белән бу якка тавышы ишетелә. Хатын-кыз тавышы. Әллә нинди шомлы, тилергән сүзләр... «Ник җаннарымны алмыйсын?!»— диме? «Арыдым, өметем юк, ал җанымны!»

Тукта, таныш тавыш бит бу?! Бу бит Айсылу тавышы!

Кыяметдин, атыннан төшеп, Айсылу ягына йөгерде. Агач төпләренә төртенә-сөртенә, әллә нинди кыргыйлык, ашкыну белән йөгерде. Сынган бит! Тезләнгән. Агач төбенә тезләнгән — барыбер тезләнгән. Кыяметдин ничә ел көтте аның бу халәтен. Йомшаруын. Сыгылып төшүен. Беләкләренә сыгылып төшеп, «Кыяметдин...»— диюен.

Килеп житкән уңайга, ул Айсылу өстенә иелде. Айсылу аны күрми. Карашы аның әллә кая киткән. Үзе әллә җил уңаеннан, әллә туктый алмый — һаман чайкала. Кыяметдин каен төбенә тез чүкте, Айсылуны җилкәләреннән алды. Айсылу аны күрми! Кыяметдин авыр гәүдәсе белән аның каршына тезләнде, башын ак каен кәүсәсенә төртте.

— Сине алырга килдем,— диде ул карлыккан тавыш белән.— Районнан сине эзлиләр.

Сүзләре бугазын яндырып, кысылып чыкты. Тәне дә яна, кайнарлана башлады. Ут булып янган башын күтәреп, күз аллары томаланып, Айсылуга карады ул. Аласы иде үзен хәзер кочакка, сары яфраклар өстендә аунатып яратасы, үзенеке итәсе иде. Менә генә бит, маңгае маңгайга тиеп тора, тын алганы ишетелә, башка хатыннар булса, күз йомарга да өлгермәсләр иде, аныкы булырлар иде. Нигә Айсылуга орынып булмый?! Нәрсә саклый аны?!

Каш астыннан гына тагын Айсылуга карап ала. Берни дә сакламый! Әнә, гап-гади хатын. Чәчләре агарган, йөзе суырылган. Тегендә, төрмәдә, әллә кемнәр аша узгандыр әле. Кыяметдин генә нигә шулай куркып, җебеп калды соң?!

Бер ыргылуда ул каенның теге ягына чыга. Тезләнеп утырган Айсылуны бөтереп үз куенына ала, беренче тапкыр куенына ала. Хатынның коры сөяккә калган гәүдәсе шыгырдап куя, сөякләре, боз булып, Кыяметдиннең тәненә кадала. Кыяметдин Айсылуның йөзенә карамаска тырыша, ул аның күзләренә дә карамас, ул аны гомер буе яратуын гына әйтер, ул аны барыбер үзенеке итәр, барыбер сындырыр.

— Мәетне мәҗбүрлисең бит... Кабердәге мәетне газаплыйсың...

Күзләре буш. Йөзе үлекнеке кебек. Ябык тәне күгәреп, зәңгәрләнеп чыккан. Йә хода, ул бит каршылык та күрсәтми! Ул бит үлгән кебек ята, үлгән кебек! Тәнендә, йөзендә ник бер җылылык әсәре, җан әсәре булсын! Ул бит үлекне яратырга җыена! Үлекне!..

Кыяметдин шашып, сикереп тора. Айсылу күккә карап яткан. Буш күзләреннән авыр, кара болытлар йөзеп уза. Ак чәчләре, сары яфраклар белән буталып, җиргә сибелгән. Изүеннән ябык күкрәге күренеп тора. Бармакларын кара җиргә батырган.

Айсылуның гәүдәсен урап узып, Кыяметдин атына таба йөгерде. Күчәрен агачларга бәрә-бәрә, атын кире борды, җан ачуы белән аңа китереп сукты, ат шашынып, куш аяклап чабып китте. Кыяметдин арбасына йөзтүбән капланды.

Айсылу өенә төнгә генә кайтып җитте. Әнисе Асылбикә карчык аны хәвефле хәбәрләр белән каршы алды. Күрше авыл Зәйнәпне яңадан алып киткәннәр икән. Яңадан җыялар, ди. Ирләреннән ваз кичмәгәннәрне беренче чиратта алалар, ди. Тагын китсәң, икебез ике якта үләчәкбез.

Карчык төне буе хәсрәтләнеп, елап чыкты. Таң атуга, киенеп каядыр чыгып китте. Айсылу авыл советына барырга җыена башлады. Ул барып да әйтер: «Мине яңадан алыгыз!»— дияр. «Менә үзем килдем. Мин халык дошманының хатыны, мине ирем янына җибәрегез»,— дияр. «Бу дөнья минем өчен төрмәдән дә тар, кысан»,— дияр. «Мин бар кешегә чит-ят, мине үз ишләрем янына җибәрегез»,— дияр. Яңадан чыкмаска дип китәр.

Ишектә әнисенең гәүдәсе күренде. Ул да җиргә кадәр иелгән, аягында чак басып тора. Айсылуның эче жу итеп китте. Ә әнисе? Аны кем белән калдырыр? Кемнәр арасында калдырыр?

Әнисе артында бер ир-ат гәүдәсе күренде. Аннан, берәм-берәм, өйгә өч бала кереп тулды. Өй эче тараеп, җылынып китте.

— Менә, кызым, Вәлиулла,— диде әнисе. Вәлиулла ике кулын сузып, Айсылу белән күреште. Куллары кытыршы, кайнар иде, бераз калтырый иде.

— Менә, кызым, Вәлиулла,— диде әнисе тагын бер кат.— Ике ай элек хатыны үлде. Өч бала ятим калды. Ризалаш, ана бул шул өч ятимгә.

Айсылу, борчылып, як-ягына каранды. Биш яшьләрдәге кыз бала атасының чабуынаябышкан, үзе Айсылудан күзен алмый. Уртанчы малай мич арасына поскан. Иң олысыдыр инде — ишек төбендә үк калган. Анысы нигәдер уңайсызлана, бер кулы ишек тоткасында, менә-менә йөгереп чыгып китәр кебек.

Айсылуның шул чак башы әйләнеп киткән кебек булды. Малай Газизҗанга охшаган иде. Шундый ук караш, шундый ук чәчләр, шундый ук язмыш... Анасыз... Ятим...

Айсылуның дәшми торуын күреп, Вәлиулла телгә килде.

— Рәнҗетмәм,— диде ул, ишетелер-ишетелмәс кенә.— Көтүче хатыны булырга хурланмасаң, өч баламны авырыксынмасаң, чык үземә.

— Без бит Вәлиуллалар белән чыбык очы туган да,— дип, әнисе дә сүзгә катышты.— Ике йортны бер итик, кызым. Минем дә үләр вакытым җитте. Син дә бик бетеренгәнсең. Ир-атсыз булмый. Галимҗан кияүнең кайчан кайтасы билгесез. Кайтамы-юкмы — анысы да билгесез. Үзеңне дә яңадан алып китәргә мөмкиннәр. Без генә күрергә димәгәндер бит?!

Карчык мышкылдап елап җибәрде. Аңа ияреп кечкенә кызчык елый башлады. Вәлиулла авыр башын аска иде. Ишек төбендәге малай бусагага таба тагын бер адым атлады. Ишекне ача да хәзер чыгып китә. Газизҗан кебек, ул да югала. Барысы да югала.

— Ярар,— диде Айсылу чит тавыш белән.— Галимҗанны хурлап искә төшермәс булсаң, үткәннәрем белән битәрләмәсең, мин сиңа чыгарга риза. Балалар хакына.

Соңгы сүз әйтелде. Үткәннәр белән ялгап торган соңгы җеп өзелде. Халык дошманы хатынынннан ул көтүче хатынына әйләнде. Соңгы тапкыр, ярсып, кыңгырау шалтырады, чулпылар чыңлап алды, аннан Галимҗан ерагайды, ерагайды. Томан аша күренмәс хәлгә килде, рәнҗеп күздән югалды.

Авыл советына ул гаризасын язып барды. Иреннән ваз кичүе турында язган иде ул анда. Үзенең көтүче Вәлиулла Вафинга тормышка чыгуы турында язган иде. Үткәннәрне кабатламыйча, намус белән көн итәргә ант иткән иде.

Аңа кагылмадылар. Көтүче хатыны булып, Айсылу авылда яшәп калды. Дөньялар бераз тынычлангач, үз урынына кайткач, аңа мәктәптә эш тә бирделәр. Авыл халкы да сүзсез, кырыс бу хатынга ияләште, читят итми башладылар. Әнисе Айсылуның үз кулында тынычлап җан бирде. Тормыш салмак кына дәвам итте.

Юк, булган икән, тынычлыгы бозылып, тагын бер дулкынланып алган икән. Галимҗан — беренче ире исән иде бит әле. Үлгәнче аны бер очратасын, аның каршында җавап тотасын Айсылу күңеле белән сизенеп яшәде. Баштарак, бәлки шунда, Магадан якларында, бөтенләйгә торып калыр, дигән өмет тә бар иде. Нигәдер курка иде ул Галимҗан белән очрашудан. Аның каршында гаебе бар кебек иде. Барын да бар инде. Көтмәде. Унөч елын түзде, ундүртенчесендә тормышка чыкты. Егерме ел көтә алмады. Газизҗаны исән булса да, әле көтәр иде ул ирен. Улын да югалткач, нәрсәдер өзелде, бетте. Юк, ирен гаепләмәде ул, аның өчен утырдым, дигән уй башына килмәде. Галимҗан үзе дә корбан иде ич. Билгесез корбан. Төште дә батты, әйтерсең, кеше дә түгел. Бар иде — юк. Юк. Әйтерсең лә яшәлмәгән дә. Карангы, куркыныч бер төш кенә...

Узган гомернең төш кенә түгел икәнлеген Галимҗан үзе искә тө-

шерде. Айсылу Казанга, Зөләйханың хәлен белергә барган иде. Бу юлы нигәдер аяклары әлек яшәгән җиренә — Театр мәйданына тартты. Алар яшәгән ике катлы йорт исән. Айсылу башын күтәреп өскә, үзләренең тәрәзәсенә карады. Тәрәзәләргә көрән төстәге атлас пәрдәләр эленгән. Айсылуныкы алсу иде. Гади иде, җиңел иде. Төннәрен ай нурлары да алар аша үтеп керә ала иде. Ай нуры да алсу, Галимҗанның аңа иелгән йөзе дә алсу булып күренә иде.

Аның ул бүлмәгә яңадан кергәне булмады. Ничек яшәгән — шулай калды. Күңелдә дә шулай саклана. Шулай калсын да...

Бу йорт янына ул башка килеп йөрмәс. Аяклары да авырлык белән атлый, авылдан да һаман-һаман чыгып китә алмас. Ишек төбендә бераз хәл җыйсын да кузгалыр...

Аларны ул тыкрыктан борылуга күрде. Зур гәүдәле, киң җилкәле картны бер хатын җитәкләгән. Хатын әллә казах, әллә башкорт — киң битендә кысынкырак күзләре ялтырый, буе ирдән шактый тәбәнәк, юантык. Картның күзендә кара күзлек, бер кулында нечкә таяк — күрми, ахры. Менә алар Айсылу утырган эскәмия янына килеп туктадылар. Утырдылар. Хатын юантык аякларын сузып җибәрде.

— Җеп өзәрлек хәлем калмады,— диде ул калын күкрәк тавышы белән.— Тотасың да шушында алып киләсең, тотасың да шушында алып киләсең. Диванага әйләндерәсең инде.

Ир дәшми. Зур гәүдәсе иелеп килгән, таяк тоткан кулы бераз дерелди. Айсылуга чит кешеләр сүзен тыңлап утыру уңайсыз кебек тоелды, ул кузгалырга уйлады. Шул чак карт телгә килде:

— Күп йөрисе калмагандыр. Күңелем сизә...

Айсылу өнсез калды. Башы әйләнеп, күзләрен йомды. Йә хода! Галимҗан тавышы бит! Күзләрен ачты. Менә янәшә утыралар. Әйтерсең лә арада утыз ике ел аерым тору юк, төрмә дә юк, кара хәсрәт тә юк. Әйтерсең лә ишек төбенә кичке һава суларга чыкканнар, тыныч кына янәшә утыралар, оныклар турында уйлыйлар.

Оныклар? Нинди оныклар?! Оныклар юк. Нәсел юк, бетте, теге елларда ук тамырына чабылды. Галимҗан... Ай, язмыш... Менә тагын янәшә утыртты. Мөгаен, соңгы тапкырдыр. Соңгы тапкыр.

Ул авыр сулап куйды. Күкрәгеннән ыңгырашу авазы бәреп чыкты. Галимҗан сискәнеп башын күтәрде.

— Монда кемдер бар, ахры? — диде ул шомланып.

— Галимҗан... Бу — мин, Айсылу... Үтеп барышлый туктаган идем...

Карт кискен генә урыныннан кузгалды. Бөтен гәүдәсе белән Айсылу ягына борылды. Нечкә таягы кулыннан төшеп китте, урам ташына бәрелеп зыңгылдады. Карт кулларын Айсылу ягына сузып, аның йөзен, чәчләрен капшады. Бармаклары белән тирән җыерчыкларны аралады, әйтерсең лә алар арасыннан Айсылуның яшьлеген эзли иде, утыз ике ел ансыз газап чигүенә җавап эзли иде.

— Көтмәдең...— Беренче сүзе шул булды.— Баш тартырга ашыктың. Курыктың...

Айсылуның бугазына төер килеп утырды. Сүзен әйтә алмас хәлгә килде. Күкрәгенә бәрә-бәрә үзенең бу елларда ниләр күрүе турында сөйлисе, төрмә газаплары, Газизҗанның хәбәрсез югалуы, ачлык-ялангачлык, шик астында яшәүләре, әнисенең ялварулары турында әйтәсе килде. «Мин бит сине гаепләмим, Галимҗан! Синең арттан мине дә алдылар. Син күргәннәрне мин дә күрдем. Мине хатын-кыз буларак, ана буларак үтерделәр. Син мине гаеплисең. Ә мин кемне гаеплим соң?!» — дип кычкырасы килде. Дәшмәде. Көтмәве дә хак. Барысы да беткән иде шул. Барысы да язмышның, михнәтнең аяк астына салып тапталган иде.

— Газизҗан сугышта югалган, Галимҗан...

— Беләм. Кырык икедә үк... Мин кайткач эзләтеп караган идем... Ленинград тирәсендә юкка чыккан бала...

Сүзгә кара хатын да кушылды.

— Телендә һаман шул Газизҗаны, һаман син. Мин аны карап торучыга гына әйләндем. Сукырайгач, көйсезләнде, сукрана, каргана. Теләгең булса, кил дә тор. Үзебезнең Оренбур якларына китәм дә барам...

Авыр тынлык урнашты. Тынлыкны Галимҗан үзе бозды.

— Кирәкми,— диде ул.— Безнең тормыш беткән инде. Бетте, утыз җидедә үк бетте.

Аннан башын Айсылу ягына борды.

— Тегендә... Магаданда синең хакта уйлау гына алып калды. «Барыбер кайтам,— дидем,— барыбер алдына тезләнеп кичерү сорыйм». Минем беркем алдында да гаебем юк — ил алдында да, партия алдында да. Синең алдыңда гына гаебем бар. Минем аркада күргәннәрең өчен.

— Синең гаеп белән түгел. Син үзең дә минем кебек үк корбан. Билгесез корбан... Күзең... кайчан болай булды?

— Тегендә... Җир астында... Андагы хәлләрне үзең беләсең, сорама.

— Миңа рәнҗемә, Галимҗан... Гаилә кордым, өч ятим тәрбияләдим.

— Беләм... Рәнгыя мине озата гына кайткан иде тегеннән... Кайтуга, сине эзләтә башладым... Өтернәстән дә сораттым. Тормышта, өч бала үстереп ята, диделәр. Шашып калдым. Үз-үземә кул салырга уйладым. Менә, Рәнгыя алып калды... Яшәү түгел инде бу... Кругом караңгылык... Бер якты нур юк, бер өмет юк... Нәрсә өчен?! Айсылу, нәрсә өчен болай булды соң бу?!

Галимҗанның ярсып кычкырган соңгы сүзләре күмелеп калды — өстә, кайчандыр Айсылулар яшәгән бүлмәнең тәрәзәсе дөпелдәп ачылып китте. Тәрәзәдә шешенгән нурсыз йөз күренде.

— Ал юк, ял юк,— дип кычкырды ул чәрелдек тавыш белән.— Көн юк, төн юк. Әле исереге җыелып чәңгелди тәрәзә төбендә, әле тиле-миле карт-карчык! Әз эләккән сезгә, халык дошманнары! Безнең атайлар сугышта үлгәндә, сез дәүләтнекен ашап яткансыз! А ну, эзегез булмасын монда! Юкса милициягә хәбәр итәм, йә өстегезгә идән юган суны җибәрәм. Тапканнар урын...

Дәшми генә кузгалып киттеләр. Ачык тәрәзәдән, җиңгән кыяфәтле булып, көрән пәрдә җилфердәде. Әле ярый Галимҗан аларны күрмәде, кайдан кычкырганнарын да аңламады. Куганнарын аңлады, башын иеп, Рәнгыянең җиңенә ябышып, бу урыннан тизрәк качарга тырышты. Дөньяга аның сораулары кирәк түгел. Дөньяның бер нәрсәдә дә эше юк. Менә шулай барачак ул, тагын бер килеп бәрелгәнче... Тарихта шәхесләр кабатланмый, ялгышлар кабатлана...

Юл чатында аерылыштылар. Галимҗан Айсылуның кулларын озак кына җибәрми торды. Бармаклары дерелди иде, гәүдәсе тагын да иелә төшкән, кечерәеп калган. Менә ул йөзе белән Айсылуның кулларына капланды, буыла-буыла: «Бәхил бул, бәхил бул...»— дип пышылдады. Айсылу чал башын аның күкрәгенә куйды, күзләрен йомды, әллә үзенә, әллә Галимҗанга: «Мең бәхил... Бәхил...»— дип әйтә алды. Ул бәхил иде, барысына да бәхил иде...

Кешеләр аларга карап, гаҗәпләнеп уздылар. Кемнәр алар, бер-берсеннән бәхиллек сорап, чат башында басып торган карт белән карчык? Очраклы танышлармы, авылдашлармы — кемнәр алар ике — ялгыз? Йөзләрендә нинди кырыс моң, газап аларның?

Беркем белми. Белергә вакыт та юк. Тормыш кайный, дәвам итә, бар нәрсә әкренләп онытыла, онытыла...

Онытмаган! Әнә бит, аерылып киткәч, борылды да:

— Кыңгырауны сакла! Кыңгырауны! — дип кычкырды.

Соңыннан, Зөләйха аша, Галимҗанның ялгыз йортта җан бирүен ишетте. Өч көн берүзе яткан. Күмгәндә янында бер-ике карт-карчык кына булган. Шулай итеп, хәтердәге ай нуры да өзелде, чулпы чыңы да тынды, ялгыз, хәтерсез буш гомер генә калды.

Кыяметдин карт таң алдыннан гына бик сәер бер төш күрде. Имеш, малай чагы икән. Балалар белән тауга чыкканнар. Укытучы Айсылу да алар арасында. Өстендә озын ак күлмәк, кара чәчләре җилкәсенә таралган, үзе яланаяк, балаларны каядыр әйди, ашыктыра. Аларга әнә шул тауга менеп җитәргә кирәк икән. Укытучы Айсылу вакыты-вакыты белән кулындагы кыңгырауны селкеп ала, арыган-алҗыган балаларга яңадан җан керә, сихерләнгәндәй, кыңгырау артыннан ияреләр. Инде тауның түбәсе дә ерак түгел, укытучы Айсылу аларны һаман үз артыннан биеккәрәк алып менә. Шул чакта караңгы үзәннән әллә нинди сәер йөк күренә. Озын чанага этләр җигелгән, ләкин дилбегәне тотучы юк, хуҗасы юк; этләр ырлап төрлесе төрле якка тарта, чана табаннары кара җирне яра, эзләргә шундук кара кан тула бара. Чанага, аркылы сузылып, хатын-кыз гәүдәләре салынган. Аларның йөзләре җир кебек соры, салкын, барысы да озын ак киемнәрдән. Тауга таба менеп барган укытучы кызны күреп, этләр аның артыннан ташландылар. Балалар, куркып, бер читкә өелде, укытучы Айсылу тауга таба ялгызы йөгерә башлады. Кулындагы кыңгыравы хәвефле авазлар чыгарып чыңгылдады, этләр өере аның саен котырынды, йотардай булып укытучы артыннан куды. Инде тау түбәсенә менеп җитәм дигәндә, укытучы Айсылуның кыңгыравы кулыннан ычкынып китте, ташларга бәрелеп зыңгылдый-зыңгылдый, түбән таба очты. Һаваны укытучы Айсылуның соңгы сүзләре телеп үтте:

— Кыңгырауны саклагыз! Кыңгырауны!..

Ул арада күк урталай ярылып китте. Яшен кылычы эт өеренең нәкъ уртасына килеп кадалды. Этләр, чинашып, һавага сикерделәр, берсенберсе йолкый, тешли башладылар, йөк таудан түбәнгә тәгәрәде. Тауның түбәсенә менеп җиткән укытучы Айсылу күкнең урталай ярылган өлешенә туры килде. Менә ул кулларын алга таба сузды, менә куллары канатка әйләнделәр, менә ак күлмәкле гәүдәсе әкрен генә җирдән аерылды, күккә тартылды. Күк аны үз кочагына кабул итте һәм ярылган урын әкрен генә ябылды, юкка чыкты.

Ә кыңгырау, таштан-ташка сикерә-сикерә, һаман түбән тәгәри иде...

Кыяметдин карт әсәрләнеп сикереп торды. Изге! Айсылу карчык изгегә әйләнгән! Күргән газаплары бәрабәренә, ул изгегә әйләнгән. Кыяметдин карт бүген үк аның янына барыр, тезләнеп гафу үтенер, кичерүен сорар. Аның каршында үзе сынар, үзе иелер. Бүген үк. Улы турында да сөйләр, аны үз кулы белән тотып бирүен дә әйтер. Урмандагы хәл өчен кичерү сорар. Гомер буе яратуын, аның өчен тәкате коруын әйтер. Шул хәтле зур гөнаһлар, әйтелмәгән сагышы белән ул җир йөзеннән китә алмый. Аны бит анда да тәмуг көтә, мәңгелек җәһәннәм!

Шул сүзләрен раслагандай, дөнья кинәт чатнап китте. «Сукты! — дип уйлап өлгерде Кыяметдин карт.— Алар турында сукты. Тагын аңа сукты!» Кыяметдин карт, атылып, урамга чыкты. Югары очта, Айсылулар өе тирәсендә, нидер дөрләп яна иде...

Өй эче кинәт яктырып китте. Юк, бу таң яктысы түгел иде әле. Бу әллә нинди шомлы, йөрәккә кадалып төшкән яктылык иде. Аның артыннан ук кинәт бөтен-бөтен дөнья чатнап алды. «Сукты!»— дип уйлап өлгерде Айсылу карчык шомланып.— Яңадан китереп сукты... Үтте дигәндә китереп сукты».

Шул чак тәрәзәләр кинәт гөлт итеп китте. «Янабыз!»— дип уйлап өлгерде Айсылу карчык. Хәлсез тәне белән почмак тәрәзәгә капланды. Йорт исән иде. Тик каршы якта, иртәнге эңгер-меңгерне ярып, ялкын теле күккә күтәрелә. Мәктәп! Мәктәп яна!..

Айсылу карчык аягына басты. Нәрсәләргәдер бәрелә-бәрелә ишеккә ташланды. Мәктәпкә кадәр ара ерак түгел, әнә генә, бернечә адым гына. Түбә кыекларыннан ялкын бәреп чыккан. Әле бәлки дөрләп тә китә алмас, юеш түбәгә чыккач, туктар...

Түбән очтан да кемдер дөпе-дөпе йөгерә. Кыяметдин булмагае. Аңа

кадәр барып җитәргә, кыңгырауны ничек тә алырга кирәк. Галимҗан төсе, Газизҗан төсе, яшьлек, өмет төсе... Өлгерергә генә кирәк... Шуннан башка аңа бу дөньяда да, тегесендә дә кичерү юк.

...Ишек-тәрәзәләр җил-давылдан каерылып ташланган. Мәктәп эче буш, караңгы, кайсыдыр почмактан чытырдаган аваз ишетелә. Янып килә, почмаклардан янып килә... Өлгерергә кирәк... Кыңгырау өстәл өстендә калды... Тагын берничә адым...

Урам якта Кыяметдин тавышы. Яшен аны да уяткан... Килгән... Аңа кадәр өлгерергә кирәк... Өлгерергә кирәк...

Дөнья нигә кинәт яктырып, җылынып китте соң? Һәм бүлмә эченнән кыңгырау чыңлаган тавыш ишетелә. Менә ул якыная, бөтен тирә-юньне чорнап ала, чыңлый, зыңлый, гүли. Бөтен мәктәп эченә, авыл өстенә, дөньяга гүли. Кыңгырау чыңы артыннан ялкын телләре сикерешеп чыга, бөтен мәктәп эчен, авыл өстен, дөньяны каплап китә. Кыңгырау һаман чыңлый, елый, хәбәр итә; ялкын телләре барысын ялмап, яндырып килә, корбаннарын эзли. Менә алсу пәрдәле йортка гөрләп ут каба, менә Себер төрмәләрендә меңләгән билгесез корбаннар яна, менә унөч яшьлек үсмер бала Газизҗанның тәнен ут чорнап ала, менә Галимҗанның иелгән гәүдәсе дөрләп яна. Алар ялкыны аңа да күчә — бөтен тәнен, җанын ялкын сарып алган Айсылу карчык гөрселдәп бусагага ава. Мәктәпне ялкын чорнап ала...

...Ул көнне авыл көтүе мәктәп янына җыелмады. Мәктәптән инде утлы кисәүләр генә калса да, һаман эссе бәреп, хәвефләндереп тора иде. Ут авылга таралмады, мәктәп үз бакчасы эчендә әкрен генә янып бетте. Беткәнче янды. Утырып янды. Сирәк-мирәк җыелган халык мәктәпнең янып беткәнен читтән карап торды...

Кыяметдин карт кына, бөтенесенең тынычлыгын алып, төркемнән төркемгә күчте. Күзләре аларган, ирен кырыйларына ак күбек җыелган. Һаман: «Күрдем,— ди,— шунда кереп китте»,— ди. Кем, нәрсә икәнен әйтми. Әле күккә ди, әле мәктәпкә, ди. Бер-ике тапкыр утлы күмерләр өстенә дә кереп китте. Чак тотып калдылар. Кыяметдин картның алышынганы күренеп тора иде. Мәктәп янудан да бигрәк, аның җүләрләнүе кешеләр өчен вакыйга булды. Кайсы кызганып, кайсы гаҗәпләнеп, кайсылары сөенеп шул турыда гына сөйләделәр. Айсылу карчыкның юкка чыкканын әле беркем дә белми иде.

Халык әкренләп тарала башлады. Кыяметдин карт кына һаман чыбык очы белән утлы күмерләрне кузгата, кисәү өеменең әле бер, әле икенче ягына чыга. Түбән очтан яман акырган тавыш ишетелә. Кыяметдин карт буш күзләре белән шул якка карый. Кара чәчле, тар маңгайлы малай аның янына килеп туктый. Бабасыннан күрмәкче, ул да кулына таяк ала, утлы күмерләрне әйләндерә башлый. Кичәге төзүче егетләр дә килеп туктый. Алар да Кыяметдин картны кыңгырау эзли дип беләләр, шуның аркасында акылдан шашкан, дип уйлыйлар. Ә ул бит утлы күмерләр арасыннан Айсылу карчыкны эзли, утлы елларны болгатып, туздырып, аннан чулпы таккан укытучы кызны эзли. Шуны беркем дә белми, шуңа беркем дә ышанмый... Аның күккә ашуына да беркем ышанмый... Бер Кыяметдин генә белә, ул ышана, ул шаһит.

Кичә мәктәпне күрше авылга күчереп саласы иделәр, терлекчеләр йорты итеп. Менә, кирәге дә бетте. Ак нигез ташлары өстендә кара кисәүләр генә торып калды. Авыл кыңгыраусыз, Айсылу карчыксыз калды... Анысын әле хәзер беркем дә белми... Барысы да, ашыга-ашыга, малларын авыл башына чыгара. Көтү куалар... Көтү... Көтү...

# Лена Шакирҗанова

## Шәрык шагыйренә ияреп...

Вакыты җиткәч, өйрәнгәнбез без дә
Әлифбадан хәреф танырга...
Кешеләрне тану өчен, нинди
Бер «Әлифба» уйлап табарга?

Истә әле кара тактабызга
Акбур белән сызып караган.
Остардык без инде һәммәбез дә
Аерырга акны карадан...

«Май чүлмәге, имеш, тышыннан ук
Билгеле», дип бәя куела.
Ак дигәнең кара булып чыкса?..
Иман әнә шулай җуела.

Һәр җемелдәп торган йолдыз булмас,
Җете кызыл артык тиз уңа.
Сул-сул диеп авыз суын корткан
Тартып китә бер мәл гел уңга...

Кылга кунган һәр кош былбыл түгел,
Чебендә дә канат яралган.
Һәр каралык әле язык түгел,
Карлыган да пешеп каралган...

Кеше — китап, укый белсәң әгәр,
Бәя бирим дисәң, укып чык...
Язмышы да аның уен түгел,
Үзе дә ул түгел уенчык...

Бик гыйбрәтле сорау: кем соң алар
Хөкем йөртүчеләр үзләре?!
Гадел күзлек аша карый белсен,
Таный белсен иде күзләре!

*1976.*

---

Лена ШАКИРҖАНОВА — *шагыйрә, «Мөлдерәмә күңел» һәм «Ышанам йөрәгемә» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

## Язмыш уены

Мин бер үзем шахмат уйныйм бүген:
уен кыры — аклы-каралы.
Кай як җиңәр?..
Үз-үземә каршы көрәш ачтым.
Ике араны
ничек үтәрмен мин,
кара якмы
җиңеп чыгар,
әллә аклармы?..
Язмыш уены — язмыш кыры алда.
Көрәш үзен үзе аклармы?..
Мин үземә үзем каршы бүген.
Җанда — көрәш:
аклар-каралар...
Акыл көче хискә «шах» биргәндә,
сыкрап куя шигъри яралар...
Аклар белән башлап җибәрсәм дә
язмышның бу серле уенын,
кара шакмакларга бүленәсен
белеп тордым гомер юлының...
Кайберләрен үтәм сикереп кенә,
вак-вак атлап үтәм кайберсен...
Ак юлыңнан чыксаң,
кара сукмак
адаштырып йөртә, хәерсез...

Мин үземне үзем әзәрлеклим,
Мин үземне үзем җиңәргә
тиеш бүген...
Ак фәрештәләрем,
бирешмәгез кара җеннәргә!..
Турыдан да үтәм, уратып та,
вак-вак адым — вакыт арасы.
Язмыш кыры гүя уч төбендә.
Абынмыйча ничек барасы...
Борынгыдан килгән бу уенда
акыл белән хәтер сынала...
Хискә бирелеп китсәң,
бик еш кына
туры килә чигенеп, сынарга...
Табындыра сине гел үзенә
бу уенның зирәк алласы...
Буйсынасың кайчак «пешкага» да,
королен дә кайчак аласың...
Уйлап уйна икән, чынлап уйна,
алдан күреп һәрбер йөрешне.
Ак атларым, бирешмәгез, зинһар,
мат куярга бүген тиеш мин!

*1988.*

## Кипсә яшел карасы...

*Бирде дөнья кирәкне,*
*Еламаска өйрәтте...*
Х. Туфан

Еламаска өйрәтсә дә,
Җырламаска өйрәтә
алмады, шөкер, дөньясы.
Җыр исән-сау йөрәктә...
Инде каныгып язмышка,
аны да алса тартып,
еламый да, җырламый да
яшәүдән үлем артык...
Еламаска өйрәтсә дә,

Җырламаска өйрәтә
алмады шул дөнья-камчы...
Җәрәхәтле йөрәктә
янсын яра, бәйләмәгез,
саркып торсын, канасын! —
Шагыйрь манып җырын язар,
кипсә яшел карасы...

*1987.*

## Капчык

Капчык аскан бер яшь хатын
ашыга тукталышка...
Авырлыкка йогамы соң инде
матурлык?!
Ыспай егет үтеп бара,
башын чөеп, горур тотып:

кинодагы рыцарьлардан калган отып...
Күз ярыгы аша качып кына
карады да,
кесәсенә кереп посты егетлеге...
Их, ир-атның шул этлеге!
«Булышырга кирәкмиме?», имеш,
камыш-чәчәк тотып барганда...
Ә арганда?
Сусаганда,
рәнҗегәндә —
ләм-мим!
...Әбисенең ике иңен баскан
шул ук капчык,
беләм мин...
Әбисе шул — өйдә.
Заманында
күпне күргән карчык...
Хәзер — күзсез.
Капчык — тупас,
карчык — дөм сукыр...
Ыспай «капчык» шәп-шәп атлап үтеп китте...
Үтеп китсә икән! —
бара һаман.
— Чәчәк бакчасына
төшсә юлы?..
— Әй, бармагае, кем малае...
...Табан асларында үксеп,
кичә генә
таҗын ачкан бер гөл
изелеп калмагае...

*1988.*

## Тормыш сәхнәсе

Ачыла да пәрдә, ябыла...
Тормыш сәхнәсенең — артынамы,
әллә —
чыгасымы алгы ягына?
Ә сәхнәдә — уен, тамаша:
ачылыр да пәрдә, ябылыр...
Аерырга Чынны
Уеннан
кемнәр килер,
кемнәр табылыр?
Уены-чыны бергә...
Гомергә
ул өлешләп безгә бүленгән.
Уйнап кына яшәргәме соң,
әллә —
чынлап уйнаргамы бүгеннән?..
Алкышларга артык ышанма! —
Кул чабалар кемнәр?..
Берәүләр
алдан түләп, яллап куелган...
Аерырга Чынны — Уеннан
кемнәр килер, кемнәр табылыр?..
Ачылыр да пәрдә, ябылыр...
Әле — кара, әле — ак пәрдә.
Сүнеп калса алкыш әгәр дә,—
хафаланма...
«Пәри туенда»
аерырга чынны уеннан
җиңел түгел...
Сәхнә алдында
без каласы гомер буена...

*1988.*

## Кабат ярат!

Ялгышканмын икән, инде монсы
Мәхәббәтнең диеп соңгысы...
Калган икән әле
өлешемә
иң газаплысы, иң моңлысы...
«Чын ярату шулай язлар сыман
кабатлана торган хәлмени»,—
дип берәүләр бәлки үртәлерләр,
өнәмичә минем хәлемне.
Кабатлана икән! Ләкин — сирәк!
Үз сәгате аның, үз язы.
Көтмәгәндә очып керә дә ул,
җан түренә үрә оясын...
Юкка гына куркып уянганмын
кичә, мәхәббәтсез калудан...
Кабат яну — янә канатлану.
Качма гүзәл кабатланудан!..

Сөю хисен ук-ядрәләр алмый,
аны күбрәк «акыл» үтерә.
Мәхәббәт җан биреп, гүргә кергәч,
күпме акыллылар үкенә...
Мәхәббәтнең була туган көне,
туа кайчак үлгән көне дә...
Җилгә очып киткән кебек
көле,
чәчәк ата сулган гөле дә...
Кабат сөя алу — язык түгел,
азгынлык та, йөгәнсезлек тә.
Көлдән гөлләр яралт,
кабат ярат,
сүнеп калма йөрәксезлектән!..

*1987, сентябрь.*

## Әниемнең мине белмәгән чагында...

Әниемнең мине белмәгән чагында
Итәгенә җилләр булып уралып йөрдем...
Чиләгенә агып кердем сулар булып,
Йөрәгенә моңнар булып үтеп кердем...
Әниемнең мине белмәгән чагында
Мин җәй идем, мин көз идем, мин кыш идем,
Һәм яз идем...
Әнинең мин үзе идем —
Мәхәббәтен көтеп йөргән бер кыз идем...
Әниемнең мине белмәгән чагында,
Төшләренә кердем колын, тайлар булып...
Әле — бөре, әле — чәчәк, әле — җимеш,
Әле — йолдыз, әле тулган айлар булып...

*1988.*

## Сезнең язлар

Сезнең язлар гөрли әле, көлә,
Безнең язлар инде елый белә...
Сезнең хисләр ташый язлар саен,
Безнең инде... елы ничек килә...
Сезнең язда бозлар китә агып,
Безнең бозлар кала эреми дә...
Сөю сәгатьләре суга сездә,
Безнең инде — кайчак йөреми дә...
Язлар сезнең әле иртә килә.

Ә безнеке — кайта соңлабрак.
Бәхет сезгә сорамыйча керә,
Без көтәбез иңрәп, елап, сорап...
Кабатлана һәр ел сезнең язлар,
Безнең инде — елы-елы белән...
Сезнең язлар көлә генә әле,
Безнең инде язлар елый белә...

*1988.*

# Илдар Әхсәнов

## Ике шигырь

❋

Шәфәкъ алыннанмы кан саудырып,
Тәгәрәде еллар йомгагы? —
Шашкын шомы алыр җаның суырып,
Хәтереңә кагылып уз тагы...

«Яши белгәннәргә» табынудан
Зиһен киткән башта таркалып;
«Шүрәлеләр» кулын кыскартудан
Калмас иде күңеле тар халык...—

Кытыклады озын куллар аны,
Кимен куймый җитез маймылдан;
Тамашада түгел Былтыр җаны,
Иманыннан түрә тайпылган.

Күршем гаеп итеп алмасынга
Бер догада телне тибрәттем...
Җилкә каккан Былтыр тарафында
Син сарыгы булма гыйбрәтнең!

И сабыр көн, үчекләгән кебек
Башка мәхлук таҗы кидерттең;
Юкса рухи туганнары идек
Без дә Былтыр атлы егетнең!

Гамьсез үткән гомер сызландыра,
Күңелемдә шигем юк-югын,—
Яшерен өмет сәбәп эзләп тора
Уйнатырга күңел мутлыгын.

Тарих сыман борылмалы микән
Көрәшченең гомер сукмагы? —
Ничек соң, әй, вәгъдә изгелеге
Егетлеккә болай сусады?

Кан коймаган идек яу кырында
Бушбугазлар илдә артсынга;
Җан кыйнала бүген сандалында,
Ут уйныйдыр аяк астында...

---

Илдар ӘХСӘНОВ — *ике шигырь китабы авторы. Әлмәттә яши.*

*И мөкатдәс моңлы сазым!..*

Г. Тукай.

Арышларны сыйпап дулкын уза...
Ихлас булган анты Җәлилнең;
Әйтә кебек узган гомер юлы:
«Разый синнән, олан, бәхилмен...»

Бәхетнең бу бәлки олысыдыр,—
Салкын акыл ирешә алмасы:
Кол Галиләр рухын калкан иткән
Керәшендә адәм баласы.

Сак-Сок бәетенә кайта хәтер,
Кайта янә Мәҗнүн гыйшкына,—
Ничек кенә бөек булмасыннар,
Монысына тиңнәр юк кына!

Асылында җырга күчте тормыш,
Тоткынлыкның үтеп мәхшәрен;
Кызыл гөлләр кайтты Туган илгә,
Тетрәндереп ятим җир шарын.

Диңгез ярын кагып дулкын уза:
«Әманәте изге Мусаның...»
Ирләр тугрылыгы тотып тора
Мәхәббәткә җанның сусавын.

Чәнечкеле тимерчыбык аша
Кояшына гөлләр үрмәли;
Биеклекләр яулый сабаклары,
Биеклекләр — йөрәк үтәли.

Мең ел буе чыңлап тора җыры —
Керәшләрдә туган хәзинә,—
Болгар бабам җирлегеннән җанга
Язның нәкъ үзедәй саз иңә:

Шәфкать тибә якты аһәңендә,
Иделемдәй моңнар агымы;
Соң тамчысы канның аңа баглы,
Дәрьясына сине салдымы...

Кылыч булган сансыз яуга каршы,
Вөҗданына саклап тугрылык;
Саф телендә калган, үткәндә дә
Тарих чәкүшкәсе орынып.

Башакларга кагылып дулкын уза:
Рухы сынмас булган Җәлилнең...
Җыр чакырган биеклекләр белән
Күрешүләр эзләп гаҗизмен.

## Җәмит Рәхимов

# ЯРСУ

ХИКӘЯ



Монда инде аяк басып торыр урын булмаса да, бүлмә тып-тын — бөтенләй буш кебек. Райбашкарма рәисе Сабиров янына ашыгыч рәвештә чакырылган, аның кабул итүен көтеп утырган авыл советы председательләре барысы да хафалы уйда: «Тагы нигә чакырган икән бу Сабиров? Халыктан тагы ни җыярга кушар да, нинди задание бирер? Дүрт ел буена барган бу сугыш дәверендә авыл халкыннан нәрсә генә җыеп алынмады да, нинди генә түләү-салымнар салынмады? Әле сугыш беткәч тә калган микәнни?..»

Колмаксар авылы башлыгы Галимулла карт килеп кергәч, бүлмә бөтенләй тулып, ташып чыккан сыман булды. Ул, мондагыларны үзенең заманына күрә юан гәүдәсе белән этеп-ешып, тыйнак кына киенгән секретарь хатын янына узды, аның йөзенә туры карап сорады:

— Көн тәртибе ни, белмисеңме?

— Вакыты җиткәч, Галимулла агай, вакыты җиткәч.

Кырә-керешкә ясаган бу һөҗүме барып чыкмагач, Галимулла халыкка таба борылды, шарран ярып әйтеп куйды:

— Инде бу чакырулардан тынып торырбызмы әллә дигән идем...

Куштирәк авыл советы председателе Надирә аның сүзен күтәреп алды:

— Сөйләмә, сугыш туктагач та тынгы юк.

Инде барысы да, уйларыннан айнып, бердәм шаулаша башладылар:

— Тагы нәрсә сорар икән?

— Бәрәңге симәнәсе, билгеле. Аны утырту планы яртылаш та үтәлмәгән бит әле.

— Әллә соң юл төзәтү хакында микән?

Бүлмә базарга әверелде, председательләрнең һәркайсы үз фаразын әйтеп калырга ашыкты. Мондый тәртипсезлеккә күнекмәгән секретарь ханым аягына торып басты, кызып киткән авыл башлыкларын тезгенләргә ашыкты:

— Иә, базар ясамагыз әле, иптәшләр!

Сүзен әйтеп бетермәде, өстәлендәге телефон шалтырады. Барысы да тынып калдылар. Тәрәзәдә талпынган кызыл күбәләкнең лепелдәве ишетелеп торды хәтта. Шул тынлыкта телефон трубкасыннан Сабировның бераз карлыккан тавышы аермачык булып яңгырады:

— Керсеннәр!

Менә алар — районда утыз җиде авылның утыз җиде башлыгы — Сабировның киң, иркен бүлмәсендә стеналар буена тезеп куелган урындык-

---

Җәмит РӘХИМОВ *(1935) — прозаик. «Девон хәбәрчесе», «Өлешемә тигән көмешем», «Тәвәккәл таш яра», «Кыядагы чәчәкләр» һәм башка әсәрләр авторы. Лениногорск шәһәрендә яши.*

ларда утыралар. Йөзләрендә борчылу, гаҗизләнү, шом. Кая ул сүз кату, ник кенә берсе төчкерсен дә, ник кенә берсе йөткерсен. Сабиров, аларны барлагандай, барына да сөзеп кенә карап чыкты да, елмаеп җибәрде:

— Сез нәрсә, әрвахларны зиярәт итәргә килгән төсле утырасыз әле?

— Шатланырлык нәрсә күренми сыман, иптәш Сабиров,— дип, барысы өчен дә җавапны Галимулла бирде.— Беләбез ич, тәти бирергә чакырмыйсың син.

— Юкны сөйлисең, Галимулла агай,— Сабиров өстәлендәге кәгазьләрдә актарынып алды, аннан шактый сыегайган кара чәчен артка таба сыпырып куйды.— Шатлыгыбыз бар һәм дә чиксез зур. Җир шарындагы иң явыз дошманны дөмектердек.

— Алаен алай да, үзебез шәрәкәй калдык, кем Сабиров,— дип бәхәсләште Галимулла, ап-ак сакалын сыпырып.

— Анысы бар,— Сабиров кинәт җитдиләнде.— Сугыш китергән җимереклектән чыгу өчен билләрне тагы да ныграк буарга туры киләчәк безгә. Ярар, сүз ул хакта түгел бүген.

Аның соңгы сүзеннән тагы да аптырабрак калдылар, дөньяларын онытып, райбашкарма рәисенә текәлделәр.

— Әйе,— дип дәвам итте Сабиров, талчыккан йөзендә кабат елмаю балкытып,— ул хакта түгел, бәйрәм турында сөйләшик, иптәшләр. Сабан туйларын уздырасы иде бит.

Куштирәкнең чая Надирәсе дәшми чыдамады:

— Шаяртмачы, Сабиров!

— Нинди шаяру ди, үткәрәбез, үткәрәбез аны! — Галимулла тәмам канатланды.

— Һы, бетең беләнме?— дип тавыш бирде Таллыярның яңа председателе Госман һәм, сүзен раслагандай, протез кулын шыгырдатып алды.

Галимулла шунда ук аңа очып кунды:

— Нигә бет белән? Сугышка кадәрге сыман ук бөтен шартын китереп уздырабыз аны, Госман. Минем, примир, сугыш чыккан елны җыйган сөлгеләрем исән. Тимер сандыкта, беләсең килсә.

— Сездә шулайдыр да бит, бездә менә...— дип мыгырданды Госман, юашланып.— Сугышның дүрт елына мин бишенче персидател Таллыярда. Минем алын Хабуш тапканын-табынганын эчеп бетерә барган. Пичәт хәтле пичәтне югалткан хәтта, хәерсез.

— Соң, барыбыз да шул хәлдә инде,— дип бәхәскә кушылды Надирә.— Алай да, юк дип, елап торып булмас. Үткәр ъез, иптәш Сабиров, гөрләтеп үткәрәбез. Соңгы сөлгеләребезне җыеп булса да...

Аның сүзен башка хатыннар күтәреп алды:

— Уздырмый ни, гомерлек бәйрәмне.

— Әбәзәтелне!

— Имынны хәзер — иң кыен чакта үткәрергә кирәк тә!

Күпчелекнең фикере ачыклангач, Сабиров тезгенне үз кулына алырга ашыкты:

— Уздырырга кирәк, иптәшләр. Һәм ничек кирәк алай түгел, нәкъ сугышка кадәргечә итеп. Тапкан-табынганны үзегез җыярсыз. Аз булса да, без дә ярдәм итәрбез. Райсоюзга күлмәк-ыштан, кирза итек сыман товарлар кайтардык. Чорына күрә бүләккә алары да ярап куяр. Димәк, июньнең икенче якшәмбесендә. Шимбә көн — авылларда, якшәмбе — районда. Каршылар юк бугай.

Авыл вәкилләре таралгач, өшән гәүдәсен бөкрәйтеп, шактый уйланып утырды Сабиров. Уздырачаклар, әлбәттә, гөрләтеп уздырачаклар. Сугыш чорының кырыкмаса кырык мәшәкатен җилкәләренә күтәргән авыл сабан туен гына оештырмый ди мени? Әйе, әйбәт узар, районда да киме булмас. Инде чаралары күреләдә башлады. Райсоюз складына көн саен диярлек савыт-саба, кызыл мал, арзанлы кием-салым кайтып тора. Аннан тыш, һәр авыл икешәр сөлге китерәчәк, гармунчысы да, җырчы-биючесе дә табылыр. Тик менә иң мөһиме — батырга бүләк юк бит әле. Гомерлек гадәт буенча, сабан туе батырына симез сарык тәкәсе бирелә иде. Анысын каян аласың хәзер? Колхозларда бүләккә бирерлек түгел, сарыкларны бәхилләтерлек тә тәкәләр калмады. Шулай ук бозау, яисә башка бер дүрт аяклы мал бирү хакында да уйлыйсы юк. Нишләргә соң? Әтәч биреп булмый бит инде батырга! Радиоалгыч, яки патефон ише нәрсә чамаларгамы әллә?

Ул шулай аптырап утырган арада, шактый талапчән итеп, ишек шакы-

дылар. Рөхсәт-фәләнне дә көтмичә кереп килүче ир-ат күренде. Агач аягы белән шапылдатып басуына караганда, райком шоферы Ишбулдин иде бу. Шул — үзе, җепкә элеп киптергәндәй чандыр, яңагы-яңакка ябышып, бите кошнмкына охшап калган. Сабиров аңа сәерсенеп карап торды да, берни аңлатмый торган тавыш белән әйтеп куйды:

— Әйдүк, Ишбулдин. Ни йомышлар белән?

Тегесе җавап бирергә ашыкмады. Титаклый-титаклый, түргә узды, председатель каршындагы урындыкка килеп утырды.

— Сабан туе уздырасыз икән.

— Шулай дип уйлашабыз, Ишбулдин,— «Әллә йөгерергә исәп бармы?» — дип тә өстәмәкче иде, вакытында тыелып калды Сабиров. Ул да түгел, Рәмзи Ишбулдинның сугышка кадәр сабан туйларында көрәшүе, хәтта берничә ел рәттән район батыры булып калуы исенә төште. «Менә ич әзер судья,— дип шатланды ул эченнән,— бирим дигән колына — чыгарып куяр юлына, ди».— Үзем дә сине чакыртмакчы идем әле, Ишбулдин, судья кирәгәчәк.

— Бездән инде көрәшүләр булмас хәзер,— дип уфтанды Рәмзи, ничектер моңсу итеп.— Ә судьялыкны булдырабыз аны. Көрәшчеләр генә табылсын.

— Да, сугыш нык изгән сине, Ишбулдин. Нишлисең бит, исән калганыңа шатлан. Көрәшчеләр исә булыр алар — үсеп торалар ич. Тик менә ни бит әле, батырга бирерлек бүләгебез генә юк.

— Шул хакта кердем дә инде мин, иптәш Сабиров. Батырга дигән бүләкне үзем бирәм. Бер дигән аккордеон! Тугыз регистрлы. Италия осталары ясаган.

Сабиров аңа шикләнебрәк карап куйды. Шаяртмыймы бу? Һәм Рәмзине башка яклабрак капшый башлады:

— Син үзең гармунчы бит, Ишбулдин. Чабатачы шөшлесен сатса, нишләр?

— Минем өчен хафаланмагыз, иптәш Сабиров. Үземнең сугышка кадәрге тальян бар минем. Таллыяр Гафият эше — мәңге тузарлык түгел.

Мәсьәлә ачыклана төште. Димәк, форсаттан файдаланып, аккордеонын сатмакчы бу. Инде сүзне чынга борырга да мөмкин иде.

— Кыйбат сорыйсыңмы соң, Ишбулдин, ул нәмәрсәң өчен дим? Алай чит ил осталары эшләгән нәрсә булгач, арзанга бирмәссең бит инде син аны?

— Кыйммәтле дип, бәяләп-сатып бирә торган түгел инде аны, иптәш Сабиров. Бушка бирәм мин аны сезгә. Үземә дә бер тиенсезгә килеп кергән мал.

— Ничек?

— Ничек дип... Будапештны штурмлаганда булды ул хәл. Алгы сызыкка боеприпаслар ташыйбыз. Чираттагы йөкне илткәч, кайтып киләм шулай. Минем алда гына әллә нәрсәләр төягән трехтонка. Шуңардан калышмаска тырышып, бар куәтенә куам полуторканы. Кинәт әллә каян гына дошман самолеты килеп чыкмасынмы. Безнең өскә килеп тә җитте, аллы-артлы өчдүрт бомба томырды бу...

— Соң, соң?

— Кайчан һәм ничек төшеп капланганмындыр юл кырыендагы чирәмгә. Анысын хәтерләмим. Аңыма килгәндә, миннән алдагы машина дөрләп яна, кабинасыннан чыгучы да күренми иде. Тиз генә торып, кабинама кердем дә, машинаны артка бирдем һәм, янып бетеп бара торган трехтонканы әйләнеп үтәргә дип, юл кырыена чыктым. Карасам, чирәмдә зәп-зәңгәр булып шул аккордеон ята. Тулы бер машина йөктән шул гына исән калган икән. Төшеп алдым моны, янәшәмә куйдым да частька алып кайттым.

— Әллә ничегрәк килеп чыккан икән, Ишбулдин.

— Бер дә әллә ничек түгел. Мин аны хуҗалык бүлегенә тапшырган идем тапшыруын. Иптәшләр бит, уйный белүемне сизеп алдылар да, һәр көн кич аптыраталар мине: «Уйна да уйна!». Шулай итеп, көн саен уйный башладым. Шулай уйный торгач, бер заман аккордеонны үземә бүләк итеп бирделәр. Аннан соң каты яраландым. Мине аңсыз килеш Горькийга, госпитальгә озатканнар. Дүрт ай аунарга туры килде койкада. Госпитальдән чыгарга дип, документлар рәтләп йөргәндә, әлеге аккордеонны китереп бирделәр. Аны, ничектер, үзем белән озатканнар да, шундагы кием-салым арасында сакланып яткан, имеш.

— Алай,— Сабиров авыр сулап куйды.— Бик зур истәлек икән ич, Ишбулдин, синең бу аккордеоның. Кызганыч түгелме?

— Сабан туе батырына кызганыч була димени?! Сугыштан соң беренче сабан туе бит, иптәш Сабиров.

Райбашкарма председателе дәшмәде, «Халыкның әллә нинди яхшы яклары бар»,— дип уйлап куйды.

Авыллардагы сабан туйлары, чыннан да, шаулап үтте. Бүләкләр ярлырак дип тормадылар, йөгерештеләр дә, чүлмәк тә ваттылар, аркан тартып та көч сынаштылар... Дөрес, көрәш мәйданнарында хәл сыеграк иде. Кая ул сыек кына, кайбер авылларда чын көрәш бөтенләй булмады.

Бу хәл Сабировны пошаманга салды. Әйе, таза ир-егетләр калмаган диярлек авылларда, исән калган фронтовиклар исә кайтып җитмәгән. Иртәгә район сабан туенда да көрәшүче булмас микәнни? Малайлар әүмәкләшкәнне карап утырырга калырмы? Чын ир-егетләр көрәшмәгәч, нинди сабан туе инде ул?! Нишлисең, заманасына күрә сые. Алай да бөтенләй өметне өзмик әле. Район хәтле районда тәмам беткәндер дисеңме көрәшчеләрне? Әнә бит, Колмаксарда ничек көрәштеләр! Кичкә кадәр барды тартышулары. Шунысы гаҗәп, батырга, бәләкәйрәк булса да, бер тәкә әзерләгән иде Галимулла. Үзенекен алып килгән дип сөйләделәр. Булыр да аңардан!

Транспорт ягын искә алып, сабан туе мәйданын район үзәге кырыендагы чирәмлеккә, дөресрәге, аэродромның бер почмагына тәгаенләгәннәр иде. Монда күләгәсенә утырып ял итәрлек куаклыклар юк югын, янәшәдә генә челтерәп чишмәләр дә акмый. Аның каравы, барасы килгәнгә ат яисә машина эзләп җәфаланасы түгел. Өстәвенә, кибетләр дә, ашханә дә якын гына — карыны ачканнар рәхим итсен. Мәйданы тагы, үзе такыр, үзе чирәмле, өстәл өсте кебек тигез.

— Һай, мәйданның нинди булуындамыни соң хикмәт?! Бөтен эш халык җыелуда, кешеләрнең активлыгында, кәефендә. Бәйрәмне бәйрәм иткән — халык үзе бит инде. Һәм, әйтергә кирәк, халык әйбәт җыелды. Дөрес, мондагыларның күбесе хатын-кыз, бала-чага. Булса ни, сугыш чорының бөтен авырлыгын шулар тартып бардылар ла. Бәйрәмдә дә урыннары түрдән булсын, рәхим итсеннәр, уйнасыннар, көлсеннәр.

Нәкъ сәгать унда райбашкарма рәисе Сабиров мәйдан уртасындагы өстәл-трибунага менеп басты. Дулкынланды, каушап калды ул. Алай да, сөйли башлагач, тавышы батырайды, гадәттәге ныклыгына кайтты. Ә сөйләр сүзе күп иде аның. Райондашларының озакка сузылган сугыш елларындагы фидакарьлеге, каһарманлыгы тулысынча килеп басты аның күз алдына. Ул шушы районда туып-үскән ун Советлар Союзы Герое белән бер рәттән дистәләрчә тракторчыларны, ат караучыларны, уракчыларны, терлекчеләрне атады, илебез иң кыен сынау кичергән чорда армый-талмый эшләүләре өчен райондашларына рәхмәт әйтте.

Шуннан инде төрле уеннар, ат чабышлары башланып китте. Халык, мәйданның әле бер башына, әле икенче ягына авышып, күңеленә хуш килгән уеннарны карый иде. Алар исә кызганнан кыза бара. Сугыш елларында бөтен авыр эшне тарткан апалар һәм сеңелләр монда да каушап калмаганнар: чүлмәген дә ваталар, арканын да тартышалар. Җыр-бию дигәнне әйткән дә юк — анысы һич кенә дә тынып тормый.

Тик менә ике ярдәмчесе — башларына түбәтәйләрен киеп, җилкәләренә сөлгеләр салган ике карт белән мәйданның бер тарафында йөренүче Рәмзи Ишбулдин янында гына сүлпәнлек. Дөрес, баштарак монда да «көрәшчеләрне» санап очына чыгарлык түгел иде. Малайларның берсе егылуга, икенчесе чәчрәп чыга. Өчне екканы исә, бүләккә трусик яки яшел тарак алып, иптәшләре янына мактанырга ашыга.

Аларны үсмерләр алыштырды — көрәш кыза төште. Халык шунда таба авышты. Тик анысы озакка бармады. Баш судья Рәмзи үзе үк үсмерләр көрәшен кыскарак тоту ягында иде. Чөнки көн кыска, ә алда әле — чын көрәш, ир-егетләр көрәше. Җыелган халык кына түгел, Рәмзи үзе дә шуны көтә иде.

Ул, кулындагы яулык, майка, күлмәк ише бүләкләрне картларга бирде дә, үзе өстәл янына килде, көрәшчеләр исемлеген кулына алды. Хәл, чыннан да, аяныч иде. Нибары унбер кеше язылган. Аларның да яртысы чын көрәшчеләр түгелдер әле, мөгаен. Рәмзи, кара коелып, исемлекне әйләндергәләде, аннан җыелган халыкка карап кычкырып җибәрде:

— Әй, көрәшчеләр, сезне көтәбез!

Рәмзи, әле уңга, әле сулга каранып, үзенә таба якынлашучы ир-егетләрне көтте. Тик, кая гына карамасын, яулык бәйләгәннәрдән башка кеше күренмәде. Кәефе тагы да кырылды судьяның. Сугыш, сугыш гаепле барына да. Ә бит элек кара төнгә кадәр көч сынаша торганнар иде көрәшчеләр. Нихәл итмәк кирәк, булганы белән канәгатьләнергә кала.

Ул, үсмерләр көрәше тәмамланганны да көтми, мәйданга беренче парны чакырды. Чандыр гына ике ир-ат кисәге. Бер-берен этеп егарга маташа торгач, кайсыныңдыр сырты җиргә тиде. Судья, бөтенләй өметен өзеп, икенче парны чакырды. Болары инде көрәшчеләргә охшаган иде. Күлмәкләрен салып аттылар, кулларын селтәштереп, физзарядка ясагандай иттеләр — күренеп тора фронтовиклар. Һәм, чыннан да, алар көрәшә башлауга, бәйрәм ямьләнеп китте. Халык бу төбәккә бөялде. Көрәшчеләргә көч биреп, кычкырып торучылар күбәйде. Инде Рәмзи дә бөтенләй башка кыяфәт алды, протез аягын да онытып, көч сынашучылар яныннан китмәде. Менә көрәшчеләрнең берсе, көндәшен җирдән өзеп алды да, күз ачып йомганчы, аны сыртына салды. Мәйдан «аһ» итте.

Алай да җиңүчеләр ачыклана башлады инде. Өчне еккан егет, сөлгесен җилкәсе аша салган да, тыныч кына чирәмдә утыра. Аның янәшәсенә башка батырлар өстәлә тора. Менә алар барысы өчәү генә калды. Колмаксарның кызыл майкалы тракторчысы, Куштирәкнең ак ситсы күлмәкле бригадиры һәм озын буйлы район киномеханигы. Тик, буе озын булса да, буыны сыеграк икән шул. Куштирәк бригадиры аны «ә» дигәнче чөеп салды. Аның каравы, Колмаксар тракторчысы белән озак алыштылар. Бригадир тәмам әлсерәде, бирешә башлады, менә-менә билен бирәчәк.

Ләкин шул чак әллә нәрсә булды. Халык төркеме шау-гөр итеп, этешә-төртешә каядыр чаба башлады. Бераздан инде көрәшчеләр белән судьялар үзләре генә торып калды. Баксаң, аэродромның теге башына самолет төшкән икән. Барысы да шунда йөгергәннәр.

Кәефе тәмам кырылган Рәмзия көрәшне туктатты. Батырның батыр калуын карап торучы булмагач, йә ни инде бу?! Ләкин берни эшләр хәл юк, мәйдан тулысы белән самолет янына күчкән иде.

Ярый әле, озак көтәргә туры килмәде. Очкыч моторын сүндерү белән, халык кабат мәйданга агылды, бераздан инде көрәшчеләрне урап алды. Бригадир белән тракторчыны көрәшкә кушарга дип кенә торганда Рәмзи янына өстенә солдат гимнастеркасы кигән чандыр егет килде, көрәшергә рөхсәт сорады. Маңгаендагы күзлегенә караганда, бу егет самолеттан төшкән иде. Очучыдырмы, юкмы — анысы әһәмиятле түгел иде Рәмзигә. Нишләргә? Көрәшкә кертергәме, юкмы гимнастеркалыны? Ул бит өчне екмаган, талчыкмаган да. Инде тәмам хәлсезләнгән егетләр белән көрәштерсәң, дөрес булырмы бу? Ишбулдин икеләнеп калды. Әмма аны урап алган халык: «Көрәшсен, көрәшсен»,— дип гүли иде. Рәмзи картларны янына чакырып алды, шыпырт кына киңәште. Аны иң өркеткәне — чит кешенең район батыры булып калуы иде. Ләкин картлар аның белән килешмәделәр, «Сиңа җәлке шту-ли, көрәшсен!» — дип, икесе бер авыздан куәтләделәр. Инде Рәмзинең дә киреләнер урыны калмады, күпчелеккә буйсынмый чара юк иде. Озак бәхәсләшкәннән соң, гимнастеркалы егет бригадир белән дә, тракторчы белән дә көрәшергә тиеш дигән карарга килделәр.

Рәмзинең шикләнүе юкка булмаган икән. Бригадирны бер ыргымда җирдән өзеп алды гимнастеркалы һәм бик ансат кына сыртына салды. Дөрес, Колмаксар тракторчысы белән озак тартыштылар. Гимнастеркалының чын көрәшче икәне әллә каян күренеп тора, ул көрәш алымнарын әйбәтрәк белә, күнегүләр узган булуы да сизелә. Тракторчы белән тарткалашуы да, болай, карап торучыларга тамаша булсынга гына түгел микән?

Шулай булып чыкты. Ул, тычкан белән уйнаган мәче шикелле, Колмаксар тракторчысына үзен җирдән өзеп-өзеп алырга биргәләде. Тик һич кенә дә сырты белән төшми иде. Шулай шактый маташкач, гимнастеркалы кискен хәрәкәт белән көндәшен кысып алды, җирдән аерды һәм, шундый ук җитезлек белән, сыртына салды.

Мәйдан гөр итте. Халыкның шау-шуына Рәмзи үзе дә кушылып китте, гимнастеркалы өчен шатлана-шатлана, өстәл янына барды, зур зәңгәр аккордеонны күтәреп алды да мәйдан уртасына ашыкты. Әмма гимнастеркалы янына барып җитмәде, тукталып калды, бүләген чирәмгә куйды. Тукта, бу ничек була соң әле? Батырга дигән затлы бүләкне чит-ят кеше алып

китэчэкмени? Бүләге черт с ним, анысы җәл түгел. Җиңгәнсең икән, рәхим ит — ал! Оста көрәшчеләрне гомере буе хөрмәт итте Рәмзи, фронт сабан туйларында да алар өчен янып-көеп йөри торган иде. Монда исә башка очрак. Бүләк кенә китми, район даны да китә ич читкә! Моңа ничек түзмәк кирәк?! Юк, юл куярга ярамый. Һәм ул, титаклый-титаклый, мәйданны урарга тотынды:

— Батырга кем чыга? Әйдәгез, егетләр, сынатмагыз! Район даны ычкына ич кулдан...

Әмма ул никадәр генә сөрән салмасын, гимнастеркалыга каршы чыгучы күренмәде. Бу хәлгә гарьләнде, сыкранды Рәмзи, ут капкандай бөтен тәне яна башлады.

— Нужәли район данын биреп җибәрәбез, егетләр?! — дип кычкырды ул, ачыргаланып.

Җавап бирүче булмады. Рәмзи кинәт, бер селтәнүдә, кызгылт шакмаклы күлмәген ярып җибәрде, аннан салып ук атты һәм гимнастеркалыга таба атлады. Шул чак артында ук хатыны Халидә чырыйлап җибәрде:

— Нишлисең син, Рәмзи бәгърем?! Тегендә, сугышта үлмәгәнне!..— Һәм ул иренең кулына килеп ябышты.

Рәмзи аны бер селтәнүдә читкә чөеп ыргытты. Ничек күзенә чалынгандыр, шул кызулыгы арасында сары майкасының ямавын күреп алды. «Ә» дигәнче анысын салып ташлады һәм гимнастеркалы каршына килеп басты.

— Яле, алышып карыйк, кордаш,— дип гыжлады ул, җирдә яткан сөлгене кулына алып.

Мәйдандагылар аның уң як җилкәсеннән башланып биленә кадәр төшкән кып-кызыл җәрәхәт эзен шунда гына күреп алдылар бугай, берсенберсе узып шаулашырга тотындылар:

— Куй, Рәмзи, имгәнерсең!

— Көрәшерлегең калмаган инде, яшьти.

— Протезсыз каласың ич, дивана!

Ишбулдин исә аларның үгет-нәсихәтләрен ишетми, һаман үзенекен кабатлый иде:

— Иә, ал сөлгеңне, солдат!

Гимнастеркалы аңа нидер сөйли, үзе акрын-акрын гына Рәмзидән читләшә иде. Ләкин Ишбулдин аңа китеп барырга бирми, сөлгесе белән биленнән эләктереп алмакчы. Ниһаять, гимнастеркалы җыелган халыкка килеп төртелде һәм, алардан ярдәм сорагандай, борылып нидер әйтте. Тик Рәмзи, аның ай-ваена карамый, сөлгесен тегенең биленә салды.

Гимнастеркалы кинәт җиргә тезләнде һәм сөлгесе белән битен каплады.

— Җиңдең, җиңдең, туган, бирелэм! — дип кычкырды ул, яшенә тыгылып.— Мә, бу сөлге дә синең иңне бизәсен.

Әмма Рәмзи инде тәмам ярсыган, үзенең протезын да, күптән түгел генә эллэлэнгэн җәрәхәтен дә онытканы иде.

— Көрәшми торыпмы?! Юк, брат, алай булмый. Көрәшче Рәмзи диләр мине! — дип шаулады ул ярсынып һәм гимнастеркалыны җилкәсеннән тартып торгыза башлады.— Тот сөлгеңне, брат!

Гимнастеркалы, җитез хәрәкәт ясап, Рәмзинең кулларыннан ычкынды һәм, кисәк борылып, халыкны аралый-аралый, мәйданнан читкә ташланды. Җанлы бөҗраны өзеп чыгуга, йөгерергә үк тотынды. Мондагылар аны карашлары белән самолетка хәтле озаттылар. Янә берничә минуттан очкыч һавага күтәрелде, сабан туе мәйданы өстендә бер әйләнеш ясады да, көнбатышка, Казанга таба юл алды.

Халык исә самолет Колмаксар урманы артына кереп югалгач кына аңына килде. Булган кадәр ир-егетләр әле һаман да ялангач килеш мәйдан уртасында торган Ишбулдинны урап алдылар һәм шаулашырга тотындылар:

— Молодец, Рәмзи!

— Район данын яклап калдың бит тәки.

— Егет икәнсең!

Аяк астында аунап калган аккордеонны райбашкарма рәисе Сабиров үзе күтәреп килде һәм Рәмзигә сузды:

— Ал, Ишбулдин, чын көрәшче икәнсең. Үз күчтәнәчен ашаган кеше үлемсез була, диләр. Мең яшә!

Әмма Рәмзи аккордеонга үрелмәде. Халыкны ера-ера мәйданнан чыкты да, күлмәксез көенчә, кызу-кызу өенә таба титаклады. Ике күзеннән дә яшь ага иде район батырының...

## Роза Хафизова

# ЗӨЛӘЙХАНЫҢ СӘГАТЬ ЧЫЛБЫРЫ

ХИКӘЯ



Кәҗәбезне бөтенесеннән алда чаптырып алып кайттым. Фатихларның кәҗәсе әллә кайда, артта калды. Фатих ник көтү каршыларга килмәде икән? Күндезен дә күренмәде. Хәер, аны очратырга вакыт та булмады минем. Әни белән урманга печәнгә мендек. Күне буе иптәшләреңне күрми тор әле. Дөньяда әллә ниләр булгандыр шикелле.

Читән аша үрелеп, ишегалдына карадым. Әни кәҗә саварга әзерләнеп йөри, миндә эше юк. Форсаттан файдаланып, тиз генә Фатихларга элдерттем. Күршедә генә алар безнең. Бер ягыбызда — Фатихлар, икенчесендә — Зөләйха апалар. Фатихларның йорты безнеке кебек гадәти генә. Зөләйха апаларныкы зур, матур. Кәрнизләре, тәрәзә кашагалары, койма, капкалары — һәммәсе берочтан челтәрләп эшләнгән, зәңгәргә буялган. Авылда бер матур йорт.

Без Фатих белән, абзар түбәсенә менеп ятып, аларның ишегалдын күзәтергә яратабыз. Ишегаллары безнекеннән әллә ни зур түгел түгелен. Ат, сыер абзарлары, аларга терәтеп салынган келәтләре. Аның янәшәсендә Гатуф абзыйның алачыгы. Гатуф абзый көннәр буе шунда кайнаша. Җилгәргеч, төрле эш кораллары ясап, аларны Борыслан ярминкәсенә илтеп сата. Гатуф абзый кайчакта Фатих белән миңа да күрек тартырга рөхсәт итә. И кызык була да соң шул чакта! Тирә-юньгә дөрләп очкын чәчри, ялкын дөрли. Зур кара күзлек кигән Гатуф абзый кулындагы тимерен ут өстендә әйләндерә-тулгандыра, аннары сандалга салып чүки. Эшләгән чакта ул ләммим бер сүз әйтми. Эшен тәмамлагач, алачык алдындагы эскәмиягә чыгып утыра да тәмәке көйрәтә.

Алтын куллы ул безнең Гатуф абзый. Әнә бит өен, каралты-курасын — һәммәсен үзе төзегән, үзе бизәгән. Кое сиртмәләре генә ни тора! Аны ул челән томшыгы кебек итеп ясаган. Чиләге коега төшкәндә, томшык ачыла, өскә күтәрелгәч, шап итеп ябыла. Кызык та була соң! Өй кыегындагы тавис кошын гына кара син: җил кай якка иссә, шул якка борылып, кукраеп утыра. Бик серле, сихерле шул Гатуф абзыйларның ишегалды. Мал-туарлары алай күп түгел үзләренең. Бер ат, бер сыер, җидеме-сигезме сарык. Берәр оя казлары, үрдәкләре һәм күзнең явын алырлык күркәләре дә бар.

Абзар түбәсеннән аларның ишегалды уч төбендәге кебек күренә. Зөләйха апа аллы-гөлле көянтәсенә шундый ук чиләкләр асып коега суга чыга. Иә баскыч төпләренә хәтле ялт иттереп, идәннәрен юып ала.

Чибәр кыз ул безнең Зөләйха апа. Озын кара чәчләрен толымлап үрә. Иелеп су алганда, каз-үрдәк ашатканда толымнары алга төшә дә чулпылары чыңлап куя. Фатих та, мин дә яратабыз Зөләйха апаны. Яратмаслык та түгел шул ул: урамда очраганда да, өйләренә керсәң дә гел елмаеп каршылый.

---

Роза ХАФИЗОВА *(1929) — прозаик. «Кирлемән», «Тантаналы вәгъдә», «Кашкарыйлар озын гомерле» һ. б. китаплар авторы. РСФСРның атказанган культура хезмәткәре. Казанда яши.*

«Түрдән уз, үскәнем, түрдән уз», — дигән була. Безнең чебиләнеп беткән аяклар белән кая түргә узасың, ди инде. Юл-юл паласлар җәйгән, сап-сары итеп юган идәннәренә безнең алаша аяклардан атлаган саен бер пот тузан коелып кала ич! Шулай да аларга кирәсе килеп кенә тора. Хикмәте бар шул аларга керүләрнең! Түр ягында алагаем зур, биек сәгатьләре бар. Идәннән түшәмгә чаклы күтәрелеп тора. Андыен зур, матур сәгать дөньяда юк һәм булмас та. Тартмасы кызгылт агачтан ясалган, үзе күзгә кебек ялтырап тора. Түбәсенә канатларын җәеп зур каракош кунган. Аның аяк астында бөгәрләнеп аждаһа ята. Каракош үткен тырнакларын аның башына батырган. Ул гынамы, сәгатьнең каракоштан әз генә астарак сап-сары, челтәрле, бәләкәй генә ишеге бар. Шул ишек ачыла да аннан кызыл канатлы сары күке чыгып «кәк-күк», «кәк-күк» дип сәгать ничә икәнен саный. Аннары, бик зур эш кырган кебек башын иеп, эчкә кереп китә. Челтәрле ишеге чыңлап ябыла...

Бу сәгатьне, Зөләйха апа тугач, Гатуф абзый җилгәргеч саткан акчасына ярминкәдән алып кайткан, дип сөйлиләр.

Мин кергәндә Фатих, бик зур эшем кешеседәй, ишегалды уртасына чыгып баскан иде. Өстендә, мин сиңа әйтим, өр-яңа буй-буй күлмәк. Баштарак игътибар итмәгән идем, аягына кара сандаллар кигән. Егылыплар үләрсең! Буржуй кебек корсагын киереп, миңа өстән генә карап тора.

— Ник кәтү каршыларга бармадың? — дигән булам.

Фатих башта, син дә йөрисең дигән кыяфәт белән, чертләтеп төкереп куйды, аннары кулларын чалбар кесәсенә тыгып, эре генә әйтеп салды:

— Эш булды.

Сизеп торам, ул минем нинди эш дип сораганны көтә. Мин юри сорамадым, «һе» дигән булдым да капкага юнәлдем. Фатих моны көтмәгән иде, билгеле, үзе дә сизмәстән: «Әй, әй», — дип кычкырып җибәрде. Мин борылганда аның «буржуйлыгы» беткән, ул элеккеге гап-гади Фатихка әйләнгән иде.

— Әти белән күрше авылга, туганнарга барган идек. Ну, малай, хәлләр булган анда! Тутайнең ире камун. Шулар бөтен кулакларны авылдан сөргәннәр. Шушы көннәрдә безнең авылдан да сөрәчәкләр, ди.

— Безнең авылда кулаклар юк ич. Сибгат бай малайлары әллә кайчан Төркиягә тайганнар, шулар йортында укыйбыз ич инде.

— Беләсең пычагымны! Бай — бай инде ул. Кулагы тагын икенче төрле. Кем колхозга кермәгән, кемнең аты, сыеры, алты почмаклы йорты бар — һәммәсе кулак. Һәммәсен сөрәчәкләр. Мин әйтте диярсең. — Фатих тагын ни әйтергәдер талпынган иде, болдырда әнисе күренде.

— Ләчтит сатып торасыңмыни әле, малай актыгы?! Кәтү кайтканга ни вакыт, кәҗә һаман күренми, тау астындадыр, бар тиз алып кайт! — дип кычкырды.

Фатих сандалларын салып болдырга куйды. Без тиз генә тау астына элдердек. Фатих үзе йөгерә, үзе миннән күбрәк белүенә куана-куана такылдый:

— Иң элек аргы якның корсак Фәтхулланы, аннары сыерчык Зәкәрия белән Гатуф абзыйларны сөрәләр, ди.

— Гатуф абзый кулак түгел ич ул!

— Түгел сиңа. Кемнең өе авылда иң матур? Кемнең күкеле сәгате бар? Районнан план килгән. Безнең авылдан өч кулакны сөрергә дип. Председатель Гыйлаҗ абзыйның әти белән сөйләшкәнен үзем ишеттем. Күрше авылда да колхозга кермәгән ялгыз хуҗалыкларны сөргәннәр.

— Гатуф абзый барыбер кулак түгел, аның колхозга гына керәсе килми.

— План килгәч, аларны калдырып, тиле Зәйнашка бармаслар ич инде. Сезнең белән безне дә сөрмәсләр...

Анысы шулаен да шулай. Безнең кәҗәдән гайре малыбыз юк. Аннары әтиләребез гражданнар сугышында катнашкан. Тиле Зәйнашның кәҗәсе түгел, сукыр тавыгы да юк. Йортлары авыл читендә, яртылаш җиргә сеңгән. Ата ялкау, такылдык бер адәм. Мең дә берне белә, эш кенә сөйми. Үзе кебек үк ялкау малае бар, Гөлдери исемле, безнең белән укый, тыңкыш бер нәрсә шунда. Шулай да соң, Гатуф абыйдан башка ничек яшәрбез? Үзе колхозчы булмаса да, ул колхозның бөтен атларын дагалый, ватыгын, китеген төзәтә. Берәрсенең комганы гына тишелсә дә яматырга Гатуф абзыйларга киләләр. Колхозга кермәвенең дә сәбәбе бар: председатель Гыйлаҗи белән дус түгел алар. «Чабатасын да юньләп кия белмәгән кеше рәис буламыни», — дип сөйләнгәнен үземнең ишеткәнем бар.

— Аларның өе иң матуры, — дип Фатих һаман үзенекен тукый.

Булса ни, аны төннәр буе йокламыйча Гатуф абзый үзе, үз куллары белән ясаган ич! Зөләйха апа да кызганыч. Атасын сөргәч, кызын авылда калдырмаслар бит инде. Сәгатьләрен нишләтерләр икән? Бәлки, үзләре белән алып китәләрдер?

Безнең башта мең төрле сораулар кайнады. Өздереп кенә сорар кешесе дә юк бит әле аның. Берәрсеннән сорый башласаң, кайдан белдең, корткыч сүз сөйлисең, дип хәзер авылдан сөрдерерләр. Ниятебез — Фатихлар кәҗәсен алып менүгә, урамга таю иде. Авыл советы янында кеше өзелми, бер-бер хәбәр ишетелми булмас. Әмма ниятебез барып чыкмады. Фатихның әнисе, коштабак күтәреп, безне урамга чыгып ук каршылады. Әниләргә бер каптыңмы, ычкыну юк инде ул — Фатихка шундук эш табылды. Мин йөгерә-атлый өйгә кайтып киттем һәм безнең капка төбендә Зөләйха апаны очраттым. Әллә җылаган димме, күзләре кызыл, битен яулык чите белән каплаган. Ул бармагы белән ымлап кына мине үз янына чакырды. Хәлемне сораган булды. Аннары, җилкәмнән кочаклап, үзләренең капка төбендә үскән сирень куагы астына алып керде. Битемә кайнар сулышын өреп, ашыгып пышылдады:

— Харис энем, минем сиңа зур үтенечем бар. Менә шушы хатны укытучы Сәхип абзыеңа гына илтеп тапшырчы. Ул хәзер йә мәктәптәдер, йә авыл советындадыр. Кайда булса да таба күр. Кеше-кара сизә күрмәсен, үз кулына тапшыр. Син акыллы малай, сиңа сер сыя, — диде һәм хушбуй исе аңкып торган өчпочмаклы хатны минем кулга тоттырды. — Җавабын да алып кайт, мин көтеп торырмын, — диде.

Мин каушап киттем. Хатны кая куярга белми аптырабрак тордым. Аннары чалбар кесәсенә, кузналар янына тыктым. Югалыр-нитәр дип, мин кузналарны кесәмдә генә йөртәм. Хат кына сыярлык урын бар әле анда.

— Йөгер, үскәнем, тиз бул, — дип ашыктырды Зөләйха апа, җиңелчә генә минем җилкәдән этәрде. Мин аткан уктай томырылып чаптым.

Авыл советының тәрәзәләре караңгы, димәк, Сәхип абый анда юк. Мәктәпкә кагылдым, аның да ишеге бикле. Димәк, фатирындадыр. Ул югары оч Мортазаларда тора. Безне ике ел укытты инде. Кайдандыр читтән килгән. Аны шәһәрдә укыган икән диләр. Кызлар кебек тәүфыйклы, юаш кына бер абый. Шыпырт кына, тавышсыз гына яши. Зөләйха апага ник кирәк булды икән ул?

Мин ишегалдына кергәндә, Сәхип абый терсәкләре белән тезенә таянып болдырда утыра иде. Нидер уйлана ахрысы, мин кергәнне хәтта сизмәде диярлек. Шулай да каушабрак калдым, аннары үзе өйрәткәнчә әдәпле генә итеп сәлам бирдем.

— Зөләйха апа сезгә менә бу хатны тапшырырга кушты...

Сәхип абый башта кып-кызыл булды, урыныннан торып басты. Миңа калса, хат аның бармакларын пешерә кебек иде. Ник шулай каушады икән ул? Мин аның йөзенә текәлдем. Ул үзе хатны укый, үзенең бите бер агарып, бер кызарып куя, иреннәре кыймылдый. Минем аны беркайчан да мондый кыяфәттә күргәнем юк иде.

Сәхип абый хатны укып чыкты да күзен бер ноктага терәп катты. Әллә янында мин барын онытты да инде?! Искәртәсе килеп тамак кырып куйдым.

— Зөләйха апа җавап алып кайтырга да кушты.

Шактый эндәшми торгач, Сәхип абый көчәнеп кенә ике сүз әйтте:

— Җавап булмас...

Мин күзләремне челт-челт йомып аңа текәлдем: ничек инде хатны җавапсыз калдырырга мөмкин, янәсе. Ул янә кабатлады:

— Җавап булмас! — Һәм Зөләйха апаның хатын кире миңа төртте. Үзе, кемнәндер качарга теләгәндәй, ашыгып өйгә кереп китте.

Инде нишләргә, ничек кайтып Зөләйха апа күзенә күренергә? Бәлки, мин үзем аңа ярдәм итә алырмын? Хатта ни язды икән соң ул?

Мин тыкрыкка борылдым. Койма буенда үскән куе кычыткан ышыгында тиз генә хатны укып чыктым.

«Сәхип җаным! Без иртәгә иртүк китәбез. Мәхәббәтебез хакына ярдәм ит. Миңа синең киңәшең кирәк. Бүген кич очрашу урыныбызда көтәрмен сине. З».

Хат кулымны өтә иде. Мин аны тиз генә кесәмә салып куйдым. Ничек Зөләйха апага кайтып күренергә?! Үзем йөгерәм, үземнең башта кесәмдәге кузналар шикелле дөбер-шатыр килеп уйлар сикерешә.

Зөләйха апа мине сирень куагы астында көтеп тора иде. Әллә мескенем

урынымнан да кузгалмаган инде. Мин атылып-бәрелеп килеп туктадым да хатны кире аңа суздым. Дөресен әйтергә көчем җитмәде, күземне дә йоммыйча:

— Сәхип абыйны районга чакыртып алганнар, тиз генә кайтмый икән әле, — дидем.

Зөләйха апа сыгылып төште. Күзләреннән ике бөртек яшь атылып чыкты. Пышылдап кына:

— Насыйп түгелдер инде, — диде. Аннары мине кысып кочаклады да, битләремнән үбеп: — Рәхмәт, Харис энем. Иртәгә без авылдан китәбез инде. Хуш, бәхил булыгыз, — диде һәм яшенә буылып, капкадан кереп югалды.

Шундый кызгандым Зөләйха апаны. Йөрәгемне үтмәс кайчы белән телеп-телеп алдылармыни? Аңа ничек ярдәм итәргә белми гаҗиз булдым. Дөрестән дә аларны иртәгә сөрәчәкләр икән бит. Йөргән егете аны шундый чакта күрергә дә теләми. Нинди кеше була инде бу Сәхип абый дигәнебез?!

Бөтен әчемне корт кимерә. Түзәрлегем калмагач, тиз генә Фатихларга йөгердем дә, койма артына посып, ике тапкыр ачы итеп сызгырдым. Бу безнең телдә: «Чык әле, ашыгыч эш бар», — дигәнне аңлата. Мин аңа тиз генә хәлне сөйләп бирдем. Ул һаман үзенекен тукый:

— Әйттем бит сөрәләр дип, тәки дөрескә чыкты.

— Сөрәләр, сөрәләр... Тапкан бер сүз. — Мин Фатихны үртәп борын тартып куйдым. — Ничек тә Зөләйха апага ярдәм итәсе иде. Бәлки аңа булса да авылда калырга рөхсәт итәрләр. Ник Сәхип абый бүген аны күрергә дә теләмәде икән? Читкә җибәрәсе түгел иде шундый матур кызны...

Фатих, ипиен чәйни-чәйни, күзләрен миңа төбәп озак кына эндәшми торды. Аннары соңгы кабымын кисәк йотып җибәрде дә әйтә салды:

— Үзен дә сөрмәсеннәр дип курыккан ул. Валлаһи, курыккан.

— Алайса, Сәхип абый начар кеше булып чыга түгелме соң?

— Знамо, шулай! Сатлык җан. Мин аның шундый икәнен элек тә белә идем. Теге чакта сәхнәдән шигырь сөйләгәндә, мин синнән яхшырак сөйләдем. Миңа ул «урта» билгесе куйды, сиңа — «бик яхшы»ны. Сатлык булмаса, шулай эшләр идеме соң?

Әй, бу Фатихның теле! Мин ярсып аның якасына ябыштым.

— Сәхип абыйны миңа сатылган дип беләсеңме әллә?! Күрсәтәм мин сиңа хәзер күрмәгәнеңне!

Без әүмәкләшеп сугыша башладык. Бу юлы мин җан ачуы белән сугыштым. Башка чакта көчләр тигез безнең. Әзрәк әүмәкләшәбез дә бетә. Хәзер мин аны җиргә егып салдым да өстенә менеп тукмакларга керештем.

— Менә бусы Зөләйха апа өчен. Бусы үзем өчен, — дия-дия тукмакладым. Фатих башын куллары белән каплап чыелдый:

— Нәстә син, минем ни гаебем бар? Ник Сәхип абый ачуын миннән аласың?

Арыдым, туйдым. Ничектер бушап калдым. Без бердәй чирәмгә аудык. Нишләргә икән? Шулай әүмәкләшүдән генә дөнья үзгәрсә икән? Без никадәр генә баш ватсак та бернинди чара уйлап чыгара алмадык.

— Әйдә, барып тәрәзәсен ватыйк шул куркак җанның!

— И җүләр, аның үз йорты түгел ич ул. Кәҗә Мортазаныкы. «Кәҗә» сине ә дигәнче эттәхияткә утыртыр. Сәхип абый кебек мәми авыз түгел ул.

Бәлки әле бер-бер чарасын да тапкан булыр идек. Әни бүлдерде. Әзли чыккан, кулында чыбык.

— Тиз бул, аш суына. Атаң җаныңны ала синең болай үзиркен йөргән өчен, — дип битәрли-битәрли, өйгә алып кереп китте.

Җәйләрен мин болдырда, ачык һавада йоклыйм. Рәхәт ул җәен тышта йоклау. Бүген кисәк кенә уянып киттем. Күрәм: әти киез эшләпәсен батырып кигән дә ишегалды себерә. Эшләпәсен батырып кидеме — ачулы дигән сүз. Кыңгыр салса, эш башка. Ул чагында аның янына барып, бераз тел чарларга, мутланырга була. Тукта, ник болай иртә уяндым соң әле мин? Урам якта шаулашкан тавышлар да ишетелә түгелме? Ә, бүген Зөләйха апалар авылдан китәргә тиеш бит әле.

Урынымнан сикереп торган шәпкә урамга атылдым. Чыксам ни күрим: урам тулы кеше! Олысы, кечесе — һәммәсе Зөләйха апалар капка төбенә җыелган. Мин тиз генә аларның ишегалдына ыргылдым. Бөтен абзар-куралары, хәтта Гатуф абзыйның остаханәсенә тикле шыр ачык. Ишегалларында күркә түгел, сукыр тавык та юк. Пәрдәләрен салдырган тәрәзәләр шәрәләнеп калган. Мин, хуҗаларның кайсын да булса күрергә теләп, ары сугылдым,

бире сугылдым. Беркем юк. Димәк, алар төнлә, мин йоклаган арада китеп өлгергәннәр. Их, бу йокы дигәнең! Саубуллашмый да калдым бит. Мин атылып-бәрелеп аларның өенә барып кердем һәм шаккаттым: авыл советы председателе Миңнулла, сыйрак Сәмигулла һәм биленә наган таккан милиционер күкеле сәгатьне урыныннан кузгатып маташалар. Алар тирәсендә тиле Зәйнулла ярдәм иткән булып өтәләнеп йөри.

Шулчак Фатих килеп җилкәмә кагылды һәм колагыма гына пышылдап:

— Гатуф абзыйлар сөргәнне көтмәгәннәр, төнлә үзләре төянеп киткәннәр, — диде. — Гатуф абзый элек эшләгән җиренә Себергә киткәндер, диләр. Әтиләр аларны озатышканнар. Мескен Зөләйха апа авылдан чыкканчы җылый-җылый артына әйләнеп карап барган. «Сәхибе килеп алып калыр, дип өметләнгәндер, күзгә туйлары буласы иде», — ди әни.

Зөләйха апаны кызганып күземә яшьләр килде. Шулчак сәгатьне урыс табуты кебек итеп идәнгә сузып салдылар. Тиле Зәйнаш алар тирәсендә тыпырдап кына йөри. Сәгатьнең пыяласын, рамнарын сыпыргалап куя. Гөлдериен генә кара әле син, кургашын кузна откан мыни, күркә кебек кукраеп кына йөри. Фатих түзмәде, шыпырт кына барып аның аркасына төртте. «Бик кукрайма, янәсе, әллә кем түгелсең!»

Сәгатьне көч-хәл белән өйдән алып чыгып, кабыргалары тырпаеп торган колхоз атының җигүле арбасына салдылар. Аннары сыйрак Сәмигулла нотык тотты:

— Җәмәгать, — диде ул тамагын кыргалап, — без менә шулай кулаклардан, байлардан тартып алынган байлыкны ярлыларга бирәбез. Гатуф кулакның мал-туарын да колхоз фермасына илтеп яптык. Бу — ярлы халыкны изеп җыйган байлык. Алар өлеше. Менә сәгатьне Хисамов Зәйнашка бирергә булдык. Ул авылда иң ярлы кеше.

— Иң ялкавы да шул, — дип кычкырды усаллыгы белән дан алган Хәкимә әби. Ул таратып бәйләгән ак яулык өстеннән кама бүрек киеп куйган, бөкресе өстеннән мамык шәл ябынган. Үзе таякка таянган.

Карчык, аллага тапшырдык, дигән кебек, тәвәккәл адымнар белән алгарак чыкты һәм таягы белән сыйрак Сәмигуллага селтәнеп, төкрек чәчә-чәчә сүзгә керешге:

— Соң, Гатуф наный кулак булгач, кемгә көн кала?! Аны сөргәнче башта моннан ары атыңны кем дагалыйсын, самавырың тишелсә кемнән яматасын уйлар идең, хәсис! Картлар белән киңәшер идең!? Рәзе Гатуфҗанны авылдан сөрергә ярый? Башыгызга тавык мие кунган нәрсәләр!

Хәкимә әбигә кушылып, башка хатын-кызлар да шаулаша башладылар.

Сәмигулланың тотлыгып калуын күргән милиционер наганына тотынып кычкырып җибәрде:

— Разговорчики!

Ул шундый каты итеп кычкырды ки, бөтен кеше дерт итеп китте. Хәкимә әби: «Ләхәүлә вә ләкуәтә», — дия-дия лып итеп артына утырды.

Безнең өчен дөньяда иң затлы-зиннәтле, эче тулы серле әкият булган сәгатьтән аерылу авыр иде. Бөтен бала-чага йөгерә-атлый арба артыннан ияредек. Шартлар дәрәҗәгә җитеп кукрайган Гөлдери берүзе утырып бара, җитмәсә, күрдегезме абзагызны дигән кебек, безгә карап-карап ала.

Бара торгач, Зәйнашләр ихатасына килеп җиттек. Ихата димәсәң хәтере калыр. Күгәненнән ычкынган җилкапкалар бер якка каерылып, асылынып төшкән. Читәннәре ауган. Өйләре тәмам җиргә сеңгән. Кыскасы, юнь-ябалә юк бу йортта.

Гөлдериненең кыланмышы үзенә күрә генә түгел: атны өйләренең ишегә төбенә үк китереп туктатты. Бай сәүдәдән кайткан диярсең. Ул арада, күкәй салган тавык кебек кытаклап, өйдән аналары килеп чыкты. Өсте-башы каткан. Яулык астыннан чәчләре бүселеп чыккан. Тиле Зәйнаш, улы, хатыны — өчәүләп сәгатьне урыныннан кузгатырга маташып карадылар. Әмма сәгать авыр иде, кузгата алмадылар. Шунда тиле Зәйнаш безгә кычкырды:

— Әй, малайлар, яле тотыгыз бер башыннан. Төшерә күрмәгез, бик затлы мал!

Тырыша торгач, сәгатьне көч-хәл белән өйләренә сөйрәп керттек. Өй эчләре дә тавык кетәге кебек бәләкәй генә икән.

Ярый, хуш, сәгатьне дә керттек, ди. Тиле Зәйнаш аны идәнгә бастырып стена буена куярга маташып карады. Кая инде ул, якын да килми.

— Алай икән, — дип сузды хуҗа, — безнең өй тәбәнәгрәк икән моңа. Башындагы келтериен алып куярга туры килер.

Балта белән шактый маташкач, Зәйнаш сәгать түбәсендәге кош белән елан сурәтен кыеп төшерде.

Тиленеке тилечә дип, безнең әби белеп әйтә икән. Кошын кыеп төшергәч тә сәгать өйгә сыймады. Аңа карап кына Зәйнаш кулга кергән малыннан баш тартамы соң! Ул, үзе кебек үк искереп шомарган кәләпүшен кулына алып, озак кына уйлангандай итеп торды. Аннары:

— Болай сыйдырып булмас моны, түбән башын бераз кисәргә кирәк булыр, — диде.

Сәгатьне кире ишегалдына алып чыгып, кузлага куйдык. Пычкының бер башын атасы, икенчесен малае тотты. Пычкы тешләре башта сәгатьнең тәненә керми интектерде: сикерә дә чыга, сикерә дә чыга.

— Һай, каһәр, — дип тагын сукранды Зәйнаш. Эшләми эшләгәнгәдер, ул шабыр тиргә батты. Ниһаять, пычкы тешләре эз алды. Шул мәлдә сәгать чын-чынлап сыкрап куйды. Валлаһи менә! Аның ыңгырашканын мин генә түгел, башкалар да ишетте. Хәтта тиле Зәйнаш үзе дә эшеннән туктап, тыңлап торды. Сәгатьнең җаны бар һәм утын пычкысы белән кискәндә аның тәне авырта иде.

Ниһаять, сәгатьнең бер өлешен кисеп төшерделәр. Зәйнаш киселгән өлешен як-ягына балта белән суккалап, такталарын каерып ташлады. Үзе:

— Кадаксыз эшләнгән, каһәр, бу такталары да бер-бер гамәлгә ярар, — дип сөйләнде. Төбен сәгатькә кире беркетергә булды. Өенә кереп, юан кадак алып чыкты. Тактаны сәгать астына көйләп куйды да чүкеч белән аңа кадак кагарга кереште. Сәгать дерелдәп, чыңлап-чыңлап китә. Маятнигы сап-сары бәләкәй кояш кебек ялтырап хәрәкәтсез ята. Әйтерсең, бездән ярдәм көтә.

— Булды бу, хәзер өйгә кертсәң дә була, — диде Зәйнаш. Ул эшеннән бик канәгать иде.

Без сәгатьне күтәреп, тагын өйгә керттек. Тиле Зәйнаш аны бер ягы белән сәкегә терәтеп, идәнгә бастырды. Чылбырыннан тотып герләрен күтәрде, маятнигын җибәрде. Әмма маятнигы бер-ике тапкыр гына тирбәнде дә хәрәкәтсез калды. Зәйнаш аны тагын җибәрде, тагын, тагын... Әмма маятник хәрәкәтсез иде. Сәгать тиле Зәйнаш йортында йөреп китәргә теләмәде...

Башларны аска иеп, үзебезне никтер гаепле санап өйгә кайтып киттек.

Кичен йокларга яткач, авыл яшьләренең гармун уйнап, җырлап узуларын ишеттем:

Гафур оста йортын бизи,
Челтәрдер кашагасы.
Кулак диеп гаеплиләр,
Килмидер ышанасы.
    Зөләйханың сәгать чылбыры,
    үзәкләрне өзә бер җыры.

Мөгаллимнең йөрәгенә
Бака оялагандыр,
Зөләйхадан качып калган,
Ничек оялмагандыр.
    Зөләйханың сәгать чылбыры,
    үзәкләрне өзә бер җыры.

Бер-ике көннән Сәхип абый авылдан юкка чыкты. Кайберәүләр аны Зөләйхага биргән вәгъдәсен бозганы өчен вөҗданы газаплый икән, халыктан ояла, шуңа авылны ташлап киткән, диделәр. Икенчеләре, ул үзе дә мулла малае икән, шуны белгәч, кулга алганнар, дип тәкърарладылар.Кайсы дөрестер, безнең өчен аның әһәмияте юк иде инде. Әти бөтенесенә йомгак ясап әйтеп куйды:

— Андый ышанычсыз кешенең китүе хәерле.

Сиздермичә генә сентябрь килеп җитте. Укулар башланды. Уку, мәктәп, уеннар белән мавыгып, күкеле сәгать, Зөләйха апа, аларга багышланган җыр-бәетләр онытыла башлаган иде инде. Шулай да октябрь башларында безне тагын бик нык дулкынландырган бер вакыйгага булып алды.

Көннәрнең берендә Тыңкыш Гөлдери мәктәпкә озын сәгать чылбыры алып килде. Тәнәфес вакытында аны кесәсеннән чыгарып, Фатих белән икебезгә күрсәтте. Без өнсез калдык: Зөләйха апаның сәгать чылбыры ич бу! Теге, егетләр җырлаган чылбыр!

Зөләйханың сәгать чылбыры,
үзәкләрне өзә бер җыры!

Тыңкыш аны тырнак асларына кап-кара балчык тулган, атна буе юмаган пычрак кулларында уйнаткалап тора. Бүрәнәгә утырып, ашыкмый гына тәмәке көйрәтүче Гатуф абзый, чулпыларын чыңлатып коедан су алучы Зөләйха апа, аларның өйләрендә, безне куандырып, сәгать саен моңлы итеп кычкыручы күке күз алдымнан узды. Йөрәгем кысылды, тыным бетте. Тыңкыш исә һаман мактаныпмы мактана:

— Мин әле аның күкесен дә каерып алган идем, инәй аны тутакайның җылак кызына биреп җибәрде.

— Сәгатен нишләттегез?

— Аның ише йөрми торган сәгатьне нишләтәсең ди. Әтәй Карамалка урысына ярты пот бодайга алмашты.

Мин сәгатьнең тәненә пычкы кисеп кергәндәге сыкрау авазын кабат ишеткәндәй булдым. Башым әйләнеп китте. Йодрыкларым үзләреннән-үзләре йомарланды. Күрәм, Фатихның да төсе качкан. Бик каты ачуы килгәндә шулай була ул. Үзе илтифатсыз гына булырга тырышып, Тыңкышка эндәшә:

— Чылбырын да алмашмыйбызмы соң?

Фатихның юри, аны мыскыл итеп сораганын Тыңкыш хәтта сизмәде дә, күзләре үк очкынланды:

— Нәрсәгә?

Фатих бераз уйланып торгандай итте һәм, кинәт борылып, Тыңкышның борын төбенә йодрык төртте:

— Менә моңа!

Тыңкыш, кинәт аңына килеп, мәктәпкә таба йөгерде. Мин аны бер сикерүгә куып җитеп, егып салдым:

— Монысы — күкеле сәгатьне ватканыгыз өчен... кеше малына хуҗа булганыгыз өчен, Зөләйха апа өчен... менә монысы — сәгать чылбыры өчен...

Фатих катышмады, карап кына торды. Безнең авылда бер малайга каршы ике малай сугышу юк.

Гөлдери: «Әтигә әйтәм, әтигә әйтәм», — дия-дия тарткалашты. Үзе чылбырны мәңге каерып алмаслык итеп кулына чорнаган. Талыйлар дип уйлый ахры. Ник кирәге бар безгә ул чылбырның? Безгә гаделлек кенә булсын!

...Кичен безгә укытучы Кәрим абый килде. Фатихның әтисе дә керде. Алар өчәүләп түр якта ни турындадыр озаклап сөйләштеләр. Хәерлегә түгел инде бу. Укытучы безнең Тыңкышны кыйнаганны әйтергә килгәндер.

Мин, ничек тә әнинең күңелен күрергә теләп, алгы якта кайнашам. Йә чыбык-чабык җыеп керткәндәй булам, йә (гомер булмаганны) идәнне себергәндәй итәм. Тиз генә кәҗәгә печән дә салып кердем. Әти чыгып арт санны укыта башласа, әнкәй шундый игелекле улын якламый калмас!

Бераздан әти кунакларны озата чыкты. Йөзе болай тыныч, алай шомлы нәрсә сизелми. Әчкә бераз җылы йөгерде.

Әти өйгә әйләнеп кергәч тә иңемнән кочаклап, мине сәке кырыена утыртты, авыр кулын җилкәмә салды.

— Ник Зәйнаш малаен кыйнадыгыз? — дип, туп-туры сорады.

— Зөләйха апаларның сәгать чылбырын күтәреп йөрмәсен иканче.

— Шул бер чылбыр өчен сабакташыгызны кыйнадыгызмы?

— Чылбыр өчен генә түгел. Ник Гатуф абзыйларны авылдан сөрделәр? Ник аларның күкеле сәгатен тиле Зәйнашләргә бирделәр? Ник? Гатуф абзый кулак түгел ич ул!

Болар соңгы вакытта җавап таба алмый интектергән сорауларым иде. Аларны бер-бер артлы әтигә тездем. Әти минем җилкәмнән сыйпагандай итте:

— Дөресен әйтәсең, улым, Гатуф абзый кулак түгел, үз кул көче белән көн итүче кеше иде. Борчылма, кайда да югала торганнардан түгел ул Гатуф абзыең. Дөньялар үзгәрми булмас. Гаделлек өскә чыгар. Күреп торырсың, Гатуф абзыең монысыннан да шәбрәк күкеле сәгать алып кайтыр әле менә. Зәйнаш мал кадерен белә торган кеше түгел ул. Шулай да малаена тимә син аның. Сугышып йөрү егетлек түгел.

Әти артык бер сүз дә әйтмәде. Мин ничектер тынычланып калдым. Әтинең салмак тавышы, җилкәмә салган көчле кулы, мине үзенә тиң итеп, салмак сөйләшүе киләчәккә ышаныч, өмет бөлып күңелемә ятты.

## Фәнис Яруллин

# ИСКЕ ЙОРТ ИСТӘЛЕГЕ

ХИКӘЯ



Иске өйне пыр туздырып сүтеп ятканда Назыймның малайлары чормадан бер пар күн итек табып алды. Аның табаны кубып, авызын ачкан чуртан тешләре кебек кадаклары күренеп тора, кунычы саргая башлаган, шулай да бөрешеп катмаган, чөнки кунычка ниндидер кәгазьләр тутырып куелган иде.

— Менә хәзинә таптым, — диде Рәсим, абыйларын кызыктырып.

— Кая әле, кая? — Малайлар итекне тарткалый башладылар.

— Моның эчендә акча! — диде Һәнүз, күн итек кунычына шапылдатып сугып.

Малайлар итек эчендәге кәгазьләрне тартып чыгардылар. Анда төрле еллардагы налог кәгазьләре, иске заемнар һәм тагын малайларның ишеткәне дә булмаган ниндидер квитанцияләр иде. Кәгазьләр арасында актарынган арада болар янына этиләре килеп җитте. Ул уллары кулыннан күн итекне алып бүрәнә өстенә барып утырды.

— Күрче! — диде ул авыз эченнән сөйләнеп. — Бу да картайган. — Назыйм кулындагы күн итекне әйләндереп-әйләндереп карарга тотынды, әйтерсең, ул аннан үзенә генә таныш булган ниндидер билгеләр эзли иде.

— Нәрсә, эти, әллә югалткан байлыгыңны таптыңмы? — дип көлеште малайлар.

— Ә сез авыз ерырга ашыкмагыз, — диде этиләре ачуланып. — Беләсегез килсә, заманында ул безнең өчен бөтен байлыклардан да кадерлерәк иде. Һәм Назыйм болай дип сөйләп китте:

— Этидән, ягъни сезнең бабагыздан калган итек бу. Эти аны сугышка китәр алдыннан гына тектергән булган. Ләкин бер мәртәбә дә киеп карарга өлгермәгән. — Назыйм бермәл сүзсез торды. Сез барыбер берни аңламассыз дигәндәй, улларына карап куйды, малайларының үзенә текәлгән җитди карашларын күргәч, бераз тынычланып сүзен дәвам итте: — Әйе, замананың бик-бик авыр чагына туры килде безнең балачак. Кайсы гына өйгә кермә, авызын ачып түр башында ачлык утыра. Әниләр безнең өскә кияргә кием, аякка чабата җиткерә алмый интегәләр иде. Ач булсак та безнең уйныйсыбыз, урамга чыгасыбыз килә. Ә киеп чыгарга әйбер юк, бигрәк тә аякка юклык нык сиздерә. Өлкәннәргә җайлырак, алар чабата кия. Ә безнең ише вак-төяккә ярарлык чабатаны ни өчендер базарда бик сирәк саталар иде. Ә бәлки сатсалар да, әнинең акчасы җитмәгәнлектән, сезгә яраклысы юк иде, дип алмый кайткандыр. Кыш көне әле иске киез итекне төпләштереп-ямаштырып булса да киясең, әмма ләкин язгы пычракларда эш мөшкелләнә.

---

*Фәнис ЯРУЛЛИН (1938) — шагыйрь, прозаик. «Җилкәннәр җилдә сынала», «Танышлар арасында», «Табыну» һ. б. китаплар авторы. ТАССРның атказанган культура работнигы. Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Яланаяк чыгарга салкын, киез итеккә су үтә. Менә шундый чакларда абый белән мин әнигә ялынырга тотынабыз:

— Әни, әтинең күн итеген киеп урамга чыгыйк әле.

— Сез нәрсә уйлап таптыгыз тагын, — ди әни әле абыйга, әле миңа карап. — Әтиегез итеген кияргә иртәрәк әле сезгә. Аннары ул юештә кия торган итек түгел, менә карагыз: аның бит табаны күн, су тидеме — җеби.

Әни итекне безгә күрсәтә. Без аны бүген генә күргәндәй гаҗәпләнеп караган булабыз. Шунда абый болай дип әйтеп куя:

— Ә мин аның белән пычракка кермәм, әни.

Бу сүзләрнең абыйдан алданрак минем башка килмәвенә үртәлеп нишләргә белмим. Әй кызык та булыр иде соң шушы күн итекне киеп урамга чыксаң! Аякларына кутәртмәле чабатадан башканы киеп карамаган малайларның күзе ут янар иде. Бәлки, әни күрмәгәндә генә берәр тапкыр суга да кереп чыгар идең. Бер тапкыр суга кергәннән генә табаны җебемәс иде әле. Кунычы да ике катлы: тышкы ягы калынрак, эче кәгазь кебек юка күннән тегелгән аның.

— Әни, — дим мин шулвакыт башыма искиткеч акыллы уй килүгә сөенеп, — моңардан ике пар итек тектереп булыр иде микән?

Минем соравымнан әни бер мәлгә югалып кала. Аннары һушына килеп болай ди:

— Сезгә күн итек тектерсәк, апаларыгыз ни сорамас? Алар инә җиткән кыз булып киләләр.

— Әйе шул, әни, — дим. — Бу күн итекне боздырмыйк, әти төсе итеп саклыйк.

Бу сүзләргә күңеле булып, әни минем баштан сыйпап куя.

— Шулай, улым, — ди ул. — Әтиегезнең төсе булып бердәнбер шушы күн итек кенә калды инде. Сакларга кирәк аны.

Үзе сакларга кирәк дисә дә, кайвакыт әни ялыну-ялваруларыбызга каршы тора алмый, итекне киеп урамга чыгарга рөхсәт итә. Абый белән без аны алмаш-тилмәш киеп урамга чыгабыз. Әни һәр икебез артыннан:

— Кара аны, ишетсен колагың, пычракка кермә, — дип кала.

Күн итек, билгеле, безгә бик олы. Бигрәк тә миңа ул бот төбеннән үк тора. Тез турысыннан бөгәрләнеп каткан һәм салып куйсаң миннән башка да басып тора ала торган киндер ыштанның балакларын кунычка тыгып итекне киеп куям да урамга чыгам. Әлбәттә, анда чыккач пычракка керми түзүе бик авыр. Малайлар алдында урамның иң тирән пычрагына кереп мактанасы килә. Мине күрүгә малайлар:

— Ыштансыз комиссар чыккан! — дип үртәргә тотыналар, ләкин мин аңа үртәлмим, чөнки беләм: бу сүзне малайлар көнләшүдән генә әйтәләр. Мин аларны тагын да ныграк кызыктыру өчен үзебезнең таш койма өстенә менеп басам. Таш койма бик киң, иркен, өстендә рәхәтләнеп йөрерлек.

Минем койма башына менеп күн итегемне пычратмый утыруым малайларга бер дә ошамый, алар өр-яңадан мине үртәргә тотыналар.

— Ыштансыз комиссарның күн итеге тишек, — дип башлый берәр хәйләкәре.

— Кәнишне, — ди икенчесе, — тишек булмаса суга керер иде.

— Ә мин менә чабата белән дә рәхәтләнеп теләсә кайда йөрим, — ди өченчесе һәм тиздән пычрак ерып баткаклыкка кереп китә. — Минем чабатага үтми, аяк кына чылана, — ди ул үзенә сокланып караган иптәшләренә. Малайларның бу сүзләреннән минем йөрәк атылып чыгардай булып тибә. Бик-бик күрсәтәсем килә күн итегемнең тишек түгеллеген, әмма ярамый. Чынлап та табаны җебеп төшсә, нишләрсең.

Мине болай гына урынымнан кубара алмагач, ничек тә катырак чеметергә теләп, арадан берсе такмак әйтә башлый:

Назыйм менгән киртәгә,
«Кикерикүк» итәргә.
Итегеңне турыйк әле
Чабатаны төпләргә.

Мин такмакларга бирешмим, нык торам. Ләкин кай көнне таш койма башында әтәч кебек кукраеп утыру туйдыра һәм мин, кемлегемне күрсәтер өчен, урам пычрагын аркылы-торкылы ерып чыкмый түзә алмыйм. Андый көнне мин инде герой: бөтен малай минем тирәгә җыела. «Тегендәрәк кер, тегендәрәк», — дип чокырның тирәнрәк җирен күрсәтәләр. Пычрак ерып

чыккач, берәр капка төбендәге эскәмиягә менеп итекләрне салам да дусларыма аякларымны күрсәтәм: «Менә карагыз, коп-коры!»

Малайлар ялан тәпиләремне тотып-тотып карыйлар, чыланмаганлыгына ышаналар. Кайберсе: «Кая, Назыйм, мин дә киеп карыйм әле?» — дип күзен мөлдерәтеп минем итекләргә карый. Бигрәк тә Низам аларга нык кызыга. Чөнки ул, кем әйтмешли, җилдән туган малай. Аның күн итеге түгел, чабатасы да булганы юк. Низамны мин чын күңелемнән җәллим, әмма итекләр тагы да җәлрәк.

Шулай да бер көнне мин йомшап китеп аңа итегемне биреп тордым. Ул аларны киеп капка төбендә озак кына басып торды да елап җибәрде. «Нәрсә булды, нигә елыйсың?» — дисәм дә җавап бирмәде. Мин һични аңламадым, хәер, озаклап ул турыда уйланып торырга вакыт та булмады, чөнки бүтән малайлар безнең тирәгә җыелып өлгерделәр. Һәрберсе: «Миңа да биреп тор», — дип итекне тарткалый башлады. Мин бирсәм дә бирдем, бирмәсәм дә бирдем. Малайларга минем итек җәл түгел иде, мондый затлы нәрсә кулга төшкәндә мөмкин кадәр ныграк файдаланып калырга тырыштылар. Итекләр пычрак суда үрдәк кебек йөзделәр. Шулвакыт әллә каян гына абый килеп чыкты да бу эшем өчен күземнән очкыннар чәчрәгәнче яңаклап ыргытты. Ә өйгә кайткач итекләрне бик әйбәтләп юдыртты. Крем ише нәрсә юк иде, абый аларны көнбагыш мае белән майлап куйды.

— Әгәр тагын аларга кагылганыңны күрсәм, җаныңны алачакмын, — диде ул.

Җанымны бер түгел, ике алсалар да мин аларга кагылмый түзә алмаган булыр идем, әлбәттә, тик безнең тормышта бер үзгәреш булып алды.

Сугыш беткән ел иде.

Беркөнне безгә көтүче Әхмәдулла абый килеп керде. Ул аксак булганга сугышка бармый калган. Яше белән егерме бишләрне узып китүгә карамастан, йөзе аның япь-яшь, чыраенда ярылып яткан балалык бар. Кызларга ул әллә ничек оялып карый. Теләсә нинди ялган сүзгә дә ышана. Без аның мондый гадәтен белгәнгә күрә еш кына алдалап торабыз.

— Әхмәдулла абый, — дибез, — бүген Минҗамалттәйнең кәҗәсе бәкәйләгән икән.

— Әйе шул, — ди Әхмәдулла абый, — ике бәкәй китерде. Бәкәйләрен үзем күтәреп апкайттым.

— Ул икене түгел, өчне бәкәйләгән булган бит, — дибез.

— Ничек өчне? — ди Әхмәдулла абый. — Берсе кая соң алайса?

— Берсе шунда көтү йөргән җирдә, Рәхмәй чокырында калган. Маһирәттәй күреп кайткан...

Әхмәдулла абзый безнең сүзгә ышанып бетә. Йөзләре кызарып чыга. «Алайса тизрәк барып алырга кирәк аны», — дип аксаклап көндез көтү көткән җиренә чаба башлый. Безгә аның бер аягы белән түмгәккә, икенче аягы белән чокырга баскан кебек аумак-тәүмәк йөгерүе кызык. Көлә-көлә артыннан иярәбез. Үзебезнең шушы мәзәгебез белән көне буе йөгереп арыган кешене газапка салуыбыз турында уйлап та карамыйбыз.

Менә шушы юаш, мөлаем Әхмәдулла абыйның безгә килүе, бигрәк тә өстенә яңа кәчтүм киеп керүе ничектер сәер тоелды.

— Газимә җиңги, — диде ул әнинең йөзенә туры карарга тартынып, — бик зур йомыш белән кергәнием сезгә.

— Әйтеп кара, — диде әни, — яхшы кешегә кулдан килгәнне эшләргә тырышабыз.

— Ни бит, Газимә җиңги, сезгә бәлки көлкерәк тә тоелыр. Ни бит... Мин өйләнергә уйлаганыем, Газимә җиңги.

— Ниятең бик изге, Әхмәдулла, — диде әни, көтүче абыйны дәртләндерергә теләгәндәй. — Әгәр тегенди-мондый эш эшләтәсең булса, тартынып торма. Эшләшергә керермен, аш-суын да әзерләшермен.

— Анысы өчен рәхмәт, Газимә җиңги. Мин әлегә алары турында уйламаганыем. Мин теге көн итегегезне сатмассызмы диеп кергәнием...

Әни әллә нишләп китте. Йөзенә күләгә йөгерде. Минем дә йөрәк үрлекырлы сикерергә тотынды. Әхмәдулла абый кулындагы кепкасына карап әнидән җавап көтә. Өйдә авыр тынлык урнашты. Һәркемнең сулаганына кадәр ишетелеп тора башлады.

Бераздан әни, кискен карарга килеп, кулындагы бәйләмен бер читкә атты да болай диде:

— Юк, Әхмәдулла энем. Монысы булмас. Әтиләренең төсе бит ул. —

Әни миңа таба борылып карады. Аның күзләрендә әллә яшь, әллә ачу ялтырый иде.

— Соң юк икән — юк инде, — диде Әхмәдулла абый авыр гына. — Бигайбә, Газимә җиңги. Аксаклыгыма риза булган кеше чабатама да риза булыр.

Әхмәдулла әллә ничек, башка вакыттагыдан да катырак аксаклап ишеккә таба юнәлде.

— Туктале, — диде әни, — син үпкәләмә, Әхмәдулла энем. Бик тә кадерле нәрсә бит ул безнең өчен.

— Аңлыйм, Газимә җиңги. Үпкәләмим дә. Минем бер нәрсәгә дә үпкәләгәнем юк. Чөнки мине туу белән үк язмыш үпкәләткән инде. Ул үпкәм янында бүтәннәре чүп кенә.

Әхмәдулла абый чыгып китте. Без әни белән, ниндидер яман эш кылган кешеләрдәй, бер-беребезгә карарга кыенсынып утырдык.

— Әллә ничек җайсызрак килеп чыкты, — диде әни бераздан. — Бәлки, сатарга кирәк булгандыр. Әхмәдулла саран кеше түгел, бәясеннән тормас иде. Онfamыз да бер-ике умачлык кына калып бара. Ә аңарда он бар да бар инде.

Әни әллә үзен, әллә мине ышандырырга теләгәндәй озак кына сөйләнде. Мин нәрсә әйтергә дә белмәдем. Итекне һич кенә дә саттырасы килми иде. Шул ук вакытта әнинең «ә аңарда он бар да бар инде» дигән сүзләре хыялымны уйнатып җибәрде. Күз алдыма яңа гына мичтән чыккан кайнар ипиләр килде. Менә аларны әни мичтән алып сәкегә тезгән дә өстен ашъяулык белән каплап куйган. Ашыйсыбыз килде дигән саен әни хуш ис бөркеп торган ипиләрне олы итеп сындырып ала да эченә яңа гына язылган ак май салып безгә бирә. Берничә минуттан май тәмам эреп ипигә сеңә. Без аны күз ачып йомганчы ялтыратып куябыз.

Шушы күренеш минем хыялымны бөтенләе белән биләп алды, хәтта борыныма яңа пешкән ипи исе килеп кергәндәй булды, авызымнан сулар килде. Мин кычкырып елап җибәрмәс өчен ач корсагымны уа-уа урамга чыгып йөгердем.

Күн итек турында сүз яңадан кузгалмас дип уйлаган идем, кич белән бөтенебез бергә җыелгач, әни читләтеп-читләтеп тагын моңа әйләнеп кайтты.

— Сәфәргали абзыйларны чакырып бер кунак итәсе иде. Былтыр да, орлыклык бәрәңгебез беткәч, алар гына коткарып калды. Ә өченче ел... Әгәр алар печән биреп тормаган булса, сыерсыз кала идек бит.

Сәфәргали абзый — безнең әнинең олы абзыйсы. Юмарт куллы, әйбәт кеше. Бездән ун-унике чакрым ераклыктагы Дим авылында яши. Аларның колхозы баеракмы, өйдә ир-ат булгач башка берәр җае бармы — заманы өчен әйбәт кенә яшиләр, ипидән өзелмиләр. Карчыгы белән безгә кунакка килсәләр дә буш кул белән килмиләр. Шуңа күрә без барыбез да ул абзыкайны да, җиңгәчәйне дә бик яратабыз, килүләрен көтеп алабыз. Әни безнең уйларыбызны сизгәндәй:

— Кунак алдына коры кашык куеп булмый, ә безнең күзгә кырып салырлык та онытыз калмады, — диде. — Әллә, мин әйтәм, эткәгезнең күн итеген сатыйк микән соң?

Без шаулашырга тотындык. Кызлар сату ягында иде. Дөресен әйткәндә, без дә артык каршылык күрсәтмәдек. Бик тә туйганчы бер ипи ашап карыйсыбыз килә иде.

Шулай итеп, без Әхмәдулла абыйга күн итекне бер пот он һәм ике капчык бәрәңгегә сатып җибәрдек. Итекне көтүче абыйның кулына тоттырганда, никадәр тыярга тырышсам да, минем күзләрдән яшьләр тәгәрәп төште. Минем халәтне күреп, Әхмәдулла абыйның үзенең дә күңеле йомшады, минем баштан сыйпап ул ниндидер юату сүзләре әйтте, аннары әнигә карап:

— Быел малларыгызны көтүдә йөрткән өчен мин сездән түләү алмам, — диде. — Ярый, миңа рәнҗемәгез инде.

Әхмәдулла абый хатынны күрше авылдан алып кайтты. Безнең авылның иң чибәр кызы Маһруй ападан бер дә ким түгел иде ул. Чәчләре ике толым итеп үрелгән, толымнары билдән түбән төшеп тора. Өстендә матур зәңгәр күлмәк. Хәер, боларын әле без бераз соңрак күрдек. Килен төшү вакыйгасына әз генә булса да тукталып китмәсәм, хикәям тулы булмас кебек. Әлбәттә инде, килен төшкән өйнең капкасын ачу безнең ише малайлар эше. Мондый бәхетне беребезнең дә кулдан ычкындырасы килмәде. «Мин ачам да мин ачам», — дип бер-беребез белән бәхәскә кердек. Чөнки капка ачкан ке-

шегә яшь кәләштән бирәр бүләк эләгә. Ул — йә чикккән кулъяулык, йә бәрхет түбәтәй була. Ничек инде шундый хәзинәне кулдан ычкындырасың килсен!

Әйе, каты бәхәсләштек без ул көнне. Тамаклар карлыкты, баш очыбызда йодрыклар да уйнашып алды. Болай да бәхәсне чишә алмагач, Мәүли исемле нык буынлы малай: «Әйдәгез көрәшәбез, кем җиңә — капканы шул ача», — диде. Мәүлинең тәкъдимен көчлерәк малайлар дәррәү күтәреп алдылар, безнең эше җеп беләкле, шулпа корсакларга гына бу ошап җитмәде. Ләкин нишлисең — риза булдык, арт урамдагы чирәмгә чыгып көрәшә башладык. Нык тырыштык без ул көнне, хәтта сабан туйларында да бу кадәр көчәнгәнебез булмагандыр. Көрәшә торгач кайсыбызның җиңе өзелеп чыкты, кайсыбызның чалбар төбе умырылды. Кара буразна сызып биттән тирләр акты. Тишек чалбар аша ялтырап күренгән тез башлары сыдырылып, канап бетте. Батыр булып тәки Мәүли калды. Капка ачу бәхете кулдан ычкынса да борыннарыбызны салындырып кайтып китәргә ашыкмадык, һәммәбез сүз куешкандай, килен төшәсе өй янына җыелдык.

Менә бер мәлне идарәнең кара айгыры җигелгән тарантас капка төбенә килеп җитте. Мәүли капканы ачып җибәрде. Ат туктап та тормастан ишегалдына кереп китте. Тарантаста Әхмәдулла абый белән кәләш икесе генә иде. Әхмәдулла абый җәһәт кенә тарантастан төште дә кәләшен күтәреп алып яшел чирәмгә бастырды. Аннары ул безгә карап шатлыклы елмайган хәлдә:

— Хәбирә апагыз шушы була инде, — диде. Хәбирә апа оялчан гына елмаеп куйды һәм тарантастан бер төенчек алып безнең учларыбызга урман чикләвеге салып чыкты. Мәүлигә кара бәрхет түбәтәй эләкте. Безнең һәммәбезнең учына, кесәләренә чикләвек салганнан соң Хәбирә апа:

— Барыгыз инде, гөлкәйләрем, хәзер урамда уйнагыз, — дип аркаларыбыздан сөеп безне урамга озатты. Ишегалдыннан чыгып барганда ничектер минем күзем Әхмәдулла абыйның аягына төште — ул бездән алган итекләрне кигән иде. Шунда мин Хәбирә апага бик зур сер әйткәндәй:

— Безнең күн итек бу! — дидем.

Хәбирә апа эшнең нәрсәдә икәнен аңламыйча:

— Нәрсә, нәрсә? — дип сорады.

— Әхмәдулла абыйның аягындагы итекләр безнеке ул, — дидем мин горурлык белән. Әхмәдулла абый кызарып китте, ләкин бер сүз дә әйтмәде, ә Хәбирә апа бу кыен хәлдән котылу өчен: «Ярый, ярый, гөлкәем», — дип тагын иңемнән какты һәм җиң эченнән матур чигүле кулъяулык чыгарып миңа бирде.

Мондый бүләк эләгүгә канатланып өйгә кайттым. Өйдә мине тагын да зуррак шатлык көтә иде. Анда әни мич тутырып ипи салган!

Билгеле инде, җиде авызга бер пот он озакка җитмәде. Аннары шунысы да бар: ач авыз зуррак та ачыла бит әле ул. Ә он ашалып беткәч, күн итекне кире үзебезгә кайтарасы килеп, башта әллә нинди уйлар чуалды. Бигрәк тә очсыз хакка саттык кебек тоелды ул миңа. Мин итегебезне читтән генә булса да күрү өмете белән Әхмәдулла абыйлар капка төбенә барып утыргалый башладым. Капка төпләрендә мине күрсә, Хәбирә апа: «Әйдә, гөлкәем, өйгә кер, хәзер ботка пешеп чыга», — дип кыстап өйләренә алып керә иде. Кайвакыт әле ул боткасын пешерергә уйламаган да була. Мин кергәч кенә тарысын юып казанга сала. Әмма мин көтәм, мин ашыкмыйм. Туңмай салынган тары боткасын туйганчы ашап җибәргәч, Хәбирә апа миңа тагын да матуррак булып күренә. Бу кунакчыл өйдән тиз генә чыгып китәсе килми. Карашым белән күн итекләрне эзли башлыйм: әйбәт сакланалармы, майланганмы, коргаксып ятмыйлармы?

Ә бервакыт, шактый вакытлар үткәч, Әхмәдулла абыйларның капка төпләренә барып утырдым да Хәбирә апаның ягымлы тавыш белән чакырганын көтеп утыра башладым. Ашыйсы килүдән эчләр чурылдый, ләкин никтер капка ачылмый, чакыручы күренми. Мин түзмәдем, әкрен-әкрен ишегалдына кердем. Ишеккә күз салдым — ишек бикле иде. Инде борылып чыгып китәргә дип кенә торганда казык башына күзем төште. Ә анда безнең итекләр эленеп тора иде. Күрәсең, Әхмәдулла абый аларны пычратып кайткандыр да юып казык башына элгәндер. Күн итекләрне күрүгә йөрәгем дөпе-дөпе тибәргә тотынды, суыкта йөреп кайтканнан соң учак каршысына килеп баскандай йөзем кызышты. Мин үз-үземне белештерми итеккә үрелдем, як-ягыма каранып алдым: бер кеше дә юк иде. Шунда кабалана-кабалана пычрак аякларымны ышкыдым да күн итекләрне киеп куйдым. Җанганиндидер

рәхәтлек йөгерде. Күпме басып торганмындыр — хәтерләмим, аңыма килеп ак-ягыма караганда мин бакча артыннан чыгып бара идем инде. Әллә ашыгудан, әллә куркудан бәрәңге сабагына абынып егылдым...

Өйгә кайтып җиткәндә аркам буйлап шыбырдап тир ага, үзем дер-дер калтырый идем. Арып баскыч төбенә утырдым. Итекләрне кая куярга? Әни күрсә, җанны алачак. Әһә, чормага меңгерергә кирәк!

Итекләрне күтәреп чормага менеп киттем. Көне буе менә-менә Хәбирә апа килеп җитәр дип көттем. Ләкин килүче булмады. Мин инде хәзер Әхмәдулла абыйлар тирәсенә барырга курыктым. Малайлар белән дә уйнарга чыкмадым. Вакыт-вакыт итекләргә күз салгалап алырга чормага менәм дә ялт кына кире төшәм. Бөтен куанычым шул. Минем чормага менеп йөрүләремне беркөнне әни күреп алган булып чыкты.

— Нишлисең син анда? — диде ул. — Нигә ыштан туздырып менәсең ул чормага?

Минем ык-мык торуым аны шиккә салды булса кирәк һәм ул мине бер якка этәреп җибәрде дә өскә менеп китте.

Чормадан итекләрне күтәреп төшкәндә әнинең йөзендә рәхим-шәфкать беткән иде.

— Ах син, оятсыз! — диде ул ярсып. — Әле синең шулай кеше әйберенә кул суза торган гадәтең дә бармыни? Чабып өзәм кулыңны! — Әни мине җилтерәтеп ишегалдына алып чыкты, утын кисә торган бүкән янына өстерәп китерде.

— Куй кулыңны бүкәнгә!

— Әни! — дип ачыргаланып кычкырдым мин, — итекләрне Әхмәдулла абый миңа үзе бирде, урламадым.

— Алдашма, — диде әни, — алдашсаң телеңне дә чабып өзәм.

Әнинең мондый чагын күргәнем юк иде. Аның иреннәре калтырады, күзләрен кан басты. Үзен белештермәс хәлгә килде. Ул утынлыктан балта эзли иде. Әллә күзләрен ачу томалаганга, аяк астында аунап яткан балтаны күрми иде ул. Күрә калса минем эш харап иде. Мин, ниндидер могҗиза килеп чыгуына өметләнеп, җан ачысы белән акырырга тотындым.

Шулвакыт тыкрыктан Бибинур әби үтеп бара икән, минем тавышымны ишетеп, читән аша әнигә эндәште:

— Газимә килен, нишлисез? Нинди тавыш бу? Бер-бер бәла бармы әллә?

Әни Бибинур әби сүзләреннән айнып киткәндәй булды.

— Ни бар, Газимә килен? — дип яңадан кабатлады Бибинур әби һәм, әнинең җавабын көтмәстән, янкапканы ачып безгә керде. Әни мине һаман кулыннан ычкындырмаган иде әле:

— Менә, — дип мине Бибинур әби каршына җилтерәтеп китерде ул, — кеше әйберенә кул сузган. Оятсыз. Яңадан кеше әйберенә үрелмәслек итеп кулын кыскартам...

Бибинур әби мине әнидән йолып алды.

— Алай ук кызма әле син, Газимә килен, Назыйм бит әле бала гына. Бала чакта кем ялгышмый...

— Нинди бала булсын инде ул. Ун яшьлек күсәк!

— Яхшылап кына аңлат әле, Газимә килен, — диде Бибинур әби. — Ни булды?

Бибинур әбинең соравыннан соң әни әр-яңадан ярсып китте:

— Оятсыз, җирбит! Авыл алдында мине рисвай итеп кеше әйберенә кул сузган. Кемнекенә диген әле? Әүлия кебек кешенекенә бит...

Әнинең сүзләрен Бибинур әби сабыр гына тыңлады. Тора-бара әни бераз сүрелә башлады, минем ни урлаганымны аңлатып бирерлек хәлгә килде.

— Әйе, — диде Бибинур әби, — Назыйм бик тә яман эш кылган. Кеше әйберенә кагылудан да олы гөнаһ юк.

Бибинур әби белән әни урлашуның начарлыгы турында бик озак сөйләделәр. Мин инде шуның белән куркыныч үтте дип уйлаган идем, әмма әни катгый итеп:

— Итекләреңне күтәр дә хәзер үк Әхмәдулла абыйларыңа йөгер, — диде. — Кара аны, ишетсәң колагың, гафу үтен.

Әнинең бу сүзләрен ишеткәч, аркамнан елан шуышып үткәндәй куркып, бөрешеп калдым. Күз алдыма Хәбирә апаның ачык йөзе килде, колагымда: «Гөлкәем, әйдә ботка ашарга утыр», — дигән сүзләре ишетелгәндәй булды. Аннан да бигрәк, Әхмәдулла абый алдында оят иде. Без бит ачыккан саен

аның көтүлегенә барабыз. Ул изге җан безгә соңгы бәрәңгесенә кадәр өләшеп бирә. Усал шаяртуларыбызга да ачуланмый. Хәзер менә шулар каршысына барып бас инде. Юк, юк! Булмый бу миннән! Алар каршына барып баскан-чы, әни кулымны киссен.

Киреләнүемне күргәч, әни итекләрне минем кулыма үзе китереп тоттырды да җитәкләп алып китте:

— Әйдә! Кулың белән алгансың икән — хурлыгын иңең белән күтәр.

Без килеп кергәндә Әхмәдулла абый өйдә үзе генә иде. Минем кулдагы итекләрне күрүгә үк ул эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлап алды, ләкин аны-моны сиздермәде. Эчендә ниндидер шатлыгы бар иде, күрәсең, йөзе серле балкыган иде. Әни аңардан:

— Хәбирә килен өйдә юкмы әллә? — дип сорады.

— Ишетмәдегезмени әле? — диде Әхмәдулла абый. — Кызыбыз бар бит безнең. Бәби табар вакыты җиткәч, әниләренә илтеп куйган идем, бүген апкайтам инде үзләрен.

— И-и, шулаймыни? — диде әни. — Котлы булсын, бәхете белән тусын.

— Рәхмәт, рәхмәт, Газимә җиңги. Менә алар кайтуга бирәр нәрсә пешерим дип маташуым ие.

— Кая әле, Әхмәдулла энем, нәрсәләрең бар икән? — Әни кече якка кереп савыт-сабалар шылтырата башлады. Күрәсең, кинәт кенә сүзне урланган итекләргә күчерү аңарга да кыен булгандыр. Бераз ияләшә төшкәч кенә ул авыр сулап минем кулымдагы итекләрне алды.

— Бик зур оятлы булдык бит без синең каршыңда, Әхмәдулла энем. Ай-һай, нык оятлы булдык...

— Нигә алай дисең, Газимә җиңги? — диде Әхмәдулла абый. — Әллә шушы көн итекләр өчен борчылып йөрүеңме?

— Соң, ничек борчылмыйм инде, энем? Урлап апкайткан бит, адәм хуры.

Әхмәдулла абый бер миңа, бер әнигә карап алды. Безнең кыяфәтләр эчке халәтебезне ачык сөйләгән булса кирәк, Әхмәдулла абыйның йөзендә ниндидер уйлар йөгереп үтте һәм ул шикләнергә һич урын калдырмаслык итеп:

— Үзем биреп җибәрдем бит мин аларны Назыймга, — диде.

Вакыйганың мондый юнәлеш алуын һич көтмәгән идем, шаккатып калдым. Миннән бигрәк әни аптырады.

— Үзең? — дип кабатлап сорады ул.

— Әйе, — диде Әхмәдулла абый бик гади нәрсә турында сүз барган-дай. — Уйладым-уйладым да биреп җибәрдем. Нәрсәгә кирәк хәзер миңа күн итек? Өйләнәсен өйләндем инде. Көтүгә кияргә барыбер җәл. Ял көне кияр идең, көтүченең ялы юк. Ә сезгә әле ул кирәк. Сезнең әнә малайлар үсә.

Әни Әхмәдулла абыйга мең кат рәхмәтләр укыды. Юлда кайтканда да:

— Булса да булыр икән изге җанлы бәндә, — дип сөйләнде.

Мине дә Әхмәдулла абыйның бу яхшылыгы нык тетрәндерде. Хәзер инде мин берәрсе аңардан көләргә уйласа, андый малай белән канга баткан-чы сугышырга әзер идем.

Ә инде үсә төшкәч, этием кебек балта остасы булырга дип шәһәргә укырга киттем. Курсларны тәмамлагач та тиз генә авылга кайтасым килмәде. Берничә ел эшләп, өйләнерлек акча җыеп кайту нияте белән шәһәрдә калдым.

Кесәгә шактый мая туплагач, авылга кайттым. Кайтканда шәһәрдән бик шәп күн итек сатып алдым. Әхмәдулла абыйны сөендерергә иде исәп. Ләкин сөендерергә насыйп булмады, мин кайткан көнне аны җирләп яталар иде.

Алып кайткан итекләремне Хәбирә апага бирдем. Ул яшьле күзләрен сөртеп:

— Әхмәдуллабыз юк шул инде, — дип авыр көрсенеп куйды.

— Соңардым, — дидем мин үкенеп. — Менә бу итекләрне күрсә, шатланган булыр иде.

Без Хәбирә апа белән озак сөйләшеп утырдык. Әхмәдулла абыйның яхшылыкларын искә алу аның өчен дә рәхәт иде.

— Кергәлә, — дип озатып калды ул мине, — Әхмәдулла абыең турында сөйләшеп утырырбыз. Ул әле минем өчен һаман тере.

— Әйе, — дидем мин, — Әхмәдулла абый кебекләр үлмиләр. Кеше бит ул аның турында башкалар онытсач кына яшәүдән туктый...

ПУБЛИЦИСТИКА

## Юрий Алаев

# КҮҢЕЛЛӘРГӘ КҮПЕР САЛУЧЫ

Алар, ун-унике яшьлек малайлар, елга буендагы кечкенә генә калкулыкка сыенып утырганнар иде. Җир белән күк бүген артык зур, иләмсез булып тоела. Су өстендә бөтерелгән тынгысыз дулкыннар да, күктә йөзгән очсыз-кырыйсыз болытлар да, җилнең бетмәс-төкәнмәс улавы да алар күңеленә шом гына сала. Бик озак сөйләшмичә утырдылар. Бер-берсенә эндәшәселәре, уйлыйсылары килми иде. Шулай да берсе түзмәде. Башта тамагын кыргалаган булды, аннары:

— Сез күрдегезме соң әле бу рельсларны? — дип сорап куйды. — Монда күпер салачаклар, имеш.

Икенчесе, теләр-теләмәс кенә, аны үчекләп алды:

— Әллә саташасың инде син? Монда нинди күпер булсын ди?!

Әлеге сүзләрдән соң бәхәс куерып китте. Малайлар, үзләре дә сизмәстән, аякка бастылар. Рельсларның ник китерелүен ачыкларга тотындылар: чыннан да, күпер салыр өченме ул? Шулай икән, кайчан башларлар? Күпер кайчан өлгерер? Әгәр күпер төзүчеләр иртәгә үк килеп төшсә...

Алар, ашык-пошык өс-башларын каккалап, өйләре ягына борылдылар, калкулыктан аска төштеләр. Җил әле һаман котыра иде. Аяк астында чүп-чар оча, тузан бөтерелә. Тик малайлар боларның берсенә дә игътибар итми, күңелләрен бу тирәләр өчен иң зур яңалык булган ялтыравыклы рельслар биләгән. «Ник китергәннәр?» дигән сорау җанга тынычлык бирми.

Әле моннан берничә сәгать элек кенә малайларның берсе әтисен сугышка озаткан иде. Сизеп торалар: башка әтиләр дә фронтка китәчәк. Бүгенме, иртәгәме?... Кырык бернең сентябре иде бу. Яңа күперләр турында хыялланыр көннәрме?!.

...Ярты гасырлап вакыт үткән, әмма инде чәчләре чалара башлаган Бибишев хәтерендә ул рельслар, әле хәзер генә китереп бушатылгандай, һаман ялтырый кебек. Ялгыз калган чакларында ул әлеге хатирәнең гел яңарып торуына шатланып-шатланып куя. Тикмәгә генә булмаган икән бу хәл. Күпергә дип китерелгән рельслар Бибишевның киләчәгенә дөрес юнәлеш күрсәткәннәр икән ләбаса!

1952 елда, Казан төзүче инженерлар институтын тәмамлагач, Бибишевны Якутиягә эшкә җибәрәләр. Ул анда, мәңге туң нигез шартларында, йортлар сала, сууткәргечләр булдыра. Аннары, тәҗрибә туплап, туган якларына кайта. Татарстан нефтьчеләренә булыша: Әлмәттә, Зәйдә, Алабугада промыселларга кирәкле төзелешләрдә катнаша. Аның фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә иске авыллар, поселоклар урынына яңа калалар барлыкка килә. Бибишев исә уңган инженер булып танылa. Аек акыллы, нык фикерле, оештыруга сәләтле, кешеләрне үзенә ияртә алучы инженерны һәр җирдә ярата башлыйлар.

1965 елны, Чаллыга кайтып, ул 3 нче идарәнең начальник урынбасары, аннары күп тә үтмәстән, башлык итеп билгеләнә. Идарә бу төбәктәге төзелеш индустриясенең нигезен тәшкил итүче күзәнәкле бетон заводын сала. Тора-бара идарә биш трестка бүленә. Мәгълүм ки, Чаллы төзелешенә һәр нәрсә: мәйданы да, көчләре дә, акчасы да мул бирелде. Бибишев кебек сәләтле һәм инде шактый тәҗрибәсе дә булган инженерга, алга-артка карамый, төзергә дә төзергә бөтен мөмкинлекләр дә бар иде кебек.

Әмма Бибишев, илнең төрле якларыннан җыелган төзүчеләрдән аермалы буларак, бу уңайлыкларга башкача карады. Чөнки ул — Чаллының үз егете. Туган җирендә теләсә нәрсәнең теләсә ничек салынуы белән сүзсез генә килешә алмый иде ул. Олы

юл түшәгәндә шәһәрнең иң татлы сулы борынгы чишмәсен күмдерүне планлаштырганнар. Яңа, киң урамны башлап җибәргәндә гомер-гомердән яшьләр күңел ачарга җыела торган аулак урындагы өянкеләрне турап ташламакчылар икән... Кагылган һәр казыкка туган йортын яхшырту, киңәйтү һәм мәңгеләштерү итеп караучы инженер шушындый «уйлап табучы»ларга каршы күтәрелә. Дөрес, аның кебек үк фикер йөртүчеләр тагын да була булуын, тик бу бигрәк кызу канлы, сабырсыз, һәр мәгънәсезлеккә каршы шундук күтәрелеп бәрелә башлый.

Мондый гадәте кыйммәткә төшә аның. Кеше язмышлары хәл ителә торган кабинетларда Бибишевның холыксызлыгы турында сүз тарала. «Үзен олы юлга чыгарган» җитәкчеләренә баш бирми, «тар урынчылык карашы»ннан котыла алмый, фәлән дә төгән... Бибишев барыбер үз фикерләреннән чигенергә уйлап та карамый. Яман сүзләр дә һаман арта бара. Берсендә хәтта: «Бибишев үз кул астында эшләүчене кыйнаган!» — дип, «аһ» итәләр.

Нишләмәк кирәк?! Андый сүзгә дә җирлек табылды шул. Яңа бер йортны дәүләт комиссиясенә тапшырыр көн иде. Йорт әзер. Бульдозер соңгы чүп-чарларны җыештырып йөри. Янәрдай чүпләрне өеп учак үрләткәннәр. Прораб та шунда. Марат Шакирович Бибишев алар янына килгәндә, учакта... плинтус калдыклары дөрләп яна иде. Әллә кайлардан, мең бәясенә төшереп кайтартылган плинтуслар яна! Бибишев, ялкыны талпынып торган бер плинтус кисәген кулына ала да, зәһәрләнеп:

— Бу ни бу? — дип, прораб каршына килә башлый.

Тегесе акыллырак җавап бирсә, бәлки, тыелган да булыр иде әле, тик прораб аны-моны уйлап тормый:

— Ә-әй, исең киткән икән! — дип кенә җибәрә.

Кайнар җан мондый ваемсызлыкка ничек чыдасын соң?! Бибишевның кулындагы утлы кисәү прорабның аркасына барып төшә. Сүз дә юк — оят хәл. Суынгач, Бибишев ялгышын үзе дә аңлый. Шул кызулыгы аркасында аны үз урынында, хәтта партия сафларында калдыру-калдырмау мәсьәләсе туа. Тикшергән чакта һәммәсе дә бары Бибишевның гаебе турында гына сөйли, прорабның халык милкенә күпме зарар салуы турында телгә алучы да булмый. Мондый берьяклылыкның Чаллы төзелешенә кире тәэсире дә сизелә: төзү кирәк-яракларын әрәм-шәрәм итү, техниканы кирәкмәгәнгә эшләтү...

Бибишев карашынча, бу — фаҗига. Адәми затның азрак кына уйлый белгәне үз карамагындагы һәр нәрсәгә, хәтта тутыккан кәкре кадакка да тиешле бәясен бирә белгән. Кая китте безнең кешеләрдәге сакчыллык?..

Мин Марат Шакирович Бибишев белән беренче тапкыр 1976 елның декабрендә очраштым. Күрешергә теләвемнең сәбәбе дә сәер иде. Берәү:

— Чаллы йортлар салу комбинаты башлыгы Бибишев хезмәткәрләрен өй тирәли чаптыра икән, — дип сөйләде.

Ышанырга да, ышанмаска да белмәдем. Бибишевны күрәсе килү теләге көчәйде. Эш көне тәмамланган иде инде. Марат Шакировичның кәефе шәп күренә. Әлеге «чабыш» турында сорарга җөрьәт иттем.

— Башта кайберәүләр, махсус кием юклыкка сылтап, баш тартканнар иде, — дип сөйләп китте ул. — Соңыннан спортка барысы да тартылды. Хәзер авыручыларыбыз кимеде, кайберәүләр тәмәке тартмый башлады...

Хикмәт бер төркем кешенең сәламәтлеге турында кайгыртуда гына түгел, хезмәттәшләрен яңача уйларга да өйрәтә ул. Нәтиҗәдә, гомуми тырышлык белән спорт комплексы салына: футбол кыры, спорт залы, мунчасы, бассейны һәм тамаша залы бар. Корылма һичнинди өстәмә чыгымнарсыз, рәсми рөхсәт кәгазеннән башка торгызылган. Проектын сызудан алып, геологик тикшеренүләренә кадәр Бибишев һәм аның теләктәшләре тарафыннан бушлай үтәлә. Материаллар производство ихтыяҗы өчен арттырып бирелә торган әйберләрне янга калдыру хисабына җыела. Гамьсезләр утка яга торган плинтус кебек әрәм мал бу юлы игелекле максатка җигелә.

Бу күңелсез хәл искә төшерелгәч, мин дә сорарга булдым:

— Битарафлар кайдан килә ул, ә? Бер-беребезнең вакытын, хезмәтен дә санга сукмыйбыз, мал кадерен белмибез, ахры...

Марат Шакирович кисәктән кырысланды:

— Җаваплылыкны өсләренә алырга теләмәүче «вакытлы хаким»нәребез күбәйде. Властьны яраталар, эшлиселәре килми...

Беренче күрүдә үк Бибишевны аңладым дип мактана алмыйм. Кабатлап әйтәм: бу 1976 ел иде. Чаллы автогигантының даны илне иңләп-буйлап гөрләгән чаклар. Марат Бибишев тормышында да күңелсезлекләр шактый артта калды: ул — ил күләмендә макталучы комбинатның начальнигы, «КамАЗ төзелеше ударнигы», СССР Министрлар Советының премиясе лауреаты. Үзе генә түгел, ул җитәкләгән коллективның башка уңганнары да илнең мактаулы төзүчеләре рәтенә басты: Р. Сәләхов, В. Фи-

лимонов, В. Мәүликов, Р. Сабиржанов кебек җитәкчеләр үсте. Уйларымны Бибишев бүлде:

— Күңелсезлекләрне артык тирәнгә җибәрергә яратмыйм мин. Яшәргә, янып-көеп эшләргә дә эшләргә! — Ул инде елмаеп сөйли иде. — Әйдә, иртәгә спорт залына кил! Яшь көрәшчеләребезнең финал ярышы!...

Мин тамаша залына кергәндә, шәһәрнең 10-12 яшьлек малайлары тәмам кызган иде. Тамашачылар — малайларның дуслары, әти-әниләре. Җиңүчеләрне пиджак якасына разрядлы көрәшче билгесе кадаган шул ук Бибишев бүләкли. Җитди рәвештә котлый, вымпеллар, дипломнар бирә. Балаларның күзендә ут яна. Заманында үзе дә көрәшче булган шундый зур җитәкче кулыны кыссын әле!

Бер караганда, барысы да гадәти иде. Шәһәрдә спорт комплексы салынырга тиеш инде ул. Анысы төзелгәч, ярышы да уздырыла инде аның. Балалар ярышына өлкәннәрнең күз-колак булып йөрүендә дә әллә ни искитәрлек нәрсә юк кебек. Әмма шул эшләрнең барын да Бибишев, үз җаваплылыгына алып, очлап чыккан бит! Күпме каршылыкларга очрый ул, күпме дәгъвалар ишетә, ничәмә-ничә комиссияләргә каршы тора! Гаҗәп: һәммә кешегә кирәкле шул игелекле эш кемнәрнеңдер ярдәме белән түгел, ә Бибишевның «үҗәтлеге» аркасында гына тормышка ашкан. Хәйран калырлык: шул ук елларда берәүләр үзләренә зиннәтле дачалар, йөзләрчә квадрат метрлы өйләр булдырган һәм аларның «эшчәнлеге» бер генә комиссияне дә кызыксындырмаган. Мәсьәләнең бу ягына карасаң, гыйбрәтләр җитәрлек. Кешедә төзүчелек, архитекторлык таланты булуы бик ихтимал, ә менә үзе турында әллә ни уйлап тормыйча, гомуми мәнфәгать өчен янып-көю — монысы инде әхлакый каһарманлык! Марат Шакирович 1965 елдан бирле бер үк фатирда яши. КамГЭС поселогында гап-гади өч бүлмәле квартира. Балконы да юк. Шунда ике улы үскән. Улларының берсе өйләнеп, үз учагын булдыргач кына бераз иркенәеп калдылар.

КамАЗның беренче конвейеры эшли башлаган чорга Чаллыда ике миллион квадрат метрдан артыграк мәйданда торак салынды. Шуның бер миллионлабы Бибишев җитәкләгән йортлар салу комбинаты өлешенә тия. Коллектив, йортлар салу комбинаты буларак, 1973 елда гына барлыкка килде. Соңрак ул үзе эре-эре идарәләр бүлеп чыгарды. Әүвәл бригадир булып эшләгән Р. Сабиржанов КПССның XXV съездына делегат итеп сайланды, В. Филимонов Социалистик Хезмәт Герое булды, түбә ябучылар бригадиры А. Волкова Ленин ордены белән бүләкләнде, Марат Шакирович — Октябрь Революциясе ордены белән.

Орден алу яхшы. Бибишев исә кешеләрдән ишеткән рәхмәтне тагын да кадерлирәк төшә кебек. Яңа шәһәрнең якташлары күңелендә тирән канәгатьләнү уятуын тели ул. Шәһәрдә яшәү рәхәтме? Кешеләр комбинатка рәхмәтлеме? Бу гигант төзелешләр, җаннарны изеп-сытып, адәм баласының табигатенә хилафлык китермиме?... Бибишевны әнә шундыйрак сораулар борчый. Ата-баба күрмәгән гигант төзелешкә, олугъ «шакмак»лардан гына торган биниһая зур йортларга җылылык өрергә, аларны «миһербанлы» итәргә тырыша ул. Минем аптырабрак калуымны сизгәч, Марат Шакирович иплән аңлата башлады:

— Кеше гасырлар буе табигать кочагында яшәгән. Табигать исә бертөрлелекне кичерми, бөтенләй кабул итә алмый. Анда — хәрләк. Форма, төс, зурлык — барысы да мең-миллион төрле. Безнең төзелешләр исә тоташтан бертөрлелеккә йөз тота. Проектларга күз салсаң, хәйран каласың! Шәһәр урамнарында күңел кунарлык бер генә сыйфат та табарлык түгел, барысы да куб, параллель... Бу хәл табигыйлеккә каршы бара. Кешенең күптөрлелеккә җайлашкан холкы гаҗизләнә, аңа күпмедер «тәртипсезлек», «хаос» кирәк. Һәм без, аз гына иҗади карасак та, кешенең бу ихтыяҗын канәгатьләндерә алабыз лабаса!...

«Кеше табигате», «хаос» кебек төшенчәләргә табынуы Марат Шакировичка шактый тал чыбыгы ашатты инде. Дөрес, аның якты фикерләрен хуплаучылар да табылды. Күпләр исә җилкә җыерудан узмады: «Нишләмәк кирәк?!» янәсе, үзеңнән биеккә сикереп булмый — проектлаучылар ни сызып бирсә, төзүче шуны салырга тиеш. Өстәвенә, төзелеш индустриясенең мөмкинлекләре дә чикләнгән.

Торак йортларны тәҗрибә төсендә проектлау үзәк фәнни-тикшеренү институтының әүвәлге директоры Борис Рафаилович Рубаненко Чаллыга килгән саен, Марат Шакировичтан:

— Хәлләр ничек? Тагын «хаос»ка бирелдекме? — дип сорый торган иде.

Мәрхүм Рубаненко Бибишевтагы иҗади омтылышны ихластан зурлады. Шулай да аның институты Бибишевча ук тәвәккәлләргә җөрьәт итә алмады. Институт киләчәккә ышанып эш итә алмый, кулда булган мөмкинлекләргә генә таяна. Шунлыктан Рубаненко Бибишевка сериялап проектланган йортлар белән канәгатьләнергә киңәш бирде. Марат Шакирович аны аңлый иде: конвейерга көйләнгән өйләрне нишләтәсең инде?! Урман кебек «үсеп» чыккан өйләргә төрлелек биреп бетерү һич мөмкин түгел.

Борис Рафаилович үзенә күрә дәлиле дә бар иде:

— Марат Шакирович, — ди торган иде ул. — Элекке агач йортлар да, нигездә, бер төрле бит. Төп үзгәлекләрен генә искә алсаң, ике-өч төрдән артмый. Әмма алар һәммәсе төрле-төрле булып тоела. Сәбәбеме? Сәбәбе — тышкы бизәкләрдә: түбә кыегының челтәрләре, тәрәзә капкачлары, капкалар, рәшәткәләр... Шуңа күрә, Марат Шакирович, кадерлем, йортларыбызны матурлау бары үзебезгә генә бәйле булып кала түгелме?!.

Бибишев үзе дә күптән шул фикердә иде инде. Тик күңелдәге теләкләрне тормышка ашыру өчен тагын мең дә бер шартның үтәлүе кирәк. Иң әүвәл һәр төзүче шул ук теләктә янарга тиеш! Аннары... материаллар: буяу, плиткалар, төсле кирпечләр, үзле балчык — азмыни төзелешкә матурлык иңдерердәй нәрсәләр?!.

Чаллыны салышуда катнашкан икенче бер оешма — «Главмосстрой»дан аермалы буларак, Бибишевның төзүчеләре йортның нигезен дә үзләре ныгытырга керешә. «Главмосстрой»ныкылар әзер нигезгә килеп эш башлый иде. Ә нигез салучыларга бәйле булу кулны тота, нык тота. Шунлыктан Бибишев алардан баш тартты. Металл конструкция җибәрүчеләр сүзләрендә тормагач, бу төр кирәк-яракны да үзләре ясарга булдылар. Алар, гомумән, эшкә аяк чалучылардан баш тарту ягын карыйлар. Сантехника өчен кирәкле полиэтилен детальләрне вакытында бирми интектерәләр иде, Бибишев хәтта моңа да чик куйган.

— Ничек? — дип сорамый булдыра алмадым, чөнки монысы һәр төзелешнең үзәгенә үтә. — Кайдан таптыгыз андый деталь коючы автоматны? Махсус предприятиесендә дә интегәләр...

— Ә-әй, мескенләнмәсеннәр лә! — дип, Марат Шакирович сүземне кырт кисте. — Интегүләре үзләре төсле генәдер. Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, диләр бензнең халыкта. Әнә, «Экономическая газета»ны укысыннар! Бераү нидер сата, икенчесе алмаштыра. Шулай берәмтекләп җыйдык. Әшли хәзер автомат! Безнең бит әле аңа махсус фондыбыз да юк...

Марат Бибишев җитәкчелегендәге эшләрнең өзлексез яңарып-үзгәреп торуында мәсьәләгә иҗади карау, эзләнү, башкалардан өйрәнү — төп этәргеч. Әйтик, 70 нче елларда Алма-Атада панель йортларны катлаулы конфигурацияләп сала башладылар. Бибишев шунда ук Казахстанга очты. Ташкенттан бизәкләү материалларын ясау әмәлләренә өйрәнеп кайтты ул. Балтик буе совет республикаларында аны витражлар белән матурланган йортлар кызыктырды. Кыскасы, Бибишев илдәге төзелешләрдә күренгән һәр яңалык белән үзе таныша баруны кулай күрә. Барып таныша, нәтиҗәләр чыгара, эзләнүләре яңа ачышларга китерә. Бибишев — уйлап табылган өч яңалык авторы. Аның җитәкчелегендә иҗат итүче башка инженерлар да, әлбәттә, яңаны булдыру дәртендә яналар. Аларның эш алымында кызыклы яклар күп. Әйтик, комбинат составындагы тугыз идарәнең берсе фәкать нигез әзерләү һәм... заводларны яңартып тору белән мәшгуль. Бу очракта күзәнәкле бетон һәм эре панельле йортлар заводлары күздә тотыла. Алар өзлексез үзгәртелә, камилләштерелә. Бер карасаң, заводларны үзгәртеп кору — бөтенләй башка оешмалар эше, әмма Бибишев бу бик тә җаваплы бурычны да үз коллективы өстенә алды. Хәзер инде нәтиҗә турында ныклап әйтергә була: заводларның мөмкинлеген арттыруны читтән көтеп утырсалар, алар бүгенге уңышларга һич тә ирешмәячәкләр иде. Ундүрт ел эчендә комбинат биш, тугыз, унике, уналты катлы йортлар сериясен җайга салды, шул ук вакытта фасадларны бизәүнең дә дүрт-биш төре үзләштерелде.

Иҗади эзләнүләргә коллективның үзендә тудырылган мөмкинлекләр дә этәргеч ясады: культура сарае, йөзү бассейнлы спорт комплексы, балалар спорт мәктәбе, шахмат клубы, ял базасы, пионер лагере... Комбинат бөтен «Камгэсэнергострой» берләшмәсен тәэмин итәрлек санаторий-профилакторий да салды. Боларны булдыру өчен исә бер-берсен аңлап эшләүче, оештыру сәләтенә ия, тәртипле, өлгер инженерлар тупланды. Бер караганда, коллективта кечкенә генә эшне җиренә җиткереп башкаруда да югарыда телгә алынган шартларның һәммәсе мөһим. Әмма, минем уемча, башында Марат Шакирович кебек әйдәүче тормаса, бик кыенга килер иде. Бәхеткә, бу коллективның әйдәүчесе кулында комбинат башлыгының власте да бар. Гомуми уңышны билгеләгәндә мондый тәңгәллекнең уңайлыгы аермачык күзгә ташлана.

Җитәкченең холкы эзләнүчән булганда, коллектив өчен янып-көеп йөргәндә, аның тирәсендәгеләр дә һичничек «йоклап» ята алмый. Марат Бибишев янында комсомол да, профсоюз вәкиле дә оешма кешесе исемен формаль гына күтәреп йөри алмый. Бу хәл мөмкин түгел. Мин, әле Бибишев белән очрашканчы ук, бассейнда ...бригадирлар ярышына йомгак ясалганын ишеткән идем. Имеш, шул вакыйгадан соң, бассейнга йөрүчеләр саны арткан, спорт белән шөгыльләнү күпләрнең күркәм гадәтенә әйләнгән.

— Сез, Марат Шакирович, хезмәткәрләрегезне мәҗбүри йөздерәсез икән бит? — дидем мин юри, әлеге мәсьәләне ачыклау өчен.

— Гаепләмәкче буласызмы? — Ул миңа сорау белән җавап кайтарды. — Теләсә ничек аңлагыз инде, яңалыкка ияләндерүнең кирәклеген тоям мин. Бу очрактагы мәҗбүр итү кешеләрнең үз файдасына бит! Дистә еллар буе «олы агайлар» өйрәтүенчә яшәгән кешеләр еш кына, инде үзләре зур ук булгач та, акны карадан аера алмый. Шуңа күрә төрлечә сынап карыйм. Бассейнга да, чаңгы юлларына да көчләп диярлек йөртә башладык. Урынбасарларымнан алып идарә аппаратындагы барлык инженерлар төзелеш технологиясе курсларына йөри. Соңыннан имтихан да алабыз. — Бибишев елмаеп куя. Бу курсларда ул үзе дә лекция укый икән. — Нишлисең?! Өйрәтергә кирәк. Күпләр әле үз абруйларын үзләре кадерли белми. Бассейнда йөзү дә, белемеңне өзлексез күтәрү дә үзен хөрмәт иткән кешенең рухи ихтыяҗы булырга тиеш иде дә бит!.. Юк. Бу очракта коры өндәмәләр көчсез. Мин бик кечкенәдән — шәхси гигиенадан башларга булдым, чын мәгънәсендәге культуралы шәхес үрнәгенә омтылабыз. Килер бер көн: без, бүгенге кебек «шакмаклар» гына салудан арынып, матурлыкка (!) ирешербез!..

Миңа Бибишев уздырган бер киңәшмәдә катнашырга да туры килде. Иң гади киңәшмә, эш турында агымдагы сөйләшү иде бу. 25 катлы йортларга куела торган лифтлар турында әңгәмә куерды. «Кемнәрне Финляндиягә җибәрәбез? Аннан кайткач, мондагы яшьләрне укытырлык булсыннар! — диделәр. — Лифтны монтажларга да, төзәтергә дә өйрәнеп кайтсыннар!»

— Безнең йортлар, кимендә 200 ел торса, бу дәвергә бер генә җиһаз да чыдамаячак, — дип, сабыр гына аңлата Бибишев. — Яңа буыннар безне тиргәмәсен өчен, без һәр җайланманы тиз арада төзәтә барырлык осталар әзерләргә тиеш!..

Шул чак бүлмәгә ят кеше килеп керде. Кулында — кәгазь. «Сез Белоярск АЭСын салучыларга 11 мең квадрат метр торак төзеп бирергә тиеш. Менә боерык!» — диде ул.

Менә сиңа мә! Соңгы вакытта комбинат «югары»дан бирелә торган әмерләрне шактый еш ала башлады. «КамАЗ»ны бөтен ил төзеде, инде сез дә ярдәм итегез!» — диләр. Болай уйлаучылар Чаллы кешеләрен дә шул илнеке икәнен бөтенләй истән чыгардылар кебек. Шәһәрнең ихтыяҗы гел артка чигерелә, мөмкинлекләр чикләнә бара.

Бибишевныкылар бүгеннән үк яңа 141 нче серияле йортлар салырга әзер, тик аңа тотыну өчен 2 200 тонна металл кирәк. Анысы юк. Шуңа күрә комбинат искечә типтагы йортларны салырга мәҗбүр. Хәтта «киләчәк шәһәре» дип игълан ителгән Алабуганың яңа кварталларында да шул ук элекке йортлар күренә башлады. Бибишевның чәчләре шушындый каршылыкларны җиңә-җиңә агарып беткән инде. Дөрес, аңа партия һәм совет оешмалары да ярдәм итәргә тырыша. Металлы да, күзәнәкле бетон заводы өчен яңа җиһазлар да табылыр. Гомумән, барысының да рәткә салыначагы көн кебек. Әмма алар хакына уздырылган йокысыз төннәрне, елларны кире кайтару мөмкин түгел. Хәер, көрәшләрнең алдагысы да җиңел булырга тормый. Партия сүзен үргә алып, халык илдәге үзгәртеп кору, тизләнеш, яңарыш өчен көрәшкә кушылды. Бибишев кебек ир-егетләр мондый вакытта тынычлана аламы?! Электән үк аякка тышау булып уралган каршылыкларга хәзер өр-яңалары, моңарчы башка да килмәгәннәре өстәлде. Бибишевка бу араларда тәүлегенә ике-өч сәгать кенә йокы тия. Әмма кешеләр аны һәрчак көләч, пөхтә, җитез итеп кенә күрәләр. Яшь егетләрнекедәй хәрәкәтләре, ышанычлы яңгыраган сүз-тәкъдимнәре, урынлы күрсәтмәләре башкаларны да эшкә дәртләндерә, иҗади янарга әйди кебек. Бибишев янында эзләнмимитми, янмый-көйми эшләү мөмкин түгел, монда битарафлыкка, ваемсызлыкка җирлек бөтенләй юк.

Уйлап куясың: ничек шулай була ала ул? Кайдан көч таба? Ничек өлгерә? Кемнән өйрәнә? Баксаң, бу иҗатның чишмә башы әллә кайларга, сабый чакка, еракта калган кырык беренче елларга ук барып тоташа икән. Салынырга тиеш булган яңа күпер күренешен искә төшерик! «Күперләр салучы булсаң икән!» — дип хыялланып яшәгән ул.

— Чын-чынлап күпер салучы була алмадым шул, — кайчак ул офтанып та куя. — Зәйдә генә әллә ни зур да булмаган бер күпер салырга туры килде...

Тирәннәнрәк уйласаң исә, Бибишев гомере буе күперләр сала — кешеләрнең күңелен тоташтыра, якынайта торганнарны! Көче генә җитсен дә, гайрәте генә сүнә күрмәсен!

## Изаил Зарипов

# СИГЕЗЕНЧЕ КОЕ

Егетләрнең кәефе шәп иде. Ата-баба аяк басмаган Себер җирендә, кита-кайта йөреп, бер кое казуны гына түгел, сигез коелы тулы бер тирәлекнең эшен планда каралганнан да алдарак алып бар әле син — кәеф шәп булмыймы соң?! Мастер Туйдул Саврандиев мондый уңышны Татарстанда да сирәк күрә иде. Ул озак еллар буена Ульян мәйданында эшләде, Андагы һәр катлам яхшы таныш иде аңа. Себергә килгәч исә аларның беренче ишеткән сүзе кисәтү булды:

— Бу сезгә Ромашкино түгел, Самотлор бу! Бер алга, биш артка карарга кирәк булачак. Сеноманга эләксәң — бетте баш...

«Сеноман» дигәннәре — газлы катлам. Кетмәгәндә шуңа килеп кагылсаң, көчле басым бораулау җайланмаларыңның бөтенесен күккә чөя. Эзлә аннары, җый! Шуңа күрә сеноман булуы ихтимал җирдә өстәмә рәвештә күп төрле чаралар кертелә. Астан чыккан балчык урынына шунда ук измә кудыртып торалар, сеноманга өстән ясалган басым үзгәрешсез калырга тиеш.

Тирәлектәге сигез коеның җидесен казу шома гына үтте. Сеноман үзен сиздермәде, газның бер куыгы гына да күренмәде. Шуңардан шикләнеп күпме сөйләнделәр, нинди генә чаралар күрмәделәр, җир астына күпме измә китте — әрәм, валлаһи! Егетләрнең кайбере кисәтүләрне искә төшереп:

— И-и, ул сеноман белән безне юри куркытканнардыр,— дип тә куйгалады.— Бер нинди дә куркыныч юк бит! Ярты ел эшлибез, җиде кое казыдык, тып-тыныч. Инде сигезенчесенең дә төбенә төшеп киләбез. Тиздән нефтьле катламга җитәбез бит инде. Бу сеноман дигәннәре, аю кебек, без килгәч кенә, качты. Аю да күргән юк бит, үзебез Себердә яшибез. Өйгә кайткач, балаларга сөйләрлек тамаша да юк...

Сигезенче коеның соңгы карышларын бораулаучы Роберт Сафиуллин да шулайрак фикер йөртә иде. Соң, тагын ни уйласын, эше көйле, моторлар тигез генә гөрелди. Алданрак түгәрәкләп куйсалар, премияне тагын да мулрак алачаклар. Измә кудырып азапланасы да юк...

Аның матур уйлары кисәктән тукталып калды. Сеноман! Мәкерле көч өстәге басымның азлыгын кай арада чамалап өлгергәндер?! Газ көпшә буйлап өскә бәрергә тотынды. Әле генә аска җибәрелгән измә дә, фонтан булып, өскә атыла. Измә елга булып читкә агып ук китте. Аның өсте меңнәрчә куыкчыклар белән чуарланган — газ!

Берничә секунд эчендә хәлне югарыдагы егет тә сизеп өлгерде. Ул арада исә измәнең атылуы бераз тына төште. Сеноман гүя тын алырга тукталган иде. Әмма икенче мизгелдә үк торба күккә таба сузая төшкәндәй булды. Коты алынган егет уктай җиргә атылды. Газ инде измә ату белән генә канәгатьләнми, коточкыч аваз чыгарып улый да иде. Бу яман тавыш шактый еракка ишетелә, күңелләргә шом сала. Ул ял итүче вахтаны да уятты, аш пешерүче хатын-кызларның да котын алды.

Мастер белән бораулаучы егет газның юнәлешен үзгәртергә тиешле җайланманы борырга чаптылар. Тагын бер генә секундка соңарсалар, эшләр харап иде. Бәхеткә, зур бәла чыкмый калды. Сеноман үзе үк шактый зур убылу ясаган да газның юлын бикләп куйган икән. Аның шул тоткарлануыннан файдаланып калырга кирәк иде.

Иң әлек бораулау эшләре идарәсенең Бөгелмә базасына хәбәр иттеләр:

— Газ бәрә!— диделәр.— Нишләргә дә аптырадык.

Базада идарәнең баш инженеры Хәлил Әюпов белән «Татнефтегазразведка» трестының баш инженеры Геннадий Ситников туры килде. Ситников менә-менә чыгып китәргә, Казанга очарга әзерләнгән иде. Ул мәсьәләне тиз аңлады, рациядән:

— Берләшмәгә дә хәбәр итегез! Янгын сүндерүчеләрне җибәрсеннәр!— дип ашыктырды.— Рациянең дә өзелүе мөмкин, шуңа күрә, элемтә өчен, бер машина әзер торсын! Без хәзер барып җитәбез...

Ситников белән Әюпов килгәндә, янгынчылар да, газ чыгу очрагында ярдәм күрсәтергә тиешле отряд та анда иде инде. Катлаулы эшләр мастеры Әхәт Харисов, үзәк инженер-технологик хезмәт бүлеге начальнигы урынбасары Кайман Камалов белән техник бүлек начальнигы Рафаэль Хәмидуллин да килгән. Алар, газ кабаттан гайрәт ормасын өчен, кулдан килгәннең барын да эшләгәннәр. Инде аны тәмам тыгынчыкларга кирәк. Хәмидуллин, Харисов һәм Камалов коега измә тутыру ысулын яклыйлар. Аларның киңәше буенча бөтенесе ашыгыч рәвештә измә ясау хәстәренә керешкән.

Әюпов исә:

— Коены саклап калырга кирәк!— диде.

Ситников та аңа кушылды. Дөрес, бу ысул бик тә четерекле. Газ чыгуны туктатуның бик төгәл планын төзергә кирәк. Ситников бу эшнең агышы һәм нәтиҗәсе өчен бөтен җаваплылыкны үз өстенә алырга булды. Иң куркынычы — котырынган газның җир асты токымнарын фонтан итеп ата башлавы. Шуннан саклану чараларын күрергә кирәк.

Бөгелмә егетләре беләләр: мондый очракта Самотлорда элек-электән бер генә чарага ябышалар. Бораулау туктатыла, казылган кадәре кое цементлап каплап куела. Аннары өр-яңадан өч кое казыла: икесе — куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен, берсе томаланган коены алмаштыра, нефть бирә. Бу ысул тыныч эшкә көйләнгән. Куркынычсыз ысул. Әмма, бу юл белән китсәң, эш бик озакка сузылачак һәм шактый кыйммәткә төшәчәк. Кое бәясе миллион сумнан да артып китәчәк. Себердә моңарчы акча белән исәпләшеп тормаганнар: нәрсә ул миллион! Исең киткән икән! Татарстан нефтьчеләре алай азынырга өйрәнмәгән. Коены коткарырга икән, димәк, бу — миллионны да сакларга, вакытны да җилгә очырмаска дигән сүз. Йөзләрчә тонна нефтьне дә мөмкин кадәр тизрәк алырга кирәк! Аннары күңел таләбе дә бар бит әле. Миллионнарны җир куенына салып куйсаң, җан тынычлыгын кайдан табарсың?! Казылган коены көрәшсез-нисез генә җир куенына томалап кую егет кеше эшеме?! Куркаклык, бер сүзсез чигенү ич бу. Татарстан нефтьчеләре «бер тиенлек куянга ун тиенлек зыян» ясап эшләргә яратмыйлар.

Егетләр, коены саклап калу чараларының бөтен кыенлыгын уйлап, шул план буенча эшкә тотынырга әзерләнгәндә, «Нижневартовскнефтегаз» идарәсеннән рәсми күрсәтмә килеп җитте:

— Коены томаларга!— диделәр.

Кагыйдә буенча, авария турындагы хәбәрне Урта Идел идарәсенә дә, Казанга да, Мәскәүгә дә ирештергәннәр иде инде. Ул тарафларның һәркайсыннан шул ук: «Коены томаларга!»— дигән күрсәтмәләр алынды.

Ситников Түбәндәге белгечләр белән дә киңәшергә булды. Мондагы бораулау эшләренең начальнигы урынбасары Мидхәт Сафиуллин, Татарстандагы хезмәтләре буенча, Ситниковны яхшы белә. Тәвәккәллеген дә, хәлгә тиз арада дөрес бәя бирергә осталыгын да хәтерли. Аның иң кулай ысулны билгеләвенә һәм җаваплылыктан һич тә курыкмавына ышана. Татарстанда Яңа Суксу мәйданындагы бер коедан газ «төчкерә» башлагач та Г. В. Ситников коены саклап калган иде. Әле дә телефоннан Геннадий Викторовичның:

— Мин коены томалауга каршы. Өч көн вакыт сорыйм,— дигән сүзен ишеткәч, Мидхәт Нәзифуллович гаҗәпләнмәде.

— Синең үзсүзле татар икәнлегеңне күптән беләм инде,— дип кенә куйды.— Әйдә, син дигәнчә булсын! Хәерле сәгатьтә!

Ситников кушуы буенча, һәркем үз постында иде. Электр энергиясе чыганаклары баш энергетик Виктор Портнов кулына тапшырылды. Монда вакытсыз елтыраган бер чаткы гына да коточкыч афәткә әйләнергә мөмкин. Кое авызына җайланмалар батыргандa өзлексез су җибәреп тордылар. Туйдул Саврандиев газны тарату пультында иде. Хәрби тәртиптәге отрядка да эш табылды: алар, кирәге чыга калса, коткару чаралары өчен җаваплылыкны үз өсләренә алдылар.

Санаулы сәгатьләр бигрәк тиз үтүчән. Биниһая четерекле эшне җайлый-җайлый тәүлекнең узуы сизелми дә калды. Инде эш тә түгәрәкләнеп бара, тәвәккәлләп, бораулый башларга да ярар иде, тик... Бораулаучылардан берәү, аны-моны уйламый гына, элеватор капкачын ачкан. Шул чак җайланма эчендәге клапанлы ялгыз торба, ычкынып китеп, аска атылган. Газлы измә эченә! Ачу китергеч авазы гына ишетелеп калды. Инде нишләргә?

Торбаны тиз арада алырга кирәк. Балык тоткан кебек эләктерергә. Бораулау вакытында моңа охшаш хәлләр булгалый. Аска киткән эш коралларын, гадәттә, махсус эләктергечләр белән «аулыйлар». Тик ул очракта бик озак азапланырга туры килә. Вакыт күп югала. Шуны күздә тотып булса кирәк Әхәт Харисов:

— Без аны зуррак диаметрлы торба белән куа төшик!— диде.— Килеп эләккәнче төшәбез дә төшәбез...

Харисов «шаян» торбаны дүрт йөз метр тирәнлектә «куып» тотты. Бик оста рәвештә эләктереп тә алды. Торба ишелгән токым арасына нык кына кысылган иде, шуңа күрә аны боргычлау шактый җайлы булды.

Забой эченә исә газ тулып тора иде. Ул инде, сиздермичә генә, торбаларга да

сарыла. Аның зур көч белән кабат бәреп чыгуын измә авырлыгы гына басып тора. Моңа әллә ни зур ышаныч юк, газ үз эшен эшли бирә, измәне дә сыегайта, какшата, янәдән бер күтәрелеп бәрелмичә аның тынычланырга исәбе юк, күрәсең. Беренчесендә аны яннан ишелеп төшкән катлам басымы гына бастырып калды. Кабат күтәрелгәндә катламның ишелмәве дә ихтимал.

Бораулаучылар бу бәладән ничек котылырга кирәклеген тәгаен генә белмиләр иде әле. Хәмидуллин белән Камалов торбаларга тулган газны чыгарырга тәкъдим керттеләр. Кайберәүләр бу чарадан шикләнеп калды:

— Газ чыгып беткәч, ни булыр? Кое нишләр? Бушлыкны тоеп сеноман кабат котырынмасмы?

Эшнең һәр секундын ныклы тәртипкә салдылар. Саллы измә әзерләнде, өзлексез шуны кудырып торырга булдылар. Сеноман һичнинди җиңеллек тә «сизмәскә» тиеш! Измә әзерләү исә кул көчен күп таләп итә. Инженерлар да цемент тутырылган капчык ташырга тотынды. Роберт Сафиуллин вахтасы алны-ялны белми тырыша иде. Чөнки алар әлеге четерекле хәл туура үзләрен гаепле саный кебек. Эш ике сменага бүлеп алып барылды. Уналтышар сәгать эшлиләр, сигез сәгать йокыга бирелә. Күбесе әле анда да йокыга китә алмады. Җан түзми, күзгә йокы керми интектерде. Лаборантка Мәрзия Харисовага ял бөтенләй тимәде, чөнки измә изү технологиясен гел тикшереп торырга кирәк. Аңа үз постында өзлексез ике тәүлек эшләргә туры килде.

Ниһаять, җитәрлек измә әзерләнде. Торбаларга тулган газны чыгарырга мөмкинлек туды. Бер үк вакытта измә дә кудыртып торырга кирәк иде.

Ситниковның боерыгы барысын да сискәндергәндәй яңгырады:

— Газны чыгара башларга!— дип тәвәккәлләде ул.

Газдан арындыру җайланмасын тоташтырдылар. Измәне быкырдатып торган газ сизелеп кими башлады. Бу инде эшнең бораулаучыларга кирәкле юнәлештә баруын күрсәтә иде. Әмма тынычланырлык ара булмады — Мәрзия Харисова измә тыгызлыгының кимүен хәбәр итте. Сеноман да, кешеләрнең ялгыш адымын сагалап кына торган диярсең, үзен сиздереп алды. Измә өстендә куыкчыклар быкырдашырга тотынды. Ситников лаборанткага:

— Тикшерүне туктатмагыз!— дип боерды. Башкаларга да күрсәтмәләр биреп чыкты.— Тирәнлеккә бик ашыкмагыз! Измә тыгызлыгын тиешле дәрәҗәгә җиткермичә ярамый. Газны да чыгарып бетерергә кирәк!..

Ул арада Ситниковка хәбәр иттеләр:

— Газ кимегәндә дә измәнең тыгызлыгы түбәнәя генә бара.

Рафаэль Хәмидуллин газсызландыру җайланмасы янына ничек киләсе иткәндер, нәкъ шул чакта электродвигательнең җиңсәсе өзелде дә чыкты. Двигатель әйләнә бирә, насос эшләми. Ничек шулай туры килгәндер. Ситников: «Газсызландыру процессын күздән ычкындырмагыз!»— дип кисәткән иде бит, югыйсә!?

Ә сеноманга шул гына кирәк: җиңеләеп калган балчык кире өскә чыга башлады. Куыкчыклар да, күзгә күренеп, артырга тотынды. Хәзер инде алар эреләнгән дә кебек. Газ килүе дә артты. Бераздан ул, насос аша үтеп, киредән коега туларга да күп сорамас. Артык көчәеп китсә, бөтен тирә-юньне кубарып ташларга да кыйбат алмый ул.

Рафаэль Хәмидуллин, җиң сызганып, бозык механизмга ябышты:

— Запас муфта бармы?

— Каян килсен инде?— дип, слесарь сорау белән үк җавап кайтарды.

Хәмидуллинның шәп ягы бар: бервакытта да югалып калмый ул. Бу юлы да әлеге мөшкел хәлдән чыгу әмәлен тиз тапты. Кадакта эленеп торучы шланг кисәгенә ишарәләде ул:

— Алып бир әле шуны!

Бер минут үтте микән — газсызландыру машинасы кабат эшләргә тотынды. Хәмидуллин, измә өстендәге күбек куыкларының азаюын күреп, елмаеп җибәрде.

— Хәзер, сабыр итеп кенә, аска төшә башласак та була,— диде.

Тирәнлеккә бик сак төшәргә кирәк иде. Ике йөз метрлап ара үткәч, комлы катлам бетте. Газ кимеде. Җиде йөз метр чамасына тирәнәйгәннән соң, измә тәмам тигезләнде. Сеноман белән ике ара йөз җитмеш биш метр калды. Димәк, тагын унбиш тапкыр тукталыш ясарга туры киләчәк. Ә тукталыш ясаганда, насослар тына, измә китми тора. Газ, «баш күтәрү» өчен, әнә шул тукталышлардан «файдаланып» кала ала. Тукталышларны мөмкин кадәр кыскартырга кирәк. Бораулаучылардан бер үк вакытта тизлек тә, саклык һәм төгәллек тә таләп ителә иде.

Ниһаять, сеноманлы катламның түбәсенә җиттеләр. Тагын да илле метрга төштеләр. Газ аны-моны сиздермәде. Ситников:

— Үтте бугай, җәмәгать!— дип, җиңел сулап куйды.— Котылдык.

Тик шатланырга өлгерми калдылар — казу коралы авыр балчык катламына барып терәлде, эшне дәвам итү мөмкин түгел иде. Нишләргә? Мондый сорауга җавапны кол-

лективтагы бер кеше генә бирә ала. Ә ул әлеге тирәнлектәге чуендай каты балчыкны юдыртып та, торба белән төеп тө «тыңлатып» булмаячагын белә иде. Кыен хәл. Белгечнең исемен дә әйтик: электр белән эретеп ябыштыру остасы Нурислам Арсланов ул. Балчыклар серен белүе — аның икенче һөнәре, ял сәгатьләрендә балчыктан сыннар ясарга ярата. Үзенең барлык танышларының балчык сурәтләрен иҗат итте инде ул. Сурәт ясауда исә дөнья рәссамнары кулланган балчыктан түгел, бораулау кораллары тирән катламнардан чыгарган сәер сыйфатлы балчыктан файдалана.

Әлеге коены казыганда да мең метрлы тирәнлектән торба «йозагына» эләгеп менгән каты токымны җыя барган иде. Кырып ала да вагонына кертеп куя торган иде. «Табыш»ны салкынча коры урында саклый. Ике атналык хезмәт вахтасы түгәрәкләнгәч, балчыкны Баулыга алып кайтып китә. Өендәге «иҗат лабораториясендә» исә Самотлор балчыгын, үзе генә белгән башка өстәмәләр кушып, тагын да ышанычлырак үзле измәгә әйләндерә. Сыннар ярылмасын өчен. Аннары төннәр буе сурәт ясый.

Нурисламның әлеге мавыгуын дуслары да хуплый, аңа, кулларыннан килгәнчә, ярдәм итәргә тырышалар. Кайчак хәтта, «сәнгать белгече»нә әйләнеп, аның иҗат җимешләрен тәнкыйть тә итәләр, киңәш бирәләр...

Әхәт Харисовның каты токымга бинаһая авыр корыч корал белән өзлексез бәргәләп торуына игътибар итеп, Нурислам мастерга эндәште:

— Юкка азапланасыз, бу токымга борау кирәк!— диде.

— Мин риза,— Харисов бораулау җайланмасын төшерергә кирәклеген аңлатты.— Әйдәгез, тәвәккәлләдек!..

Бөгелмәлеләр, үзләре башлаган эшне җиренә җиткереп тәмамлагач кына, иркен сулыш алып куйдылар. Сигез коелы чыганак нефть бирергә әзер иде!

• • •

Нижневартовскидан Мегионга барганда бетон юл Мега елгасына килеп чыга. Шактый араны елга яры буйлап үтәсең. Мега монда бик матур текә борылыш ясый. Борма турысындагы яр да кинәттән текә кыяга әйләнә. Кыя төбәсеннән аска күз салсаң, йөрәк «жу-у» итә. Тирә-юньдә — иксез-чиксез тайга. Ямь-яшел! Үзәнлекләрдә учаклар яна. Ял итүчеләр балык сөзә, шулпа кайната. Учакларның берсе — безнеке. Балык шулпасы авыз иткәч, кайберәүләр җыр сузып җибәрде. Мин исә читтәрәк йөрүче Ситниковка әллә кайчаннан бирле тел очымда йөргән соравымны биреп калырга ашыктым:

— Әйт әле, син теге сеноман белән көрәшергә тәвәккәлләгәндә ахырының ни белән бетәсен азрак чамалаган идеңме? Күңелең ышандымы?

— Юк,— ул икеләнеп тә тормады. Нәкъ теге вакыттагыча.— Әмма ул чакта барыннан да мөһимрәге кешеләрдә ышаныч тудыру икәнен белә идем.

— Ай-йай, малай, тәвәккәл икәнсең!

— Безнең эштә шунсыз ярамый. Мин ул чакта янгын чыгудан бик курыктым. Шуңа күрә башта янгынга каршы торырдай бөтен чараларны барлап тотындым. Инде безнең ысул челпәрәмә килсә, берләшмәнең коены томаларга, дигән әмереннән файдаланачак идек. Коены күмдерү планы кесәдә иде.— Инженер уйланып торды да дәвам итте.— Эшләнгән эшне каплап кую өчен инженер булуның кирәге дә юк. Шул хакыйкатьне аңлау җен ачуларымны китерде минем. Җимереп ташлаган өчен берәү дә берәүне дә гаепли алмый, янәсе, сеноман гына гаепле. Тирәннәнрәк уйласаң, без түгел, сеноман бездән куркырга тиеш бит...

Учак янындагыларның моңлы да, дәртле дә җыры инженерның бу сүзләрен хуплау булып яңгырый сыман иде...

## Дмитрий Табачник

# ГЕНШТАБНЫҢ ҮЗЕНДӘ...

Күптән түгел генә әле Киевта 1943—1945 елларны Ерак Көнчыгыш фронты штабының начальнигы булган, күренекле хәрби белгеч, генерал-лейтенант Федор Иванович Шевченко яши иде. Мин, аның белән күрешкән саен, Бөек Ватан сугышына, бу дәһшәтле елларда каһарманлык күрсәткән кешеләргә бәйле бик күп мәгълүматлар ала килдем. Берсендә Кызыл Армиянең Генеральный штабы турында сөйләшергә тотындык. Сүз иярә сүз китеп, С. М. Штеменконың истәлекләр китабына да «кагылдык». Китап Генштабның үзәге булган Оператив идарә эшчәнлеген дә яктырта. Федор Иванович Шевченко исә үзенең Генштабта, Советлар Союзы Маршалы Б. М. Шапошников кулы астында хезмәт иткән еллар турында аерруча горурланып искә ала. Бу хакта сөйләгәндә ул хәтта яшәреп киткәндәй була, карашлары яктыра, Генштабтагы дусларын санарга тотына, һәркайсын сурәтләп чыга. Арадан берсенә — дусты Шакир турындагы истәлекләргә Ф. И. Шевченко бигрәк тә озаклап туктала торган иде.

Шакир төгәллеге, тәвәккәллеге, эшне җиренә җиткереп үтәве ягыннан Генштаб хезмәткәрләре өчен үрнәк саналган. Аның хәрби эшне оста оештыра белүе, офицерларны гадел тәрбияләве, фикер йөртүенең киңлеге, укымышлылыгы да күпләрне сокландырган.

Федор Ивановичның «Шакир» дип, бик үз итеп мактаган кешесе турында мин җентеклəбрәк кызыксындым. Өлкән дустымның яраткан «Шакир»ы Генштабтагы Оператив идарәнең тәҗрибәле җитәкчеләреннән берсе, биш сугышта катнашкан, совет генералларының беренчеләреннән саналган Шакир Нигъмәтулла улы Гыйниятуллин булып чыкты. Федор Иванович дөньядан киткәч тә, мин каһарман турындагы мәгълүматларымны баетырга тырыштым. Күз алдыма Ватанына һәм халкына тугрылыклы хәрби җитәкче образы килеп басты.

...1942 елның язы. Фашистлар ябырылуыннан коткарып калынган Мәскәү әле һаман хәрбиләрчә, фронт яны шәһәре кебек яши. Урамнарда җыелмый яткан кар көртләреннән дары исе аңкый. Төннәрен көчле прожекторлар шәһәр күген капшап-капшап тора. Дошман әлегә әллә ни еракка куылмаган. Кич. Эңгер-меңгерне сискәндереп, җиңел автомобиль килеп чыкты. Машинаның балчыкка буялып беткән ишек-тәрәзәләре үк әтәге хәрби җитәкченең фронттан Мәскәүгә кайтканлыгын белдереп тора. Ставкага ярдәм сорап килүедер. Бәлки, үзен Генштабка чакырткannардыр, кем белә?!

Арткы утыргычта, чыннан да, инде шактый яшь яшәгән генерал Шакир Гыйниятуллин иде. Арыган. Йокысыз төннәр аның йөзенә кара күләгә салган, күзләре кызарып чыккан. Ул ачулы карашын Мәскәү урамнарыннан аерып ала алмый: «Сугышка кадәр гөр килеп торган урамнар, шат күңелле кешеләр белән тулы мәйданнар нинди хәлгә килде?!» Аның йөрәге чәнчеп-чәнчеп куя: хәрби кеше бит, ә дошман башкала капкасына ук килеп җитте...

Шакир генералның фронттан кайтып килүе. Кичен, гадәттәгечә, хәлне аңлату өчен, Генеральный штаб начальнигы маршал Б. М. Шапошников янына керәчәк ул. Аңа кадәр исә әйтәчәк сүзләрне ныгытып уйлап куясы бар. Һәммәсе кыска һәм аңлаешлы булырга тиеш. Борис Михайловичны ялыктыру килешмәс. Ул бит җитди авырый. Шул хәлендә дә эшләп йөри. Соңыннан, киңрәк итеп, Василевский белән сөйләшергә мөмкин...

Әмма маршал барын да тәфсилләп сөйләүне үтенде. Әңгәмә озакка сузылды. Төн уртасына кадәр. Ахырдан Шакир генерал, мәсьәләне чишү буенча, үзенең тәкъдимнәрен тезеп китте. Ниһаять, Шапошников, картадан аерылып, Гыйниятуллинга карады:

— Сез бик нык арыгансыз, Шакир Нигъмәтуллович,— диде.— Хәтта картаебрак

та киткәнсез кебек. Күз кабакларыгыз җилсенгән. Йокламагансыз, димәк. Ярамый, ярамый! Болай озакка чыдамассың, туган. Сакланырга кирәк!— Борис Михайловичның күзләре сагыш белән тулы.— Сезнең сәламәтлек какшаса, мин кем белән эшләрмен? Барыгыз! Сезгә тугыз сәгать йокларга боерам. Хәзер үк йокларга яткан булыгыз!..

Генштаб начальнигыннан чыккан генерал, ял бүлмәсенә керүгә, караватка ауды. Итекләрен көчкә салып өлгерде, керфекләре йомылырга тора иде инде. Тик шулай да тиз генә йоклап китә алмады әле ул. Шапошниковның кешеләргә миһербанлылыгы турында уйланып ятты: «Үзе дә авырый бит. Бу хәлендә шундый авыр йөкне күпмегәчә тартып бара алыр ул?» Бераздан Шакирны үткәндәге якты хатирәләр биләп алды...

Аның балачагы Бөгелмә өязендә, бинһая авыр елларда узды. Шакир унбер яшендә үк батрак хезмәтен, хуҗа типкесен байтак татыды. Беренче тапкыр әтисе белән Бөгелмә ярминкәсенә барганда аңа инде унбиш тулган иде. Монысы 1910 елда булды. Сабан сөрергә чыккан яз да хәтердә. Әнисенең шул чагында шатланганнарын Шакир мәңге онытмас кебек. Бите-күзе көлә, авыр эштә ярганалып беткән кулы белән улының чәчен, битен-күзен сыйпый. Баласының иген кырына аяк басуына шул кадәр шатланган иде әнисе!

1915 елны исә Шакирны империалистик сугышка озаттылар. Яшьлек — юләрлек, дип, белми әйтмәгәннәр. Шакир ул чакта, сугышның ни икәнен дә белмичә, сәфәр чыгуына шатланган иде бит! Хәерчелеккә баткан авылдан ычкыну — үзе генә дә нинди зур сөенеч ләбаса! Тырышып хезмәт итсәң, унтер-офицер булсаң, ефәк чуклы погоннар тагып җибәрсәң, әй!

Яман яу кырында ике еллап сугышты ул. Очсыз-кырыйсыз тоелган шул юлларда Шакир офицерларның солдат язмышындагы хәлиткеч ролен аңлады. Патша офицерларының солдаттан көлүләре, аны изүләре, мыскыл итүләре Шакирның тәмам үзәгенә үткән иде. Ниләр генә күрмәде ул: көннәр буе тездән су эчендә ятулар, патронсыз винтовка белән һөҗүмгә күтәрелүләр, коралдашларның һәлакәте һәм мәетләр белән капланган яу кырлары. Аннары — госпиталь...

Госпитальдәге хәлләр дә коточкыч иде. Палаталарда ыңгырашу авазы эленеп тора. Җәрәхәтләрдән авыр ис тарала, ике яралының берсе дөньядан китеп бара. Шакир Идел буенда яшәгән рус егете белән танышты. Ул газ белән агуланган иде. Өзлексез кычкыра. Аның акылына зәгыйфьлек килгән. Өстенә карарга авыр. Хәтта больница стеналары да аны кызгана сыман...

Шушындый бәхетсезлекләргә дучар ителгән солдатлар тормышына Февраль революциясе яшен ташы атылгандай тәэсир ясый. Митинглар башлана: кем ни тели, шуны сөйли. Шакир Гыйниятуллин исә бу чорда политик яктан ныгып өлгергән иде инде. Октябрь вакыйгалары якынлашканда, ул чын дөреслекнең большевиклар ягында икәнлегенә, бары тик аларның гына халык хакына көрәшүенә ышанган иде.

1917 елның ноябрь башында Шакир, яраларын аннан-моннан җөйләп, туган якларына әйләнеп кайта. Монда ул Бөек Октябрь социалистик революциясе өчен көрәшкә кушыла. Казан губернасында Совет власте урнаштыруда актив катнаша. Декабрьдә инде Шакир — Кызыл гвардия солдаты. Ул эшче һәм крестьян улларын хәрби хезмәткә өйрәтә башлый. Бу өлкәдә Шакир кебек фронт юлы үткәннәр алтынга алыштыргысыз саналган. Өстәвенә, егетнең табигатьтән бирелгән командирлык сәләте дә көчле. Һәм 1918 елның февралендә Шакир Гыйниятуллин үз теләге белән Кызыл Армиягә языла. Күңел түрендә балачак хыялы канатлана: «Бәлки әле кызыл командир булырмын!»

Шакир Гыйниятуллин бу юлны бик дөрес сайлаган. Хәрби хезмәт аның бөтен барлыгын биләп ала. Егет бу хезмәткә гомеренең соңгы минутынача тугры кала. Сүз уңаенда әйтеп китәргә кирәк: Совет Армиясе хәрби начальникларының язмышына хас бер уртак сыйфат бар. Армияне оештыру, булдыру артыннан йөргән беренче белгечләр аңа мәңге тугрылык саклыйлар. Бу буын безнең армиягә тиңдәшсез батырлык үрнәге бирде, Бөек Ватан сугышында җиңеп чыгардай полководецлар үстерде. Илебез һәм Армиябез тарихы аларны мәңге олыларга, онытмаска тиеш!

Гражданнар сугышы елларында Шакир Нигъмәтуллович уннарча бәрелешләрдә катнаша: ак чехлар, дутовчылар, колчакчылар белән йөзгә-йөз килә; Россиянең көньягында да, Украинада да, Төньяк Кавказда да була. Командир ышанычлы чыныгу ала, кавалерия дивизионы белән дә, кылыччылар эскадроны белән дә җитәкчелек итә. Аннары аңа кавалерия полкын тапшыралар. Һәм аның кавалеристлары, нинди генә һөҗүмгә катнашсалар да, таң калырлык батырлыклар күрсәтә. Кылган каһарманлыклары өчен 1919 елда ук Шакир Гыйниятуллин Советлар республикасының ул чактагы иң зур бүләгенә — сугышчан Кызыл Байрак орденына лаек була. Шул елны Шакир большевиклар сафына да алына.

Аның гади солдаттан полк командиры булып өлгерүе өчен нибары ике ел вакыт җиткән. Әмма еллары нинди бит аның! Гражданнар сугышының коточкыч бәрелешлә-

рендә нинди генә хәлләр кичерергә туры килми. Ул үзе иптәшләренә, арада иң хәтәре Төркестан һәм Фирганә фронтлары булды, дип сөйләгән. Басмачыларның мәкеренә һич төшенерлек түгел икән. Таҗикстандагы, Кара Ком чүлләрендәге бәрелешләр 1931 елга кадәр дәвам итә. Гыйниятуллин җитәкчелегендәге полк Җунаид хан, Мәдәмин бәк бандаларын һәм уннарча вак бәкләрнең гаскәрен тар-мар итә. 1920-27 еллар эчендә Шакир, ат өстендә, 80 мең чакрымлап хәрби юл үтә. Сиксән мең чакрым! Бу бит — каһарман егет Җир шары билдәмәсен — экваторны ике тапкыр ураган дигән сүз! Данлы кавалеристның бу елларда күрсәткән тапкырлыгы «Краснознаменный Туркестанский» дигән китапта бөтен тулылыгы белән тасвирлана, Шакир командир анда илнең иң мәртәбәле хәрби җитәкчеләре белән бер рәткә куелган.

Төркестан сугышы — фронтсыз һәм тылсыз, икмәксез һәм сусыз сугыш. Юлсызлыктан җәфалана-җәфалана көне-төне алга бару. Эссе. Ком. Чүл шартларында сугышу. Хәтта пулеметлар, эсселеккә чыдый алмыйча, атудан туктап-туктап кала, әмма Гыйниятуллин кавалеристлары, кылыч уйнатып, алга баруларын дәвам иттерәләр. Сугышчы өчен моннан да четереклерәк сынауның булуы мөмкин түгел кебек. Шул юлда Шакир Гыйниятуллин белән бер отрядта сугышкан коммунист, отставкадагы подполковник Александр Кондратенконың истәлекләреннән бер генә эпизод белән танышыйк.

«...Тау-ташлар арасындагы ермаклар, текә сырт өстендәге сукмаклар буйлап алга барабыз. Сукмакка кергәндә ат өстеннән төшәбез. Кайчак ишәккә атланырга туры килә. Аның бит шул тар сукмагы да ишелергә генә тора. Бик эссе булганга, күбесенчә төнлә йөрибез. Иң кыены — су юклык. Отрядның йөгендә, шәхси кораллар белән су савытларыннан башка, бер нәрсә дә юк. Суны, ишәк сыртына салып, күн капчыклар белән 120—170 чакрым ераклыктан алып-алып киләләр. Коелар очрый очравын, тик бандитлар аларны агулап киткән. Кайчак яшь солдатлар, сабырлыкларын җуеп, арыктагы суны эчә. Анда исә күзгә күренми торган вак сөлекләр бар. Үңәчкә ябышып бүртәләр дә кешене үтергеч дәрәҗәдә газаплый башлыйлар.

Бу юлда солдат аяклары кырылу гына түгел, хәтта атларның тоягы ашалып бетте. Юлның соңгы чакрымнарын үткәндә кайберәүләрне, носилкага салып, күтәреп барырга туры килде. Хәрби сизгерлек, һәр адымда сугышчан хәрәкәт башларга әзер тору — болары инде тулаем командирыбыз Шакир Гыйниятуллин җаваплылыгында иде...»

Ул елларда Советлар Союзы Герое дигән исем бирү гамәлгә кертелмәгән әле. Аеруча батырлык күрсәткән кешеләргә шәхси хәрби корал, Реввоенсовет Грамотасы, кайчак хәтта кием-салым бүләк итәләр иде. Хәзерге Алтын Йолдызга тиң булырлык бүләк итеп Республиканың Кызыл Байрак ордены билгеләнде. Шакир Гыйниятуллинның күкрәген Бохара Халык Республикасы тәкъдиме белән бирелгән ике (!) Кызыл Байрак ордены бизи. Ул чордагы орденнар... Хәер, бу хакта мин хәрби хезмәтен утызынчы елларда башлаган һәм Төркстан хәрби округы гаскәрләренең командующие булган генерал-полковник С. Е. Белоножко сүзләрен китерим:

«...Мин бик яхшы хәтерлим,— дигән ул яшь солдатларга.— Ул чактагы орденга ия булган сугышчыларны халык ифрат зурлый иде. Аларның абруе гаҗәп иде. «Орденлы» дигән билгеләмә үзе генә дә аның иясен кыю, тугрылыклы, халык һәм ил язмышы өчен җанын аямаучы икәнлеген күрсәтеп тора иде...»

Шакир Гыйниятуллин Гражданнар сугышы белән Бөек Ватан сугышы арасындагы елларны хәрби осталыкка өйрәнү, уку өчен файдаланды. Үзенә тапшырылган полкны, аннары бригаданы һәм, ахырдан, дивизияне хәрби маневрларда, кырда үткәрелә торган тактика дәресләрендә чыныктырды. Барыннан да күбрәк үзе өйрәнде ул. Сугыш юлында күргәннәрен теория белән ныгытырга кирәк иде аңа. Шуны аңлап, ул Фрунзе исемендәге Хәрби Академияне «бик яхшы»га тәмамлый. Аннан соң 1936 елда, Генштабның яңа гына ачылган Академиясенә, беренчеләрдән булып, тагын укырга керә.

Әлеге Академия ачылганда, Шакир Гыйниятуллинга бригада командиры вазифасы йөкләтелгән була инде. Коралдашлары аңа шул эшендә тыныч кына хезмәт итәргә, яңадан укып азапланмаска киңәш итәләр. Янәсе, армия сафында үсү, тагын да зуррак дәрәҗәгә ирешү җиңелрәк. Әмма Шакир Гыйниятуллин сугыш кануннарының иң тирәнгә яшерелгән серләрен белергә тели һәм тагын укырга тотына. Генштаб Академиясенең хәрби уеннарында, команда-штаб өйрәнүләрендә Шакир Гыйниятуллинның хәрби таланты бөтен тулылыгы белән ачыла. Утызынчы еллар азагында аны хәрбиләр даирәсендә, РККАның Генштабында гаять тәҗрибәле, киң эрудицияле, югары абруйлы җитәкче итеп таныйлар. Аны Генштаб начальнигы, күренекле хәрби теоретик, совет полководецларының аксакалы маршал Б. М. Шапошников та югары бәяли. Шакир Гыйниятуллинның Генштабтагы Оператив идарәдә эшли башлавы да Шапошниковның игътибарлылыгына бәйле...

Шакир Гыйниятуллин бу үтә җаваплы посттагы эшләрен дә, кавалериядә гаҗәп оста җитәкчелек иткән кебек үк, элекке «үҗәтлеге» белән дәвам иттерә. 1940 елны Кызыл Армиядә беренче тапкыр «генерал» исеме кертелә. Беренче совет генералларының



*СССР Оборона Халык Комиссариаты һәм Генераль штабы җитәкчеләреннән бер төркем Кызыл Мәйданда. Сулдан беренче — генерал Гыйниятуллин Ш. Н., икенче — генерал Карпоносов А. Г., уңнан беренче — генерал Шевченко Ф. И., уңнан өченче — генерал Тихомиров П. Г.*

исемлеге «Красная звезда» газетасының май-июнь ае саннарында чыга. Алар арасында Гыйниятуллин фамилиясе дә бар. Шунда ук генералның фотосурәте дә бирелгән.

Генерал Гыйниятуллин Оператив идарәдә эшен дәвам иттерә. Ни соң ул Оператив идарә? Генштабны еш кына «армиянең мие» дип йөртәләр. Шул атама белән килешкән очракта Оперидарәне «Генштабның йөрәге» дип бәяләргә туры килә. Бөек Ватан сугышының бер генә операциясе дә Оператив идарә эшчәнлегеннән башка узмады. Сорауны тагын да куерта төшәргә мөмкин. Шакир Гыйниятуллин анда нишләгән соң?

Бу сорауга төп-төгәл җавап бирү өчен мин СССР оборона министрлыгы Үзәк архивында сакланган характеристиканы китерәм. «Бөек Ватан сугышы чорында Ш. Н. Гыйниятуллин Генштабтагы Оператив идарәнең җаваплы җитәкчелек эшендә РККА Генеральный штабының һәм Верховный Башкомандование Ставкасының мөһим хәрби бурычларын үтәде, зур хәрби операцияләр оештыруда катнашты». Бу кыска бәяләмәнең һәр сүзе ни аңлатканны тою авыр түгел. Бу — адәм баласы чыдамаслык авыр хезмәт, йокысыз төннәр һәм, әлбәттә, Ватанның зур бүләкләре. Дөрес, аның исеме Башкомандующийның рәхмәт сүзләре теркәлгән приказларга кертелми. Шакир Гыйниятуллин Европаны фашизмнан азат иткән гаскәрләр башында да йөрми. Мәскәүдәге күз камаштыргыч салютлар вакытында андыйларның исеме телгә алынмый. Әмма шуны белергә кирәк: әгәр Генштабта тәүлекләр, айлар, еллар буе өзлексез эш кайнап тормаса, анда Шакир кебек укымышлы, сизгер фидакарьләр шөгыльләнмәсә, җиңү салютын күрү дә мөмкин булмас иде.

Генштаб хезмәткәрләренең эшчәнлегенә караган күп кенә язуларга «аеруча яшерен» тамгасы сугылган. Шунлыктан Шакир Нигъмәтулловичның ниләр башкарганлыгын төгәл тасвирлау әлегә җиңелдән түгел. Сугышның беренче этабына караган документлар белән танышу бигрәк тә кыен. Безнең бу каһарман турында шуны гына әйтергә мөмкин: Шакир Гыйниятуллин Генштаб Оператив идарәсендәге юнәлеш начальнигының урынбасары һәм аннары башлыгы булган, бераз вакыт бөтен идарәнең начальнигы вазифасын да үтәгән. 1942 ел башында ук ул, Генштаб хезмәткәрләре арасында беренчеләрдән, хөкүмәт бүләгенә лаек табыла. Аерым басым ясап әйтергә кирәк: ул елларда Генштабтагы командирларның бик азына гына әлегә андый бүләкләр. Шунлыктан 1941 елгы һөҗүмнәр өчен орден алу Шакир Нигъмәтулловичка бигрәк тә күңелле булгандыр. 1942 елның 26 маенда Кремльдәге бу шатлыклы вакыйгадан соң бүләкләнүчеләр фотога төшәләр. Шакир Гыйниятуллин Калинин белән бер рәткә баскан. Шунда ук Генштаб начальнигы А. М. Василевский, Генштабның хәрби комиссары Ф. Е. Бойков һ. б.

Бу вакытта Гыйниятуллин Генеральный штабның икенче дәрәҗәдәге аеруча мөһим постында эшли. Ул — Генштабтагы Оператив идарә начальнигы. 1943—1946 елларда Генштаб начальнигы постында Армия генералы С. М. Штеменко торган. Аның «сугыш елларындагы Генеральный штаб» исемле истәлекләр китабында мондый юллар бар: «А. М. Василевскийның Генштаб начальнигы постына күчерелүе (Б. М. Шапошниковның каты авыруы сәбәпле — Автор) Оператив идарә эшендә күп катлаулылыклар китереп чыгарды. Монда ярты ел эчендә биш-алты начальник алмашынды. Шул хәл аркасында эштә киеренкелек сизелә башлады. Тәгәллек җитенкерәмәс булды. Бер-ике ай эчендә генә бу җаваплы хезмәтне аңлап бетерерлек түгел, шунлыктан начальникларда үз-үзләренә ышаныч та була алмый. Оператив идарә начальнигы, кирәге чыгуы ихтимал дип, үз янында төрле юнәлешләрнең начальникларын «бәйләп» тота, алардан әледән-әле белешмәләр сорый. Ставкага доклад белән кергәндә дә шул мәгълүматлардан гына файдалана. Мондый шартларда, үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, Идарә ишек төбендә күп кеше җыела. Алар билгесезлектән, үзләрен ни көтүен белмәүдән җафалана, кайберәүләре исә шунда да эшләп азаплана иде...»

Шакир Гыйниятуллин Генштабның Оператив идарәсе начальнигы булып нибары ике ай эшләгән. Ике ай... Ник алай гына? Бу посттагыларны нигә бик еш алмаштырганнар? Бу сорауларга минем кадерле танышым Федор Иванович Шевченко бик нигезле җавап бирде:

— Бу урындагы кешегә хәрби начальникка хас талант кына җитми иде. Шуңа өстәп, бик күп ярдәмчел сыйфатларга ия булуың да мөһим: азрак политик та, бераз дипломат та, зур начальникларга яраклаша белү осталыгы да — әле тагын әллә ниләр кирәк. Сугыш шартлары исә бу сыйфатларга булган бәяне бермә-бер арттырды. Хәзер Шакир Нигъмәтулловичны «Верховный» белән уртак тел таба алмауда гаепләп тә булмый. Аңа ошау өчен ни генә кирәкмәс, аларны кем исәпләп бетерсен?! Кайчак синең хәбәр итү темпы ошамый, кайчак — сөйләү тизлегең, тавышыңның яңгырашы. Нишләрең бар!? Вакыты нинди бит аның. Кырык икенче елның җәе. Тоташ чигенүләрдә кемне генә гаепләргә белми аптырадылар. Мәшһүр 227 нче приказ бирелгән көннәрне генә алыйк — «Бер адым да артка чикмәскә!» дигән приказ. 1942 елның июль азаклары иде. Верховный Башкомандующий Оператив идарәнең ул чактагы начальнигы П. Г. Тихомировтан совет гаскәрләренең Харьков янындагы җиңелү сәбәпләрен аңлатуны сорый. И. В. Сталин үзе алдан ук әйтеп куя, бу бәрелешләрдә һәр төрдәге командованиеләр зур-зур хаталар җибәрде һәм башкалар шул ялгышларны кабатлый бирделәр, ди.

Тихомиров тирән анализлар белән директива проектын әзерли. Аңа С. М. Штеменко да, башка күп офицерлар да булыша. Фронт мәгълүматларыннан да, югалтуларыбыз турындагы хәбәрләрдән дә, төрле приказлардан да — һәммәсеннән файдаланалар. Кыскасы, саф-дөресен теркәп бирмәкче, хәлнең шәп-шәрә сурәтен тасвирламакчы булалар.

— Нәтиҗәдә нәрсә килеп чыкты дип уйлыйсыз?!— Ф. И. Шевченконың йөзе караңгыланып китте.— Кудылар Тихомировны. Бөтенләйгә. Генштабта аңа урын калмады. Ленинград фронтына чыгып китте. Генштабтагы ифрат талантлы башка хезмәткәрләрнең дә күбесенә шундый ук кырыс язмыш эләкте.

С. М. Штеменко истәлекләрендә әйтелгәнчә, Сталин әледән-әле кабатлап торган: «Генштабта тупланган тәҗрибәне, әнә, фронтка барып тормышка ашырсыннар!»— дигән. Генерал А. Г. Карпоносов, А. И. Антонов кебек бик талантлы начальниклар да шул ук язмышка дучар ителә.

— Шакир белән дә шул ук хәл,— дип аңлатуын дәвам итте Федор Иванович.— Аның, Оператив идарә начальнигы буларак, һичнинди җитешсезлеге дә юк. Ниндидер җайсыз чакка туры килгән дә — вәссәлам. Табигый сәләткә ия, ике хәрби академия тәмамлаган, өстәвенә, Шапошников кебек мәшһүр остаздан өйрәнгән генералның әлеге хезмәткә туры килмәслек кимчелеге була алмый!..

Шулай да Шакир Гыйниятуллин Генштабның Оператив идарәсе начальнигы постыннан алынуын шактый авыр кичергән. Әмма Башкомандующийның холкын тирәннән аңлаганга күрә, үпкәләвен һич тә сиздермәскә тырышкан. Баштанаяк яңа эшенә чумган. Башкача була да алмый — сугышның кайнаган чагы.

Һәр хәрби эшлекленең бары тик аңа гына хас, яраткан бер хезмәте бар. Гыйниятуллинның шундый эше итеп Генштабтагы офицерлар корпусын җитәкләүне, махсус подразделение белән командалык итүне санарга кирәк. Бу оешманың ни икәнлеген белү өчен без кабат С. М. Штеменко китабын күздән кичерик. Анда мондый юллар бар:

«...Генеральный штабтагы офицерлар корпусы дигән нәрсәгә дә тукталмыйча уза алмыйм,— дип яза ул.— Бу оешма 1941 елда төзелде. Сугышның ифрат авыр барган беренче айларында Генштабка фронттан килгән хәбәрләр бик сыек иде. Без кайчак, үз эшебезгә караганда, дошман хәлен тәгәлрәк белә идек. Мондый кимчелекне бераз шомартыр өчен операторлар үзләре фронтка очалар, кайберләре шул юлда һәлак та

була иде...» Бу исә квалификацияле кадрларның азаюына китерә. Шунлыктан, Генштабта фронт белән турыдан-туры элемтә тәэмин итүче аерым группа булдырыла. Ставка бу группаны Генштабның офицерлар корпусы дип атый. «Офицер» атамасы, Кызыл Армиядә беренче башлап, менә шунда телгә керә.

Корпус белән җитәкчелек генерал-майор Н. И. Дубининга тапшырыла. Бераздан аны Оператив идарәнең ветераны генерал-майор Шакир Гыйниятуллин алмаштыра. Политбүлек эше буенча урынбасар итеп генерал-майор Ф. Т. Перегудов билгеләнә.

Генштаб офицерлары башта, махсус бурыч алып китәләр дә, фронтта шуны үтәгәч, Мәскәүгә кайталар. Соңрак бу кайтып-китеп йөрүләр туктатыла, һәр фронтта, армиядә, ә кайбер юнәлешләрдә, хәтта корпус һәм дивизияләрдә дә Генштаб офицерлары даими тора башлый. Алар гаскәрләрнең хәлен тикшерә, сугыш-көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин ителеш дәрәҗәләрен ачыклый һәм барысы турында да Генштабка җиткереп тора. Бу хәбәрнең төгәллеге нык таләп ителгән. Офицер бары тик үз күзе белән күргәнне генә Генштабка ирештерергә тиеш булган. Аларның күбесе коточкыч бәрелешләргә дә дучар ителә һәм мондый очракларда бу офицерлар тиңдәшсез батырлык үрнәге күрсәткән. Фронттагы хәлләрдән чыгып, алар бик мөһим нәтиҗәләр ясыйлар, Генштабта зур мәсьәләләр күтәрәләр. Бу корпус офицерлары Генштаб өчен яу кырында чыныккан кадрлар чыганагы булып та санала. Аларның күбесен, кирәк булган саен, аппаратка эшкә чакырып алалар.

1943 елны офицерлар корпусының эшчәнлеге бераз кечерәя төшә. Бу чорга инде фронтларда тәҗрибә ныгый, эш билгеле ритмда бара башлый һәм әлеге офицерлар Оператив идарә составына кертелә. Чехословакия, Польша, Румыния милли армияләре формалашканда һәм сугышчан адымнарын башлап җибәргәндә дә Генштаб офицерлары билгеле бер роль уйныйлар. Кыскасы, бу офицерлар башкарган намуслы, зур хезмәт күптәрле дәлилләр белән раслана...»

Һәм менә шул бик кирәкле, үзе ифрат четерекле, үзе нечкә, үзе катлаулы һәм авыр эшнең башында, сугыш тәмамланганчы, Шакир Нигъмәтуллович тора. Бу фидакарьлеге өчен аңа Ленин ордены, өч Сугышчан Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары һәм Монголиянең Котып Йолдызы ордены бирелә.

Сугыштан соң Шакир Гыйниятуллинның сәламәтлеге кинәттән какшый башлый. Күрәсең, сугыш чоры киеренкелегеннән ябышып калган авырулар үзен сиздерергә тотына. Сталин кушуы буенча, Генштаб тәүлек буе эшли. Офицерларның эше иртәнге өчтә-дүрттә генә бетә. Шул ук тәртип әле сугыштан соң да бик озак дәвам итә. Гыйниятуллиннан унөч (!) яшькә яшьрәк Штеменко да үзенең истәлекләрендә болай яза: «...Без иң соңгы көчебез беткәнче эшли идек. Чөнки, юк кына хата өчен дә, һичнинди шәфкать күрсәтелмәячәге көн кебек ачык иде. Мондый киеренкелеккә кайберәүләр чыдый алмады. Сугыштан соң күпләр, яшьләре тулмас борын, запаска китте.»

Гыйниятуллин китми. Ничек китәсең? Эш — муеннан: яу кырларын иңләгән армияләр өйгә кайта, аларны урнаштырырга кирәк! Сәламәтлек кенә һаман начарлана бара. Биш сугышта йокысыз үткәрелгән йөзләрчә төннәр, армия шартларында узган утыз еллык гомер — уенмыни?! 1946 елның 3 апрелендә Шакир Нигъмәтуллович Гыйниятуллин вафат була. «Красная звезда» газетасына басылган матәм белдерүендә мондый юллар бар: «... Без көчле рухлы, сугышчан генерал, нык холыклы большевик һәм шәфкатьле иптәшебез белән хушлашабыз. Ул үзенең якты гомерен бөтенләе белән Ватанга, Ленин партиясе эшенә багышлады...» Некрологка СССР Маршалы А. М. Василевский, армия генераллары А. И. Антонов, М. В. Захаров, С. М. Штеменко һәм башка күренекле хәрби начальниклар кул куйган.

Татар халкының гына түгел, бөтен илебезнең горурлыгы булырдай каһарманның якты истәлеге буыннан-буынга яңартылып торырга тиеш. Чөнки андый шәхесләрнең язмышы — безнең гомум тарихыбызның да, бүгенгебезнең дә, киләчәгебезнең дә аерылгысыз бер өлеше ул.

*Киев шәһәре.*

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

## Назыйм Ханзафаров

# ВАКЫТ ИЛӘГЕ — ВАК ИЛӘК...

Халык әйтсә хак әйтә шул... Берәр нәрсә турында бәхәс куерып китсә, дөнья күргән абзыйлар әңгәмәне «озын сүзнең кыскасы — киләчәктә күрербез» дигәндәй очлап куялар. Бу инде, хакыйкатьне вакыт ачыклар, дигән сүз... Бүгенге үзгәрешләр яктылыгында рухи мирасыбызны яңадан барлаганда әлеге зирәк сүзләр хәтергә төшә. Шөкер, бик көттереп, әлеш-әлешләп булса да, хакыйкать ачыклана бара. Шагыйрь әйтмешли, якутлар табыла вакыт белән.

Мирасны яңача бәяләү, һәрнәрсәне үз урынына утырту зарурияте методологик принциплар, яңа концепцияләр нигезендә эш итүне сорый. Дөресен әйткәндә, әле ул принципларны булдыру проблемасы үзе дә көн тәртибендә тора. Ләкин, шулай булуга карамастан, илдәге революцион яңарышның үзәк концепциясенә таянып, рухи мирасны яңача бәяләү мөмкинлеге инде ныграк ачыклана бара.

Безнеңчә, әлеге эштә ышанычлы маякларның берсе — бәяләмәләрдә гомумкешелек кыйммәтләренә алдынгылыкны бирү, гомумкешелек мәнфәгатьләренә йөз тоту.

Сыйнфыйлыкны «кискенләштерү», аңа артык басым ясап, гомумкешелек мәнфәгатьләрен читтәрәк калдырып фикер йөртү заманнары бүген инде артта калды. Мәгълүм булганча, социализмның асыл идеалы — кешеләрне кешеләргә каршы кую түгел, кешеләрне бәхетле итү.

Яңача фикер йөртүне куәтләгәндә М. С. Горбачев бу мөһим тезиска аеруча басым ясап болай ди: «Мин инде ничектер әйткән идем: үзгәртеп кору казанында бөтен җәмгыять яңадан коела. һәм аннан тагын да көчлерәк, ныграк булып чыга, аның демократик, гуманлы потенциалы тагын да киңрәк ачыла — бигрәк тә кеше интересларында ачыла».[1]

Үткәндәге бәяләмәләребезгә яңа заманның шундый карашлары нигезендә игътибар итсәк, элекке хаталарыбыз байтак икәнен күрербез. Бу хаталарның нинди булуын аңлар өчен, аерым алып, драматургиябезгә мөрәҗәгать итик.

Табигате белән бөек гуманист, иҗаты белән гаять халыкчан, чыгышы ягыннан «ярлылар»дан булмаган Мирхәйдәр Фәйзи иҗаты бу яктан аеруча гыйбрәтле. Ничәмә еллар буе аның «Урал суы буенда» дигән пьесасындагы «чатаклыклар» турында язып килгәнбез. Имеш, автор сыйныфларны аера белми, иллюзияләр дөньясында яши...

Әлеге әсәрне бүген укып карасак, гаҗәп хәлгә тап булабыз: М. Фәйзи 1917 елда язган бу пьесасында хәтта кооперация мәсьәләсен дә бүгенгечә аңлаган түгелме? Сыйныфлар — мәхәббәт — гаилә проблемасын да ул чын гуманистларча хәл иткән ләбаса. Геройларның мондый яшәешен ул табигый нәрсә дип саный. Шуңадыр һәртөрле уйдырмаларга корылган гаепләүләрне мөмкин булганча кире кага.

Революциягә кадәр үк бөтен йөрәге белән ярлы халык, эшче-крестьян ягында торган М. Фәйзи илне социалистик үзгәртеп коруны «үзенчә»— гуманистларча аңлады. Яңа, бәхетле тормышны ул «Урал суы буенда» драмасындагычарак күз алдына китерде. Алпавыт кызын крестьян егетенә кияүгә чыгарып, мал-мөлкәт мөнәсәбәтләреннән югары күтәрелгән мәхәббәтне, андый гаиләнең бәхетле тормышын драматург түбәндәгечә күрде.

«З и ф а . Күңелле тормыш, валлаһи! Матур кыр, таулар, күлләр... Табигать кочагында, үзеңнең сөйгәнең белән бергә, үз эшеңне үзең дус кына, тыныч кына эшләп яшәүдән дә кү-

---

[1] Горбачев М. С. «Вашингтон пост» газетасы һәм «Ньюсуик» журналы сорауларына җаваплар.— «Социалистик Татарстан» газетасы, 1988 ел, 24 май.

нелле ни бар? Моннан да зур тагы нинди бәхет булыр? Белмиләр бу тормышта нинди тәмнәр барын, күрмиләр бу тормышта нинди ямьнәр барын! Шушы саф һаваны иснәп йөрүе генә дә ни тора. (Иснәп). Тереклек дәвасы бу... (Куыш тышына чирәмгә ашъяулык җәеп, чәй урыны хәзерли башлый). Авыл халкының тормышын агартырга дигән теләгем нинди җимешләр бирә башлады. Мин килгәндә берәү дә юк иде, хәзер унөч кешедә сепаратор бар. Калыплап ясап куйган ап-ак майлары күзләрнең явын алып торалар. Безгә ияреп никадәр кеше карбыз-кавын чәчте. Тырмаларга да гел хатын-кыз гына утыра башлады. Менә озакламый потребитель кибете ачалар. Акрынлап алдагы ниятләремә дә җитәрмен, авыл тормышына айлар тудырырмын»[2].

Аныңча, күңелле тормыш булдыру өчен, кешенең табигый теләкләренә киртә куймау кирәк. Фән-техника, культура казанышларын авылга кертү, хатын-кызларны ирләр белән тигез хокуклы итү, ярлы белән бай арасындагы сословиячелекне бетерү, дини хорафатлардан арыну, тырышып эшләү фарыз. Зифа белән Әхмәт нәкъ менә шул киртәләргә каршы көрәшәләр, җиңәләр һәм менә дигән тормыш башлап җибәрәләр, башкаларга үрнәк күрсәтәләр.

Әмма мондый карашларны 1922-1923 еллар тәнкыйте инде кабул итәргә теләми. Шуңа ачынып һәм күпмедер чигенергә мәҗбүр булып, М. Фәйзи көндәлекләрендә болай дип яза: «Уфа халкы «Урал буенда»ны тормыш картинасы түгел, дип гаеплиләр. Ә шуны язуга сәбәп булган Гайшә ханым, «Зифа» имзасы белән хат язып, мине рухландыра. Хыялда тудырган тибымны тормышта күрсәтеп күңел көчемне баета».[3]

30 елларга килсәк, без тагын да аянычрак хәлләр күрәбез. Мәсьәләгә якынаеп, шул дәвердәге комедия әсәрләренә игътибар итик. Иң элек бу елларның көлү әсәрләрендә «корылык» афәте күзгә ташлана. Репрессияләр көчәю, сатирик жанрларда язарга кыюлыгы җиткән бик күпләрнең әдәбият мәйданыннан алынуы, көлү сәнгатенә карата нигезсез таләпләр куюм, сатирикларны коточкыч гаепләүләр — болар һәммәсе комедиографиянең бик нык зәгыйфьләнүенә китерде. Әдәбиятта бай төсмерле көлү традицияләре югалып калды, жанр ярлыланды. Драматургиядәге көлү, бигрәк тә заман темаларына караган комедиография, үзен декларатив, агитацион кысалар белән чикләргә мәҗбүр булды. Тик фольклор мотивларына нигезләнеп язылган аерым әсәрләр генә («Хуҗа Насретдин», 1939, Н. Исәнбәт) мондый афәтләргә бирешмәскә омтылуны сиздерәләр.

Бу югалтуларның сәбәпләре ачык. С. Хафизов язганча:

«Утызынчы еллар өскормасына нәкъ менә фәнни принцип җитмәде, вульгар социологизм, догматизм, шәхес культы кебек субъективизм йогынтысында рухи тормышта зур хаталар ясалды, җитди югалтулар булды. Әле бүгенге көннәрдә дә без бу югалтуларның күләменә, асылына һәм сәбәпләренә төшенеп җитә алмыйбыз».[4]

Чыннан да, заман җитешсезлекләренә, шул исәптән, сталинизм золымнарына да «бәйләнүчән» чын сатира һәм юмор бу елларда мәйданнан сөрелде. Әдәби тәнкыйть тә сатираның булган кадәр тәҗрибәсен гомумиләштереп җитди анализлаудан читләште. Шуңа күрә дә сатира турында һәртөрле субъектив фикер куертулар көннән-көн көчәя барды. Андый карашлар еш кына авторларны идея-политик яктан гаепләүләргә барып чыкты. Менә шундый шомлы вакытта әлеге проблемаларны хәл итү кирәклеген кузгатучыларның берсе, үзе дә кыю һәм талантлы сатирик, Әхмәт Фәйзи булды. Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Коммунист» газетасында ул болай дип язды: «Татар әдәбиятында сатира һәм юмор өлкәсендәге тәҗрибәләрне җыю, уртаклашу, аны баету, тиранәйтү юлында берни дә эшләнгәне юк дияргә була. Киресенчә, кайбер кешеләр авызыннан: «Бу жанр безнең пролетариат әдәбиятына хас жанр түгел»,— дигән сүзләр ишеткәләргә туры килә. Кемнән көләргә? Ничек көләргә? Кайберәүләр өчен бу — чишелмәгән мәсьәлә. Шушы көннәрдә генә әдәбиятка якын торучы бер кешедән шундый сүз ишетергә туры килде: «Неужели бу «Чаян» журналы безнең уңышларыбызны күрми? Гел кимчелекләр турында гына яза».[5]

Шулай итеп, «социалистик җәмгыятьтә сатира бетә бара, дигән формалистик теория бу елларда совет комедиясенең үсешенә тоткарлык ясады, комедиографларның игътибарын җиңелчә көлү сәнгатенә юнәлтте»[6].

Шул елларда ясалма куертылган «сыйныфлар каршылыгы көчәя бара» дигән караш комедиографиягә һәрьяклап басым ясап торды. Бу мотив пьесаларның ясалма проблема-

---

[2] Фәйзи М. Сайланма әсәрләр, ике томда.— К., 1957, I том, 360-361 битләр.

[3] Фәйзи М. 2 том, 427 бит.

[4] Хафизов С. «Үзгәрергә кирәк безгә, үзгәрергә!»—«Социалистик Татарстан», 1988 ел, 11 июнь.

[5] Фәйзи Ә. Бездә көлке жанры.—«Коммунист», 1934 ел, 24 июль.

[6] Микулашек М. Пути развития советской комедии 1925-1934 годов. Издано университетом им. Я. Э. Пуркине, философский факультет в Брно, в Государственном педагогическом издательстве, Прага, 1962.

сына, конфликтына, интригасына үтеп керде, кайбер пьесаларның исемнәре дә шуңа ишарә иде. («Соры кортлар», 1938-39. «Канлы куллар», 1939, Х. Вахит).

Жанр анықлыгы ягыннан караганда да комедиография күп нәрсәләр югалтты. Шикләнү һәм фаш итүгә корылган мондый пьесаларда күңел җылысы, халык юморы һәм чын комедиячел интригалар, конфликтлар югалды. Мондый шартларда хәтта К. Тинчурин да, танылган комедия остасы булуына карамастан, уңайсыз хәлдә калды. Аның «Алар өчәү иде» (1935) пьесасы, комедия дип аталса да, бу жанрдан шактый ерак булып чыкты.

20 еллар комедиографиясе традицияләреннән читләшеп, К. Тинчурин әлеге әсәрендә яңа әхлак проблемасын кузгата. Студентлар һәм фән эшлеклеләренең рухи дөньясын анализлап, обывательлек, индивидуалистлык күренешләренең яшәү җирлеген фаш итәргә омтыла. Бер үк вакытта шәхес һәм гаилә бәхете, иҗтимагый бурыч кебек җитди проблемаларны да күтәрә.

Әмма шундый киң һәм җитди проблемаларны психологик пландагы комедиядә ачарга омтылу уңышлы килеп чыкмый. Заманның вульгар-социологик кысалары бу талантлы авторны да мәгълүм фраза һәм лозунгларны кабатлауга китерә, аның тискәре типлары үз-үзләрен камчылаучы һәм финалда үз хаталарын танучы мәгълүм штамп-образларга охшап калалар.

Дөрес, мондый шартларда да К. Тинчурин таланты үзен сиздерми калмый. Әйтик, «тормыштан аерылган» язучы Зарҗан, «зур кешенең хатыны» мещан Марварит, авыл карчыгы Мәхмүдә образларының халыкчан сатирик һәм юмористик төсмерләрдә бирелүләре әлеге пьесаны шактый җанландыра.

Ленинчыл принциплардан читләшү, ясалмалык, күпертүләр күп кенә пьесаларның идея-эстетик яктан җиңелчәлегенә, жанр ягыннан тоныклыгына китерде. Жанры анык булмаган түбәндәге пьесалар әнә шундый шартларда дөньяга килделәр: Г. Насрый — «Делегат» (1936), «Путевка» (1938), «Ялкау Бикмөхәммәт» (1932); С. Шәкүров — «Орденлы Касыйм» (1938); А. Әхмәт — «Көршеләр» (1933); И. Сәләхов — «Ярату» (1935); Ф. Сәйфи-Казанлы — «Зәңгәр алан» (1933), «Зөбәрҗәт» (1936); К. Тинчурин — «Ударниклар бәйрәме» (1933); К. Әмин — «Зәңгәр күл»; Т. Гыйззәт — «Бөек борылыш» (1930), «Көрәш» (1931), «Фамилиясез тимерче» (1933), «Мактаулы заман» (1935).

Мондый авыр хәлне лирик һәм музыкаль комедия жанрларында да күзәтергә мөмкин. Лиризм урынын чынлыктан аерылган ниндидер ясалма тәчеләнү алды. Әсәрләрдәге җыр-музыка сызыгы да Сталинның «бөеклеге»нә, ул заманның «ирек, бәхетләр»енә дан җырлауга корылган иде. Комедия үзенең комедиячеллеген югалта. Мондый әсәрләрдә тенденциоз шикләнүчәнлек эзләү мотивы үзәктә тора. Конфликт әнә шундый «корткыч элементлар»ны фаш итү ситуацияләренә корыла. Бу шаукым, кызганычка каршы, киң колачлы һәм дәвамлы булды. Ә. Камалның «Туй» (1939) музыкаль комедиясендә, Ә. Фәйзинең «Беренче елмаю» (1939-40) лирик комедиясендә, Т. Гыйззәтнең «Акбаш вакыйгасы» (1932), «Җиңү бәйрәме» (1933) агитпьесаларында әнә шул шаукымны бик ачык күрергә мөмкин.

Әлбәттә, бу еллар пьесаларында колхозлаштыру вакыйгалары зур урын алып тора. Аерым хуҗалык кешесенең психологиясе мондый пьесаларда типик «кире карт» образында ачыла. Заман бу кешенең уй-хисләрен үзенчә аңлата, сталинизм кушканча бәяли. Шуңа күрә мондый әсәрләр, образлар бүгенге бәяләргә бик мохтаҗ.

Шундый әсәрләрнең берсе — Т. Гыйззәтнең «Акбаш вакыйгасы». Әсәрнең үзәгендә — середняк Котбетдин. Пьеса аның тискәрелегеннән, колхозга кермәвеннән көлеп язылган булса да, асылда «бөгелешләр» елларындагы аяныч вакыйгалар, халык драмасы турында сөйли.

Хезмәт сөючән Котбетдин, башка күп кенә крестьяннар шикелле, тизләтелгән колхозлаштыру шартларында инде ике сыерын суйган кеше, хәзер ак башлы танасын «җыештыру» уйлары белән яши. Аның улы комсомолец Барый, Ф. Бурнашның «Ялгыз Ярулла» сындагы Ярулланың улы кебек, тырышып-тырышып үзенең әтисен тәрбияли. Әмма дөньяда күпне күргән, кендеге белән җиргә береккән Котбетдиннең тәрбиягә мохтаҗ түгеллеге, безнең заманнан караганда, бигрәк тә ачык сизелеп тора:

«Б А Р Ы Й . Тукта әле, әти, бер нәрсә булса, тотасың да кооперативны аласың. «Социализмга барыр өчен кооперацияләр күпер булырга тиеш»,— дип әйтеп калдырды бит иптәш Ленин.

К О Т Б Е Т Д И Н . Менә, менә, мин шул кооперациядән гыйбрәт алып, колхозга да кермим. Кооперацияләрне оештырганда да әллә нинди өмет таулары тоттырган иделәр. Ә хәзер ни хәлдә?

Б А Р Ы Й . Соң бит инде хәзерге көндә кооперацияләрдә товар азайган икән, аның сәбәпләре бар. Бишьеллык план бетүгә, товар белән дөньяны тутырып ташларбыз, инде ул хәзер үк билгеле, күрәсең, кооперацияләргә товарлар кайта башлады.

К О Т Б Е Т Д И Н . Кайта башлады да, үзара бүлешә дә башладылар диген. Мин, улым, бишьеллык планның безнең өчен файдалы буласын беләм, товар юклыгына да бер дә исем китми, тик менә шул барлы-юклы кайткан товарны нигә безгә тигез итеп бирмиләр? Кемнең кулында — шуның авызында дигәндәй, начальство кисәкләре ашап бетерәләр. Менә мин

колхоз эшен дә шулай булыр дип куркам. Кооперациядәге Тәхау белән сельсоветтагы кайбер кешеләрне акылга утыртмый торып, мин колхозга кермим.

БАРЫЙ. Син, әти, бик кызык кына кеше. Сиңа анысы да ярамый, монысы да килешми. Белмим инде, нишләргә тели торгансыңдыр?!

КОТБЕТДИН. Йорт-җирләрне, мал-туарларны сатып бетерик тә аннан заводка китәрбез»[7].

Шулай итеп, автор тарафыннан комик персонаж буларак тәкъдим ителгән Котбетдин асылда драматик халәттәге шәхес булып чыга, ул колхозлаштыру еллары фаҗигаләрен үз тормышында татыган кеше. Ул — җирнең хуҗасы, шуңа күрә хуҗасызлыкны җене сөйми.

Т. Гыйззәтнең элек читкә кагып киленгән бу әсәре тагын бер яктан әһәмияткә ия: ул — татар драматургиясендә колхозлаштыру елларында хайваннарны кыру вакыйгалары турындагы берդәнбер әсәр. Мондый аяныч хәлләр, әлбәттә, музыкаль комедия жанрын түгел, ә бәлки халык драмасы жанрын сорап тора. Чөнки «коллективлаштыру һәм кулакларны бетерү крестьяннарны рәхимсез көчләү һәм чамадан тыш тизләтү шартларында үткәрелде, күп кешеләрнең үлеменә китерде... Коллективлаштыру һәм кулакларны бетерү вакытында авыл хуҗалыгының җитештерү көчләреннән бик мөһим элементлары нык җимерелде (малтуарның яртысы суелды һ. б.)[8].

Шул рәвештә заманның актуаль проблемалары турында язганда чын драмалардан, чын комедияләрдән читләшү (дөресрәге, читләшергә мәҗбүр булу), җиңелчә комедияләргә һәм жанры анык булмаган «пьеса»ларга йөз тоту жанр нигезләренең шактый ул деформацияләнүенә, эчтәлек белән форма дисгармониясенә, реалистик принциплар бозылуга китерде.

Чынбарлыкның комедиячел конфликтларыннан, драматик хәлләреннән читләшү күп кенә авторларны ясалмалыкка китерде, конфликтлар очраклы вакыйгалардан эзләнде: табигать стихиясе белән көрәш, уйдырма дошманлык һәм корткычлык кебек нәрсәләр алгы планга чыкты. Ялган конфликтлылык чире әнә шулай таралды.

Бу хәлләрне тәнкыйть күрмәде дип булмый. Әмма тәнкыйть еш кына «патриотик» аклануга барып тәртелде. Моның ачык мисалы — «Мактаулы заман» (Т. Гыйззәт, 1935) пьесасы уңае белән кузгалган дискуссия. Бу пьесаны Г. Камал исемендәге театрда тикшерү үткәрелә. Режиссерлар коллегиясе әгъзалары һәм күренекле актерлар әсәрне камилләштерү юнәлешендә байтак тәкъдимнәр кертәләр: «Бу бит сыер, үгезләр турында язылган»,— диләр[9].

Ул еллар драматургиясендәге һәм театрындагы иң характерлы зәгыйфьлекләрне ассызыклап, «бер кабыргалы геройлар»ны кире кагып, Әхмәт Фәйзи болай яза:

«Сәхнәдә сыйнфый көрәшне күрсәтү бездә күп вакыт «сыйнфый көрәшле» уйнау булып чыга. Берякта —«бик яхшы коммунистлар, ударниклар, намуслы инженер». Алар шундый «яхшы», хәтта... тәмәке дә тартмыйлар. Икенче якта вредитель, лодырь һ. б. Алар шундый явызлар, аларның эшләмәгән бозыклыгы юк. Вредитель явыз планын эшкә ашырырга тели, лодырь яки рвач аңа булыша. Ә шул вакыт тамаша залында тамашачы дигән халык утыра. Ул алдан ук вредительнең бу явыз планы ачыласын, ударникларның «ура»! кычкыруы белән пәрдә төшәсен белеп, рәхәт кенә авызын ачып исни.

Ә театр тәнкыйтьчесе? Спектакльдән эстетик тәм алу берякта торсын, ул, спектакльдән элеп алып, бәйләнеп китәрлек берәр «гайре диалектик» момент эзләп, шуны табалмый йөдәп, тирләп утыра. Чөнки аның элекке стандарт рецепты бөтенләе белән театр тарафыннан үтәлгән. Мәсәлән, ячейка секретареның роле кая монда? Ә комсомол секретаре? Ә завком? Промфинплан чагылганмы? Ударниклык күрсәтелгәнме? Ә пионер оешмасы кая? һәммәсе бар. Театр үз геройларын тәнкыйтьче рецепты буенча формаль урнаштыруда кулыннан килгәннең бөтенесен эшләгән. Агымдагы кампанияләр турында берәр сүз белән генә булса да кагылып киткән. Көннең «кадагына суга торган» спектакль!

Ләкин монда театр тәнкыйтьчесе, драматург һәм театр онытып калдырган бер тәнкыйтьче бар. Ул үзе сүзсез, ләкин усал. Ул үзе простой, беркатлы, ләкин аны менә бу «геройларга» ышандыруы кыен. Ул ышанмый. Аның тәнкыйте — ул уенның иң «патетик» җирендә авызын ачып исни. Аның тәнкыйте — ул пәрдә төшәр-төшмәс ашыга-ашыга вешалкага йөгерә. Бу тәнкыйтьче — тамашачы»[10].

Шартлар әнә шундый авыр булуга карамастан, 30 еллар комедиографиясендә эзләнүләр тукталмый. Моны Ә. Фәйзи, Н. Исәнбәт, М. Әмир, М. Җәлил, Ш. Камал, Ф. Бурнаш,

---

[7] Таҗи Гыйззәт. Әсәрләр, дүрт томда.— Казан, Татарстан китап нәшрияты, т. 2, 1976, 99-100 битләр.
[8] Даннилов В. П., Тепцев Н. В. Коллективизация: как это было.—«Правда», 1988, 26 августа.
[9] Гыйззәт Т. Мин ничек артист һәм драматург булдым. Китапта: Таҗи Гыйззәт. Әсәрләр, 4 томда.— Казан. Татарстан китап нәшрияты, т. 4, 1978, 266 б.

[10] Әхмәт Файзи. Сәхнәдә йөрүче аяклы плакатлар белән тамаша залында утыручы геройлар турында.—«Коммунист», 1933, 22 март.

Г. Насрый һ. б. язучыларның кайбер пьесаларыраслый. Әйтик, Ә. Фәйзинең «Төтен», «Туракай» кебек сатирик пьесалары заман темасына язылган шактый кыю әсәрләр булып саналырга хаклы.

Муса Җәлил дә бу жанрда «Кешеләр» (1934-1935)[11] пьесасын иҗат итә. Колхоз малмөлкәтен урлаучыларны фаш итүдә традицион калыплар сизелсә дә, бу комедия театральлек отышлы интригалары белән аерылып тора.

Ил тормышындагы болганчык хәлләр, битлек алыштырулар үткен көлүче Шәриф Камал сатирасында да чагылып калды. Аның «Алтынчы башня» (1933) дигән сатирик комедиясе аерым игътибарга лаек. Кую өчен «уңайсыз» булу сәбәпле, ул сәхнә күрми кала. Хәтта ул елларда басылмый да. Тик 1959 елда гына «Совет әдәбияты» журналында (№2) аның ике пәрдәсе дөнья күрә. Бу комедиянең «Шик» дигән икенче исеме дә бар.

Конфликт картлар белән яшьләрне, элеккеләр (Гитарин, Миков, Шумский) белән яңа кадрларны каршы кую рәвешендә алынса да, бу комедия революция идеалларыннан ерак торучы, түрә булырга омтылучы, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып йөрүче, совет аппаратларына кереп оялаган типларга үткен пародия булып яңгырый. Ә мондый көлү ул еллар комедиографиясендә сирәк очрый иде.

Дөрес, бу саркастик көлү башлап «оппортунист-куркак»ларны фаш итүгә юнәлтелгән. Сатирик гипербола алымнарын киң кулланып, автор элекке поп Геннадий белән элекке мулла Фәтхелгаяны политагарту агитаторлары итеп эшкә билгеләгәндә уңайлы урынга омтылучылар, карьеристлар аумакайлыгыннан үтергеч көлә... Битлекле ответработниклар, бюрократлар, түрәләрнең күн портфель һәм галифе яратулары, шулай бүтәннәрне өркетеп рәхәт яшәргә омтылулары әсәрдә ачы ирония белән сурәтләнә. Менә, мәсәлән, әлеге «вакытлы» җитәкчеләр җылы урынга омтылучы «яңа агитаторларны» ничек киендерәләр:

«М И К О В *(яза)*. Ике костюм, ике пальто, ике пар ботинка, ике кепка, бер дюжина белье, ике дюжина носки... Тагын кирәк әйберләрегез булса, Сармаков иптәшкә әйтерсез. Ордерсыз гына да бирергә мөмкин булыр.

С А Р М А К О В. Ә башка снабжение мәсьәләсе?

М И К О В. Ответработниклар снабжениесе булыр. Сергей Петрович, шулай дип уйлыйм.

Г И Т А Р И Н. Әлбәттә, әлбәттә. Анда ике сүз булырга мөмкин түгел.

Г Е Н Н А Д И Й. Ответработник булгач, анысы инде нихәл итәсең...

Ф Ә Т Х Е Л Г А Я Н. Алай. Ә... иптәш Шабан Мазарыч, миңа бер портфель языгыз, портфель, материаллар куеп йөртергә портфель кирәк булыр... Ә... чалбар галифе булсын иде, галифе.

М И К О В. Аның ишеләрен иптәш Сармаковка тапшырабыз. Ул үзе һәммәсен рәтләр.

С А Р М А К О В. Ярар, булды!

Сармаков, Геннадий, Фәтхелгаян чыгалар.

Ш У М С К И Й. Кешеләре юньлегә охшыйлар.

М И К О В. Күренеп тора ич. Социализм төзергә ашкынып кына торалар»[12].

Шул рәвешчә, 30 еллар татар драматургиясендә Остап Бендер, Бывалов кебек сатирик персонажларны хәтерләткән образлар сирәк булса да иҗат ителде.

Бу дәвернең яңача бәяләнергә тиешле комедияләре арасында Ф. Бурнашның 1939 елда язылган «Ялгыз Ярулла»сы да бар. Агитпьеса рәвешендә иҗат ителгән бу әсрдә колхозга керми тарткалашучы Ярулла карт төп көлү объекты итеп алынган. Бүген тарих сабакларын искә алып, бу кешенең сүзләрен, аргументларын тыңлап карасак, элекке көлүләр шактый ук урынсыз булганлыгы аңлашыла. Алай гына да түгел, аның җир хуҗасы буларак әйткән киңәше-акылы бүген дә гаять актуаль икәнлеге ачыклана. Күрәсең, биредә Ф. Бурнашның таланты, реалистик каләме,— авыл картының аек акыл белән көн күрүгә корылган тормыш тәҗрибәсен объектив чагылдыруы,— хәлиткеч роль уйнаган. Ярулла белән улы Батырҗан диалогына игътибар итик:

«Б А Т Ы Р Җ А Н. Әти, колхоз быел йөзәр пот ала, дип әйтәләр.

Я Р У Л Л А. Сөйләмә тузга язмаганны!

Б А Т Ы Р Җ А Н. Билләһи! Гөлсем сөйләп утырды... Алар уңышны, синең белән миңа караганда, бермә-бер артык алалар. Әнә бит...

Я Р У Л Л А. Нәрсә белән алалар? Хөкүмәт җилкәсенә салынып мы? МТС тракторларына аркаланыпмы? Теләсә кайдан кредитка машиналар китерепме?

Б А Т Ы Р Җ А Н. Шунда шул менә хикмәт, әти... машина... трактор...

---

[11] Җәлил М. Кешеләр.— Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты кульязмалар бүлегендә саклана. Фонда 10, 1 тасв., с. б. 274

[12] Шәриф Камал. Алтынчы башня.—«Совет әдәбияты», 1959, № 1, 85 б.

ЯРУЛЛА. Ә кем машинасы? Кем тракторы? Кем орлыгы? Хөкүмәтнеке. Ул бурычларны түли-түли колхозның бирәне чыгар әле.

БАТЫРҖАН. Алай түгел, әти. Безнең колхозның бүгенгә бер тиен бурычы юк.

ЯРУЛЛА. Ә хөкүмәт үз хисабына алганмы? Беләбез без аны.

БАТЫРҖАН. Анысы инде хөкүмәт, колхоз... колхоз, хөкүмәт... Ул синең белән минем хисап түгел.

ЯРУЛЛА. Бозга язган хисапмы? Таянып кара әле син аңа»[13].

Аерым хуҗалык тарафдарларыннан шул рәвештә көлү С. Батталның «Язулы яулык» (1931-58) комедиясенә дә хас. Бу пьеса герое «киреләнүче» Хафиз да көнкүреш турында Ф. Бурнашның Ярулласы, Т. Гыйззәтнең Котбетдине кебегрәк фикер йөртә.

Сталинның сыйнфый көрәшне кискенләштерү чаралары гомумкешелек әхлагы принципларына мөнәсәбәтне бик нык чуалта, нахак кан коюларга, зур фаҗигаләргә китерә. 1958 елда күпмедер төзәтмәләр кертү нәтиҗәсе буларак, С. Батталның бу пьесасында халыкны әнә шундый «канлы уенга» алып керүченең исеме дә атала. Мондый кан коюлардан ризасызлык мотивы авыл советы председателе Хәнәф белән аның күршесе Морза диалогында бик ачык аңлашыла:

«ХӘНӘФ. Нигә азрак утырмадың... Хотя минем дә хәзер җыелышка барасым бар.

МОРЗА. Шулай итеп мине раскулачить итәсез икән... ярый!

ХӘНӘФ. Үзең беләсең, шундый хәлләр... Нишлисең бит, туры килер шул.

МОРЗА. Беләм, беләм. Мин бу эштә сине гаепләмим бит. Сталин тешкә суга...

ХӘНӘФ. Әкрен!..»[14]

Шәхес культы нәтиҗәсендә 30 еллар татар комедиографиясе җитди югалтуларга дучар була. Реалистик принциплардан читләшү, конфликтсызлык теориясе, ясалмалык, штамплар бигрәк тә заман темасына караган әсәрләргә зур зыян итте. Эчтәлек һәм форма дисгармониясе традицион жанрларның шактый ук гарипләнүенә китерде. Шулай да талант ияләре язган пьесаларда чорның аерым мөһим төсмерләре, тормышның «су асты» агымы сизелә. Аларны бүгенге биеклектән күрү, бәяләү — көн тәртибендәге җитди бурычыбыз.

[13] Фатхи Бурнаш. Сайланма әсәрләр, ике томда.— Казан, Татарстан китап нәшрияты, том 1, 1959, 217-218 битләр.

[14] Салих Баттал. Комедияләр.— Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1959, 42 бит.

**Зөфәр Рәмиев,**
филология фәннәре кандидаты

# ВАКЫТ ҖИТӘР, КОЯШ ЧЫГАР!

Күренекле әдип, шагыйрь, тәрҗемәче һәм драматург, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе, 1919 елдан Коммунистлар партиясе члены, 1929 елдан «буржуаз милләтче» Сәгыйть Сүнчәләйнең тууына быелның августында 100 ел тула. Илебез тарихының гаять тә катлаулы, сикәлтәле чорларында яшәп, көрәшеп уздырган, кырык яше тулу көннәрендә репрессияләнеп, дистә елга якын гомерен төрмәләрдә, лагерьларда үткәргән һәм, иң фаҗигалесе — илле яше дә тулып өлгермәстән атып үтерелгән бу зур шәхеснең исеме өч дистә ел чамасы тыелган исемнәр рәтендә булды. Тик партиянең тарихи XX съезды карарлары гына, хаксызга җәберләнгән миллионлаган совет кешесенең берсе буларак, Сәгыйть Сүнчәләйгә дә туган халкына, әдәбиятына, Ватанына «кайтырга» юл ачты.

Әмма сталинчылык репрессияләренә дучар булган дистәләрчә язучыларның абруйлы исемнәрен татар әдәбиятында торгызу эше, кызганычка каршы, җиңел генә бармады. Моның өчен көч куярга, догматик фикерләүләрдән арынырга, архивларда эзләнүләр алып барырга кирәк иде. Бу эшнең Сәгыйть Сүнчәләйгә кагылган кадәресен әдипнең бертуган абыйсы, педагог һәм журналист Шәриф Сүнчәләй (1885-1959), әдипнең мирас комиссиясе членнарыннан язучыларыбыз Риза ага Ишморат, Әмирхан ага Еники башлап җибәрде. Алар тырышлыгы белән 1961 елда Татарстан китап нәшриятында С. Сүнчәләйнең «Сайланма әсәрләр»е дөньяга чыгарыла (кереш сүзнең авторы әдәбиятчы-галим Гали Халит). Китап шактый зур күләмле иҗат мирасының чагыштырмача аз өлешен — 63 шигырьне, бер пәрдәле «Сәнгатьчеләр» пьесасын һәм Тукай турындагы ике истәлекне генә эченә алган булса да, әдипнең яңада кайтуына хәбәр итү көченә ия иде, билгеле. Риза Ишморатның истәлек язмалары, Х. Госман, М. Мәһдиев, Э. Нигъмәтуллин һәм башка кайбер галимнәрнең хезмәтләре С. Сүнчәләйнең тормыш һәм көрәш сәхифәләрен ачыклау, иҗат мирасын барлау юлында шактый уңышлы адымнар булды. Күптомлы «Татар әдәбияты тарихы»ның өченче китабында унынчы еллар татар поэзиясе турындагы бүлектә Гали Халит аның шигъри әсәрләренә махсус тукталып уза.

С. Сүнчәләйнең иҗат мирасы — җитди әдәби күренеш. Бүген аны хакыйкатьтә барынча өйрәнү әше әле башлангыч хәлендә генә тора дисәк тә ялгышмыйбыздыр. Күп мәсьәләләрне куясы, җентекләп өйрәнәсе, хәл итәсе бар әле. Сүнчәләйнең 100 еллыгына багышланган бу мәкаләдә дә сүзне әдипнең тормыш һәм иҗат юлына караган кайбер күзәтүләр белән генә чикләргә туры килер.

Документаль чыганакларда С. Сүнчәләйнең (Сәгыйть Хәмидулла улы Сүнчәләевнең) туу урыны итеп ул замандагы административ-территориаль бүленеш буенча Саратов губернасының Хвалын өязенә кергән Иске Мастак авылы күрсәтелә. Ләкин аңа монда озак яшәргә насыйп булмаган. 1891 елгы ачлык газабыннан котылырга теләп, Хәмидулла агай үзенең гаиләсе белән Әстерхан шәһәренә килеп урнаша. Шулай итеп, Сәгыйть тә бик кечкенәдән шәһәр кешесе булып китә. Үсә төшкәч исә шәһәр мәдрәсәсенә — «Вәһабия»гә кереп укый. Аны тәмамлагач, ике ел балалар укыту белән шөгыльләнә. Тагын бер нәрсә мәгълүм безгә: яшь-яшь булуына да карамастан, Сүнчәләй 1905-1907 елгы революция чорында Әстерханда булып торган хәрәкәтләргә бик теләп катнашкан, агасы Шәриф белән бергә ул прокламацияләр, сул фикерле брошюралар таратучыларның берсе булган.

1907 елларда язмыш аны Казанга алып килә. Шакирҗан Хәмиди укыткан мәдрә-

сәгә йөрүдән зиһенле, кызыксынучан, укуга дәрте ташып торган егет зур мәгънә таптый һәм тиздән, абыйсы үрнәгендә, Казан татар укытучылар мәктәбенә укырга керә. Тик матди кысынкылыклар бер елдан соң ук Сүнчәләйне бу уку йортыннан аерылуга китергән. 1909 еллардан башлап ул — Пермь губернасының Уса өязе Сараш авылындагы дүрт сыйныфлы земство мәктәбе укытучысы (бу мәктәптә Ш. Сүнчәләй дә эшли башлаган була). Әнә шулай халкыбыз күңелендә мәгърифәт уты кабызуны олуг максат иткән татар мөгаллимнәре сафына баса С. Сүнчәләй. Р. Ишморат истәлекләреннән күренгәнчә, ике туган бу эшне гаять яратып, бар көч-сәләтләрен, хис-ялкыннарын салып башкарганнар, һәм укучы балаларның, бөтен авыл кешеләренең мәхәббәтен казанганнар.

С. Сүнчәләйнең әдәбиятка килүе дә шушы Сараштагы яшь һәм эшли башлавы еллары белән бәйле. Дөрес, ул элегрәк тә кулына каләм тотып карамады түгел. Әстерханның «Борһане тәрәккъый» газетасында хәбәр-информацияләрен бастырса, 1908 елда аның «Кавказ тоткыны», «Тунгатай» исемле тәрҗемәләре, «Күл — күз яше» дигән хикәясе юка гына китаплар булып дөньяга чыккан иде. Ләкин алар С. Сүнчәләй иҗат биографиясенә эз салмыйлар.

Сараштагы яшәгән елларында С. Сүнчәләй беренче чиратта үзен лирик шагыйрь итеп таныта. Россиянең төрле почмакларында (Казан, Әстерхан, Оренбург, Петербург, Томск, Уфа кебек шәһәрләрдә) чыгып килгән татар газета һәм журнал битләрендә «С. Сүнчәләй» («С. С.», «Хәмидулла углы») имзалы әсәрләр бу дәвер укучысына бик еш тәкъдим ителгәннәр. 1913 елда заманы өчен зур күләмле шигъри җыентыгы да дөнья күрә аның.

Әдәбият галимнәре унынчы еллар татар әдәбиятында, тәнкыйди реализм белән янәшәдә, иҗат методы буларак романтизмның да куәтләнеп китүен язып киләләр. Әйтергә кирәк, С. Сүнчәләй дә бу күренештән читтә торып калмаган. Күпчелек чордаш шагыйрьләрендәгечә, аның да сәнгатьчә фикерләвендә, дөньяны тоюында, хис итүендә романтиклык өстенлек итә. Ни өчен килеп туган соң бу хәл? Әдәбият үсеше, иҗтимагый тормыш вакыйгалары яшь шагыйрьгә нык тәэсир иткәннәр — бусы бәхәссез. Әмма монда Сүнчәләйнең шәхси тормышына нисбәтле факторларның йогынтысы да аз булмагандыр кебек. Авылда туса да, шәһәрдә үскән, дөньяга карашы формалашкан, заманының алдынгы уку йортында — Казан татар укытучылар мәктәбендә шактый тирән белем чишмәләреннән татыган, интеллектуаль багажга ия булган алдынгы фикерле шәхесне язмыш татарның мәдәни үзәкләреннән, аеруча Казаннан, ерактагы татар авылына китереп ташлый («Үтте яшь гомрем шәһәрдә, хәзер Мин караңгы, ярлы авылда торам»). Җитмәсә, бәләкәй баласын — Таһирны якты дөньяга тудырган хатыны Сәлимә дә үлеп китә аның. Нәтиҗәдә, романтик хис-фикерләүнең нигезендә яткан ситуация — реаль чынбарлык, тормыш хәлләре белән рухи дөнья, күңел омтылышлары арасындагы каршылыклар кискенәйгән.

Мондый рухи конфликтлы хәлләрдән, каршылыклардан ничек чыга соң шагыйрьнең лирик герое? Чынбарлыкны каһәрләпме? Кешеләрдән, халыктан бизепме? Табигать кочагына качыпмы? Ул елларда татар романтик шагыйрьләреннән үзләрен шулай хис кылучылар да булмады түгел, булды. Әмма бу нәрсә Сүнчәләйдә бөтенләй күренми диярлек. 1910-1914 елларда язылган ике йөз иллеләп шигыренең иң зур күпчелегендә лирик геройның күңел көрлеге, тормышка актив мөнәсәбәт, оптимистик рух өстен чыккан, шагыйрьдә иҗтимагый чынбарлыкның асылын аңларга теләү, авыл кешеләренә теләктәшлек эмоциональ гәүдәләнеш тапкан. Ничек кенә булмасын, тормыш хәлләре нинди генә газаплы хис-кичерешләргә этәрмәсен, аның хис-фикер дөньясында җаваплылык тойгысы яшәүдән туктамый. Авылга мәгърифәт таратырга дип килгән икән, ул аны ташлап китәргә тиеш түгел, аның кешеләр алдында олы вәгъдәсе, анты (гаһеде) бар.

Романтик шагыйрь Сүнчәләйнең уй-кичерешләре тормышчан эчтәлек белән сугарылуда аның беркадәр вакыт бөек Тукай белән аралашып, дус-иптәш булып яшәвенең дә роле зур. Сүнчәләй Тукайны 1907 еллар ахырында ук күргәләгән булса да, алар беренче мәртәбә 1910 елның маенда күрешәләр, ләкин анда да яшь автор әле үзенең кем икәнлеген әйтми; яңа гына матбугатта күренә башлаганлыктан, аңа «бу мөһим булмас күк» күренә. Шул елның көзендә Сүнчәләй тагын укыткан авылына — Сарашына кайта һәм Тукайга беренче хатын яза, ә бераздан батыраеп китеп, үзе тәрҗемә итә башлаган «Шильон мәхбүсе»нең бер кисәген Тукайга җибәрә, киңәшләр сорый. Тукай исә, яшь авторга «элек вак шигырьләр тәрҗемә кыйлып карарга кирәк» дигән булса да, «Шильон мәхбүсе»н ярата, һәм төзәткәләп күчереп чыккач, «Мәгариф» нәшриятында үзенең кереш сүзе белән китап итеп бастырып та чыгара.

Ике шагыйрьнең хат язышулары бер ел чамасы дәвам иткән (Сүнчәләй бер истәлегендә аңардан уникеләп хат алганлыгын әйтә). 1911 һәм 1912 елларның җәй ахыры — көз башларында алар якыннан аралашып та яшиләр, кай көннәрдә Тукайның

«фәкыйрь генә, күңелле генә бүлмәсендә... күңелле, рәхәт, сабыр сәгатьләрне, кичләрне, төннәрне» уздыралар, сөйләшәләр. Тукай теләге белән сүздән калып, тынып та торалар.

Бу аралашу, бу дус-иптәшлек, һичшиксез, Сүнчәләйнең иҗатына бәрәкәтле йогынтысын ясамый калмаган, аны һәм фикри, һәм хисси җәһәттән баеткан. Өлкән иптәшенә, бөек шагыйрьгә атап язылган «Азат», «Хат кисәге», вафатыннан соң иҗат ителгән «Тукай хатирәсе», «Иңеш», «Г. Тукаев», «Мәрхүм Тукаевка» кебек әсәрләрен укыганда, Сүнчәләйнең күңел дөньясы Тукайга олы хөрмәт һәм эчкерсез ярату хисләре белән тулганлыгын бик ачык күрәсең. Тукайның үлем хәбәрен ишеткәч, Сүнчәләй авыр кичерешләр эчендә кала. Сараш авылының «зират коймасы буенда әле күптән түгел генә яшелләнеп чыккан чирәмгә яткан да, шул чирәмле җирне тырмый-тырмый елый» (Р. Ишморат. Гомер сукмаклары. 71 б.)

Сүнчәләй иҗат мирасының гаять зур өлешен тәрҗемә әсәрләр биләп тора, ул — бу чорның күренекле тәрҗемәчесе. Бу эшне ул оригиналь шигъри иҗат белән бер үк вакытта, тыгыз бәйләнештә алып барган. Исемнәре янәшәсендә үк кайсы автордан алынганлыгы (тәрҗемә ителүе, ияреп язылуы) күрсәтелгән шигырьләренең гомуми саны аңарда берничә дистәгә җыела. С. Сүнчәләй рус һәм Көнбатыш әдипләреннән кемнәргә мөрәҗәгать иткән соң? Менә алар: Жуковский, Крылов, Пушкин, Лермонтов, Некрасов, Тургенев, Майков, Никитин, Шевченко, Надсон, Блок, Бальмонт, Байрон, Гюго, Гейне һ. б. Күренә ки, С. Сүнчәләй Көнбатыш Европа, рус, украин әдәбиятларының күп кенә реалист һәм романтик шагыйрьләреннән тәрҗемә итә. Ул күбрәк ирекле тәрҗемә бирә, башлыча романтик шагыйрьләр әсәрләре белән кызыксына. Реалистик язучылар иҗатына да ул үзенчә якын килгән, аларның әсәрләрен дә романтик эстетика кануннарына буйсындырып тәрҗемә иткән. Тагын шуны да искәртеп үтәсе килә: еш кына ул Көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятыннан тәрҗемәләрен татар тормышына якынлаштырып бирә. Көнчыгыш романтизмы өчен хас булган сурәтләр белән баета.

Тәрҗемәче Сүнчәләйгә хас икенче бер нәрсә — аның зур күләмле шигъри әсәрләрне (поэмаларны, шигъри трагедияләрне) татарча яңгыратырга омтылуы. Байронның «Шильон мәхбүсе»н ул әдәбиятка килүенең беренче елларында ук Тукайның эчкерсез ярдәме белән дөньяга чыгарган иде (исеме 1910 елгы басмада: «Мәхбүс», 1924 тә: «Шильон мәхбүсе»). 1911 елда ул Пушкинның «Коръәнгә тәкълидләр»ен бирә. Бераздан Сүнчәләй даһи Гейне иҗатына килеп чыга һәм оригиналдан, ягъни немецчәдән аның мәшһүр «Әлмансур»ын тәрҗемә итә. 1913 елгы «Аң» журналының 21 санындагы рецензиясендә Сүнчәләйнең шигъри иҗатын гаять тупас рәвештә юкка чыгарырга теләгән Фатих Сәйфи-Казанлы «Әлмансур»ны да уңышсыз эшләнгән дип санаса, Галимҗан Ибраһимов бу ирекле тәрҗемәләргә шактый уңай карашта тора. Патша цензурасы, Смирновлар трагедиянең татар сәхнәсенә менүенә һаман тоткарлык ясап килгәннәр, шунлыктан ул бары тик Февраль революциясе алдыннан гына Оренбургта, 1917 елның мартында Казанда уйнала алды.

1914-1916 елларда С. Сүнчәләй рус язучысы Изабелла Гриневскаяның Ирандагы милли-азатлык хәрәкәте тарихыннан алып язылган «Баб» трагедиясен тәрҗемә итә, озак еллар авторның үзе белән хатлар алышып яши.

1915 елдан башлап Уфа шәһәр китапханәсенең татар бүлегендә мөдир булып эшләгән С. Сүнчәләй Октябрь революциясен «инсаният тарихының иң мөкатдәс бер таңы» итеп кабул итә, ул тәрҗемә иткән «Интернационал», «Марсельеза», «Матәм» кебек революцион җырлар тиз арада көрәшче халык арасында таралып та өлгерә.

С. Сүнчәләй — 1919 елдан партия члены. Тиздән аңа гаять җитди эш йөкләнә һәм, үзәк органнарның кушуы буенча Кырымга килеп, ул Ялта өязендәге Партанет авылында мөгаллимлек итә. Шул чорда алып барган көндәлегеннән күренгәнчә, ул биредә Казанны, Галимҗаннарны, Әмирханнарны сагынып яши, Э. Верхарнның «Таң»ын, М. Метерлинкның «Сукырлар»ын тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнә. Кырымда идарә Деникин кулыннан Врангельга күчкәч, аңа яшерен эшләр алып бару гаять кыенлаша һәм ул 1920 елның июнендә диңгез аша Төркиягә качып чыга. Өч айдан соң С. Сүнчәләйнең Мәскәүгә кайтып кергәнлеге, Кырым һәм Төркиядәге иҗтимагый-сәяси хәлләр турында партиянең Үзәк Комитетына һәм Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетына фикерләрен язып биргәнлеге мәгълүм.

Врангель җиңелү белән Сүнчәләйне янәдән Кырымга җибәргәннәр. Ул анда өч ай була. Партиянең Үзәк Комитетына адресланган доклад язмасында (күчермәсе Татарстан Дәүләт музее архивында саклана) Сүнчәләй совет властен көтеп алган Кырым халкында ачлык хөкем сөрүен, җирләренең крестьяннарга кайтарып бирелмәвен хәбәр итә. 1921-1922 елларда ул — Кырым АССРда Милләтләр эше халык комиссариаты вәкиле. 1921 елның декабрь ае өчен Сталинга адресланган отчетында Сүнчәләй берише ОГПУ хезмәткәрләренең кайбер төбәкләрдәге татар авылларында законсыз репрессия-

ләрен туктату, җирләрне крестьяннарга кайтарып бирү, мәгариф эшләрен җайга салу, ачларга ярдәм итү буенча чаралар күрелгәнлегеп яза, шул ук вакытта ачлыктан җәфа күрүче җирле татар халкы турында кайбер җаваплы работникларның аз кайгыртулары басым ясый (Кырымдагы эшчәнлегенә караган материаллар Татарстан дәүләт музееның татар әдәбияты бүлегендә саклана, инвентарь саны 17520).

Әдипнең егерменче еллардагы тормышы һәм әдәби, иҗтимагый эшчәнлеге Уфа шәһәре белән бәйле. Хезмәт урыны — республика Мәгариф комиссариатында коллегия члены һәм сәнгать бүлеге мөдире, аннары Уфа сәнгать музее мөдире. Башкортстан АССР театр-сәнгать техникумы җитәкчесе. Сүнчәләй бер ел чамасы (1926-1927 еллар) СССР Тышкы эшләр халык комиссариатының Измир шәһәрендәге (Төркия) генераль консуллыгында драгоман (тәрҗемәче) булып та эшләгән. Әмма мондый шартларда да ул әдәби иҗаттан аерылмый яши. Кызганычка каршы, бүгенге татар укучысы аның бу чор әсәрләрен — шигырьләрен, пьесаларын, тәрҗемәләрен — укудан бөтенләй диярлек мәхрүм булып тора. Әдәбиятыбыз тарихын тикшеренүчеләрнең дә аларны әлегә җентекләп өйрәнгәннәре юк. Югыйсә Сүнчәләйнең Октябрьдән соңгы иҗаты татар әдәбиятында романтик юнәлешнең яшәвенә ышанычлы дәлил булып тора, төгәлрәк әйтсәк, гыйсъянчылык романтизмының куәтләнеп китүендә зур роль уйный. Әле иллөнче еллар ахырында ук Әхмәт Фәйзи Сүнчәләй иҗатының әһәмиятле бер темасы дип гыйсъянчылыкны атаган иде.

Р. Ишморат үзенең истәлекләрендә шагыйрьнең Сараштагы шәхси тормышы һәм педагогик эшчәнлегендә җыр һәм музыканың зур урын алып торуы хакында да язып чыкты. Сәгыйть скрипкада һәм мандолинада оста уйнаса, абыйсы яхшы гармунчы да икән. Әйе, С. Сүнчәләй гомере буе музыкага гашыйк булып яшәгән, үзе уйнау, үзе җырлау белән генә чикләнмичә, бу өлкәдәге оештыру эшләренә дә бик теләп катнашкан. Мәсәлән, «Көрәш» газетасы 1918 елның 25 март санында Уфада «Татар әдәбияты һәм музыкасы җәмгыяте» төзелүен һәм аның рәисе Сүнчәләй булуын хәбәр итә.

Аның музыкага, сәнгатькә гашыйклыгы әсәрләренә дә үтеп кергән (бу сыйфатлар үзләре генә дә аның романтик шагыйрь икәнлеген дәлилли). «Сәнгатьчеләр» исемле пьесасына күз ташлыйк. Мондагы үзәк образлар — актриса Әлфия, сукыр музыкант Халикъ, җырчы Биньямин, художник Рәшит, шагыйрь Борындык. «Таң алдыннан», «Скрипка моңнары» дигән сәхнә әсәрләренең эмоциональ-эстетик дөньясы да музыкага нисбәтле моментлар белән сугарылган. Сүнчәләй композиторлык сәләтенә дә ия булган, ул — унлап көй-җыр авторы.

Әдипнең революциягә кадәрге лирик әсәрләрендә болытлар сурәте еш очрый һәм ул шагыйрьнең оптимистик рухын чагылдырган кояш, таң, нурлы, якты дөнья кебек образларга каршы куела иде. Менә шомлы, фаҗигале утызынчы еллар килеп җитә һәм әлеге кара болытлар Сүнчәләйнең баш очында да куера башлый. Аның «контрреволюцион солтангалиевче» икәнлеге ачыла, иҗатына кара тамга сугыла. Мәсәлән, «Матур әдәбиятта буржуа милләтчелеге» дигән китапта (Казан, 1930): «Борнашлар, Бәдәйлиләр, Сүнчәләйләр, Рахманкуловлар, Агиевларның әсәрләрен тикшерергә, аларның буржуа агуы белән зәһәрләп калдырган әйберләренә пролетариат методы белән реакция ясарга кирәк», — дип язылган (редактор Ф. Сәйфи-Казанлының кереш сүзе).

1929 елда Сәгыйть Сүнчәләй кулга алына һәм ун елга хөкем ителә. Хатыны Әминә Милушевага, әнисе Һаҗәргә язган хатларыннан, Бакый ага Урманче истәлекләреннән аның Сталин төрмәләрендә һәм лагерьларында (Бутырка, Соловки һ. б.) уздырган иң авыр, иң фаҗигале елларда да күңел төшенкелегенә бирелмәве, тизрәк ирекка чыгып туганнары янына кайту өмете белән яшәве ачык күренә. Ләкин мондый бәхет насыйп булмый аңа: 1938 елда С. Сүнчәләй атып үтерелә. Бу күренекле татар әдибе, шагыйрь, тәрҗемәче, драматург, зур җәмәгать эшлеклесе, коммунист шулай вәхшилекнең, золмәтнең корбаны булды.

Әмирхан Еники 1962 елгы рецензиясен («Совет әдәбияты», 2 сан) «Шагыйрьнең яңадан кайтуы» дип исемләгән иде. Кызганычка каршы, әле бүген дә бу әдипнең исеме, күпкырлы иҗаты халкыбызга тулысы белән кайтып җиткәне юк. Бу яктан да без, аеруча әдәби мирасны өйрәнүчеләр, Сүнчәләй алдында үзебезне бурычлы итеп сизәргә тиешбез.

**Китап күзәтү**

# ТОРМЫШНЫҢ ҮЗЕННӘН

Инде күптән вафат булган әбиемне — күз нурымны «очраттым...». Халкыбызның гүзәл сыйфатларын үзендә туплаган иң якын кешемнең мөлаем образы күңелдә җанланды... Язучы һәм публицист Альберт Хәсәновның «Шулай бер мәлне» җыентыгындагы (Татарстан китап нәшрияты, 1987 ел) «Көләч йөз» исемле повесте сәбәп булды моңа. Әбием әсәрдәге карчыкка шул хәтле охшаган ки, нәкъ менә ике тамчы су кебек. Шәфкатьле әбиләр шулай бер-берсенә охшаш булалар, күрәсең.

...Дәһшәтле сугыш еллары. Фронт турында кайгыртуның, тылның, дөнья көтүнең төп йөген үз җилкәсенә күтәргән, ирләрен һәм улларын алыштырган искиткеч булдыклы, түзем, кешелекле, ярдәмчел әбиләр. Безнең буынга да шул сыйфатларны нык итеп сеңдергән әбиләр. Авыр елларда әлеге сыйфатлар тоныгаеп калырга тиеш иде кебек. Чөнки һәркемнең үз хәле хәл. Әмма бу сыйфатлар, киресенчә, сугыш вакытында тагын да көчәеп киттеләр.

Повестьта әллә ни искитәрлек вакыйгалар да юк үзе. Ләкин ул еллардагы күпләргә таныш вакыйгалар аша автор әбисенең халык педагогы, чын шәфкать иясе, интернационалист, катгый хөкемдар булганлыгын үтемле итеп ачып бирә.

Әби белән оныкның арасындагы мөнәсәбәтләр аеруча җылы һәм мөлаем итеп сурәтләнгән. Таң атса, Навалбикә әби оныгы белән чабата үрергә керешә. Әби оныгын эш сөяргә, осталыкка ия булырга ничек оста өйрәтә диген! Ул аның һәр адымын күзәтә бара, уңышын күреп ала, аны дәртләндереп, илһамландырып тора. «Син, улым, чабата үрмисең, сурәт ясыйсың»,— ди ул. Нәтиҗәдә оныкның «хан кызлары гына кия торган бу фасонлы чүәкләрне үрүнең серләренә тәмам төшенеп, хәзер осталыкның арьягына чыгып бара». Шуның белән бергә, Навал әби оныгына ярдәмчеллек, шәфкатьлелек дәресләре дә бирә. Чабата — ул заманда иң кирәкле нәрсә. Әби аны авылның һәм тирә-юньнең һәр мохтаҗына тарата, аз булса да хәлләренә керергә тырыша: «Мәле, улым, җиңел аягым, җәннәт фәрештәсе булып кына шушы чабатаны Саескаинарга кертеп чык».

Әби белән оныкның арасындагы мөнәсәбәтләрдә никадәр туган җанлылык, үзара ихтирам, табигыйлек, самимилек! Өлкәннәрнең нәниләргә һәм нәниләрнең өлкәннәргә игътибарлы, ихтирамлы мөнәсәбәте! Күп халыкларның, шул җөмләдән безнең халыкның да гасырлар буена кадерләп һәм ишәйтеп килгән күркәм рухи тәҗрибәсе ул. Фән-техника прогрессы, шәһәрләшү, халыкларның күченешүе, җәмгыятебез үсешендә шәхес культы һәм торгынлык еллары китереп чыгарган тайпылышлар, кешенең кешедән читләшүе буыннар һәм туганнар арасындагы социаль элемтәләрне йомшарткан безнең заманда әнә шул кадерле тәҗрибәне, изге мирасны әдәби чаралар белән халыкка җиткерү аеруча мөһим бүген.

Навалбикә әби — авылдашларына карата да ихтирамлы һәм шәфкатьле җан иясе. Ул һәркемгә ярдәм кулы сузарга, кыенлыкка төшкән, бәлагә тарган һәр кешенең хәленә керергә әзер. Әлеге сыйфатлар аны бөтен тирә-якның иң абруйлы кешесе итә. Аның сүзенә һәркем колак сала, аңа һәркем киңәшкә килә. Авылның иң хөрмәтле һәм гадел кешесе буларак, Навалбикә әби — хөкемдар да әле. Автор шуны гәүдәләндерүче бер вакыйганы — эвакуацияләнеп килгән Элеонорага карата үзенең әшәке тәкъдиме белән кагылган чатан Гатаны акылга утырту күренешен бирә. «Гатаны өстерәп амбар алдына алып чыкты да, чалт берне тегенең яңагына! Күзеннән утлар күренгәндер». Амбар алдындагы халыкның ник берсе арага катышсын да, гарип кешене нигә рәнҗетәсең, дип ник берсе сүз әйтсен! Киресенчә, халыкның барысы да аның яклы: Навалбикә абыстай, җәлләмә бер дә, биргән юлы ныграк бир, безнең өчен дә булыр»,— дип хуплап тора. Гата да бу хөкемне тиешенчә кабул итә.

Без дуслык дибез, интернационализм дибез... Ә бит бу сыйфатлар гап-гадәти тормыш шартларында, үзара аралашып яшәү барышында туа һәм тамыр җибәрә. «Кеше булган кешенең һәр кешедә эше бар» диган кагыйдә белән яшәүчеләр башка милләт вәкилләренә карата да ихтирамлы була. А. Хәсәнов үз героеның шушы сыйфатын үтә бер җылылык һәм мөлаемлык белән самими итеп сурәтли алган. Иң элек бу сыйфат Навалбикәнең Фекла әби белән үзара мөнәсәбәтләрендә чагыла. Автор сынландырганча, бу ике карчыкның язмышлары уртак. Икесе дә иртә тол калганнар, икесенең дә уллары фронтта. Үзләре бер-берсенең телләрен дә юньләп белмиләр, ләкин «бер-берсен бик оста аңла-

шып, бер көрешсәләр аерыла алмыйча рәхәтләнеп эч бушаталар». Шунысы әһәмиятле, бу ятимә карчыкларның милли гореф-гадәтләргә ихтирам белән караулары игътибар үзәгенә куелган. Фекла әби, мәсәлән, Навалбикәләрдә һичкайчан гыйбадәт кылмый, чукынмый, күчтәнәчсез йөрми. «Фекла түти ишектән керүенгә, әбием дә орчык булып бөтерелә башлый. Мине тавык оялары карап керергә йөгертә. Үзе, тик шушындый тантаналы очраклар өчен генә дип сандыкта бик пөхтәләп саклаган, баш-башларын бик матур итеп чиккән, ап-ак батист яулыгын бөркәнеп ала. Аны үзенчә матур итеп, бик килештереп артка каерып бәйләп, коштабакта коймак туглый». Кыскасы, ике ахирәтнең һәр очрашуы бәйрәм төсен ала. А. Хәсәнов сурәтләвендә болар төрле милләттән булган гади хезмәт кешеләре арасындагы эчкерсез һәм кунакчыл мөнәсәбәтләр булып кабул ителә.

Автор үз героеның интернационалист җанлы булуын рус хатыны Элеонора белән мөнәсәбәтләрендә дә ассызыклый. Навалбикә әби ире сугышка киткән ике балалы бу хатынга үз өендә җылы почмак бирә, авыл һөнәрләренә өйрәтә, юклы-барлы ризыгын уртаклаша.

Авылы халкы җыеп биргән акчага төзелгән танкта сугышып яраланган һәм Сарапул госпиталенә эләккән латыш егете Перкунасны алып кайтып, колхозда калдыру фикерен дә Навалбикә әби әйтә. Соңрак бу егет күрше кызы Васфиягә өйләнеп тә куя. Бусы инде, минемчә, авторның арттырып, чама хисен онытып җибәрүе. Әдәби әсәр — ботка түгел, кат-кат май өстәү аның тәмен дә, ямен дә җуя...

Тулаем алганда, әсәрдә төрле милләттәге гади кешеләрнең дуслыгы, рухи туганлыгы матур гәүдәләнеш тапкан. Халыклар дуслыгы тәҗрибәсен үтемле итеп сурәтли белү безнең көннәрдә аеруча актуаль.

Әсәрдән аңлашылганча, өлкән буын кешеләренең гүзәл сыйфатлары һәм тәҗрибәсе хикәяләүчегә — Навалбикә әбинең оныгына да табигый күчкән. Малайда өлкән буынга карата олы хөрмәт хисе формалашкан. «Аның матур истәлегенә лаек булып яшисем килә»,— ди повестьның яшь герое.

Китапта әдәбиятыбызда җиң сызганып эшләгән һәм эшләп килүче әдипләргә багышланган истәлекләр, әдәби портретлар зур урын тота. Автор үзе яхшы белгән әдипләр турында яза. Әдипнең шәхесе һәм иҗаты берлеге аны аеруча кызыксындыра.

Очерк геройлары барысы да (Г. Әпсәләмов, И. Гази, С. Сөләйманова, Г. Афзал, Р. Төхвәтуллин һ. б.) — язучылык эшенә халыкка хезмәт итү дип карап, аны илаһилык дәрәҗәсендә күтәргән, шуңа мөкиббән киткән, әдип шәхесенә ифрат зур таләпләр куйган кешеләр. «...Безнең хезмәт — дөньяда иң авырларның берсе... Монда сиңа берәү дә, хәтта яраткан хатының, сөйгән балаларың да ярдәм итә алмый... Шуңа күрә дә безнең хезмәт иң почетлы хезмәтләрдән санала, шуңа күрә дә халык аны ихлас күңелдән ихтирам итә». Менә язучы хезмәтенә күренекле прозаик һәм публицист Г. Әпсәләмовның бәһасе, мөнәсәбәте. «Совет язучысы энҗе бөртегедәй саф булырга тиеш». Бусы — язучы өчен И. Гази бәян иткән әхлакый канун.

А. Хәсәнов очеркларының тарту көче шунда, ул үз геройларының халык язучысына хас булырга тиешле сыйфатларын декларация рәвешендә генә игълан итеп калмыйча, аларны үзләренең яшәү рәвеше принципларына әверелдерүләрен, ягъни сүзләре белән эшгамәлләренең берлеген күрсәтә алган. Әйтик, ул моны шул ук Г. Әпсәләмов һәм И. Гази мисалларында исбатлаган.

Автор үз геройларының халыкчанлыгын, хезмәт сөючәнлеген, кешелеклелеген, гадилеген, киң күңеллелеген, ярдәмчеллеген һәм башка сыйфатларын да төрле хәлләрдә, еш кына көлке ситуацияләрдә җанландырган. Бер-ике мисал китерим. Габдрахман Әпсәләмов, мәсәлән, «кешегә ярдәмгә дигәндә, йөрәген ярып бирергә әзер» торган әдип итеп сурәтләнә. Әнә ул, каты авыру булуына карамастан, Лениногорскидан урынсызга рәнҗетелгән урта мәктәп укытучысына ярдәм кулы суза. Әдип партиянең шәһәр комитеты секретаре исеменә хат язып сала. Икенчедән, бу эшне истәлекләр авторына да тапшыра, «кайткач та райкомга да, райисполкомга да кер, минем исемнән сөйләш»,— ди ул. «Әгәр вакытында рухи теләктәшлек күрсәтелмәсә, бу укытучы мәктәптән китәр, бу исә аның үзе өчен генә түгел, ә бәлки мәктәп, балалар өчен дә зур югалту булыр иде». Ә инде Габдрахман аганың һәм аның гомер юлдашы Маһинур апаның истәлекләр авторына күрсәтеп килгән ярдәмнәрен сөйләп тә торасы юк.

Яки менә Хәсән ага Туфанның киң күңеллелеген, кешелеклелеген алыйк. Без аның өметле яшь авторларны аталарча һәм бабаларча ничек кайгыртып үстергәнен байтак беләбез. Ул аларга материаль яктан да ярдәм итеп килгән икән. А. Хәсәнов сурәтләгәнчә, җиде төн уртасында кунакханәдә ничек җылы кабул итә ул ике яшь язучыны. Алар төн буе гәпләшеп чыгалар. Хәсән ага тәкъдим итә:

«— Егетләр, сез нигә миннән әҗәткә акча сорап килмисез?.. Яшь чакта бит ул акча җитми, ә кирәк чагында гына сорап торыр кешесен дә тапмыйсың. Андый чакта туры үземә килегез». А. Хәсәнов бик дөрес әйтә: «чиксез киң күңелле, үзеннән бигрәк башкалар турында кайгыртып яшәгән Хәсән ага бу сүзләрен дә ихлас күңелдән, яшьләргә аз булса да ярдәмем тияр, дип әйткәндер инде».

Яки менә И. Газига хас сыйфатларның китапта ничек күрсәтелүенә игътибар итик. Без И. Газиның ялагайлануны, астыртынлыкны куралмаган шәхес булганлыгын яхшы беләбез. Менә шул сыйфатны истәлекләр авторы түбәндәге вакыйгага аша сынландырып бирә.

Республика язучылар Союзы идарәсе рәисе булып эшләгән чагында И. Газины Лениногорск сайлау участогыннан СССР Верховный Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәткәннәр икән. Менә ул сайлаучылар белән очрашуга килә. Аны озатып йөрү, иҗаты турында сүз әйтү вазифасы истәлек авторына йөкләнә. Билгеле инде, ул И. Гази тирәсендә әйләнә. Әмма өлкән әдип моны һич тә өнәми. Бу егет минем тирәдә ялагайланып йөри, йә повестен журналда бастырасы, йә китабын чыгарасы килеп сырпалана дип шикләнә. Эшнең асылына төшенгәч кенә аның мөнәсәбәте үзгәрә. «Гади кешеләр» романына карата тәнкыйть сүзләре ычкындыргач бигрәк тә. «Менә болары өчен рәхмәт сиңа,— диде Ибраһим ага һич көтмәгән тонда.— Югыйсә мине, председатель итеп сайлаганнан бирле, гел мактыйлар гына. Ни язсам, шуны мактыйлар. Күзгә карап дөресен әйтүче дусларым кимеде».

Китаптагы һәр истәлектә шулай: табигый да һәм көлкеле дә вакыйгалар аша һәр әдипнең теге яки бу сыйфаты ачыла. Шуңа күрә очеркларны йотлыгып укыйсың, һәм уйлыйсың: безнең танылган әдипләребездә халыкның үзеннән килгән төпле әхлак тәҗрибәсе бар. Таратасы, яшь буынга сеңдерәсе кыйммәтле тәҗрибә ул.

Китапта ике публицистик әсәр дә урын алган. Болары — «Гәрәбә диңгез ярларында» һәм «Бал дисәң, бер кими...» исемле очерклар. Аның беренчесендә автор Литва ССРның истәлекле урыннарына сәяхәт вакытында туган тәэсирләрен уртаклаша. Икенчесендә сүз — умартачылык серләре турында. Соңгысы табигать дөньясының күбебезгә аз таныш булган бер могҗизасы — бал кортларының «яшәү рәвешен» танып-белү җәһәтеннән кызыклы. Очерклар укучының дөньяви карашын киңәйтүгә булышалар.

«Гәрәбә диңгез ярларында» исемле юльязма Литвада табигатьне, аның җанлы һәм җансыз байлыкларын саклау тәҗрибәсенә багышланган. Литва халкы үзенең туган-үскән җирен ярата, кадерли, иркәли. Анда 194 дендрологик парк, 97 геологик истәлек, 261 төр үсемлек хөкүмәт тарафыннан сак астына алынган. Автор әнә шул табигать һәйкәлләренең гүзәллеген, файдасын, саклавышын тәфсилләп сурәтли.

«Баһбайлар ял йортында» дигән бүлекчә аеруча хисле һәм тәэсирле. Клайпеда шәһәреннән берничә чакрым читтәрәк безнең илебездә бердәнбер булган атлар санаторие бар икән. Шул санаторий, андагы баһбайлар аеруча бер җылылык һәм ихласлык белән язылган. Бу сурәтләмәнең игътибарны тарту көче шунда, автор үзенең үсмер чагындагы атлар дөньясына бәйле шәхси тәҗрибәсен атларга мәңгелек мәхәббәтендә яңарта. «И-их, егетләр! Атларны яратмаган кеше буламыни! Әй мин үзем аларны гомер буена сүнмәс-сүрелмәс кайнар мәхәббәт белән яраттым. Бер уйласаң, гаҗәп инде, үзе ачы, үзе дегет сымак күе тир исе минем өчен иң тәмле, иң затлы хушбуй исләреннән дә татлырак. Яшь колыннарның әнкәсенә иркәләнеп, нечкә генә итеп, ярым кыргый айгырларның топ-топ дөньяны яңгыратып кешнәвен, валлаһи, симфонияләргә тиңләп тыңлыйм. Үзегез дә тыңлап карагыз әле: тигез таш юл өстеннән дагалы атның чаптырып килүе симфония түгелме?» Атларга мәхәббәт авторның нәселеннән үк килә икән. Алай гына да түгел, халык тәҗрибәсе буларак, буыннан-буынга күчеп килә икән. Авылда атларга мөнәсәбәтне кешенең кешелеген билгели торган сыйфат итеп караганнар. Бу — безнең заманда аеруча актуаль түгелмени!

Әлбәттә, табигать һәм аның байлыгы хакындагы сурәтләр автор өчен үзмаксат түгел. Ул безнең төбәк табигатенең дә Литваныкыннан ким булмавын ассызыклап бара, аны саклый белмәвебезгә офтана. «Безгә, Татарстан кешеләренә, суын эчкән, ипиен ашаган, урман-суларыбызны, кыр-басуларыбызны зурлап, кадерләп, саклап тоту өлкәсендә литвалы дусларыбыздан күп яхшы, гыйбрәтле нәрсәләргә өйрәнеп булыр иде», ди. Чыннан да, бездә бу хакта күп сөйләнә, әмма аз эшләнә. Һәм автор конкрет мисаллар да китерә. Әйтик, Лениногорск якларында урманнарны самолеттан дуст белән агулыйлар. Язучы укучыга турыдан-туры мөрәҗәгать итә: «Хөрмәтле замандаш... Бу нәрсәләр турында син дә уйлансаң икән. Чөнки табигатьне саклау — безнең уртак эшебез».

«Бал дисәң, бер кими...» очеркы да табигатькә мөнәсәбәт хакындагы сүзнең дәвамы. Беренчедән, анда бал кортлары турында нинди генә кызыклы мәгълүматлар юк! Үзе бер тикшеренү нәтиҗәсе. Юкка гына автор: «Бу мәсьәләне өйрәнүгә бер бөтен җәемне багышладым»,— дими. Юньле очерк язьйм дисәң, бу табигый. Икенчедән, очеркта умартачылыкның халык хуҗалыгындагы экономик файдасы исбатлана. Умарта хуҗалыгы, эшне белеп оештырганда, бер сумга йөз сум табыш бирә. Җитмәсә әле, бал кортлары чәчүлекләрне серкәләндерүдә әйтеп бетергесез файдалы эш башкара. Ә бу — глобаль проблема. Алай гына да түгел, бал кортлары ышанычлы метеорологлар да әле.

Өченчедән, А. Хәсәнов умарта хуҗалыгын алып баруның үткәндәге һәм хәзерге тәҗрибәсенә дә, күмәк һәм шәхси тәҗрибәгә дә мөрәҗәгать итә, үзенең тәҗрибәсен дә «кушып» җибәрә. Бу тәҗрибәләрнең барысы да үтә мавыктыргыч тасвир ителгән. Моның сере, мөгаен, авторның әлеге тәҗрибәгә актив мөнәсәбәтендә, фәннилекне эмоциональлек белән сугара белүендә, ихласлыгында. Ягъни публицист автор тәҗрибәне үзенең хисләр өермәсе аша уздыра. Ниһаять, автор ярсып-ярсып файдалы тәҗрибәне үзләштерергә һәм таратырга чакыра. «Әгәр мин булсаммы?! Миннән генә торсамы? Умартачылыкны текә

күтәрү, аннан мул итеп уңыш ала башлау өчен, хуҗалыкның бу тармагын штанга күтәрүчеләргә, гөрс-гөрс килеп көрәшеп мәйдан тотучы яшьләргә йөкләр идем... Әгәр миннән генә торса, һәр авыл кешесенең өй түрендә кимендә ике-өч баш умарта асратыр идем. «Асрату» дип әйтү бу очракта дөрес тә түгел әле. Чөнки умарта кешенең үзен асрый...»

Кыскасы, А. Хәсәнов укучыларга файдалы җыентык тәкъдим иткән. Аннан гыйбрәт тә, үрнәк тә алырга мөмкин.

Үзгәртеп кору заманында акыллы публицистиканың абруе бик үсте. Әйтик, руста аның сыйфаты бик тә күтәрелде, сугышчанлыгы, аналитик көче артты, яңа исемнәр пәйда булды. Моның төп сәбәбе — яңа фактларның ачылуында, хәбәрдарлык һәм демократия биргән иҗат ирегенең колач җәюендә генә түгел, ә фән белән публицистиканың бергә кушылып китүендә. Кызганычка каршы, безнең татар публицистикасында сыйфат үзгәреше бик аз сизелә, хәзергә сүлпәнлек, пассивлык хөкем сөрә. Мондый шартларда публицистика кануннарын әйбәт үзләштергән А. Хәсәнов актуаль проблемаларны күтәрүгә, анализлауга һәм аларны чишү юлларын эзләшүгә зуррак өлеш кертә алыр иде. Димәк, тагын да активлаша төшәргә, кыюлыкны арттыра барырга, иҗтиһат итәргә генә кирәк.

**Флорид ӘГЪЗАМОВ.**

# БОРЫНГЫ ДУСЛЫК ЭЗЛӘРЕННӘН

Бер генә халыкның да мәдәнияте милли кысалар эчендә генә бикләнгән хәлдә үсеш кичерә алганы юк, бу яңалык түгел. Бик борынгы заманнарда ук инде халыклар бер-берсе белән тыгыз мөнәсәбәттә булырга омтылганнар, сәүдә иткәннәр, мәдәни бәйләнешләры торган саен ныгый, киңәя барган. Шуның өчен дә кардәш халыкларның әдәбиятын, тарихын өйрәнгәндә үзара уртаклыкларның күплеге күзгә чалына.

Хәзерге чорда мәдәни-әдәби бәйләнешләрны өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Гасырлар буена яшәп килгән дуслык, тугандашлыкны яктырткан хезмәтләр басыла. Бу — заман таләбе. Илебез күләмендә татар халкының тарихы, мәдәнияте белән кызыксыну арткан-нан арта бара. Кыргызстан һәм Үзбәкстан нәшриятларында дөнья күргән китаплар да әнә шуны раслый. Беренчесе — Кыргыз туганнарыбыз җиренә төрле сәбәпләр аркасында барып урнашкан татарлар турында булса, аның икенчесе татар халкының үткәненә, әдәбиятына, шагыйрьләренә, революционер улларына багышланган. Сүзебез — икенчесе хакында.

Ташкент шәһәрендә Гафур Голәм исемендәге әдәбият һәм сәнгать нәшрияты «Киләчәккә сәлам» исемле әдәби-тәнкыйть мәкаләләре тупламын бастырып чыгарды. Җыентык дүрт бүлекне үз эченә ала. Шуларның өчесен («Дуслык җепләре», «Дәвер, мохит, иҗаткарь», «Шигърият авазлары») Бегали Касыймов һәм берсен («Тарих сабаклары») Әкрам Каттабеков язган[1].

Б. Касыймов мәкаләләрендә татар халкы белән үзбәк халкы арасындагы тарихи дуслык сәхифәләре яктыртыла. Әкрам Каттабеков исә үзенең тикшеренүләрен үзбәк әдәбиятында тарихи романның үсеш проблемаларына юнәлтә.

«Галиҗәнап Искәндәр дөньяны басып алды. Ләкин аның тынгы белмәс күңеле барыбер тынычланмады... Искәндәр уйга талды». Бу борынгы төрки халыклардан булган татарлар һәм аларның VII-XVI гасырлардагы бөек шәһре Болгар турындагы риваятьтән алынган юллар, әлбәттә. Әмма ул дөреслектән ерак түгел»,— дип яза автор. Бу бүлек унике бүлекчәдән гыйбарәт. Аларның һәрберсендә билгеле бер чор, аерым тема күздән кичерелә. Мәсәлән, «Шәһре Болгар хикаяте» һәм «Болгар хакыйкате» дип аталган бүлекчәдә Идел буе Болгар дәүләтенең үз вакытында Урта Азия һәм Европа халыкларын бер-берсенә якынайтуда зур роль уйнаганлыгы әйтелә. Биредә Болгарга килгән Ибне Фазланның, Хәмит әл-Гарнатыйның танылган галим Ягъкуб бин Ногман белән очрашуы турында сөйләнә һәм, татар галимнәренең хезмәтләренә таянып, «X гасырда ук инде болгарның укымышлы зыялылары әл-Харәзми, Ибне Сина әсәрләрен укыганлыклары» күрсәтелеп үтелә. Автор татар һәм үзбәк халыклары арасындагы дуслык тамырларын бик борынгы заманнардан эзләү кирәклеген әйтә. Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» әсәре Харәзм дәүләте җирлегендә язылган булуы ихтимал икәнлеген һәм яңарак заманнарда яшәгән харәзмле Насретдин Рабгузиның күрсәтелгән әсәрне белгән булуы да мөмкин, дип фараз кыла мәкалә авторы (9 бит).

«Әгәр Сарай шул булса, ул чыннан да сокланырлык».

[1] Косимов Б., Каттабеков А. Салом келажак. Тарих сабоклари. Тошкент, 1986.

«Сарайның шагыйре — илнең гидайе».

Камал Хуҗәнди һәм Сәйф Сараи шигырьләреннән алынган бу юллар «Сарай язмышы» дигән бүлекчәгә эпиграф итеп куелган. Тарихта 1219-1221 еллар Урта Азия халыкларына кара кайгы алып килүе белән билгеле. Чыңгыз гаскәре Бохара, Сәмәрканд, Үргәнеч шәһәрләрен дә, Болгар, Биләр, Суар шәһәрләрен дә хәрабәгә әйләндерә. Тарихка шул рәвешчә мөрәҗәгать итеп, Б. Касыймов кайбер кулъязмалар турында мәгълүмат китерә. Мәсәлән, фән өчен гаять кыйммәтле «Коман мәҗмугасе» турында танылган татар галиме Газиз Гобәйдуллинның фикере күздән кичерелә.

Бу җыентык сәхифәләрендә Казанның тарихи урыннары телгә алына. Казан маликәсе Сөембикә исеме белән бәйле манара турындагы риваять укучыда зур кызыксыну уята, әлбәттә. Беренче Май мәйданында басып торган Муса Җәлил һәйкәле, Татарстан республика музеенда сакланган экспонатлар хакында да мавыктыргыч итеп язылган. Пугачевның Казан Кремле гауптвахтасыннан ничек итеп качканлыгы да хикәя ителә.

Казан ханлыгы мөстәкыйль дәүләт буларак яшәүдән туктагач та илдә тынычлык урнашмаган, моның шулай икәнен без тарих сәхифәләреннән укып беләбез. Б. Касыймов, бу чорда булып узган вакыйгалар турында язганда, рус чыганакларына да мөрәҗәгать иткән. «Ирек сөяр татар халкы басып алынуның беренче көннәреннән үк каты көрәш алып барган. Мәсәлән, князь Курбский 1553-1558 елларда татарлар һәм руслар арасында алты ел дәвамында туктаусыз барган сугышлар турында язып калдырган. 1670-1671 елларда Хәсән Айбулатов җитәкчелегендәге татарлар Степан Разин белән иңгә-иң барганнар. 1773-1775 еллардагы Пугачев восстаниесендә исә татарлар һәм башкортлар бик зур роль уйнаган» (14 бит).

«һәр халыкның үз моңы бар, ләкин дөньядагы барлык аналар да балаларына бишек җыры җырлаганда бер үк мәгънәдәге сүзләрне файдаланалар: исән үс, бәхетле бул, олыларга итагать күрсәтә торган бул, белемгә омтыл һ. б. «Өна алласи»— үзбәк телендә бишек җыры дигән мәгънәдә йөри. Шундый баш астында җыентыкның алтынчы бүлекчәсе башланып китә.

*Әлли-бәлли итәр бу,*
*Бохарага китәр бу.*
*Гыйлем тәхсил итәр бу,*
*Максудына җитәр бу...*

Бу җырны татар аналары бала тирбәткәндә җырлаганнар. Бохараның даны татарлар арасында киң таралган булуы мәгълүм нәрсә. Татар язучыларының әсәрләрендә бу шәһәр гыйлем үзәге буларак та сурәтләнә.

Әлеге бүлекчәдә йөзләп татар укучысының Бохарада белем алулары турында әйтелә, кайберләренең исемнәре дә искә алына: Мөхсин бин Ибраһим әш-Шәши, Мөхәммәт Йосыф әл-Ясакый, Хөснетдин бин Бәшир әт-Түнтәри, Габдерәхим Утыз Имәни һ. б.

Төрле чыганакларны тирәнтен өйрәнү авторга хезмәтен уңышлы башкарып чыгарга ярдәм иткән. Мәсьәләне тагын да тәфсилләрәк итеп өйрәнергә теләүчеләр өчен биредә татар галимнәренең хезмәтләре күрсәтелә. Мәсәлән: «...танылган татар мәгърифәтчесе, галим Риза Фәхретдиневнең 565 татар галименең тәрҗемәи хәлен яктыртуга багышланган ике томлык «Асарь» исемле китабы битләрен актарып чыксагыз, бу галимнәрнең күбесе Бохарада укыганлыгы мәгълүм булыр»,— дигән тәкъдим турыдан-туры укучыга төбәп әйтелә.

Үзбәк укучысы Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил, Һади Такташ кебек татар язучыларының иҗаты, аерым әсәрләре белән дә яхшы таныш. Ә менә Габдерәхим Утыз Имәни, Әбелмәних Каргалый, Габденнасыйр Курсавиларны белүчеләр үзбәк укучысы арасында бармак белән санарлыктыр. Алары да тел һәм әдәбият фәне өлкәсендә эшләүчеләр генә дисәк, ялгыш булмас. Менә шуңа күрә Б. Касыймовның, форсаттан файдаланып, үзбәк җәмәгатьчелеген XVIII-XIX йөз татар шагыйрьләре белән таныштыруын әһәмиятле эш итеп карарга кирәк.

Мәкаләдә Әбелмәних Каргалыйның Төркиягә җибәрелгән илчелек составында кәтиб (секретарь) вазифасын башкаруы һәм Мәккә, Мәдинә, Хиҗаз, Каһирә шәһәрләрендә булганлыгы хикәя ителә. Аның «Тәшәккүр», «Сәхрәдә» исемле шигырьләре, «Тәрҗемәи Хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» дигән әсәре турында мәгълүмат бирелә.

Көнчыгыш халыклары арасында үзенең фәнни хезмәтләре белән зур ихтирам казанган Шиһабетдин Мәрҗани Бохарада унбер ел яшәгән. Биредә галим, белем алу белән бергә, остазлык та иткән. Б. Касыймов бу уңайдан Мәрҗанинең йөзләгән шәкерткә дәрес биргәнлеген әйтеп уза, фәнни хезмәтләре арасында «Үзбәкстан халыкларының тарихын өйрәнү өчен дә кыйммәтле материал» барлыгын әйтә.

В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты китапханәсенең тарихы, анда саклана торган китаплар, шунда эшләгән аталы-уллы Хәлфиннар, Мәхмүдов, Фәезхановлар һәм аларның хезмәтләренә кагылышлы кайбер мәгълүматлар да мәкаләдә урын алган.

XX гасыр башларында Россиядә исә башлаган революция җилләре Төркстан далаларына да килеп җитә. Кардәш үзбәк халкы арасында революцион фикерләрне пропагандалауда актив катнашкан татар уллары да аз булмаган. Әйтик, В. В. Куйбышев юлламасы белән Бохара Коммунистлар партиясенең Үзәк Комитетында җаваплы вазифаларны

башкарган Ш. Әхмәдиев, соңрак шунда ук матбугат назире (министры) булып эшләгән Мәхмүт Бәдәйли, Урта Азиягә килеп мамык эшкәртүчедән Бохара халык республикасы җитәкчеләренең берсенә әверелгән Акчурин һәм башкалар бар. Күп еллар дәвамында Урта Азия дәүләт университеты рабфагында Зариф Бәшири үзбәк теленнән дәресләр биргән (1919-1926 еллар).

Иҗат язмышлары теге яки бу дәрәҗәдә Үзбәкстан белән бәйле татар язучыларының саны бик күп икәнлеген икърар итеп, «татар совет әдәбияты ветераннарыннан булган Дәрҗия Аппакова һәм беренче карлыгач, актив җәмәгать эшлеклесе Гыйффәт Туташ хакында аерым әйтми узу кыен»,— дип искәртеп уза автор. Дәрҗия Аппакова 1928-1943 елларда Ташкентта яши. Биредә ул үзенең берничә әсәрен иҗат итә, шулар арасында Үзбәкстанда коллективлаштыру хәрәкәтен яктырткан «Хезмәт» (үзбәкчә исеме «Мехнат») романы да бар. Бу роман 1935 елда Ташкентта нәшер ителә.

Гыйффәт Туташ (Заһидә Борнашева) 1917-1933 елларда Үзбәкстанда яши, җитәкче эшләрдә эшли, ә соңрак Хатын-кызлар мәгариф институтының директоры була. Б. Касыймов аларга үзбәк халкының ихтирамы зур икәнлеген әйтә. Мәкаләдә үзбәк-татар театрлары арасындагы бәйләнешләр да бәян ителә.

1923-1936 елларда үзбәк язучыларыннан Гафур Голәм, Зыя Сәгыйть, Әбелхәмит Мәҗиди һәм Шакир Сөләйман һ. б. Татарстанда булып китәләр. Алар Татарстан республикасының тормышы, мәдәнияте белән танышалар, язучылар белән очрашалар. Шул ук бүлектә татар әдипләреннән Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, М. Максуд һ. б. ның әсәрләре үзбәк укучысы тарафыннан яратып укылуы да әйтелә.

Китапта татар халкының сөекле шагыйре Габдулла Тукайның тормышын, иҗатын яктыртуга зур урын бирелгән. Бу бик табигый хәл, чөнки аны үзбәкләр дә үзләренең шагыйрьләре итеп саныйлар. Моның шулай икәнлеген үзбәк халык шагыйре Гафур Голәм язып чыккан иде инде.

Габдулла Тукайга багышлап 1914 елда Төркстан матбугатында күп санлы мәкаләләр басылып чыга. Бегали Касыймов әлеге мәкаләләрнең авторлары хакында яза; үзбәк язучысы Таволлоның Тукайның вакытсыз үлеменә әрнү белдереп язган шигырен искә ала:

*Җөмлә фикерем кичен-көндез сезнең хакта,*
*милләтем,*
*Син сәламәт — мин тынычмын, ә сырхавың*
*илләтем!*
*Мәрхүм Габдулла Тукай күк яшь чагымда*
*китмәсәм,*
*Гаҗизанә шагыйрең булмакка бардыр*
*ниятем...*

Тукай үзбәк шагыйре Таволлоның (Түләгән Хуҗамеров 1882-1939 елларда яшәгән) яраткан шагыйре була. Ул үзенең язмышын Тукайныкына охшата. Таволло да Габдулла Тукай шикелле ятимлекнең әрнүле көннәрен күп күрә, аның әчесен кечкенәдән татып үсә. Үзбәк шагыйре өчен халкыбызның бөек улы гадел җырчы, гуманист, олы шәхес булып кала. Таволлоның иҗатын өйрәнгән галим Әкрам Каттабеков «Шагыйрьнең хакыйкать сүзе» исемле мәкаләсендә «Тукай аның (Таволло — Җ. З.) өчен тормышта да, иҗатта да үрнәк һәм һәйкәл булып калды»,— дип яза. Шул уңайдан Таволлоның халыклар дуслыгына дан җырлавын да әйтеп үтәсе килә. Ә. Каттабеков Ташкент шәһәрендә үзбәк телендә театр уйнала башлаган көннәрдә Таволлоның: «...Рус, әрмән, үзбәк, татарыбыз белән янма-ян утырып алардан файда алам, алар белән аралашудан ләззәт табам»,— дип язып чыкканлыгын күрсәтә.

Б. Касыймов үз мәкаләсен «Халкы яраткан шагыйрь» исемле бүлекчәнең түбәндәге юллары белән тәмамлый: «Чыннан да, Габдулла Тукай үз шигырьләре белән бүгенге укучыга да замандаш. Ул гасырыбызның бөек төзелешендә — яңа җәмгыять төзүдә катнаша...» (53 бит).

Тарихи фактларга мөрәҗәгать итәме, әдәбият-сәнгать мәсьәләләре турында язамы, татар халкының күренекле уллары-кызларының исемнәрен искә аламы — Б. Касыймов гадел күзлектән карап, конкрет фактларга таянып эш иткән һәм уңышка ирешкән. Бәхәссез ки, Б. Касыймов күпкырлы белем таләп итә торган мондый хезмәтне уңышлы башкарып чыга алган, шуның белән үзбәк һәм татар халыклары арасында күп гасырлар буена яшәп килгән традицион дуслыкны ныгытуга зур өлеш керткән.

**Җәмил ЗӘЙНУЛЛИН,**
филология фәннәре кандидаты.

*Илебез тәнкыйтьчеләре*
*татар язучылары турында*

## Виталий Василевский

# КӨМЕШ ДАГА

Фәнгә һәм анда эшләүче кешеләргә багышланган матур әдәбият әсәрләре артык күп язылмый. Хәтта меңләгән язучысы булган рус совет әдәбиятында да бу шулай. Шуңа күрә татар язучысы Җәвад Тәрҗемановның бөек галим Лобачевскийга багышланган «Көмеш дага» романы бер татар әдәбиятында гына түгел, ә бөтен совет әдәбияты өчен күңелле яңалык булып тора.

Әле алай гына да түгел. Фән һәм галимнәр тормышын сурәтләүгә багышланган бу әсәр татар әдәбиятында интеллигенция темасын ачуга шактый зур өлеш кертә, әдәбиятның зыялыгын арттыруга булыша. Лобачевский яшәгән чордагы — унтугызынчы гасыр башындагы — Казан романда алдынгы фәнни үзәк буларак тасвирлана. Укытучыларның да күбесе чын мәгънәсендә зыялы кешеләр. Әсәрдә татар зыялыларының сурәтләнүе дә, һичшиксез, романның зур уңышыннан саналырга лаек. Аларның саны ишле түгел — ләкин, аның каравы, фәнгә һәм үз эшләренә чын күңелдән бирелгән җаннар. Гимназиянең өлкән укытучысы Нигъмәт Ибраһимов бигрәк тә аерылып тора. Ул фәндә үзеннән соң үсәчәк күпләгән милли кадрларның чишмә башын тәшкил итә.

Китапның үзәгендә, әлбәттә, бөек галим Лобачевский образы. Ул — Россия фәне тарихына гына түгел, ә бөтен дөнья хәтеренә фәннең өр-яңа юлын ачучы булып керде. Чынбарлыкны һәм галәмне өйрәнүдә табылган әнә шундый яңа гениаль ысул өчен аны хаклы рәвештә «геометрия Колумбы» дип атадылар да. Бу уңайдан тагын шуны да әйтеп узасы килә. Көнбатыштагы кайберәүләр Россияне фән һәм культура ягыннан артта иде дип гаеплиләр. Ә бит Ломоносов белән Лобачевскийның титаник образлары гына да андый ялганны юкка чыгара! Димәк, илебез укучыларында патриотик хисләр тәрбияләү ягыннан да романның әһәмияте зур дип әйтә алабыз.

Матур әдәбиятта фән дөньясы турында язуы җиңел эш түгел. Ә математикның фәнни иҗаты хакында психологик яктан белеп һәм төгәл итеп язу — тагын да кыенрак. Ләкин биредә автор үз алдындагы бурычны уңышлы үтәгән. Романны укыган чагында укучы бөек галимнең иҗат лабораториясенә үтеп керә, аны шактый реаль күз алдына китерә. Әлбәттә, математика кебек катлаулы өлкәнең гади укучы өчен кайбер серләре калу да гаҗәп түгел. Алар әсәрдә күренә. Ләкин эш бит анда түгел. Иң мөһиме — әсәрдә бөек галимнең алга рухланган халәте, олы омтылышлар һәм изге ниятләр белән җан-фәрман мавыгып йөрүе бар. Ә моны үзенең күп төрле тасвирлау чаралары белән бары тик әдәбият кына эшли ала. Димәк, тормышның күп кенә әхлакый һәм фәлсәфи якларын яктыртучы проза әсәре буларак та роман әһәмияткә лаек.

Инде романны укый башлыйбыз. 1802 елның көзендә Мәкәрҗәдән Казанга үзенең өч малаен ияртеп чиновник хатыны Лобачевская килеп төшә. Бу образ әсәрдә зур җылылык белән тасвирлана. Иренең нык кына эчүенә карамастан, Лобачевская ханым үзендә балаларын тәрбияләп аякка бастырырлык, укытырлык көч һәм түземлек таба. Әлеге гаиләнең ярдәмчел дусты булган укымышлы барин С. С. Шебаршин да истә кала. Бу кеше дөньясын онытып математика белән мавыга, аны бөтен фәннәрнең атасы дип саный. Шебаршинның һәм әниләренең математикага булган зур мәхәббәтләре балаларга да күчә. Коля — булачак галим — бу фәнгә бигрәк тә әвәс булып чыга... Ләкин өй шартларында гына уку үзенең йомшак ягын да ача — гимназиягә имтихан вакытында кечкенә Коля югалып кала, аннан соң да әле тәртипкә ияләшә алмыйча, өенә кача. Әнисеннән тагын түземлек һәм акыл таләп итела.

Ул чактагы Казан тормышын тасвирлаганда да язучы уңыш казана. Ярминкәләр, базар күренешләре, төрле-төрле милләт кешеләре белән кайнап торган борынгы шәһәр укучы-

ның исендә кала, аны тәэсирләндерә... Ә гимназия тормышы исә, киресенчә, кырысрак итеп сурәтләнә. Коля бары тик өйдә генә җылылык таба. Өйдәге китаплар аңа үз-үзенә ышанычны югалтмаска, күңелен төшермәскә булыша. Һәм Коля бераздан: «Яңадан гимназиягә барасым килә...» — ди башлый.

Күп уку аның күңелен бертуктаусыз баетып тора. Әлбәттә, иң мөһим ачышлар да була. Китаплар аша Колумб образы белән танышуны бәләкәй Лобачевский өчен әнә шундый бер ачыш дип әйтергә кирәк. Бу каһарман шәхес белән булачак галим үтә нык мавыга, гимназиядә укыганда аңа багышлап шигырьләр дә яза. Шулай итеп романга Колумбның метафорик образы килеп керә. Биредә автор «яшь галим формалашу» дигән теманың нечкәлеген оста сиземли. Сәнгатьчә уңышлы чагыштырулар куллана. Мисал өчен, малайның әнисе белән беренче мәртәбә Казанга килеп керүен генә искә төшерик. Шәһәргә таба баручы юлның ике ягына да тәбәнәк баганалар утыртылган... Ул баганалар ике янәшә рәт булып еракка сузылганнар... Әнә шул мизгелдә автор яшь малай зиһенендә параллельлек күренешенең моңа кадәр күренмәгән көчле бер чагылышын искәреп үтә. Бу параллельләр аны каядыр дәшә сыман, нәрсәгәдер юл күрсәтә шикелле, ди... Шулай итеп яшь Николай күңелендә геометриягә илтәчәк бөек юл тәүге кат сизелеп ала. Җ. Тәрҗеманов бу нотага бик сак кына кагыла. Һәм дөрес тә эшли. Гомумән, әсәрнең буеннан-буена автор чагыштыру, метафоралар белән бик сак эш итә. Ләкин кайчагында әлеге саклыкның артыбрак китүе дә күзгә бәрелә. Чөнки алынган материал андый метафораларга урынны күбрәк бирергә дә мөмкинлек тудыра.

Бу романда Ибраһимов, Краснов, Корташевский кебек укытучы образларының аеруча оста иҗат ителгәнен билгеләп узарга кирәк. Әйе, ул чакта гимназиядә артык каты тәртип һәм муштра да булган, стройга өйрәтү дәресләре һәм карцерга утыртулар да булган... Ләкин алар белән бергә гимназиядә фәннәрне чын-чынлап үзләштерү дә барган. Романның бер өлешендә гимназист Коляның бүтәннәргә дәрес бирүе тасвирлана. Болай эшләү гимназиядә укучыны дәресен тагын да тирәннәнрәк үзләштерергә мәҗбүр иткән. Аның математикага булган сәләтен тагын да ныграк ачкан.

Ибраһимов һәм Корташевский кебек укытучылар белән якыннан аралашу булачак математик Николайның күңелен үстереп җибәрә, яңадан-яңа уңышларга дәртләндерә. Корташевскийның математиканы борынгы философия белән бербөтен итеп каравы яшьләргә бигрәк тә тәэсир ясый. Алар бу ике фәннең гармониясен аңларга тырышып үсәләр. Нәтиҗәдә дөнья турында киң масштабта уйлый белүче, күпкырлы фән кешеләре тәрбияләнә.




*Мәскәүнең «Радуга» нәшриятында француз телендә басылган китапның тышлыгы*

Гимназия тормышы шактый гына каршылыклар аша ага: карцерлар һәм баш күтәрүләр, начар ашатулар... Яңа буын интеллигентларның формалашуы әнә шундый каршылыклы шартларда бара. Ә берникадәр вакыт үтеп, Казанда университет ачылыр чак җиткәч — аңа 38 егетне кабул итәләр. Ләкин кемнәрне диегез?! Исемлекне укыйбыз: Сергей Аксаков, Еварист Грубер, Александр Княжевич, атаклы язучы бертуган Панаевлар, бертуган Перевощиковлар — һәм башка атаклы кешеләр.

Бу исемлекне укыган саен анда ил һәм халыклар өчен эш күрсәткән кешеләрнең һаман күбрәк табыла баруы кызыклы. Романның авторы да әсәрендә ул шәхесләргә киңрәк туктала алган булыр иде, әлбәттә. Мисал өчен Аксаков белән Панаевларны гына алыйк. Укучы кызыксынып кабул итәрдәй күпме тарихи вакыйгалар, фактлар алар язмышында!

Казанда университет ачылу тантанасына зур-зур галимнәр җыйнала. Фәннәр академиясенең вице-президенты Румовский да килә. Әсәрдә менә мондый өзек аеруча истә кала: вице-президент Казанга килгәч Коля Лобачевскийның бик бирелеп бер китап укып утыруын күрә. Аның китабын! Чынлыкта мондый хәл булган яки булмаган дип, бәхәсләшергә җыенмыйм — иң мөһиме: бу тарихи яктан булырга мөмкин күренеш. Димәк, дөрес күренеш!

Яңа ачылган университетка җитәкче итеп карагруһ Яковкинны куялар. Ә аннары инде карагруһның кара эшләре дә озак көттерми: ул Корташевский белән профессор Каменскийны эштән чыгара, Ибраһимов та авырый башлый... Карагруһ Яковкин үзенең кара эшләрен башкарганда барыннан да бигрәк немец профессорларына таяна — русча бөтен-

лай диярлек белмәүче, лекцияләрне дә бары тик немец телендә генә укучы немецләргә.

Кайбер урыннарда Җ. Тәрҗеманов гел мәгълүмат бирү юлына гына баса. Ә бу, минемчә, бик үк акланып җитми. Мисал өчен әсәрнең 181 битендә гимназиядә укучылар белән чит илдән килгән профессорлар арасында мөнәсәбәтләр киеренкелеген күрсәтүгә багышланган урын бар. Имтихан вакытында укучылар белемен объектив бәяләү урынына немецләр мыскыллы көләләр. Бу укучыларда ризасызлык уята... Тик автор менә шушындый четерекле мәсьәләгә багышланган күренешне өстән генә узып китә. Стилистик яктан төгәл булмаган җөмләләр дә кулланa.

Үзенең яраткан укытучылары киткәч, тиз кабынучан, хисчән Николай да университетны ташларга тели. Ләкин Корташевскийның хаты аңа ашыкмаска куша. Булачак галимнең язмышын хәл иткән бу урын укучының хәтерендә кала.

Яз килә. Бертуган Лобачевскийларның өчесе дә тормыш баскычлары буйлап әкренәкрен өскә таба күтәрелә. Өлкән бала Александр үзенең бик тә сәләтле булуын раслап тора, аңа бигрәк тә физика җиңелдән бирелә. Кечкенә Алексей да университетның беренче курсына кабул ителә. Николай исә гаиләдәгеләрне һәм таныш-белешләрен математикадагы казанышлары белән куандыра.

Билгеле, романда туганнар образларының өчесе дә бер үк дәрәҗәдә тирән эшләнмәгән. һәм моны аңлап та була. Чөнки авторның төп игътибарын билгән Николайның укучыга тасвир ителердәй хәл-әхвәлләре бик күп. Икенче яктан караганда аларның тормышында охшашлыклар да байтак. Шуның өчен дә Лобачевскийларның берсе турында тәфсилләп сөйләү бу яктан да аклана.

Николай гимназиядә укыган вакытта ук аны «математик» дип йөртәләр. Ә студент булгач бер мәлне «химик» кушаматы да тагыла. Чөнки ул чорда Николай, абыйсы Александр кебек, бу фән белән дә мавыгып ала. Ләкин Казанга күренекле математик Бартельс килгәч барысы да үзгәрә. Яшь егетнең зур галим белән беренче очрашуы романда әйбәт күрсәтелгән. Билгеле, биредә укытып киткән Корташевский инде Бартельска студент Николай Лобачевский турында әйткән була. Ләкин зур галимнең яшь егеткә ихтирамы мондый тәкъдим нәтиҗәсендә түгел, ә аларның тигез торып дусларча сөйләшүләреннән соң, егетнең чыннан да кем икәнлеге күренгәннән соң уяна. Менә шушы битләрне автор танып-белү ягыннан тирән мәгънәле итеп яза алган.

Билгеле, романның бөтен урыны да мавыгып укыла дип булмый. Чөнки сүзнең фән дөньясы турында баруын онытырга ярамый. Мисал өчен укытучы Ибраһимовның өчпочмаклар проблемасы турында сөйләгән өлешен үтү укучыга кыенрак булыр. Ләкин дикъкать биргән кеше биредә дә авторның мавыгып язуын сизми калмас.

Романда укучы өчен кызыклы мәгълүмат күп. Мәсәлән, 221 биттә Николай Лобачевский үзенең укытучысы Корташевскийга мондый хат яза: «Адъюнкт Хәлфиннең «Татар теле грамматикасы һәм әлифбасы» дигән китабы университет типографиясендә басылып чыкты. Хезмәт хакымны алгач та, мин аны сатып алачакмын һәм өйрәнә башлаячакмын».

Менә шушындый урыннарны укыганда минем, укучы буларак, әлеге вакыйга турында тагын да күбрәк беләсем килде. Казан университетының ул чакта ук инде бөтен тирә-юньгә аң-белем тарату үзәге булганлыгы мәгълүм бит. Нәкъ менә Казан университеты каршында рус булмаган халыклар өчен учительская семинария дә оештырыла. Анда татар һәм башка халыклар мәктәпләре өчен укытучылар әзерләнә. Әлбәттә, бу инде Лобачевскийның чоры диган сүз, төп образдан киңәю диган сүз.

Тормыш ул кайчан да һәм кайда да тормыш инде. Шуңа күрә Николай Лобачевскийның да яшәве гел фәннәр үзләштерүдән генә тормаган. Бигрәк тә яшь чагында. Язмыш шуклыгы белән ул Яковкинның кече кызы Аннага гашыйк була. Тик кызганыч — романның бу өлеше бераз корырак, өстәнрәк язылган. Авторга биредә эмоция — хисләр, кичерешләр җитеп бетми.

Мәхәббәт белән бергә үк социаль конфликтлар да килә. Зур сәләткә ия икәнлеге күпләргә билгеле булса да, разночинец Лобачевский да ул конфликтлардан читтә кала алмый. Аннаның әтисе Яковкинның: «Аягызны юрганга карап сузмыйсыз! Бай кызга өйләнеп, үзегезгә карьера эшләмәкче буласыз!» — дигән яшь егеткә зур удар ясый.

Әйтергә кирәк: романдагы фәлсәфи һәм математик бәхәсләр бик тә җентекләп, күп көч салып иҗат ителгәннәр. Яшь галимнең үзендә чынбарлык хакында фәнни карашлар булдыру процессы бөтен катлаулылыгы белән күз алдына китереп бастырылган. Корташевский, Броннер кебек галимнәр белән аралашу, фәнни эңгәмәләр яшь галимнең фәлсәфи һәм атеистик фикерләрен тагын да ныгыта төшәләр. Шулай итеп Николай Лобачевский акрынлап ачылачак яңа математикага бара. 1811 елда ул, Яковкин интригаларына да карамастан, магистр итеп раслана.

Романда 1812 елгы Ватан сугышына шактый гына игътибар бирелгән. Ләкин әле, минемчә, биредә Лобачевский кебек бөек галимнең көчле патриотик хисләрен тасвирларга мөмкинлек зуррак иде. Төрле милләт вәкилләренең бу җиңүгә зур өлеш кертүләрен искә алсак — халык массаларының ничек итеп Наполеонны җиңә алуы, чыннан да, тирән фәлсәфи уйлануларга лаек. Шушы уйланулар нигезендә Лобачевский шәхесе үзе дә зурая ала иде.

Ә инде Казан университетындагы 1816—1817 уку елы егерме өч яшьлек профессор Лобачевскийның менә диган лекциясе белән башланып китә. Әлбәттә, бу лекция белән танышу укучыдан байтак кына махсус әзерлек һәм көч таләп итә. Ләкин, икенче яктан алганда, романның үзенчәлеге дә әнә шунда. Ул бит галим турындагы роман.

Әйе, без хәзер сокланып яза торган бөек галим Н. Лобачевскийның гомер юлы җиңел булмаган. Төрле киртәләр, көчле каршылыклар аңа бер-бер артлы очрап кына тора. Башта Анна, аннары Лиза — үзләре егетне яратсалар да — дворян булмаган кешегә гаиләләренең ризалык бирмәячәген белдерәләр... Иҗтимагый тормыш авырлыгын да истән чыгармыйк. Александр патша вакытында Голицыннар, Магницкийлар фикер хөрлегенә каршы чып-чын көрәш башлыйлар. Нәкъ шул вакытта университетның 9 профессоры үзләренең ирекле карашлары өчен эштән куыла. Лобачевскийга да ул чорда китапханәдә чистарту үткәреп, андый авторларның китапларын кулланудан алырга тәкъдим ителә. Хәтта илдәге университетларның бөтенләй ябылу куркынычы да килеп туа. Чөнки атеизм һәм ирек сөю учагы булган уку йортларыннан хаким кешеләр нык куркалар.

Фән ягыннан алып караганда да Лобачевскийга җиңел туры килми, аны ялгызлык тойгысы изә — чөнки евклидныкы булмаган геометрия заманны нык кына узып туа, ул Эйнштейнның нисбәтлелек теориясенә алшарт булып туа. Ул галәмгә, ә вакыт ягыннан алганда безнең чорга һәм әле аннан да ераккарак төбәлгән. Хәтта кайбер аспектларында аны әле бүгенге галимнәр дә аңлап ук бетерә алмыйлар.

Тик менә романның соңгы өлешендә фәнни материал артык күп. Автор матур әдәбият кануннарын бөтенләй үк истән чыгарган. Фәнни төгәллек кенә калган. Бусы яхшы билгеле. Тик...

Соңгы өлештә Лобачевскийның Петербургтан әнисенә язган хатлары бик уңышлы. Алар хискә бай, җылы күңел белән, яратып язылганнар. Хәлфиннәр гаиләсенә багышланган битләр дә язучының мактаулы эше дип саналырга тиеш.

Йомгак ясап шуны әйтәсем килә: бу әсәрдә, бөтен совет әдәбиятында беренче мәртәбә буларак, Лобачевскийның тулы канлы образы тудырылган. Безнең алда бер үк вакытта милли дә булган һәм гомумкешелек идеалларына да хезмәт итүче фән каһарманы гәүдәләнә. Романның төп әһәмияте әнә шунда.

---

## *Котлыйбыз!*

### Яхъя Халитовка — 60 яшь

Яхъя Мөхәммәтгали улы Халитов 1929 елның 22 августында Татарстан АССРның Тәтеш районы Үтәмеш авылында туа. Университетның соңгы курсында укыганда ул «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли башлый. 1952 — 55 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы аспирантурада укый. Аны тәмамлагач, журналдагы хезмәтенә кире кайтып, унтугыз ел буе шунда эшли. 1976 елдан башлап Я. Халитов Татарстан китап нәшриятында өлкән редактор.

Яхъя Халитов — иҗади сәләтен тулысынча әдәби тәрҗемә эшенә багышлаган каләм осталарының берсе. Аның бу өлкәдәге эшчәнлеге 1952 елдан, рус язучысы Н. Тихоновның хикәяләрен тәрҗемә итүдән башлана. Шул вакыттан бирле ул дөнья әдәбияты классиклары, рус совет язучылары, тугандаш халыклар әдәбиятлары вәкилләренең зур күләмле дистәдән артык роман һәм повестьларын, берничә дистә хикәясен тәрҗемә итте. Алар арасында М. Шолоховның мәшһүр «Тын Дон» роман-эпопеясының беренче һәм өченче китаплары, «Күтәрелгән чирәм» романы, В. Каверинның «Ике капитан»ы, Ю. Бондаревның «Кайнар кар», В. Лацисның «Яңа тормышка» романнары, Ч. Айтматовның «Бәхил бул, Гөлсары», «Анам кыры» һәм «Дөя күзе» повестьлары, шулай ук күпләгән чит ил авторларының әсәрләре бар.

Я. Халитов — Татарстан АССРның атказанган культура работнигы.

Ул 1966 елдан СССР Язучылар союзы члены.

**Равил Әмирханов,**
тарих фәннәре кандидаты

# ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕБЕЗНЕҢ ТИРӘН ТАМЫРЫ

Бүгенге тарихи яки тарихи-популяр әдәбиятта революциягәчә яшәп килгән татар милли мәктәбен сугышчан тәнкыйтьләү һәм рәхимсез камчылау күренешләре әледән-әле кабатланып тора. Мәсьәләнең аяныч ягы шунда ки, әлеге караш җаваплы урыннарда эшләгән кайбер абруйлы иптәшләрнең җирле һәм хәтта үзәк матбугатта басылган хезмәтләрендә, рәсми чыгыш һәм интервьюларында үткәрелеп килде һәм килә. Гүяки элеккеге мәктәп-мәдрәсәләр укучы яшьләрне рухи яктан гарипләүдән башка эш башкара алмаганнар. Ул гына да түгел, кайбер рәсми чыгышларда эш революциягә кадәр татар халкының хәтта үз язуы, шулай булгач, әдәбияты, китаплары да булмаган дигән уйдырмаларга кадәр барып җитә. Мисал өчен ТАСС хәбәрчесе А. Дьяченконың «Комсомолец Татарии» (1972, 12 ноябрь) газетасында басылган бер мәкаләсеннән өзек китерик. «Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр,— дип язды ул,— татар телендә китаплар басылмады». Ә бит 1913 елда гына да, китап белгече Ә. Г. Кәримуллин ачыклаганча, татар телендә тиражы 3 миллионга җиткән 539 китап басылганы билгеле.[1] Мәктәп-мәдрәсә программалары, аларда уку-укытуның торышы, дәреслекләр, халыкның грамоталыгына бәя бирү мәсьәләсендә дә еш кына томаналык өстенлек ала. Мәсәлән, М. Ф. Вәлиев «Журналист» журналында (1970, 6 сан) басылган «Республика на Волге» дигән мәкаләсендә революциягә кадәр Казан губернасында халыкның 85 проценты укый-яза белмәгән, ә татар халкында грамотасызлар тагын да күбрәк булган, дип язып чыкты.

1986 елның 4 декабрендә «Вечерняя Казань» газетасына биргән интервьюсында ТАССР Мәгариф министрының элеккеге урынбасары Р. А. Галиәхмәтов, революциягә кадәр татар мәдрәсәләрендә диннән башка нәрсә укытылмаган һәм 1924 елга кадәр хәтта дәреслекләр дә булмаган дип күрсәтә.

XIX йөз азакларына буржуаз милләт булып формалашып җиткән халыкны шундый надан, томана итеп күрсәтүне нәрсә белән аңлатырга? Ә бит атап кителгән мәкалә-интервьюлар рус телендә басылган, димәк, аларны илебездә генә түгел, чит илләрдә дә укыйлар һәм шул нигездә татар халкының культура дәрәҗәсе турында хөкем йөртәләр.

Мондый нигилистик чыгышларның нигезендә халкыбызның культура тарихын белмәү, аның белән бөтенләй кызыксынмау ята. Самодержавие шартларындаа социаль һәм экономик эксплуатациядән тыш аяусыз милли-колониаль изелүгә дучар булган халык өчен шул чордагы мәгърифәтнең дәрәҗәсе дә казаныш. Бу фактны бер селтәнү белән инкарь итәргә маташу кем дигәндә тарихилык принцибына каршы килә, чынбарлыкны бозып күрсәтә.

Татар халкының революциягә кадәр ким дигәндә мең еллык мәгариф тарихы бар. Ул бай тарих олуг әһәмияткә ия булып, зур күләмле фәнни хезмәтләрдә, монографияләрдә өйрәнелүгә, популяр әдәбиятта армый-талмый яктыртылуга мохтаҗ. Әмма, кызганычка каршы, бу өлкәдә бүгенгә кадәр сизелерлек уңышларыбыз юк.

Бу мәкаләнең максаты: татар мәгарифенең үсү шартларын күрсәтү, мәктәп-мәдрәсәләрдә кулланылышта йөргән дәреслекләргә кыскача күзәтү ясау һәм грамоталык мәсьәләсенә тукталу. Үзара тыгыз бәйләнгән шушы өч моментны тиешенчә ачыкламый торып, татар халкының революциягә кадәрге мәгариф тарихын этрафлы күзаллау мөмкин түгел.

Билгеле булганча, XIX йөзнең соңгы чирегенә кадәр татар халкының милли уку йортлары күп кенә «тикшеренүчеләр» тарафыннан кара мөһер сугылган конфессиональ, ягъни

[1] Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 3 т. Казан, 1986, 23 б.

дини мәдрәсәләр рәвешендә яшәп килә. Моның күп санлы сәбәпләренә тәфсилле тукталып тормыйча, берничә иң әһәмиятлесенә генә күз салыйк.

1552 елда Иван Грозный тарафыннан Казан яуланып алынганнан соң, татарларда мөстәкыйль дәүләт югала, шуның нәтиҗәсендә һәм дөньяви, һәм рухани аристократия бик нык зәгыйфьләнә. Патша самодержавиесенең милли-колониаль изүенә җавап реакциясе сыйфатында дини һәм милли хисләр бермә-бер көчәя. Бу шартларда дин татар халкының милләт буларак югалуына каршы тора алырлык туплаучы, берләштерүче көч вазифасын үти. Тора-бара руханиларның яңа буыны калыплана һәм җәмгыятьтә аларның роле торган саен арта бара. Ислам, христиан диненнән аермалы буларак, «саф» дин генә булып калмый, бәлки шәригать формасында татар халкы өчен яшәү рәвешенә әверелә. Бик күп функцияләрне башкарган шәригать дөньявилык белән турыдан-туры бәйләнештә тора.

Царизм татарларга дөньяви белем бирүгә теше-тырнагы белән каршы килә. Бер яктан, самодержавие татарларны фанатизмда, мәдрәсәләренең дини характерда гына булуында гаепли, икенче яктан, аларга дөньяви фәннәрне кертүне тыя, татар балаларын миссионер мәктәпләренә бирүне таләп итә. 1818-1880 елларда патша хөкүмәтенең төрле идарәләренә Европа тибындагы урта мәктәп ачу буенча ким дигәндә сигез радикаль проект тәкъдим ителә. Алар арасында академик В. В. Радлов, мәшһүр галим, мәгърифәтчеләр Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов һ. б. була. Әмма царизм аларның барысын да кире кага. Мәсәлән, күренекле татар мәгърифәтчесе һәм фикер иясе Р. Фәхретдинев урта мәктәп сыйфатында «мәгариф мәдрәсәсе ачу» фикерен алга сөрә. Аның проекты буенча, мәдрәсә ике бүлектән торып, берсендә «шәригать гыйлемнәре», икенчесендә «мәгыйшәт гыйлемнәре», ягъни арифметика, геометрия, география, алгебра, философия, химия, астрономия, медицина, ботаника, тарих, логика, механика, хокук гыйлеме (право) һ. б. укытылырга тиеш була. Ләкин галимнең шушы проектын тәкъдим иткән «Китабел интисар лил-игътибар» («Абруй»ның тәэсире турында китап) хезмәтен басарга цензура рөхсәт итми.

Эчке эшләр министрлыгы каршында 1910 һәм 1914 елларда үткәрелгән Махсус җыелышлар татар мәктәп һәм мәдрәсәләренең дөньяви фәннәрне һәм хәтта рус телен алып ташлауны куәтлиләр, уку процессында дини предметлар белән генә чикләнү турында күрсәтмә бирәләр.[2] Шулай итеп, татарларда дөньяви мәктәп төзү эше үзе үк рәсми рәвештә кискен төстә гаепләнә. Бу карарлар нигезендә ачу турында махсус рөхсәте булмаган һәм 1870 елдан соң төзелгән барлык татар мәктәпләре дә ябылырга тиеш була. Һәм бу эш актив төстә тормышка ашырыла. Хөкүмәт, карагруһ миссионер Н. И. Ильминский сүзләре белән әйткәндә, русча белемгә һәм телгә ия булмаган фанатик, цивилизацияле татарга караганда яхшырак, дип санап килгән.

Православие миссионерлары, патша властьларының линиясен хуплап, мәктәп реформасына, руслаштыру политикасын үткәрүдә өстәмә кыенлыклар туар дип, һәрвакыт аяк чалалар.

Менә бу факторлар мәдрәсәләрдәге уку-укыту характерына (XIX йөзнең ахырларынача бигрәк тә) турыдан-туры йогынты ясый. Уку йортлары, нигездә, дини канунннар җирлегендә эшлиләр. Һәм бу тарихи котылгысыз, закончалыклы күренеш. Милли татар мәктәбе, үз чорының җимеше буларак, үз дәверен сикереп үтә алмый. Мәдрәсәләр дини характерда булгач, алардан дөньяви мөгаллимнәр чыга алмавы һәркемгә аңлашылса кирәк. Дөньяви белем алган укытучылар булмагач, алардан дөньяви фәннәр укытуны көтеп булмавы бәхәссез. Шулай итеп, сәбәп нәтиҗәгә, нәтиҗә сәбәпкә бәйләнеп, мәктәп торгынлык боҗрасыннан чыга алмый.

Болар барысы да шулай һәм ачык аңлашыла. Әмма шул ук вакытта түбәндәге фактларны кая куярга дигән сорау туа: татарның мәшһүр мәгърифәтчеләре, үзләренең эшчәнлекләре, күп санлы хезмәтләре белән дөньявилыкны алга сөргән Х. Фәезханов, Ш. Мәрҗани, Г. Фәезханов, К. Насыйри, Ш. Күлтәси, С. Күкләшев, М. Акмулла, Г. Мәхмүдов, З. Һади, Г. Ильяси, Р. Фәхретдинев, Ф. Кәрими һ. б. бик күпләр кадим, дини мәдрәсәдән чыкканнар бит! Дини мәдрәсәләрдә Х. Ямашев, Г. Колахметов, Г. Тукай, Г. Камал, М. Гафури, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, Ш. Камал, Г. Ибраһимов кебек татар пролетар һәм демократик культурасының күренекле вәкилләре үзләренең башлангыч белемнәрен алганнар.

Димәк, конфессиональ уку йортлары, үзләренең бөтен артталыкларына, җитешсезлекләренә, дин, схоластика белән сугарылган булуларына карамастан, үз шәкертләренә, объектив караганда, ниндидер белем биргәннәр, аларны фикри яктан үстергәннәр, яшәешкә турыдан-туры бәйләнешлы иткәннәр. Әгәр шулай икән, конфессиональ уку йортлары турында сүз алып барганда алардагы рациональ элементларга тарихилык принцибыннан чыгып бәя бирүнең әһәмияте тагын да арта. Һәм менә шушы тарихилык принцибыннан чыгып карамыйча, иске мәдрәсәләрне тоташ дин сөреме, схоластика, торгынлык карамагына гына калдырсак, мәгарифебез тарихына янә бер тапкыр пычрак аткан булыр идек.

Билгеле булганча, татар культурасы күп гасырлар буена барысыннан да элек Шәрык

---

[2] СССР Үзәк дәүләт тарих архивы, 821 ф., 133 тасв., 469 эш, 27-47 б.; 576 эш, 122 б.

мәдәниятенә йөз тоткан. Бу — мәгърифәт өчен дә хас күренеш. Көнчыгыш илләрендә реакцион дини идея, фанатизм, схоластика чүбеннән тыш гасырлар буена тәпле фикерләр яшь, фәнни эзләнүләр алып барыла. Анда бөек акыл ияләре әл-Фараби, әл-Бируни, Ибн-Сина, Ибн-Рөшд, Фирдәүси, Хәйам, Низами, Нәвои, Сәгъди, Фөзули һ. б. иҗат иткән. Дини-ортодоксаль әсәрләрдән аермалы буларак, аларның хезмәтләре ахирәткә түгел, ә дөньяви проблемаларга багышланган. Алардан рационализм, гаделлек, кешелек рухы бөркелгән. Татар халкының иң алдынгы вәкилләре беренче чиратта Шәрыкның әнә шул фәнни, фәлсәфи һәм иҗтимагый-политик фикерләренә теләктәшлек күрсәткәннәр.

Мәгариф өлкәсендә зур эз калдырган укымышлыларның күбесе антик фәлсәфә, иҗтимагый һәм әдәби фикерне яхшы белгәннәр. Аерым алганда, Ш. Мәрҗани үзенең «Вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф» («Бабайларның үлеме һәм аларның киләчәк буыннарга васыяте») дигән хезмәтендә Аристотель, Платон, Пифагор, Анаксимен, Анаксагор, Эвклид, Фалес, Сократ һ. б. философларның әсәрләрен тикшерә һәм аларга үзенең бәясен бирә. Әлбәттә, мәдрәсәдә укыту дәверендә дә ул бу гыйлем ияләренең хезмәтләре белән шәкертләрен таныштыра, укучыларны мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәтә. Ш. Мәрҗани астрономия, география һ. б. фәннәр белән тирән кызыксына, мәдрәсәсендә программада каралмаган математика дәресләре алып бара. Ул татар педагогикасы тарихында беренче булып үз мәдрәсәсендә эчке тәртип кагыйдәләре кертә. Кадим мәдрәсә өчен бу бөтенләй яңа күренеш була.

Гәрчә дини мәктәп-мәдрәсәләрдә тарих, география кебек дөньяви фәннәр махсус укытылмаса да, иң алдынгы хәлфәләр үз инициативалары белән бу предметлардан да дәрес биргәннәр. Мәсәлән, XIX йөзнең 80 нче елларында Казанның «Касыймия» мәдрәсәсендә шәкертләрнең дәрестә астролябия, циркуль һ. б. геометрик прибор һәм җайланмалардан файдаланулары билгеле.

Кадим мәдрәсәләрендә китап күчереп язу эше киң таралган булган. Мәсәлән, XVIII йөздә татар-башкорт крестьяннарының азатлык хәрәкәте башында торган Батырша укыган Ташкичү (Татарстанның хәзерге Арча районына керә) мәдрәсәсендә заманында бик күп оригиналь, шул исәптән тарих буенча, китаплар күчереп язылган. Бу эш бик мактаулы, «саваплы» хезмәт дип хисапланган һәм күчереп язылган китаплар, буыннан-буынга ирешеп, мәдрәсәләрдә дәреслекләр вазифасын үтәгәннәр.

Кадим мәдрәсәләрдә нинди китаплардан укыганнар соң? Әлбәттә, «Иман шарты» (әлифба белән), «һәфтияк», Коръән, «Гакаид», «Мәвакыйф», «Мәүләви Хәсән», «Хәмидулла», «Гыйльме хәл» һ. б. дини әсәрләргә зур урын бирелгән. Әмма боларны күрсәтү белән генә чикләнү чынбарлыктан шактый гына читләшү булыр иде. Иске татар мәдрәсәләрендә дәреслек рәвешендә кулланылып килгән иң популяр әсәрләрдән беренче чиратта мәшһүр болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасын күрсәтергә кирәк. 1839-1917 еллар арасында поэма 70 тапкырдан артык басылып чыга. 1846 елда Казанда «Мәликә китабы» басылып чыга. Халыкта шулай ук популяр ярымфантастик сюжетка корылган бу әсәр, дини-әхлакый формада булса да, тапкырлык, гыйлем, гаделлекне пропагандалаган сорау-җавап текстларын да үз эченә алган. Мәдрәсәләрдә киң-таралган уку китапларыннан Пиргули (Мөхәммәт Пиргули, 1538-1578), Устуани (Мөхәммәт Устуани, 1607-1662), «Бәдәвам», «Рисаләи Газизә», «Фәзаил-әшшеһүр», «Фәүзен нәҗат», «Мөһиммәтел мөслимин», «Сөбател-гаҗизин», «Мөхәммәдия», «Гыйбрәтнамә», «Бакырган» һ. б. атарга кирәк. Аларның бик күбе... борынгы авторларның әсәрләре булып, гасырлар дәвамында кульязма хәлендә йөргәннәр, ә XIX йөз башыннан басма рәвештә таралганнар. Мәсәлән, «Бәдәвам» Болгар дәүләте чорында ук нисбәт ителгән, авторы билгесез көйле әсәр. «Кыйссасел-әнбия» авторы Рабгузи XIII-XIV йөзләрдә яшәгән. «Мөхәммәдия»— төрек шагыйре Мөхәммәт Чәләби Язычы углы (1451-1453 еллар тирәсендә үлгән) тарафыннан төзелгән көйле әсәр. «Алты бармак китабы»ның авторы Мөхәммәт Чокырзадә XVI гасырда (1601 елда үлгән) яшәгән. «Сөбател-гаҗизин»— XVII йөз төрки шагыйре Аллаһияр (1624-1713) каләме белән язылган. Боларның күбесе маҗаралы сюжетка корылган һәм тарихи повестька тартым, ярым дини, ярым әхлакый эчтәлекле уку китаплары булганнар. Дөньявилыктан шактый ерак торсалар да, алар шәкертләрнең зиһене артуга, фикере ачылуга ярдәм иткән. Чөнки Ә. Г. Кәримуллин күрсәткәнчә, элек «нәби», «изге», «пәйгамбәр» геройлар рәтенә дин әһелләре генә түгел, күренекле тарихи шәхесләр дә кертелгән. Алар арасында галимнәр, полководецлар, әдипләр дә күп очрый (Аристотель, Ибн-Сина, Әбү-Харис, Александр Македонский, Гомәр Хәйам һ. б.)[3]. Шунысы да мәгълүм, XVI-XVII гасырның беренче яртысында рус мәктәпләре өчен бердәнбер уку китаплары булып «Часословец», «Псалтырь» кебек дини эчтәлекле әсәрләр хезмәт иткән. Иске мәдрәсәнең «тетмәсен» тетәрдән элек бу турыда да онытмау яхшы булыр иде.

Кадим мәдрәсәләрдә дәреслек булып «Мохтасар» китабы киң кулланылышта йөргән.

---

[3] Кәримуллин Ә. Китап дөньясына сәяхәт. Казан, 1979. 189 б.

Ул тәһарәт, намаз, ураза кебек дини ритуаллардан тыш никах, сату-алу, кәсеп итү, әйберләрне закладка салу буенча мәгълүматлар биргән, ягъни яшәешкә бәглы проблемаларны чишәргә өйрәткән. Дини уку йортларында, әлбәттә, дүрт гамәл турында төшенчә биргән «хисап», ягъни арифметика укытылган.

Конфессиональ уку йортларында Болгар чорларыннан ук озак вакытлар математиканы алмаштырып килгән «Гыйльме фәраиз» («Бүлү») укытылган. Ул мөселман юриспруденциясе составына кергән һәм беренчел математик мәгълүматлар бирүдән тыш шәригать нигезендә мөлкәт бүлү ысулларын бәян кылган. Шәкертләрнең фикри үсешенә этәргән предметлар укыту кадим мәдрәсәләргә дә хас күренеш булган. Мәсәлән, аларда схоластик характерда булса да, укучыларның сәләтле өлешенең зиһенен үстерергә ярдәм иткән мантыйк (логика) фәне укытылган һәм шул җирлектә моназара-диспутларга зур урын бирелгән. Бу фән буенча «Сөлләм», «Хикмәтулла», «Шәмсия», «Тәһзиб», «Мирза», «Мулла җәлял» китаплары кулланылган. Иске мәдрәсә программасында «Тәүзыйх» китабы, ягъни логиканың бер бүлеген укыту да киң таралган күренеш булган. Кайбер мәдрәсәләрдә борынгы грек философы Порфирийның логика буенча трактаты «Исагуҗи», ягъни «Аристотель категориясенә кереш» өйрәнелгән.[4]

Иске татар мәдрәсәләрендә тагын «Мөллә Җами китаплары», ягъни фарсы һәм таҗик философы һәм язучысы Габдрахман Җаминың (1414-1492) гарәп теле грамматикасы, рифма һәм шигырь үлчәве (метрика), шигъри мөгаммәләр (ребуслар) төзү буенча кулланмалары укылган. Соңрак чор әдәби ядкарьләрдән татар шагыйре Әхмәт Уразаев-Курмашиның (1883 елда үлгән) «Кыйссаи Бүз егет», «Таһир илә Зөһрә» поэмалары укылган. Алда исемнәре атап кителгән борынгы авторларның фәнни-фәлсәфи карашларын бәян иткән кульязма китаплар мәдрәсә китапханәләрендә электән ук күп булган. Кызыксынучан шәкертләр ул хезмәтләр белән мөстәкыйль рәвештә таныша алганнар һәм, инде алда әйтелгәнчә, күчереп язу белән шөгыльләнгәннәр.

Дини мәдрәсәләрнең чәчәк аткан чорында да шәкертләргә, алдынгы карашлы зыялыларга адресланган күп кенә дөньяви хезмәтләр дөнья күргән. Мәсәлән, 1842 елда М. Иванов татар теле грамматикасы һәм «Татар хрестоматиясе» исемендә җыентык төзи. Анда татар халык иҗаты әсәрләре белән русчадан тәрҗемә ителгән 17 мәсәл (күбесенчә И. А. Крыловныкы), берничә хикәя дә урын алган. Проза бүлеген патшалар, ханнар, Мисыр дәүләте, Нил елгасы турындагы хикәяләр алып тора. Китапның бер бүлеге поэзиягә багышланып, андагы әсәрләр арасында А. Нәвои классик поэзиянең аерым үрнәкләре урын алган. 1859 елда С. Күкләшевнең «Диване хикәяте татар» дип аталган хезмәте дөнья күрә. Хрестоматиянең кереш өлешендә автор татарларның тел культурасына бәя бирә һәм татар телен өч стильгә бүлә. Әсәрдә мәкальләр, әйтемнәр, рус һәм башка телләрдән тәрҗемә ителгән хикәя һәм новеллалар зур урын алган. Шушы типтагы хрестоматияләргә тагын Әхмәтҗан бине Мотахарның 1840 елда басылган хезмәтен дә кертергә кирәк. Аларның аеруча кыйммәтле ягы шунда, авторлар үз укучыларын алдынгы фикер ияләре, галим, философ, әдипләрнең дөньяви әсәрләре белән таныштырганнар.

Кадим мәдрәсәләр дәверендә үк аеруча уңыш казанган хезмәтләрнең берсе — академик В. В. Радлов төзегән һәм 1872 елда Казанда басылып чыккан «Белек» китабы. Китап балалар өчен аңлаешлы, саф татар телендә язылган һәм дини эчтәлекле материаллардан бетенләй азат булуы белән аерылып тора. Хезмәт алты бүлектән гыйбарәт [illegible] күләмдә хайваннар, үсемлекләр дөньясы, табигать күренешләре, астрономия буенча мәгълүматлар бирә, балаларга әхлакый характердагы хикәяләр тәкъдим итә, мәшһүр шәхесләрдән Сократ, Демосфен, Александр Македонский белән таныштыра. Бишенче бүлек тулаем Россия географиясенә, ә алтынчысы — Россия тарихына багышлана. Ватан тарихы буенча материалларда шәкертләр Олег, Ольга, Мономах, Иван IV, Борис Годунов, Минин, Пожарский, Сусанин, Петр I, Екатерина II һ. б. тарихи шәхесләр, алар яшәгән, идарә иткән дәвер турында мәгълүмат хасил иткәннәр.

Шул ук чорда (1873) К. Насыйриның математика фәне буенча «Хисаплык», соңрак (1895) геометрия буенча «Истыйляхате гыйльме һәндәсә»се дөнья күрә. Аннан да элгәрәк (1860 һәм 1868) бөек мәгърифәтче табигать белеме буенча «Буш вакыт» исемле китабын бастырып чыгара. Бу хезмәт балалар һәм башлангыч белем алучылар өчен табигать күренешләреннән кыскача мәгълүмат биргән. Анда кешенең анатомиясе турында да сөйләнә. Насыйри үзе үлгәннән соң, 1909 елда, бу китапның әһәмиятен аңлап, аны балалар китапханәсе сериясендә биш кисәккә бүлеп бастырып чыгаралар.

Татарларда дини мәдрәсәләр хакимлек иткән чорда К. Насыйри география фәннәре буенча «Истыйляхате җәгърәфия» (1890), «Ысуле җәгърәфияи кәбир» (I, II һәм III кисәкләр, 1894-1899), ботаникадан «Гөлзар вә чәмәнзар, ягъни үләнлек һәм чәчәклек» (1894), физика, химия, механикага кагылышлы «Сәнаигы гольфания» (1890) исемле китапларын бастырып чыгара.

[4] Знаменский П. Казанские татары. Казань, 1910. 26 б.

XIX йөз ахырына кадәр мәктәп-мәдрәсәләрдә махсус рәвештә укытылмаган татар теле буенча К. Насыйри шулай ук җитди хезмәтләр иҗат итә. 1860 елда аның «Кыскача татар нәхүе» басылып чыга. 1892 елда мәгърифәтче дөрес һәм матур язу кагыйдәләрен күрсәткән беренче кулланма «Кавагыйде китабәт», 1895 елда татар теленең фәнни грамматикасына нигез салган «Әнмүзәҗ», шул ук елны татар теленең аңлатмалы сүзлеге «Ләһҗәи татари»ны төзи. Шул ук вакытта мәгърифәтче рус телен үзләштерү, рус китапларыннан файдалану өчен беренче чиратта кирәк булган дәреслекләр эшли. Аның «Нәмүнә яки әнмүзәҗ», ягъни рус теленең грамматикасы (1891), «Кыйраәте рус», ягъни «Русча уку» китабы 1899 елда дөнья күрә. Рус теле буенча әлифба китаплары арасында иң күренекле урынны аның «Кавагыйд кыйраәт русия» («Русская азбука», 1889), ягъни рус теленең уку кагыйдәләре исемле китабы алып тора.

Биредә мәгърифәтче Габдюш Ваһапов исемен дә читләтеп үтәргә ярамый. Әле 1851 елда ук аның руслар өчен татарча, татарлар өчен русча үзөйрәткече дөнья күрә. Ул бик еш, хәтта Октябрьгәчә басылып килә. 1882 елда гына да бу үзөйрәткечнең сигезенче басмасы чыга. Шунысы игътибарга лаек, аңа «Татар җырлары» дигән бүлек кушымта итеп бирелә. 1862 елда Хөсәен Фәезхановның татар теле грамматикасы буенча бастырып чыгарган китабын телгә алмый китү дә гадел булмас иде.

Без, билгеле, кадим мәдрәсәләрдә шәкертләрне нәкъ менә шушы дәреслекләр буенча гына укытканнар, дип катгый төстә расларга җыенмыйбыз. Әмма зыялылар, алдынгы карашлы мөгаллимнәр алардан файдаланганнар, шулар нигезендә программадан тыш дәресләр биргәннәр дип кистереп әйтә алабыз. Ш. Мәрҗани мисалы шул турыда сөйли. Хәзергечә әйтсәк, ул хезмәтләр класстан тыш уку өчен искиткеч мөһим әдәбият булып хезмәт иткәннәр.

Кадим мәдрәсәләрдә киң планда гарәп һәм фарсы телләре дә укытылган. Аны яхшы үзләштергән шәкертләр Көнчыгыш әдәбияты, аның культура казанышлары белән турыдан-туры һәм мөстәкыйль рәвештә таныша алганнар.

Безнең уебызча, кадим мәдрәсә шәкертләре, укуның схоластик системасына, дини характерына, практикага бәйләнеше түбән булуына карамастан, зиһен дәрәҗәсе һәм дөньяга караш җәһәтеннән башка милләтләрдән булган замандашларыннан калышмаганнар. Бу фикерне заманында Казан уку округының татар, башкорт һәм кыргыз мәктәпләре инспекторы булган В. В. Радлов сүзләре дә куәтли. 1872 елда ул болай дип яза: «Шәкертләрнең фикри үсеше шактый зур һәм белемнәренең беръяклыгына карамастан, алар шәһәрдәге безнең приход мәктәпләре укучыларына караганда зиһен җәһәтеннән югарырак торалар» (!)[5] Искәртик, сүз әлеге «ямානаты чыккан» конфессиональ мәдрәсә турында бара. Рәсми шәхес, олуг галим буларак кына түгел, намуслы, интеллигент кеше буларак та Радлов объективлыкны барыннан да өстен куя. Һәм нигәдер мәгариф өлкәсендә буржуаз эшлеклегә хас объективлык хәзерге кайбер тикшеренүчеләргә еш кына җитеп бетми.

Әйе, кадим мәктәп нигездә дини җирлектә эшләп килгән, илаһи проблемалар баткагында кайнаган. Без моны инкарь итәргә дә, акларга да җыенмыйбыз, моңа ихтыяҗ да юк. Ләкин шуны да истән чыгармаска кирәк: революциягә кадәрге чорда Россиядә бер генә халыкта да дин укытылмаган яисә дин белән сугарылмаган уку йортлары булмый. Хәтта классик гимназия, институт, университетларда да «илаһи фән» предмет буларак керә һәм аның буенча имтиханнар кабул итела. Мәсәлән, Казандагы хатын-кызлар Югары курсларында төп предметлар сыйфатында «Диннәр тарихы», «Православное богословие», «Христиан чиркәве тарихы» укытыла.[6] Ә рус башлангыч мәктәпләре: «министрлык», шәһәр, чиркәү-приход, грамота, «изге» Гурия туганлыгы мәктәпләре асылда дини нигездә эшлиләр.

Татарларның кадим мәктәпләреннән рус шәһәр һәм чиркәү-приход мәктәпләре нәрсә белән аерылган соң? Аерма шунда гына: беренчеләрендә укуның нигезен ислам, икенчеләрендә христиан дине догматлары тәшкил иткән. 1884 елгы кагыйдәләр буенча, мәсәлән, приход мәктәпләренең максаты «халыкта иманны православие өйрәтүенчә ныгыту, христианлык әхлагын урнаштыру һәм белемнең башлангыч төшенчәләре белән таныштыру» була. Аларның программаларында 1) «илаһи закон» (намазлар өйрәнү, «изге тарих» һәм гыйбадәтне аңлату, кыскача катехезис), 2) чиркәү җыры, 3) чиркәү һәм дөньяви басманы уку һәм язу, 4) арифметика буенча башлангыч мәгълүматлар бирү каралган. Епархия училищелары һәм духовная семинарияләрнең максаты дин әһелләре әзерләү була.

XIX йөз азагында кадим мәктәп-мәдрәсәләргә яңа методлы, җәдит уку йортлары алмашка килә башлый. Татар буржуаз милләте калыплану, милли узаңның үсүе, иҗтимагый ихтыяҗ, рус-Европа культурасына йөз тоту, мәгърифәтчеләр, алдынгы карашлы интеллигенциянең, шәкертләрнең дөньяви мәктәп өчен армый-талмый көрәшүе — җәдит уку йортлары килеп чыгуга зур этәргеч ясый. Икенче яктан, дини мәктәп радикаль карашлы татар буржуазиясен дә канәгатьләндерә алмый. Капитализм үсеше чорында аңа дөньяви

[5] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 92 ф., 1972 ел, 58 эш, 15 б.
[6] Отчет о состоянии и деятельности Казанских высших женских курсов за 1912/13 уч. год. Казань, 1913, 27-29 бб.

белемнең билгеле бер минимумына ия булган, эш белүче кадрлар кирәк була. Гомумроссия, ә аерым очракларда, чит ил базарларындагы конкуренция татар буржуазиясеннән югарырак культура дәрәҗәсен таләп иткән. Шушы шартларда XIX гасыр ахырында балаларны укытудагы схоластик тәртипләрдән ваз кичү, дөньяви белемгә омтылу процессы буларак, заманы өчен үтә прогрессив күренеш — яңа методлы мәктәпләр туа башлый. Әмма яңалык үзенә юлны искелек белән аяусыз көрәш процессында яра.

Яңа методлы мәктәпнең принципиаль үзенчәлекләренә артык киң тукталып тормастан, аның прогрессив аваз методы («ысуле саутия») һәм күп санлы дөньяви фәннәргә нигезләнүен әйтеп китәргә кирәк. Әлбәттә, башка халыкларның уку йортларындагы кебек үк, татарларның җәдит мәктәпләрендә дә дин, дингә кагылышлы фәннәр өйрәнүгә шактый урын бирелә. Әмма дөньявилык торган саен алгы планга чыга бара. Мәсәлән, XX гасыр башында Казанның мәшһүр «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә (бирелә үз вакытында Х. Ямашев, Г. Камал, Ф. Әмирхан, М. Гафури, К. Тинчурин, З. Бәшири, М. Укмасый, Б. Урманче, Н. Исәнбәт, С. Сәйдәшев, С. Габәши һ. б. укыган) арифметика, рус теле, рәсем, матур язу, табигать белеме, география, физика, геометрия, Россия тарихы, гомуми тарих, төрки тарих, психология, этика, гигиена, логика, бухгалтерия, риторика, метрика, гарәп, фарсы телләре һ. б. дөньяви предметлар укытылган, гимнастика буенча дәресләр бирелгән.

Биредә гыйбрәтле бер хәл ачыклана: бүгенге мәктәпләребездәге реформа турында уйлаганда бу мәдрәсәләрнең педагогик тәҗрибәләренә дә игътибарыбызны юнәлтү кирәк түгелме икән! Мәдрәсәләрдә традицион фәннәр белән бергә логика, психология, философия, гигиена, этика, шигырь поэтикасы, экономикага бәйләнешле предметлар укыту, физик тәрбия, хезмәт күнекмәләре бирү һ. б. киң таралганлыгы ачыклана. Бабаларыбызның рухи дөньясы һәм хезмәткә хөрмәте әнә нинди чыганакларга тоташа. Элекке рухи мирастан һәм педагогик тәҗрибәдән аерылмау кирәк дип санасак, без бу байлыгыбызны үзебезнең хәзинәбез итәргә тиешбез!

Вятка губернасы Сарапул өязендәге Буби мәдрәсәсендә (хәзер Әгерҗе районына керә) математика, физика, химия, гомуми тарих һ. б. дөньяви фәннәрдән тыш француз теле, Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә немец теленнән дәресләр бирелә («Вакыт», 1906, 19 декабрь). Казан уку округы инспекторы Я. Д. Коблов боларны истә тотып 1916 елда менә нәрсә яза: «Бу фәннәрне өйрәнү аркасында, гомуми белем предметларын элементар формада бирүгә карамастан, укучыларның фикри үсеше шактый югары дәрәҗәгә җитә».[7] Ә 1911 елда инглиз журналы The Moslem World яңа методлы татар мәдрәсәләренең уку программаларына анализ ясап, аларның классик гимназияләргә охшашлыгын һәм биредә латин, грек телләре урынына гарәп һәм фарсы телләренең укытылуын күрсәтеп китә.[8]

Шулай итеп, җәдит мәдрәсәләрнең шактыенда үз заманының барлык гомумбелем дисциплиналары да диярлек урын алган. Шунысы әһәмиятле, СССР Министрлар Советы һәм ВКП(б) ҮКның 1948 ел, 10 февраль Карары нигезендә Казандагы «Мөхәммәдия» һәм «Касыймия», Уфадагы «Галия» һәм «Госмания», Иж-Бубидагы «Буби», Оренбургтагы «Хөсәения», Троицкидагы «Рәсүлия» мәдрәсәләрен тәмамлаучыларның хокуклары рәсми рәвештә педучилищелар биргән белемгә тиңләштерелә.

Ике гасыр чигендә мәктәп-мәдрәсәләргә дөньяви фәннәр буенча дәреслекләр, төрле кулланмалар куәтле ташкын булып килеп кергән. Аларның гомуми саны берничә йөзгә җиткән, әмма, кызганычка каршы, бүгенге көнгә кадәр татар мәдрәсәләрендә дәреслек булып йөргән китапларга (әлифбаларны исәпкә алмаганда) берниндн фәнни анализ ясалмаган.

1917 елда Казан цензура комитеты башлыча 1911-1913 елларда дөнья күргән һәм татар мәктәп-мәдрәсәләрендә кулланышта йөргән 394 дәреслеккә кыскача күзәтү ясаган. Шунысы игътибарга лаек, әлеге 394 китапның 120 се (30 процент тирәсе) дингә кагылышлы булса, калган 274 е дөньяви фәннәргә багышланган.

Яңа методлы мәктәп-мәдрәсәләрдә киң планда күп кенә тарихи предметлар укытылган. Алар арасында гомуми тарих (бу исәпкә ислам мәмләкәтләре, төрки халыклар тарихын да кертергә кирәк), Россия тарихы һәм Болгар, Казан дәүләтләре тарихына зур урын бирелгән. Беренче чиратта гомуми тарих дәреслекләренә күз салыйк. Бу җәһәттән Харис Фәйзи Чистапулиның 1903-1904 елларда дөнья күргән «Хөласаи тарих гомуми»се игътибарга лаек. Ул алты зур кисәктән торган. Шуларның 1-3 бүлекләре борын заман, 4-5 — урта гасырлар тарихына, 6 — яңа тарихка багышланган. Заманында бик популяр һәм бай эчтәлекле бу дәреслек мәдрәсәләрдә куллану өчен 1907 елда Мөгаллимнәр җәмгыяте тарафыннан кабул ителгән. Бу тип дәреслекләрдән Морад Рәмзинең «Мохтасар тарих гомуми»сен дә күрсәтергә кирәк. Ул да борынгы заман, урта гасыр һәм яңа чор тарихына багышланган. 1911 елда Фатих Кәриминең дә шул исемдәге дәреслеге дөнья күрә.

Гомуми тарих буенча тикшеренү буларак та, дәреслек-кулланма буларак та Гафур Колахметовның «Тарих сәхифәләре» дигән хезмәте бик әһәмиятле урын тоткан. Кешелек

[7] Коблов Я. Д. Конфессиональные школы казанских татар. Казань, 1916, 94 б.
[8] Ханбиков Я. И. Педагогика джадидизма.— Ученые записки КГПИ Вып. 193. Казань, 1979, 62 б.

җәмгыятенең үсеш закончалыгын татар телендә беренче мәртәбә марксистик позициядән торып аңлаткан бу китап өч аерым кисәктән тора: «Тарихтан әүвәл адәм балалары» (1908), «Әүвәлге мәмләкәтләрнең урыннары һәм халык» (1909) һәм «Мисыр» (1909). Тел галиме И. Абдуллинның мәгълүматларына караганда, борынгы дәүләтләрнең барлыкка килү һәм үсешен тарих законнарына таянып аңлаткан бу китапчыкларны Г. Колахметов Ф. Энгельсның «Гаилә, хосусый милек һәм дәүләтнең килеп чыгышы», Ч. Дарвин хезмәтләре, Г. Спенсерның ике томлык «Социология нигезләре», француз географы Э. Реклюның күп томлы «Кеше һәм җир», борынгы грек тарихчысы Геродотның «Тарих»ын өйрәнү нигезендә язган. Беренче китапчык чыгу белән үк Ф. Әмирхан «Әльислах» газетасында язган рецензиясендә аны барлык халыкка аңлаешлы һәм җиңел телдә язылган китап буларак мәдрәсәләрнең югары сыйныфлары өчен дәреслек итеп файдаланырга яраклы дип тәкъдим итә. (Әльислах. 1909, 15 январь).

1909 елда Әхмәт Рәфикыйның төрек телендә Истанбулда басылган «Бөек тарих гомуми» дигән әсәре дә уку китабы булып йөргән. Ф. Әмирханның бабасы Хөсәен бине Әмирханның 1884 елда Казанда чыккан «Шәҗәраи галия фи бәян әл-әнсаб» («Нәсел-нәсәпләрне бәян иткән бөек шәҗәрә китабы») дигән хезмәтен дә гомуми тарих әсәренә кертү дөрес булыр. Гомуми тарихи проблемалар Корбангали Халидовның «Китабе тарих җәридәи җәдидә» (1889), Хәбибелнәҗар бине Мөхәммәткафинең «Китабе мифтах (ачкыч) әт-тәварих» (1889), Й. Акчураның «Голүм вә тарих» (1906) дигән хезмәтләрендә дә күтәрелгән. Гомуми тарих буенча язылган һәм мәктәп-мәдрәсәләрдә актив кулланышта йөргән хезмәтләрдә Сәмигулла Сибгатуллинның «Мәдхәл тарих ислам» (1897), Габдулла Садыйкыйның «Тарих әл-ислам» (1899), Госман Хисаметдинның «Тәварихел хәлифәи» (1903), Лотфи Галиминең «Пәйгамбәрләр тарихы һәм тарих ислам» (1908), Әсгать Мәхмүтнең «Тарих ислам» (1908), Шакир Сөләйманинең «Тарих ислам» (1908), Х. Зәбиринең «Хөласаи тарих ислам» (1909), Госман Җәлилнең «Тарих ислам» (1912), Җирҗи Зәйданның «Ислам мәдәнияте тарихы» (1912-1913, Закир Кадыйри тәрҗ.) һ. б. санарга кирәк. Болардан башка С. Камалның рөшди мәктәпләр өчен дәреслек буларак йөргән «Мөсәүвәр тарих ислам»ын, шулай ук Й. Хәлилинең «Ислам тарихы»н, Г. Ибраһимовның «Борынгы ислам»ын (1909) күрсәтергә мөмкин. Ф. Кәриминең популяр «Мохтасар тарих ислам»ының 1917 елда бишенче басмасы дөнья күрә.

Революциягә кадәрге мәктәп-мәдрәсәләрдә гомуми тарих буенча XIX гасыр ахыры — XX йөз башында язылган дәреслекләрнең шактый өлеше төрки кабиләләр тарихына багышланып, төрле дәүләтләрнең яшәеше башлыча төрки халыкларга бәйләнеше ягыннан өйрәнелгән. Мондый хезмәтләрдән беренче чиратта Хәсәнгата әл-Габәшинең Казанда 1907 елда басылган «Мохтасар тарих кауме төрки. Җөзьәе әүвәл», ягъни «Төрки халыкларның кыскача тарихы. Беренче кисәк»не күрсәтергә мөмкин. Шул ук авторның 1909 елда дөнья күргән 316 битле «Мөфассал тарих кауме төрки», ягъни «Төрки халыкларының тулы (тәфсилле) тарихы» проблеманы тагын да киңрәк күтәргән. Беренче мәртәбә 1824 елда дөнья күргән һәм соңыннан күп тапкырлар басылып килгән Әбу әл-Газинең «Шәҗәраи төрки»се дә мәдрәсәләрдә киң кулланылышта йөргән.

Болгар-татар тарихына багышланган китаплардан 1883 елда Казанда Хөсәен бине Әмирханның «Тәварихе Болгария»се дөнья күрә. Ул җирле чыганакларга киң таянган булуы белән әһәмиятле.

Татар халкы тарихын өйрәнү буенча иң кыйммәтле һәм фундаменталь китапларның берсе — Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфад әл-әхбар...» әсәре. Ул мәдрәсәләрдә дәреслек буларак киң кулланылган. Хезмәтнең беренче кисәге 1897, икенчесе 1900 елда дөнья күрә. Ш. Мәрҗани беренче томда Русьнең борынгы Болгар, ә соңрак Казан халкы белән күптәнге экономик һәм культура элементләрен тасвирлый. Икенче том Казанның Россия составына керүеннән соң татар халкы тарихына багышлана. Бөек мәгърифәтченең «Мокаддимәт китаби вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф» («Бабайларның үлеме һәм аларның киләчәк буыннарга васыяте китабына кереш»— 1883) әсәре дә уңыш казанган.

Мәдрәсәләрдә Морад Рәмзинең Оренбургта 1908 елда басылып чыккан «Тәлфик әл-әхбар вә тәлких әл-әсар фи вәкаин Казан вә Болгар вә мөлек эт-татар», ягъни «Казан һәм Болгар тарихы, татар идарәчеләре турында җыйналма мәгълүматлар» дигән ике томлы хезмәте дә кулланылган.

Яңа методлы мәдрәсәләрдә популяр тарих дәреслекләреннән Казан университеты каршындагы археология, тарих һәм этнография җәмгыяте члены Г. Әхмәров хезмәтләрен күрсәтергә кирәк. Аның иң күренекле китаплары: «Болгар тарихы» Казанда 1909, «Казан тарихы»— 1910 елда басылып чыга. Галим бу китапларында Болгар һәм Казан дәүләтләренең эзлеклелеген тасвирлый, казан татарларын Идел буе болгарларының турыдан-туры варислары итеп күрсәтә.

Мәдрәсәләрдә кулланылышта йөргән тарих китапларыннан Ш. Хәмидуллинның «Голяма тарихы»н (Казан, 1907) күрсәтергә мөмкин. Бу хезмәттә борынгы авторлар, соңгы дәвер татар галимнәре, Казан мәчетләре, алардагы имам һәм муллалар, 1905-1907 ел рево-

люциясе нәтиҗәсендә туган татар көндәлек матбугаты турында материаллар урын алган. 1907 елда Казанда Г. Зәбиринең «Мәкятип ибтидаиә өчен кыскача тарих Болгар» 1913 елда Г. Батталның «Татар тарихы» дөнья күрә һәм уку китаплары булып хезмәт итә. Җирле тарих буенча кулланма буларак К. Биккуловның «Татар ханнары» (1911), һ. Атласиның Совет чорында да (1920) дөнья күргән «Казан ханлыгы» (1914), «Сөембикә» (1914) һ. б. китаплар да гамәлдә булган.

Төрки-татар тарихына кагылышлы хезмәтләрдән Габделҗаббар Җиһаншаның «Тарих Әстерхан» (1907), һ. Атласиның «Себер тарихы»н (1911) атарга мөмкин.

Россия тарихы буенча язылган һәм татар мәктәпләрендә дәреслек булып йөргән хезмәтләрдән беренче чиратта К. Насыйриның 1890 елда басылган «Зөбәдәт мин тәварихи әр-Руси», ягъни «Кыскача Россия тарихы»н күрсәтергә кирәк. Китап балаларга җиңел аңлаешлы телдә язылып, Россия тарихын IX йөздән башлап XIX гасырның азагына кадәр күзәтүгә багышланган. Ул Н. Г. Устряловның «Русская история» дигән хезмәтеннән файдаланып язылган.

Россия тарихына багышланган дәреслек авторлары арасында Нургали Надиев лаеклы урын тоткан. 1908 елда Казанда аның «Русия тарихы» исемле дәреслеге дөнья күрә. Бу дәреслек берничә мәртәбә басыла, беренче басмасыннан мәктәп программаларына кертелә.

1907 елда Казанда «А», 1908 елда «А. Г.» инициаллары белән генә басылган авторның «Русия тарихы» исемле китабы дөнья күрә һәм мәктәп-мәдрәсәләрдә абруйлы дәреслек-кулланма булып йөри. Шулай ук Ә. Биктимеровның «Русия тарихы» (1914) да уңыш казана. Биредә Г. Авыргазинның «300 ел элек. Русия тарихыннан бер нәбзә» (1913) дигән хезмәтен дә искә алу тиеш.

Дөньяви фәннәр укыту процессында география дәреслекләре дә әһәмиятле роль уйнаган. Бу өлкәдә беренче җитди адымнарны инде әйтеп үтелгәнчә, К. Насыйри ясаган. Әмма бөек мәгърифәтчегә кадәр үк, 1886 елда Вәлиулла Әнвәров «Җәгърафияи математикый», 1887 елда Габделгалләм Фәезханов «Гомуми җәгърәфия» исемле китаплар чыгаралар.

Революциягә кадәр мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек сыйфатында йөргән география китапларының саны берничә дистәгә җитә. Аларның авторларыннан Шиһабетдин Габделгазизов, Мөхәммәт Идрисов, М. Корбангалиев, Габдерәшит Фәхретдинев, Харис Фәйзи, М. Рафикый, Мөхәммәтвафа Надиев, Габдулла Фәйзи, Г. Җәгъфәров, Габдерахим әл-Хәнәфи, Ф. Кәрими, һ. б. күрсәтү тиеш. География дәреслекләре төзү юлында иң зур хезмәт башкаручыларның берсе — Харис Фәйзи. 1907 елда аның өч аерым китап буларак «Мөсәүвәр тәгълим җәгърафия»се басылып чыга. 1913 елда гына да 41 мең тираж белән география буенча җиде китап дөнья күрә.

Мәктәп-мәдрәсәләрдә елдан-ел сыйфатлырак басылып килгән Россия, Европа, Азия, Африка, Америка, Австралия карталары киң кулланыла. Аларны әзерләп чыгаруга бигрәк тә Мөхәммәт Идрисов зур хезмәт куя. Мәктәп-мәдрәсәләрдә Мөхәммәт Әшрәфнең «Ибтидаиә атлас», «Мәктәп атласы», «Җәгърафия гомуми атласы», Мөхәммәт Җәләл, Ә. Хәлимнең «Җәеб(кесә) атласлары», М. Идрисовның «Кыйтгате хәмсә»се (җир шарының биш кисәге) һ. б. кулланылышта йөри.

XIX йөз ахыры — XX гасыр башларында мәктәп-мәдрәсәләрдә математика (арифметика, алгебра, геометрия) буенча берничә дистә исемдәге хезмәтләр кулланылышта йөри. 1891 елда Г. Галиевнең «Нәмунәи хисаб»ы басылып чыга. 1892 елда Салих Габидулланың «...Әл-хисаб»ы, 1894 елда билгесез авторның «Гыйлем хисап рисаләсе» дөнья күрә. 1903 елда Мөхәммәт Зиһнинең «Мәсаил әл-хисаб», 1905 елда Касыйм Җамалетдинның шул ук исемдәге хезмәте дөнья күрә. Башлангыч мәктәп балалары өчен арифметикадан Мөхәммәт Идрисовның берничә дәреслеге дөнья күрә. 1907 елда ибтидаи беренче һәм икенче сыйныфлар өчен аның «Хисабе зиһни», өченче сыйныф өчен ике кисәктән торган «Хисап гамәле» дөнья күрә.

Арифметикадан Верещагинның «Задачник по арифметике» китабы Г. Гыйсмәти, В. А. Евтушевскийның мәсьәләләр җыентыгы А. Гайнетдинов тәрҗемәсендә кулланыла. Болардан башка Шәрифулла Әхмәровның арифметика дәреслеге, Зыя Насыйриның «Хисап мөгаллиме», И. Хәлили, С. Габделбәдигыйларның мәсьәләләр җыентыклары абруй казана. Арифметика дәреслекләреннән тагын Вишневский (I, II, III бүлек, Ш. Мәхмүтов тәрҗемәсендә), Шапошников һәм Вальцев («Хисап мәсьәләләре»— Г. Богданов тәрҗемәсендә), Н. Соколов һәм И. Сахаров («Гавам мәктәпләре өчен яңа хисап мәсьәләләре — Н. Думавый төзегән), Н. Вәлишев белән Г. Хәбировның «Хисаб»ын күрсәтергә мөмкин. Соңгы дәреслек 1910-1914 елларда гына да биш мәртәбә дөнья күрә һәм революциядән соң да басыла.

Математика буенча М. Корбангалиевның берничә кисәктән торган һәм күп мәртәбә басылган «Хисап мәсьәләләре», «Хисап мәсьәләләре һәм гадәде мисаллар»ы әһәмиятле дәреслекләрдән саналалар. Геометрия буенча К. Насыйриның алда атап кителгән «Истыйляхате гыйльме һәндәсә»се, И. Давыдовның «Мохтасар һәндәсә»се (Г. Мостафин тәрҗемәсендә), Г. Гыйсмәтинең «Гамәли вә нәзари ысуле һәндәсә»се Мөхәммәт Рафикыйның «Нәзари вә гамәли һәндәсә»се һ. б. китаплар кулланылган. Алгебрадан Ильяс Таһирның «Гыйльме җәбер»е уңыш казанган.

Табигать белеме буенча Х. Корбангалиевнең «Хикмәте табигыя», Я. Аймановның «Табигать», И. Хәмидинең «Гыйльме мәгъдан», астрономия буенча Ж. Абызгильдинның «Гыйлем әл-галаик тарихчасы», М. Бәхтиярның «Горрәи даими», Р. Ибраһимовның «Дәүри галәм», ботаникадан Г. Фәхретдиновның «Рәсемле гыйльме нәбатат», И. Хәмидинең «Гыйльме нәбатат», В. Тимофеевның «Үсемлекләр дөньясы. Бакча.», зоология буенча К. Сент-Эйлерның «Мөкаммәл хәйванат атласы» (Г. Нугайбәк тәрҗемәсе), И. Хәмидинең «Гыйльме хәйванат», «Рәсемле гыйльме хәйванат», химия буенча Г. Шонасиның «Мохтасар кимия», физика буенча Г. Гыйсмәтинең «Гыйльме әшья яки тарих табигый», Х. Зәбиринең «Әшья дәресләре», М. У. Усковның «Гыйльме әшья», Х. Фәйзи тәрҗемәсендә «Гыйльме әшья...», анатомия һәм гигиена буенча И. Хәмидинең «Гыйльме ташрихтән», Д. Габидуллинның «Хифзы сыйххәт», Ш. Камалның «Хифзы сыйххәт дәресләре» (Г. Дәмини тәрҗемәсе), Х. Гайнелгыйбадның «Шәгъбәи тыйб китабы», педагогика буенча Ә. Мостафин тәрҗемәсендә Х. Тәүфыйкның «Педагогияи гыйльмия», метрика буенча Габдулла әл-Җәлдариның «Гыйльме гаруз нәмунәсе», логика буенча Габдулла әл-Мәхдүминең «Логия яхуд мантыйк фәне», К. Насыйриның «Әхлак рисаләсе» (1881), И. Сәйманиның «Нәмунәт әл-әхлак» (1902), Садыйковның «Нәмунәи әхлак», Р. Фәхретдиневнең «Әдәбе тәгълим», Ш. Хәмидинең «Тәһзиб әл-әхлак» К. Биккулов һәм Г. Гыйсмәтинең «Әхлак», Х. Зәбиринең «Әхлак дәресләре» һ. б. бик күп исемдәге дәреслекләр мәктәп-мәдрәсәләрдә кулланма булып йөриләр.

Укыту, тәрбия эше буенча методик кулланма буларак Г. Шонасиның «Фән тәдрис. Ысуле тәгъдим вә тәрбиядән» дигән хезмәте уңыш казана.

Яңа методлы мәктәп-мәдрәсәләрдә укыту өчен рус теле буенча берничә дистә әлифба-дәреслекләр дөнья күрә. Бу өлкәдә Г. Ваһапов һәм К. Насыйриның бәрәкәтле эшчәнлеген һ. Максуди, Ш. Хәмиди, Ш. Рәхмәтуллин, М.-С. Иманкулов, С. Максуди һ. б. уңышлы дәвам итә. 1901 елда Мөхәммәтйосыф Казаковның «Мөгаллимел рус» дигән хезмәте дөнья күрә. 1911 елда һ. Максудиның «Русыстан. Русча дөрүс шифаһия (телдән дәресләр)» исемле хезмәте басылып чыга. Бу чорларда бигрәк тә И. Казаковның «Рус мәктәбе», «Рус мәктәбе ачкычы» уңыш казана. Шул ук авторның рәсемле «Русская азбука»сы әлифба гына түгел, уку китабы булып та хезмәт итә. С. Максудиның «Тәрҗеман руси», һ. Максудиның «Мөгаллим әүвәле», Ш. Хәмидинең «Рус теле» һ. б. популяр дәреслекләр булган. И. П. исемле авторның «Минем тәрҗеманым» дигән хезмәте хәтта «рус һәм француз телләреннән мәгълүмат кәсеп итүне теләгән кешеләр өчен эшләнмеш» дәреслек була. 1910 елда билгесез авторның I һәм II кисәкләрдән торган «Русча дөрест язу кагыйдәләре» дөнья күрә. Русларга — татар, татарларга — рус теле өйрәтү өчен чыгарылган «Үз-үзеннән өйрәткечләр»нең саны да ишәя бара. Әле 1887 елда ук Казанда «Яңа язылган үз-үзеңне өйрәткеч, татарларга урысча, урысларга татарча сөйләшергә һәм укырга» дигән китап басыла. Ш. Рәхмәтуллинның мондый хезмәте исә Кәримовлар тарафыннан дистәгә якын мәртәбә басыла. Кайвакытта аның тиражы 10 меңгә җитә. М.-С. Иманкуловның «Русча-төркичә-фарсыча үзе-үзеннән өйрәткече» дә бишәр мең тираж белән таралып, рус телен өйрәнүгә үзеннән өлеш кертә.

Октябрьгәчә чыккан ана теле (без әлифбаларга кагылмыйбыз) дәреслекләре шул кадәр күп ки, аларны санап кына китү дә бер мәкаләлек урын алыр иде. Татар теленең фонетика, морфология, синтаксисы буенча инде алда атап кителгән К. Насыйридан башка Камил Бәширов, Зөфәр Касыйми, Мөхәммәткәрим Дибердеев, Давыт Гобәйди, Касыйм Биккулов, Г. Рамазанов, Зыя Насыйри, Шәмси Вәлиев, Н. Думави, Габделкотдус Фәхри, Г. Алпаров, Г. Нугайбәк, Әхмәтҗан Мөхәммәтрәхимов, Бәдретдин Паравн, Габбас Сәйфуллин, Шакирҗан Ибраһимов, Шәехгаттар Иманаев, С. Жантурин һ. б. бик күпләр дәреслекләр иҗат иткән.

Әле 1809 елда ук И. Хәлфинның «Шаһиншаһның Казан гимназиясендә лисан төрки вә хатт гарәби үгрәтелә торган әлифба илә кечкенә нәху (синтаксис) вә сарыфыдыр (морфология)» дөнья күрә һәм 1812 елда кабат басыла. Китап рус мәктәпләрендә татар теле өйрәнү өчен чыгарылган булса да, аның практик кулланылышы киңрәк булуында шикләнмәскә мөмкин. 1887 елда Габделгалләм Фәезхановның «Татар теленә кыскача гыйльми сарыф» дигән хезмәте басылып чыга. 1892 елда Г. Фәизинең «Кавагыйд төркия»се дөнья күрә. З. Ишмөхәммәдевнең 1893 елда басылган «Берьюлы уку-язу»ы да телне өйрәнү буенча кулланма буларак хезмәт иткән. 1901 елда исә М. Өметбаевның «Татар нәхүсенең мохтасары» мәйданга чыга.

Заманы өчен иң зур уңышны Г. Ибраһимов хезмәтләре казанган булса кирәк. Аның «Татар нәхүе», «Татар имлясы», «Татар сарфы» дигән китаплары моңарчы күрелмәгән югары бәя ала. 1913 елгы «Әсами кәтеп»тә бирелгән бәядә мондый юллар бар: «Бунлар мәйданга чыгу белән Оренбургның «мәдрәсәи Хөсәения», Казанның «Касыймия» вә «Мөхәммәдия» мәдрәсәләре, Троицк, Чиләбе вә башка якта кагыйдәләр төзүче галимнәрнең гыйльми комиссияләре тарафыннан милли тел хакында дәрес китабы итеп кабул кылынды; матбугат исә бер авыздан алкышлап, һәммә газитә вә журналларымызда бу ике дәреслекнең мөкәммәллеге, моңарчы чыккан басмалардан чагыштыргысыз дәрәҗәдә яхшылыгы гомумән

расланып язылды һәм язылмактадыр». Бу хезмәтләргә соңрак атаклы тюрколог, академик А. Самойлович югары бәя бирә.[9] Г. Ибраһимовның атап кителгән дәреслекләре ана теле буенча төп уку китаплары булып китәләр, революциягә кадәр ел саен диярлек дөнья күрәләр һәм Совет чорында, 30 нчы елларга кадәр басылып киләләр.

Татар теле буенча сүзлекләрнең дә кулланылышта күп булуын әйтеп китү урынлы булыр. Мәсәлән, Габбас Сәйфуллинның «Мәктәп лөгате» (1917), «Кечек лөгать» (1912), Ильяс Таһирның «Әлмөфид» (гарәпчә-татарча мөкәммәл лөгать китабы) (1912) шундыйлардан.

Татар әдәбияты буенча дәреслекләр, уку китаплары, хрестоматияләр турында да бик күп язарга мөмкин. Бу өлкәдә зур хезмәт куючылардан Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, М. Корбангалиев, Габдулла Фәйзи, С. Рахманколый, Н. Думави, Ф. Агиев, Г. Биктави, И. Идрисов, Х. Фәхретдин, М. Арсланов, Макай Хөсәен бин Зәйнетдин һ. б. исемнәрне атау да җитсә кирәк. Әдәбият буенча дәреслекләр үзе бер мөстәкыйль тема. Йөзләгән төрле исемдәге мондый дәреслекләр аерым тикшерүгә лаек.

Әлбәттә, без революциягә кадәр татар мәктәп-мәдрәсәләрендә кулланышта йөргән барлык дәреслекләргә дә югары бәя бирергә җыенмыйбыз. Алар арасында урта кул сыйфатлылары да, примитив эчтәлеклеләре дә байтак булган. Ә гомумән алганда, XIX йөз ахыры — XX гасыр башында чыккан дәреслекләрне бәяләгәндә, ул заманның тарихи шартларын — культура һәм фәннең ни дәрәҗәдә торуын нинди социаль шартлар хөкем сөрүен исәпкә алмыйча, хәзерге көн дәрәҗәсеннән генә чыгып хөкем йөртү ялгыш булыр иде. Заманы өчен, чор продукты буларак, алар мәгариф системасында әһәмиятле роль уйнаганнар.

Мәгариф тарихыбызны өйрәнгәндә бер нәрсәне һич истән чыгарырга ярамый: патша хөкүмәте татар милли мәктәп-мәдрәсәләрен материаль ярдәмнән тулысынча диярлек мәхрүм иткән. Милли уку йортлары гасырлар д вамында башы мохтаҗлыктан чыкмаган халык акчасына яшәп килгән. Мәхәллә халкының кызганыч тиеннәренә тотылуына карамастан, хәтта һәрбер кечкенә авылда да мәктәп яшәп килә. Бернichә документка мөрәҗәгать итик. Казан земствосының «Народное образование в Казанской губернии» (1905) дигән рәсми басмасында мондый юллар бар: «Татар мәктәпләре бөтенләй диярлек халык акчасына тотыла һәм аларның барлыкка килүе дә бөтенләе белән халыкның үз инициативасы белән бәйләнгән». Инде рус телендәге «Казанская газета»га (24 июль 1905) күз салыйк: «Казан губернасы халкының яртысын диярлек мөселманнар тәшкил итә. Халыкның бу өлеше салымнар авырлыгын рус һәм башка милләтләр белән тигез күтәрә, әмма земство мөселман халкын агарту юлында бернәрсә дә диярлек эшләмәде». Петербургта татарча чыккан «Дума» газетасы (1907, 8 май) болай дип язган: «Татарларның уку вә прогресслары өчен Русия хөкүмәте миссионер мәктәпләрне санамаганда, бер тиен көмеш акча тотканы юктыр».

Әмма шунысы белән чын мәгънәсендә горурланырга мөмкин: самодержавиенең үтә реакцион политикасына, мәгариф эшенең гаять зур тоткарлыкларга юлыгуына карамастан, татар халкы революциягә кадәр Россиядәге иң грамоталы халыкларның берсе булган.

Объективлык максатыннан чыгып биредә беренче чиратта рус рәсми әһелләре һәм зыялыларының фикерләренә урын бирик. А. Сперанский, П. Знаменский, Я. Коблов, М. Машанов һ. б. күп рус галимнәре татарларның укый-яза белү җәһәтеннән бик югары торуын кат-кат күрсәтәләр. XVIII-XIX йөзләргә тукталмыйча, бу очракта XX гасыр башындагы кайбер мәгълүматларга игътибар итик. Казан губернаторы Хомутов (1905): «Татарлар үзләренчә барысы да диярлек мәгърифәтле».[10] Духовная академия профессоры М. Машанов (1910): «Россиядәге татарлар, аерым очракларны исәпкә алмаганда, барысы да диярлек укый-яза беләләр».[11] Алда атап кителгән «Народное образование...» китабында (19 б.): «Грамота тарату буенча татар халкы бик алга киткән... Безнең рустагы грамоталылык күпчелек очракта татарларныкыннан югары түгел, ә еш кына түбән дә». А. Сперанский (1914): «Татарлар арасында грамоталык русларныкына караганда югарырак... Казан татарлары белемне яраталар һәм хөрмәт итәләр. Укый һәм яза белмәгән татар кешесенә якташлары түбәнсетеп карыйлар һәм ул, гражданин буларак, ихтирам ителми. Татарларның хатын-кызлары да белемсез калмый һәм алар арасында тиешле рәвештә укый-яза белмәгәннәре аз табылыр».[12] П. Знаменский (1910): «Татарлар арасында укый-яза белү, хатын-кызларны да исәпкә алып, киң таралган күренеш... Үзләренең күп санлы мәктәпләре һәм матбугатлары аркасында хәзерге көндә татар халкы бөтенләй грамоталы диярлек... Китапка күнегүе аркасында татар кешесе рус грамотасына да җиңел генә өйрәнә, полкларда күзәтелгәнчә: татар солдатлары русларга караганда уку-язуны тизрәк үзләштерәләр. Шунысы кызык, университет типографиясендә татарлар һәрвакыт университет һәм духовная академиянең фәнни журналлары

[9] Хасанов М. Х. Галимджан Ибрагимов. Казань, 1969, 100-101 бб.
[10] ТАССР ҮДА, I ф., 4 тасв., 1622 эш, 10 б.
[11] Машанов М. Современное состояние татар-мухамедян и их отношение к другим инородцам. Казань, 1910, 53 б.
[12] Сперанский А. Казанские татары. Казань, 1914, 9., 28, 30 бб.

өчен иң яхшы работниклардан саналдылар».[13] Я. Коблов (1916): «Россиядә Казан татарлары арасындагы кебек грамоталык киң таралган бүтән халыкны күрсәтүе кыен. Укый-яза белмәгән татар кешесен бик сирәк очратырга мөмкин, һәм бу хәл һәрбер мөселманның укый-язарга өйрәнүенең тулы мөмкинлегенә ия булуыннан килә, чөнки һәрбер авылда, ул нинди генә ярлы һәм кечкенә булмасын, мәктәп бар».[14]

Безнең бу раслауларга ышанмаска нигезебез юк. Ә бит мондый фактларны тагын берничә дистә китерергә мөмкин.

Сүз уңаенда күп кенә хезмәтләрдә теркәлгән һәм елдан-ел бер басмадан икенчесенә күчеп килгән бер ялгыш факт турында әйтеп китик. Аларда: революциягә кадәр Казан губернасы грамоталык ягыннан караганда Европа Россиянең 50 губернасы арасында 44 нче урында торган дип күрсәтелә һәм шуның аркасында татарларда грамоталык дәрәҗәсе үтә түбән булган дигән фикер үткәрелә. Беренчедән, сүз солдатка каралу яшендәге егетләр турында гына бара. Икенчедән, Казан губернасы халкы татарлардан (31,7 %) гына тормаган. Өченчедән, бу мәгълүматлар 1898 елда Ярославльдә үткәрелгән күргәзмә материаллары нигезендә генә китерелгән, ә аларның тулы булмавы рәсми басмада икърар ителгән.[15] Дүртенчедән, биредә сүз Казан губернасында яшәгән татарлар турында гына бара, ягъни башка халыклар турындагы саннар ил күләмендә китерелгәндә, татар халкы турындагы мәгълүмат Казан губернасы буенча гына китерелә. Ә алар Россиядә яшәүче татарларның 40 процентын гына тәшкил иткәннәр.

Шул ук вакытта Казан губерна идарәсе 1915 елда чыгарган «Великая Отечественная война. Казанская губерния» (28 б.) дигән китапта татарлар арасындагы грамоталык 80 процентка җитә, дип күрсәтелә.

СССРда 1926 елгы халык саны алу материаллары татарларның бөтен союз күләмендә укый-яза белү дәрәҗәсе буенча беренче урында торганлыкларын күрсәтә. Әлбәттә, революциягә кадәр надан булган халыкның 7-8 ел эчендә андый югарылыкка күтәрелүе бик шикле. Грамоталык дәрәҗәсен күтәрүдә, башка факторлар белән берраттән, әлбәттә, ана телендә кулланылышта йөргән йөзләрчә дәреслекләрнең роле зур булган.

Йомгак ясап шуны әйтергә кирәк. Культура мирасыбызны хурлау, чыбыркылау, мескенләнү өлкәсендә без инде, мөгаен, башка халыкларны шактый артта калдырганбыздыр. Кайчагында бу үз-үзеңне кыйнау революциягәчә булган культура (без монда мәгариф өлкәсенә генә кагылдык) казанышларын санга сукмау, танымау күренешен ала. Болар һәммәсе — 20-30 нчы еллардан килә торган вульгар социологизмның аяныч җимешләре яисә аның тотрыклы калдыклары.

Күптән түгел генә СССР язучылар идарәсенең Пленумында ясаган чыгышында Чыңгыз Айтматов: милли нигилизмга бирелеп, милли культураларның әһәмиятен киметергә тырышуны, шәһәр мәктәпләре һәм балалар бакчалары ачуга төрлечә аяк чалуларны хаклы рәвештә гаепләп чыкты. һәм, гомуми аралашу теле белән берраттән, диде ул, һәр регионда халыкның милли теле үзенең тарихи барлыгын һәм эшчәнлеген дәвам итәргә, дәвер коямы астында чәчәк атарга, үзен тулы хокуклы итеп сизәргә, үзенә йөкләнгән төрле функцияләрне башкарырга тиеш.

Аяныч ки, без инде «Кем идек, һәм кем булдык» тезисын декларатив рәвештә кабул итеп, культура һәм, беренче чиратта мәгариф казанышларына балта чабудан да тартынмыйбыз. Әгәр революциягәчә ана телендә укый-яза (һәм сөйләшә!!) белүчеләрнең процентын бүгенге күрсәткечләр белән янәшә куеп карасак, артык мөкиббән китәрлек нәтиҗәләр чыгарырга ашыкмас идек.

Әйтергә кирәк, татар халкының революциягәчә культура уңышларын (ә алар турында китаплар язасы бар) болай бәяләү изге максаттан эшләнә килде: Бөек Октябрь социалистик революциясенең әһәмиятен тагын да калкурак, масштаблырак итеп күрсәтү кирәк иде. Әлбәттә, Бөек Октябрь барлык халыклар, шул исәптән татарлар өчен дә яңа эра ачты. Татар халкы яшәешнең барлык сфераларында зур уңышларга ирешә, аның культура офыклары киңәйде.

Ләкин материалистик фән һәрбер иҗтимагый күренешкә диалектик бөтенлек итеп карауны һәм бәя бирүне таләп итә. Бер хакыйтьне икенчесенә каршы кую шул принципка каршы килә. Тарихны дөрес яктырту, андагы ак тапларны бетерү бүгенге үзгәртеп коруның мөһим бурычлары рәтендә тора. Шуңа бүген бу проблемалар аеруча актуаль төс ала.

[13] Знаменский П. Казанские татары. Казань, 1910, 24, 29 бб.

[14] Коблов Я. Д. Күрсәтелгән хезмәт, 3-4 бб.

[15] Народное образование в Казанской губернии. Вопросы внешкольного образования. Казань, 1905, 10-11 бб.



## *Татар халык музыка уен коралларры*

# СОРНАЙ

*Курайдан килгән, сорнайга китәр.*

(Татар халык әйтеме.)


Тикшеренүчеләр фикеренчә, тынлы уен коралларының килеп чыгышы төрки халыклардан дип санала. Бик борынгы заманнарда тынлы уен коралларының тишемнәре булмаган һәм алар ерак араларга сигнал бирү өчен кулланылганнар. Кулларны авыз янына куеп кычкырсаң, тавыш көчлерәк чыга. Шушы принциптан чыгып безнең бабаларыбыз мөгездән, каен тузыннан, калайдан һәм башка материаллардан сигнал бирү өчен быргылар ясаганнар. Соңга табарак быргыларны көпшәгә тишемнәр тишү ысулы белән дә ясый башлаганнар. Шулай итеп, көтүче быргысы, аучы быргысы, камыл курай, курай, сорнай һәм башка уен кораллары барлыкка килгән.

Хәзерге көнгә кадәр сакланып калган иң гади уен коралларының берсе — камыл курай. Камыл курай Татарстанның Минзәлә, Мөслим, Актаныш, Арча, Кукмара районнарында еш очрый. Бу төр уен коралында көзге кыр эшләре вакытында, көтү көткәндә, кичке уеннарда, аулак өйләрдә яшьләр уйнаган.

Республикабыз сәхнәләрендә, смотр-конкурсларда камыл курай моңнары бүгенге көндә дә яңгырый һәм халык тарафыннан яратып кабул ителә.

Камыл курайны ясау өчен 160-180 мм озынлыктагы өлгергән салам алына. Кисеп алынган саламның бер башы ябык, ә икенче башы ачык булырга тиеш. Саламның буынтыклы янсә пластилин белән томаланган шул ябык башыннан юка гына итеп (киңлеге 2,5-3 мм, озынлыгы 20-25 мм) тавыш сыбызгысы ясыйбыз. Тавыш сыбызгысы ясаганда аеруча игътибарлы булырга кирәк. Чөнки уен коралының сыйфаты, тембры, тавышының көче шуңа бәйле. Сыбызгыны ясап бетергәч, сызгыртып карарга кирәк. Тавышны үзеңә кирәк югарылыкка көйләү өчен саламны аз гына кыскартырга мөмкин. Менә сез үзегезгә кирәкле тавышны таптыгыз. Хәзер инде бармакчаларны (тишемнәрне) тишәргә кирәк. Моның өчен саламның ачык калган түбәнге башыннан беренче тишем ясала һәм алар шул тәртиптә санала. Тишемнең озынлыгы 4-5 мм, киңлеге 2-2,5 мм булырга тиеш. Әгәр музыкаль тавыш түбән булса, тишемне — югарыга, әгәр югары икән, тишемне аска таба зурайту сорала.

Түбәндә камыл курайның үлчәмнәре бирелә.




Камыл курайда аваз чыгару өчен тавыш сыбызгысын авызга кабып бетерергә һәм тигез генә өрергә кирәк. Өрү көченә карап тавыш югарылыгы үзгәрергә мөмкин. Көйне матур, аһәңле итеп уйнау өчен, дөрес итеп өрү аеруча әһәмиятле һәм бу эш уйнаучыдан зур осталык сорый. Тавышның көче — «меццофорте». Диапазоны — октава. Лады — пентатоника. Камыл курайда дәртле, шаян көйләрне дә, моңлы, салмак (диапазоны зур булмаган) көйләрне дә уйнарга була.

Нәкъ шул ук юл белән мондый уен коралын камыштан, әрекмән сабагыннан, кара әрем яки кура сабагыннан да ясарга мөмкин. Бу уен коралын икенче төрле сорнай дип тә йөртәләр. Сорнай сүзе күп халыкларда тынлы музыка уен коралы буларак кулланыла. Мәсәлән, сур, сурма, зурна, сырнай, сырбаснай һәм башкалар.

Сорнай ул — төрки сүз. Ике сүзне берләштерә: сор — мөгез, най — камыш. Ә казах халкы «сырнай» сүзен «сер», «серләшү» дип аңлата.


Г. Ф. Миллер үзенең «Казан губернасында яшәүче мәҗүси халыклар мари, чуваш, удмуртлар» (СПб., 1791, 80 б.) исемле хезмәтендә «татар сорнае» дип волынкага охшаш уен коралын атый. Шундый ук уен коралы мариларда «шюббер» яки «шыбыр» дип атала, ди.

Халкыбызның күп кенә әкиятләрендә, табышмакларында, әйтемнәрендә, дастаннарда, җырларында сорнай бик күп мәртәбәләр телгә алына. Төрле мәҗлесләрдә, халык уеннарында сорнай яшьләрнең яратып уйный торган музыка уен коралы булган.

Хәзерге көндә сорнайны камилләштереп, аның милли үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, халык уен кораллары остасы Ифрат Хисамов ясый. Ул эшләгән сорнайның тавышы көчле, моңлы һәм уйнау мөмкинлекләре дә зур. Оста башкаручы сорнайда озын көйләрне дә, шаян, тиз башкарыла торган көйләрне дә йөрәккә үтәрлек итеп уйный ала.


Тавышының көче — ике «форте»га кадәр, диапазоны — октава, лады — диатоника.

Сорнай өч өлештән тора. Сыбызгы өлеше, көпшә һәм мөгез өлешләре. Сыбызгы өлешен ясау аеруча катлаулы. Аны ясау өчен 40-45 мм озынлыгындагы металл яисә пластмасс көпшә (диаметры 8-10 мм) алына. Бер башын томаларга кирәк. Көпшәнең ябык башыннан 30-35 мм араны 1-1,5 мм тирәнлектә буеннан-буена эче күренеп торырлык итеп игәү белән игәләр.




30-35 мм озынлыгындагы кипкән агачтан яки пластмасстан трость, ягъни юка тел ясала (киңлеге 4-5 мм.). Аның бер башын лезвие яки игәү белән юкартырга кирәк. Ә икенче башын, сыбызгының төбенә резина балдак (диаметры 6-7 мм шланггтан ясала) кигезеп беркетеп куялар. Резина балдакның киңлеге 4-5 мм. Резина балдак куллануның икенче уңайлылыгы шунда, тростьны резинага кертебрәк куйсаң, тавыш күтәрелә, ә чыгарыбрак куйсаң, тавышы түбәнәя.

Көпшә өлешен ясау өчен озынлыгы 225 мм, диаметры 9-10 мм үлчәмдәге металл, эбонит яки камыш көпшә алына. Көпшәнең бер башын сыбызгы белән тоташтырабыз (көпшәгә сыбызгы 10 мм кертеп беркетелә). Ачык, түбәнге башыннан башлап бармакчалар тишәбез. Барлыгы 7 бармакчалы бу сорнайда халкыбызның «Наласа», «Ай матур гөл генә», «Мәк чәчәге», «Дүртөйле» һ. б. көйләрен тулысынча уйнап була.




Көпшәнең ачык башына чистартып шомартылган сыер мөгезе киертеп куялар, мөгезсез генә уйнарга да мөмкин. Камыл курайда да, сорнайда да уйнау алымнары бер үк төрле. Тавыш сыбызгысын авызга кабарга һәм һава чыкмаслык итеп иреннәр белән капларга кирәк. Сул кулның баш бармагы белән сорнайның аскы тишемен, беренче бармак белән беренче тишемне каплыйлар. Шул тәртиптә, сул кулның икенче бармагы белән — икенче, өченче бармагы белән өченче тишемнәр каплана. Уң кулның баш бармагы сорнайның астыннан тота. Беренче бармак белән дүртенче, икенче бармак белән бишенче, өченче бармак белән алтынчы тишемнәрне каплыйлар. Тишемнәр һава чыкмаслык итеп каплана.


Ринат **ГЫЙЛӘҖЕВ**,
Татарстан АССР культура министрлыгының
фәнни-методик үзәге директоры.

# УКУЧЫ СҮЗЕ

Хөрмәтле Мәхмүт!

Былтыр бер танышым «Казан утлары» журналының «Язгы аҗаган» романы басылган саннарын бирөп торды. (Башны гафләт басу аркасында, соңгы бер-ике елда журналга язылмый калган идем.) Ашауны да, йокыны да онытып дигәндәй, бу романны укып чыктым. Роман геройлары язмышы белән янып, горурланып, куанып, нәфрәтләнеп бер «тәкә яше» гомере яшәп алдым.

Бу язмышлар, вакыйгалар, Сезнең гаҗәп матур «чын безнеңчә матур, милли» тел белән язылган романыгызның эчтәлеге, шигъри көче күңелемә генә сыеша алмады. Соңгы елларда халыкара хәл, туган ил, намус һәм вөҗдан темаларына халык алдында лекцияләр белән чыгыш ясый идем. Ә менә романыгызны укыгач, башыма бер уй килде: нигә әле миңа яшьләр белән сөйләшкәндә шушы романны төп тема итеп алмаска! Китап кибетләрендә китабыгыз булмаса да, журнал вариантына нигезләнеп, халык алдында чыгышлар ясый башладым. Роман геройлары үземнең агай-энеләрем кебек якын булып китте. Чыгышларымны рус телендә алып барам. Бөтен милләтләр дә аңласыннар, белсеннәр, күрсеннәр, ишетмәсәләр — ишетсеннәр, димен. Юкса Астафьев, Рыбаков, Пикуль һәм башка берничә исемне мисалга китерәләр дә, бүгенге совет әдәбиятын шуның белән чикләп тә куялар.

Безнең Нефтекамск шәһәре һәм аның халкы турында берничә сүз. Халкы 130 меңнән артып китте. Һәрхәлдә, шуның яртысыннан күбрәге — татарлар һәм башкортлар. Татарча газета басылмый, радио аша да татарча сүз ишетмисең. Ләкин халык татарча концертларга, спектакльләргә атлыгып йөри. Ике клубта (бездә аларның икесен дә ни өчендер «Дом техники» дип йөртәләр. Шаккатырлык, валлаһи!) татар-башкорт халык театрлары уңышлы гына эшләп килә. Моннан берничә ел элек каләм тибрәтүче яшьләрне, картларны бергә җыеп, «Инеш» исемле иҗат берләшмәсе төзеп җибәргән идек. Шигырь һәм проза әсәрләре язучыларыбыз күрше районнарда чыга торган район газеталарында, Уфадагы «Кызыл таң» газетасында дөнья күргәлиләр. Узган җәйне Чаллыдагы иҗат көчләре дә кунакка килеп киттеләр. Сөйләшер сүзләр күп булды. Инде соңгы сүз итеп шуны әйтәсем килә: каян табыйк икән китабыгызны? Бу хакта Казан кибетләренә дә язып карадык, ләммим, бер җавап та килмәде.

**Низам ХӘМЗИН.**
БАССР, Нефтекамск шәһәре.

* * *

Без, татарлар, татарча китап укырга шундый мохтаҗбыз. Безнең кулга уйламаган җирдән «Язгы аҗаган» дигән китап килеп керде. Мәхмүт Хәсәнов язган. Без аны тугыз хатын җыелып кычкырып укыдык. Төн йокламадык, эшне эшләмәдек, ашны ашамадык. Кайсыбызның ирләре орыша: җитәр! дип. Кайсыбызны балалар һәм карчыклар орыша. Шулай да укып чыктык. Рәхмәтләр яусын сиңа, Мәхмүт! Язгансың, дөньяның астын-өскә китергәнсең. Бар да чын бит алар. Шөкер, Гали белән Гөлүсәне азга гына булса да кавыштыргансың. Сиңа бу китабың өчен алтын медаль бирер идек.

Без сиңа чын йөрәктән таза, тыныч, илһамлы булуыңны телибез.

**Нина, Мәрьям, Лиза, Рокыя** һәм
башкалар.
*Киров өлкәсе, Малмыж районы,*
*Чавал авылы.*

* * *

Хөрмәтле Мәхмүт ага!

Сезгә Бөгелмә шәһәренең Сукырлар җәмгыяте китапханәсе мөдире Роза яза. «Язгы аҗаган» дигән китабыгызны укучыларыбызга үзем кычкырып укыдым. Ул китапны укыганда китапханәдә басып торыр урын да булмады. Бик тә ошады халыкка китабыгыз, чират торып тагын укыйлар, китабыгыз гел кулда. Ә быел инде әсәрегез магнитофон тасмасына да күчерелде.

**Роза.**
*Бөгелмә шәһәре.*

РЕДАКЦИЯДӘН. Күп санлы укучылар соравы буенча, быел Татарстан китап нәшрияты Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган» романын 50 мең тираж белән кабаттан бастырып чыгарды. Ул китапны түбәндәге адрес белән соратырга мөмкин: 420057, г. Казань, ул. Октябрьская, 18. Магазин «Книга-почтой».

* * *

Хөрмәтле Ибраһим ага!

«Тайгак кичү» романыгызны укып чыккач, Сезне ирексездән Муса Җәлил белән янәшә куеп карадык. Язмышларыгыз күпмедер уртак. Әмма Җәлил фашизм тоткынлыгында: аның алдында ачык максат, ул кан дошманнарына каршы көрәшә алган, башын шул юлда корбан иткән. Сез болардан мәхрүм, алдыгызда өметсез тирән упкын... Кыскасы, әдәбиятыбызга бу әсәрегез белән бергә дөреслек тә әйләнеп кайтты. Сезнең шәхес, иҗатыгыз белән горурланабыз.

**Сөембикә ИХСАНОВА.**
**Хәсән СӘЙФУЛЛИН.**
*Менделеевск шәһәре.*

* * *

Мин озак еллар инде «Казан утлары» алдырам, һәр санын тулысынча укып барам. 1988 елда басылган әсәрләр арасында Якуб Зәнкиевнең «Иртеш таңнары», Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» романнары миңа аеруча ошады.

«Тайгак кичү» романы — татар әдәбиятында шәхес культы тоткыннарының коточкыч авыр язмышларын чагылдырган беренче әсәр. Аны тетрәнмичә һәм еламыйча укырга мөмкин түгел. Өзлексез кыйналулар, кимсетелүләр, ачлык, мохтаҗлык, ялгыз камера, карцерлар, салкын бараклар, көн саен унсигезәр сәгатькә сузылган каторга хезмәте һәм иң начары — кешелек дәрәҗәсенең тапталуы. Боларның барысын да язучы үзе кичергән.

Ирекгә дә аны кайгы-хәсрәт каршылый. Бу хәлләрдән соң инде аны рухи яктан да үтерелгән дип санарга мөмкин иде. Юк, ул көчле рухлы булып кала, үзендә «Тайгак кичү» кебек роман язарлык көч таба. Бу, минемчә, Ибраһим Салахов тарафыннан эшләнгән зур батырлык. Минем аңа «Казан утлары» журналы аша кайнар рәхмәтемне белдерәсем килә.

**Фуат КӘРИМОВ.**
*Пермь шәһәре.*

* * *

«Тайгак кичү» романын укыгач, йөрәгемне әрну басты. Вакытсыз һәлак булган халык улларының язмышын сөйләгәне өчен авторга рәхмәт. Үтерелгән ул кешеләр турында һәрчак сөйләргә кирәк. Алар онытылмаска тиеш. Аларның истәлеге терелергә кирәк. Аларның хакы изге. Тарих мондый хәлләрне яңадан кабатламасын өчен гел искә алып, моңсу хатирәләрен балаларга җиткереп торырга кирәк.

**Әминә МӨРСӘЛИМОВА.**
*Үзбәкстан ССР, Фирганә шәһәре.*

• • •

«Тайгак кичү» дигән роман-хрониканы укыгач, язучыбыз Ибраһим Салаховка ачык хат язарга мәҗбүр булдым. 1948—53 елларда мин Воркута лагерьларында конвой башлыгы булып хезмәт иттем. Арестантлар арасында төрле кешеләр бар иде. 58 нче статья белән гаепләнгән «контрлар» лагерь тәртибен боза торган кешеләрдән түгел иде. Алар бездән белемлерәк, намуслы һәм Ватанга хөрмәт белән карый торганнар иде. Язучы, кызганычны кызыклы итеп, «күтәрим дип бөгелгән идем, җиргә сеңеп китә яздым, аркага приклад төште», ди. Әгәр конвой приклад белән кеше аркасына берне төшерсә, кабыргасын сындыра. Үзем өлкән сержант идем. Ул елларда комсомол идем. Миңа буйсынган конвой да, үзем дә тоткыннарга сукмадык, кычкырмадык. Өлкән командирлардан инструкция алып, югары тәртип белән хезмәт итә идек. Чөнки Ленин белән Дзержинский 1918 елда ук закон язганнар: һәрбер конвой һәр тоткын өчен башы белән җавап бирә дигәннәр. Социалистик революция законын бозган конвойның үзен төрмәгә ябалар иде. Бигрәк тә 58 нче статья белән гаепләнгән тоткыннардан сак була идек. Роман-хрониканы укучылардан андагы хәлләргә тулаем ышанучылар да бардыр әле. Шундый әсәрне «Казан утлары» журналы битләрендә урнаштыру дөрес булды микән? Чөнки журналны чит илләрдә дә алалар икән. Язучы Ибраһим Салахов үз әсәренең кайбер урыннарында әнәдән лом ясаган. Ватаныбызның вакытлыча тоткын булган кешеләрен рәнҗетергә, аңа карата тәртипсезлек күрсәтергә конвойларга рөхсәт юк иде. Алар инструкция нигезендә хезмәт иттеләр.

Бу хатымны журнал битләренә урнаштырыгыз. Язучы да, башка укучылар да укысыннар, фикеремне белсеннәр.

**Бәдри ӘМИРХАНОВ.**
*Әстерхан шәһәре.*

• • •

«Казан утлары»н өзлексез укып барам. Соңгы елларда аерата уңышлы әсәрләр чыга башлады. Х. Камаловның «Үлгәннән соң яздым» дигән романы — әнә шундый әсәрләрнең берсе. Хәрби госпитальдәге тормыш, андагы кешеләр арасында барган вакыйгалар, шәфкать сагында торучыларның игелекле хезмәтләре ягымлы булып күңелдә кала.

Бөек Ватан сугышында мин аягымны югалттым. Бер ел госпитальдә яттым. Әсәр безнең ишеләр турында язылган. Анда тасвирланган шәфкать туташлары кебекләр безне — үлгәннәрне терелттеләр ич. Авторга, әсәрне журнал өчен әзерләүчеләргә зур рәхмәт.

**Камал ХӘЛӘПОВ.**
*Әлмәт шәһәре.*

• • •

Кадерле якташлар!

Журналның былтыргы 11-12 саннарыннан Рәшат Низамиевның «Язмыштан көчлерәк» дигән роман-хроникасын бик игътибар белән укып чыктым. Язучыга бик күп рәхмәтләр әйтәм. Романда миңа таныш булган җырчылар, музыкантлар турында да язылган. Мин алар белән очрашкан кеше. Әсәр аша Фәрит Яруллинның тормыш юлы белән ныклап таныштым. Тик йөрәгем уртасында ачу калды. Революциядән соң күтәрелеп килгән безнең композиторларны, бигрәк тә яшь Фәрит Яруллинны сугыштан алып кала алмаганнар...

Без, Казаннан ерак яшәсәк тә, үзебезнең культура белән һәрвакыт кызыксынып яшибез. Тәүфикъ Әйдинең күренекле татарлар турында язган очерк һәм китапларын укып та татарлар арасында шундый данлы кешеләр барлыгын белеп сөендем.

**М. ЗЫЯТДИНОВА.**
*Ленинград шәһәре.*

• • •

Иптәш Низамиев!

Мин сезнең «Казан утлары» журналында басылган «Язмыштан көчлерәк» исемле әсәрегезне укып чыктым. Шулкадәр матур тел белән яза алгансыз, зур рәхмәт.

Сез бит әле яшь. Фәритнең үзен күреп белмисездер, ә ничек шулкадәр үзен күргәндәй, бергә эшләгәндәй итеп сурәтләгәнсез композиторны! Аның уйларын, хыялларын оста итеп биргәнсез. Әсәрегезне укый башлагач аерылып та булмый. Зур талант иясе бигрәк тә яшь килеш әрәм булды шул. Өстәвенә, 42 елдан соң гына кабере табылуы да үзәкне өзә. Талантларны саклый белмәгәнбез шул.

**Зәкия ӘМИНОВА.**
*Әгерҗе районы, Иж-Буби авылы.*

* * *

Хөрмәтле редакция!

Күп еллар журналны яратып укыйбыз. Без әле Заһидулла Яруллин, аның улы Фәрит Яруллин турында бик аз белә идек. Рашат Низамиев романын укып, ниһаять, барын да белдек. Елый-елый укыдык. Талантларны һәлак итте шул сугыш. Журналга, язучы Р. Низамиевка уңышлар телибез.

**Тәлгат һәм Нурия ӘБДРӘШИТОВЛАР.**
*Оренбург шәһәре.*

* * *

Кадерле Рашат Низамиев!

Сезнең «Язмыштан көчлерәк» дигән роман-хроникагызны укып чыктым.

Әйе, Фәрит Яруллинның иҗаты, тормышы турында күптәннән беләсем килә иде. Сез мине бу әсәрегез белән канәгатьләндердегез, рәхмәт. Романыгыз җиңел укыла, телегез матур, халыкчан.

Фәритнең «Шүрәле» балетын ничек язуын җентекләп сурәтлисез. Без ул балет белән горурланабыз. 1987 елның март аенда Ленинград шәһәрен күрергә барган идек (минем әти Ленинград блокадасын кичергән кеше). Урамнан барганда төрле афишаларга күзем төште. Бардым. Укыйм. Үз күзләремә ышанмыйм: Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты Ленсовет культура сараенда куела, диелгән. Куючысы Л. Куватова икән. Кайчандыр Габдулла Тукай Петербургка килгән, шәһәрне ныклап күрә алмыйча кайтып киткән. Ә хәзер Ленинград халкы Тукайның «Шүрәле»сен карый. Нинди шатлык! Бик озак горурланып тордым.

Безнең Башкортстан укучылары Фәрит турында язылган әсәрегезне бик җылы каршы алдылар. Рәхмәт.

**Әмир МӨЛЕКОВ.**
*БАССР, Кырмыскалы районы,*
*Иске-Шәрәй авылы.*

* * *

«Казан утлары» журналы татар халкының мәдәни һәм әдәби мирасы мәсьәләләренә элек-электән үк нык игътибар итә. Милләтебезнең тарихы, теле, әдәбияты турында, гомумән, мәдәниятның күп төрле өлкәләренә караган һәртөрле тикшеренүләр, мәкаләләр, хәбәрләр гел басылып килде. Ә узган 1988 ел саннары безнең өчен бигрәк тә куанычлы булды — инде ничәмә дистә еллар онытылып яисә басыла алмыйча яткан җәүһәрләр яңадан халыкның үзенә кайта башлады. Журналның 1 саныннан ук Ш. Мәрҗанинең «Казан һәм Болгар хәлләреннән файдаланылган хәбәрләр» дигән әсәре, 3 санда исә Кол Галинең мәшһүр «Кыйссаи Йосыф»ы хәзерге әдәби телгә тәрҗемә итеп басылуы укучылар өчен күптән көтелгән бүләк булды.

Һәм менә журналның 9—10 саннарында урта гасыр татар прозасының гүзәл бер үрнәге булган «Мәҗмугы-л-хикаят»нең хәзерге әдәби телгә күчерелеп басылуы — безнең өчен бигрәк тә зур яңалык. Чөнки моңа кадәр ни өчендер, татарларда XIX гасырның өченче чирекләренә кадәр игътибарга алырлык проза булмаган, поэзия өстенлек иткән дигән караш яшәп килә иде. Журналда нибары тугыз хикәят басылган, шулар буенча гына да прозаның нинди бай, һәртөрле сурәтләү чараларының муллыгы сизелеп тора. Ә бит кереш мәкаләдә җыентык 33 хикәяттән тора дип язылган. Димәк, ул 25 табаклар чамасындагы бер калын китап дигән сүз. Мәкаләнең авторы андый җыентыкларның әле шактый күп булуы турында әйтеп уза.

Хикәятләрне укыгач шундый бер гаҗәп нәрсә ачыла: татар халкы дөньякүләм билгеле әдәби җәүһәрләрдән, ачыграк әйткәндә, әдәбияты көчле үскән илләрдә тарал-

ган әдәби сюжетлардан һич тә мәхрүм калмаган икән. XVIII гасырда французлар, итальяннар, немецлар «Мәҗмугы-л-хикаят»тәге сюжетлар белән таныш булсалар, татарлар андый әсәрләрне хәтта иртәрәк тә укыганнар. Бары шунда аерма: иҗтимагый, икътисади (экономик) һәм мәдәни үсешләре чагыштыргысыз югары булган Көнбатыш Европа халыклары ул сюжетларны югарырак дәрәҗәдә — пьеса, спектакль, опера рәвешендә файдаланганнар.

«Мәҗмугы-л-хикаят»нең өлешчә басылып чыгуы бер куаныч булса, аны борынгы әдәби телебездән хәзерге телгә күчереп басмага хәзерләүченең, кереш мәкалә авторының безнең якташыбыз Н. Исмәгыйлов булуы минем өчен икенче сөенеч. Чөнки аның инде күп еллар буе урта гасыр татар прозасын өйрәнүен, тырышып-тырышып иске кульязмалардан әсәрләр эзләвен белә идем. Туган ягына кайткач та, ул районыбыз авылларына чыгып китеп борынгы кульязмаларны җыеп йөрер иде. Без, якташлары, аның бу игелекле эшендә алга таба да зур уңышлар телибез.

**Мансур ФАЗЫЛОВ.**
*Мамадыш районы, Үсәли авылы*

* * *

Сталин заманында миллионлаган совет кешеләре шәхес культы корбаны булдылар. Башка совет халыклары шикелле үк, безнең татар халкы да бу дәвердә үзенең иң яхшы улларын һәм кызларын югалтты. Алар арасында күренекле әдипләребез булуы да мәгълүм. Үкенечкә каршы, без шул әдипләребезнең кайда һәм ничек юк ителгәнлекләрен дә, аларның саны күпме икәнен дә юньләп белмибез.

Хөрмәтле «Казан утлары»! Шәхес культы вакытында корбан булган язучы һәм шагыйрьләребезнең, галимнәребезнең, сәнгать кешеләренең исемлеген үзегезнең сәхифәләрегездә бастырып чыгарсагыз иде, аларның дәһшәтле язмышлары хакында кыскача булса да белешмә бирсәгез иде.

**Хәмит ТӨХФИ.**
*Ташкент шәһәре.*

* * *

Казан мәктәпләрендә татарча укыту бетерелгән дип ишетәбез. Бик тә аяныч хәл. Моны ишеткәч, күңелдә гарьләнү һәм нәфрәт уянды. Кемнәргәдер ачу килә. Ниткән эш бу? Ничек инде шаулап торган бер милләтнең ана телен кысрыкларга мөмкин? Үзебезнекеләр (ил морткалары) ни караганнар диген, су өстендәге камыш шикелле, җил кайсы якка иссә — алар да шул якка ауганнар, күрәсең. Юкса, мондый кызганыч хәл килеп чыкмас иде. Оятлы ни тора! Үз телен белмәгән кеше — ярты үлек ул. Үз моңын сөймәгән, көйләмәгән, үзенең ата-бабалар җирен яратмаган, үз халкын якын итмәгән кешене шулай дип атар вакыт җитте.

Үз милләтеңнең гореф-гадәтләрен, тапкыр сүзләрен ата-анаңны яраткандай яратырга кирәк. Шулай булмаганда, кайда синең кешелегең? Андыйларның кешеләрне яратуына ышанмыйм мин.

Бик тә бай тарихлы, чиксез җәфалар, сугышлар, басып алулар, талаулар күргән халкыбыз үз телен исән-сау саклап, бүгенге көнгә хәтле китерә алган бит. Шул изге хәзинәне нигә кысрыкларга?

Үзеңнең рухи байлыгыңа хуҗа булмау, үз телеңдә иркенләп сөйләшә алмау — ике яклы булудан, куркаклыктан килә ул. Ә бит халкыбыз төшеп калганнардан түгел. Ул батыр да, үтә эшчән дә. Фән-техника, сәнгать өлкәсендә дә сынатмый. Европаның культура ягыннан алда барган халыкларыннан борын-борыннан һич тә калышмый.

Төрки милләтләр арасында татар хатын-кызлары башка милләт кешеләренә кияүгә чыгу буенча беренче урында торадыр, мөгаен. Монда хатын-кыз милләте юкылып кала, берничә буын эчендә бөтенләйгә югала. Кайберәүләр моны, халыклар арасындагы дуслык, аларның бер-берсенә якынаюы, дип атый. Югалтуларга китергән дуслыкны мин аңламыйм.

Мин туып-үскән Башкортстанда да хәлләр күңелсез. Күп районнарда татар мәктәпләре юк, булганнары ябылган, балалар русча гына сиптерәләр. Бу хәлләрне кичекмәстән төзәтәсе иде. Нинди зур рухи югалту!

**Х. ЛОКМАНОВ.**
*Казахстан ССР, Кентау шәһәре.*

## КАЗАННЫ САГЫНУ

*Хөрмәтле редактор әфәнде!*

*Без сезләрнең «Казан утлары» исемле журналыңызларны укып, милли әдәбиятымыз һәм дә милләтебез тәрәккыяте белән танышып торабыз. Йөрәгебездәге «Их, Казан!» дигән утларны шул «Казан утлары» белән ялкынлатабыз. Безләр язмыш булып бу чит илләрдә яшәсәк тә, милли хисләребез, Казанга булган сөйгеләребез, мәхәббәтебез чит илләшмәгән. Һаман да үзебезне шул Казанның бер фәрзәнде (улы, баласы — ред.) кеби хис итәбез. Рәхмәтлек әтием:*

*Казан илем, Казан җирем,*
*Казанда тормасам да.*
*Бер-ике җыр җырлап бирим,*
*Җыручы булмасам да,*

*— дип җырлый торган иде. Ә хәзер мин дә болай җырлыйм:*

*Казан илем, Казан җирем,*
*Казанда тумасам да.*
*Ватаным дип җырлыймын мин,*
*Чын шагыйрь булмасам да!*

*Мин үземнең милли хисләремне сезләр белән уртаклашырга телим. Шуңа күрә, әгәр дә кабул күрсәңезләр мин бер-ике гади генә шигырь кушып җибәрәм. Татар мәктәбендә укып, татар әдәбиятын өйрәнмәгәнлектән, әдәби хаталары булса, гафу итәрсезләр.*

*Хөрмәт илә: Гайшә Вәлиева. (Иншаллаһ, хатка бер җавап ала белермен дип ышанамын.)*

*Австралия, Престон шәһәре.*
*10 апрель, 1989 ел.*

* * *

И Казан, данлы Казан, шанлы Казан!
Сине уйлап, күңелемдә ямьнәр табам.
Түгелмәгән булса да кендек каным,
Ни бәхет, ахирәттә синдә калсам!

Гомеремдә үзеңне күрмәсәм дә,
Туфрагың миңа ифрат таныш тоела.
Дөньяның бер читендә яшәсәм дә,
Күңелем һаман, Казан, сиңа омтыла.

Хыялымда яшим синдә ямьле генә,
Хис итәмен уйларымда тәмле генә.
Мин булам татар халкым белән бергә,
Сөйләшәм татар теле белән генә.

Бары да таныш: урамдагы кешеләрең,
Исәнләшә, елмаешып бер-беренә.
Мин урамда чакта иптәшләрем,
Барыйк дип мәктәпләргә бергә-бергә.

Айрылмыйча халкымнан, дусларымнан,
Яшәсәм иде мәңге синдә генә!
Уянсам шул тәмле уйларымнан —
Мин тагын шул чит-ят илдә генә.

**P. S. Исегезгә төшерәбез: чит илдә яшәүче милләттәшләребез «Казан утлары» журналына я зылу өчен түбәндәге адреска мөрәҗәгать итә алалар:**
**113095, г. Москва,**
**ул. Дмитриева, 39/20,**
**Международная книга.**

# Әдхәт Синугыл

## Адәм әүлиясе

монолог

Була бит ул алла каргаган бәндәләр:
Анысына, монысына бәйләнәләр...
Азгын канлы ала каргалар шикелле,
Кар-кар килеп, баш очыңда әйләнәләр.

Әкәм-төкәм чокынып, чүплектә алар
Чурт-чураман чәйнәп сару кайнаталар,
Кирәк-кирәкмәгән җиргә һаман тыгылып,
Бер дә юкка авыз-борын канаталар.

Нигә кирәк, кар-кар килеп, борын тыгу,
Нигә кирәк бүрәнәдән бүре куу?
Белер-белмәс эт өрсә — буран китерә,
Белгәнеңне үзең белеп, кирәк тыну.

Өс-баш тишек, тамагың ач булса — бер хәл.
Көрлеккә шул чыдый алмый кайбер халык.
Бездәй, менә, тәүфыйк, әдип иясеннән,
Шөкер кылып, яши белми үрнәк алып.

Сукыр бул син, барын-югын күрмә бер дә.
Мәҗнүн бул син, юләрлеккә башың салып.
Боздай бул син койрыгың шомалыкта,
Бозау бул син, кирәк җирдә, бул син сарык!

Кызу гына канлы булма кояш кебек,
Һәрвакытта салкын канлы кыш бул, суык...
Ашыгып син, кабаланып капсаң өрми,
Кабуың бар, януың бар пешеп куеп!

Уйна да көл, әртистлән син, клоунлан,
Чын йөзеңне яшерүче битлектән бул.
Әрсезлектә әверел эт каешына,
Кирәк чакта, кемгәдер бул, бил бөгеп, кол!

Чукрактан да чукрак бул син әрләгәндә,
Тыңлаучан бул, тик булма ишәк киресе...
Ачкүз бул син, комагай бул комсызлыкта,
Чыдамлыкта — чыдам бул нәкъ эт тиресе!

---

Әдхәт СИНУГЫЛ *(1935) — шагыйрь, татар һәм кырым-татар телләрендә дөнья күргән берничә шигырь китабы авторы. Тәрҗемә өлкәсендә дә эшли. Ташкентта яши.*

Тел озайтма! Телдән дә юк агу-зәһәр!
Күп сүз — юк сүз! Күп сөйләшмә, бирми сөт сүз.
Кулың юа алмаганны — телең юсын,
Дуганы да, кирәк икән, диген син төз!

Туры сүзле үгез күзне итмә һич үз,
Ерак йөре андыйлардан, тиз чөер йөз.
Күрер өчен бирелгән булса да ул күз,
Еш күренмә хуҗаңа син бик күзгә-күз.

Кирәккәннең кырык кылын яр кырыкка,
Иш иткәннең ишәге бул, бул дөясе...
Фәкать күндәм җанлы булган адәм генә
Була ала, миндәй, адәм әүлиясе!

## «Алла бабай» белән әңгәмә

*Хур кызларың йөрер уңда-сулда,*
*План да юк анда, стимул да...*

Г. Афзал

Мин камырдан яратылмаган ич...
Түгел пәйгамбәрләр нәселеннән.
Газраил дә, Иблис тә түгел мин,
Мин адәми бер зат нәсәбеннән.

Адәм булып туган өчен генә,
Гөнаһлымын икән җирдә нигә?
Фани дөнья — тоташ таплы дөнья,
«Теге дөнья» — пакьле дөнья менә!

Син бит, ходай, тугрыга өндисең,
Үзеңнең гел тугрыданмы юлың?
Ник яраттың гөнаһ кылыр итеп —
Азгын итеп, җиргә барча колың?

Диндармы без, динсезме без-юләр,
Болай диләр бердәм барлык диннәр:
Газап өчен сезнең туган җирләр,
Җир астында көтә оҗмах, түрләр!

Оҗмахыбыз, үлгәч, кара гүрләр...
Оҗмахны соң кем күргән бирәр?!
Дөньялыкта буйсын, булып коллар,
Буйсынмасаң, җәһәннәмгә юллар!
(Кол булганга, оҗмахка юл ачык,
Адәм заты, шунда тизрәк ашык!).

Җир астында, никтер, җәннәт, бәхет?
Җир өстендә булсын иде тәхет!
Нигә шунда яратмадың, ходай,
Тәмугын да җир өстендә, кулай?
(Янганнарны күрсәк әгәр шулай,
Булмас иде гөнаһ җирдә болай!).

Белмим, нигә рөхсәт иткәнсеңдер
Хур кызларын, хур итеп, кочарга...
Хур кызларын гөнаһ түгел кочу,
Җир кызларын ник гөнаһ кочарга?!
(Бәндәң генә микән инде, ходай,
Үзең дә бик камил түгел бугай?)

Син ничектер... Әмма туган җирдә
Ал-ял белми алга барабыз без!
Җир йөзендә камиллекне яклап,
Көрәшәбез, Алла бабабыз, без!

## Каргалар карары

мәсәл

Серле, шау-шулы карурман
Җырдан тынып калганда,
Чәчәкләрнең, күңеле тулып,
Яше чыкка тамганда:

— Җитте, бу эш түгел! — диган
Былбылга шулчак Карга.—
Сине генә тыңлап торсак,
Акылдан язар бар да.

Безнең өчен Чыпчыктан да
Уңай кандидат булмас...
Дөрес сөйлимме, җәмәгать?
Бәлки, кемдер кул куймас?..

— Дөрес булмаган кая ул! —
Диештеләр козгыннар.—
Былбылдан йөдәгән инде,
Җырлары да — озыннар!

Чыпчык, ичмасам, җырлыйм дип,
Бик дәгъва дә белдерми;
Тавышы яныннан китми,
Йокыны да бүлдерми.

...Безнең арада да, кайчак,
Куеп юк-бар таләпләр,
«Каргалар карары» белән
Үсалмый яшь талантлар.

## Дуңгыз — Сарык абзарында

*мәсәл*

Дуңгызның башы уйлардан гарык...
Куркуга калды аңардан Сарык.

Тирләде-пеште, коелып төште,
Кыюлык өчен ул нидер эчте.

Шундый зур кунак, уен эш түгел:
Калуы бик бар юк-бардан күңел.

Мәш килде Сарык, йөзе бик арык,
Сый-хөрмәт итте Дуңгызны, арып.

Бушангач берчак дәхи күп шешә,
Кәефләр килеп, тел көрмәлешә:

«Мин, Сарык, гарык синең сыеңнан,
Корсак шартлардай, туйдым, муеннан!»

(Шулвакыт Дуңгыз, мырык-мырык килеп,
Тау ишелгәндәй, куйды төчкереп).

«Ләкин, белмим, ник синең юк мөгез,
Мөгезсез Сарык булмый, ди, симез.

Яшисең үзең, болай, бик белеп,
Тик тиреӊ юка, целлофан кебек!

Туның тун түгел, минем тун нәфис,
Юеш борын син, белсәң, йонтәпис!»

Бәйләнә Дуңгыз, кунак булса да:
«Кертмәдең,— ди ул,— ягып мунча да!

Апара белән,— дип ул белдерә,—
Сыйламавың да нидер сиздерә...»

...Дуңгызга вәгазь уку керми дә...
Дуңгызлыгын, тик, итсен өендә!

# Вахит Монасыйпов

## ТАНТАНА

Харис Хөсәеновичның алтмыш еллык юбилей-мәҗлесе тантаналы төстә ачылды. Юбиляр үзе, май кояшыдай балкып, түрдә утыра. Хезмәттәшләренең дустанә елмаюы, җылы карашы тәэсирендә ул бүген ярыйсы ук яшәреп киткән.

Шешәләр ачылып, бәллүр бокаллар затлы шәраб белән мөлдерәмә тулгач, юантык гәүдәсен урындыктан җиңел генә кубарып, местком председателе торып басты.

— Җәмәгать! — диде ул, калын пыялалы күрәкарау күзлеген ялтыратып. — Җәмәгать! Безнең хөрмәтле юбилярыбыз озын һәм катлаулы тормыш юлы узган. Уен түгел — бу фани дөнья буйлап алтмыш ел буе теркелдәп кара әле син. Әлбәттә, хәзер Харис Хөсәенович без белгән элекке Харис түгел инде. Чәчләргә кырпак төшкән, күз кабаклары шешенгән. Шуның өстенә, хәтере начарланган. Нихәл итмәк кирәк, җәмәгать, кыска шул кеше гомере, бик тә кыска! Тик, минемчә, иртәрәк әле җеназа турында сөйләргә. Әйдәгез, күңеллерәк нәрсәләр хакында сөйләшик. Күтәрегез бокалларны. Кадерле дустыбыз Харис Хөсәенович хөрмәтенә! Аңа мең-мең сәламәтлек теләп...

Барысы да эчеп куйдылар, бокаллар яңадан тулды.

Кәҗә сакаллы, чандыр гәүдәле кеше — идарәнең баш экономисты сүз сорады.

— Һи-и, хәтерлим әле мин Харис Хөсәеновичның егет чакларын, — дип башлады ул үзенең тәбрикләү сүзен. — Типсә тимер өзәрлек ир-егет иде ул. Чиртсәң, каны чәчрәп чыгарга тора, күзләрендә очкын уйный! Бөтен машбюро хатын-кызлары аңа гашыйк булып, яшертен генә уфтанып-көрсенеп йөрде... Менә шул кеше — хөрмәтле юбилярыбыз — үзенең яшьлеген, бөтен матурлыгын, бар булган сәламәтлеген яраткан эшенә корбан итте. Әйе, әйе, тәүлекләр буенча кабинетыннан чыкмыйча, утырган урыныннан купмыйча отчетлар төзеде. Кыскасы, үз-үзен кызганмады, аямады. Һәм нәтиҗәдә, үзегезгә мәгълүм, картлык көнендә бөсер чиренә тарыды!

Юбиляр авызына капкан азыкны чәйнәүдән туктады. Тәмам каушап, күзләрен әлеге ораторга текәде. Ләкин нәрсә дә булса әйтергә өлгермәде, юка иренле елгыр хисапчы урыныннан сикереп торды:

— Бөсер нәрсә ул! Бөсер — шул да булдымы хаста! Бирегә, шушы бинада, күз алдыбызда Харис Хөсәенович радикулитка юлыкты. Шушы йорттан алып китеп, хирургия бүлегендә аның сукыр эчәгесен кисteләр. Һәм без бүген хаклы рәвештә горурлана алабыз: шундый кеше — безнең арада, без — шундый фидакарь кеше янында!..

Харис Хөсәенович, алдындагы бокалны читкә этеп куйды, еш-еш сулап, калтыранган куллары белән, кесәсен капшады, кульяулык чыгарып, маңгай тирен сөртте. Аның хәрәкәтләрен күзәтеп утырган фельдшер ханым, валидол чыгарып, юбилярның авызына каптырды

— Рөхсәт итегез, юбилярыбыз хөрмәтенә мин дә бер-ике сүз әйтим, — диде ул аннары. — Искиткеч яхшы кеше булу белән бергә, безнең Харис Хөсәенович менә дигән авыру да әле. Мин һәрвакыт гаҗәпләнәм: шул тикле авыр чирләрне җиңеп барырга күпме түзем, күпме батырлык кирәк! Аның урынында башка берәү булса, күптән инде теге дөньяга...

Харис Хөсәеновичның йөзе акшарлы морҗадай агарды, сулышы тагын да ешайды, бөтен тәне калтырарга кереште. Ул, тантаналы нотыкларның беткәнен көтеп тормастан, йөрәген тотып, әкрен генә урыныннан торды һәм... ишеккә юнәлде.

# БУРЫЧ

«И-и Сафа яшьти, Сафа дус! Нишлибез инде хәзер?..» Бату Хәмматович, үзен-үзе куяр урын тапмый, бүлмәләр буйлап әрле-бирле сугыла, Сафа яшьтәшенең хәләл җефете Фәния Басыйровнага шалтырата, дәвалаучы докторга шалтыратып, янәдән тегенең хәл-әхвәлен сораша.

— Артык борчылмагыз, кадерлем, — ди терапевт. — Кулдан килгәннең барысын да эшләрбез.

Әмма... Доктор вәгъдәләре дә тынычландыра алмый Батуның әрнегән күңелен. Ул, ашарын ашамыйча, төннәр буе медицина белешмәләре актара, махсус сүзлекләр, аңлатмалар табып, каны качкан юка иреннәрен көчкә-көчкә кыймылдатып, тел әйләнмәслек терминнар ятлый: «Миокардит, перекардит, гло-мерулонефрит, лейкоцит, хо-лестерин»...

Ә иртән таң атуга, шул шешенгән күзләре белән больницага йөгерә. Кием элгечтә Фәния Басыйровнаның төлке якалы пәлтәсен күрсә, түземсезләнеп, аның чыкканын көтеп ала:

— Иә, ничек ул анда?

— Яхшыга таба бара кебек, Бату Хәмматович.

— Строфонтин бирмиләрме? Адреналин кадамыйлармы? Бик ярдәме тия, дип ишеткән идем.

— Рәхмәт инде, рәхмәт, Бату Хәмматович.

— Аларның файдасы тимәсә, натрисалицил дигәннәрен сынап карасыннар.

— Хөрмәтлем Бату Хәмматович, сезгә ничекләр итеп рәхмәт укырга да белмим... Шул тикле борчылып йөрүегез...

— Куегыз, Фәния Басыйровна. Бурыч дигән нәрсә дә бар бит әле... Ни әйтсәң дә, бер бүлектә эшлибез. Өстәлләребез терәлеп тора, дигәндәй... Карагыз әле, алай-болай мине телгә алмагандыр бит? Исенә төшсә...

— Рәхмәт-рәхмәт, аңа бернәрсә дә кирәкми. Сезгә бик күп сәлам тапшырырга кушты...

Икенче көнне иртән Бату янәдән больница ишеге төбендә Фәния Басыйровнаны көтеп алды.

— Нинди яңалыклар? Бром-натрий эчәме? Ә Павлов микстурасын? Шулаймы? Бик шәп, бик мәслихәт. Ә миңа... Берәр сүз әйтергә кушмадымы?

— Юк, кушмады... Хәер, туктагыз әле. Иа алла, тәмам башым каткан бу көннәрдә, — Фәния Басыйровна кул сумкасында актарына-актарына һаман сөйләнде. — Тәмам һушымны алды аның болай кинәт аяктан егылуы. Шушы ун көн эчендә үзем аяктан кала яздым. Ул әле сезгә ун сум бурычлы икән бит. Менә, алыгыз рәхмәте белән. Гафу итә күрегез.

— Зарар юк, зарар юк. Кемдә булмый андый гына...

Бату, акчаны дүрткә бөкләп, эчке кесәсенә салып куйды. «Вчүтеки онытмаган! Вчүтеки исенә төшергән!» дип уйлады ул эченнән генә. Ә йөзендә... Йөзендә соңгы ун көн эчендә беренче мәртәбә шатлыклы елмаю галәмәте төсмерләнде.

# ШИКАЯТЬ

Азамат, Госман һәм Локман өчесе исеменнән редакциягә шикаять хаты язарга булдылар.

«Хөрмәтле редакция! — дип яза башлады Госман. — Безнең комендантны шабыр тир түктергәнче «мунча кертсәгез» иде. Юкса, бөтенләй алып узды, кыл да кыймылдатмый. Кышын безнең тулай торакта адәм түзешле түгел. Идәндә бармак сыешлы ярыклар. Җәй көне алай да ярый, ни әйтсәң дә, вентиляция. Ә хәзер кыш лабаса. Карасаң, юньлерәк балта остасына нибары ике сәгатьлек эш...»

— Тукта әле, парин, — диде Азамат. — Морҗа хакында да әйтми ярамас. Яз әйдә: морҗабыз кубып, яргаланып беткән, һәр ярыктан төтен бәрә, диң. Ремонт ясарга теләсәләр, сукыр бер тиенлек эш, диң. Ике-өч кирпечен каерып аласы да, төтен юлын чистартасы да, яңадан сылап куясы да, диң, вәссәлам, эш тәмам, диң.

— Дөрес! — дип хуплады Локман. — Тәрәзәләр турында да әйтергә онытма. Яз: тәрәзәләрдә бөтен-бөтен бүлкәләр ватык, мендәр тыгып кына котылабыз, төнгә юрган элабез. Җитәкчеләр ни уйлый торгандыр, белмибез...

...Хатны конвертка салыр алдыннан Госман, йомычка сыман аксыл бөдрә чәчләрен артка чөеп, әйтеп куйды:

— Куркып язганнар икән дип уйламасыннар, әйдәгез, кем икәнлегебезне тулысынча күрсәтик.

— Хак әйтәсең! — диде Локман.

— Дөрес! — дип хуплады Азамат.

Һәм алар шикаять хатына бер-бер артлы кул куйдылар:

Госман — балта остасы;

Азамат — морҗачы;

Локман — пыяла куючы.

## Батулла

# НОТЫКЧЫ

Хөрмүт бичара үз тормышыннан канәгать түгел. Болай бер уйлап карасаң, аның тормышы бик үк начар да түгел, югыйсә. Гаиләсе — тулы-тыгыз. Хатыны, өч баласы бар. Биш кешелек, уртача, матур гаилә. Ике малай, бер кыз. Йорт-җире дә җитеш, дигәндәй. Шулай да, Хөрмүт төннәр буе пошыргалана, нидер уйлый. Уйлый-уйлый кара сагышка батты. Хатыны Җомрия:

— Атасы, сиңа ни булды? — дип сораган иде, Хөрмүт аны кырт кисте:

— Мышнавыңны бел! — диде дә, хатынына аркасы белән борылды.

Дөресен генә әйткәндә, көнчелек корты төште аның бәгыренә. Әнә, кешеләр — байый. Умыралар гына малны. Кайсысы алты почмаклы йорт сала. Алай дисәң, Хөрмүтнеке дә алты почмаклы. Әнә, Гөрдүки сигез почмаклы итте йортын. Дача дигән булып, тагын өстенә җәйге бүлмәләр ясап бетерде. Кайткан булалар да балаларын ияртеп — кияүләре, киленнәре белән шәһәрдән — шаулашкан булалар. Баян уйнаган булалар. Өерелеп бәрәңге алырга, печән әзерләргә чыккан булалар. Кеше көнләшсен дип юри көләләр, юри кычкырып җырлыйлар төсле тоела Хөрмүткә аларның шулай шау дулкын булып кайтулары, күмәкләшеп Гөрдүкигә булышып йөрүләре. Дүшәмбе көн иртән, кайсы «Волга», кайсы «Жигули», кайсысы «Запорожец»ка утырып, ду килеп китеп тә баралар.

Кешегә гел килеп кенә тора бит ул. Кияүләре олы урында, киленнәре зур кибеттә, ди. Гөрдүкие мәтәлеп китсен, аның белән ярышып булмас, ә менә Сәмәнтәй булып Сәмәнтәйнең маңкадан бушамый торган кызлары, үсеп буйга җиттеләр дә, кай арада менә дигән ике гөрнастай кебек чибәр кияү ияртеп кайттылар. Хәзер «бабакай да әбекәй», «кияү балакай да кияүкәй» дип кенә торган көннәре.

Җитмәсә, икенче көнне иртән чәй эчеп утырганда улы Тефүр болай да янган йөрәккә тоз салып:

— Сәмәнтәй абыйның рәсемен мактау тактасына куйганнар! — диде.

Хөрмүтнең уң кулы малайның арт чүмеченә чалт иттерде. Хөрмүт үзе дә аптырап калды. Ул сугарга уйламаган иде бит, югыйсә. Ул уйлап өлгергәнче, кул Тефүрнең башына менеп тә төште. Тефүрнең борыны алдындагы чәйгә барып керде.

— Нишлисең син, атасы, чәй шау кайнар бит! — диде Җомрия кыюсыз гына.

— Тәк кенә утырсын! — диде ата, акланган сыман.

Анасы улының борынына салкын суга чылатылган чүпрәк япты.

— Ы-ы, — дип еламсырап мыгырдый башлады үсмер. — Бер сүз әйтергә ярамый... Куйганнар шул... Сәмәнтәй абыйның рәсемен мактау тактасына куйганга мин гаепләме?

Тефүр алдында үзен гаепле сизепме, Хөрмүт бер сүз дә әйтмичә, ишегалдына чыгып китте.

Шул көннән соң Хөрмүт кинәт үзгәрде. Һәр көн саен шат йөз белән кайтып кергән була. Хатыны, балалары белән матурлап күрешә.

— Сәламнар бәхетле балаларыма! Исән тордыңмы, карчыгым! — ди.

Җае чыккан саен ул Сәмәнтәй, Гөрдүки кебек күзгә күренеп баеп баручыларның кыланышына карата ризасызлык сүзләре әйткәли башлады. Ризасызлык сүзләреннән соң, аз-азлап, үзләренең көнкүрешен мактый торган булып китте. Нишләсәләр дә, ул күршеләрнең кылганнарын ошатмыйча, гаеп таба, аларны балалары, хатыны алдында кимсетергә тырыша. Балалар да, хатыны да моңа әллә ни игътибар бирмәде.

Тора-бара тегеләрне түбәнәйтергә тырышу ачыктан-ачык хурлауга күчкәндә, үз ягын күтәрә төшү маңгайга бәреп мактануга әверелде.

— Чүп кеше ул Сәмәнтәй! Авызыннан сүзе чыкмый, ыңгыр-мыңгыр шунда! Ул да кеше санында йөргән була. Ярый инде кияүләре бар. Шулар булмаса, мокыт тек мокыт булып калыр иде...

— Мокыт булса да, машинага гына утырып йөри! — дип кыстырып куйды Тефүр.

Хөрмүт бу дорфалыкны көтмәгән иде, башта каушап калды, аннан:

— Үз машинасы түгел, — дип кычкырды. — Киявенеке!

— Киявенекеме, чуртныкымы — Сәмәнтәй мокыт машинада йөри! — диде үсмер элеккесеннән дә каты тавыш белән.

Хөрмүткә җитә калды. Ул, малаеның сырт якасыннан тотып, өстәл арасыннан алып чыкты да, сугып җибәрде. Тефүр урынында нык басып калды. Еламады, бары тик нәфрәтле күзләре белән атасына текәлде:

— Син шуннан башканы белмисең бит, әти! — диде дә йөгереп чыгып китте.

Ашның тәме, табынның яме качты.

— И, син инде бигрәк! — диде хатыны.

— Шулай кирәк! — диде ир. — Атасына каршы әйтергә иртәрәк әле аңар.

— Ы-ы! — дип мөңгерәде моңарчы дәшми утырган улы Дөндек.

— Ашатам, эчертәм, киендерәм, ә ул энә нәрсә ди?

— Ы-ы! — дип кабатлады Дөндек. — Әти дөрес әйтә.

— Кысылмале син! — дип ысылдады аңа сеңлесе Көфия.

— Әти әйткән — хак! — диде Дөндек.

Хөрмүт хатыны каршысына килеп, янаулы кыяфәт белән, имән бармагын аның борын төбендә селкеде:

— Тагын бер каршы әйтсә балаң, матри, кортка! — диде дә эшкә китте.

Бу вакыйгадан соң байтак вакыт узды. Ямьсез күренеш онытылды кебек. Гаилә тулысы белән янә табынга җыелды.

— Аллага шөкер! — диде ата. — Бөтен җиребез җитеш. Йортыбыз әйбәт. Мал-туар җитәрлек. Яшә дә яшә.

Ул тәмлеп кенә сөтле чәй эчә иде. Бер кем дә бер сүз дә әйтмәде, бары тик Дөндекнең генә атасы сүзен җөпләгәне аңлашылды:

— Ы-ы, сиңа рәхмәт инде, әти! — дип мыгырдады ул.

Тынлык урнашты. Һәркем үз уе белән мәшгуль иде. Бишәүләп чәй шопырган, Дөндекнең ара-тирә чурык-чурык борын тарткалаганы гына ишетелеп калды.

Шул чак Тефүр тамак кырды. Чәй эчүдән хушланганын белгертеп, чокырын тәлинкәсенә каплап куйды да китәргә дип калыкты һәм:

— Сөмеки Сәмәнтәй симертергә ат алган! — диде.

— Чанага сатып алды ул аны, — диде ата.

— Үзе ясаган чанага! — диде Тефүр.

— Урланган имәннән ясалган чанага! — дип кычкырды ата.

— Ю-ук! Урман хуҗалыгына барып эшләп кайтканга алды ул имәнне! — диде үсмер.

— Ах, денсез малай! — дип, атасы улын бөтереп алды, тиз генә сайгакны ачып, Тефүрне базга төртеп төшерде.

Сайгак ябылды. Ата сайгак өстенә менеп басты.

— Күрсәтәм әле мин сиңа симергән атны! — диде ул.

— Ы-ы, — диде Дөндек. — Утыр әнә шунда күселәргә иптәш булып. Эти дөрес әйтә. Сәмәнтәй урман урлап байый. Гөрдүкинең кияүләре, киленнәре бай. Ы-ы, эти дөрес әйтә. Без генә әйбәт, эти дә әйбәт, тегеләр караклар бит алар.

— Ачыгыз! Ач! — дигән тавыш ишетелде баздан.

— Ачасы булмагыз! Акылына килгәнче утырсын, уйлансын! — диде дә, сайгак бөҗраларына йозак салды, ачкычын алып өйдән чыкты Хөрмүт.

— Ы-ы, аннары чыгарсың, — дип җөпләде Дөндек атасының бу кыланышын. — Гөрдүкиләр бит алар кеше хакы белән яши. Алар эск... эскплантатырлар! Сәмәнтәй дә эск... эск-плантатыр. Аларның бакчасында びкаларат корты күп. Ы-ы, алар... Тефү бит алар. Без әйбәт. Безнең бакчада корт юк. Чөнки без әйбәт.

— Кысылмале син! — диде Кәфия, аннан соң абыйсына дәште. — Абый, син курыкма. Мин монда, мин бер кая да китмим. Сиңа иптәш булып, шушында утырам.

— Нишләргә инде? — диде ана.

— Барыгыз, китегез! — диде Тефүр. — Үзе кайткач ачар әле.

Ләкин ата каты бәгырьле булып чыкты, кайткач та ачмады.

— Йә, акылыңа килдеңме? — диде Хөрмүт.

— Килсәм, килмәсәм — шуннан сиңа ни файда? — диде Тефүр. — Син барыбер үзгәрмәячәксең бит! Син — көнче! — Башкаларның тормышыннан көнләшәсең син. Шул ачуны миннән аласың. Алар кебек яшәргә синең кулыңнан килми!

— Дәшмә-ә! Үтерә-әм! — дип кычкырды ата. — Утыр, алайса, шунда. Ачтан үлсәң дә чыгармыйм мин сине. Акылыңа килмичә...

Ана кече якка чыгып елый башлады. Аның янына кызы Кәфия дә чыкты. Ул да елый. Олы якта ачудан тешен шыгырдатып Хөрмүт утыра, аңа Дөндек елышкан.

— Ы-ы, утыр шунда ач килеш! — диде Дөндек.

Ике көн шулай узды. Ләкин Тефүр гафу сорарга уйламады да. Хәтта сеңлесе Кәфия бирергә теләгән азыкны да ярыктан алмады.

Сәгатьләр, көннәр буе караңгыда утыру, ачыгу аркасында Тефүрнең башы әйләнгәләп куя. Ул әкренләп үзгәрә торды. Ул йә кычкырып җырлый, йә кычкырып көлә, йә сәгатьләр буе сораганга җавап бирми тик утыра. Төнлә беркемгә дә йокы бирмичә, нигезне ишә, кыштырдый, идән тактасына бәрәңге ата.

Дүртенче көнне иртән, артык тынычлыкка шомланып, Хөрмүт сайгакны ачты. Аста Тефүрнең зур булып ачылган күзләре елтырый, бите-башы тузантуфракка буялганлыктан, караңгыда күренми. Атаның йөрәге жу итеп куйды.

— Чык, Тефүр! — диде ул. Бала дәшмәде.

— Чык! — дип кабатлады ата. Тефүр чыгарга теләмәде.

— Чык!

Тефүр кинәт телгә килде.

— Миңа берни дә кирәкми! — диде ул.

— Әй, киреләнсәң, тагын утыр! — диде Хөрмүт, шундук сайгакны бикләп куйды.

Ана белән кызы иплән кенә килеп Хөрмүткә әйттеләр.

— Эти, чыгарыйк инде! — диде кызы.

— Атасы минәйтәм... — диде ана.

— Чыкмый бит! — дип кычкырды Хөрмүт.

Атаның күңеленә чыннан да шик төште, ул янә сайгакны ачты:

— Карале, улым Тефүр, — диде ата. — Әллә чыгасыңмы? Монда, өстә сөйләшәбезме?

Тефүр кинәт көләргә тотынды, ләкин аның көлүе сәер иде, әллә ничек, кызыктан түгел, мәгънәсез көлү сыман тоелды аның бу көлүе. Тефүр көлеп туктады да җыр башлады:

Дулкынланып сулар керә
Парахут иданенә;
Иң бәхетле, матур тормыш
Тик безнең илдә генә...

— Чык, улым, чык! — диде ата.

Тефүрне ирексезләп алып чыктылар. Ул шат, ләкин беркемне дә күрми кебек иде. Аның карашы берәүгә дә тукталмый. Тукталган чакта да ул караган кешесен күрми, үзе һаман бер җырны кабатлый:

Дулкынланып сулар керә
Парахут иданенә...

Аннан соң ул аркалы урындыкларын тезеп, мөнбәр ясап, булмаган кешеләрне күргәндәй булып, озак-озак нотык сөйли торган булып китте.

Врачларга күп йөрттеләр аны. Ләкин һичбер файдасы тимәде. Үзе болай зыянсыз. Аңлый да. Ярамаган нәрсәләрне эшләми. Кушсаң, йомышны тыңлый. Кушмасаң — нотык сөйли, җырлый.

Атасы да, анасы да эштән кайтты, энесе Дөндек белән Кәфия дә укудан кайтып керде. Кайтып керүчеләр өй эченә тәртипләп тезелгән урындыкларны күреп, аптырап калдылар. Һәр рәттә — сан, һәр урындыкка номер тагылган. Тефүр артык җитди кыяфәт белән керүчеләрнең булмаган билетларын ертып торган булды да:

— Үз урыннарыгызга утырышыгыз, иптәшләр! — диде.

Аннан соң, булмаган мөнбәр артына басып, лекция укый башлады:

— Иптәшләр, безнең каралты-кура — иң яхшы хуҗалык. Алты почмаклы, биек түшәмле, якты, киң өебез бар. Без бик рәхәт яшибез. Безнең бер кайгыбыз да юк. Мал-туарыбыз да җитәрлек, шөкер. Сыер, кышлау тана, җиде сарык. Мунча, алты баш умарта. Өйдә — телевизор, радио, магнитофон. Уңөченче ел белән чагыштырганда, иптәшләр, Хөрмүт Җамансыев өендә кеше ышанмаслык үзгәрешләр булды. Уңөченче елда Җамансыев Хөрмүтнең атасы Әфкәл Җамансыев өендә телевизор булмаган, радиосы да юк иде. Электр да кертелмәгән иде. Хәтта аларның патефоны да булмаган, иптәшләр. Ә бүген...

Бик озак кемнәрнедер хурлап, тагын үзләренең хуҗалыгын мактап, Тефүр нотыгын җыр белән тәмам итте:

Дулкынланып сулар керә
Парахут иданенә;
Иң бәхетле, матур тормыш
Тик безнең өйдә генә...

Дөндек рәхәтләнеп көлә-көлә арып бетте. Ана сыгылып елый. Кәфия, абыйсына карарга кыенсынып, моңаеп утыра. Ата нишләргә белмичә:

— Иә, булды! Кая, ашарга нәрсә бар? — дип урындыкларны үз урыннарына урнаштырырга алынды.

Шул чак Тефүр этисе янына якын ук килеп болай диде:

— Эти, синеңчә сөйлим бит, син теләгәнчә сөйлим, нигә шатланмыйсың? Син максатыңа ирештең. Мин гел мактап-мактанып кына яшим. Син миннән икенче Дөндек ясамакчы идең. Мә, ал, менә мин ул Дөндек!

Шул чак Кәфия, шашардай дәрәҗәдә сөенеп, абыйсын кочаклап, җилтерәтергә тотынды:

— Олабыйкаем! Син юримени? Ха-ха-ха, ул юри генә шулай!..

Энисе Җомрия, эшне аңлап, башта аптырады, аннан шатланып елый башлады да:

— Ах, чукынмыш бала, анаңа-атаңа шулкадәр кайгы ташлап, шаярасыңмы әле! — дип, мич авызында торган олтанлы итек белән улын кыйный башлады. — Дуңгыз баласы, синең арканда чәчем агарды!..

— Тимә, анар! — диде ата, улы белән хатыны арасына кергәч. — Тимә!..

## ТАТАРСТАНДА БАШКОРТСТАН АССР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ СӘНГАТЕ КӨННӘРЕ

27 майда Казан хезмәт ияләре Башкортстан АССР әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә катнашучыларны каршылады.

Башкортстан АССРның рәсми делегациясе составында КПССның Башкортстан өлкә комитеты беренче секретаре Р. Х. Хәбибуллин, БАССР Министрлар Советы Председателе М. П. Миргазямов, КПССның Башкортстан өлкә комитеты секретаре Ә. М. Дилмөхәммәтов, КПССның Башкортстан өлкә комитеты идеология бүлеге мөдире М. Т. Хәкимов, БАССР культура министры С. Х. Әминев, КПССның Уфа шәһәр комитеты беренче секретаре Р. Р. Гәрәев, профсоюзларның Башкортстан өлкә советы секретаре Ә. М. Сәмирханов, күп кенә район комитетлары секретарьлары, халык депутатларының район һәм шәһәр Советлары башкарма комитетлары председательләре, Башкортстанның производство алдынгылары бар иде. Әдәбият һәм сәнгать көннәрендә катнашу өчен Башкортстанның халык шагыйре, Социалистик Хезмәт Герое, Ленин премиясе лауреаты Мостай Кәрим, СССРның халык артисты композитор Заһир Исмәгыйлев, СССРның халык художнигы Борис Домашников, РСФСРның халык художнигы, СССР Художество академиясе член-корреспонденты Әхмәт Лотфуллин, иҗат союзлары җитәкчеләре, күпләгән әдәбият-сәнгать эшлеклеләре, БАССР халык биюе ансамбле, БАССР дәүләт симфоник оркестры, БАССР дәүләт хор капелласы, фольклор группасы коллективлары, партия һәм совет хезмәткәрләре, җәмәгатьчелек вәкилләре килде.

Кунакларны КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Г. И. Усманов, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ш. Ә. Мостаев, ТАССР Министрлар Советы Председателе М. Ш. Шәймиев, КПСС өлкә комитеты секретарьлары Р. Р. Идиатуллин, Г. Ф. Самойлов, ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре М. А. Гаделшин, иҗат союзлары җитәкчеләре, хезмәт коллективлары вәкилләре каршылады.

Тугандаш Башкортстаннан килгән кунакларны каршы алуга багышланган митинг булды. Аны партиянең Казан шәһәр комитеты беренче секретаре Г. И. Зерцалов ачты.

Митингта ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, БАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары В. Х. Байтурина чыгыш ясадылар.

28 майда Башкортстан кунаклары Казанның Ирек мәйданындагы В. И. Ленин һәйкәленә чәчәкләр салдылар, шәһәрнең истәлекле урыннары белән таныштылар.

Казанның Матбугат йортында Татарстанда Башкортстан АССР әдәбияты һәм сәнгате көннәрен уздыруга багышланган матбугат конференциясе булды. Конференцияне КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. Р. Идиатуллин ачты. КПССның Башкортстан өлкә комитеты секретаре Ә. М. Дилмөхәммәтов бәйрәм программасы, анда катнашучы коллективлар турында сөйләде, хуҗаларга былтыр Башкортстан АССРда узган Татарстан әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә төшерелгән документаль фильм тасмасын бүләк итте, күп төрле сорауларга җавап бирде.

Татарстан Язучылар союзында узган очрашу вакытында татар һәм башкорт язучылары ике әдәбиятка караган мәсьәләләр, алда торган бурычлар турында зур сөйләшү алып бардылар. Аны ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Ринат Мөхәммәдиев ачты. БАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Динис Бүләков башкорт язучыларының иҗат планнары турында сөйләде.

Башкортстан язучылары Шәриф Биккол, Муса Гали, Ногман Мусин, Әнгам Атнабаев, Факиһә Тугызбаева, «Агыйдел» журналының баш редакторы Булат Рафиков, «Башкортстан кызы» журналының баш редакторы Гөлфия Юнысова; Татарстан әдипләре Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Мәдинә Маликова, Баян Гыйззәт һ. б. тугандаш ике халык әдәбиятларын тагын да үстерү мәсьәләләрен күтәрделәр.

Сөйләшүдә КПССның Татарстан өлкә комитеты идеология бүлеге мөдире О. В. Морозов, КПССның Башкортстан өлкә комитеты идеология бүлеге мөдире М. Т. Хәкимов катнашты.

ТАССР Композиторлар союзында Татарстан һәм Башкортстан композиторлары очраштылар. Очрашуны республикабыз композиторлары союзының җитәкчесе М. Ярullин алып барды.

Кунаклардан җавап сүзе белән БАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе Р. Газизов чыкты.

ТАССР Художниклар союзының Күргәзмәләр залында Башкортстан АССР рәссамнарының 500 дән артык эшен туплаган күргәзмә булды.

Бәйрәм көннәрендә Казан Актерлар йорты Башкортстан Театр эшлеклеләре союзы вәкилләрен кабул итте.

«Татарстан» кинотеатрында Башкортстан АССР турында фильмнар фестивале булды.

Очрашуның рәсми бүлегеннән соң тамашачыларга «Башкорт мотивлары» дигән

документаль һәм «Салават Юлаев» дигән нәфис фильм күрсәтелде.

Бу көннәрдә Театр урамында башкортның киез тирмәләре тезелде. Башкортстанның дистәләгән район вәкилләре Казандагы кардәшләрен үз халыкларының тарихы, гореф-гадәте, йолалары белән таныштырдылар.

Халык иҗаты аллеясын ачуда КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Г. И. Усманов, КПССның Башкортстан өлкә комитеты беренче секретаре Р. Х. Хәбибуллин, ТАССР Министрлар Советы Председателе М. Ш. Шәймиев, БАССР Министрлар Советы Председателе М. П. Миргазямов һәм башкалар катнашты.

28 майда кичен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында әдәбият һәм сәнгать көннәрен ачуга багышланган тантаналы кичә булды.

Тантаналы кичәне ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ш. Ә. Мостаев ачты.

КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Г. И. Усманов партиянең Татарстан өлкә комитеты бюросы, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советы исеменнән, республиканың барлык хезмәт ияләре исеменнән кадерле кунакларны сәламләде.

Җавап сүзе белән КПССның Башкортстан өлкә комитеты беренче секретаре Р. Х. Хәбибуллин чыкты.

Татарстанда Башкортстан АССР әдәбияты һәм сәнгате көннәре истәлеге итеп, Р. Х. Хәбибуллин Татарстан вәкилләренә истәлекле бүләк тапшырды.

Тантаналы кичәдә Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Р. С. Мөхәммәдиев, Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим, Казан «Теплоконтроль» производство берләшмәсе бригадиры В. П. Дмитриев, Башкортстанның атказанган артисткасы Таңчулпан Бабичева, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты студенткасы Р. Мөхәммәтҗанова чыгыш ясадылар.

Тантаналы кичәнең икенче өлешендә Башкортстан АССР сәнгать осталарының зур концерты булды.

Бу көннәрдә дуслык бәйрәмнәре Татарстанның күпләгән шәһәр һәм районнарында да узды. Кунаклар, биш төркемгә бүленеп, Балтач, Арча, Зәй, Түбән Кама, Мамадыш, Алабуга, Менделеев, Сарман, Минзәлә, Лениногорск, Бөгелмә районнарында булдылар. Ике республиканың күрше район хезмәт ияләрен дә кызыклы һәм шатлыклы очрашулар көтте. Чаллыда яшәүчеләр Башкортстанның Нефтекамск шәһәреннән, азнакайлылар — Туймазы, актанышлылар — Илеш, баулылар — Ярмәки, мөслимлеләр — Бакалы районнарыннан, әлмәтлеләр — Октябрьск шәһәреннән килгән кунакларны кабул иттеләр. Башкортстанның танылган артистлары, сәнгать коллективлары Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы, Чистай тамашачыларын үз осталыклары белән таныштырды.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры каршындагы мәйданда шигырь бәйрәме булды.

Аны кереш сүз белән шагыйрь Роберт Миңнуллин ачты.

Башкортстан АССР Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Кадим Аралбаев ике республика шагыйрьләре арасындагы иҗади дуслык турында сөйләде.

Шагыйрьләр бәйгесен Мостай Кәрим башлап җибәрде. Аны, бер-берсен аралаштырып, татар һәм башкорт шагыйрьләре Р. Фәйзуллин, К. Кинҗәбулатова, Л. Шакирҗанова, М. Гали алыштыра. Тамашачылар Ф. Тугызбаева, Рәшит Әхмәтҗанов, Р. Зәйдуллин, Ә. Таһирова, Ә. Әхмәтхуҗин, Р. Гатауллин, Ш. Биккол, Р. Мифтахов, Ә. Баянов, Б. Ногманов һәм башкаларның шигырьләрен, БАССРның халык артисткасы Җ. Килдиярованың матур итеп җырлавын, курайчылар С. Динмөхәммәтов белән Ю. Гайнетдинов башкарган моңлы көйләрен сокланып тыңладылар.

2 июньдә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында әлеге бәйрәмне ябуга багышланган тантаналы кичә булды.

Тантаналы кичәне кереш сүз белән ТАССР Министрлар Советы Председателе М. Ш. Шәймиев ачты.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ш. Ә. Мостаев саубуллашу сүзе әйтте.

Үткән көннәр истәлеге итеп, Ш. Ә. Мостаев башкорт дусларга сувенир — картина-чеканка тапшырды.

Башкортстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ф. В. Солтанов җавап сүзе белән чыкты.

Кичәдә шулай ук КПССның Вахитов район (Казан) комитетының беренче секретаре Б. Д. Леушин, БАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Д. М. Буләков, СССРның халык артисты М. Х. Сәлимҗанов, Башкортстаннан партиянең Аургазы район комитеты беренче секретаре М. М. Ишморатов чыгыш ясадылар.

Тантаналы кичәнең икенче өлешендә Башкортстан һәм Татарстан сәнгать осталарының зур программалы, төрле жанрларга бай концерты булды.

Тантаналы кичәдә ике яктан да партия һәм совет органнарының күп кенә җаваплы хезмәткәрләре катнашты.

Татар һәм башкорт халыкларының милли культураларын үстерүгә һәм үзара баетуга зур өлеш керткәннәре өчен, ТАССР Верховный Советы Президиумы Указы белән, Башкортстан АССР иҗат союзлары һәм коллективлары — язучылар, композиторлар, художниклар, театр эшлеклеләре союзлары, дәүләт филармониясе, хор капелласы, халык бию ансамбле Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

3 июньдә Башкортстан әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә катнашучылар ике самолет белән өйләренә кайтып киттеләр. Аэропортта җылы, эчкерсез озату митингысы булды.

# УКАЛЫ КҮКРӘКЧӘ

Татарстан сынлы сәнгать музее хәзинәсенә татар халкының декоратив-гамәли сәнгате әйберләре һаман өстәлеп тора. Бу эштә безгә татарлар гомер-гомергә яшәп килгән төбәкләргә халыкның мәдәни мирасын өйрәнүче экспедицияләр оештыру зур ярдәм итә. Шундый экспедицияләрнең берсен 1987 елның җәендә музейның өлкән фәнни хезмәткәре Р. Шаһиева Ульяновск өлкәсенең көньяк районнарында оештырган иде. Алар тырышлыгы аркасында музей коллекциясенә тагын укалы ике күкрәкчә өстәлде. Тышлыкның беренче битендә урнаштырылган рәсемдәге әлеге сәнгать әйберләре Иске Кулаткы районында табылды.

Күкрәкчә — хатын-кызлар милли киеменең иң борынгы өлешләреннән берсе. Ул 40х25 сантиметрлы туры почмаклы тукыма кисәгеннән гыйбарәт. Күкрәкчәнең өске ягы нечкә тасма белән муенга бәйләнә, ә аскы ягы күкрәк астыннан беркетелә. Шулай итеп, ул хатын-кыз кием-салымының зарур бер өлеше ролен башкара. Күкрәкчә күлмәк астыннан киелә, чигүле өлеше күлмәкнең өске кисеменнән күренеп тора. Ә күлмәк өстеннән изү киелә (уртадагы рәсем).

Күкрәкчә аппликация яисә тамбурлы чигү белән бизәлә, хатын-кыз киемен бизәүдәге җирле традицияләргә карап, еш кына алтын белән укалап чигелә. Горький өлкәсе мишәрләреннән үзгә буларак, көньяк мишәрләрендә укалап чигү күбрәк очрый. Бу Урта Азиядәге укалап чигү сәнгатенең гүзәл традицияләре белән борын-борыннан килгән элемтәләргә бәйледер.

Күкрәкчәләрдәге милли бизәкләрнең баштагы мәгънәсе хатын-кызларны бәла-казадан, авырулардан, яман күздән саклауга бәйле булган. Әлеге билгеләрнең иң әүвәлгеләре борынгы төрки бабаларыбызның күк җисемнәренә табынуын чагылдыра, болгар-татар милли бизәкләрнең далада көн иткән төрки телле халыклар сәнгатенә барып тоташуын күрсәтә.

Бу бизәкләр җыйналмасының күп элементлары татар халкы читтәрәк, аерылып яшәгән (Иске Кулаткы районы кебек) төбәкләрдә борынгы килеш диярлек сакланган. Анда табылган күкрәкчәләрдә без кояш билгеләреннән ясалган архаик һәм самими мотивларның сурәтләмәсен күрәбез. Һәр күкрәкчәнең уртасында — алты нурлы «өермә» сыман нәни тәлинкә, ул кояшны яки кояш яктысы дигәнне аңлата.

Бер күкрәкчәдә исә кара тукымага чигелгән алтын бизәкләрнең космик символика белән турыдан-туры аваздашлыгы сизелә (сулдагы рәсем).

Укалы чигү алсу ефәк тукыма кисәгендә башкарылган икенче күкрәкчәнең бизәкләре тагын да катлаулырак. Композициянең уртасында — алты канатлы нәни тәлинкә. Нурларның очлары, икегә аерылып, яфраксыман бизәкләр тәшкил итә. Үзәктәге бизәкнең читләрендә билгеле бер нисбәттә үсемлек сурәтләре урнашкан. Алар кояш символикасына турыдан-туры бәйләнешле булган гөлҗимеш ботакларын, яфракларын хәтерләтә.

Бу күкрәкчәләрне өйрәнү — мишәрләр киемендә җирле милли үзенчәлекләр күп гасырлар буена үзгәрешсез сакланган дип нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

**В. ЦОЙ,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның бүлек мөдире.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казан Кремленең тышкы диварлары күренеше. XIX гасыр инглиз рәссамы Э. Турнерелли эшеннән репродукция.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотолары.

## *«Казан утл*


**Аяз Гыйләжі**

— «Балта ке сәрләремнән үзгә
буларак, шакты ы. Шәһәр дә бар
монда, җан бир онның мактаны-
чы, даны — күр а Нәҗип белән
Наилә...
Мине соңгы е әр хәбәрдарлык,
үзгәреш заманы елларда, илебез
һавасы чак кын булса? Без ни-
чек яшәр идек ын, ул китергән
җәбер-җәфаларн исәплап, каһәр-
ләнгән заманнь тканын чутлап
чыгардык. Торгь режнев, Суслов,
Черненколар арі терешләрне әле
санарга керешмә корбаннарының
саны да сталинчі һич тә ким тү-
гел. Әфганстанн знең корбан бу-
луын санап та чь клы сугышның
рухи зыяны әле ргынлык елла-
рында өскә яңа сыйныф — бюрократлар сыйныфы калкып чыкты. Ул бөтен тармакларда властьны үз кулына алды. Алар, үз иярченнәре белән халыкны талап, ил байлыгын имеп коммунизмда яшәделәр. Торгынлык чорының яшәү шартлары бөтен кешегә дә кагылды: берәүләр «коммунизмга» чыкты. Ә икенчеләр, аларга ярарга тырышып, тәлинкә тотты, ялагайланды, алдашты, буш вәгъдәләр сипте, вакланды, кыскасы, атабыз Адәмнән башлап җирдә никадәрле пычрак бар, торгынлык елларында шуларның барысы да чәчәк атты. Әйтик, эчкечелек торгынлык заманында халыкның бюрократия сыйныфына каршы протесты иде ул. Караклык, ялган шаһитлык, эшлексезләрнең иң югары постларга менеп утыруы, эшләмичә генә муллыкта яшәү мөмкинлеге — боларга халык бүтәнчә протест ясый алмады... Талантлар һәлак булды, халыклар халык булудан туктады, тел, милли хисләр онытылды. Мөнәсәбәтләрне бары тик галиҗәнап аракы гына билгели башлады, ришвәт хөкемдар булды...

Әсәр әнә шул куркыныч заманга багышланган. Исеме шактый шомлы яңгыраса да, анда халкыма булган тиңсез мәхәббәтем, йөрәк сагышларым, үкенечләрем, күңел серләрем һәммәсе дә бар.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)